

ЛӘБИБ ЛЕРОН

# Чыктым аркылы күпер



**Юмористик хикәяләр, пьесалар, парчалар, мәзәкләр**

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89(470)
ББК 84(2 Рос=Тат)-4
Л 47

**Лерон Лэбиб**

Л 47 Чыктым аркылы күпер: Юмористик хикәяләр, пьесалар, парчалар, мәзәкләр. — Татар. кит. нәшр., 2004. — 351 б.

Язучының яңа китабында юмористик хикәяләре, пьесалары һәм мәзәкләре урын алган.

ISBN 5-298-04069-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2004

## I бүлек

# Ике кыйсса, ике пьеса



# Шайтан шаяруы

*(Бүгенге кайбер әсәрләргә хыялый пародия)*

Ул, ана карынындагы сабый шикелле бөгәрләнеп, ике кулын да бот арасына кыстырган килеш, палас җәелгән салкын идәндә мендәрсез-нисез йоклап ята иде. Трусиғының Татарстан картасына охшаш ямаулыгында тәрәзә пәрдәсе ярыгыннан кысылып кергән ай яктысы бии.

Көзге төннең суыгы аның җелекләренә хәтле үтте, ахры, кинәт ул бизгәк тоткан кеше кебек, калтыранып, дер-дер килеп уянды. Уянды, әмма, йокысын качырудан куркып, күзләрен ачмаска тырышты. Җылыга сусаган гәүдәсен тагын да җыя төште. Яткан уңайга, әле генә бозлы судан чыккандай, куырылып куйды. Авызындагы «хөкүмәт» тешләре, бер-берсенә шыкы-шыкы тигәләп, күсе алан-ялан каранып кына урындык аягын кимергән мәлдәге шикелле тавыш чыгарып алды. Аның бу мизгелдәге хәрәкәтчән очлы ияге урлашып кына кәбестә сыптырган кәҗәнекенә тач охшаган иде.

Ул уң кулын җылы ботлары арасыннан иренеп кенә чыгарды да, шәрә гәүдәсен капларга теләп, юрганын кармаларга кереште. Гөнаһ шомлыгына каршы, юрган ни ян-ягында, ни аяк шәрифләре очында юк иде. Теләсә дә, теләмәсә дә, бер-берсенә эренләп ябышкан авыр керфекләрен урыннарыннан кузгатырга туры килде.

Күзләргә иң әүвәл ялкау гына сүрән яктылык иңде. Аннары бүлмә эче шәйләнде. Өстәл аяклары, урындык тәпиләре, йөнтәс башмаклар...

Шунда гына ул идәндә ятканын, аңарчы караваттан егылып төшкән булуын, әмма мәтәлгән чагында үзенең берни дә тоймаганын аңлады.

«Кичә хәтер киселгәнче эчелгән» — уянгач беренче уе шул булды аның. Йокысы тәмам качты. Комсызланып, шешәле, сап-салкын су... юк ла инде... сыра эчәсе килде. Ул кипшенгән иреннәрен теле белән юешләде, күтәреп булмаслык дәрәҗәдә авырайган башын кухня тарафына борды. Шул вакытта кухнядагы суыткычның җиңелчә гөрелдәгәне ишетелде. Их, суыткычта хет бер сы-

ңар гына шешә сыра булса-а... Тын да алмыйча, шешәнең үзеннән генә эчәр иде ул. Юк, алай итмәс иде...

Иң элек парланган шешәне иркәләп-назлап кына кулына алыр, аңа бер тын сөеп карар, аннары ашыкмый гына касәгә сыра агызыр, күбекнең өскә менгәнен, касәдән ташып ишелгәнен ләззәтләнеп күзәтер. Шуннан соң кулы тигез ритм белән дерелдәткән касәне алгысынган иреннәренә якын китерер. Сыраның ымсындыргыч исеннән борын тишекләре соң чиккәчә киңәйгәч һәм баш миенең һәрбер күзәнәге татлы рәхәтлек кичерә башлагач, алтын суны сөзеп кенә эчәргә керешер. Касәдәге сыра тамак упкыны аша түбән шугач, ул өске ирененә кунган ак күбекне кул аркасы белән сыпырып алыр, яшәү нуры кабат иңгән күзләрен шешәдә калган сыра өстендә биетер дә канәгать елмаеп «Шә-ә-эп!» дияр...

Әйе, гадәттәгечә, нәкъ менә шулай «Шә-ә-эп» диярде... Ләкин ул хәзер әлеге сүзне бик теләсә дә әйтә алмый. Чөнки белә: суыткычта сыра юк. Кичә кибеттән, анда булмаса, алыпсатарлардан алган булса да, барыбер эчеп бетергән булыр иде. Гадәте шундый аның: авызына бер тамчы аракы ялгыш кына тамсын — туктый алмый, ахыргача бара. Түнгәнче. Акчасы исәпсез чагында затлы коньяк-мазардан башлар, эчегән букый-сукый алма шәрабы, йә булмаса, ат сидеге төсле үтә болганчык сыра белән төгәлләр. «Тән спиртка мохтаҗ. Берни эшләп булмый. Табигать мине шулай бар иткән» дияргә ярата ул үзенең дус-ишләренә. Күп очракта кесә төбендә уралып йөргән ипи валчыгын яисә ни туры килсә шуны капкалап-иснәп, эчемлекләрне тез буыннары тотмас дәрәҗәгә җиткәнче җилпегәч:

— Тәэмин итеп торыр өчен минем үземә генә бер аракы заводы кирәк! — дип мактанып, шапырынып ала...

Ул коры иреннәрен теле белән янә юешләп алды. Тирән итеп көрсенде. «Гомереңнең соңгы мизгелләре җитсен, авызыңа бер тамчы да сыра да салучы булмаячак бу өйдә!» — дип, авыр сулап уйлады ул һәм кулларын кабат җылы бот арасына шудырды.

Шудырды... һәм анда шундук икенче теләк уянды. Уянды дип, ул күптән уянган иде инде...

Аның гел шулай, махмыр булды исә, ике нәрсә эшлисе килә: баш төзәтәсе һәм хатын-кыз белән йоклыйсы...

Юк, монда, әлбәттә, хатын-кыз заты белән болай гына, аркага арка терәп яисә кочаклагандай итенеп кенә яту турында сүз бармый. Чын мәгънәсендә хатын-кыз белән «йоклыйсы» килә аның. Дәрт-дәрманы шиңгәнче...

Хатын-кыз дигәндә, әллә нинди чит-ятларны түгел, үз хатынын күз алдында тота инде ул...

«Йоклыйсы килә дә килүен, ләкин берни майтарып булмый — ул махмырдан интеккән көнне, аның хатыны салам өстендәге эт белән бер... Синең сыйпау-иркәләвеңә дә, газаплана-газаплана тәмле телләнүеңә дә игътибар итми — терсәге белән саллы гына төртеп җибәрә... Кайвакытларда идәнгә очып төшкәнеңне сизми дә каласың...

Белә ул, аңлый да — аның эчеп кайтуыннан хатынының шулай үч алуы бу.

Хатын дигәннән, әллә тагын сынап карарга мы? Бәлки, бу юлысы төртеп төшермәс...

Менә ул торып утырды. Ваемсыз гына тез астын кашырга тотынды. Шуннан соң гына караватка күз төшерде.

Һәм... сискәнеп китте. Караватта, алагаем гәүдәсен җәеп ташлап, чәчләренә дистәләгән бигуди чорнаган ят хатын ята иде.

Бу бит... Бу бит...

Ул секунд эчендә бүлмәне күзләп, карашы белән капшап чыкты.

Бу бит... аның фатиры түгел...

Шайтан алгыры!

Каяндыр гайре көч алып сикереп торганын сизми дә калды ул.

Яп-яланаяк!..

Чит фатирда... ниндидер хатын янында... Аракы мичкәсенең төбенә төшкәнче эчте, әмма мондый хәл... ят хатын өендә кунып калганы моңарчы булмады... Әгәр бу хакта хатыны белсә... Ярабби!.. Күрмәгәнеңне күрсәтәчәк... Күрсәтеп кенә калса... Берсүзсез үтерәчәк...

Уф, сәгать ничә микән? Төнге берләр-икеләр тирәсе бардыр, мөгаен. Махмырдан шул вакытта уяна торган иде ул. Хәер, вакыт кайгысымыни монда. Тизрәк өйгә ычкынырга кирәк. Бу ят хатын уянганчы. Кайтышлый хатыны алдында аклану өчен берәр сәбәп уйлап табар әле. Бәлки, үтермәс. Кәефе әйбәт булса, үтерми инде ул. Балалардан хат-хәбәр килгән булса гына ярар иде. Ул чакта аның хатыны майлаган тәгәрмәч кебек йөри, бөтерелә. Үзе быдыр-быдыр нидер сөйләнә, йөзеннән тиле елмаю китмәс...

Ул чалбарын, балагыннан эләктереп, үзенә тарткан иде, урындык шапылдап идәнгә ауды. Дөмберт!

Шул гына җитмәгән иде.

Ул урындыкны шыпырт кына торгызып азапланганда, караватта яткан хатынның йокы аралаш әйткәне ишетелде:

— Ни җимерәсең тагын?

Ул дәшмичә калуны кулай күрде. Бәлки, уянмас, дип уйлады.

Һе, уянмас, бар... Шундый чакта уянмаса, хатын-кыз буламыни ул! Андый вакытта алар синең чебен булып очканыңны да, мәче булып йөргәнеңне дә ишетә.

— Күзең чыкмагандыр бит!

Бу инде бернинди кысага да сыймый иде. Үз хатының шулай дисә бер хәл. Гаҗәпләнмәс тә идең. Ул шулай кычкырып, колак төбендә өзлексез өреп торыр өчен генә туган кебек. Ә бу... Бу бит... нindидер чит хатын. Сөяркә шикелле нәмәрсә дә түгел, җитмәсә. Моның кем икәнен дә белми бит әле ул. Беренче күрүе дигәндәй... Кичә... салган баштан ияреп кайтылган инде... Шул... Әллә... берни дә майтарып булмады микән? Җүләр, ничек булсын инде. Шул кадәрле эч тә... Кече йомышыңны йомышлый алсаң ярый әле...

Ул чалбарының икенче балагын кия алмый интекте. Каушауданмы, әллә ят хатынның көтелмәгән сүзләреннән шүрләүдәнме, аның маңгаена тир тамчылары бәреп чыкты.

Хатын юрган астыннан кулын чыгарды да үрелеп кенә браны кабызды.

— Син! — диде ул, аның тарафына борылгач.— Син! Төн уртасында кая җыендың?

Чурт! Тәки уянды бит, нәгаләт...

— Сиңа әйтәм! Телеңне йоттың мәллә?

Ул чит хатын алдында тәмам каушады. Чалбарының соңгы сәдәбен каптыралмый чиләнде.

— Минме... мин...— Ашаячак бит бу хатын аны хәзер, ашаячак. Бер генә кабып йотачак. Эх... Каһәр суккан бармаклары да тыңламый бит аның...

— Син булмый кем булсын, мәхлук.

— Мин... мин — өйгә ие! — Ниһаять, ул җәфа сәдәпне каптырды.— Хатын үтерә... Кайтырга кирәк...

Ул, хатынның төксе күзләренә, мәңге кояш күрмәгән ак юан беләкләренә карамаска тырышып, карашы белән кичә каядыр салып ташлаган майкасын, күлмәген эзләде.

Шул вакыт көтелмәгән мәхшәр купты. Болай буласын белсәме ул! Хәер, белеп нишләгән, ни кырган булыр иде...

Аның «Кайтырга кирәк...» дигән сүзләренең мәгънәсен бик авырдан төшенгән хатын, кинәт чәчрәп, урыныннан торды, чырыйлап кычкырып җибәрде:

— Син! Кая кайтам дисең?

Никләр генә эчте икән ул кичә.

— Минме... мин... үземә... туест... өйгә...

Никләр генә ияреп кайтты икән ул бу явыз хатынга.

— Синең әле тагын бер өең... себеркең... бармыни, тәребаш?!

Хатынның зәһәрләнгән зәңгәр күзләренә карарга куркыныч иде.

Ул, кымшанмыйча, ниндидер шуклык кылган өчен почмакка «кадаклап» куелган сабый сыман, аңгы-миңге булып, бер урында басып тора. Эченнән генә үзен сүгә: никләр эчтем, никләр ияреп кайттым? Су эчәсе килү теләге (кая ул сыра) тәмам сүнде. Аның каравы үтереп тартасы килде. Йотлыгып хет бер генә суырасы иде...

— Сөйрәлчек тәре! Яшь кәнтәй таптыңмыни?

Хатын очынып аның янына килеп басты. «Сөйрәлчек тәре» урынында килеш гәүдәсен артка авыштырды. Бульдозер кебек килгән хатынның эчке күлмәгеннән бүселгән күкрәкчәсез күкрәкләре аның очлы иягенә төртелде. Ул, аякларын көчкә атлатып, бер адым артка чикте дә:

— Гаф... гаф-фу... Ис-семегезне әйт-тмәссез мик-кән! — дип, авыз эчендә абынган телен хәрәкәткә китерә алды.

Аның тотлыгып, үзен кулга алыбрак әйткән бу тыныч сүзләре хатынның колагына кереп юл алса да, баш миенә үк барып җитмәде бугай. Шул сәбәплеме, хатын, үзе ни әйткәнне белештермичә генә:

— Гөлсара мин... Садыйковна,— диде. Диде дә кинәт чәрелдәп җибәрде: — Нәрсә? Нәрсә дидең, карт кәҗә?

«Карт кәҗә»нең (хатын бая үзгәрәк, тагын да зәһәррәк сүз әйткән иде, әлбәттә) бер чатлы очлы ияге янә ике кибән арасына кадалды.

«Минем хатыннан да уздыра бу!» — Ул кинәт касык тирәсе авыртудан ыңгырашып куйды.

— Син! Син мине аерып та өлгердеңмени, хөрәсән? «Сез»гә күчтеңмени?..

«Хөрәсән», ул ук «карт кәҗә», артка чигенә-чигенә хатыннан котылу әмәлен эзләде. Ул арада аны бүселгән күкрәкләр стенага китереп кысты.

— Тук... тук...тагыз әле...— дип, көч-хәл белән гырылдады ул.— Сөйл... ләшик... ип... иптәш... Гөл... Гөлсара... Са... Са...

Хатын, мәче тарафыннан почмакка кысрыкланган тычкан хәлендәге ирнең бүтән чигенер чамасы калмаганын аңлап булса кирәк, очлы иякне чумдырган күкрәкләрен бушандыра төште. Ул иркен сулыш алды.

— Мин... аңлап бетермим... сезне...

— Тагын «сез»ме?

Әле күптән түгел генә сыра исен иснәп ләззәтләнергә

теләгән борын тишекләренә ниндидер ислемаймы, хушбуймы белән буталган тир исе янә ургылып керде.

— Паж-жалысты...— дип, үтенү катыш ялварды ул, су астында кислороды беткән водолаз шикелле сулыш алырга омтылып.— Алыгызчы... Алчы ими... күкрәк...

Хатынның гайрәтләнүе сүрелә төште, ахры, ул артка чигенеп куйды.

— Йә, сөйлә, кая җыендың, мөртәт?

«Мөртәт», ул ук «хөрәсән», ул ук «карт кәҗә» бу мизгелдә мескен бер халәттә иде. Сугып аю үтерерлек ир-ат башың белән, ниндидер карт хатын астында чак кына үлмичә кал инде... Чебиләргә сөйләсәң, чебиләр тәгәрәп көләрлек бит... Адәм ыстырамы!..

— Мин... мин әйттем бит инде... өйгә кайтам, дип...

— Син нәрсә, миннән көләргә уйладың мәллә?

Хатын, аның иягеннән юантык бармаклары белән каптырып, өскә күтәрде, күзләренә төбәлде.

— Юу-ук, уемда да юк...

Ирнең күзләрендә, йөзендә бернинди дә шаяру галәмәте юк иде.

«Әллә, Ходаем, ычкынды микән бу?» — Аның башына кинәт шундый уй бәрде.

— Син! Син... алышынмагансыңдыр бит?! Үз хатыныңны танымыйсың...

Ир гаҗәпләнүдән «дерт» итте.

— Сез... син... минем хатынмы?

«Ычкынган, валлаһи газыйм, ычкынган бу! Егерме ел бергә яшәгән хатынын танымый бит... И Ходайкаем, күрәселәрем бар икән!..»

Хатын беравык ни әйтергә белмичә торды. Бераздан икеле-микеле генә:

— Алайса... мин кем булам инде? — диде.

— Соң, әйттегез... әйттең бит... Гөлсара, дидең... Садыйковна...

Хатын, артка чигенеп, караватка «лып» итеп утырды. «Күрәселәрем шушы икән...»

— Ә-ә-ә... үзеңнең кем икәнеңне беләсеңме соң? Кем син? Исемең ничек? — диде ул, нәрсәгәдер өметләнеп һәм шул ук вакытта нәрсәнедер ачыкларга теләгәндәй.

— Минме? Садрый мин... Садрый Мәҗитов,— диде ир.

Йа Хода! Үз исемен дә хәтерләми!

— Син бит Садрый түгел... Мәхмүт син! — диде хатын.— Исеңә төшер...

«Берни дә аңламыйм. Бу хатын әллә тегендирәк микән?» — дип уйлады Садрый-Мәхмүт.

Бик мөмкин. Шизик-мизик хатыннар белән дөнья тулган бит. Ир-ат назына мантый алмаган кыз-хатыннар, яши-яши, шулай җүләр сымакка әйләнә икән, диләр түгелме соң?! Менә бу да, үзен Гөлсара Садыйковна дигән хатын да, бәлки, шундыйларның берседер? Кичә ул аның дөпел исерек икәнен күргәндер дә мәгълүм максат белән үз фатирына ияртеп кайткандыр. Дөм исерек кеше кая атлаганын беләмени ул. Өйгә кайткач, аңа тагын эчерткәндер... Кем белә, нәкъ шулай булгандыр. Әле аракыга берәр нәмәрсә кушып эчертүе дә ихтимал. Хатын-кыз дигәнең үзенә кирәкне алыр өчен, үз теләгенә ирешер өчен әллә ниләр кылырга маһир зат бит ул. Аны үз ире дип кылануы, тора-торганнан аңа ярсып кычкыруы тиктомалдан түгелдер. Тәгаен ир-ат халкына сусаганга охшый бу...

— Юк, Садрый мин...

«Моңарчы болай үз киресен сукалаган чагы юк иде. Моның белән чынлап та бер-бер хәл булган». Хатын моннан гайре бүтән ни уйларга да белмәде.

Нишләргә? Артык сүз куертыргамы, юкмы? Садрый, ди бит һаман... Җүләрнекен белмәссең... Әгәр дә ул, җене котырып, эт шикелле өскә сикерсә... Эт дигәннән, бәлки, аны кичә урамда берәр котырган эт тешләгәндер?!

Хатын үз уеннан үзе куркып куйды.

— Син... Сиңа тынычланырга кирәк... Мәхмүт,— диюдән башка сүз әйтә алмады ул.

«Әйдә, Мәхмүт, дия бирсен... Көенә генә торырга кирәк моның. Йә тагын өскә килер... Ул чагында...» — Садрый-Мәхмүт хатынга елмайгандай итте: «Дулап кычкырмаган чагында, болай ярыйсы гына кыяфәтле күренә бу хатын...»

— Мин... мин тынычландым инде,— диде ул. — Тик менә... шылтыратып кына аласы бар иде... Телефон юктыр бит?

Хатын бу сәер тамашаның (тамаша дими тагын ни дисең инде!) шаһиты булудан (үзе бер үк вакытта катнашучы да, тамашачы да дигәндәй) тәмам гаҗиз калган иде. Телефон белән нишләргә җыена икән инде бу хәзер?

— Телефонмы? Бар, бар... Әнә, ишек янында,— диде ул. Аннан «Хәерлегә генә булсын инде. Акылы тулы кеше төн уртасында кешегә шылтыратамыни» дип уйлады да болай гына кызыксынгандай өстәде: — Ә-ә-ә... Кая шылтыратмакчы идең?

Садрый-Мәхмүт:

— Өйгә инде. Хатынга. Галиягә,— дигәнен сизми дә калды. Ул, ят хатын тагын дулый башламаса гына ярар иде дип шүрләп үк куйды.

Юк, дуламады хатын. Күрәсең, тынычлангандыр. Ят ирне болай гына кулга төшереп булмаслыгын аңлагандыр, димәк. Эчкече дигәч тә, алай тиз генә башы буталырга ир-ат бит ул, инкубатор чебиләрен, ата-анасыз үрдәк бәбкәләрен кушар өчен махсус аракы йоттырудан исертелгән тавык түгел. Тавык кына ул, айныгач, үз тирәсендә бөтерелгән ят чебиләрне, ят үрдәк бәбкәләрен күрсә дә аптырамый. Шулай тиеш дип уйлый. Уйлый белсә, әлбәттә. Әле, җитмәсә, бер өер үрдәк бәбкәсенә сөеп карыйдыр, «Бигрәкләр дә үземә охшаганнар инде!» дип уйлап куя торгандыр ул, махмырбаш...

Садрый-Мәхмүт телефон җайланмасы янына килде дә кулына трубканы алды. Ашыкмыйча гына үзенә кирәкле саннарны җыйды. Гөлсара аның һәр хәрәкәтен күзәтте. «Бер караганда җүләр кешегә охшамаган да үзе...» — дип уйлады.

Трубканың кызыл помидорга охшаш башын кабып йотардай булып:

—Алло! Алло! — диде Садрый-Мәхмүт.— Алло! Галия!

Ләкин аңа җавап бирүче-дәшүче булмады булса кирәк, ул трубканы теләр-теләмәс кенә урынына кире куйды.

— Алмый. Йоклый торгандыр. Йокласа, каты йоклый ул. Мәрткә киткән кеше белән бер,— диде Садрый-Мәхмүт.— Ә бәлки, күрше хатын янына кунарга кергәндер. Сәмигага. Ялгызы өйдә кунарга курка торган гадәте бар иде...

— Номерны дөрес җыймадың мәллә? — дигән булды Гөлсара, аның хәленә кергәндәй.

— Дөрес. Утыз ике, унбер, егерме дүрт инде. Телефон чакыра, алучы юк,— диде Садрый-Мәхмүт.

«Утыз ике, унбер, егерме дүрт... Утыз ике, унбер, егерме дүрт...» — Гөлсара саннарны хәтерендә калдырырга тырышты. Бик әйбәт булды әле бу. Телефонның теге башында кем яшәгәнен беләчәк хәзер Гөлсара. Кем икән ул Галия? Мәхмүтнең себеркесеме? Әгәр шулай икән, якты көн күрсәтмәячәк ул аңа. Кандала урынына сытачак, изәчәк...

Гөлсара халатын алып киде.

— Минем күлмәк кайда икән? — дип сорады Садрый-Мәхмүт. Үзенең кулында — саргылт күлмәк. Башы каткан бугай инде моның тәмам...

— Кулыңда нәрсә соң ул?

— Минем күлмәк түгел бит бу?

— Менә сиңа мә! Кемнеке булсын тагын, синеке булмыйча.

— Өйдә минем бөтен күлмәгем зәңгәрсу. Шундый төстәгеләрне кияргә яратам мин. Ә бу, үзең дә күреп торасың, сары...

— Ә чалбарың кемнеке? Анысы да үзеңнеке түгелдер әле,— дип усал көлемсерәде Гөлсара.

— Чалбар?!

Садрый-Мәхмүт чалбарына иелеп, текәлеп карады, бармаклары белән аны тоткалап-тарткалап карады.

— Әйе шул, чурт, минеке түгел! Минеке буй-буй сызыклы иде. Һе, сәер...

— Сәер шул менә. Бик сәер. Синең кыланмышың миңа инде күптәннән сәер! — диде Гөлсара, тавышын күтәрә төшебрәк.— Баядан бирле кәмит уйныйсың бит... Кичә әйбәт идең, ә бүген...

— Кичә әйбәт булганмын шул... Бик әйбәт булганмын... Әллә шул әйбәт килеш мунчага да бардым микән? Мөгаен, шунда алыштырганмындыр әле бу чалбарны... Күлмәкне дә берочтан... Чалбар... чалбар Ишниязныкына охшаган шикелле...— дип сөйләнә-сөйләнә, Садрый-Мәхмүт кичә мунчага бару-бармавын исенә төшерергә азапланды. Әмма ни ләүкә, ни душ, ни мунчала-сабын ише әйбер-санаклар хәтеренә ялгыш та килмәде.

«Барганмындыр, шәт. Ишниязныкыдыр бу киемнәр. Ә ул минекеләрне кигәндер. Өйгә кайтканчы, аңа сугылып, бүген үк алыштырасы булыр» дип уйлады да саргылт күлмәкнең җиңенә йонлач кулларын тыкты.

Аның күлмәк сәдәпләрен каптырганын карап торган Гөлсараның миен «Үзем белән бер-бер хәл булмагандыр бит, Ходаем?!» дигән уй өшетеп алды. Тфү, тфү! Аллам сакласын берүк!..

Садрый-Мәхмүтнең пинҗәге дә үзенеке түгел иде. Ул искергән, терсәк тирәләре каешлана төшкән пинҗәкнең кесәләрен караштырды. Аларда өч-дүрт теше коелган кызыл тарактан, бөгәрләнеп, таушалып беткән кәгазь берлектән һәм тиштерелгән троллейбус талоннарыннан башка нәрсә юк иде.

— Кызык һәм сәер! — диде Садрый-Мәхмүт.— Маҗарага бай төн булды бу. Лыкынганчы эчсәң, менә шулайрак буладыр инде ул...

— Ничек... эчсәң?

Гөлсараның гаҗәпләнүдән күз кабаклары өскә сикерде.

— Кичә эчкәнне әйтәм. Нык эчелгән, каһәр,— диде Садрый-Мәхмүт, пинҗәк кесәсеннән чыккан тарак берлән чуалган сирәк чәчләрен тараштырып.

— Син соң... кичә исерек түгел идең! Синең эчмәгәне-

ңә ел ярым була бит инде. Врачлар язвы дигәннән бирле эчкәнең юк лабаса!

«Җавапсыз табышмак кына булмады бу төн. Әллә нәрсә булды. Хәзер, әнә, кичә исерек түгел идең, дип бара бит бу...»

Алар икесе дә бер-берсенә бактылар. Икесенең дә башында бертөсле уй, сорау: «Ул тилеме, әллә мин җүләрме?»

Көн беленә башлады. Бүлмәдәге ут яктысы белән тәрәзә пәрдәләре аша үтәли саркыган зәңгәр кучкыл яктылык бергә кавышты.

Алар тагын ни уйларга, ни эшләргә белмичә шактый басып тордылар...

Ошбу әсәрнең авторы өчен дә сәер булган бу тамашаны Гөлсара дәвам итте. Ул, каударланып, сервант янына барды да аның тартмачыгын шыгырдатып тартып чыгарды. Кинәт тартылган тартмачык эчендәге әйберләре белән чак идәнгә очмады. Гөлсара аннан яшел тышына чәчәкле сурәт төшерелгән фотоальбом алды. Аннары аны җәһәт-җәһәт кенә актара башлады. Актара торгач, үзенә кирәк нәрсәне тапты, ахрысы... Кулына туу турында таныклык зурлыгындагы бер фотосурәт тотып, Садрый-Мәхмүт тарафына борылды.

— Кара менә монда! Таныйсыңмы боларны? — диде ул. Кулындагы шул фотосурәт белән бүгенге сәер тамашага нокта куярга теләгәнен аның ошбу вакыттагы халәтеннән сизәргә, күрергә була иде.

— Ә нигә? — диде Садрый-Мәхмүт, берни аңламыйча.

— Кара, кара. Аннан сорау бирерсең.

Садрый-Мәхмүт Гөлсара янына килде, аның кулыннан фотосурәтне алды.

— Синмени бу? Матур төшкәнсең. Ә бусы... иреңме?

Гөлсара янә ярсый башлавын, тәнендәге бөтен тамырларында берьюлы каны кызышуын тойды.

— Әйе шул, ирем! Минем ирем! Син ул, мәхлук! Кара әйбәтләп. Танымыйсың мәллә үзеңне?

«Тагын башланды!» — Садрый-Мәхмүт, чыраена көндәшенең алагаем саллы йодрыгы төшәсен сизенгән боксчыдай, артка чигенде, үзе дә белештермәстән, кулларын өскәрәк күтәрде.

— Үземне? — диде ул.

— Үзеңне, үзеңне! — диде хатын.

— Хет үтер, Гөлсара... Танымыйм... үземне...

Хатын аны җилтерәтеп аяклы көзге янына алып килде дә төксе генә:

— Кара, кара. Сурәткә кара да көзгегә кара. Чагыштыр үзеңне! — диде.

Садрый-Мәхмүт әле сурәткә, әле көзгегә карады.

— Йә, ничек? Таныдыңмы инде?

— Бераз охшаган шул...— дия генә алды Садрый-Мәхмүт. Аның күңеленә ниндидер корт төште. Чыннан да, Садрый-Мәхмүтнең кыяфәте белән сурәттәге ир-атның чырае бертөсле иде. Бераз гына аерма бар барын... Ләкин ул аерманың бары тик сурәтнең сыйфатсызрак булуына гына бәйле икәнлеге сукыр күзгә дә күренүе аяз көн кебек ачык иде.

— Бераз гына түгел, бөтенләй охшаган! — диде Гөлсара.— Сурәткә төшкәнгә әле өч ай да юк. Июльнең тугызында кияү төшерде безне. Камил. Феночкабыз-Фәниябез бүлнистә шул көнне кыз тапкан иде. Оныгыбыз туган көнне...

— Әле минем... онык та бармыни? — Садрый-Мәхмүтнең гаҗәпләнүе чиктән ашты.

Бирәм дигән колына — чыгарып куяр юлына... Менә, Ходай бирсә бирә ул. Бая гына икенче хатыны булган иде. Хатын өстенә хатын. Инде хәзер шуңа өстәп кызы, кияве, оныгы да булды.

— Бар шул менә. Марисабил. Исемен мин әйттем. Балалар ошатты. Син җөпләдең...

— Исеме ничек дидең... оныкның? Марийсабый дисеңме? Татарда андый исем йөртүчеләр дә бармыни? — диде Садрый-Мәхмүт.

— Син үзең — Марыйсабый. Марисабил, дидем бит, колак!..

— Беренче тапкыр ишетәм мондый исемне...

— Нишләп беренче тапкыр гына булсын! Ел буе ишетәсең инде син аны. Телевизордан «Байлар да елый» киносын караган саен...

— Нинди кино ул тагы?

— Борының агач ботагы! Кичә генә шуны карап йокладың бит, адәм тәганәсе...

— Үтер, хәтерләмим...

— Аяк өсте мәрткә киткән идең мәллә соң син кичә?! Һаман да уяна алмыйсың...

Садрый-Мәхмүтнең йөзе балкып китте. Һы... Бәлки, чыннан да, ул мәрттә генәдер, ә?! Изрәп берни белмәс, хәтерләмәс хәлдә йоклыйдыр. Болар... болар һәммәсе дә төш кенәдер? Бу хатын... Чалбар-күлмәк... Кыз-кияү... Ниндидер Мырыйсабыйл-Марисабый дигән онык... Тизрәк уянасы иде... Бу мәхшәр төштән арынасы иде...

Ул уң кулы белән сул беләген каты итеп чеметте. Беләге кинәт авыртудан, чак кына кычкырып җибәрмәде. Йөзен чытты. Димәк, бернинди мәрт тә түгел бу, төш тә түгел... Котны алырлык өн?!

Гөлсара тәрәзә пәрдәләрен ян-якка тартып куйды. Браны сүндерде.

Тышта яп-якты иде.

Садрый-Мәхмүт стенадагы сәгатькә күз төшерде: җиде туларга егерме дүрт минут. Сәгать. Ә... аның кул сәгате кайда микән? Әһә, менә аяклы көзге алдында икән. Юк, бу сәгать аныкы түгел. Каешы да.

— Инде сәгать тә синеке түгелме? — диде Гөлсара сәгатьне кулында әйләндереп карап торган Садрый-Мәхмүткә.

— Түгел шул,— диде Садрый-Мәхмүт, гаепле кеше сыман.— Минеке «Ракета» иде, ә бу — «Амфибия»... Каешы да гади күн каеш иде... Чылбыр каешны яратмыйм мин. Мондыйлар кулдан төшеп калучан...

— Кемнеке соң, алайса?

— Кемнеке, дип... Ирең...— Садрый-Мәхмүт «ирең-некедер» димәкче иде, тынып калды.— Ишниязныкыдыр инде... Сәгать тә мунчада алышынгандыр...

«Кем алышынгандыр әле» — Гөлсара урын-җирне җыештырып бетерде. Бүгенге хәл турында Әдип белән киңәш-табыш итешәсе булыр. Әдип — Гөлсараның якын танышы. Таныш дип, таныш кына да түгел инде. Аратирә ир ролен үтәүче, дисәң дөресрәк булыр. Зур түрә кеше... Балаларга да хәбәр итәргә кирәк. Әгәр Мәхмүт чынлап та алышынган икән, аны җүләрләр йортына салырга туры килмәгәе...

Гөлсара, берни булмагандай, сүзне икенчегә борды:

— Син! Чәй эчәсеңме хәзер? Кайнатырга куям,— диде.

— Чәй?! Ә-ә... чәйме? Юк, чәй эчәсе килми. Рәхмәт! — Садрый-Мәхмүт сүзнең башка юнәлеш алуыннан аптырап китте.

Чәй дигәннән, аның бит-кулларын юмаганлыгы исенә төште. «Әйдә, ярар, берәр җирдә юынырмын әле» дип, хатынны борчымаска булды. Ялгыш сүз ычкындырырсың да хатын тагын ниндидер җүләр сорауларын биреп йөдәтә башлар... Ишниязга сугыласы бар бит, аның өендә юынырмын әле...

— Тагын телефоннан шылтыратып карасам дигән идем... Аннан китәсе булыр,— диде Садрый-Мәхмүт.

Гөлсара кухняда краннан чәйнеккә су агыза иде, аның сүзләрен ишетмәде.

Садрый-Мәхмүт телефон трубкасын алды, саннарны җыйды. Бераздан озын-озын итеп пипелдәгән тавыш ишетте. Телефон чакырды, әмма теге баштан трубканы бу юлы да алучы ишетелмәде.

«Тәгаен күршедә кунган. Сәмигада. Шунда гына. Гөл-

сара шикелле зәһәрләнеп көтәдер инде ул аны хәзер. Эт итеп сүккәндер Сәмигага. Алкаш, квартирант, җилкуар, дигәндер...» Садрый-Мәхмүт трубканы куйды.

Китәргә кирәк. Хәзер үк өйдән чыгып китәргә кирәк...

Ул ишек төбендәге кара ботинкаларга оекбашсыз аякларын тыкты. Үзенеке түгел түгелен, ләкин ярыйлар тагы. Кысмыйлар да.

Кухня ягыннан савыт-саба шалтыраган тавыш ишетелә. Гөлсара, димәк, ашарга хәстәрли. Бик әйбәт. Хәстәрләсен. Хәзер сиздермичә генә чыгып китәчәк ул...

Садрый-Мәхмүт аяк астындагы портфельне эләктерде дә ишек бигән сак кына читкә этәрде, тишегендә калган ачкычны тавышсыз гына борды...

Ниһаять — ул тышкы якта!

Баскычлар буйлап, өченче каттан ничек тиз төшкәнен, подъезд ишегеннән урамга ничек очып чыкканын ул үзе генә белә иде...

«Нишләптер Мәхмүтнең тавыш-тыны ишетелми. Чыгып таймагае тагы...»

Гөлсара күсе зурлыгындагы дуңгыз колбасасын суыткычтан алып өстәлгә куйды, үтмәс пычак белән бармак калынлыгы телем кисте, аннары аны авызына капты да, чәйни-чәйни, зал ягына чыкты.

— Син колбаса ашыйсыңмы?

Соравы һавада эленеп калды: Садрый-Мәхмүт залда юк иде.

Ишек төбендәге ботинкалар аякланган, димәк, сызган, мөртәт...

Кая китте микән инде ул, җүләр тәре. Бүген аның эш көне дә түгел бит. Ял көне. Чәршәмбе.

Гөлсара ишекле-түрле йөренеп алды.

Кичә әйтте бит, чәршәмбе дәресләрем юк, диде, балыкка барам, диде. Гөлсара эченнән генә куанып та куйган иде. Әдипне чакырырмын дип план да корган иде кичен... Әллә... балыкка китте микән? Алай дисәң, кирәк-ярагы тутырып куелган биштәр монда. Ә менә портфеле юк. Алган, үзе белән алган...

Шылтыратырга кирәк. Тик кая шылтыратырга? Университеткамы? Бераздан шылтыратып белешәсе булыр. Аның алдында юри кәмит уйнагандыр да... университетка киткәндер. Ә... бәлки, этлеккәдер? Олыгайгач, ир-ат азып-тузып ала, диләр бит. Әгәр дә шулай булса... Туктале, ниндидер Галиягә телефоннан шылтыратып карады түгелме соң? Телефон...

Тел-ле-фо-он...

Нинди саннар әйткән иде әле ул?

Утыз ике, диде бугай... Аннары, унбер, диде... Тагын — егерме дүрт... Әйе, утыз ике, унбер, егерме дүрт!.. Утыз ике, унбер, егерме дүрт!..

Шылтыратып карасын әле ул менә хәзер. Кем икән ул Галия? Юри генә әйттеме Мәхмүт бу саннарны... бу хатын исемен... Әллә...

— Әйе, Галия тыңлый сезне! Галия Кәбировна тыңлый.

Йа Хода!

Йөзләре кинәт агарынган Гөлсара кулыннан телефон трубкасын төшереп җибәрә язды.

Йа Ходаl Га-ли-я... диде түгелме?

Бәлки, ялгыш кына ишетелгәндер? Гөлсара кулы калтыраткан трубканы колагына янә якын китерде.

Чәй кәгазе кебек шыштырдавык тавыш кабат ишетелде:

— Алло! Тыңлыйм сезне! Тыңлыйм! Кем әле бу?

Гөлсара теле ни әйткәнне үзе ишетмәде:

— Бу... бу... мунчамы бу?

— Юк. Квартир. Ялгыш эләккәнсез...

Кәгазь тавыш киселде.

Гөлсара каз бәбкәсе шикелле пипелдәгән трубканы тоткан килеш бермәл исәңгерәп торды.

Аңгырага салышкан булды... Уеннан уймак чыкмагае әле Мәхмүтнең. Әгәр ул хатынның чәчләрен умырып тотып, үзен идәнгә атып бәрмәсәме Гөлсара?! Шулай итмәсә, Гөлсара булмый да ул...

Адресын белешәчәк. Аннан ул явызның өенә барачак. Барачак, ишеген тибеп керәчәк. Шыштырдавык тавышның чыраен тырмап төшерәчәк, ике күзен дә төртеп тишәчәк. Идәндә яткан җансыз гәүдәсенә менеп басып, утлы күмер өстендә биегән кыргый кешеләр шикелле, үрле-кырлы сикерәчәк...

Әйе, тантана итәчәк әле ул!

«Тәки котылдым бит хатыннан!»

Садрый адымын акрынайтты. Артына борылып карый-карый, моңарчы таныш булмаган йортлар арасыннан бара торгач, ниһаять, ул бер урамга килеп чыкты.

Бәй, автовокзал ягы бит бу. Әнә тегендә — Тинчурин тукталышы. Кара син аны, ә! Кая килеп чыккан бит кичә. Бу тарафка аның йомышы төшмәгәнгә шактый иде инде. Ишнияз белән бергә сыра эзләп елга портына кадәр килгәннәренә дә биш-алты айлар бардыр. Ул көнне бу якта юллары уңмады аларның. Ярты литрлы ике банка

сыра эчәр өчен Каравайга хәтле бардылар. Эчтеләр эчүен, әмма аңарчы тел бистәсе Горбачның тетмәсен теттеләр. Мотоциклга тагылган бишек шикелле, ул кая барса, шунда барып, тыкылдап йөргән хатынына да эләкте...

Тукталышта өстенә җәйге пәлтә, башына зур кепка кигән, иңсәсенә «спорт» дип язылган букча аскан бер адәм аңа арты белән баскан килеш тәмәке төтәтеп тора иде.

— Друг, угасти, пажалысты,— диде аңа Садрый, килә-килешли. Урысча аңламаса, эпәчә аңлар диптерме, ул соравын бер үк вакытта ишарә белән дә белдерде — портфель тотмаган кулының ике бармагын кипшенгән иреннәренә тигезгәләп алды.

Тәмәкече адәм кырт борылды, үзенә мөрәҗәгать иткән Садрыйның башыннан аягына кадәр күздән кичерде.

Ха! Садрыйның авызы иләк булды: бу бит... теге... шагыйрь! Кем әле... э-э-э... Фидәррис! Фидәррис... Фамилиясе нинди соң әле... Ә... Әслән...

Әсләмов! Тучны, шул, үзе — Фидәррис Әсләм! Кайчандыр бер очрашканнар иде. Сыраханәдәме шунда...

— Сәлам, Фидәррис! — Садрый күрешергә дип кулын сузды.

«Тучны Фидәррис» булырга тиеш адәм кием щеткасы кылларын хәтерләткән кара мыегын сикертеп алды, төбенә хәтле янып бетә язган тәмәке төпчеген «фырт» иттереп җиргә төкерде:

— Не курящий!

Ул шулай диде дә кепкасын батырып киде. Аннан, янә кырт борылып, башын бер якка янтайтып, җил-җил атлап китеп барды.

Хы!..

Аңлашылмады бу.

Садрый күзләрен челт-челт йомгалады. Соң... шул шагыйрь үзе иде бит инде. Юри танымаганга салышты. Ә бәлки, Фидәррис булмагандыр да әле ул. Шуңа охшаган бүтән кеше булгандыр. Шундый кешеләр була бит — берберсенә бер тамчы сыра кебек охшаган игезәкләр шикелле... Әнә бит, Садрый да бая теге хатын өендә күргән фотосурәттәге адәмгә тач охшаган иде...

Тукталышка шәһәр үзәгенә таба баручы троллейбус килеп туктады. Төшүче-мазар күренмәде. Садрый урта ишектән эчкә узды.

Троллейбус кузгалды. Салондагы көчәйткеч аша йөртүченең ике телдән винегрет ясап укмаштырылган тавышы яңгырады:

— Эслидующий — тиатр Камал. Талун кампастируй-

тә. Перюд прахудим. У кава нит, покупайте вадителя. Адин пачка дисет рубли. Вадителя имеется месячник!..

«Бер пачкасы ун тәңкә, диме?» — Садрый колагын шомрайтты. Берсе бер тәңкә булып чыга түгелме соң? Урысча белүе чамалы, ялгыш әйткәндер, мескен... Каушагандыр... Микрофон каушата ул шулай... Кичә Садрый шикелле шактый гына төшергән булса, биш тиенлек билетны ун тәңкә дип тә әйтерсең...

Садрый троллейбус тәрәзәсе аша тышка карады.

Гөлсара Мәхмүтне, аның шыштырдавык кәмәшен каһәрли-каһәрли, көзгегә карап, чәчендәге бигудиларны алды. Массаж тарагы белән чәчләрен кабартты, кыяфәте нәкъ Алла Пугачева булды да куйды. Шул урыс җырчысы шикелле, ботларын кысып торган кыска, тар итәк тә киеп җибәрсә...

Гөлсара, ирен читен бөрештереп, көзгедәге ботларына мыскыллы караш ташлады.

Юк шул, кызганычка каршы (ул авыр сулады), кия алмый андый итәкне Гөлсара. Бик-бик теләсә дә, кия алмый. Кыска итәк юклыктан түгел... Чырае ярыйсы гына карт күренгәнлектән дә түгел... Иннек-кершән сөрткәләсәң-сыласаң, ирен-кашны буяштырсаң, бер биш яшькә яшәреп була ла... Пугачева да телевизордан гына яшь күренә ул. Янына барып, якыннан текәлеп карасаң, коточарлык әллә нинди карт марҗадыр әле. Дөрес, сыйракларны биргән үзенә Ходай. Биргән. Бер сүз әйтерлек түгел. Ир-ат халкы гына түгел, хатын-кыз да сокланырлык! Аныкы шикелле ботлар Гөлсарада булса, кимәс иде мәллә ул да кыска итәк. Кияр иде, әлбәттә. Урамда барганда, арт санын юри биетеп, яшүсмер кызлар кебек тырт-тырт атлар иде. Бер-берсенә сыланып беткән ботлары арасыннан җил ялгыш та уза алмас иде... Иде... Уза шул җил. Әле ничек кенә уза! Җил генә түгел, футбол тубы сызгырып узарлык аның ике бот арасыннан. Мәктәптә укыган чакта, бигрәк тә соңгы елларында, күпме балавыз сыкты ул шул кәкре аяклары аркасында. Кая ул егетләр белән йөрү... Алар елмаеп кайчак бер-ике генә сүз әйтсә дә, башы күккә тия иде Гөлсараның. Андый бәхет егетләр тарафыннан сирәк тәтеде шул. Аның ул чактагы кушаматы да Камытсылу иде бит. Дус дип санап йөргән кызлары да аның алдында гына «Гөлсарам җаным, Гөлсара дустым» диләр иде. Үзе юкта Камытсылу дигәннәрен ул бөтен җаны-тәне белән сизә иде. Сизә иде...

Гөлсара күңелсез хатирәләреннән арынды. Телефон янына килде. Нияте Әдипкә шылтырату иде. Эшенә. Өеннән күптән чыгып киткәндер инде.

Дөрес чамалаган икән. Трубканы Әдип алды:

— Да! Я слушаю!

Кайчан гына шылтыратсаң да, ул гына шулай калын, көр тавышы белән «Да! Я слушаю!» дияр. Әгәр дәшмичә юри бераз тын торсаң, «Говорите! Адип Максимович слушает!» дип тә өстәр...

— Говорите! Адип Максимович слушает!

Әдибен Әдип, әмма Максимович түгел ул үзе. Мәгъсүмович. Нигәдер «Максимович» дияргә ярата үзен Әдип. Үзенә дә шулай дип дәшсәң, коры, көр тавышы дуңгыз мае шикелле эри дә китә...

— Әдип Мәксимычкаем!

«Мәксимычкаем»ның тавышы эреде.

— Синме бу, сабыем?

Әдипнең һич үзгәрмәс, канына сеңгән бер гадәте бар: беркайчан да телефон аша Гөлсарага исеме белән дәшмәс. «Сабыем» дияр. Юк, Гөлсарага гына түгел, чит-ят кешеләргә дә еш кына шулай ди ул. Бу хакта Гөлсара аның үзеннән кызыксынган иде бервакыт, пыяла прилавкага каймаклы кечкенә шешәләр шикелле тезелгән тешләрен балкытып елмайды гына Әдип «Мәксимыч»: «Конспирация! Саклаганны саклармын, дигән Бог!» — диде.

— Мин идем шул, Мәксимычкаем!

«Мәксимычкаем»ның эш бүлмәсенә ят кеше кергәндер, мөгаен, юкса тавышын кинәт үзгәртмәс, әүвәлге халәтенә кайтармас иде:

— Да, да! Слушаю вас! Говорите! Только вкратце, пожалуйста...

Гөлсара җәелеп сөйләшеп булмасын аңлады, шуңа күрә тиз-тиз сөйли башлады:

— Теге имгәк белән бүген әллә нәрсә булды. Мәхмүтне әйтәм. Җүләрләнгән кеше шикелле. Мине танымый. Үзен «Мин — Садрый» ди. Башта шаярта, юри мине котырта дип уйлаган идем. Хәлләр бер дә шаяруга охшамаган. Нindидер Галия исемле хатынга шылтыратып маташты. Сөяркәсе булырга тиеш. Күңелем шулай сизә.

— Да? Не может быть?!

— Әйе, әйе, сөяркәсе! Ул хатынга шылтыраттым инде, бар андый хатын.

— Ничего не понимаю. А где он сам?

— Мин кухняда чагында чыгып качкан. Җүләр бит. Кая киткәндер инде, Ходаем?..

— А сейчас что делать собираетесь?

— Собираетесь дип... Син берәр киңәш бирерсең мәллә дигән идем, Мәксимычкаем... Үземнең башкайларым

бер дә эшләми. Бәлки, өйгә сугылып чыгарсың. Теге имгәк тиз генә кайтмас әле ул...

— Хым-м-м... Знаете, у меня скоро совещание. Где-то полвторого постараюсь быть у вас. Ждите. До свидания, пока...

«Ждите» диде. Димәк, килә. Киләчәк. Ул вакытка теге тиле тәре генә кайтып кермәсен инде берүк. Хәер, кайтып керсәни! Җүләр бит ул... Барыбер Гөлсараны хатыны дип танымый лабаса...

Чү! Ишнияз бара түгелме соң урамның теге ягында?

Шул! Нәкъ үзе. Ул гына шулай, ике кулын да кесәсенә тыгып, аякларының берсен мәшрикъкә, икенчесен мәгърипкә каратып атлар.

— Ишнияз!

Садрый, троллейбус тәрәзәсеннән башын тыгып, урам яңгыратып кычкырды. Каян килгәндер аңа шулкадәр тавыш — ул үзе дә аптырап куйды.

Үзенә дәшкәнне ишеткән Ишнияз, атлавыннан туктап, тирә-юньнән тавыш хуҗасын эзләде. Садрый аңа кул болгады:

— Ишнияз! Мин монда!

Ишнияз, ниһаять, аны шәйләде.

Садрый, тәрәзәдән башын алып, троллейбус йөртүчегә таба борылды.

— Водитель! Останови машину!

Йөртүче ишетеп тә әллә ишетмәмешкә салышты — троллейбус тизлеген әз генә дә киметмичә теркелдәвен белде.

— Водитель! — дип янә сөрән салды Садрый, алгы ишеккә таба авыш-тәвеш килә-килешли.— Останови! У меня там друг остался!..

Троллейбус йөртүче хатын мыеклы иде. Ник бер төге селкенсен мыегының!

— Паж-жалысты,— дип ялварып дәшәргә мәҗбүр булды Садрый.— Будь человеком!

Троллейбус Камал театры тукталышына килеп җиткән иде. Туктады. Мыеклы хатын урыныннан торды. Алгы ишек ачылды. Садрый тышка омтылды, ләкин чыгып өлгерә алмады.

— Придъяви талун!

Мыеклы хатынның көчле кулы аның пинжәк итәгеннән эләктергән иде.

— Какой-такой талон? — дип, тышка тартылды Садрый. Каһәр, талон тиштермәде бит ул. Хәер, тиштерергә яңа талоны да юк иде ләбаса...

— Придъяви талун! Сичас милитсия пазаву!

Садрый чуртан каптыра торган кармакка ялгыш эләккән этләч балык шикелле бәргәләнде. Ләкин кармак нык каптырган иде. Болай гына ычкынып булмаслыгын аңлады. Садрый киләксезгә бәргәләнүдән туктады.

— А-а-а... тало-он! Давно бы так сказали...— дип мыгырдана-мыгырдана, ул пинжәк кесәсенә кулын тыкты. Бармаклары белән кармалый торгач, иртән теге хатын өендә күргән троллейбус талонын тартып чыгарды.

— Пажалысты...

Мыеклы хатын кулын Садрыйның пинжәгеннән ычкындырды, талонны алды. Садрый, кармактан котылган бәхетле балык кебек, тротуарга сикерде.

Талонның үзе йөрткән троллейбуста тиштерелмәгәнен аңлаган мыеклы хатын аның артыннан, шәрран ярып, нидер кычкырып калды...

Ишнияз бая туктаган урында йөренгәләп тора иде. Сул чигәсе турысындагы яңа ярасын, күз төбендәге «фонарь»ын капларга теләптер инде, таушалган «москвичка»сын батырып кигән.

«Кичә хәйран гына тамызганнар моңа» дип уйлап алды Садрый, аның йөзенә игътибар итүгә.

— Сәлам, Ишнияз!

— Сәлам!

Ишнияз, үзенә Садрыйның текәлеп карап алганын сизенеп:

— Кичә таеп егылдым... сабакы! — диде.— Өйгә кайтышлый... Тротуар читенә бәрелдем...

Таеп?! Көз көнеме? Карның әсәре дә юк бит әле. Ну, алдаса алдый инде Ишнияз. Йә, ярар... Тайган, егылган... Буласы булган, күз төбенә мөһер кунган...

Садрый төпченмәскә булды.

— Ыслушай, бу синең пинжәкме? — диде ул.

— Ник алай дисең? — Ишнияз кулы белән ярасын сыйпап алды.

— Синекеме, түгелме, дим?

— Нишләп минеке булсын... Минеке — үземдә!

— Ә кемнеке соң, алайса?

— Прокурор мәллә син! Сорыйсың да сорыйсың. Каян белим ди мин...

— Кичә салган баштан мунчага барганмын бугай. Кемнекендер кигәнмен инде, алайса... Кемнеке булырга мужыт бу, белмисеңме?

— Шайтан белсен... Карале, син салуны ташлаган идең түгелме?

Садрый сорауны ишетмәде.

— Чалбар да синеке түгелме? Ә ботинка? Бу портфель?..

— Юк, дидем бит? — Ишниязның ачуы чыга башлады.— Тинтәк сорауларыңны биреп башны катырма әле. Болай да чигә авырта... Баш та чатный...

М-м-м-да-а... Ишниязныкы булып чыкмадылар болар, алайса.

— Баш дигәннән... Баш минеке дә авырта ул. Иртәдән бирле...

— Аның чарасы бер генә инде — төзәтергә кирәк.

Садрый кесәсендә бөгәрләнгән кәгазь берлек барын исенә төшерде:

— Сыңар берлек белән әллә кая барып булмый шул...

— Бер кап шырпы алырсың...

— Йөзне, диген...

— Бирделәр ди йөзне, әйе... Тот капчыгыңны. Син нәрсә, бүген генә күктән төштең мәллә?

— Нигә?

— Нигә-нигә... Бер тәңкәгә йөз кап шырпыны синең шикелле күктән төшкән җүләр кеше генә алырга мөмкин.

— Но-но... Сүзне чамалап...

— Йә ярар, Мәхмүт, сүзнең бетәсе юк. Нишлибез? Төзәтәбезме бу газиз башларыбызны, әллә юкмы?

— Кем дидең? Кем дидең әле генә?

Садрый кинәт, кулындагы портфелен төшереп җибәреп, Ишниязның каешланган курткасы якасыннан эләктереп алганын сизми дә калды. Аны җилтерәтә-җилтерәтә:

— Кем дидең? Миңа кем дип дәштең? — диде.

— Кем дип... Үз исемең белән дәштем. Мәхмүт, дидем...

Ишнияз аптырау катыш курkkынган күзләрен челтчелт йомгалады. Садрый кулларын аның якасыннан алды.

— Бүген миңа бер хатын Мәхмүт, дигән иде инде. Инде хәзер син...

Ишнияз якаларын рәтләштерде.

— Псих... Мәхмүт булмый кем буласың тагын? Әкәлә Хәсәнме?

Хикмәти Хода! Бернәрсә дә аңлашылмый. Инде бусы да Мәхмүт, ди.

Садрый бер сүз дә дәшмәде. Беравык аптырап торды да китеп барды.

— Әй, псих! Портфелеңне миңа калдырдың мәллә? — дип кычкырды аңа Ишнияз.

— Портфель? Ә, әйе... Кәҗә — это хорошо...

Шулай дип, бер бәйләнешсез сүзләр сөйләнә-сөйләнә, Садрый портфелен кире килеп алды.

Бая гына нәрсәгәдер өметләнгән Ишнияз, төшенке тавыш белән:

— Баш төзәтмибезмени? —диде.

Садрый җавап кайтармады...

* * *

Шыкы-шыкы! Шык-шык!

Галиянең өч көн инде җүнле-башлы йоклаганы юк. Өч көн инде аның җаны үрмәкүч пәрәвезенә эләккән бөҗәк шикелле чәбәләнә. Йөрәге урынында түгел, берөзлексез дөпелди. Башы авыртуын әйткән дә юк. Цитрамон да эчеп карады, корвалол да... Йокы даруы да калмады. Алга китеш сизелми. Күз алдында һаман Марисабель тора...

Чаж-чыж! Чаж-чыж!..

...Быел җәй дачада аңа бер мәче ияләште. Дөресрәге, Галия ул мәчене үзе ияләштерде. Мәче яисә мәче баласын күрсә, дөньясын оныта торган гадәте бар аның. Шәһәрдә туып үскәнгәдерме, мәчеләрне үлепләр ярата инде ул. Авыл кешесенең мәче халкына артык исе китмәвен, мәчене болай гына, тычкан-мазар тотар дигән максат белән генә асравын белә Галия. Берәрсенең түшәктә ваемсыз гына йокымсырап яткан мәчене җилтерәтеп идәнгә бәреп төшергәнен, «Аяк астында чуалма әле, әрәмтамак!» дип, аяклары белән эткәләп-төрткәләп ишектән чыгарып җибәргәнен күрсә дә, йөрәге әрни аның. «Типкәләрлек булгач, нигә асрарга инде аны? — дип аптырый ул.— Изге җан иясе бит ул мәче!»

Галия үз бакчаларында күргән мәчене дә кемдер артыксынып өеннән китереп ташлаган иде. Шулай булмаса, ул мәче ачка интегеп, төзелеп беткән-бетмәгән йортларның берсеннән икенчесенә кереп йөрмәс иде, каршыңа килеп, күзләрен мөлдерәтеп, мияулап, синнән ризык өмет итмәс иде...

Мамык шикелле йомшак йонлы ак мәче әллә каян гына пәйда булды да Галиянең аякларына килеп сарылды. Аннары, башын күтәреп, нәзек тавыш белән:

— Мияу! — дип куйды.

Галия аңлады: мәче ашарга сорый иде.

— Хәзер, матурым! — диде Галия.— Хәзер сыйлыйм мин сине, аппагым!

Мәче Галиягә иярде.

— Хәзер колбаса бирәм мин сиңа. Пешкән күкәй дә бар. Сөт юк инде менә. Ә-ә... сөтле чәй бар ич! Сөтле чәй эчәсеңме, матурым, ә? — дип сөйләнә-сөйләнә, Галия өйдән алып килгән ризык-нигъмәтләрен, хуҗалык букча-

сыннан чыгарып, каен тактасыннан әвеш-тәвеш китереп ясалган өстәл өстенә тезә башлады.

Ризык исен сизгән мәче нишләргә белмәде. Түземсезләнеп әле Галиянең аяклары арасында буталып йөрде, әле ике тәпиенә генә басып, муенын өскә, өстәлгә таба сузды, әле ал тәпие белән авыз тирәсен сөрткәндәй итте...

Сөтле чәйне термостан кечкенә тәлинкәгә агызган вакытта, мәче бер зур кисәк колбасаны ялт иттергән иде. Аның, теле белән авыз читен ялап, «Тагын юкмы соң?» дигән кебек карап торганын күргәч, Галия янә бер кисәк колбаса бирде.

Тәмам ачка интеккән икән мескенкәй — колбаса күз алдында гаип булды. Йомыркага да чират җитте.

Ач мәчегә сөтле чәй дә тансык иде...

Шул көннән соң мәче, Галиянең киләсен әллә каян сизеп, бакчада көтеп тора торган булды. Сизеп дип... Кем белә, бәлки, ул Галияләр килмәгән көннәрне дә аларның бакчасында яшәп яткандыр. Читкә-санга сугылып йөрмәгәндер. Шулайдыр... Шулай булгандыр әле...

Шык-шык!.. Мөкаддәс балконда кайнаша. Балконга тәрәзә куймакчы. Урам як бит. Тавыш каты ишетелә. Тәрәзә арасына тузан-корым да кереп сылана аннары соң...

Чаж-чыж!..

...Бакчага төшкәч, Мөкаддәс, мәчене күрүгә:

— О, безнең бомж! Дүрт аяклы дәрвиш! — дип сөрән сала.

Кайчагында:

— Сәлам, Мырыйсабыйль! — дип тә эндәшә, «Байлар да елый» киносындагы Марианна белән Луис Альберто тәрбиягә алып үстергән Марисабельгә үзенчә шулай ишарәләве инде.

— Дәрвиш, димә, Мөкаддәс. Җан иясе бит ул да! — дип каршы төшеп карый аңа Галия. Көлә генә Мөкаддәс. Нигәдер мәчеләрне яратмый ул. Шул, әлеге дә баягы, авылда үскәнгәдер инде.

— Мәче — йорт хайваны ул. Ә йорт хайваны авылда яшәргә тиеш. Рәхәтләнеп яшәсен шунда. Яңа сауган сыер сөте эчсен. Тычкан тотсын. Эшләп ашасын. Шәһәрдә болай да ялкаулар җитәрлек! — ди Мөкаддәс.

Аның мәче халкына карата фикере шулай катгый. Шуңа күрә фатирда мәче асрау хакында хыяллана да алмый Галия. Сүз кузгатып карамады түгел анысы...

— Бүгенге заманда кибеттән үзеңә ашарга ризык алалсаң ярый әле. Артык тамакның кемгә файда китергәне бар? — дип кырт кына кисте Мөкаддәс.

Җитмәсә, Мөкаддәснең сүзен куәтләгәндәй, соңгы вакытларда гәҗитләрдә «Эт-мәче асраган өчен хуҗаларыннан салым алырга кирәк» дигән язмалар күренә башлады. «Хәерчегә — җил каршы» дигәннәре менә шул буладыр инде ул.

«Җәен бакчада җылы, ничек тә яшәр, менә көзге суыклар башлангач, кыш килгәч нишләр Марисабель?» — дип еш борчылды Галия. Әйе, Мөкаддәс мәчедән «Мырыйсабыйль» дип көлгән көнне, Галия дүрт аяклы ятимгә Марисабель дип исем кушты. Мәче дә үз итте, яратты исемен.

Галия:

— Марисабель, табын әзер! Ашарга рәхим ит! — диюгә, шул тирәдә сукыр тычканнар күзләп йөргән мәче ялт кына өстәл янына килеп җитә иде.

Иде... Урыны оҗмахта булсын инде Марисабельнең. Ни әйтсәң дә — җан иясе бит, аларга да оҗмах бардыр. Тәмугы булмаса да, оҗмахы бардыр... Бардыр, булырга тиеш...

Шыкы-шыкы!.. Шак-шык!..

Мөкаддәс эшли. Мөкаддәс тәрәзә куяр тиздән. Бүтән тузан кермәс өйгә. Тавыш та ишетелмәс. Өй эче тагын да җылы булыр. Җылы булыр... Ә Марисабель...

Өченче көн Галия бакчага барды. Калган кишер-чөгендерләрне дә алып кайтырмын, бер уңайдан Марисабельне дә күрермен, дигән иде. Күрде... Күрде Марисабельне...

...Көтәргә гадәтләнгән урынында мәче юк иде. Шул вакытта ук Галиянең йөрәге чәнчеп алган иде. Тикмәгә генә булмаган икән...

Марисабель өстәл астында, нәни тәпиләрен гәүдәсенә кысып, күзләрен йомган килеш ята иде.

Йөрәгенең кайсыдыр җирендә нәрсәдер өзелгәндәй булды Галиянең.

Марисабельнең җаны бу дөньядан очып киткән иде. Галиянең күз аллары караңгыланды... Кайдандыр, ерактан килгән тавыш колакларны телгәли:

— Мияу! Шакы-шыкы! Шак-шык... Мияу!.. Чажчыж...

Максимыч килеп җиткәнче, өйне тәртипкә китерәсе булыр. Бусы бер. Аннан соң теге азгын хатын янына барырга кирәк. Хәзер үк. Бусы — ике. Өйне кайткач та рәткә китерер. Ә менә теге хатын янына барып, аны туздырып кайтмыйча ярамый. Ятмасын әле кешенең газиз ирен аздырып! Тик менә аның өй адресын ничек белергә? Һай, баш!.. Соң, Фәйрүзә «Белешмәләр бюросы»нда эшли ләбаса. Әлбәттә, туп-туры шунда барачак Гөлсара. Ку-

решмәгәннәренә дә байтак вакыт узды шикелле. Фәниянең бәби туена килгән иде. Шуннан бирле очрашканнары юк. И өелгәндер инде, и бер кочак булгандыр инде Фәйрүзәдә яңалыклар! Бер сөйли башласа, теле-телгә йокмый инде аның. Исәнлек-саулык алуга ук, «Ишеттеңмәле, ахирәткәем...» дип сүз башлый. Аннан бертуктаусыз сөйли дә сөйли, сөйли дә сөйли... Үзе белән бергә эшләүче бер хатын турында Фәйрүзәнең сүз саен буылып көләкөлә сөйләгәнен әле дә хәтерли Гөлсара...

...Гадәттәгечә, эштән кайтышлый троллейбуска утырган бу хатын. Хатын дип, яшь әле ул. Гөлсараның аны күргәне бар. Утызлар тирәсендә генә. Кияүгә чыкмаган. Ул көнне ап-ак, озын күлмәк кигән булган бу. Ниндидер Мәһдиевнең, диме шунда, шундый бер язучының инде, китабын бик мавыгып укып кайтышы икән. Янәшәсендә урын буш булган. Бер тукталышта троллейбуска яшь кенә ир-егет кергән. Үзе исерек, ди. Килеп утырган бу моның янына лып итеп. Утырган да кызыйга карап авызын җәйгән дә. Янында яшь хатын бит. Яшь хатынга кем кызыкмый инде. Исерек кеше бигрәк тә. Хет янында бичура корткасы үзе утырсын, аңа да елмая ул исерек. Бу елмаеп кына калмаган, әчегән шәраб, тозланган кильки балыгы исләре аңкытып, моңа сүз дә каткан. Башта кызый ишетмәмешкә салынган. «Мин сине кайдадыр күргәнем бар» дип, теге бәйләнчек сагыз кебек ябышкан моңа. Исерекнең бытылдавыннан колаклары тонган кызый, китабыннан аерылып, сәрхушкә күтәрелеп караган да:

— Иптәш, бәйләнмәгез әле! — дигән. Теге аның саен бәйләнә икән. Исерек кешегә бер сүз әйттеңме — хет уңай, хет кире сүз — һич туктатырмын димә инде...

Исерек булса да, теге ир-егет бик чибәр икән үзе. Әртист Равил Шәрәфинең яшь чагы шикеллерәк. Кызыйның да сөйләшәсе килә башлаган башлавын берзаман... Ләкин...

Кызыгы шул. Болар шулай кирле-мырлы әйткәләшеп барган бер вакытта, кинәт кызый агарынып каткан — нәрсәдер ни то. Йомшак җир тирәсендә...

Сәрхуш һаман бытылдый да бытылдый икән. Ә кызыйда аны тыңлау да, китап уку кайгысы да калмаган. «Йа Хода! Вакытсыз башланды бит!» дип кенә уйлый алган ул. Шулай уйламый хәле юк — асты һаман җылынганнан-җылына икән моның. Кызый, сиздермәскә тырышып кына, күлмәк итәкләрен рәтләштергәндәй иткән. Бармак очлары юешкә тигәч...

Ярый әле теге исерек үз тукталышына җиткән булган. Йөзләре агарып каткан кызыйга сәерсенеп карап:

«Бер очрашырбыз әле, Мона Лиза!» — дигән дә, чайкала-чайкала, троллейбусның ачык ишегеннән төшеп калган. Энә очында гына утырып барган кызый икенче тукталышта ук — ялт! — артына китабын каплаган килеш очып чыккан...

Өенә кайткач, күлмәген салып караса... Ни күзләре белән күрсен — ап-ак күлмәкнең арткы өлешендә аш тәлинкәсе хәтле кызыл тап икән! Соңыннан ачыклаган ачыклавын... Теге сәрхушнең чалбар кесәсендәге шешәсеннән кызыл шәраб аккан булган...

Гөлсара, әлеге мәзәк хәлне исенә төшереп, үзалдына көлеп куйды. «Барырга кирәк, хәзер үк барырга кирәк Фәйрүзә янына!» Ул аякларына затлы итекләрен кияргә булды. Чит илнекен, Италиядә тегелгәнне. Ул аларны сирәк кия киюен... Бәйрәм-сәйрәм көннәрне генә. Бүген бәйрәм түгел түгелен. Әмма Гөлсара шуларны киячәк. Теге себерке өенә чегән хатыны кебек киенеп-ясанып кына барып булмый. «Беткән хатын икән бу, хәерче икән!» дип уйламасын әле, явыз тәре. Баргач-баргач, шәп киенеп барырга кирәк. Сүз белән, хәрәкәт белән генә түгел, затлы киенгән булуы белән дә изәчәк-сытачак аны Гөлсара...

* * *

...Садрый кинәт туктады. Туктале, ә ул кая бара? Эшкәме? Юк. Бүген аның ял көне булырга тиеш. Әйе, кичә сишәмбе иде, бүген чәршәмбе, димәк, эшкә аңа иртәгә генә чыгасы. Хәер, иртәгә әле эшкә булырмы, әллә хуҗа үз бакчасына алып китәрме? Мөгаен, шулай булыр да. Ансаф Галәветдинеч үзе әйтте бит, аның җилкәсенә дустанә сугып әйтте:

— Садрый Шәүкәтевич,— диде,— синең алтын кулларыңа тагын эш чыгарга тора әле,— диде.— Егетләр икенче катны бетерделәр, тәрәзәләр сине көтә,— диде. Садрый, хуҗаның үзенә шулай җылы мөгамәлә белән дәшүеннән күңеле булып, борын аслары куыкланып торган пионерлар шикелле:

— Мин һәрвакыт әзер, Анфас Галәветдинеч! — дигән иде.

Анфас Галәветдинеч, елмаеп:

— Шундый булганың өчен хөрмәт итәм дә инде мин сине, Садрый Шәүкәтевич! Эшкә синдәй атлыгып торучылар сирәк бит бу заманда. Шулай бит?! — дип, аны тагын да үсендереп җибәрде.

Садрый, карт солдат шикелле үрә катып, авызлары

ачылган ботинкаларының үкчәләрен бер-берсенә шыкылдатты:

— Так точно, Анфас Галәветдинеч!

Анфас Галәветдинечкә Садрыйның шулай шаярып җавап кайтаруы ошады, ахрысы, ул төшеп китүдән чалбар каешы гына тотып торган дәү корсагын дерелдәтә-дерелдәтә хахылдады. Хуҗаның канәгатьләнеп көлүенә Садрый да кушылды. Дөрес, Анфас Галәветдинечнең «ДТ-75» тракторы шикелле тырылдый-тырылдый хахылдавы янында аның, Садрыйның, моторлы вилсәпид кебек пытырдавы пышыйк чыкты анысы.

— Ну әртист! Ну әртист тә инде үзең, Шәүкәтевич! — диде хуҗа, көлүеннән туктый алмыйча.— Сиңа әртист буласы гына калган, Шәүкәтевич... Әртист...

— Кая инде ул безгә — каткан тезгә әртист булу, Анфас Галәветдинеч... Бездәйләргә балта остасы булсаң да бик җиткән...

— Во! Менә монысын дөрес әйттең! — Хуҗа сосискины хәтерләткән имән бармагын югары чөйде.— Миңа әртист түгел, балта остасы кирәк! Син кирәк, Шәүкәтевич...

Анфас Галәветдинеч кабартма кулы белән аның җилкәсеннән янә кагып алды.

— Йә, ярар, Садрый Шәүкәтевич,— диде ул,— мин сиңа хәбәр бирермен...

Шулай диде дә хуҗа, аю шикелле лап-лоп атлап, китеп барды...

Әйе, иртәгә хуҗаның дачасына барасы булыр, мөгаен... Хуҗа гына кире уйламаса. Юк, уйламас. Садрый узган барганында, Анфас Галәветдинеч: «Кышка кергәнче төреп бетерәсе иде инде йортны»,— дип сөйләнде бит...

Ә бүген нишләргә? Хатынына да шылтыраталмаган бит әле ул. Кичә өйгә кайталмавы турында аның алдында ничек акланасы булыр. Бер Ходай үзе генә белә...

Ул Болак күпере култыксасына сөялде. Култыксага ат башы чаклы хәрефләр белән «Мы были, есть и будем булгарами!» дип язылган иде. «Сәламәтлек» мунчасының сыраханәсенә кереп сыра эчәргәме соң әллә? Теге бер тәңкәгә ике бокал сыра җилпесәң, ә?! Шулай итмичә дә булмас...

— Ха! — Садрый портфельсез кулы белән култыксага сугып алды. Әгәр дә ул хатынына: «Анфас Галәветдинеч дачасында кунып калырга туры килде. Эш күп булды»,— дисә? Шәп! Садрыйның күңеле күтәрелеп китте, барлык борчулары юып алынгандай юкка чыкты...

«Шәп фикер бит бу, нәгаләт!..»

Гаҗәп, сыраханәдә кеше аз иде. Бәләкәй буйлы, кы-

зыл чырайлы бер адәм, ярты литрлы банкасын ике кулы белән тоткан килеш, комсызланып, сыра чөмерә. Үбешү ләззәтен кичергән хатын-кыз шикелле күзләрен йомган үзе. Дон Кихот белән Санчо Пансоны хәтерләткән ике егет, банкаларындагы сыраны ара-тирә йоткалап, бер тәмәкене алмаш-тилмәш суыра-суыра, гәп куерта.

— Я та-а-ак долбанул одному верзилу... Тот сразу кәпис... вдребезги! — ди берсе, озыны, Дон Кихотка охшаганы.

— Мин дә кичә тоже берәүгә ямадым. Потом карыйм, мой сосед булып чыкты. Ты знаешь аны, дядя Петьканы. Керәшен. Ну, потом с ним опять бер бутылканы сындырдык,— ди Санчо Пансо.

Шомбай кыяфәтле бер карт калтыранган куллары белән махра төреп азаплана. Дөньяда гаме юк кеше шикелле авызын ерган... Бер аягын икенчесе өстенә куеп, терәткечсез урындыкта утырган сыра сатучы егет битараф кына сигарет төтәтә иде. Үзе берөзлексез сагыз чәйни.

— Пиво есть? — дип сөаль бирде аңа Садрый.

Егет кулы белән стенадагы язулы калайга ишарәләде. Анда «В продаже имеется пиво. «Ячменный колос» дип язылган иде.

Садрый сыра бәясенә игътибар итмәде. Сатучы егет урындыгыннан торды да, Садрыйга ымлап:

— Сколько? — диде.

— Две кружки,— диде Садрый һәм йомарланган кәгазь берлекне кесәсеннән алды да, аны рәтләштергәләп, өстәлгә кадакланган калай тәлинкәгә салды.

— Ты че, мужик? — Сатучы егет краннан ярты литрлы ике банкага да сыра агызып өлгергән иде.

Ул, ачулы карашын Садрыйга төбәп, янә:

— Ты че, мужик? — диде.

— Ничего,— диде Садрый, ни булганын аңламыйча.

— С луны, что ли, свалился?

— А что случилось? — диде Садрый.

— Да ты хоть знаешь, козел, сколько стоит кружка пива?

— Знаю, сорок копеек.

Сатучы егет калай тәлинкәдәге кәгазь берлекне алды да Садрыйның йөзенә ыргытты:

— Пошел вон, старый козел!

Ни булганын тәки аңламаган Садрый, идәндәге кәгазь берлекне иелеп алырга да онытып, ишеккә таба атлады.

Кәгазь берлек Шомбай кыяфәтле карт кесәсенә күчте.

Садрый тышта, сыраханәдән читтә исәнгерәп торган

бер вакытта, аның яныннан таныш түгел бер егет белән Ишнияз сыраханәгә таба үтеп китте. Юлдашына карап сөйли-сөйли, кулларын җил тегермәне шикелле әйләндерә-әйләндерә килгән Ишнияз Садрыйны шәйләмәде:

— Чигәгә чуан чыккан иде... Столбищедагы таныш врачка иртүк шуны ярдырырга бардым...

Садрый нишләргә, кая барырга белмичә тора иде, кемдер сүз катты.

— Закурить есть?

— Ә? — диде Садрый тавыш хуҗасына, ыспай гына киенгән егеткә карап.

— Закурить есть? — дип кабатлады егет.

— Не курящий! — диде Садрый, үзе ни әйткәнен белештермәстән...

* * *

Галия күзләрен ачты. Мөкаддәс һаман балконда икән әле, шакылдаган тавыш сирәк-мирәк ишетелгәләп куя. Ул стенага эленгән яшел кыршаулы сәгатькә күз төшерде: бәй, төш вакыты җиткән икән бит инде. Ике сәгать чамасы йоклап алган түгелме соң ул?! Шулай шул. Һай, Ходаем, Мөкаддәснең карыны ачкандыр инде. Ни дә булса хәстәрләргә кирәк.

Галия хәлсез гәүдәсен урыныннан кузгатты: «Аһ, Марисабель, Марисабель...»

Ак мәче аның уйларына һаман тынгылык бирмәде.

Софа янындагы кәнәфидән халатын алып киде Галия, урын-җирне җыештырды. Телефон штепселен тоташтырырга кирәклеге исенә төште. Вакытлы-вакытсыз борчымасын, шылтырап Галиягә комачау итмәсен дип, Мөкаддәс кичә кич телефонны өзеп куйган иде.

Хатын телефон бавын кулына алды. Штепсель тоташтырылган иде. «Мөкаддәс мин йоклаган чакта тоташтырып куйгандыр инде»,— дип уйлап алды ул... Ә юк! Иртән кемдер шылтыратты бит. Әйе шул. Ниндидер хатын-кыз тавышы «Мунчамы бу?» дип сорады. Галиянең исенә төште: штепсельне бит ул әлеге хатын-кыз ялгышып шылтыратканга кадәр үк үзе тоташтырган иде.

«Марисабель турында гел-гел уйлап, нәрсә эшләгәнеңне дә белмәссең!..» — Галия юыну бүлмәсенә таба атлады.

Нәкъ шул вакыт ишектә кыңгырау чыңлады.

Галия, чылбырны келәдән ычкындырып, ишекне ачты.

Тышкы якта башына көрән эшләпә, өстенә чит илнеке икәнлеге ярты чакрымнан күзгә төртелеп торган яшькелтсу куртка-пәлтә кигән, кулына затлы ридикюль тот-

кан бер хатын басып тора иде. Йөзендә ниндидер ясалма, төче елмаю.

— Исәнмесез! — диде ят хатын.

— Исәнмесез.

— Сез Галия Кәбировнамы?

— Әйе, мин булам,— диде Галия.

— Ә мин Гөлсара... Садыйковна. Бәлки, ишетеп беләсездер?

— Гафу итегез, бер дә хәтерләмим...

«Беләсең, эт, юри белмәмешкә салынасың,— дип уйлады Гөлсара.— Минем турыда Мәхмүт бер генә түгел, мең тапкыр сөйләгәндер әле син себеркегә...» Ишекне тибеп керәм, дип адарынган Гөлсара Галиянең агарынган йөзенә, хәлсез генә чыккан тавышына әле генә игътибар итте. Шуңадырмы, бермәл сүзне нидән башларга белмичә торды.

— Мин... миңа... минем сезнең белән сөйләшәсе бар иде,— диде ул, ниһаять, Галиянең күзләренә туры карап.

— Рәхим итегез. Әйдәгез, узыгыз! — диде Галия.— Пәлтәгезне менә монда элегез.

«Аһ, юха елан! Кобра! Хамелеон! Аждаһа! Әртистләнеп маташа бит әле, җитмәсә!» — Гөлсараның күңелендә буран уйный, ләкин ул аны ни сәбәптәндер тышка чыгара алмый.

Гөлсара, ашыкмыйча гына, үз дәрәҗәсен белеп кенә, пәлтәсен, эшләпәсен кием элгеченә элде, ридикюлен кулына алды.

— Бирегә, залга рәхим итегез,— диде Галия.— Менә монда утырыгыз.

«Тәмле телләнеп сөйләшкән була бит, кабахәт!» — Гөлсара эченнән шулай тузынса да:

— Рәхмәт! — димичә булдыра алмады.

Ул диван-караватка утырды, балкон тарафыннан шакылдаган тавыш ишетеп, шул якка борылды.

— Минем ирем ул. Мөкаддәс балконда тәрәзә куя,— диде Галия, ят кунак алдында үзен нигәдер уңайсыз хис итеп.

«Ирем, диме, димәк, ире өстеннән йөри...» — Гөлсара кулын кушырып басып торган Галиягә карады.

— Бик әйбәт. Ireңнең...— Гөлсара «иреңнең» сүзенә аеруча басым ясады.— Анда булуы яхшы... Әлегә... Кирәксә, чакырырмын...

Галия ят хатынның шундый тонда сөйләшүеннән сискәнеп куйды: «Ни кирәк бу хатынга? Ни тели ул?»

— Тыңлыйм сезне.— Галиянең тавышы баягыдан да хәлсезрәк, сыеграк чыкты.

— Сүзне турыдан бәреп әйтергә яратам мин. Табигатем шундый! — дип сүз башлады Гөлсара.— Кайчан сез миннән издеваться итүдән туктыйсыз?

— Ничек? Ничек... издеваться итүдән? — диде Галия, көтелмәгән сораудан аптырап. Гөлсара «син»гә күчте.

— Син минем ирем белән шухыр-мухыр эшлисең икән. Качып-посып гыйшык-мыйшык уйныйсың икән...

— Сез... сез... ни сөйлисез сез?

Галиянең теле тотлыкты.

— Әһә! Туры әйткән туганына ярамаган! Коелып төштеңме? Димәк, дөрес икән!

— Сез... сез нахак бәла ягасыз...

— Хакмы, нахакмы, әмма мин шуны беләм: син минем ирем белән йөрисең! — Гөлсара балкон тарафына ымлады.— Ирең беләме? Хәер, белмәсә — белер. Белгертербез.

— Сез... ни сөйлисез? Берни дә аңламыйм.

— Аңлыйсы-нитәсе юк. Буласы булган. Башыңны җүләргә салып, әртист булып кыланма! Әйт дөресен: кайчанга кадәр барачак бу хәл? Канса-крае булачакмы моның? Кайчанга кадәр сез икәүләп миннән издеваться итәргә уйлыйсыз?

Әлегә кадәр берни дә аңламаган Галия үзен кулга алырга тырышты:

— Сез... сез... гөнаһ сүз сөйлисез.

— Ачуымны китереп боргаланып-нитеп торма, ичмасам. Нахак бәла, гөнаһ сүз, имеш... Әйт тә бир дөресен «Йөрдек!» диген, «Йөрибез!» диген... Аннан соң сезне ничек адәм мәсхәрәсе итәргә кирәклеген үзем белермен...

— Сезнең... соң... ирегезнең исеме ничек? — диде Галия, бүтән ни диярга дә белмичә.

— Сорап торган була тагы! Аның Мәхмүт икәнен син караватка җәелеп ятканчы ук белгәнеңне белмиләр ди монда.

— Сез... сездән... чамалап сөйләшүегезне сорыйм...

— Сорыйсы-нитәсе юк... Барысы да ачык монда!

— Мин бернинди дә Мәхмүтне белмим,— диде Галия.— Сез мине кем беләндер бутыйсыз, ахры...

— Бутамыйм, бутамыйм. Кем белән сөйләшкәнемне бик белеп сөйләшәм.

— Шулай да...

— Качышлы уйнап маташма. Ирем әйтте инде миңа. Хәтта сине «хатыным» дип атады, кабахәт.

— Булмас! Ирегез башка хатынны күздә тоткандыр.

— Тотты ди, тотмый ни! Юк инде, җанкисәккәем! Менә бу телефон номеры белән ул үзе минем күз алдымда

сиңа шылтыратты.— Гөлсара, ридикюленннән телефон номеры язылган кәгазь кисәге алып, аны Галиянең кулына дорфа гына төртте.— Шушы номер белән мин үзем дә шылтыраттым. Трубканы үзең алганыңны оныттың дамыни? — Кәгазьдә, чыннан да, Галияләрнең өй телефоны номеры язылган иде.

— Сез... сез... ничек... кайчан шылтыраттыгыз?

— Кайчан булсын — бүген!

— Бүген безгә беркем дә шылтыратмады...— диде Галия.

— Ничек шылтыратмасын?! Ә кем мунчаны сорады?

— Ул ... сез идегезмени?

— Мин булмый, Алланың кашка тәкәсе булсынмыни тагын! Борын астыннан сөекле иреңне алып китә башласалар, үзең нишләр идең микән әле?

— Барыбер берни дә аңламадым.

— Менә хәзер иреңә әйтсәм, ул бер сүздән аңлаячак! — Гөлсара, ярсып, урыныннан тора башлады.

Галия, кабаланып, аның янына килде:

— Юк, юк, әйтә күрмәгез берүк!

— Әһә, шөлләдеңме? Димәк, дөрес! — Гөлсара тантаналы елмайды.

— Әйтмәгез, зинһар. Аның... Мөкаддәснең йөрәге сау түгел...

— Алдыңны уйлаганчы, артыңны уйларга иде элек! — Гөлсараның елмаюы зәһәр төс алды.— Мондый эшне яшереп калып булмый шул, туганкаем...

— Зинһар, дип әйтәм...

— Без бит хәзер туганнар, шулай бит?! Икебезгә — бер ир. Дөрес, синең икәү бит әле...

Шул вакыт телефон шылтырады.

* * *

...Бу фани дөньяда шушы яшенә җитеп, Садрыйның болай адәм мәсхәрәсенә калганы юк иде әле. Теге тилемсә хатын, ни сөйләгәнен үзе дә белмичә, аның башын бер катырды. Җитмәсә, Ишнияз аны «Мәхмүт» дип икенче мәртәбә шаккатырды... Инде сыраханәдә тагы... Сатучы егет тиктомалдан аңа акыра башлады. Эчкәнгә күрә дулыйдыр дияр идең, егет бер дә салмыш кешегә охшамаган иде. Берни аңлашылмый торган хәерсез көн булды бу!

Садрый, борылып, сыраханәгә, аннан ерык авызын кул аркасы белән сөртә-сөртә чыккан Шомбай кыяфәтле картка карашын ташлап алды да Бауман урамына таба атлады...

Чаттагы «Икмәк» кибете ишегеннән аңкып чыккан яңа ипи исе, Садрыйның ашыйсын китереп, киңәйгән борын тишекләрен кытыклады. Садрый, үзе дә сизмәстән, кесәсендәге кәгазь берлекне капшады.

— Нәгаләт! Аның акчасы, бердәнбер берлеге сыраханәдә калды лабаса.

Садрыйның эче сызып куйды. Акчасы юклык аның ашыйсы килүен отыры көчәйтте. Ул кибет турыннан тиз-тиз генә китү җаен карады.

Үзәк мәйданда, моңарчы Садрый күрмәгән, әллә күреп тә игътибар итмәгән берничә калай киоск янында, сары чәчле бер юантык марҗа, казан чаклы зур мискидән өчпочмак сатып тора иде. Садрый, ул тарафка карамаска тырышып, җир асты юлына төште.

Хикмәти Хода! Менә кайда икән ул умарта күче!

Кулларына чәчәк бәйләме тоткан әби-чәбиләр, түтиләр, кызлар үткән-сүткәнгә тәмле телләнә:

— Алып җибәр, апаем!

— Бири, бири, дишува даю!..

— Пирмәчи с рисым-мәсем!

Яшь-җилкенчәкләр бер тирәгә өелешкән. Нәрсә саталар микән дип, Садрый борынын шунда сонды. Озынча катыргы өстәлгә төрлечә кыландырып төшерелгән шәрә кызлар сурәтләре, әллә ниткән эреле-ваклы китапчыклар, гәзит-журналлар тезелгән иде.

Борынының бер тишегеннән аксыл куыгы күренеп-күренеп алган бер үсмер «Эротикон» дигән журнал сатып алды. Илле тәңкәгә. Садрыйның гаҗәпсенүдән күзләре маңгаена менде. Балта сабы кадәрле әтрәк-әләм малайның шулхәтле акчага дәфтәр калынлыгы журнал сатып алуына таң калды Садрый. Бер уч тутырып сагызмазар сатып алган булса ул малай, Садрыйның моңа әллә ни исе дә китмәс иде. Юк бит. Бу бит, «әһ» тә итмичә, фырт яңа ике егерме бишлек чыгарып, шәрә кыз сурәтле журнал ала. Җитмәсә, ул «балта сабы»ның акчасы да ул гына түгел иде бугай...

Әйе, үзгәрә замана, үзгәрә...

Садрый ары китте. Китте дип, китеп өлгерә алмады, борылды гына. Ике-өч адым читтә, нәкъ уртада, йөзен сакал-мыек баскан бер таза гәүдәле адәм бетон идәндә аякларын үзбәк карты шикелле бөкләп утыра иде. Хәер сораган кеше кебек, уң кулын алга сузган иде. Төссез, нурсыз күзләрендә ниндидер ялвару галәмәте чагылып-чагылып ала...

«Әллә бу хәер сорый инде?» — Садрыйның тәне кымырҗып куйды. Әйе шул, хәер сорый бу, теләнеп утыра.

Әнә бит тәти генә киенгән бер хатын әлеге сакалбайның сузылган кулына кәгазь акча төртте.

Сакалбай телсез кеше сыман, сүзсез генә башын иеп алды. Күрәсең, үзенчә шулай рәхмәт әйтте булса кирәк.

Садрый, сакалбай яныннан үтеп китүгә, янә шундыйрак бер адәмгә тап булды. Монысы стена янына утырган. Алдында ямьшәйгән бүрек. Бүрек эчендә берничә кәгазь акча күренә. Хәер сорашучының бусы да сакал-мыеклы иде. Ләкин монысының сакалы озын да, чаларган да. Менә ул таушалган чалбар кесәсеннән фильтрлы сигарет тартып чыгарды. Бер кулына мөштек тотты. Сигаретның фильтрын сындырып, үз янындагы чүп савытына ыргытты. Аннан соң мөштеген каккалагандай итте дә эченә сигаретны тыкты, шырпысын кабызды...

Әйе-е-е... Бар икән монда хәлләр. Җир астында хәлләр бар икән. Өстә бер дә күренми бит болар. Тормыш өстә генә бара, дип уйлап ялгышкан икән бит Садрый, ялгышкан. Баксаң, ул аста да бара икән...

Садрыйга һава җитми башлады. Ул, бу җир асты шәһәреннән ничек тә тизрәк өскә чыгу уе белән, каршысындагы көн яктысы төшкән баскычка таба атлады...

Өстә, ни әйтсәң дә, һава сафрак иде. Суларга җиңел иде һава. Садрый, аптыраган үрдәк арты белән суга керә, дигәндәй, болай гына, тиктомалдан гына «Балалар дөньясы» кибетенә сугылып чыгарга булды. Өйгә кайтканчы ничек тә вакытны үткәрергә кирәк бит инде.

Туктале, ә нигә болай киләп сарып йөрергә соң? Тотарга да хатынга шылтыратырга кирәк. Сүксә сүгәр, тетсә тетәр Галия. Һәрхәлдә, үтермәс әле...

Кайтырга кирәк...

«Балалар дөньясы» ишегеннән эчкә узуга, Садрый, бүре күргән шикелле, шып туктап калды: идәннең капылт уртасында әлеге дә баягы Шомбай кыяфәтле карт хәер сорап утыра иде. Нәрсә соң бу? Казанга чәчкәннәрме соң әллә моны? Сәҗдәгә киткәндәй утырган картка сәерсенеп карый-карый, түргә узды Садрый.

«Балалар дөньясы» залындагы телефон янына килгәч, ул янә акчасы юклыгын исенә төшерде. Ярый әле телефон аппараты янына язып куелган калай язуга игътибар итте. Анда «Звоните. Бесплатно» дип язылган иде.

«Коммунизм бит бу! Хрущев теге дөньядан терелеп кайткан мәллә?»

Садрый, бу хәлгә тагын да гаҗәпләнеп, ышаныр-ышанмас, телефон номерын җыйды.

— Алло! Алло! Галия, синме бу?

— Әйе, тыңлыйм сезне. Кем әле бу?
— Бу — мин. Садрый. Кичә...
Галия аны бүлдерде:
— Кем дисез? Садрый?!
Гөлсара сагайды.
Садрый тавышы:
— Әйе инде. Танымыйсың мәллә? Кичә мин...
— Сез кем соң? Мин сезне белмим бит.
Садрый тавышы:
— Тилегә салынма инде, Галия. Бу — мин, ирең...
Галия:
— Карале, иптәш, сез кемгә шылтыратканыгызны белеп шылтыратасызмы соң?
Гөлсара:
— Белеп шылтырата инде, кабахәт, белеп шылтырата. Кыланып маташмагыз. Сора лутчы, каян шылтырата ул мәхлук?
Садрый тавышы:
— Сүксәң сүк, тетсәң тет, Галия... Кичә миңа Анфас Галәветдинеч бакчасында кунып калырга туры килде. Эш күп булды.
Галия:
— Анфас Галәветдинович? Ә сез аны каян беләсез?
Садрый тавышы:
— Галия, дим... Кыланма инде. Хуҗа бакчасында кундым дим бит. Төнгә хәтле эшләдек.
Галия:
— Иптәш, кем... Садрый, сез каян шылтыратасыз?
Гөлсара:
— Ну кыланып та күрсәтәсең инде. Күзгә карап төтен җибәрәсең бит, ә?
Садрый тавышы:
— Үзәктән. «Балалар дөньясы»ннан. Галия, дим...
Галия Гөлсарага борылды:
— Минем аңлавымча, бу сезнең ирегез бугай...
Садрый тавышы:
— Галия, дим, Галия!..
Гөлсара:
— Соң! Шул булмый кем булсын инде тагы... Әйт, әйт, курыкма. Сагындым, Мәхмүтем, диген... Фәлән җирдә очрашабыз, диген...
Садрый тавышы:
— Галия, дим... Мин хәзер кайтам...
Галия:
— Тыңлагыз әле, кем... Садрыймы сез, Мәхмүтме. Миңа барыбер... Монда сезнең хатыныгыз утыра. Килсәгез

бик әйбәт булыр иде. Әгәр адресны белсәгез... Какрас ирем дә өйдә. Ачыкларбыз...

Садрый тавышы:

— Ни сөйлисең син, Галия? Нинди хатын? Нинди ир?

Галия:

— Сезнең хатыныгыз. Кем әле, гафу... Гөлсара... Гөлсара Садыйковна биредә. Ирем Мөкаддәс тә өйдә...

Гөлсара:

— Чакырыгыз, чакыр. Килсен. Бик әйбәт булыр.

Садрый тавышы:

— Гөлсара?! Мин андый хатынны белмим. Ничек бездә ул?..

Телефонда тынлык урнашты.

Галия:

— Алло, алло!..

Телефон өзелде.

— Сезнең исемегез тәэсир итте бугай. Куйды трубканы,— диде Галия.

— Иткәндер шул. Сөяркәсе өендә хатыны утырсын әле! — Гөлсара баягы урынына барып утырды.— Мәсьәлә тәгаен ачыкланды. Пичәт кенә сугасы калды.

— Ни сөйлисез сез һаман? — Кинәт Галия ике кулы белән башын тотты.— Әйтегез әле,— диде ул, шулай беравык тын торгач,— сезнең ирегез кайда эшли?

— Доцент, университетта укыта. Хәер, син аны үзең дә бик шәп беләсең. Ә нигә сорыйсың әле?

— Университетта?! Ә ул каян белә минем иремнең исеме Садрый икәнен? Анфас Галәветдиновични каян белә?

Гөлсара янә колагын сагайтты:

— Ничек инде — «Иремнең Садрый икәнен?..» Моны ни дип аңларга? Синең тагын бер ирең бармыни? Ай-һай, бай хатын булып чыктың бит син, алайса... Әле генә ирењне Мөкаддәс, дидең... Инде менә хәзер Садрый димәкчесең...

— Садрый ул минем беренче ирем иде,— диде Галия.

— Аерылыштыгызмыни? — дип көлемсерәде Гөлсара.

— Юк. Үлде ул. Ике ел элек...

Галиянең сүзе шунда бүленде. Балкон ишеге ачылды, аннан Мөкаддәс күренде.

* * *

«Тәки теге явыз хатын барып кергән икән өйгә. Әллә ниләр сөйләгәндер инде. Хәзер ничек Галиянең күзенә күренергә? Нindидер язучы әйтмешли, едва ли хәзер өйгә кайтулар? Галиянең үз-үзен тотышы аңлашылмый. Ят кеше кебек сөйләште. Теге хатын булганга гына шулай

сөйләштеме ул? Белмәссең... «Ирем дә өйдә»,— дигән булды. Нигә кирәк инде монысы тагы. «Син гүләйт итсәң, мин дә тик тормыйм!» — дип әйтергә теләве микән? Шулайдыр. Мөгаен, шулайдыр...

Аһ, явыз хатын! Дөньяны тәки бутады бит. «Үз дигәнемә ирештем»,— дип сөенгәндер инде, юан мичкә. Каян белде икән ул өй адресын? Телдән бернинди дә адрес-мазар ычкынмады бит югыйсә. Вәт шайтан хатын... Телефон номерын хәтерендә калдыргандыр әле. Хәтерләсә, мондый хатынга өй адресын белү пүчтәк кенә инде анысы. Әйе, нәкъ шулай булгандыр әле ул.

Хәзер нишләргә инде? Өйгә кайтам дисәң дә кайтырга ярамый хәзер. Ярамый. Тимбулье, теге хатын да өйдә чакта. Кайчан чыгып китә әле ул... Эт белгән...»

Садрыйның тешләре бердәм сызлый башлады. Әллә «хөкүмәт» тешләре дә сызлый инде? Мондый хәерсез көнне тимер тешләрнең сызлавы да бер дә гаҗәп түгел.

Садрый, «Балалар дөньясы»ның җил ишегеннән кергән кешеләргә бәреләсугыла, урамга чыкты.

Бүген вокзалда кунарга туры килер микәнни?..

Юк-барга баш катырудан ни мәгънә соң әле. Кичкә кадәр күпме вакыт бар.

Садрый сәгатенә күз салды: төш җиткән икән бит!

Ә ул әле авызына бер тәгам ризык капмаган...

Кәгазь берлек янә искә төште.

* * *

Мөкаддәсне күрүгә, Гөлсара урыныннан сикереп торганын сизми дә калды.

— Син?!

— Гөлсара?! Син ничек монда? — Мөкаддәс сул күзен челт-челт йомгалап алды. Аның гел шулай, әүвәлге берәр танышын очратса яисә көтелмәгән хәлгә тарыса, сул күзе шундук «кәртечкә»гә төшерә башлый.

Галия моны искәрде: димәк, болар элекке танышлар. Әмма икесенең дә йөзләренә чыккан гаҗәпләнү билгеләренә караганда, гади танышлар гына түгел...

— Мин — мин... Ә син үзең ничек монда әле? — диде Гөлсара.

— Мин... монда яшим! — диде Мөкаддәс һәм үзенә сынап диярлек карап торган Галиягә елмайды. Көтелмәгән бу хәлдән кулларын кая куярга белмичә аптырап торган Галия шул мизгелдә үзен артык кеше итеп тойды. Ул Гөлсарага «Кара аны! Чамалап сөйләш!..» дигән караш ташлап алды да:

— Гафу итегез... Сез сөйләшә торыгыз... Мин хәзер чәй куеп җибәрәм,— дип, кухняга атлады.

Кухня ишеге ачык калды. Кеше сүзен тыңлап тору — түбәнлек анысы, әмма Галия бу икәүнең сүзләренә колак салмыйча булдыра алмады...

— Ә Нәркисә? Кызың да бар иде бит. Алар кайда? — диде Гөлсара.

Мөкаддәс тирән итеп сулыш алды: «Юри кыланамы соң бу?..»

— Ник басып торабыз соң әле. Утырып сөйләшик,— диде ул, сорауны ишетмәмешкә салынгандай.— Безнең белән укыганнарны күргәләгәнең юкмы, Гөлсара?

— Менә сине очраттым,— дип елмайды Гөлсара. Утырды.— Тик нигәдер син минем сораудан качасың әле. Мин бит Нәркисә турында сораган идем. Аерылыштыгызмыни?

— Бер сүз белән генә әйткәндә: әйе.

— Характерлар туры килмәде, димәкче буласың инде. Ә бит сез, университетта укыганда, шәп пар идегез. Күпләр көнләште сездән.

— Ә син? Син көнләшмәдеңме?

— Үзең әйтмешли, бер генә сүз белән әйткәндә: юк! Чөнки син үҗәтне кулга ияләштереп булмасын мин күптән аңлап өлгергән идем. Аннан соң синең күзләр ул чакта Нәркисәдән башка кызларны күрми дә иде бит.

— Әйе, бар иде яшь чаклар, кесә тулы борчаклар... Үзең шул Мәхмүт белән яшисеңме?

— Шуның белән инде, шул мәхлук белән. Әле менә ниндидер маҗара чыгарып ята.

— Бервакыт ерактан гына күреп калган идем мин аны. Үзгәрмәгән. Шул килеш. Университетта укытамы?

— Укыта микән инде, студент кызларның шәрә ботына карап, селәгәен агызып утыра микән? Барып тикшергән юк. Моннан соң проверка ясамыйча булмас. Поводлар чыгара башлады инде. Моңарчы ул маймылга кем карасын дип уйлый идем, карыйлар, ахры...

Гөлсара кухня ягына карап алды.

— Мәхмүт укуга бик хирыс иде бит ул. Кызлар исемен ишетсә дә кызара иде,— диде Мөкаддәс.— Ничек кавыша алдыгыз сез, әле дә аптырыйм?

— Сүзне читкә борма әле, Мөкаддәс... Әйт әле, ник аерылыштыгыз Нәркисә белән?

— Аерылышкан — беткән... Әйдә бу хакта бүтән сүз кузгатмыйк, Гөлсара...

— Беләсе килә бит. Бер-берсен үлеп яратышканнар нилектән аерылыша икән?

— Менә көз хәзер, әйеме? Бик күпләр кышка дип, пыя-

ла банкаларга кыяр-помидор тозлап куйды инде. Кайберәүләрнең банка капкачлары атарга да өлгерде. Нигә шулай, берәүләрнең банкасы әйбәт тора, икенчеләрнеке ата?

Көтелмәгән сүз сөрешеннән аптыраган Гөлсара җилкәсен сикертеп куйды:

— Ну-у... Серкә салырга онытканнардыр... Яисә тозлаганда кирәк булган тәмләткечләрне тиешенчә салмаганнардыр...

— Шулай, һәркем үзенчә тозлый. Мин дә тозлавын үземчә шәпләп тозладым. Ләкин нәрсәнедер онытканмын, ахры...

— Ни әйтергә теләгәнеңне төшенеп бетермим, Мөкаддәс...

— Нәркисәне беркайда да эшләтмәдем. Үзең беләсең инде. Өйдә генә утырттым. Ягъни мәсәлән, тозлап тоттым өйдә. Ә ул калай капкач кебек көн саен акрынлап кабарды-кабарды да беркөнне — шарт! — атты. Домохозяйкаларның башына төрле уйлар килүчән була бит. Менә шул уйларга кайбер сәбәпләр дә өстәлсә...

— Кызганыч...

— Кызганычмы, түгелме... Кыскасы, уткән эшкә — салават, дип әйтә торган иде минем бабай.

— Ә хәзер... ничек соң, бәхетлеме син?

— Бәхет нәрсә ул? Бәхет ул, минемчә, җан тынычлыгына ирешү. Менә мин, Галия белән бергә яшәгәндә генә, җан тынычлыгына тиендем. Димәк, бәхетлемен...

Кухня ишеге яңагына сөялгән Галиянең йөзенә елмаю иңде. Ләкин озакка түгел...

— Ә бит ул җан тынычлыгын бозу өчен кайчак бер сүз дә җитә,— диде Гөлсара.— Әйтик...

Галиянең йөрәге дөп-дөп тибә башлады: «Мәрхәмәтле Ходаем...»

— ...менә синең хәзерге хатынны алыйк. Галияңне... Әйтик ул...

Галия түзмәде, кухнядан атылып диярлек чыкты.

— Мөкаддәс, чакыр кунакны. Чәй әзер! — диде ул, үзен кулга алып.

— Әйе шул. Әйе, Гөлсара, чәйләп алыйк. Мәй дә бар иде шикелле...

— Юк, юк, рәхмәт. Чәй эчеп тә, мәй эчеп тә тормыйм. Башка вакытны...— Гөлсара Галиягә мәгънәле карап алды.— Кайтыйм әле, газиз ирем өйдә зарыгып көтәдер... Әгәр җүләрләр йортына китмәгән булса...

Мөкаддәс Гөлсарага киенергә булышты.

— Тәки әйтмәдең, Гөлсара, нинди йомыш белән килгән идең соң безгә?

Гөлсара янә Галиягә карап алды. Галия кулын йөрәгенә куйды.

— Сер,— диде Гөлсара.— Хатыннарның уртак сере булырга тиештер бит, Мөкаддәс?

— Әлбәттә, әлбәттә,— диде Мөкаддәс.

— Ярый, кузгалырга вакыт. Телефон номерыгызны беләм. Шылтыраткалармын әле мин. Килгәләргә дә туры килмәгәе... Кайтып теге мәхлуктан допрос алыйм әле...

— Безнең ишек һәрвакыт ачык. Мәхмүт белән бергәләп тә килегез,— диде Мөкаддәс.

— Әйе, әйе, килегез,— дигән булды Галия дә.

— Сау булыгыз... Әлегә! — диде Гөлсара.

Ишек ябылды. Галия җиңел сулап куйды.

Мөкаддәс ишекне эчтән бикләде дә Галиягә карады.

— Уртак серегез бар, алайса? Ә син беләсеңме Гөлсараның кем икәнен? Университетта җәнҗал чыгаручы, кеше арасын бутаучы булып дан алган иде ул...

— Керүгә үк төшендем инде мин аны,— диде Галия.

— Безнең Нәркисә белән икебезнең араны да ул бутады. Хәзер дә нидер майтарырга җыена, ахры. Сак бул, Галия. Минем турында гайбәт сөйләдеме сиңа?

— Юк. Башка мәсьәлә. Синең монда икәнеңне белеп килмәгән ул.

— Сер, дисең инде, алайса.

— Сөйләрмен әле бүген. Бераздан. Кәефем яхшырсын да.

— Нучтуж, мадам, көтәбез синең кәефең яхшырганны...

* * *

Садрый Наипка сугылып чыгарга булды. «Бәлки, өйдәдер, беркая да китмәгәндер...— дип уйлады ул. Нигә элгәре үк шундый уй килмәде соң әле? Югыйсә Наип яшәгән йорт яныннан үтеп китте ләбаса. Париж Коммунасы урамындагы ике катлы йортта тора ул. Фатиры икенче катта. Садрыйның анда еш булганы бар.

Наип — фотограф. Гәзитләрдә сирәк-мирәк кенә булса да, ул төшергән сурәтләр күренгәли. Үзе болай беркайда да төпләнеп эшләми. Бер тапкыр да өйләнеп карамаган. Өйләнергә исәбе дә юк.

— Камытны аны үшән атлар гына кия. Ә мин — канатлы ат! Кая телим — шунда очам, кемгә телим — шуңа кунам... Ха-ха-ха!..

Бу — аның яраткан тәгъбире.

Наипның каморкасыннан (фатирын ул шулай дип йөр-

тә) хатын-кыз заты өзелгәне юк. Берсе килә, берсе китә дигәндәй...

Хатын-кыз дигәндә — таягы идәндә аның. Теле бер хәрәкәткә килсә, тиз генә туктатырмын димә. Үзенең китап-журнал укыганын да күрмәссең, әмма китап сүзләрен сибә инде, иллә мәгәр! Аны өч секунд кына тыңлап торсаң да, дөньяда хатын-кыздан да гүзәл зат юк икәненә тәмам ышанасың. Сыраханәдә кружка җыеп йөрүче кипкән аяклы сәрхуш «синеглазка»лар алиһә булып күз алдына килеп баса хәтта.

Сандугач кебек өзлексез сайрый-сайрый, Наип ватык фотоаппаратын берничә мәртәбә чертләтеп сурәткә төшергәндәй итсә, каршында авызын ачып утырган гүзәл затның тәкате бетә, күзләре яна, иреннәре күперә башлый, капшап кына табарлык күкрәкләре күз алдында кабара, тулылана, җыерчыклы битләре алсулана, ботлары җәелә...

Тәҗрибәле Наип ашыкмый әле. Аның теле һаман телгә йокмый. Садрый инде мең кат тыңлаган анекдотка да чират җитә...

— Тәк, болай... Василий Иваныч белән Чапай... Чапай, дидеммени?.. Әйе инде, Чапай белән Петька, икесе акча җыешып, беркөнне «мерседес» сатып алганнар. Василий Иванычның ат йөртү хокукыннан башка правасы булмаганлыктан, руль артына Петька утырган. Утырганчы, Петька «мерседес»ның арткы тәрәзәсен ватып, пулеметын урнаштырган икән әле. Выжт итеп кузгалып киткәннәр болар. Петька инде, билгеле, классный шофер! Совет драндулитларын Арча — Казан юлында йөртә-йөртә остарып беткән кеше. Кирәксә дә, кирәкмәсә дә ыскурыстны алыштырып, үзгәртеп кенә бара икән бу. Менә бервакыт «мерседес», ыжгырып, Чаллы юлына килеп кергән.

— Петька, давай, Шәлегә ку! Туйганчы катык белән сыйланып кайтыйк бер! — дигән Василий Иваныч.

— Есть, товариш главнокомандуший! — дип, Петька газга тагын да баса төшкән.

Юлда кырмыска шикелле теркелдәгән «Волга», «Жигули»лар яныннан болар бал корты кебек безелдәп кенә очып китәләр икән.

Менә берзаман офыкта кулын күтәреп торучы бер әби күренгән. Әлбәттә, бер кулына төенчек тоткан инде әби.

— Петька, туктат «мерседес»ны! — дип фәрман биргән Чапай.— Әби яныннан җилдереп узып китү уңайсыз. Белмәссең, Владимир Ильичның хатыны булып чыгуы бар...

Бөкре гәүдәле гүзәл әбинең чабаталы аягына терәп диярлек туктаткан «мерседес»ны Петька.

— Сәлам, анакай! Аклар юкмы? — дигән Чапай әбигә.

— Юк шул, бәбкәйләрем, юк шул аклар,— дигән әби.— Менә чикмәнле бәрәңге белән сало гына бар. Шуны бирәм...

— Петька, сиңа бәрәңге белән сало кирәкме? — дип сораган Василий Иваныч.

— Кирәкми,— дигән Петька.

— Киттек алайса. Алга! — дигән Чапай.— Пока, әби!

Ары очкан «мерседес». Бераз баргач, боларга бер хатын очраган. Чиб-бәр икән үзе! Ну, синнән бераз кайтышрак инде, әлбәттә...

— Баһадирлар, әгәр утыртып алып барсагыз, акча бирәм,— дигән ул.

Чапай, хатынның бүлтәеп торган күкрәкләренә карап, мыек чылгыен сыйпап куйган да:

— Петька, сиңа акча кирәкме? — дигән.

— Мин — үзем акча! — дигән Петька.

— Ә мин — валюта! Киттек алайса, катык эчәргә! — дигән Чапай.

Киткәннәр. Хатын калган инде, кәнишне, акчасын учлап.

Бара торгач, «мерседес» бик сылу, әкияттәге шикелле гүзәл бер кыз янына җитеп туктаган.

— Абзыкайлар, утыртыгыз әле! Натуралата түлим,— дигән сылукай.

— Петька, сиңа натуралата кирәкме? — дигән Чапай.

— Юк.

— Соң, нишләп торабыз алайса. Киттек катык эчәргә! — дигән Василий Иваныч.

Тагын киткәннәр. Шактый баргач, Чапай Петькага эндәшкән:

— Ыслушай, Петька, нәрсә ул — натуралата?

— Белмим шул, Василий Иваныч,— дигән Петька.

— Кире киттек, Петька,— дигән Чапай.— Сорыйк теге кызыйдан, нәрсә микән ул — натуралата? Бәлки, катыктыр ул. Катык булса, Шәлегә үк барып тормас идек. Барлы-юклы бензинны әрәм-шәрәм иткәнче.

Килеп туктаган «мерседес» теге гүзәл янына.

— Карале, иптәш сеңелкәш,— дигән Василий Иваныч,— әйт әле миңа, данлы Кызыл Армиянең атаклы героена, нәрсә ул — на-ту-ра-ла-та?

— Ничек әйтергә инде... Менә мин ыштанны салам да... бирәм,— дигән сылукай. Дигән дә күлмәк итәген күтәрә дә башлаган...

— Ыштан! — Василий Иваныч, борынын җыерып, Петькага караган: — Ишеттеңме, Петька? Ыштан, ди. Сиңа хатын-кыз ыштаны кирәкме?

— Кирәкми, Василий Иваныч. Хатын-кыз ыштаны белән нишлим мин,— дигән Петька.

— Миңа да кирәкми,— дигән Чапай.— Киттек, Петька, Шәлегә!..

Китеп барганнар... Ха-ха-ха-ха-ха...

Наип тәрәзә пыялаларын зыңгылдатып көлеп җибәрә. Каршысындагы мәлҗерәйгән хатын да...

Аннары алар икәүләп матрасы, җәймәсе каралып, төрле таплар белән чуарланып беткән караватка авалар. Күпне күргән пружиналы тимер карават хәрәкәткә килә: «Шыгыр-шыгырт... шыгыр-шыгырт...»

Бушка булса да, мондый «кино» карарга яратмый Садрый. Шуңа күрә ул, Сталинград хәрабәләрен хәтерләткән өстәл өстеннән башланган бер ярты белән стаканны җәһәт кенә эләктереп, кухняга таю ягын карый.

Бүлмәдән аның чыгып киткәнен күреп калган карават отыры хәрәкәтләнергә тотына, ухылдаулар-ахылдаулар көчәя, ешая...

Садрый, тәмәке төтәтә-төтәтә, аракыны стаканга агыза да тамак юлына озата. Белә ул, хәзер шабыр тиргә баткан, кызарынган-бүртенгән Наип чыгачак та әйтәчәк аңа:

— Давай, бырат, синең чират.

Нәкъ шулай булды да. Наип, чалбар телтенбиен өскә таба шудыра-каптыра, кухняга килеп керде дә:

— Ну, бырат, класс! — диде. Аннары Садрый стаканга яртылаш агызган аракыны авызына койды. Кухнядан кабарга ризык тапмагач, кул аркасын иснәде.

— Ыф-фо! Давай, бырат, синең чират!

Садрыйның җавабы әзер:

— Карурманга сукмакны мин үзем салырга яратам...

Наип шешә төбендә калган аракыны стаканга бушатты.

— Кешедән соң җирәнәм, димәкче буласың инде...

— Юк. Теләк юк.

— Үзеңә кара. Мин әйттем. Киенергә кушам алайса,— дип, Наип хатын ягына кереп югалды...

Җирәнү дигәннән, Садрый үзе белән булган бер хәлне исенә төшерде, елмаеп куйды...

...Шул Наип фатирында булды инде бу хәл. Садрыйның баш төзәтергә дип кергән чагы иде.

— Во! Килүең шәп булды әле,— дип каршылады аны Наип. Гомерендә булмаганча киенгән-ясанган, кырынган. Күлмәк якасының муен «ашаган» өлеше күренмәсен диптер инде, галстук шикелле нәрсә дә таккан хәтта.— Миңа хәзер бер мәткә килергә тиеш. Класс! Үзебезнең ха-

лыктан. Ә өйдә...— Наип тамак төбенә бармагы белән чиртеп алды,— ...тамчы да аракы юк. Кунакны хлорлы су, ипи катысы белән генә сыйлап булмый бит инде. Капкаларга да нәрсәдер алырга кирәк...

Ул бетәшкән карт шикелле авызын кыйшайтып ачкан төтен төсендәге ботинкаларын киеп, йөз кат өзелеп төйнәлгән бауларны бәйләргә тотынды.

— Мин айн момент кына кибеткә барып киләм. Әгәр мин юкта мәткә килсә, аны әйбәтләп каршы ал. Киемнәрен салдырып эл, күңелен күрә тор...— Ишекнең теге ягына чыккач, борылып кычкырды:

— Исеме Фәридә. Онытма!..

Наип аны-моны уйламыйча гына «Күңелен күрә тор...» дип әйткәндер әйтүен, ә Садрый исә аның ул сүзләрен чынга алды.

Фәридә яшь кенә, сылу гына бер нәмәрсә иде шул. Җитмәсә, ул килеп керүгә үк, сүз бары тик билдән аскы өлеш тирәсендә генә барды. Шуның өстәвенә, Наип стенага ябыштырган эреле-ваклы шәрә сурәтләр икесенең дә җенси теләкләрен көчәйтте генә...

Наип та, бәхетләреннәндерме, тиз генә әйләнеп кайтмады.

Ишекне шәпләп кенә бикләде дә Садрый, Фәридәнең биленнән эләктерде һәм — һоп! — музейда Екатерина патшабикәнең ятагы белән янәшә торырга лаек караватка...

...Фәридә, Наип әйтмешли, класс иде...

«Күпне күргән, чукынчык» дип уйлады Садрый, ата куян шикелле бер якка мәтәлеп төшкәч.

Шухыр-мухырны Наип сизмәсен дип, икесе дә тизтиз генә киенделәр. Яңа гына танышкан кешеләр шикелле бер-берсеннән:

— Кайда эшлисең? Кем булып? — дип сорашкан булдылар.

Ә Наип кайтмады да кайтмады.

Соңгы вакытларда еш эчеп йөрүе сәбәпле, Садрыйга хатыны назы әллә ни тәтемәгән иде. Шуңа күрәдерме, аның дәрте янә уянды.

— Әллә соң... Наип булып та... нитимме? — диде Садрый.

Фәридәнең әле бая кабынган дәрте дә сүрелә башламаган иде булса кирәк. Ул тузгыган сары чәчләрен җилкәсенә салды да:

— Наип кайтып җитмәсме соң? — диде.

— Ул кайтканчы өлгерәбез! — диде Садрый.— Айн момент!..

...Аһ, җен мәткәсе! Фәридә, сөешүнең кабатланасын сизгән кебек, теге... уч төбенә сыеп бетәрлек эчке киемен киеп тормаган иде...

Наип һаман кайтмады.

Тагын юк-бар турында сөйләшә башладылар. Билдән югарырак темаларга кагылдылар, сәясәткә дә кереп чыктылар. Дөресен генә әйткәндә, икесе дә сәясәт мәсьәләсендә бум-бум иделәр. Шуңа күрә аларга сәясәттән ашау-эчү тирәсенә күчү җиңел булды. Садрый инде хәзер Наипның тизрәк кайтуын эченнән генә түземсезләнеп көтә иде. Эчәсе, котырып ашыйсы килде аның.

Ә Наип, үч иткәндәй, һаман күренмәде.

«Нәгаләт, берәр җирдә сыра чөмереп торадыр әле!» — Садрый, шулай уйлап, аптыраганнан Фәридәгә карап-карап алгалады. Шунда гына ул хатынның йөзе, куллары шактый таушалган, җыерчыкланган булуын искәрде.

— Наип берәр җиргә кереп батты бугай,— дип көрсенеп куйды Садрый. —Нишләптер кайтмый һаман...

Фәридәгә Наип ул хәтле үк кирәкми иде инде, ахры, ул:

— Кайтыр әле. Кая китсен. Сыер да ашаган тагарагы янына кайта,— дип, битараф кына әйтеп куйды. Аннары баягы күк елмаеп, Садрыйга дәште: — Ничек уйлыйсың... Үзең булып... әллә тагын...

Туймаса туймый, арымаса арымый икән бу хатын-кыз дигәнең. Байтактан бирле бер стакан аракы дөңкү турында гына уйлап утырган Садрый:

— Кешедән соң җирәнәм,— дигәнен сизми дә калды. Фәридә, башын артка ташлап, көләргә тотынды...

— Ну ты даешь!.. Впервые слышу такое! Уф, уми-раю...

Садрый да хихылдады.

Алар шулай туктый алмыйча көлешкән вакытта, ишек шакыдылар. Садрый, очып диярлек барып ишекне ачты.

Шакучы Наип иде. Чалбар кесәләре бүлтәйгән, кулында гәҗит төргәк...

Соңыннан, бер-ике ай үткәч, җаен туры китереп бу хакта Наипка сөйләде Садрый. Наип бот чабып көлде.

— Аптыраган идем аны ул көнне... Нишләп, мәйтәм, сулы чиләккә сыек чыбык тыгып болгаган кебек кенә булды соң әле бу... Ну, баҗай, хәйләкәр дә икән үзең! Рәзве ярый инде шулай, дустыңның пачти хатынын тартып алырга, ә?

— Үзең бит...— дигән булды Садрый.— Кайтмадың да кайтмадың... Җитмәсә, мин махмырдан... Сиңа ачудан инде, сиңа ачудан!..

— Син көн саен махмырдан... Махмыр булган саен миңа килсәң... Ха-ха-ха!

Шәп дус — шәп дус шул инде! Менә бүген дә махмырдан Садрый. Әле, җитмәсә, бер тәгам ризык та капмаган...

Садрый таныш фатирның ишеген шакыды. Эчтә «шылт» иткән тавыш та ишетелмәде. Йодрык белән тагын дөбердәтте Садрый. Ачучы булмады. Тавышка Наипның уң як күршесе чыкты. Сакаллы татар.

— Кем кирәк сиңа?

— Наип кирәк иде. Нишләптер ишекне ачмый.

— Ачмас та,— диде сакаллы татар.

— Нигә?

— Былтыр үлгән кешенең быел өенә кайтып ишек ачканын күргәнем дә ул хакта ишеткәнем дә юк әле минем.

— Ничек... үлгән кеше? Кем үлгән?

— Кем булсын — Наип! Яман шештән китте бит ул тегендә...— Сакаллы татар бармагы белән өскә ишарәләде.

— Син нәрсә! Шаярма әле, туган, мин аны өченче көн генә күрдем бит... Бергә сыра эчтек. Ничек былтыр үлсен инде? Син нәрсә, ычкындың мәллә?

— Кем ычкынгандыр әле! — Ишек шапылдап ябылды. Эчтән бик чылбыры чылтыраганы ишетелде.

Садрый Наип фатиры ишеген янә дуамалланып дөбердәтергә тотынды...

* * *

Гөлсара фатирына кайтып кына керергә өлгерде, артыннан ук кыңгырау чылтырады.

— Кем бар анда? — диде ул һәм сыңар күзен ишектәге зурайткыч пыялалы нәни тишеккә терәде.

Әдип икән:

— Бу — это я...

Ишек ачылды. Әдип, май урлап ашаган мәче шикелле, як-ягына каранып алды да җәһәт кенә эчкә узды.

— Әй Ходаем, мин бит әле ашарга хәстәрләргә дә өлгермәдем! — дип үрсәләнде Гөлсара, аякларына сыланган итекләрен азапланып сала-сала.

— Ничего, зыян юк. Минем тамак тук,— диде Әдип.

— Теге җүләр белән булган хәлдән соң башларым катты инде. Әле генә сөяркәсендә булып кайттым.

— Да-а?! — дип гаҗәпләнгәндәй итте Әдип. Һәм көзге каршына басып чәчләрен тарагандай итте.— Как она-то выглядит? Берәр старухадыр инде?!

— Старуха, дип әйтмәс идем,— диде Гөлсара, аякла-

рына җиңел башмаклар кия-кия,— әмма шлюха булуы хак суканың...

— Да-а? Смотри-ка?! — дип янә гаҗәпләнгән булды Әдип.— Муж-то хоть есть у нее?

— Бар. Анысы да үз хатынын ташлап, моңа йортка кергән бер мөртәт шунда.

Зал ягына чыктылар. Әдип, фокусчы шикелле, әллә каян гына коньяк шешәсе чыгарып өстәлгә утыртты.

Гөлсара шешәнең чит ил сүзләре язылган кәгазенә текәлде.

— Импортный! Каян таптың моны, Әдип? — диде ул, куанычын яшерә алмыйча.

Әдип, йөзенә җитди кыяфәт чыгарып:

— А-а... одна баба подарила,— диде. Гөлсараның йөзенә кара болыт кунуын күргәч, өстәп куйды.— Шучу, конечно!

— Ну чукынчык! Шулай диген аны! — дип бармак янады Гөлсара. Ә үзе эченнән генә: «Теге җүләр тәрегә тагын мондый эчемлек табу!» — дип уйлап алды.

— Ну-с, начнем-с! Давай рюмкаларны! — дип, Әдип кулларын бер-берсенә ышкып алды.— Гулять тек гулять! Один раз живем. Так ведь, сабыем?!

— Да, да, шулай. Хәзер мин тиз генә закускага бирәр нәрсә алып чыгыйм инде,— диде Гөлсара.

Әдип стенкадан рюмкалар алды да аларга коньяк агызды. Кухня ягыннан Гөлсараның тавышы ишетелде:

— Әдип, син озаккамы? Бәлки, кайнар ризык әзерләргәдер?

— Кирәкмәс. Не надо. У меня шоколад есть!

«Ну Максимыч! Молодец та инде син!» Гөлсара, симез тавык кебек очына-очына, өстәлгә какланган колбаса, голланд сыры ише коры-сары ризыклар чыгарып куйды.

— Ну-с,— диде Әдип Максимыч, кыяфәтен вәкарь белән генә тотып,— давай, выпьем за здоровье твоего мужа! Все-таки он твой муж, хоть и ненормальный, как ты говоришь, и сомнительный отец твоей дочери, и мой баҗай, который еще не знает моего существования!

— Да ну его! — диде Гөлсара, ире хакында Әдипнең урынсыз тост әйткәненә үпкәләп, хәтере калып.— Нинди ир булсын ул, бер имгәк шунда! Безнең якта андыйларга мүкләк кәҗә, диләр...

— Кәҗә — это хорошо! — диде Әдип, шоколад кәгазен ача-ача.— А чучка — еще лучше! Потому что, чучка ничего не думает, кроме еды и грязи. А кәҗә еще что-то думает, соображает, если он, конечно, мужчина... Ну, ладно... Давай, Гагарин әйтмешли, поеха-ли...

Шулай диде дә Әдип рюмкасындагы эчемлекне түнтәреп куйды, шоколадның бер шакмагын сындырып авызына капты.

Гөлсара аңа сәерсенеп карады. «Бүген Әдипкә әллә ни булган. Ниндидер тозсыз, тузга язмаган мәгънәсез сүзләр сөйли... Әллә, Ходаем, бусы да ычкынган инде?..» дип уйлап куйды ул.

— Давай, сабыем, эчеп куй, әйдә,— диде аңа Әдип.— А то юкса...

Юк, ычкынмаган, ахры, Әдип...

— «А то юкса...» нәрсә була? — дип, Гөлсара рюмканы иреннәренә якын китерде.

— Хәзер ирең кайтып керүе бар...— диде Әдип һәм колбаса белән сыр кисәген икесен берьюлы капкан килеш чәйнәргә кереште.

— Элек курыкмый идең, Әдипкәм! — Гөлсараның борын тирәсендә берни белән дә чагыштырып булмаслык әллә нинди хуш ис бөркелде. «Импортный импортный шул инде!» Гөлсара коньякны йотып җибәргәнен сизми дә калды.

— Раньше мой шофер синең ирең нең кайтып килгәнен телефон аша заранее извещать итә иде. Ә бүген, как назло, мин аны срочный эш белән җибәрдем,— диде Әдип.

— Тиз генә кайтмас әле ул. Тегене әйтәм. Аннан соң, кем белә әле аның кайда йөргәнен. Милициягә хәбәр ителмәгән. Бәлки, ул психбольницададыр инде. Син киткәч, эзлисе-белешәсе булыр инде ул сөйрәлчекне. Баягынак, теге шлюхадан кайтышлый, кызыма шылтыратып әйткән идем. Ул алай-болай килсә, «Кайда эти?» дип сораса, ни дияргә белмәссең...

— Эзлисе-нитәсе юк... Ирең тиздән монда кайтып җитәчәк...

— Каян беләсең, Әдипчигем,— дип, Гөлсара исерә төшкән хатын-кыз шикелле хихылдап алды,— әллә син күрәзәчеме?

Аның иртән Садрыйның очлы ияген үзенә чумдырган күкрәкләре арасыннан тир исе ургылып чыкты да Әдипнең борын тишекләренә таба юл алды. Әдип, эсседән интеккән кеше төсле, уң кулы белән борын эченә агылган исләрне куалап алды да көчәнеп көлемсерәде:

— Нет, у меня другая профессия. Можно сказать, околоземная...

Гөлсара Әдипне кочаклап ук алды.

— Беләм, беләм. Син — зур начальник кеше! Дөнья кешесе син! Син... син...

— Я — это ты, ты — это я...— диде Әдип.

Коньяк шулкадәр тәэсир иттеме, әллә дәрте үзеннән-үзе кузгалдымы, күзләре сәер ялтырый, битләре уттай кызыша башлаган Гөлсара, Әдипкә сылана-ышкыла, аны ятак тарафына әйдәде...

— Дөрес әйттең, Әдипчигем... Син — ул мин, мин — ул син...— дип пышылдады аның ни әйткәнен үзләре дә аңламаган кайнар, мәлҗерек иреннәре...

Бу вакытта Болак буендагы култыксага таянып, Наип турындагы сәер вә аңлашылмаслык хәлне сөт чүлмәге чаклы башына берничек тә сыйдыра алмыйча торган Садрыйга кинәт әллә ни булды. Аның күзләре пыялаланды, куллары махмырдан интеккән сәрхушныкы төсле, берөзлексез дерелдәргә тотынды. Куллары гына түгел, бөтен гәүдәсе калтырый башлады. Кипшенгән иреннәре әле аерылды, әле кавышты... Ниндидер сүз әйтергә теләдеме ул — белмәссең... Үтеп-сүтеп китүчеләр аңа әллә ни артык әһәмият бирмәделәр. Чөнки мондый халәттә басып торган, яисә бөгәрләнеп җирдә яткан кешеләрне күрү алар өчен гадәти хәл иде. Хет шунда ник чәнчелеп үлеп ятмыйсың...

Менә, ниһаять, үзе шикелле кәкре таяк белән тротуарны чукый-чукый килгән бер карчык игътибар итте аңа. Карчыкның икенче кулындагы челтәрле шакшы букчасында сырадан бушаган бер яшел шешә тирбәлеп килә иде.

Карчык теркелдәвеннән туктады, авып китмәскә ышанычлырак булсын диптерме, кәкре таягын янә бер мәртәбә тротуар ташына төртеп куйды, букчалы кулы белән авыз тирәсен сыйпап алды, аннары вак-вак буразналар белән чуарланган каракучкыл чыраен калтыравык ир тарафына янтайтты. Ирнең аяклары тирәсенә, аяклары янындагы портфеленә карап алгач, карчыкның шешенке бәбәкләре арасыннан ипи валчыгы кебек кенә күренеп торган күзләрендәге өмет чаткысы кинәт сүнде — исерек ир янында (карчык аның сәрхуш булуына тәмам инанган иде) буш шешә күренмәде...

Букчадагы сыңар яшел шешә акрын гына тирбәлә-тирбәлә ерагая-кечерәя барган бер мәлдә... ул кинәт кычкырып җибәрде:

— Кәҗә — это хорошо!..

Шулчак аның әлеге кискен тавышына кушылган урам шавы колакларына ургылып керде, башы гөжләргә тотынды, күзләре көчле яктылыкны шәйләде...

«Бернәрсә дә хәтерләмим» — үз аңына килгәч, уйлаган беренче уе шул булды.

Нишләп йөри ул монда — Болак буенда? Нигә әле аның башы шулхәтле авырта? Өйдән кайчан чыгып китте икән

ул? Бу халык, бу машиналар кая шулай ашыга? Нигә аның бик яман эчәсе, ашыйсы килә? Иртән ризык-мазар капкаламады микәнни соң ул?..

Башында сораулар өере... Ә ул берни дә хәтерләми. Нәрсә бу? Әллә анда хәтерсезлек чире башландымы? Бернигә карамыйча өйгә ашыгырга кирәк! Ул, иелеп, портфельне кулына алды. Өендә нинди хәлләрдер әле?..

* * *

— Син бүген бөтенләй башка... Хатының белән бергә ай ярым йокламаган кеше кебек...— дип пышылдады Гөлсараның кайнар иреннәре.

Әдип дәшмәде. Ул, еш-еш сулый-сулый, һаман хәрәкәтләнә иде.

— Хәтта бүген чалбарыңны да төшереп бетермәдең,— диде Гөлсара, канәгатьлек кичерә-кичерә.— Дәртең шулкадәр ташыган икән...

Әдип бу юлы да дәшмәде. Ул күзләрен йомган килеш һаман селкенүендә булды.

— Синең туктарга исәбең юк, ахры...— диде Гөлсара, куллары белән Әдипнең шәрә аркасын сыйпый-сыйпый.

— Хәзер... хәзер...— диде, ниһаять, Әдип һәм нигәдер: — Кәҗә — это хорошо! — дип тә өстәде.

— Ниткән бетмәс кәҗә булды инде ул? — Гөлсараның ачуы килеп куйды.— Дуңгыз — еще лучше! диген инде тагын...

— Болай гына, ялгыш әйттем...— диде Әдип. Ул кинәт гәүдәсен катырды.— А-а-аһ!.. Пош-шел!..

— Вулкан — это хорошо...— дип әйтеп куйды шулчак Гөлсара, Әдипнең йонлач гәүдәсенә сеңеп бетәрдәй булып.

Шул вакыт аның кулы каты сымак нәрсәгә тиде.

— Әллә сиңа койрык үсеп килә инде, Әдипчик?! — дип көлде Гөлсара.

— В этом странном мире все может быть. Атавизм! — диде дә Әдип бер якка авып төште.

— Нәрсә ул — атавизм? Коммунизмнан соң була торган берәр рәхәт тормыш түгелдер бит?

Әдип яткан килеш кенә чалбарын күтәреп куйды. Гөлсараның соравын ишетмәмешкә салынды.

— Берәр стопка манчыйк булмаса! — диде ул, коньяк шешәсенә ымлап.

Гөлсара, урыныннан торып, иңенә халатын элде.

— «Манчыйк» дигән сүзне белми идең бит син! — диде ул Әдипкә, гаҗәпләнеп караган булып.

— Как белмәскә. Знаю. Мин аны только один раз манчыдым, а у нее через сколько-то месяцев — двойняшки! Правильно я сказал, а? Ха-ха-ха...

Әдипнең көлүенә Гөлсара да кушылды.

— Еще тагын бер предложение. Мин аңа та-а-ак манчыдым!.. Через секунду он уже лежал как скошенный стебель. Правильно сказал? Ха-ха-ха...

— Правильны-правильны, сугып ектым Равилны...— дип, такмак әйтеп алды Гөлсара.

Ул коньяк салынган рюмканы Әдипкә сузган гына иде, шул вакыт ишек шакыдылар. Гөлсара баскан урынында катып калды.

— Твой муж,— диде Әдип битараф кына.

— Бәлки, кызымдыр?! Каян беләсең? — дип пышылдады Гөлсара, иреннәрен көч-хәл белән генә әйләндереп.

— Я все знаю.— Әдип торып утырды.

— Кая булса да качып тор! — диде Гөлсара һәм, халат сәдәпләрен каптыра-каптыра, ишеккә таба атлады.

— Да. Качарга пора...— диде Әдип.

Гөлсара ишек янына ук барып җитә алмады, ишекне үз ачкычы белән ачып, Садрый килеп керде.

— Син? — Гөлсараның йөзеннән кан качты.

— Мин.

— Садрый?! — диде Гөлсара, нигәдер өметләнеп.

— Нинди Садрый тагы? Мәхмүт икәнемне оныттың мәллә?

Садрый-Мәхмүт, портфелен идәнгә куеп, ботинкаларын сала башлады. Шулчак ул идәндәге ят аяк киемен күреп алды.

— Нәрсә, әллә миңа ботинка алдыңмы? Акча туздырмасаң да була иде. Монысы да бик әйбәт әле...

Гөлсара кулларын, кулларын гына түгел, үзен кая куярга, ни әйтергә белмәде.

«Ходаем, нишлим? Коткарсана...» — дип эченнән ялварды ул. Һәм, артына чигенә-чигенә, зал ягына чыкты.

«Качып өлгерсә генә ярар иде Әдип...»

Әдип качып өлгергән иде. Ләкин кая? Өйдә качарлык җир дә юк лабаса...

Гөлсара, коньяк шешәсен кая яшерергә белмичә торганда, залда Садрый-Мәхмүт пәйда булды.

— Нәрсә, кунак-мазар килде мәллә? — диде ул, әле Гөлсарага, әле аның кулындагы шешәгә, әле өстәл өстендәге кабымлыкларга карап.

— Кунак дип... Садрый... Мәхмүт...— дип, авыз казанында шулпа кайнатып алды Гөлсара.

— Нинди Садрый? Кем ул Садрый?

— Соң бит... соң бит... үзең бит... Иртән бит... «Садрый мин...» диден бит...

— Хәтерләмим,— диде Садрый-Мәхмүт. Һәм кинәт кызыксынып сорады: — Тагын нәрсәләр дидем?

Телефон шылтырады.

— Кызым! — Гөлсара телефон трубкасын кулына алды.— Алло, тыңлыйм!

— Бу мин әле, сабыем. Мин, Әдип.

— Кем, кем? Кайсы Әдип? — Гөлсараның аяклары икесе тиң хәлсезләнә башлады.

— Кайсы дип... Бу мин инде, мин — Әдип! Бая килә алмадым. Прости. Совещание озакка сузылды. Хәзер килеп җитәм... Целую...

Гөлсара акрын гына идәнгә чүкте.

Аның агарынган йөзен күреп хәвефләнгән Садрый-Мәхмүт кабаланып килде:

— Ни булды, Гөлсара? Нәрсә булды?

— Шайтан... шайтан...— диде Гөлсара.

Ул аңын югалтты.

# Бәллүр төн

## Гаилә кыйссасы

*(Эротик әсәрләргә пародия)*

Сәламәтлек саклау министрлыгы кисәтә: тиз ярсучан кешеләргә ошбу әсәр зыянлы.

Мизгел сискәнде: димәк, дөньяда бер-бер хәл булды.
*Яфмами Иасонд, тыкав философы.*
Куркытмагыз йолдызларны! Алар гаепле түгел...
*Мтао Лфалб, ратат шагыйре.*

— Син мине яратасыңмы? Әйт инде, яратасыңмы мине?

— Ну.

— Юк, син әйт, матур итеп әйт!

— Ну... Яратам.

— Алай түгел... Тутырып әйт.

— Стакангамы?

— Шаярма инде... Йә?

— Нәрсә — «йә»?

— Яратам, диген...

— Әйттем бит инде.

— Юк, син әйбәт итеп әйтмәдең...
— Әйбәт дигәне ничек була?
— Мин сине яратам!
— Мин дә.
— Юк, юк... Яратмыйсың син мине. Яратсаң әйтер идең...
— Нәрсәне?
— Мине яратуың турында.
— Уф-ф... Соң, матуркаем, әйттем бит инде. Тагын ни таләп итәсең миннән?
— «Мин сине яратам!» дип әйтүеңне.
— Әллә мин ычкына башладым, әллә... Әйе, мин сине яратам! Яратам! Яратам! Булдымы, йә?
— Кычкырма шулхәтле! Аңладым мин сине. Яратмыйсың син мине. Гомер буе яратмадың.
— Ничек инде — «гомер буе»?
— Сигез ел синең белән яшәү — минем өчен гомер буе инде...
— Шулай диген аны.
— ...газаплы гомер...
— Һе. Кызык. Алай булгач, ник әллә кайчан ук аерылышмадың соң?
— Син җүләрне яраттым.
— Газапланып-интегепме?
— Әйе. Ләззәтләнеп тә.
— Аллага шөкер! Юкса мин уйлаган идем, син сигез ел буе гел газапланып яшәгәнсең икән, дип.
— Ялгыш уйлагансың. Сирәк тәтесә дә, бәхетле көннәрем дә булды.
— Минем беләнме, әллә бүтәннәр... белән дәме?
— Сүзне читкә борма. Синең белән! Хәтерлисеңме очрашкан көнне?
— Хәтерләмәскә. Мине бит әле склероз җәфаламый.
— Кавышкан, өйләнешкән көн дә исеңдәме? Йә, әйт әле, кайчан, кайсы елны, кайсы көнне язылыштык без?
— Кыш көне.
— Юк, син төп-төгәл итеп әйт.
— Төп-төгәле әнә паспортларга язылган...
— Шул, шул, хәтерләмисең! Исеңдә калган булса, әйтер идең... «Паспортларга язылган» имеш... Син бит безнең кызның кайчан туганын да белмисең... Иманым камил, белмисең! Тагын «Паспортларга язылган...» диген.
— Димим. Беләм. Унберенче май. Биш ел элек...
— Әйе, беләсең... Син ул көнне лыкынганчы эчеп, милициягә эләккәнгә күрә беләсең... Шатлыктан эчтем, имеш... Кызыбыз туган сөенечтән бәйрәм иттем, имеш...

Миңа соңыннан әйттеләр. Белми бу дип уйлама тагы. Беләм. Бөтенесен дә беләм. Ул көнне кайда, кемнәр белән эчкәнеңне дә, кемгә барып йоклап кайтканыңны да...

— Белсәң, беләгеңә җылы б...к әләм.

— Тупасланма. Сиңа тупаслык килешми.

— Рәхмәт. Белмәгәнмен моңарчы.

— Белә идең. Мин сиңа гел әйтә идем.

— Ә мин, нишләптер, бер дә хәтерләмим.

— Кыланма. Сиңа кылану да килешми.

— Килешми дә килешми... Бер башлагач, санап чык инде, миңа тагын ни килешми? Киләчәктә истә тотарга тырышырмын.

— Соң инде. Син мәңге үзгәрәчәк кеше түгел!

— «Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген, йә булмаса, үзем үзгәрәм...» дип язган бер татар шагыйре.

— Үзгәргәнме соң? Үзгәрткәнме дөньяны?

— Үзен — белмим. Ә менә дөньяны үзгәртте булса кирәк. Үзгәрде бит дөнья. Бәяләр сикерә, ә байлар кикерә...

— Син дә шигырь яза башладың мәллә?

— Синең белән яшәп шагыйрь дә булырсың...

— Көлмә... көлмә...

— Сиңа көлү килешми, диген тагы...

— Юк. Менә монысын әйтмим. Сиңа, киресенчә, көлү килешә...

— Комплиментың өчен рәхмәт. Күрәсеңме, борын өскә күтәрелә башлады...

— Бүтән нәрсәң күтәрелмиме тагы?! Юк, гафу, шаяртуым гына... Терсәгеңне тегеләйрәк әз генә ал әле, зинһар... Кабыргаларны сындырасың бит юкса...

— Булдымы? Бәлки, урыннан ук торыргадыр?

— Юк, кирәкми. Ят. Синең белән яткан килеш сөйләшү рәхәт. Торгач, син агрессивлашасың. Юкка-барга бәйләнә башлыйсың...

— Карале, кызны кемгә илтеп куйдым дидең син баягынак?

— Менә хәтер! Әниләргә илтеп куйдым, дидем бит.

— Ә-ә-ә... Мин әйтәм, нишләп Айгөлне Әминәгә илтте икән бу, дим. Баядан бирле баш ватам... Ялгыш ишеткәнмен инде, алайса.

— Әминәгә күзең төшкәндер әле. Шуңа кыбырсуыңдыр. Йә, әйт, кызыктың мәллә Әминәгә? Карале күзләремә...

— Йә, шуннан.

— Кара аны, әгәр Әминә белән тегеләй-болай килергә уйласаң...

— Запретная зона что ли...

— Ул минем подругам. Әгәр ул-бу ишетсәм...

— Нишләтәсең?

— Кара, кара!.. Мине котыртуыңмы, әллә уйнап кына сөйләшүеңме?

— Котырырга син эт түгел лә... Уйнап, билгеле.

— Шулай диген аны... Әминә — минем лучшая подруга!

— Лучшая подруга жены — лучшая любовница.

— Кара, кара... Тагын ни сайрыйсың син?

— «СПИД-инфо» гәзитен укыганың юк мәллә? Анда тагын әллә ниләр язалар... «Лучшая любовница — это мужчина», «Лучший любовник — это я»...

— Җитте, җитте... Косасыны китерәсең... «Голубой»ларны үземнең эштә дә, урамда да күреп туйган...

— Каян беләсең аларның «зәңгәр» икәнен?

— Күзләрем күрә лә минем. Әлбәттә, кыланышларыннан, йөрешләреннән...

— Бәлки, алар артистлардыр. Болай гына кыланып йөриләрдер...

— Һе, артист... Алайга китсә, һәрбер артист — голубой, тумыштан ук...

— Ничего себе!

— Артист дигәннән, син Теннеси Уильямсны беләсеңме?

— Моңарчы бергә аракы эчәргә туры килмәде шикелле... Кем ул? Теннис уйный мәллә???

— Сиңа көләргә генә булсын... Драматург ул, беләсең килсә. Америка драматургы. Кайчандыр артист та булган...

— Шуннан ни? «Зәңгәр» мәллә ул да?

— Булган...

— Хәзер хәлсезләнгәнме?

— Юк. Үлгән. Йокы даруы шешәсенең бөкесе ялгыш тамагына тыгылып үлгән... Беләсеңме, ул нәрсә дигән?

— Мин каян белим. Ә син каян беләсең? Безнең өйгә килгәне бар иде мәллә?

— Юк инде... «Современная драматургия» журналыннан укыдым.

— Син пьесалар язмыйсың. Диссертацияң дә ул хакта түгел.

— Укыдым инде. Случай! Эштә берәү биреп торды.

— «Зәңгәр»ме?

— Не важно. Менә шул журналда Уильямсның «Плейбой» журналына биргән әңгәмәсен басканнар. Ул әйтә, болай ди...

— Ул әйткәнне син ятлап өлгердеңме?

— Туктале син... Истә кала. Менә нәрсә ди... Минем дәртем һичкайчан сүрелмәячәк, ди. Һәм мин үлем түшәгендә яткан чагымда да, ди, хәлемне белергә килгән докторны, ди, әгәр дә ул яшь һәм чибәр егет булса, ди, һичшиксез кочаклаячакмын, ди...

— Кызык икән... Яшь хатын-кыз булса, мин дә кочаклаячакмын аны. Чибәр булмаса да ярый...

— Кара, кара...

— Сиңа сөйләгән бар микән, миңа бервакыт шундый күт чыпчыгы бәйләнгәне бар бит.

— Сине ошаткан, димәк...

— Миңа димәгәе...

— Берәр исәбең бар идемени?

— Син нәрсә! Шаярып сөйләгәнне аңламыйсың мәллә?

— Соң... Мин дә шаярып кына әйттем ләбаса...

— Бер капитан иде. Милиция капитаны. Кырык-кырык бишләр тирәсендә булгандыр. Минем студент чак. Беренче курста укыйдырыем бугай. Әйе, шул чакта. Бүлмәдәш малай янына килеп йөри бу. Урыс малае янына. Слава исемле иде. Югары Осланныкы. Килгән саен, капитан үзе белән булган хәлләр турында сөйли. Милиция, хулиганнар турында. Кызык сөйли. Ничек итеп берүзе бер шайкага каршы сугышкан, ничек итеп шайка башлыгын акылга утырткан... Ул шайка башлыгы төрмәдән чыккач...

— Чибәр идеме соң?

— Кем? Шайка башлыгымы? Каян белим мин...

— Юк. Капитан.

— Капитан, капитан, авызыңа чап итәм... А черт его знает. Кыяфәтле иде инде. Татар.

— Ә ул нишләп татар башы белән урыс малае янына килеп йөри иде соң?

— Мәхәббәт, значит! Ишеткәнең юкмыни, «Мәхәббәткә маңка мишәйт итми...»

— Бар.

— Шулай булгач. Гаҗәпләнмә. Кыскасы, болай... Бар әле тегеләйрәк. Төртеп төшерәсең бит...

— Йә, шуннан...

— Утырган да шуган... Беркөнне кич, төнгә таба инде, килде бу. Теге иптәш малай каядыр киткән иде. Шулай була бит ул гел. Кемдер килә, кемдер — юк... Үзенең яңа маҗараларын сөйләде бу. Гадәтенчә. Мин авызны ачып тыңлыйм инде. Ул сөйли, мин тыңлыйм... Берзаман мин, моның һаман туктарга исәбе юклыгын сизенгәч,

урын җәеп, йокларга әзерләндем. Бу әйтә, өйгә кайтып йөрмим инде, ди, ачуланмасаң, монда гына калыр идем, ди. Хатын барыбер өйдә юк, ди. Миңа нәрсә?! Урын бар — теге малайныкы. Кайтса — бергә йокларлар... Моңарчы шулай йоклаганнары бар иде инде. Кем белгән аларның ул чакта без йоклагач нишләгәннәрен. Мин бит әле ул вакытта — салага, мокыт, акылга утырмаган бер авыл малае...

— Акыл сиңа әле дә утырмаган ул...

— Утырды. Менә хәзер ятып тора. Синең янда, шәпшәрә булып.

— Әйдә, әйдә, читкә борма...

— Үзең бит... Минем күзләр йомыла башлады бермәл. Бу һаман сөйли. Инде йоклап киттем дигәндә генә әйтә бу: давай, синең янга ятыйм әле, ди... Ә-ә, бер нәрсәне әйтергә оныткаңмын икән әле. Аңарчы... Ну, йокларга ятканчыга кадәр, без бер шешә акны икәү бөкләп ташлаган идек.

— Сәерсенеп уйлаган идем аны. Ничек син үз гомереңдә бер көн эчмичә йокладың икән дип.

— Аракыны ул алып килгән иде. Закускага — башлы суган, кильки консервасы, кара ипи...

— ...кара икра... кызыл балык...

— Аларны син студент чакта үзең ашагансыңдыр. Без укыган вакытта, андый затлы ризыклар ике ятып, бер төшкә дә кермәде. Хәзер генә ул... Кайсы гына кибеткә кермә — тулып ята... Алып кына булмый...

— Алырлык акча эшләргә иде...

— Аны алып ашаганчы, трусик алып киям мин. Барыбер шул ук бәя.

— Чалбарың булса, трусиксыз йөрергә дә була инде.

— Не ги-ги-е-нич-но! Шуннан... Менә оныттырдың да инде. Кай төштә калдым әле?

— Кара ипи катысы кимерә идең...

— Әйе... Давай, синең янга ятыйм әле, ди бу. Нишләптер, салкын, ди, бүлмәгез... Самом деле, бүлмә салкын иде. Көз көне иде, ноябрьләр тирәсе иде чөнки. Миңа нәрсә, ят, мин әйтәм... Яттык шулай. Аркага арка терәп. Бу һаман сөйли. Минем башка әллә аракы китте, әллә арылган шунда — бермәлне йоклап киткәнмен... Ниндидер сәер төш күреп ятам... Ә-ә-ә... Исемә төште. Атка атланып каядыр барам икән... Ул көнне кино караган идек. Егетләр белән. «Свой среди чужих, чужой среди своих» дигән кино иде бугай. Гражданнар сугышы турындамы, әллә басмачылар турындамы шунда... Һәрхәлдә, атлар бар иде ул кинода. Барам шулай атта. Ияр-

дә. Бер кулда — кылыч, икенчесендә — наган... Каршыда — әллә аклар, әллә кызыллар, белмәссең... Бермәлне, какрас бер дошманның башын чабып өзәм дигәндә генә, нәрсәдер каты гына төртелде бит. Авырттырып төртелде. Дошман юкка чыкты. Кулдан кылыч ычкынды... Астагы иярне капшыйм. Бар. Ниндидер каты нәрсә бар. Читкә алып ташладым моны... һәм... уянып киттем. Баш чатный. Аз эчелгән иде, ну барыбер баш чатный...

— Сиңа беркайчан да җитми инде...

— Су эчәсе килә. Су бар — өстәлдә генә, үрелеп чәйнекне генә аласы. Тик... торасы килми. Чөнки одеал астында җылы, ә бүлмәдә суык.

— Теге капитан юкмы инде?

— Бар. Йоклый. Соңыннан гына уйладым мин аны. Йокламаган ул. Йоклаганга салышып кына яткан. Читкәрәк елышам. Минәйтәм, бу капитан бер тәмле төш күреп ята инде. Чөнки андый төшләрнең үземә дә кергәләгәне бар иде. Тагын алгарак елышкан идем — дөберт — идәнгә... Әле ярый бер җир дә авыртмады... Тиз генә тордым да, су эчәргә дә онытып, теге иптәш малайның караватына барып яттым. Ә теге... Берни белмичә йоклый. Җитмәсә, шундук гырлап та җибәрде...

— Әйтәм бит, тумыштан ук артист алар, дип.

— ...Мин янә изрәп йоклап киткәнмен. Иртән ниндидер тавышка уяндым. Капитан икән. Киенгән. «Туган, гафу ит,— ди,— саташылган,— ди,— хатын белән күптән йоклаган юк иде,— ди...» Үзен сатты, заразы. Шулай димәсә, беләсе түгел идем. Мин икенче якка борылдым да яттым. Чыгып китте теге. Сау бул, диде дә...

— Бүтән килдеме соң?

— Шуннан соң эзе суынды. Бүлмәдәш урыс малае да, укуын ташлап, каядыр юкка чыкты...

— Минем бер дус кыз да... син аны белмисең... бер кызык хәл сөйләде. Син сөйләгәнгә охшаш. Охшаш дип, бик үк охшаш та түгел инде.

— Нәрсә, ул да минем шикелле корбан була язганмыни?! Не завидую...

— Шыгрым тулы троллейбуста бара икән бу... Минем дус кыз инде...

— Аңладым инде. Капитан бәйләнде дигәч тә, ул кадәр җүләр түгел бит әле мин...

— Нидер уйлап, тәрәзәгә карап бара икән... Яңгырлы көн. Коеп ява икән яңгыр урамда. Кешеләрнең кулларында зонтиклар. Шыгрым тулы трамвайны беләсең инде: ызгыш-төртеш, аякка басыш...

— ...ватылган шешә, сытылган күкәй...

— Минем дус кызның да аягына кемдер баскан, кемдер күкрәгенә терсәге белән төрткән... Җитмәсә, кемдер аның арт җиренә зонтигын кадап бара икән. Авыртуга чыдый алмыйча, ул кулы белән зонтикны читкә тибәргән... Көлмә, көлмә... Бер дә кызык түгел... Бер шулай иткән бу, ике... Өченчесендә түзмәгән... Борылган да чыйлап кычкырып та җибәргән... Сиңа кызык... Дус кыз шыгрым троллейбусның арткы өлешеннән алгы ишеккә ничек барып җиткәнен, ничек төшеп калганын да сизмәгән...

— Ну и комедия! А ля француз!

— Көлмә ул хәтле. Трагедия, диген...

— Трагикомедия, алайса. Урысча-татарча вариант.

— Дус кыз әйтә, шул вакыйгадан соң бер ай исәнгерәп йөрдем, ди...

— Ну теманы таптык без. Сөйләшергә бүтән сүз беткән диярсең...

— Үзең башладың бит.

— Башладым да ташладым. «Зонтик» күрәсең килмиме?

— Кит әле, оятсыз! Капла тизрәк!

— Каплыйм, карале, минем тамак кипте. Ашыйсы да килә башлады. Суыткычта башланган ярты бар иде бугай...

— Бар иде — юк инде.

— Ничек — юк инде? Кемгә эчердең? Әллә теге мин шабашкада чакта авылга әниләреңә алып кайткан егетне чакырдыңмы? Әйт хәзер үк!

— Син нәрсә! Кагылма беләккә! Нинди егет ди ул тагын? Үзем эчеп бетердем. Әллә миңа эчәргә ярамыймы?

— Ярый. Ләкин син аны эчеп бетерсәң, кая барып мәтәлгәнеңне дә белмәячәксең бит.

— Мәтәлде ди! Тот капчыгың! Хатын-кызны белмисең әле син! Безнең эштә бер хатын туган көнен билгеләп үтте. Бервакыт. Берүзе әллә никадәр эчте. Агын да, кызылын да... Тап-таза мужиклар селәгәйләрен агызып өстәл астында яткач та, бер-ике рюмка эчте әле. Барыбер аягында калды. «Кая җүнле ир? Китерегез монда!» дип кычкыра-кычкыра чишенә башлаган иде, ире генә тыеп калды. Ире дә бездә эшли. Тамчы да эчми. Бер мәхлук шунда. «Сонечка, Сонечка, киска моя» дип, исерек хатыны янында бөтерелеп йөри. Алып кайтып китте. Машиналары бар. «Запорожец»...

— «Запорожец» машинамыни ул?

— Синдә андые да юк бит әле, хәчтерүш... Теге хатын машинага кереп утырганчы ук җырларга тотынды: «Мой

миленок, твой теленок, только одна разница...» — дип, бөтен урамга суза гына... Беләсеңме, әйтсәм — ышанмыйсың, машинага кереп утыргач айныды. «Вовочка, салмак кузгал... Вовочка, күрмисеңмени, каршыңда кеше ич! Вовочка, сулга борыл! Вовочка!..» Ә син хатын-кыз исерә, дисең. Исертерсең безне!

— Сез елан затыннан шул. Агулы еланны бернинди агу да алмый!

— Ә сез — ишәкләр... И-а! И-а!

— Сиңа килешәрәк төшә барыбер. Телләрен әйбәт беләсең сыман...

— Сезнең телне дә белмәсәң. Дөньяда нигә яшәргә! И-а! И-а!..

— Җитте. Күршеләрне уятасың. Нинди ишәк алып кайттылар микән, диярләр. Белмәсләр синең ишәк булып кычкырганыңны...

— Әллә алар йоклый дип беләсеңме? Алар да синең белән минем кебек кешеләр ич!

— Елан белән ишәк, диген... Әй, әйдә, салыйк инде бер йөз грамм, ашыйсы килә, дидем бит.

— Юк. Бетте, дидем түгелме соң?

— Кая куйдың алайса?

— Әз-әзләп эчеп бетердем. Син командировкада йөргән чакта, мин нишләргә тиеш соң ялгыз башым? Күземне шарландырып юеш мендәр кочаклап ятыйммыни?

— Нигә юеш мендәр? Корысы беткән идемени? Әнә ничаклы!

— Эһе, киптергәч... Әгәр чынлап торып еласам, минем күз яшьләре белән бер ваннаны тутырырга була.

— Элгәре җылауларың әле ул чынлап җылау түгел идемени?

— Әлбәттә.

— Монысы икән баласы, алда икән анасы...

— Әйе шул, күрәселәрең алда икән әле...

— Ә мин, син җылый башлауга ук, өйдән чыгып таячакмын.

— Таеп кая барасың. Күп тайдың бит. Барыбер минем аякка кире кайтып егылдың. «Кичер, матуркаем, бүтән синсез яши алмыйм!» янәмәсе...

— Үзең арттан килеп, ялынып алып кайттың бит. Бик тиз онытасың икән син, ә!

— Үземә кирәген онытмыйм мин.

— Анысы шулай.

— Ничек шулай булсын? Син сораган йөз грамм хакында онытмадым бит әле менә.

— Әллә эчәбез?

— Эчмичә! Сөекле ирем белән кайчан шулай гөрләшеп, чут-чут үбешеп эчеп утыра алам әле тагы...

— Тагы, тагы, ботагы... Кая китте бу тагы... Во! Шигырь! Яхшы! Мин рюмкаларны алып киләм. Юк, бәллүр стаканнарны. Без бит немецлар түгел — күгәрчен күкәе кадәр рюмкадан өч тамчы аракы йотарга... Без бит — татарлар! Татарлар — башыңны тотып атарлар! Теләсәләр, кәнишне...

— Кара, кара... Аракы дигәч тә... Сөенүен күр... Йөрмә инде тиле төсле шәрә килеш...

— Нигә? Без кеше өендә түгелдер ич? Үз өебездәдер. Кемнән куркырга? Үз өемдә нәрсә телим — шуны эшлим, стаканлап хәмер эчәм, рюмкадан эчмим. Во! Тагын шәп шигырь! Гомәр Хәйям пүчтәк булып калды минем янда...

— Ул да синең төсле шәрә йөрмәгәндер бит?

— Белмим. Ә кем белә... Әһә, тагын бер шигырь:

Шәрә, шәрә, шәп-шәрә! Аракы да шәп-шәрә. Стакан да шәп-шәрә. Хатыным да шәп-шәрә. Мин үзем дә шәп-шәрә...Бөтен кеше шәп-шәрә... Бөтенебез ялангач... Шуңа күрә карын ач!

Во! Классика! Дәреслекләргә керерлек! Тукай исән булса, билләһи, көнләшер иде. Матуркаем! Язып ал шигырьне! Бүтән андый шедевр башка әллә килә, әллә юк... «Татарстан яшьләре»нә бирерсең. Юк! Анда бирмә! «Акчарлак»ка бир. Бассалар, акча-мазар бирсәләр — миңа булыр. Басмасалар — сиңа... Шәп әйттем бит, ә?!

— И очына инде, и очына... Ки инде трусигыңны, ичмасам. Тәрәзәдән күрсәләр әле...

— Кемне? Минеме? Кемнәр? Тугызынчы каттагы тәрәзәдән кем карый алсын. Шул... оча торган тәлинкәләрдәгеләр махсус мине килеп күзәтсәләр генә инде...

— Ки инде. Ризык алдында ярамый. Гөнаһ була, ди торган иде минем әби.

— Синең әби ни әйтмәс, минем бабай ни әйтмәс... Ярый, киям. Кая трусик?

— Шундадыр.

— Юк бит, син кимәдеңме?

— Синең кара трусигыңны кияргә мине җүләр дип белдең мәллә?

— Ялгыш киюең бар. Трусы... Трусы... Российские траурные трусы...

— Үзең уйлап чыгардың мәллә?

— Әһә! Монда икән... Юрган арасына буталган... Нәрсә дисең? Нәрсәне каян чыгардым?

— Каян, димим, уйлап, дим! Колак!

— Ә-ә-ә ... Студент чакта бер егет Евтушенко дигән шагыйрьнең шигырьләрен укып җенләнә иде. Шул Евтушенко язган бугай. Шәп әйткән бит, ә? «Российские траурные трусы...» Кара трусик, черный трусик, димәгән бит. Тапкан сүзен.

— Шагыйрь булгач, тапкан инде.

— Мин аңа шушы сүзләре өчен генә дә и-и-иң зур премия бирер идем.

— Нобель премиясенме!

— Чит илнеке лә ул.

— Булса ни.

— Булса ни — булмаса ни... Әйдә тот, карчык!

— Әбекәй димисеңме тагы?

— Ярар инде, карчык — яратып әйтелә торган сүз бит ул!

— Картайгач әйтерсең шулай дип. Кирәгем калмагач...

— Ярар, бетте, үпкәләшмик... Тот, әйдә, матуркаем, былбылым, сандугачым... Син бит кара карлыга-а-ач... Син бит сары сандуга-а-ач...

— Бераз сикергәләп тә җырласаң, «Халык артисты» исеме бирергә була сиңа...

— «Халык хөртисте» диген...

— Йә, хөртист, нәрсә өчен эчәбез?

— Ничек — «нәрсә өчен»? Кем өчен, кемнәр өчен эчәбез, диген... Үзебез өчен, үзебезнең исәнлек өчен эчәбез... Кая, йоласын китереп, чәкештергән булыйк...

— Тост әйтмисеңмени?

— Тост? Ник әйтмәскә, әйтәм! Тост... тост... Тә-ә-әк... Алга барабыз, тост әйтеп алабыз... Күптән тост әйтеп эчкән юк инде... Шундый бер шәп тост белә идем... Искә төшми, яп-яланаяк... Әллә соң... бу юлысыга тостлап тормыйбызмы? Сүзсез генә җилпибезме? Күзгә-күз карашып...

— Алкашларның шул булыр инде аның. Тизрәк салып кую ягын карарлар... Тончыгасың бит, бүрәнкә авыз!

— Ыф-ф-фы!.. Шәп, авызын... төчкерткере! Синең исәнлеккә эчтем... Яндыра, каһәр... Каян алдың моны?

— Каян булсын — кибеттән инде. Киләсе ай башыннан тагын бәяләр күтәрелә бит.

— Дөрес эшләгәнсең. Маладис син, карчык! Мин сине шул маладис булганың өчен яратам да инде...

Ай, Кукмара, Кукмара, ерагаймасын ара.
Сагынырсың, саргаерсың, читләргә китеп кара-а-а...

Тә-әк... Каяле, тагын бераз мактанышып алыйк әле...

— Азрак тавышың да булса, менә дигән җырчы чыгасы икән синнән, билләһи газыйм...

— Җырчы, җырчы, мин сине... Кайда синең стакан? Әһә!.. Сагынып көттем ел буе... Бәй, син ник эчмәдең?

— Кыстамадың бит.

— Менә кызык. Аракыны кыстатып эчмиләр инде аны. Бар икән — бушат. Юк икән — табып эч. Язылмаган закун бу.

— Ул бит синдәйләр өчен генә шулай.

— Синдәйләргә шулай, миндәйләргә шулай... Бер стакан аракы ач корсакка кулай... Тот, әйдә, хөртист хатыны! Капла. Мә, менә бу калҗаны кабып җиф-фәр!.. Во! Әллә кайчан ук шулай бушаталар аны. Яндырамы? Әйтәм бит... Чистага охшаган — спиртын ялгыш күбрәк тондырганнар, ахры... Каяле, мин дә тагын бер тәмен татып карыйм әле...

— Исерәсең бит хәзер...

— Минме?! Никогда! Кешесе ул түгел.

— И-и-и... Хәчтерүш! Чучка булганчы эчкәне юк диярсең...

— Ыф-ф-фы!.. Шә-ә-әп!.. Яшәсен урыс аракысы! Барлык илләрнең салмыштыйннары, берләшегез!

— Берләшеп нишләмәкче буласыз, кызыл танаулар?

— Безме? Берләшепме? Дөньядагы бөтен аракыны үзебез генә эчәчәкбез. Сезгә бер тамчы да бирмибез. Чәчләрегезне йолкый-йолкый җыласагыз да, юк.

— Җылыйм ди шуның өчен.

— Син җыламасаң, бүтәннәр җылар... Сигезенче мартларда, сабан туйларда, Яңа ел бәйрәмнәрендә типтереп, телләрегезне әлсерәгән сарыклар шикелле салындырып йөрегез шунда... Эчегез әнә лимонадтыр, компоттыр-чурттыр ише суларны. Ә без аракы чөмерербез...

Ай эчәбез, эчәбез,
Кайда безнең шешәбез?
Шешә төпләрендә бетсә,
Ыштан сатып эчәбез...

— Йә инде, йә, җитте! Шөрепләрең бушый башлады бугай инде.

— Бетте-бетте... Җырламыйм. Минем өчен хатын сүзе — закун! Син бит минем хатын гына түгел, син бит — минем ханбикәм! Син бит минем... ыйк!.. Кемдер мине... ыйк! ... сөйли, ахры... ыйк!.. Очкылыгыңны ... ыйк!..

— Су эч әнә... Су эчкәч бетә ул...

— ...ыйк!.. Син бит минем... ыйк!.. бәллүркәем... Син бит минем алтыным... ыйк!.. Син яшәсәң, мин яшәрмен,

мәңге яшә, хатыным... ыйк!.. Во! Тагын шигырь туды! Сизәсеңме, эчкәч... ыйк!.. шәбрәк эшли башлады баш... Әллә бу шагыйрь халкы эчкәч кенә яза микән шигырьләрне?.. Ыйк!..

— Шулайдыр инде, әйе, көт... Ул чагында һәрбер исерек шагыйрь булыр иде...

— Карале, карчык, уйлап-уйлап торам да, тагын бер уйлап куям... Ыйк!.. Мин сиңа өйләнеп бик дөрес эшләгәнмен, ахры... Синең башың миллион хатынныкына караганда да шәбрәк соображать итә икән бит... ыйк!.. Әйдә, шуның өчен тагын берсәк кенә кәккәндәй итик...

— Эчеп бетерәсең бит инде... Кая, алып куйыйм, иртәгә башыңны төзәтергә кирәк булыр...

— Иртәгә өчен ишәк кайгырган, диләр, карчык... Торсын шулай матур гына урынында. Әйдә, тот стаканны... Аннан соң бераз яратышып алырбыз.

— Китчәле. Булды бит инде, яратыштык.

—Анысы бит аның генераль репетиция генә иде. Ә монысы — премьера!

— И мактанчык! Тагын эчсәң, хәзер гырлап йоклап китәсең бит...

— Стоп, карчык!

— Ни булды?

— Стоп! Стоп! Дәшми тор. Бер анекдот искә төште. Хәзер сөйлим... Әйдә, боларны бушатыйк та...

— Бушатмыйча гына сөйләп булмый идеме инде аны?

— Юк, булмый. Тамак кипте чөнки... Бер, ике, өч!.. Бездә бөтен көч! Һоп!.. А-а-аһ!..

— Кыяр булса да кап инде, ичмасам...

— Ыслушаюсь, ханбикәм! Әйдә, яшел нитрат чапсын эле аракы абзыйсы артыннан...

— Нинди нитрат булсын ул! Авылдан алып килгән кыяр ич.

— О, әбинең кыярымыни?! Алайса, тагын берне тәвәккәллим...

— Нитрат, имеш... Сәламәтлеген кайгырта берәү. Ул нитратны тоннасы белән ашасаң да, чуртым да булмый сиңа. Аракыдан гына торган организмны нинди агу җиңсен...

— Саклангандны сакләрмын, дигән Ходай. Тыңла, карчык, анекдот сөйлим...

— Тагын шул тозсыз мәзәктер инде...

— Юк, юк. Бусы культурный... Бер мужик эштән арып-талып кайткан өенә. Хатыны пешергән ашны тәлинкәсеннән генә чөмергән дә, аннан-моннан чишенеп, җәелгән урынга барып та яткан. «Хатын,— ди икән бу

йокылы тавыш белән,— әйдә, утны сүндер дә тизрәк ят минем янга. Табак-савытларыңны иртәгә юарсың...» Хатынның йөзе кинәт балкып киткән. «Ниһаять!..» дип уйлаган ул һәм, сөенә-сөенә, халатын салган да, эчке күлмәкчән генә ире янына килеп, юрган эченә кереп чумган. Синең шикелле...

— Әйттем бит, тозсыз мәзәктер әле, дип...

— Тукта инде, карчык. Сөйләп бетергәнне көт... Хатын юрган астына кереп чумуга, ире әйткән моңа: «Хатын, бик каты ардым, ачуланма инде, бүген күтне генә куеп ятам...» — дигән. «Дүртне?! Һи, сиңа тагын! Унбиш көнгә хет бер булса ярый әле...»—дигән хатын. Ә үзе назланып кына ирен кочып алган. Ире, аның кочканын гына көткән төсле, гырлап йокыга да киткән... Ха-ха-ха! Кызык бит, ә?!

— Кай төше кызык инде моның? Менә мин сөйләячәге кызык, ичмасам! Синеке шикелле тозсыз да түгел...

— Әйдә, әйдә, сөйләп кара. Иш янына куш булсын...

— Бер ир өенә ашыгып кайтып кергән дә тиз-тиз генә чемоданга киемнәрен тутыра да башлаган. «Син кая җыендың?» — дигән моңа хатыны. «Чит илгә! — дип җавап кайтарган ире.— Анда бер кочкан өчен хатын-кыз иратка егерме доллар түли икән...» Бераздан чемоданын шыплап тутырып бетергәч, ир күрә: моның хатыны да чемоданына киемнәрен дыңгычлап ята. «Ә син кая?» — дигән ир, хатынына сәерсенеп карап. «Мин синең артыңнан күзәтергә барам. Беләсе иде, син айга кырык доллар белән анда ничек яшәрсең микән?»—дигән хатыны.

— Ха-ха-ха-ха...

— Менә бу мәзәк, ичмасам. Шулаймы?!

— Ярый инде... Әйдә, миннән булсын изгелек. Очколар тигез: бергә — бер. Пока — ничья!

— Нинди эчү инде ул, ә? Куй әле шешәне урынына! Күптән кешеләрчә сөйләшеп утырган юк бит инде...

— Ир белән хатын кебек, диген...

— Һаман эчү турында гына уйлыйсың. Җитәр инде, туктап тор.

— Дөрес әйтәсең, карчык. Туктап торырга кирәк. Төн озын әле. Эчү качмас. Әйдә, физкуль... Юк, секскультура белән шөгыльләнеп алабыз. Юкса һаман сөйлибез дә сөйлибез...

— Кирәкми инде. Бүгенгә җитәр. Йоклыйк кына лутчы...

— Эчү качмас, йокы качмас... Мин бит үзем сөйләгән анекдоттагы мужик түгел — йокы бүсәргә... Кил әле, карчык, кочаклыйм әле үзеңне...

— Егерме доллар сорамыйсыңмы соң?
— Причем монда доллар?
— Бер кочаклаган өчен, дип әйтүем...
— Ә-ә-ә... Син дә мәзәгеңне искә төшерәсең икән... Юк, хәтта агач берлек тә сорамыйм... Бушка кочаклыйм мин сине, карчыккаем!
— Утны сүндер, яме.
— Ә мин ут яктысында хочу.
— Ярар инде... Кыланма. Сүндер, пажалысты... Беләсең бит, мин ут янганда яратмыйм.
— Лампаны кабызыйммы?
— Юк, юк, ансы да кирәкми.
— Как хошь, ханбикәм. Күзләреңне йом—сүндерәм...
— Ай!.. Сыразы өскә ятма инде. Сытып үтерәсең бит.
— «Кич җитте, күктә йолдызлар кабынды, хатыным мине ябынды...»
— Тагын шигырь уйлап чыгардыңмы?
— Юк. Монысы минеке түгел. Кемдер сөйләгән иде, шул хәтердә калган...
— Китап укый-укый, тәки шагыйрьгә әйләнеп беттең инде... Миңа су җибәр әле ваннага.
— Баш өсте, алиһәм!
— Кара аны, моны эчеп бетермә.
— Курыкма, аз гына йотам. «Эш беткәч, уйнарга ярый» дигән Тукай бабаң. Әнә телефон шылтырый. Кая, үзем алам... Алло! Алло! Әйе, дим!.. Алло!.. Шантрапа... Тавышны ошатмады.
— Кем шылтыратты?
— Телсез Герасим! Муму!.. Юынуыңны бел!
— Нинди керосин?
— Син үзең — керосин! Герасим, дидем. Муму! Муму!
— Сөлгене бир әле... Карап торма инде...
— Курыкма, сиңа карамыйм мин...
— Чәй куеп җибәрмисеңме? Нигәдер тамак кипте.
— Махмырдан шулай була ул гел. Лутчы аракы эчәргә кирәк... Что-то ашыйсы килеп китте әле...
— Колбаса белән бутерброд яса. Колбасасы әйбәт. Финский.
— Оһо! Затлы яшисең.
— Ир командировкада, дип ач ятып булмый инде, җанкисәгем...
— Җанкисәгем, аппагым, сиңа ни кирәк тагын?
— Суыткычта бер башланган вино бар. Сухой. Кагор. Ал әле шуны.
— Алам, ләкин мин сухой эчмим.

— Синең өчен түгел лә... Үзем өчен. Кагор канны яхшырта, диләр...

— Яхшырта, пычагым! Аракыга җитми инде. Ыф-ф-ф... Сыразы башка китте...

— Көтеп тор инде. Бергә эчәрбез.

— Эчәбез, әлбәттә. Ләкин монда аракы бетеп килә әле менә. Бүтән юктыр?!

— Каян булсын инде! Әйттем бит!

— Ништож. Ул чагында сиңа булышырга туры килә. Аракыдан соң сухой дәрәҗәне төшерә инде төшерүен...

— Эчмә. Кем әле сине сухой эчәргә кыстый...

— О-о-о. Җиңел пар белән!..

— Рәхмәт.

— «Красави-ца!.. Комсомолка!.. Спортсмен-ка!..»

— «Кавказская пленница»дагы Наталья Варлейга охшаганмын мәллә?!

— Әлбәттә. Суйган да каплаган! Утыр әйдә монда... Мин ул киноны биш-алты тапкыр караганмындыр...

— Мин дә яратам ул киноны.

— Әйдә, шуның өчен!

— Бәллүр — бәллүр инде! Ничек матур зеңли, әйеме?!

— Естественно, бәллүр зеңләргә тиеш!

— Стенкага алып куярга кирәк әле шундый берәр бәллүр ваза...

— Ыф-фы!.. Ботлар шәп синең.

— Шушы ботларга кызыгып алдың түгелме соң инде син мине?!

— Юк, ботларыңа гына түгел.

— Болар бервакыт берсе дә булмаячак бит инде, әйеме?!

— Ничек — булмаячак?

— Ну... мин үлгәч... тфү-тфү!.. болар юкка чыгачаклар...

— Юктан бар булмый, бардан юк булмый, дип өйрәттеләр безгә мәктәптә физика укытучылары. Так што, бик борчылма!

— Ничек инде! Менә бит без юктан бар булганбыз.

— Мәсьәләнең асылына төшенсәң, бер дә син уйлаганча түгел ул.

— Ә асылына ничек төшенәсең?

— Китапларны аракы чөмергәндәй эчкән кеше булarак, мин фәкыйрегез болай уйлый. Без, ягъни кешеләр, кабыкка төренгән җаннар. Безнең үлүебез — менә шул кабыкларны салып ташлау гына. Тәннән аерылган, ягъни мәсәлән, тән-гәүдә белән алыш-бирешен өзгән җаны-

быз Аллаһы хозурына юл ала. Анда аны янә дүрт язмышның берсе көтә. Минем уйлавымча, әлбәттә.

— Дүрт?! Дүрт язмыш?

— Әйе, дүрт язмыш. Язмышларны җан үзе сайлап алмый. Ала алмый чөнки. Беренче язмыш: җан кире әйләнеп җиргә кайта...

— Ничек инде? Гәүдә кабат терелә мени?

— Юк, кәнишне. Аллаһы хозурына эләккәч, җан җирдә узган тормышы турында отчет бирә. Мин, командировкадан кайткач, бухгалтерга отчет биргән шикелле. Икенче төрле итеп әйтсәк, болай: җирдә чакта кылган яхшылыклары, шулай ук гөнаһлары турында бәйнә-бәйнә сөйли.

— Шуннан.

— Менә шул отчетны тыңлагач, Аллаһы Тәгалә гадел фәрманын бирә: «Фәлән улы Төгән җанын яки Төгән кызы Фәләния җанын Җир өслегенә кабат командировкага җибәрергә!» «Әле генә шуннан арып-талып кайттым бит, зинһар өчен, бераз ял итим инде!» — дип ялыну-ялвару файдасыз, фәрман үтәлергә тиеш! Бару-кайту срогы Аллаһы хозурындагы баш бухгалтерның папкасына теркәлеп куелган командировочный кәгазендә четко күрсәтелә: фәлән ел да төгән көн. Командировочный кәгазен кулга тоттырмыйлар. Кирәге юк чөнки...

— Әйбәт икән.

—... Командировка срогын Аллаһы Тәгалә генә үзгәртә ала. Исключение рәвешендә: йә кыскарта, йә озынайта...

— Нәкъ бездәге шикелле икән...

— Пачти... «Бару-кайту, ашау-эчү, яшәү-куну өчен акча кирәк» дип, бухгалтерны тинтерәтәсе юк. Акчаны барыбер бирмәячәк. Аннан соң, анда акча дигән нәрсә дә юк чөнки. «Бару-кайту өчен билетлар алынган, ашауяшәү турында, җиргә баргач, үзең кайгыртырсың!» диячәк тә бухгалтер... и все! Ә юк, «Кайткач ук отчет тапшырырга онытма!» дип тә өстәячәк икән әле. Менә шул отчет ярдәмендә синең үсешеңне, күпмегә камилләшүеңне беләчәкләр дә инде...

— Кызы-ык... Ә икенче язмыш ничек?

— Икенчесен дә, өченчесен дә син инде беләсең; минем кебек бик яхшы кеше икәнсең — яшәвеңне оҗмахта дәвам итәсең, әгәр инде... гөнаһларың минем алда күп икән — үзеңә үпкәлә. Сине тәмуг көтә!

— Син кайда — мин шунда инде, җанкисәгем!

— Ярар. Ходай Тәгалә белән сөйләшеп карармын...

— Нәрсә, әллә анда да блат кирәкме?

— Әлбәттә. Тик шуны бел: әгәр кырын эшең бар икән,

Аллаһы Тәгалә берничек тә ярдәм итмәячәк. Президент минем иң якын дустым иде, дигәнеңә дә игътибар бирмәячәк. Алдашканыңны беләчәк чөнки.

— Әгәр мин «Мәгърифәт» гәҗитенә интервью биргән теге җырчы шикелле: «Мин — Президентның иң яраткан җырчысы!» — дисәм дә файдасы булмыймы?

— Юк, булмый. Ярдәм итә алмыйм. Нигә, ул җырчы точно шулай дип әйткәнме? Башларына суккан икән башка җырчыларның...

— Әйе. Нәкъ шулай дигән.

— Хитрый прием. Ә ул каян белә икән соң именно үзен Президент яратканны? Интерес-но!

— Шулай дип авыз тутырып әйткәч, белә инде, димәк...

— Алай артык шапырынырга ярамый. Вкус һава торышы шикелле үзгәреп торучан ул, бүген берәүне яратасың, иртәгә — икенчене...

— Синең дә вкусың шундыймы?

— Мин бит Президент түгел. Мин — бәләкәй кеше. Дөресрәге, мин — бәләкәй бөек! Ә бәләкәй бөекләрнең вкусы бүтән төрле була. Гомумән, вкус ул кешенең кәефенә карый. Синең кәефең шәп икән бүген, хәтта әнә теге... кем белә... безнең подъезд баскычларын җырлый-җырлый җыештыручы тыңкыш танаулы шадра Нәсимә дә гүзәл булып күренергә мөмкин.

— Кит инде... Син бигрәк арттырасың...

— Точно шулай! Дөрес, синең күңелең саф, җаның эчкерсез, камил булырга тиеш.

— Пычрак җанлы кеше теләсә кайсы кешедә матурлык күрә алмый, димәкче буласың инде...

— Әлбәттә, шулай. Ничек инде... Син пычрак җанлы да бул, иске-москы кигән урам бичурасында матурлык та күр... Алай булмый ул. Алай берничек тә була алмый.

— Нигә, мин пычрак җанлымыни?

— Юк ла инде, син һәр сүзне үзеңә алып ятма. Синең җаның болай чиста күренә...

— Каян күрәсең инде син аны?..

— Күзләреңнән. Күзләргә алдау дигән нәрсә ят. Алар һәрвакыт дөресен сөйлиләр. Күзләр сөйләгәнне тыңлый белергә генә кирәк. Әмма син шуны онытма: җаның кристалл кебек яисә бәллүр стакан шикелле никадәр генә чиста булмасын, аны пычрату— айн момент! Бер пычрандымы, җанны инде краннан аккан кайнар су белән генә юып булмый. Җан ул чөнки!

— Әйбәт сөйлисең. «Белем» җәмгыятендә лектор булырлыгың бар.

— Нигә, кирәк икән, лектор да була алам. Кайчандыр «Ит-сөтне күбрәк җитештерик, вакытыннан элек дәүләткә тапшырыйк! Озакламый коммунизмда рәхәт чигәчәкбез!» дип йөргән агитатор этием малае ла мин.

— Син, сүзгә бирелеп, җанның дүртенче язмышын әйтмәдең әле...

— Дүртенчесенме? Дүртенчесе шул: кайбер җаннар командировкада күрсәтелгән урынга килүгә, җирнең, табигатьнең, дисәк тә ярый инде, каршылыгына очрыйлар. Ягъни мәсәлән, ана карынындагы сабыйның тәненә бөтенләй үк кереп урнаша алмыйлар. Бала табу йортларында кайбер сабыйларның үле тууын шуның белән аңлатырга кирәктер...

— Һе! Ә кая китә соң ул чакта командировкага килгән ул җаннар?

— Туда-суда йөриләр.

— Ничек инде — туда-суда?

— Ну... Җир белән күк арасында буталып, исәнгерәп очып йөриләр. Очып аргач, берәр фатирга Барабашка булып «йортка керәләр» дә стена шакыйлар... Синең менә бу ботларыңнан чеметәләр, имиеңнең очыннан тарталар... Ачулары синеке шикелле килсә, тәлинкә очырырга да күп сорамыйлар...

— Кит инде... зинһар... куркытма, пажалысты...

— Полтергейстлар! А ну-ка, да-вай, менә бу стаканны әнә тегендә томырыгыз әле!.. Менә болай ит-т...

— Аһ!.. Харап иттең! Парсыз иттең стаканны!..

— Ничава, кайгырма, тагын алырбыз кибеттән.

— Аласың, бар... Мондый бәллүр стаканнар кибеттә юк ул хәзер...

— Бүтән төрлесен алырбыз.

— Миңа бүтәне кирәкми.

— Шуның өчен җылап утырып булмый инде.

— Полтергейст... Барабашка... Үзең син — Барабашка! Җыеп ал хәзер үк ватыкларны!

— Ыслушаюсь! Тик син җылама гына, яме...

— Җыларсың да монда.

— Җыламасаң, кәнфит бирә-ә-әм... Тагын берәр әкият сөйлим. Во! Менә көлдердем дә...

— Үземнең көләсе килде минем. Синең тырышуыңның нәтиҗәсе түгел...

— Миңа сирауна. Главный — көлдең... Каяле, аякларыңны күтәреп тор...

— Синең сөйләвеңнән мин барыбер берни дә аңламадым әле.

— Нәрсә аңламадың? Кая түгим бу ватыкларны?

— Бүген генә дөньяга килмәгәнсеңдер бит? Чүп чиләгенә илтеп сал.
— Нәрсә аңламадың, дим?
— Ну, үлгәч... гәүдәнең кая китүе турында сөйләмәдең бит.
— Кая китсен... Беркая да китми.
— Череп таркаламы? Бөҗәкләр ашап бетерәме?
— Кәнишне. Алар да җанияләре бит... Санитарлар!
— Абау, коточкыч!
— Табигать законы. Берни эшли алмыйсың...
— Уйлавы да куркыныч.
— Кемгә — куркыныч, кемгә — юк...
— Күктә үлүгә ни җитә!..
— Самолетта шартлап дисеңме? Тфү-тфү, диген...
— Тфү-тфү!
— Ә барыбер гәүдәңне калдырып үлү әйбәтрәк, минемчә.
— Ничек әйбәт булсын инде...
— Информация кала чөнки.
— Нинди информация ул тагы?
— Кайбер галимнәр әйтүенчә, үлгән кешенең тәнендә, чәчләрендә, канында, гомумән, бөтен гәүдәсендә билгеле бер күләмдә информация кала икән. Аны хәтер, дип әйтсәң дә була инде. Ягъни мәсәлән, буыннан-буынга, нәселдән-нәселгә геннар аша күчүче хәтер. Ә син, кыстати, бүгенге көн маңкортлары кайдан килеп чыкканын беләсеңме?
— Белми-им...
— Белмисең шул. Дөресрәге, аны берәү дә белми һәм аңлата да алмый. Ә мин беләм дә аңлата да алам. Чөнки хәзер син ишетәчәк шаккатыргыч фикер минем башыма әле яңа гына килде. «Без барыбыз да Гогольнең «Шинель»еннән чыктык» дигән бер урыс язучысы. Мин бу тәгъбирне үзләштереп, болай дип әйтәм: «Маңкортлар барысы да... дуңгыз итеннән һәм колбасадан чыкты!»
— Колбасадан???
— Шаккаттыңмы? Шаккатырсың да шул! Тыңла, гади генә итеп аңлатырга тырышып карыйм. Чыңгыз Айтматов дигән язучы әйтә, маңкорт ул, ди, үзенең нәсел-нәсәбен, хәтта үзенең кем икәнлеген оныткан хәтерсез кеше, ди. Ну, шулай диебрәк аңлата инде. Ничего падобного! Маңкортның хәтере бар! Ләкин ул хәтер аның җанында түгел, ә тәнендә! Баш миендә, һәрбер күзәнәктә... Кыскасы, бөтен организмда. Әмма җанда гына түгел! Җан хәтере юк маңкортларда...

— Син ачыш ясыйсың түгелме соң?

— Кем белә, бәлки, ачыштыр да... Аллаһы Тәгалә каршындагы отчет — әнә шул җан хәтере инде ул. Димәк, кешедә ике төрле хәтер бар: җан һәм тән хәтере. Әйткәнемчә, маңкортларда бары тик тән хәтере генә бар. Борынгы заман маңкортлары кайдан һәм ничек барлыкка килүе турында конкрет әйтә алмыйм. Әмма дә ләкин бүгенге үзебезнең арадагы татар маңкортларының килеп чыгышы турында сөйли алам. Алар әлеге дә баягы чучка ите һәм колбасадан килеп чыкканнар. Ни өчен нәкъ менә шулярданмы?

— Әйе, ни өчен нәкъ менә шулардан? Нигә, мәсәлән, ипидән яки судан түгел?

— Берсәк алардан да. Ләкин зур роль уйнаучылар — чучка ите һәм колбаса. Безнең борынгы бабайларның нәрсә ите ашауларын беләсең инде син, ат ите, сарык ите, алардан эшләнгән казылыклар, тутырмалар... Менә шундый итләр ашап көн иткән безнең бабайлар заманында бүгенге маңкортларга охшаш кешеләр булгандыр дип уйламыйм. Башка халыкларда булган. Мәсәлән, индеецларда. Ләкин аларда да индеец токымыннан булган кешеләр түгел, ә бәлки индеецларга әсир төшкән ак тәнлеләр. Алар — ясалма маңкортлар. Билгеле бер максат белән, ягъни кушканны сүзсез үти торган кол ясау уе белән, индеецлар ак тәнле таза бер дошманның чәче кыркылган башына икенче дошманның баш тиресен кеше исән чагында ук салдырып алып кидерә торган булганнар. Тунап алынган ул баш тиресе скальп дип атала бугай. Әйе, әйе, скальп. Башка кидерелгән менә шул скальп бер кипсә, аны берничек тә кире салдырып булмый икән. Бичара әсирнең скальп эчендәге чәчләре әкренләп үсә тора икән, ә үзе, хәтереннән яза-яза, әкренләп маңкортка әйләнә бара икән. Бераздан, индеецлар ни кушса, шуны үтәүче, ни бирсә, шуны ашаучы күндәм, шыр мокытка әверелә икән.

— Бу турыда мин дә кайсыдыр бер әсәрдә укыдым бугай. Фенимор Купердамы соң?

— Мин, кем әйтмешли, темадан бераз читкәрәк киттем. Ягъни тарихи чигенеш ясадым... Дальше киттек. Иван Грозный Казанны яулап алган чакка тукталыйк. Бу чор турында хәзер гәзитләрдә, журналларда күп язалар. Радиодан да, телевизордан да сөйлиләр. Былтыр синең белән «Хәтер көне»нә дә бардык бит. Менә шул Иван Грозный җиңгәч, байтак татар ирләренең исән калуы, һәм ул ирләрнең дошманның табан астын ялаучы, куркак, хыянәтче түрәләр булуы турында, аларның христиан ди-

ненә күчеп, урыс исеме алуы турында син дә беләсең, мин дә. Халкын саткан, башка дингә күчкән бәндәгә чучка ите ашау берни тормый. Лишь бы ул исән генә булсын да, корсак кына тулып торсын. Пока бернинди дә нәтиҗә ясамыйча, сикерәбез егерменче гасыр башына—унҗиденче елга. Инде бу чорда гади татарлар да итне бик талымлап тормый, бигрәк тә пролетар татарлар, урыс быратларга охшарга тырышып, чучка итен сыптыра башлыйлар. Приютларга, детдомнарга эләккән татар балаларының ни ашаулары турында әйтеп тә торасы юк...

Шулай итеп, инде хәзер бер бәләкәй генә нәтиҗә ясарга да мөмкин: Октябрь революциясе татарның ачык авызына чучка көтүе агылып керә башлаган чор булса, аннан соңгы еллар — әлеге чучкалар татар корсагында аунап, мыркылдап яткан заман ул. Менә без синең белән бая гына колбаса ашадыкмы?

— Ашадык. Шуннан ни?

— Шуннан шул: без дә дуңгыз ашадык.

— Әһ-һә, ялгыштың. Ул «Говяжье» дигән колбаса иде...

— Стоп! Ә син беләсеңме соң менә шул «Говяжье» дигән колбасаныңниләрдән әзерләнгәнен?

— Сыер ите, крахмал... Аннан килеп — целлюлоза... Кәгазь инде...

— ... һәм тагын дуңгыз ите!

— Дуңгыз ите дә кушалармыни?

— Кушмыйча!.. Тагы плюс күселәр, по собственному желанию...

— Абау! Костырасың бит инде хәзер.

— Безнең будущий оныклар маңкорт булмас, дип бик үк гарантия бирә алмыйсың син. Дөрес, без күрәләтә чучка ите сосмыйбыз сосуын. Ләкин...

— Әйе, ләкин... Ләкин моның син әйткән тән һәм җан хәтеренә нинди бәйләнеше бар соң?

— Ит комбинатында хайваннарны ток суктырып, куркытып үтерәләр. Шулай үтерелгән дуңгыз белән сыерның ите, кушылып, колбасага әверелеп, безнең корсакка күчә. Корсактан — тәнгә... Ягъни хайваннарның тән хәтерләре безнең тән хәтере белән кавыша, гибридлаша. Без шундый интернациональ итләрне, колбасаларны күбрәк ашаган саен, безнең тән хәтере җан хәтерен хәлсезләндерә башлый. Нәтиҗәдә, ул җиңә һәм син чистый маңкортка әвереләсең...

— Уф-ф... Шундый катлаулы итеп сөйлисең... Минем баш кына аңлый торган түгел...

— Дурацкая логика в квадрате дип атала бу.

— Исерек баштан туган, очы-кырые күренми торган логика, диген...

— Хәзер килик әлеге хайваннарның нәрсә ашауларына...

— Сыер печән ашый инде, дуңгыз — понятия не имею...

— Печән дигәннән... һәр авылның зираты бар. Игътибар иткәнең бар микән, зиратларда үләннәр, чәчәкләр болындагыларга, аландагыларга караганда куерак, калынрак булып үсә. Гадәттә, аларны, печән вакыты җиткәч, зират караучылар чабып ала. Чапканын әрәм итеп калдырмый бит инде ул зират караучы, әлбәттә, печәнне киптереп, өенә алып кайта, аннары сыерына, сарыгына, аты булса — атына ашата. Монда сугыш вакытында үлгән кешеләрнең мәетләре кайда туры килсә, шунда күмелгән дә һәм ул җирләрдә дә зираттагы шикелле үлән-чәчәкләр үсүен дә искә төшереп алырга кирәк. Аларның да хайваннар авызына ризык булу ихтималы юк түгел. Бәс, шулай итеп, синең бая әйткән соравыңа җавап: кабердәге гәүдәләр череп таркалгач, тән хәтере менә шул үсемлекләргә күчә, бер өлеше туфракка сеңә, туфрактагы бөҗәкләр ярдәмендә башка җирләргә күчә, парга әйләнә. «Чәчәкләр, гөлләр, агачлар үзләренә кагылганны алдан ук сизәләр, сискәнәләр, куркалар икән» дип укыганың-ишеткәнең бардыр. Дөрес ул. Әгәр син прапрабабаң турында информация алырга уйлыйсың икән,— дөрес, аның каберен төгәл белү кирәк,— бу күпмедер дәрәҗәдә мөмкин эш. Каберенә барып, бер уч туфрак аласың да, өеңә алып кайтып, гөл төбенә саласың. Менә шуннан соң гөл прапрабабаң белән синең арадагы арадашчы-информатор ролен үти башлый. Җан хәтерең белән элемтәгә керә. Әлбәттә, син аны үзең сизмисең. Әлеге гөл сиңа бәлаказаларны булдырмауда да ярдәм итәргә мөмкин. Синең җан хәтереңә алдан ук кисәтеп куя чөнки.

— Күрәм, син ачылып киттең... Телең телгә йокмый башлады.

— Кыскасы, общий нәтиҗә ясасак, шундый бер фикергә килербез: без ашаган һәр ризыкта, һәр суда хәтер бар. Төрле тән хәтерләре. Синең начармы-әйбәтме яки батырмы-куркакмы булуың, яисә маңкортмы-вундеркиндмы булуың әнә шул хәтерләргә бәйле. Кешеләрнең үзара сугышуы, туганнарның бер-берсен үтерүе, ата — улны, ул атаны бар дип тә белмәве — болар барсы да табигатьтәге төрле хәтерләрнең, винегрет булып, безнең организмга сеңүләренең нәтиҗәсе ул. Минем уйлавымча, кешелек бүген үзенең бугы белән уйнап утырган са-

бый хәлендә генә әле. Без — кемдер үткәргән уңышсыз эксперимент корбаннары. Кем әйтмешли, Җир шары бүген бар, иртәгә булмаска мөмкин.

— И-и-и, бигрәк мрачный итеп бетердең. Яшисе килми башлады хәтта.

— Яшибез әле. Экспериментны вакытыннан элек кенә туктатмасыннар... Каяле, тамак кипте, сухойны юешлик әле...

Үземә кырлы стаканга салырга туры килә инде.

— Ватмыйлар аны.

— Терсәк гаепле, мин түгел... Әйдә, безнең тән хәтере дә, җан хәтере дә менә шушы сухой кебек чиста, саф булсын өчен эчәбез!

— Кызыл булсын, әчкелтем булсын, дисеңмени?

— Ә-ә, дөрес әйтәсең, анысы бар икән шул... Просто чиста булсын өчен эчәбез алайса. Күтәрдек!

— Әкият сөйләп, колбасадан гайрәт чиктердең. Хәзер аңа караган саен косасы килә.

— Каплап куябыз аны... Менә болай итеп... Әнә кәнфит кап. Сухой тотканнан соң кәнфит шәп инде ул!

— Баллы бит ул.

— Ә син әче дип уйла. Ә-әһ... Тартып җибәрсәң шәп булыр иде хәзер.

— Өйне сасытма, зинһар.

— Теләсәм дә, тарталмыйм. Тәмәке юк чөнки.

— Бүген йоклатмадың син мине. Иртәгә эштә мәлҗерәп утырырмын микән инде...

— Нинди иртәгә? Бүген, диген! Сәгать дүрт бит инде!

— Бу шимбәдә... ә-ә-ә... иртәгә икән инде... авылга кайтып, Айгөлне алып киләбез. Әнигә күчтәнәчләр аласы булыр...

— Алырсың... Ләкин, к сожалению, мин кайта алмыйм.

— Ничек? Үзеңнең кызың янына кайта алмыйсыңмы?

— Эш бар чөнки.

— Бетмәс монда синең эш. Кайтабыз!

— Син кайтырсың...

—Ю-ю-у-ук инде. Бергә кайтабыз! Мунча да кереп киләбез.

— Әйтеп торам бит, срочный эш бар, дим!

— Кайтабыз булгач кайтабыз!

— Карале... тыңлале... Гәзиткә срочно мәкалә язып бирәсе бар. Дүшәмбегә эбизәтельне өлгертергә кирәк!

— Бүген яз! Менә хәзер үк яза башла!

— Бүген булмый. Мин эчкән чөнки.

— Берәр сәгать йокларсың да айнырсың...

— Йоклыйсы килми минем!

— Йоклыйсыңмы, йокламыйсыңмы, анда минем эшем юк. Әмма бүген язасың! Бүген язалмасаң, авылдан килгәч язарсың! Редакторыңа үзем шылтыратып әйтәм...

— Шылтыратма! Болай да синең шылтыратуыңнан туйган инде ул.

— Туйсын! Гел сине генә командировкага җибәреп ятмасын анда.

— Редакциядә бүтән яшь кеше юк чөнки.

— Тапсын! Үлгәнче пенсионерлар белән эшләргә кушылмагандыр бит аңа?!

— Пенсионерлар да кеше. Аларның да яшиселәре, тамак туйдырасылары бар...

— Ашыйсылары килсә, командировкага барсыннар!

— Кызык син! Авыру бит алар. Кайсында — геморрой, кайсында — язвы...

— Авырсалар, больницада ятсыннар! Больничный алсыннар!..

— Болай да кайберләре больницада ята инде. Ә бит гәзитне чыгарырга кирәк.

— Редакторың үзе чыгарсын! Өч тиенлек тә мәкалә язганы юк!

— Нигә язмасын! Басылып тора бит гәзиттә. Сан саен диярлек...

— Һе, син язып биргәнне белмиләр ди, морда. Оятсыз! Бер җөмлә дә яза белми үзе...

— Зато коллектив белән руководить итә белә.

— Төкерәм мин аның руководить итә белүенә... Коллектив, имеш... Сезнең сөрсегән коллектив белән хәтта дворник дядя Миша да руководить итә ала. Чыкылдап торган урыс булса да...

— Итәрсең, бар... Редакция диләр аны!

— Бетте. Бүтән артык сүз куертмыйбыз. Кайтабыз!

— Мин кайта алмыйм.

— Соңгы сүзең шулмы?

— Шул.

— Син... син... Айгөлне яратмыйсың син! Әни янына кайтмас өчен юри кыланасың!..

— Айгөлне яратам мин, гәрчә ул...

— Нәрсә — гәрчә ул?.. Әйтеп бетер җөмләңне. Йә, нәрсә — гәрчә ул?.. «Минеке түгел» димәкче буласыңмы? Йә, әйт, әйт! Эчеңдә калмасын...

— Мин кайта алмыйм! Аңлыйсыңмы? Мин кайта алмыйм!

— Оятсыз син! Әрәмтамак!

— Сүзеңне үлчәп сөйлә, яме...

— Үлчәмим дә, нитмим дә! Син — әрәмтамак! Әни җибәргән ризыкларны ашап ятучы сорыкорт син! Квартирант!

— Беттеме?

— Бетми генә торсын! Йодрыгыңны төйнәмә, яме. Курқытырмын дип уйлыйсыңдыр... Шишь — сиңа! Синнән курка торган нәселдән тумаган мин!

— Нәселеңне ачыклыйсы бар әле.

— Ачыкларммын мин сиңа, яме! Минем нәсел белән авыз чайкый башладыңмы инде хәзер?!

— Үзең башладың, мин түгел.

— Бик ачыклыйсы килсә, үзеңнең нәселеңне ачыкла! Хәерчеләр, сараннар нәселе!..

— Хәерче саран булалмый.

— Миңа фәлсәфә сатма, яме!

— Сатмыйм, әйтәм генә.

— Синең бит өйләнешкәннән бирле өйгә зарплата акчасы алып кайтканың юк. Айгөлгә берәр күлмәк алып биргәнең булдымы синең? Хет, кәнфит, ичмасам... Юк. Сөйләшеп торган буласың тагы! Алкаш несчастный!

— Ә син — алкаш хатыны.

— Сиңа кияүгә чыгып дурак булдым мин...

— Аңарчы да сизелә иде ул... Нәселегездә...

— Нинди шәп егетләрне кире бордым. Шул чакта ук синең ахмак икәнеңне белгән булсам...

— Әле соң түгел.

— Соң түгел шул! Соң түгел әле, Аллага шөкер! Син имгәктән арынырга вакыт бар... Күпме әйтте әни, күпме ялынды: «Чыкма, кызым, аңа, чыкма... Тормыш алып бара торган кеше түгел бу!» — диде...

— Тыңларга иде анаңны. Мине дә, үзеңне дә бәхетле иткән булыр идең!..

— Тыңлыйсым калган шул. Тыңлыйсым калган... Синең тәмле телләнүеңә ышанасыларым калмаган. Әни булмаса, күптән ачтан үлгән идек инде без. Синең булдыксыз икәнеңне белгәнгә күрә, кайткан саен, ризык төяп җибәрә әни. «Ач булмасыннар, кешечә яшәсеннәр!» дип җибәрә...

— Җибәрмәсен иде.

— Минем кешечә киенәсем дә килә! Натураль тун кимәслекмени мин?! Әни мине сәләмә киенеп яшәсен дип үстердемени? Кара аякларыңа! Шыпырт кына киенеп яткан буласың... Бу оекларны әни төн йокыларын калдырып бәйләде. «Кияү зур кешеләр арасында эшли. Тишектошык оек белән йөрмәсен» дип җибәрде ул сиңа.

— Мә, алайса, рәхмәт әйтеп, кире бирерсең...

— Аягыңның сасысы сеңгәчме? Оятсыз! Әни боларны биргән чагында, рәхмәт тә әйтә белмәдең бит син!

— Зато егетең рәхмәт әйткәндер. Авылга кайткач, аңа да оек биргәндер бит анаң?

— Бирсәни.

— Тем более... Баҗай рәхмәте дә бик җиткән алайса анаңа.

— Күпме төн йокыларымны калдырып көттем мин сине... Ә син сөяркәләреңдә кунып яттың. Командировкага кайчан киткәнеңне, аннан кайчан кайтканыңны белмәде бу, дип уйлама... Сөйрәлчек тәре! Белдем, бөтенесен дә белеп тордым. Дәшмәдем генә...

— Артың юеш булгач...

— Бала хакына түздем... Алло! Алло! Әйе. Соңыннан... Не туда попали... Это квартира...

— Сөйләш инде, сөйләш баҗай белән... Боргаланма. Үзең әйтмешли, кем шылтыратканын белеп торам бит. Бая да шул шылтыратты. Муму!..

— Син үзең — Муму! Кабахәт! Чыгып китеп кайда бармакчы буласың... Сөяркәләреңәме? Бар, бар, аларга синең кебек имгәк кирәк, ди! Артыңа тибеп чыгарырлар...

— Анда синең эшең булмасын!

— Барыбер миңа кайтып егылачаксың!

— Ни-ког-да!

— Син сөйрәлчек белән торганчы, суыткыч белән торам мин! Нервың да бетми, очсызга да төшә...

— Яшә, яшә, хет тузан суырткыч белән яшә! Чукынып кит!

— Мин урыс түгел. Чукынып тормыйм. Болай гына китәм...

— Кит, кит! Берәр җирдә кат шунда! Кадал, чәнчел!

— Каргама, каргышың үзеңә төшмәгәе!

— Бар, олак, күземнән югал!

— Ват, ват, минем савытлар түгел.

— Ватсын! Синнән сорап ватмыйм.

— Әнә бәллүр стаканыңны тондыр... Чао!

— Иблис син! Таракан син!.. Бөҗәк син!.. Син... Син... мин... мин... ңһе-һе-һе-һе... мин... ңһе-һе-һе... мин... яратам сине... кабахәт!..

*1993, декабрь*

# Җүләр малайның әтисе

*(Экстрасенс)*

**Ике пәрдәлек шаян пьеса**

КАТНАШАЛАР:

Гибралтар — авыл клубы мөдире, үзен «клуб директоры» дигәнне кулайрак күрә.
Миңниса — авыл карчыгы.
Ләйсән — Гибралтарның кызы.
Салават — авыл егете, Ләйсәнне ярата.
Хөббел — шәһәрдә слесарь булып эшләп кайткан авыл җилкуары, эчкече.
Кафил — тиле яшүсмер.
Фатыйма — җилбәзәк хатын, Кафилнең анасы.
Самат — Гибралтарның абыйсы, колхоз рәисе.
Галләм — бушкуык «экстрасенс».
Рифат — Галләмнең «ярдәмчесе».
Авыл халкы.

Вакыйга эт — баш, сыер аяк булган, СССР таркалган көннәрдә бер авыл клубында бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авыл клубы сәхнәсе. Сәхнәдәге һәммә җиһазның иске икәнлеге күзгә бәрелеп тора. Ян-яклардагы һәм арттагы бәрхет пәрдәләрнең (төсе нинди булуы мөһим түгел) аскы өлешләре тузып, ертылып беткән. Сәхнәнең уң ягында, алда фанердан эшләнгән трибуна тора. Трибунага СССР гербы төшерелгән. Герб уртасы чәрдәкләнеп беткән. Арттагы пәрдәгә «Хуш киләсең, Яңа ел!», «Хуш киләсең, экстрасенс әфәнде!», «Саулык — зур байлык!», «Акчаң булса, саулыгыңны кайгырт!» дигән лозунглар эленгән. Әүвәлге елларны искә төшереп торган лозунглар зал стеналарында да бар: «Сәнгать — халыкныкы! *В.И.Ленин*», «Партия — ум, честь и совесть народа», «Религия — опиум народа», «Кеше кешегә дус һәм (лозунг шушы урында ертылган)...» Сәхнәнең сул ягында, алгы тарафта марля тарттырылган ишек тора. Ишек өстенә «Директор ГИБРАЛТАР МАНСУРОВИЧ КӘШӘФЕТДИНОВ» дип язылган. Аңлашылганча, бу бүлмә — клуб мөдире бүлмәсе, шул ук вакытта гримм салу бүлмәсе дә.

«Зал» ягыннан шау-шу ишетелә. Кулларын «юк-юк» дигән төсле селти-селти, «Бар, бар, Миңнисаттәй, йөрмә аяк арасында чуалып! Кайт та ят өеңдә! Син яшисен яшәгән инде...» — дип кычкыра-кычкыра Гибралтар үз бүлмәсенә таба атлый. Аның артыннан: «Нишләп чуалыйм мин синең аяк арасында. Нишләп кайтыйм мин өйгә... Кайтмыйм әле!..» — дип сөйләнә-сөйләнә, таякка таянган, бер кулы белән чәйнек тоткан Миңниса карчык кыймыл-кыймыл килә. Ул, сәхнәгә менү өчен куелган баскычка абынып, гөпелдәп егыла. Чәйнеге кулыннан ычкынып-тәгәрәп китә — суы түгелә.

М и ң н и с а. Әстәгыфирулла! Суым! Хараплар булды сукаем! *(Азапланып тора да Гибралтар кереп киткән ишеккә карап.)* Синең артыңнан җитешәм дип, Гыйбрәт улым, аяксыз калам инде... *(Әүвәл кулындагы таякның кәкре башы белән чәйнекнең тоткасыннан эләктермәкче була, алай булдыралмагач, көч-хәл белән генә иелеп, чәйнекне ала. Көрсенеп.)* Азапланып алып килгән суымны хараплар гына иттем...

Миңниса карчык, ишектән эчкә үтәм дигәндә генә, ишек турысында кинәт пәйда булган Гибралтарга бәрелеп, чүт артына утырмый.

М и ң н и с а. Лә-хәүлә-вәлә куәтә! Тәмам котымны алдың, Гыйбрәт улым...

Г и б р а л т а р *(ярсып кычкыра)*. Миңнисаттәй! Күпме тукыйм инде мин синең шалкан үскән колагыңа. Әйтмә миңа Гыйбрәт, дип! Әйтмә! Канса да кансов, минем исемем — Гибралтар... Аңладыңмы, бабуля? Ги-брал-тар!

М и ң н и с а. Аңладым, аңладым, Гыйбрәтләр улым... Аңламыйммы соң! Сиксәнне генә узсам да, Аллага шөкер, ул кадәрле үк томана карчык түгел әле мин. Би-ик аңладым, Гыйбрәтләр улым...

Г и б р а л т а р *(кулларын гаҗизләнеп як-якка җәеп ала да биленә таяна)*. Уф! Җелегемне син генә корытасың, Миңнисаттәй. Бу чәчләрем агарса... *(Кулы белән башын сыйпаганда, башының ярым пеләш икәнен шәйли.)* Синең аркада гына агарачак!

М и ң н и с а. Китчәле, Гыйбрәт улым, булмастайны сөйләмә... Юк чәчеңне ничек агартыйм мин. Булмаганны. Сезнең бөтен нәселегездә... чәчләрегез агарганчы коелып бетеп бара.

Г и б р а л т а р. Җә, җә, булды. Җитте. Безнең нәселгә үк кереп чокчынма.

М и ң н и с а. Чокчынма, дип... Үзкәең «пеләшем агара» дип әйтеп-әйтеп әйткәнгә күрә генә әйтүем...

Г и б р а л т а р. Булды, булды. Җитте. Бүтән миңа Гыйбрәт, дип тә, Гыйбрәтләр, дип тә әйтеп-әйтеп әйтмә. Бик әйтәсең килеп телең кычыта икән, Кәшәфетдинов әфәнде, диген. Ишетсен колагың! Экстрасенс иптәшләр алдында оятка калдырма. Адәм хуры итмә мине! Җәле, әйтеп кара: Кәшәфетдинов әфәнде, диген...

М и ң н и с а. Әйтәм, әйтәм. Ник әйтмәскә. Хәзер әйтеп әйтәм. Авызымдагы төкерегемне генә йотып җибәрәм дә... *(Авыз тирәсен әле таяк тоткан кулы белән, әле чәйнеклесе белән сөртеп ала.)* Кә-шә-фет-дин-уф... уф әф... әфән-де... Кәш-шә-бет... бет...

Г и б р а л т а р. Стоп! Стоп! Нәгаләт! Нишләп бет булыйм

мин, телеңә тилчә чыккыры! Йөз яшькә җиткәнсең, ә үзең кешенең исем-фамилиясен дә җүнле рәтле әйтә белмисең.

М и ң н и с а. Каян килеп йөз яшь булсын. Сигез дистәне дә түгәрәкләмәгән әле мин. Җитмешкә яңа җитеп киләм. Нишләп йөз булсын...

Г и б р а л т а р. Ярар, ярар. Йөз булмаса — булыр. Бу мәңге арымас телең белән син йөз дә бер яшькә дә җитәрсең әле.

М и ң н и с а. Авызыңа бал да май, Гыйбрәт у... у... *(Гибралтарның акайган карашын күреп, ялгышын төзәтмәкче була.)* Кә-шә-бет-дин-уф... уф эф...эф-ән-де... улым! Бирсен Ходай берүк! Әле бүген кылубка икестырасилус та килә, дип тә әйтеп-әйтеп әйтәләр бит. Ул икестырасилус та сихәтләндереп китсә, Аллаһы Тәгалә дә мәрхәмәтеннән ташламаса, йөз иллегә дә җитәрбез, иншалла.

Г и б р а л т а р. Җитәрсең, җитәрсең. Аңарчы бөтен авылны нервынныйга әйләндерәсең әле син.

М и ң н и с а *(чәйнегенә ишарәләп)*. Менә суым түгелеп хараплар булды бит әле. Икестырасилуска шифа иңдерергә дип алып килгәнием. Тагын алып киләсем була инде. Чишмәдән очыртып кына алып кайтканыем...

Г и б р а л т а р. Очырткансыңдыр инде бик... бу ташбака аякларың белән. *(Кулындагы сәгатенә карый.)* Синең белән әвәрә килеп, ярты көнем әрәм булды. Бар, бар, торма монда бакча карачкысы кебек. Кайт өеңә. Мунча як.

М и ң н и с а. Мунча? Нишләп әле тиктомалдан мунча ягыйм мин?

Г и б р а л т а р. Тиктомалдан түгел. Кирәк булганга.

М и ң н и с а. Кемгә кирәк булганга? Сиңамы? Синең бит, Гыйб... әйем лә... Кә-шә-бет-дин-уф эф... эф-ән-де, улым, үзеңнең алагаем зур мунчаң бар. Эскерт чаклы.

Г и б р а л т а р. Миңа түгел, Ходай бәндәсе. Синең үзеңә кирәк. Экстрасенс иптәш сеанстан сиңа кайтыр. Юлдан килгән кеше. Мунчаң бик әйбәт кенә булыр үзенә. Берочтан үзеңне дә карар.

М и ң н и с а. Мунчадамы?

Г и б р а л т а р. Абзардамы, диген тагы... Нишләп мунчада карасын инде, өеңдә карар.

М и ң н и с а. Чынлаплар әйтәсеңме, Гыйбрәт улым? *(Ялгышын төзәтмәкче булып.)* Әфәнде улым? Карт кешене шаяртуың гына түгелдер бит?!

Г и б р а л т а р. Чынлап инде, чынлап. Ахирәт корткаларыңны да чакыр. Сине карагач, аларны да карар.

М и ң н и с а. И-и-и... Бигрәкләр дә кешелекле кеше инде син... әф-фән-де улым. Аллаһы Тәгаләдән рәхмәтләр яусын үзеңә. Берүк мәрхәмәтеннән ташламасын. Минем ни инде... ырматиз. Аякларым бик яман сызлап интектерә. Төннәр буе улап чыгам...

Г и б р а л т а р. Мин, җүләр, нинди бүре улый соң, дип, төннәр буе йоклый алмый ятам тагы. Син булгансың икән, Миңнисаттәй.

М и ң н и с а. Көлмә, көлмә... улым... әфәнде. Менә шул... ике... ике... икестырасилуста инде бөтен өметкәйләр... Икестырасилусларның куллары бик шифалы була икән, дип әйтеп-әйтеп әйтәләр бит. Аннан соң... Беләкләрем дә бик каты сызлый. Билкәем авыртып җәфалый. Күкрәгемдә дә нәрсәдер өзелеп-өзелеп киткәндәй була. Тешләрем дә капка баганалары кебек селкенеп тора. Аларын да карар микән икестырасилус?

Г и б р а л т а р. Карый инде, карый. Кайсы төшеңне күрсәтсәң, шул җиреңне карый. Бар, бар... Кайт та тизрәк мунчаңны як! Дасвидание!

М и ң н и с а. Кайтам, кайтам... Очыплар кайтам. Рәхмәтләр яусын үзеңә, әф-фәндекәем! *(Баскычтан «зал»га төшәргә азаплана.)* Шушы җәһәннәм баскычыннан гына төшәм дә кайтам... Кайтам да дөрләтеп җибәрәм мунча мичен. Абыныплар гына хараплар булмасам... Лә-хәүлә-вәлә куәтә.

Шулай быдыр-быдыр сөйләнә-сөйләнә, чәйнеген шалтырата-шалтырата, Миңниса чыгып китә.

Г и б р а л т а р. Үземнең дә кайчак баш эшләми тора. Әллә кайчан ук шулай дип кенә алдап-йолдап җибәрәсем калган икән бу карт үрдәкне. (*Миңниса чыгып киткән якка карап.)* Персидәтелнең алты почмаклы мунчасына бармыйча, синең туксан тугыз җирдән йомран кебек җил сызгырып торган эчерек утын өемеңә кайтты ди экстрасенс. Аның башына тай типкән ди... Әһе, көтеп тор!

Гибралтар бүлмәсенә кереп китә. Л ә й с ә н керә.

Колакларында наушник. Ул, колакларында яңгыраган ниндидер җыр тәэсирендә селкенгәләп, башын дәртле чайкалдырып, сәхнәгә менә. Кулына микрофон тоткан кыяфәт ясап җырлый башлый.

Л ә й с ә н.

Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсуланам,
Бәгырькәем сине күрдисәм...

Бүлмәсеннән Г и б р а л т а р чыга да Ләйсәннең кыланмышын күзәтә.

Г и б р а л т а р. Кызым! Ләйсән, дим! Нишләвең бу?

Ләйсән Гибралтарны күреп ала. Җыр тәэсиреннән арына алмыйча селкенүен дәвам итә.

Л ә й с ә н. Әти! Экстрасенслар килмәдеме әле? *(Наушнигын сала.)*

Г и б р а л т а р. Юк әле. Ниемә кирәк алар сиңа?

Л ә й с ә н *(селкенүеннән туктап, әтисе янына килә)*. Болай гына соравым. Бөтен авыл халкы көтә бит. Чиләкләп, чәйнекләп ташый-ташый, колонканың суын бетерәләр инде.

Г и б р а л т а р *(кызының кыска күлмәк итәгенә ишарәләп)*. Тагы да кыскарак күлмәгең юк иде мәллә?

Л ә й с ә н (боргаланып). Бар иде. Табалмадым. Әни каядыр яшереп куйган бугай.

Г и б р а л т а р. Дөрес эшләгән. Бар. Монда чуалма. Хәзер кешеләр килергә тиеш монда. Экстрасенслар килеп төшсә, кайдан килгән цирк артисты бу, дип уйларлар үзеңне.

Л ә й с ә н. Уйласалар тагы. Бик исем китте.

Г и б р а л т а р. Бар, кызым, бар. Кайтып озынрак күлмәгеңне ки. Минем эшем күп. Төшке ашка кайтып тормам. Әниеңә әйтерсең. *(Бүлмәсенә кире кереп китә.)*

Ләйсән янә сәхнә уртасына чыгып баса.

Л ә й с ә н *(хыялга-хискә бирелеп)*. Җырлый Ләйсән Фәтхетдинова!

Шул вакыт С а л а в а т керә.

С а л а в а т *(килә-килешли)*. Ниткән Фәтхетдинова ул тагы? Кәшәфетдинова бит син!

Л ә й с ә н. Салават?!

С а л а в а т. Салаватын Салават... Тик Салават Фәтхетдинов кына түгел. Салават Корбыев булыр абзаң!

Л ә й с ә н. Фи! *(Җирәнгән сыманрак.)* Кор-бы-ев... Шушы да булдымы фамилия. *(Сокланып.)* Фәтхетдинов! Менә ул фамилия, ичмасам!

С а л а в а т. Шул Салават Фәтхетдиновың белән җенләнәсең бугай инде. Күбрәк мине уйла син, мине. *(Ләйсәнне кочып алмакчы була.)* Мин дә Салават бит!

Л ә й с ә н *(читкә тайпылып)*. Тс-с-с! Әти монда. *(Чытлыкланып, кыланып.)* Синең фамилияң җүнле түгел шул... Кор-бы-ев... Ләйсән Кор-бый... Юк, яңгырамый... Фамилияңне кыскартсаң да булмый... Пшыйк!

С а л а в а т. Бабай Корбый исемле булганга, мин гаепле түгел инде.

Л э й с ә н. Аннан соң җырлый да белмисең...

С а л а в а т. Минме? Җырласам, синең Салават Фәтхетдиновың шикелле генә җырламыйм инде мин.

Л э й с ә н. Хәчтерүш! Мактанган була тагы. Салават Фәтхетдиновка җитәргә әле сиңа. Сыерлар тоз ялаганда, бозаулар ими имә... Минем бабай синең ишеләргә шулай ди. *(Салаватның борынына бармагын тидереп ала.)* Вәйт!

С а л а в а т. Көлмә, көлмә... Синең бабаң белеп әйтми ул... Син менә мин җырлаганны тыңла башта. *(Җырларга әзерләнә.)*

Л э й с ә н *(нәфис сүз осталары сыман)*. Сәхнәдә — Салават Фәтхетдинов! Әй лә... Салават Корбыев!

С а л а в а т *(нәкъ Салават Фәтхетдинов кебек кылана, сөйләм-тавышын да аңа охшатырга тырыша)*. Кадерле тамашачылар, әбиләр, апалар, кызлар! Хәзер мин сезгә өр-яңа бер җыр сылаем!

Л э й с ә н *(кулларын чәбәкли)*. Афәрин!

С а л а в а т *(җырлый)*.

Урамнардан уйнап киткәнем бар,
Иптәш итеп бала-чаганы.
Акыл тешем күптән чыккан инде,
Акыл ягы гына чамалы-ы-ы...

Мин һаман да унсигездә кебек,
Йөрәк һаман шулай түземсез.
Тик унсигез яшьлек кызлар гына
«Абый, абый! Салават абый!
Салават абый!» — диләр, шунсы күңелсез...

Л э й с ә н. Браво, Салават! Афәрин, Салават! (Бармагын авызына кабып, сызгырып та җибәрә.)

Г и б р а л т а р бүлмәсеннән чыга.

Г и б р а л т а р. Салават Фәтхетдинов килгән мәллә дип торам. Нинди бака туе монда? *(Ләйсәнгә.)* Әле син кайтып китмәдеңмени?

С а л а в а т. Без... ни... Гибралтар абый... Ләйсән бит әнә... Җырларга куша...

Л э й с ә н. Минме? Мин куштыммы? Җырлый белсәң ярар иде...

Г и б р а л т а р. Барыгыз, бар... Чуалмагыз монда. *(Ләйсәнгә.)* Әйттем бит инде мин сиңа, кызым.

Л э й с ә н. Китәбез, эти, китәбез. Киттек, Салават... *(Мыскыллы елмаеп.)* Фәт-хет-ди-нов!

С а л а в а т. Ә син... ә син... *(Сүз табалмый тора.)* Мәчтүрә!

Чыгып китәләр.

Гибралтар *(артларыннан кычкырып кала)*. Ләйсән! Туп-туры өйгә кайт. *(Үзалдына.)* Филармония! Тфү! *(Кулын селтәп ала да бүлмәсенә кереп китә.)*

Тышта җыр тавышы ишетелә. Бераздан «зал» ишеге ачылып китә дә аннан салмыш Хөббел керә. Изүләре шыр ачык. Каралып беткән юка чүпрәк кепкасын алдын артына әйләндереп кигән. Алпан-тилпән килеп, яшелле-зәңгәрле тавыш чыгарып җырлый-җырлый, сәхнәгә таба атлый.

Хөббел.

Югарочтан түбәночка
Тәгәрәтәләр мичкә.
Әби, кызың бигрәк нечкә,
Түзәр микән бер кичкә?..

Хөббел җырның соңгы ике юлын янә бер мәртәбә кабатлый да баскыч турысына җиткәч туктый.

Хөббел *(Гибралтар бүлмәсенә карап кычкыра)*. Гыйбрай! Выходи, подлый трус!

Гибралтар бүлмәсеннән чыга.

Гибралтар. Нәрсә акырасың, одеколон бүчкәсе?

Хөббел. Син үзең бүчкә! *(Гибралтарның бүлтәйгән корсагына ишарәләп.)* Ит бүчкәсе!

Гибралтар. Хөбби, эчкәнсең икән, буеңа сеңдер. Ничу монда кешене мыскыл итәргә!..

Хөббел *(көйләп)*. Не шуми, друг... *(бармак яный)*... а то вдруг... (*Бармагын кыңгырау төймәсенә баскандай итә.)* Челтер-рефун! Здрасте! Слесаря вызывали?

Гибралтар. Әйдә, әйдә, артистланма! Керсәң кер бүлмәгә, кермәсәң — дүрт ягың кыйбла! Минем болай да вакыт юк! *(Бүлмәсенә кереп китмәкче була.)*

Хөббел *(баскычтан менмәкче була, ләкин артка сөрлегеп китә)*. Гыйбрай! Руку давай! А то баскычың өскә шуа...

Гибралтар *(Хөббелгә якынрак килеп, кулын суза)*. Әйдә, әйдә, тизрәк бул. Персидәтел килгәнче сөйләшеп куярга кирәк.

Хөббел. Ыслушай, Гыйбрай! Төкерәм мин синең персидәтелеңә! Мин үзем персидәтел! Понял!

Гибралтар. Понял, понял. Тагын йөз грамм манчысаң, район башлыгы булырга да ерак калмый сиңа. Әйдә, кер тизрәк!

Хөббел. Кермим! Монда гына алып чык!

Гибралтар. Нәрсәне?

Х ө б б е л. Ыслушай, Гыйбрай! Әллә син дә исәр Кафил кебек *(чигәсендә бармагын биетеп ала)* полоумный инде? Әле генә йөз грамм манчытам, дип әйттең бит...

Г и б р а л т а р. Ну, зимагур... Ну, Хөбби...

Хөббел. Саранланма, Гыйбрай. А то Хөббел умирай... давай, быстро шагай! Одеколонның махмырын үзең беләсең... Егылдым-үлдем булыр... Ник чакырганыңа үкенерсең аннары...

Г и б р а л т а р. Бүлмәгә кереп салсаң булмыймы?

Х ө б б е л. Булмый. Кәтигәрический против. Синең бүлмәнең исе ярамый миңа. Аллергия! Теге вакытны кереп эчкәнгә дә үкенеп бетәлмим. Очкылык тотып, өч көн мучыйтсы иттем.

Гибралтар үз бүлмәсенә кереп китә. Хөббел, кулларын артка куеп, канәгать елмаеп, сызгырына-сызгырына, ишек төбендә йөренә. Яртылаш аракы салынган стакан тотып Г и б р а л т а р чыга.

Г и б р а л т а р. Мә, кеше күргәнче салып куй. Закуска юк. Кипкеңне иснәрсең.

Х ө б б е л. Аның иснәрлеге калмады инде. *(Стаканны кулына тота.)* Ну, саран да кеше инде син, Гыйбрай. Шуны тутырып булмый идеме? Җә, ярар, кабат алып чыгарсың. *(Аракыны җәһәт кенә авызына коя да Гибралтарның кәчтүм очын тотып исни.)* Үземнең кәчтүмгә «Тройной» одеколон түгелгән иде. Җә укшып, аракыны косып әрәм итәрмен...

Г и б р а л т а р. Булдымы, Хөбби?

Х ө б б е л *(бераз дәшми торганнан соң)*. Пока булды. Яхшы пошел. Давай, әйт инде хәзер... Ник чакырдың?

Стаканны Гибралтарга бирә. Гибралтар аны кәсәсенә тыга.

Г и б р а л т а р. Менә-менә экстрасенс иптәш килеп җитәргә тиеш.

Х ө б б е л. Экстра, дисең, берәр аракы заводы директоры мәллә?

Г и б р а л т а р. Мин сине тыңладым. Йөз грамм эчердем. Хәзер инде син мине тыңла. Юк-бар сораулар бирмә. Экстрасенс ул — чирле кешеләрне дәвалый торган иптәш-әфәнде. Менә шул иптәш-әфәнде главный ярдәмчесе белән бергә безнең авылга килә.

Х ө б б е л. Аңлашылды.

Г и б р а л т а р. Нәрсә аңлашылды?

Х ө б б е л. Синең ул экстрасинусың безнең авылны терелтергә дип килә.

Г и б р а л т а р. Авылны түгел, авыл халкын терелтергә килә.

Х ө б б е л. Барыбер инде. Авылы да чирле, кешеләре дә. Мин генә сау-сәламәт! Шәһәрдә слесарь булып эшләп кайтмаган булсам, мин дә сезнең кебек чирләшкәгә әйләнгән булыр идем.

Г и б р а л т а р. Тыңла, Хөбби. Сөйләп бетергәнне көт. Менә шул экстрасенсның главный ярдәмчесе беркөнне килеп, мине күреп китте. Шул әйтте, бер-ике кеше әзерләп куй, диде. Мәһәреннән тормабыз, диде. Без кушканны эшләр, диде.

Х ө б б е л. Аңлашылды.

Г и б р а л т а р. Нәрсә аңлашылды?

Х ө б б е л. Димәк, мин маймыл булам. Шимпанзе, ягъни мәсәлән. Ә синең экстрасинусың тәҗрибә үткәрә... Күпме эчәргә кирәк?

Г и б р а л т а р. Нәрсәне?

Х ө б б е л. Соң... Нәрсә булсын инде. Аракы! Ул экстрасинусың миңа аракы эчерә, мин исермим. Ул миңа тагын эчерә, мин исермим...

Г и б р а л т а р. Дөрес аңламагансың, Хөбби. Аракыны син соңыннан эчәсең. Ә сәхнәдә басып кына торасың.

Х ө б б е л. Һәйкәл кебекме?

Г и б р а л т а р. Әйе, һәйкәл кебек. Ләкин минем үз гомеремдә селкенеп торган һәйкәл күргәнем юк әле. Селкенмичә басып торалсыңмы?

Х ө б б е л. Бер дә әйтә алмыйм бит. Моңарчы алай басып торган булмады. Коймага сөялеп торган бар. Бәлки, сөялеп кенә торыргадыр?

Г и б р а л т а р. Ярар, монысын экстрасенс иптәш килгәч хәл итеп бетерербез. Бәлки әле урындыкта гына утырып торырсың...

Х ө б б е л. Яхшы. Тик син урындыкның тазасын әзерләп куй. Ялгыш аяклары чыгып очарлык булмасын... Ятарсың аннары идәндә адәм мәсхәрәсе булып!

Г и б р а л т а р. Ярар, ярар. Анысын гына карармын. Син риза инде алайса? Кара аны, падвадить итмә!

Х ө б б е л. Шту син! Шту син! Беләсең бит инде, Гыйбрай... Аракы бирәм, дисәләр, мин лампочка шикелле эленеп торырга да риза.

Г и б р а л т а р. Килештек алайса?! *(Кулын Хөббелгә суза.)*

Х ө б б е л. Килештек... *(Хөббел дә кулын суза да кинәт кире ала.)* Ә-ә-ә... юк!

Г и б р а л т а р. Нәрсә тагы?

Х ө б б е л *(хәйләкәр елмая)*. Тагымы? Алып чык тагы? *(Гибралтарның кесәсендәге стаканга ымлый.)* Шуннан соң по рукам!

Г и б р а л т а р. Булсаң да булырсың икән бүрәнкә авыз.

Х ө б б е л. Җә, җә, чәпчемә. Алып чыксаң алып чык... А то... киттем бардым булыр...

Гибралтар бүлмәсенә кереп китә дә аракылы стакан тотып кире чыга.

Г и б р а л т а р. Сеанска алданрак килеп утырырсың. Кара аны!

Стаканны Хөббелгә суза. Хөббел җәһәт кенә эчеп куя да җиңен исни.

Х ө б б е л. Синең бүлмәгә килергәме?

Г и б р а л т а р. Нишләп минем бүлмәгә булсын... Залга! Алгы рәткә утырырсың. Анда сиңа урын булыр.

Х ө б б е л. Понятно! Экстрасинусыңа әйтеп куй, Хөббел килә, диген. Бармотухалар белән вакланмасын. Денатураттан болай да туйган! Чын аракысы булмаса, сәхнәгә атлау түгел, үрмәләп тә менмим. Безовсяки алдаусыз әйтәм. Мин әйтсәм — үзең беләсең... Хөббел әйттеме — ул закун!

Г и б р а л т а р. Ярар, ярар. Бар, кайтып бераз йоклап ал... Кеше кыяфәтенә кер...

Х ө б б е л. Менә монысы булмас, Гыйбрай. Йоклап ятып, авызга керергә торган аракыдан колак кагасым юк! Шалиш! Үзең беләсең, мин йокласам, каты йоклыйм. Ник шунда калхузыгызның барлы-юклы сигез тракторы килеп пытырдамый — селкенмим дә.

Г и б р а л т а р. Анысы бар икән шул... Син, алайса, ничек тә йоклама инде, Хөбби.

Х ө б б е л. Есть, тавариш генерал, один солдат умирал, Хөббел абзаң өендә, калганнары пелиндә!.. Гыйбрай! Мин киттем... Закускалар хәстәрләп куй! Первый... Втарай... И тагдалие. *(Җырлый-җырлый «зал»га төшә.)*

Зимагурны шуннан таныйм —
Сул ягында кесәсе.
Кесәсеннән күренеп тора
Одеколон шешәсе-е-е... *(Чыгып китә.)*

Г и б р а л т а р *(артыннан карап)*. Филармония! Закуска сиңа... Первый... Втарай... Тфү! Тот капчыгыңны!

Бүлмәсенә кереп китмәкче була. Шул вакыт, су тутырылган ун литрлы банка күтәреп, «зал»га К а ф и л керә.

К а ф и л *(Гибралтарга таба килә-килешкә кычкыра)*. Дирехтыр абзый! Менә-ә! Булды!

Г и б р а л т а р *(Кафилгә бермәл текәлеп карап)*. Булдымы, бырат? Булса, күтәр ыштаныңны!

Кафил, атлавыннан туктый да, бер кулы белән банканы кочаклап, икенчесе белән чалбарын күтәрмәкче була.

К а ф и л. Чалбарыңны, диген, дирехтыр абзый... Ыштан түгел бит бу... Хәзер күтәрәм...

Г и б р а л т а р. Нишлисең син, яп... яланаяк! Төшереп ватасың бит банканы!

К а ф и л. Яп-яланаяк бернишләмим... *(Каушаудан банкасын чүт кулыннан ычкындырмый.)* Үзең бит... дирехтыр абзый... Үзең бит... күтәрергә кушасың ы-ы... чалбарны...

Кафил бер кулы белән чалбарын өскә тартып тора.

Г и б р а л т а р. Вәйт, тиледәр сыңары! Күтәрмә ыштаныңны, төшер! Мин бит болай гына әйттем. Сүз өчен генә. Әйдә, кил монда тизрәк! Сак бул, банканы вата күрмә!

К а ф и л *(кузгалмыйча тора)*. Төшериммени, дирехтыр абзый?

Г и б р а л т а р. Нәрсәне?

К а ф и л. Чалбарны-ы...

Г и б р а л т а р. Ну... *(Ярсуыннан үзен-үзе кая куярга белми.)* Үзем дә җүләрләнәм бугай инде. *(Туктап, Кафилгә карый.)* Кафил туган! Быр-рат! Үскәнем! Акыллым! Тилекәем! Тимә ыштаныңа. Җибәр кулыңны каештан. Зинһар, ике кулың белән дә тот банканы. Хәзер акрын гына кил монда... Берүк сак атла...

Кафил баскыч янына килеп җитә.

К а ф и л. Баскычтан менимме, дирехтыр абзый? Мин менә беләм!

Г и б р а л т а р. Мен әйдә, мен... Ә юк! Стоп! Җә банканы харап итәрсең. Шунда гына тор.

Гибралтар баскычтан төшә дә Кафил кулыннан банканы ала.

К а ф и л. Мин — маладис, әйеме, дирехтыр абзый?

Г и б р а л т а р *(баскычтан менә-менә)*. Маладис, маладис... Уф!..

Кафил аның артыннан иярә.

К а ф и л. Жывачка бирерсең инде, җәме, дирехтыр абзый?! Маладис та булгач...

Г и б р а л т а р *(банканы сәхнә уртасына куелган башка сулы савытлар янына идәнгә куя)*. Бирермен, бирермен... Берне түгел, икене бирермен... *(Билен турайтып баса.)* Уф!.. Авыр икән шул бу!

К а ф и л. Авыр шул, дирехтыр абзый. Мин дә көчкә күтәрдем.

Г и б р а л т а р. Чишмәдән алгансыңдыр бит суны?

К а ф и л. Әйе, дирехтыр абзый. Чишмәдән алдым. Мин тагын маладисмы?

Г и б р а л т а р. Маладис, туган, маладис.

К а ф и л *(сөенеп)*. Алайса, тәмәке дә бирерсең инде, җәме, дирехтыр абзый?

Г и б р а л т а р. Тәмәке? Нәрсәгә ул сиңа?

К а ф и л *(ботинкасының очы белән идәнне «чокый»)*. Тартырга инде... Нәрсәгә булсын тагы...

Г и б р а л т а р. Синең бит башың яшь, Кафил туган. Нәрсәгә дип тартасың аны?

К а ф и л. Кызык бит.

Г и б р а л т а р. Нәрсәсе кызык аның?

К а ф и л. Авыздан төтен чыгуы кызык.

Г и б р а л т а р. Һе! Төтен морҗадан да чыга ул. Менә анысы кызык, ичмасам!

К а ф и л. Ю-ук, морҗаныкы кызык түгел. Авыздан чыкканы кызык. Хөббел абзый танавыннан да чыгара белә. Анысы тагы да кызык!

Г и б р а л т а р. Хөббел абзаңа карама син. Алкаш бит ул. Ул сиңа әллә кайсы җирләреннән чыгарып күрсәтер. Син менә миңа кара — миннән төтен чыкмый бит.

К а ф и л. Ы-ы-ы... Син бит — дирехтыр абзый! Дирехтыр абзый булсам, миннән дә төтен чыкмас иде.

Г и б р а л т а р. Җә, ярар, күп сүз — чүп сүз. Тәмәке юк. Кәнфит бирәм.

К а ф и л. Кәнфит кирәкми. Жывачка бир. Күп итеп акча да бир. Тәмәке алырга җитәрлек булсын! Җәме, дирехтыр абзый?!

Г и б р а л т а р. Ярар, ярар... *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

К а ф и л *(үзалдына сөйләнә)*. Тиле дигәч тә... Чишмәгә йөгертмәкче була мине. Барды ди ул хәтлүк еракка. Колонкада су була торып...

Бүлмәсеннән Г и б р а л т а р чыга.

Г и б р а л т а р. Мә, Кафил туган! Тәмләп чәйнә! *(Бер сагыз бирә.)*

К а ф и л. Бирәү генәмени? Икене бирәм, дидең бит?!

Г и б р а л т а р *(кесәсеннән янә бер сагыз чыгара)*. Әй, монысы кесә төбендә онытылып калган икән...

К а ф и л *(сагызны ала да)*. Ә акча?

Г и б р а л т а р. Уф!.. Авызыңда сагыз, кулыңда сагыз... Үзең дә чистый сагыз булырсың икән... Мә, мә! Бөтен булганы шул. Бүтән юк.

К а ф и л *(кәгазь акчаны ала да)*. Тәмәке алырга җитәме бу, дирехтыр абзый?

Г и б р а л т а р. Җитә инде, җитә. Тәмәке алмасаң, ике сагызга какырас җитә. Бар, бар! Кибеткә чап инде хәзер!

К а ф и л *(китмәкче була да кинәт туктап)*. Дирехтыр абзый!

Г и б р а л т а р. Нәрсә тагы? Нишләп китмисең инде?

К а ф и л. Тагын алып килимме?

Г и б р а л т а р. Нәрсәне?

К а ф и л. Су алып килимме тагы? Тегесен түк тә банкыны бир...

Г и б р а л т а р. Уф! *(Башын тота.)* Бар әле, бар! Җитә миңа бу су, җитә! Экстрасенс өшкереп бирсә, бер елга җитәрлек! Бар, бар! Нишлим мин ул хәтле су белән?

К а ф и л *(сагызын тәмләп чәйни-чәйни)*. Эчәрсең. Менә тагы! Битеңне юарсың... Су кирәк була инде ул. Сусыз яшәп булмый. Без өйдә чәйне гел су белән эчәбез...

Г и б р а л т а р. Уф!.. *(Йөренә.)* Уф!.. Чыда, газиз башкаем! Чыда! Бу тиләләр арасында миңгерәүләнә күрмә берүк! Кемнәр белән бәйләндем бит! Кемнәр белән бәйләндем... Кайдан гына килеп чыкты бу чәнчелгере экстрасенслар?! Үтерәләр бит мине монда хәзер... Аңгырайтып үтерәләр!..

К а ф и л. Алып килимме инде, дирехтыр абзый? *(Бармагы белән битараф кына борын тишегендә казына.)*

Г и б р а л т а р. Аһ, Ходай бәндәсе, синең телеңне бәйләп куеп та булмый бит, ичмасам...

К а ф и л. Ә нигә бәйләргә аны? Эт түгел лә ул... Тел *(телен чыгарып, үз теленә карамакчы була)*... Нигә бәйләргә аны...

Г и б р а л т а р. Низна-ю! Низна-ю! Атвались атсюды!

К а ф и л. Мин дә урысча беләм... Бер сүз беләм... Хөббел абзый шәһәрдән өйрәнеп кайткан. Шул өйрәтте. Әйтимме, дирехтыр абзый?

Гибралтар куллары белән кирәкми дигән хәрәкәтләр ясый.

К а ф и л. Персидәтел абзый белми икән ул сүзне. Мин аңа беркөнне әйткән идем... Аңламады. Шуннан ул мине йодрыкларын төйнәп куарга тотынды. Миңнисаттәйләр өенә чаклы куды... Тоттырмадым! «Пафтаринука! Пафтаринука!» дигән була... Нәрсә дип әйтүе булгандыр... Әй, тиле кешенең нәрсә әйткәнен аңлап буламыни аны!

Г и б р а л т а р *(көч-хәл белән)*. Үт-терә-сең!.. Бар... чыгып кит!

К а ф и л. Филдшер абзыйны чакырыйммы, дирехтыр абзый? Хәзер алып киләм мин аны... Өендә микән, ат печәргә китте микән?..

Кафил чыгып китмәкче була. Каршысына ашыгып керүче Самат очрый. Самат Кафилгә йодрыгын селки. Тегесе, телен күрсәтеп, җәһәт кенә чыгып сыза.

Самат. У-ух, мин сине, тиле тәре!

Самат, җил-җил атлап, мөдир бүлмәсенә таба атлый. Гибралтар, сызланып-ухылдап, аны көтеп тора.

Гибралтар *(күрешергә кулын сузып)*. Саумы, абый? Өеңдә бер көедер бит? Җиңги сау-тазамы?

Самат *(күрешә)*. Нәрсә булсын аңа. Селкенә шунда.

Гибралтар. Селкенгәч ярый инде. Селкенмәсә, нишләр идең...

Самат *(лозунгларны бер кат күздән кичереп)*. Син нәрсә, үләргә җыендың мәллә? Бөтенләй төсең качкан. *(Зал ягына ишарәләп.)* Нишләп йөри ул Фатыйма тилесе?

Гибралтар *(кулын селти)*. Әй... Экстрасенс өшкергән су файдалырак булмасмы дип, Ерак чишмәдән су китерткән идем. Башымны катырып чыгып китте. Тилебәрән орлыгы ашаган дуңгыз малай...

Самат. Тилегә йомыш кушмасаң... Башка кеше беткән идеме?

Гибралтар. Ун литрлы банка белән су алып килде. Аны Хөббелгә кушалмыйм бит инде. Аңа кушканчы, шушы җүләре лутчырак булмасмы, дигән идем...

Самат. Су дигәннән, миңа да ике битун су китереп куярлар. Сәхнәнең урта бер җиренә куйдырт.

Гибралтар. Шулай итәрмен, абый.

Самат *(сәхнәдәге банкаларга, шешәләргә карап йөри, сулы бер аракы шешәсен кулына ала, борынына ук якын китереп иснәп карый)*. Чынлап та су икән. Аракы мәллә дип торам. *(Шешәне кире урынына куя.)* Артистлар икәүме әле алар?

Гибралтар. Икәү, икәү, абый. Экстрасенс иптәш и ас... ас... ассис... тисент! Үзе и ярдәмчесе.

Самат. Килгәч, аларны ашханәгә алып барырсың. Анда аларга кое-што әзерләнеп куелган. Үзең оештырырсың. Алар белән минем булалмавым ихтимал. Штобы тәртип булсын! Артыгын җилләтмә! Калганнарын үзеңә алырсың. Шулар чутыннан списать итәрбез.

Гибралтар. Рәхмәт, абый. Барысын да син әйткәнчә эшләрмен. Экстрасенс иптәшләр довольный калырлык итеп эшләрмен.

Самат. И ишше: иптәшләргә әйтеп куярга онытма. Концерттан соң миңа кайталар. Җиңгәң мич каршында нәрсәдер маташтырып калды анда.

Гибралтар. Концерт, дип, концерт түгел инде ул, абый. Сеанс.

Самат. Неважны анысы. И ишше: түләү мәсьәләсендә борчылмасыннар. Сөйләшкәнчә: бер сыер аларныкы. Какырас көтүдән бер сыер күбенеп үлә язып кайткан иде. Шуңа тагын бер сыерны плюсовать итәрмен. Күз төшереп йөргән бер кысыр сыер бар иде. Шуны икебезгә хәл итәрбез.

Гибралтар. Рәхмәт, абый. Болай да гел булышып торасың инде.

Самат. Бертуганга да булышмагач, кемгә булышыйм тагы. Чит-ят авызларга *(бармагын өскә күтәреп)* болай да китеп бара инде. Вакытыннан файдаланып калырга кирәк! Кара аны, иптәш артистларга күбенеп үлә язган сыер иде, дип ычкындыра күрмә тагы!

Гибралтар. Син нәрсә инде, абый. Колхоз серен сатарга... кем дип белдең син мине!

Самат. И ишше: иптәшләрнең концертын ачып, берике сүз әйтергә килеп җитәрмен. Йомгаклау сүзен дә үзем әйтерменме, әллә сиңа әйтергә туры килерме — анысын на месте хәл итәрбез. Обстоятельствога карап...

Гибралтар. Яхшы. Шулай итәрбез, абый.

Самат. Кая, ниме, тамак чылатырга берәр нәрсәң юкмы? Минем машинада бар барын...

Гибралтар. Сорап торасың тагы, абый. Әбизәтельне бар. Әйдә, керик минем кабинетка.

Саматны бүлмәсенә уздыра. Шул вакыт зал ишегеннән бәйрәмчә киенгән, бизәнгән-ясанган Фатыйма керә. Кергәч тә чәчләрен төзәткәләп ала. Аннан, тырт-тырт басып, Гибралтар бүлмәсенә таба атлый.

Фатыйма *(ишек янына килеп җитәр-җитмәстән)*. Гибралтарчик! Син мондамы?

Фатыйма ишекне ачам дигәндә генә, Гибралтарның башы күренә.

Гибралтар. Монда булсам, ни диярсең? Нәрсә кирәк, Фатыйма?

Фатыйма *(кыланчыкланып)*. Нихәл, Гибралтар? Мин эчкә узыйммы соң, син монда чыгасыңмы дигәндәй...

Гибралтар *(ишектән гәүдәсен яртылаш кына чыгарып)*. Ни йомыш?

Фатыйма. Йомыш, дип...

Гибралтарны этәреп, авызындагы ризыкны тәмләп чәйни-чәйни, Самат чыга.

Самат. Син... нишләп фермада түгел?

**Фатыйма.** И-и... Самат Мансурович та монда икән. Исәнмесез, Самат Мансурович?

**Самат** *(төксе генә)*. Исән әле. Мин әйтәм, син нишләп фермада түгел, дим?

**Фатыйма.** Калхуз эшен эшләп үләр хәлем юк әле, Самат Мансурович. Әзрәк ял итим, дидем. Кафилгә дә күз-колак булырга кирәк.

**Самат.** Нинди ял ул тагы? Казаннан себерелеп кайтканыңа ничә ел, җүнле-башлы эш күрсәткәнең юк. Һаман ир-атларның аяклары арасында чуаласың... Туймасаң туймыйсың икән!..

**Фатыйма.** Туярсың сезнең белән. Тол хатынның күңелен күрерлек җүнле ир-ат та юк бит авылда.

**Гибралтар.** Башкаларга яраган сиңа ярамый инде...

**Фатыйма.** Башкаларга ярый торган кирәкми миңа, үземә ярый торган кирәк!

**Самат.** Үзеңә яраганны Казаннан эзлиләр аны, авылга кайтып егылмыйлар...

**Фатыйма.** Казанның исеменнән башка ние бар соң аның?

**Гибралтар.** Чит илгә бар әнә.

**Фатыйма.** Бик барырыем да, акчам гына юк. Сыер, сыер! Сөт! Сөт! дигән булып, көне-төне изаланасың, акча түләргә уйлаган кеше юк.

**Самат.** Җә, җә, чәпчемә, Фатыйма. Синдә акчаның беткәне юк. *(Гибралтарга.)* Ярый, Гибралтар, мин ашыгам. Бетмәс монда Фатыйманың кирле-мырлы сүзләре. Кара аны, мин әйткәннәрне онытма. Тәртип булсын!

**Гибралтар.** Барысы да тәртип булыр, абый. Борчылма.

Самат чыгып китә.

**Фатыйма.** Сау булып торыгыз, Самат Мансурович. *(Гибралтарга.)* Эчеп чыгарга кергәнме абыең?

**Гибралтар.** Анда синең ни эшең бар. Җә, ник килдең? Монда килгәнеңне хатын белсә, бәреп үтерә бит хәзер сине.

**Фатыйма.** Фи! Курыктым ди синең карачкыңнан. Син калтырап яшә аннан.

**Гибралтар.** Үзең дә әллә кем түгел. Кагылма аңа. Аның сиңа зыяны тигәне юк әле.

**Фатыйма.** Тиеп кенә карасын! Малаеңны илтеп кулына тоттырырмын. Карарсыз шунда бергәләп.

**Гибралтар.** Кафил — минем малай түгел! дип күпме әйтергә була инде сиңа, ә! Тапкан бер сүз: «Синең ма-

лай! Синең малай!» Казанда тапкан балаңның атасы нишләп мин булыйм?! Миннән дурак тумый.

Ф а т ы й м а. Бәр-рәч! Казанга килеп, мине күрмәдем, дигән буласың мәллә? Синеке булгач, кемнеке дип әйтим тагы?

Г и б р а л т а р. Ышан сиңа. Син бит сайланып тормыйсың. Кемнең чалбар каешын күрәсең, шуңа барып тотынасың... Бар, бар, йомышың булса, әйт тә тайт! Синең белән сайрашып торырга вакытым юк минем.

Ф а т ы й м а. Мин дә синең белән сайрашырга дип килмәдем. Белешергә генә дип килдем.

Г и б р а л т а р. Нәрсә белешергә?

Ф а т ы й м а. Экстрасенс авылда кунадыр бит?

Г и б р а л т а р. Куна. Шуннан?

Ф а т ы й м а. Кайда куна?

Г и б р а л т а р. Куначада.

Ф а т ы й м а. Шаяртмәле, Гибралтар. Мин бит чынлап сорыйм.

Г и б р а л т а р. Сиңа, кая кунса да, барыбер түгелмени?

Ф а т ы й м а. Кунар җире булмаса, миндә урын бар.

Г и б р а л т а р. Соңгарак калдың шул. Абый... ту ест... персидәтел аларны үзләренә алып кайта.

Ф а т ы й м а. Ничек аларны? Экстрасенслар икәү мәллә?

Г и б р а л т а р. Әһә. Берсе — ас... ас... сие... тисент. Ярдәмче ягъни.

Ф а т ы й м а *(шатлана төшеп)*. Соң... алайса, ярдәмчесе миңа кайтсын!

Г и б р а л т а р. Син нәрсә, бройлер тавык! Алар аерым-аерым йөрми инде. Персидәтелгә икән персидәтелгә! Все! Бар, дасвидание! Бүлдереп йөрмә эш кешесен.

Ф а т ы й м а. Китәм, китәм... Кумасаң да китәм. *(Төзәтенеп-ясанып алгандай итә.)* Ниме соң... *(Көязләнеп.)* Үзең, сеанстан кайтышлый, миңа сугылып чыкмыйсыңдыр? Хәер, синең карачкы да киләдер әле клубка...

Г и б р а л т а р. Хатын өйдә булмый минем. Кичкә аналарына китәргә тиеш. Бар, бар, сырпаланма. Кәнтәйләнмә. Минем бүген вакытым юк.

Ф а т ы й м а. Кызганыч... Бүген бигрәк моңлы чагым иде.

Г и б р а л т а р. Ымсындырма. Барыбер ымсынмыйм. Болай да синең белән авыз бер пеште инде.

Ф а т ы й м а. Авызың пешмәсен дисәң, өреп кабалар аны. Үзең гаепле. Чәчәкле трусигыңны мунчада калдырып китмәскә иде.

Г и б р а л т а р. Ә сиңа кем кушкан аны хатынга китереп бирергә?

Ф а т ы й м а. Бәр-рәч! Мин бит аны синекедер дип белмәдем. Карачкыңа күрсәтергә генә алып барган идем. Мин аңа: «Су буеннан таптым, Гибралтарныкы түгелме?» — дигәнием... Ә ул миңгерәү: «Гибралтарныкы икәнен каян беләсең? Күргәнең бармыни?» — дип, үзе чәчемә ябышты. Хәзер бит трусик-носкилар кыйбат тора. Бәлки, синең бүтән трусигың юктыр, дип уйладым...

Г и б р а л т а р. Бик каты уйлагансың шул. Хатынга китереп тоттырырлык булгач. Ә бит аны миңа, минем үземә бирә ала идең.

Ф а т ы й м а. Башта сиңа илтеп бирергә уйлаган идем дә, курыктым. Синеке булып чыкмас та, син миңа кемнеке бу, дип бәйләнерсең дип курыктым. Самат абыеңның ялгыш онытылып калган оекбашларын күреп тә пыр тузындың бит. Хөббелнең тишек майкасы өчен дә күпме җенләндең. Алар чәй эчәргә генә кергәннәр иде. Мунча бик эссе булгач, салып торганнар иде. Ахырдан икесе тиң онытканнар булып чыкты.

Г и б р а л т а р. Нәрсә, алар сиңа икәүләп чәй эчәргә керделәрмени?

Ф а т ы й м а. Нишләп икәүләп керсеннәр инде. Син бигрәк тагы. Самат абыең беркөнне кич кергән иде, Хөббел — икенче көнне иртән... Башын төзәтергә. Ә син алардан соң кердең. Тужы... чәй эчәргә.

Г и б р а л т а р. Што-то бер дә чәй эчкәнемне хәтерләмим.

Ф а т ы й м а. Хәтерләрлек хәлдә идеңмени соң? Лыгырык идең бит. Ул каешыңны әйтер идем... Ныклап тартсаң, өзелергә тора... Каеш дигәннән, синең каеш түгелдер бит минем өйдә?

Г и б р а л т а р. Минеке — үзем белән. Бәлки, малаеңныкыдыр?

Шул вакыт К а ф и л керә.

Г и б р а л т а р. Гомере озын булыр, нәгаләт!

К а ф и л *(керә-керешли)*. Дирехтыр абзый! Син әле үлмәдеңмени?

Г и б р а л т а р. Нишләп үләргә тиеш әле мин, ахмак!

К а ф и л. Үлми тор, җәме, дирехтыр абзый. Филдшер абзый киләлми. Эче китә. Патифун Гайшәнең бозавын печкән булган. Шуларда әллә нәрсә ашаган. Әбрәкәйдә генә утыра. Хәлең бик начарайса, үзең шунда бар, җәме, дирехтыр абзый. Филдшер абзый шулай дип әйтергә кушты.

Г и б р а л т а р. Хәзер, шул әбрәкәй сандугачы янына гына барасым калды...

Ф а т ы й м а *(көлә-көлә)*. Памушнигың да үзең сыңары икән... Әйдә, улым, кайтыйк өйгә. Сеанска кадәр мунча да кереп чыгасым бар...

Г и б р а л т а р. Бар, бар, Кафилне дә алып кит әнә. Мунча кертерсең.

Ф а т ы й м а. Әйдә, Кафил улым.

К а ф и л. Исәр мәллә син, дирехтыр абзый? Әни белән мунча керергә. Мин хәзер зур бит инде! Өйләнгән булсам, бер хәл ие. Ул чагында хатын белән керер ием...

Г и б р а л т а р. Бар, бар, әниең белән кайт. Шунда мунчада өйләндерер ул сине берәр кызга.

К а ф и л. Кит әле, дирехтыр абзый. Мунчада өйләнмим мин.

Ф а т ы й м а. Өйләнмә, өйләнмә, улым. Бу дирехтыр абзыең әллә ниләр сөйләр ул. Тыңлама син аның сүзләрен. Тиле бит ул!

Г и б р а л т а р. Тилерерсең дә монда сезнең белән. *(Фатыймага.)* Бар инде, бар... Буксовать итеп торма монда. Мунча пәриләреңне көттермә.

Ф а т ы й м а. Киттем, киттем. Улым, үз вакытың белән кайтырсың. Дирехтыр абзыеңны тагын бераз йончыт та.

Г и б р а л т а р *(Кафилгә)*. Ә син нишләп торасың, бастырык?

К а ф и л. Бә-әй! Оныттың дамыни? Филдшер абзыйга барып килдем бит. Әйт инде, маладис, диген!

Г и б р а л т а р. Бар, бар, маладис!..

К а ф и л. Хәзер акча бирәсеңме инде, дирехтыр абзый?

Г и б р а л т а р. Нинди акча ул тагы?

К а ф и л. Бә-әй... Маладис, диден бит...

Г и б р а л т а р. Уф! Бар әле, бар... Башны катырмале! Миндә акча ясый торган машина юк!

К а ф и л. Алайса, жывачка бир!

Г и б р а л т а р *(ачуына чыдый алмыйча)*. Войт, анаңны эт орган!.. Үз башыма гына иyләштердем мин сине. *(Йөзен чыта.)* Карале... Монда минем акчам да, сагызым да юк. Бетте. Иртәгә алып килермен. Чәйнәмичә түзәрсең әле... Мине хәзер, зур эшләргә чакырып, ил дәшә...

К а ф и л *(аңламыйча)*. Кем дәшә дисең, дирехтыр абзый?

Г и б р а л т а р. Атаң башы! Ил дәшә, дим! Ил дәшә! Зур эшләргә чакырып... *(Үрсәләнә.)* Хәзер мин тиз генә бәдрәфкә барып киләм...

К а ф и л. Нәрсә, дирехтыр абзый, әллә синең дә эчең китәме? Филдшер абзыйныкы шикелле...

Г и б р а л т а р. Булсаң да булырсың икән сумала са-

гызы! Ыслушай, мин хәзер киләм. Син монда гына торып тор. Алай-болай мин юкта ят абзыеңнар күренсә, мине хәзер килә ул, диярсең. Аңладыңмы?

Кафил. Аңладым, дирехтыр абзый. Сине сорасалар, хәзер әбрәкәйдән килеп җитә ул, дип әйтермен...

Гибралтар. Надан! *(Башын чайкый.)* Әбрәкәйдә, димә, монда гына, диген.

Кафил. Ярар. Әбрәкәйдә түгел, монда гына, диярмен.

Гибралтар *(теләсәң нишлә дигәнне аңлатып, кулын селти)*. Уф, ычкынам бугай инде... *(Ашыга-кабалана ишеккә таба бара.)*

Ишек тарафында Миңниса күренә.

Миңниса. Гыйбрәт улым...

Гибралтар *(кулларын гасабиланып селти-селти)*. Мин монда юк, мин юк! Әйдә, әйдә, атчаливали!.. *(Чыгып китәләр.)*

Кафил идәнгә утыра да, бармакларына төкереп, ботинкаларын сөрткәләргә тотына.

Кафил. Дирехтыр абзыйныкы шикелле ялтырап торсыннар әле...

Үз эшеннән канәгать булгач, торып баса да әрле-бирле йөренергә тотына. Кинәт машина килеп туктаган тавыш ишетелә. Кафил, сагаеп, ишек тарафына текәлә. Бераздан иңнәренә юл букчалары аскан Галләм белән Рифат керә.

Галләм *(Кафилне ерактан ук күреп алып исәнләшә)*. Әссаләмегаләйкүм!

Машина кузгалып киткән тавыш ишетелә. Кафил, бер сүз дә дәшмичә, боларга карап, борын тишеген казып тора.

Галләм *(Рифатка)*. Чукрак бугай бу. *(Түргә таба атлый-атлый кабат исәнләшә.)* Әссаләмегаләйкүм!

Кафил һаман дәшми.

Рифат. Хатипыч, тучны саңгырау!

Кафил. Нишләп саңгырау булыйм мин, вәйт тиле!

Рифат. Алайса, нигә Галләм Хатипыч сәламен алмыйсың?

Кафил. Миңа бу абзыйның бернәрсә дә бирергә җыенганы юк бит әле.

Рифат та, Галләм дә, Кафилгә сәерсенеп карап, аны баштанаяк күздән кичерәләр.

Г а л л ә м. Син нәрсә, энекәш, әллә бераз *(чигәсендә бармак уйната)* полоумныймы?

К а ф и л *(уң кулының баш бармагын борынына төртеп, калган бармакларын селкеткәләп ала)*. Син үзең шундый!

Г а л л ә м. Рифат, кая килеп эләктек без?

Р и ф а т. Клуб инде бу, клуб. Әнә бит лозунглар язып элгәннәр... *(Кафилгә.)* Кайда директорыгыз? Кәшәфетдинов кайда?

К а ф и л *(башын югары күтәрә төшеп)*. Мин калдым дирехтыр абзый урынына.

Рифат белән Галләм бер-берсенә карашалар.

Г а л л ә м. Бу авыл да барып чыккан икә-ән... Сыерны алып китеп булса ярый инде.

Р и ф а т. Персидәтел бирәбез, диде. Борчылма, Хатипыч. *(Кафилгә.)* Исемең ничек синең, быр-рат?

К а ф и л. Кафил абзый мин, абзый.

Галләм, кулларын артка куеп, стенадагы язу-лозунгларны укый-укый йөренә.

Р и ф а т. Менә нәрсә, Кафил быр-рат...

К а ф и л. Дирехтыр абзый, диген! Мин бит аның урынына калган кеше.

Р и ф а т *(Кафилгә йөзен чытып карап тора да)*. Ярар, синеңчә булсын. Менә нәрсә, дирехтыр абзый... Бар әле син, җәһәт кенә Кәшәфетдиновны эзләп тап. Кунаклар килде, диген... Экстрасенслар... Сручны монда килсен.

К а ф и л. Аны эзлисе юк. Әбрәкәйдә ул.

Р и ф а т. Бар, алып кил шуннан.

К а ф и л. Юк, бармыйм. Минем эчем китми лә...

Г а л л ә м. Да-а-а... Килеп җиттек, кода! Җүнләп каршы алучылар да юк. Персидәтеле дә каядыр тайган... Бусы юк! Оештыруың җитмәгән, быр-рат...

Л ә й с ә н керә. Кафил, кулларын артка куеп, болар тарафына карый-карый йөренә.

Р и ф а т *(Галләмгә төртеп ала)*. Шәп, каһәр!

Г а л л ә м *(бармагын Рифатка «Во!» дип тырпайтып)*. Минеке бу. Класс!

Л ә й с ә н *(оялчан)*. Исәнмесез.

Р и ф а т. Әссаләмегаләйкүм, туташ!

Л ә й с ә н. Сез... экстрасенслармы?

Г а л л ә м. Шулайрак иде, туташ, ачуланмасаң.

Л ә й с ә н. Нишләп ачуланыйм инде мин сезне. Кире-

сенчә, сөенәм генә. Миңа бик кирәк идегез сез. Ярдәм итсәгез, сез генә ярдәм итә аласыз.

Рифат. Безнең Хатипыч любой чирдән дәвалый. Кайсы төшегез авырта, сылукай? Әйтегез, тартынмагыз.

Ләйсән. Мин авыртмыйм. Чирләрем юк минем.

Галләм. Как так? Үзегез ярдәм сорыйсыз, үзегез авыртмыйсыз. Што-то аңлашылып җитмәде әле бу.

Ләйсән. Мин... мин... яратам аны!

Галләм *(як-ягына карана)*. Кемне яратасыз? *(Кафилгә ишарәләп.)* Аны мәллә?

Рифат *(әле Ләйсәнгә, әле Кафилгә карап ала)*. Да-а... Юкәдә икән чикләвек!

Ләйсән. Юк ла инде. Сез нәрсә! Аны яратам мин. *(Бушлыкка ишарәли.)* Салават Фәтхетдиновны!

Галләм, Рифат *(икесе бергә)*. Ә?!

Ләйсән. Ну инде... җырчы Салават Фәтхетдиновны!

Галләм. Кыз-зык... Ә мин нишли алам?

Ләйсән. Минем аның белән танышасым килә.

Рифат. Соң... концертына барасың да танышасың инде.

Салават керә, тыңлап тора.

Ләйсән. Ул, мине күрүгә, үлеп гашыйк булсын иде. Ә моның өчен бары тик сез генә булыша аласыз.

Галләм. Ничек итеп?

Ләйсән. Сез мине үзегезчә өшкерәсезме шунда. Әллә берәр әфсен-төфсен укыйсызмы?.. Әй, сез бит экстрасенслар, үзегез беләсездер инде... Сез миңа шулай итеп ярдәм итегез — Салават Фәтхетдинов, мине күргәч, минсез яши алмаслык булсын.

Рифат. Моны гына булдыра ул Хатипыч. Шулай бит, Хатипыч?

Галләм. Әлбәттә. Мин Чаллыда сеанслар биргәндә, Салават минем һәрбер сеанска килә. Миравай егет! Минем сеансларга пастаянны йөри-йөри шулай танылды инде ул халыкка. Хәзер нормальный халык аның концертына чаба да минем сеанска килә. Теләсәң, мин синең үзеңне дә җырчы итәм. Мәшһүр җырчы итәм!

Ләйсән *(тагын да очынып-куанып)*. Чынлапмы?

Галләм. Только синең белән индивидуаль сеанс үткәрергә кирәк. Берничә мәртәбә. Сезнең авылда мин бер генә сеанс бирәм. Теләсәң, мин сине үзем белән алып китәм. Берничә көндә җырчы итәм мин сине. Салават Фәтхетдиновың да артыннан калмаслык итәм. Китәсеңме минем белән? Ризамы?

Л э й с э н. Риза, риза, китәм!

С а л а в а т. Китми генә тор әле, яме!

Һәммәсе дә Салаватка борылып карый.

Г а л л э м *(Ләйсәнгә)*. Кем бу? Йөргән егетең мәллә?

Л э й с э н *(көлә)*. Нинди йөргән егетем булсын! Салават кына ич бу! Классташ.

С а л а в а т. Беркая да җибәрмим мин сине, Ләйсән. Башыңны җүләргә салып йөрмә. Әйдә, киттек! *(Галләмгә.)* Кеше котыртып, алдап йөрмәгез монда. Әнә, әби-чәбиләрнең башын катырыгыз. *(Ләйсәнне ишеккә таба тарткалый.)* Киттек.

Л э й с э н *(ачуланып)*. Нишләп минем арттан йөрисең син һаман? Туйдырып бетердең инде. *(Галләмгә.)* Мин риза. Мин әле сезнең сеанска да киләм.

Галләм, аңлашылды дигәнне аңлатып, елмаеп кулын селти. Салават Ләйсәнне өстерәп диярлек алып чыгып китә. Кафил, борын тишеген казый-казый, һаман йөренә.

Р и ф а т. Кыз шәп!

Г а л л э м. Үзсүзле. Китәчәк бу безнең белән. Үзе керәчәк кочакка. *(Кулын кулга сугып ала.)* Сыерны алырга да, кызны әләктерергә дә — әллүр моннан!

Р и ф а т. Хатипыч, бу авылда арттырып җибәрергә тырышма инде, җәме! Теге юлы да чүттән генә фаш ителми калдык. Сүзләрне дә үлчәп кенә сөйлик. Алданганнарын сизсәләр, башларыбызны бот арасына да кыстырырга күп сорамаслар!

Г а л л э м. Курыкма, Рифат дус. Сизмәсләр! Сиздермәбез. Абзаңның Сәлмән карт оныгы икәнлегене онытма. Миндә аның каны ага! Атаклы им-томчы иде минем бабай. Кайлардан гына килмиләр иде Сәлмән карт янына! Хәтта им-том, бозым-китем дигәндә, үзләре дә махы бирмәгән марилар да, чуашлар да юл сапты безгә. Үлән белән дә, гипноз белән дә дәвалады бабай. Үлеп-бетеп, сөйрәлеп, күтәрәмгә калып килгәннәрнең һәммәсе дә савыгып, рәхмәтләр әйтеп кайтып китә иде... Их, бабайда булган сәләт миндә дә булса!

Р и ф а т. Акча бирәләр идеме соң бабаңа? Әллә шул коры рәхмәтләрне генә учлап кала идеме?

Г а л л э м. Бирәләр иде... Тик алмый иде бабай... Авызына кереп чыгыйм! Әти белән мин өнәмәгән шундый гадәте бар иде бабайның. Кыстап-кыстап бирмәкчеләр иде... Юк, алмый тек алмый. Әти сүгенеп ята мунча алдында... Махмырдан интегеп. Мин ухылдыйм печәнлектә. Бабайның тетмәсен тетәбез икәүләп...

Р и ф а т. Яп-ялангач кыз каршында тун өстеннән тулып кия башлаган кебек булган икән гел... Бабаңны әйтәм... Импотент несчастный! Учыңа суырылып акча керсен, ә син шуны җилгә сибеп җибәр... Үзеңне уйламасаң да, калтырап яткан малаең белән ухылдап интеккән оныгың турында уйларга кирәк бит инде, ә! Махмыр бит ул — любой авырудан да яман...

Г а л л ә м. Махмыр, дигәннән... Бабайның Брежневны эчүдән биздерә язганы турында сөйләгәнем бар иде ме сиңа?

Р и ф а т. Күптән үлгән Брежневта минем эшем юк. Менә сине дә, атаңны да айныталмаган бабаң... Анысы — факыт!

Г а л л ә м. Тырышуын тырышты бабай... Безне дәвалау чарасын гына табалмады. Теләсә нәрсә эчеп бозылган организмга каршы көрәшергә... Ай-һай...

Р и ф а т. Хатипыч! Т-с-с-с! Кемдер керә, ахрысы.

Г и б р а л т а р керә.

Р и ф а т *(сөенеп)*. Әнә үзе!

Г и б р а л т а р. О-о-о... Кунак әфәнделәр килеп җиткән икән! Исәнмесез! Вәгаләйкүм сәлам! Саумысыз! Здрасте!

Күрешә. Кафил дә Гибралтарга кулын suза. Гибралтар ялгыш аның белән дә күрешә.

Г и б р а л т а р *(Кафилнең кулына сугып)*. Кит әле!.. Нишләп сәнәгеңне сузасың... *(Галләмгә.)* Әйбәт кенә килеп җиттегезме, иптәш әфәнделәр?

Г а л л ә м. Әйбәт. Зарланырлык түгел.

К а ф и л. Мин бу абзыйларга сине хәзер килә, дидем... Мин маладисмы, дирехтыр абзый?

Р и ф а т. Маладис, маладис...

Г и б р а л т а р *(Кафилгә)*. Бар, бар, юлыңда бул.

К а ф и л *(Рифат янына килә)*. Мин маладисмы?

Р и ф а т. Маладис, дидем бит инде. Маладис!

К а ф и л. Алайса, акча бир!

Р и ф а т *(Гибралтарга)*. Бу кем? Рэкитер мәллә?

Г и б р а л т а р *(исе китмичә кулын селти)*. Хужы. Тиле ул. Игътибар итмәгез... Ничек соң планнар? Капкалап алабыз мәллә?

Г а л л ә м *(үзен эре тотып)*. Капкалап алу зыян итмәс, иптәш...

Г и б р а л т а р *(башын ия төшеп)*. Кәшәфетдинов әфәнде булам.

Г а л л ә м. Бик яхшы. Очень приятны. Капкалап ал-

мыйча булмас, Кәшәфетдинов әфәнде. Сеансны ач килеш үткәреп булмый. Энергия кирәк!

Кафил *(Рифатка)*. Алайса, жывачка бир!

Гибралтар. Бирегез инде шуңа берәр нәрсә. Үзенекен алмыйча туктамый ул. Мине бүген генә өч кат чишендерде инде.

Рифат, кесәсеннән бер кәгазь акча алып, Кафилгә бирә.

Кафил. Юмарт абзый икәнсең... Тәки бирдең.

Рифат. Юмарт түгел мин, саран! Понял?

Гибралтар. Урысча аңламый ул... кем... асси...сентент әфәнде.

Галләм. Кешеләр заряжать итәргә сулар китерә башлаган икән...

Гибралтар. Әлбәттә. Кәнишне. Әнә бит... *(Сәхнәдәге сулы савытларга ишарәли.)* Сулы савытларына урын занимать итә башладылар инде. Так шту барысы да тәртиптә булыр.

Гибралтар, сулы савытлар янына барып, аларны санап йөри. Шул вакытта Галләм белән Рифат үзара сөйләшеп ала.

Рифат. Эш пешәргә тиеш, Хатипыч!

Галләм. Сыерны эләктереп китсәк, базарда матур гына хакка төртербез. *(Гибралтарга.)* Кәшәфетдинов әфәнде, түләү мәсьәләсе... шул... сөйләшкәнчәдер бит инде? Сыер суйгансыздыр?

Гибралтар. Барысы да тәртиптә булыр, иптәш әфәнделәр. Сыерны иртәгә иртән суячаклар. Сез итне свежий килеш алып китсен дип, шулай итәргә булдык. Каршы түгелсездер бит?

Галләм. Юк, юк. Што сез! Бигрәк шәп! *(Канәгать елмаеп, Рифатка.)* Класс!

Гибралтар *(болар янына килеп)*. Карыныгыз ачкандыр... Әйдәгез, экстрасенс әфәнделәр... Ашханәгә кереп чыгыйк... Әйдәгез, әйдәгез... Рәхим итегез, әфәнделәр! *(Ишеккә таба ишарәли.)*

Чыгарга таба баралар.

Кафил. Дирехтыр абзый, мин дә барыйммы? Минем дә ашыйсым килә.

Гибралтар *(борылып карамыйча гына)*. Син генә җитмәгән иең...

Кафил *(Гибралтар артыннан иярә)*. Син үзең дә маладис кеше инде, дирехтыр абзый...

Гибралтар *(кинәт артына борылып, Кафил тавышы белән)*. Син кая?

К а ф и л. Ашарга. Үзең әйттең бит, дирехтыр абзый, «син генә җитмәгән иең...» дидең.

Г и б р а л т а р. Тәмам миемне череттең! Бар, анаң янына кайт та аша! Әйдә, әйдә, кыймылда!

Чыгып китәләр.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнә пәрдәсе алдында, ягъни «клуб ишеге төбендә», Г и б р а л т а р белән Галләм басып тора. Сеанска килүчеләр, алар белән берәм-берәм исәнләшеп, клубка кереп китәләр.

Г а л л ә м. Халык җыела... *(Сәгатенә карап.)* Башларбыз да инде, мөгаен... Теге сөйләшенгән кешеләрегез килгәндер бит?

Г и б р а л т а р *(кемнедер көткәне сизелә)*. Хәзер, хәзер, экстрасенс әфәнде... Берсе менә хәзер килеп җитәргә тиеш. *(Куанып.)* Әнә, үзе дә килә...

Алпан-тилпән атлап, болар янына Х ө б б е л килеп баса.

Х ө б б е л. Здрасте! Слесаря вызывали? *(Честь бирә.)*

Г а л л ә м *(Гибралтарга иелә төшебрәк)*. Урыс мәлләбу?

Г и б р а л т а р. Юк, юк, аның татарчасы шундыйрак. Хөббел бу. *(Хөббелгә.)* Бар инде, бар, керә тор. Урын ала тор.

Х ө б б е л. Кайчан салабыз? *(Чайкалып куя.)* Гыйбрай, наливай!

Г и б р а л т а р. Соңыннан, соңыннан. Керә тор. *(Хөббелне эткәли.)*

Х ө б б е л . Только без рук, пажалысты. Я сам! *(Кереп китә.)*

Г а л л ә м. Бу төтен булган түгелме соң инде?

Г и б р а л т а р. Аның төтен булмаган чагы да юк. Тик сез борчылмагыз. Барысы да сез әйткәнчә булыр. Керәбезме?

Г а л л ә м. Барыгыз, бар, сез керә торыгыз. Атмосфераны ачыклый торыгыз. Мин бер-ике минуттан керермен. Халыкка җиткерәсе энергияне тәртипкә китерим. Минем ассистент белән кирәкле нәрсәләрне хәстәрли торыгыз. Сөйләшенгән кешеләрегезнең исенә тагын бер кат төшерегез.

Г и б р а л т а р. Яхшы. *(Кереп китә.)*

Галләм спортчылар сыман кулларын, аякларын хәрәкәтләндереп ала, башын уңга-сулга боргалый, бармакларын язгалагандай итә. Ашыгып диярлек Л ә й с ә н керә.

Л ә й с ә н. Уф! Соңга калдым дип торам. Башланмаган икән әле. Хәерле кич!

Г а л л ә м. Хәерле кич, хәерле кич, туташ! Сез тагын да сылуланып киткәнсез, дип әйтимме... Нәкъ Нефертити кебек гүзәлсез!

Л ә й с ә н *(үзен мактаганга күңеле булып)*. Ә кем соң ул Нефертити?

Г а л л ә м. Үзен күргән-белгәнем юк. Кайчандыр яшәгән бер патша хатыны бугай шунда.

Л ә й с ә н. Ә-ә-ә... Әллә берәр чит ил җырчысымы дип торам тагы.

Г а л л ә м. Ничек соң, гүзәл туташ, баягы уеңнан кире кайтмадыңмы әле?

Л ә й с ә н. Юк, юк! Мин сезнең белән китәм! Салават Фәтхетдиновсыз яши алмыйм мин!

Г а л л ә м *(икеләнгән булып)*. Ни бит, туташ... Аның хатыны да бар бугай...

Л ә й с ә н *(үз-үзенә ышанучан тавыш белән)*. Булса ни! Мине күргәч, аерып җибәрә ул аны!

Г а л л ә м. Молодец! Шундый тәвәккәл кызларны яратам мин. Сездән менә дигән җырчы чыгачак. Бөтен дөньяга атаклы итәм мин сезне! Әти-әниең ризадыр бит?!

Л ә й с ә н. Фи! Алардан сорап торам ди! Мин хәзер үзем-үзем хуҗа.

Г а л л ә м. Ә егетең? Баягы егетеңне әйтәм?

Л ә й с ә н. Әй, егетмени әле ул. Бер бәйләнчек шунда. Сагыз! *(Бу сүзләрне Салават тыңлап тора.)* Әле үзеннән көчкә котылдым.

С а л а в а т. Миннән котылдыңмы?

Л ә й с ә н. Уф! Әнә тагы ияргән. *(Салаватка.)* Мин сиңа әйттем бит инде. Йөрмә минем арттан, дидем.

С а л а в а т. Алдыңнан артка карап йөри алмыйм мин. Алай җайсыз атлавы.

Г а л л ә м. Да-а... Сагыз икән шул бу. Стиморол — устойчивый вкус!

С а л а в а т. Абзый, син тик кенә тор, яме. Шундый итеп установка бирермен, сәламәтлегеңне ныгытырга ун сыер саткан акчаң да җитмәс.

Л ә й с ә н. Ник бәйләнәсең әле син аңа, карт кешегә.

Г а л л ә м. Ярый, ярый, мин болай гына... Сүз уңаеннан гына... *(Салаватка.)* Ирләр булыйк, быр-рат! Минем үз юлым, синең үз юлың дигәндәй...

С а л а в а т *(Ләйсәнгә)*. Әйдә, киттек.

Л ә й с ә н. Тарткалама мине. Мин сеанска керәм.

С а л а в а т. Алайса, мин дә керәм.

Л ә й с ә н. Мишәйт итеп утырсаң, бүген үк Салават Фәт-

хетдинов янына китәм. *(Галләмгә елмаеп.)* Экстрасенс абый белән китәбез.

Шулай сөйләшә-тӛрткәләшә кереп китәләр. Галләм дә алар артыннан керергә омтылганда гына, Фатыйма пәйда була.

Фатыйма. Киче дә киче! Нинди матур! Ап-аяз күк йөзе...

Галләм. ...Йолдызлар җемелди... Исәнмесез, ханым-туташ!

Фатыйма. Исәнмесез, экстрасенс әфәнде! *(Капылт шикләнеп.)* Сез экстрасенстыр бит?

Галләм. Әлбәттә. *(Гәүдәсен турайтып.)* Атаклы экстрасенс — Галләм Сәлмән! Сезне кем дип белик?

Фатыйма. Фатыйма. Туташ дисәгез дә ярый. Фатыйма гына дисәгез дә була. Сез бүген сеанстан соң персидәтелгә кайтасыз икән дип ишеттем. Теләгегез булса, миндә дә *(басым ясый)*... урын бар.

Галләм. Теләк, дип... Бик кызык тәкъдим бу. Шушындый гүзәл туташ чакыруына каршы килеп тә булмас, ахры. Персидәтел белән киңәшләшкәннән соң, бер уртак фикергә килербез дип уйлыйм.

Шул вакыт Гибралтар чыга.

Гибралтар. Экстрасенс әфәнде, сезне халык көтә. *(Фатыйманы күреп.)* Ә-ә... Фатыйма... Син тоткарлап торасыңмыни әле иптәш әфәндене?!

Фатыйма. Нишләп тоткарлыйм ди. Исәнләшеп кенә тора идем.

Галләм *(Фатыймага)*. Сөйләшербез әле. Әйдәгез, Кәшәфетдинов әфәнде. Әйдәгез, туташ.

Гибралтар Фатыймага сәерсенеп карап ала. Галләм белән икесе кереп китәләр.

Фатыйма. Сөйләшербез, сөйләшербез... Туктале, кайдадыр күргәнем бар кебек бу чукынчыкны... *(Бераз исенә төшерергә тырышып тора да клубка кереп китә.)*

Ут сүнеп ала. Сәхнә пәрдәсе ачыла. Гибралтар бүлмәсе караңгыланып калган. Төрле яктан янган ут көлтәләре бары тик сәхнәне генә яктырта. Сәхнә алдындагы сулы банкалар, шешәләр, мискиләр, чәйнекләр тагын да ишәйгән. Урта бер җирдә кырык литр су сыешлы ике бидон тора. Савытлар тирәсендә тастымалларга куелган төрле ризыклар — ипи, бәрәңге-кишер, бәлеш һ.б. да шәйләнә. Трибуна янәшәсендә өстәл һәм ике урындык бар. «Зал»да кемдер кул чаба башлый, аңа бүтәннәр дәррәү кушыла. Алдагы рәттә утырган Самат урыныннан вәкарь белән генә тора да, тамашачыларга карап, кулын өскә күтәрә — кул чабуларны туктатырга ишарә ясый. Бер читтәрәк Гибралтар басып тора.

С а м а т *(учына төкереп ала)*. Кыхым!.. Кыхым!.. Уважаемые... кадерле авылдаш иптәшләр! И ишше... иптәш калхузчы иптәшләр! И тагдалие...

Х ө б б е л *(утырган җиреннән башын калкыта, бер бармагын тырпайткан кулын өскә чөеп ала)*. Короче, пред! Краткость — сестра таланта! *(Башы кинәт салынып төшә.)*

С а м а т *(Хөббелгә карап)*. Күз алдыннан югалтыгыз әле шул дуңгыз боламыгын! *(Очкылык тота.)* Ыйк!

Гибралтар тиз генә Самат янына килә дә аның колагына нидер пышылдый.

Ф а т ы й м а. Йоклый инде ул, Самат Мансурович, йоклый!

С а м а т. Ладны, алайса, йокласын!.. Ыйк!.. Иптәш кадерлеләр... ыйк!..

Гибралтар үз бүлмәсенә кереп китә дә стакан белән су алып чыга, аны Саматка суза. Самат стакандагы сыеклыкны эчеп җибәрә дә йөзен чыта.

С а м а т *(авызын кулы белән җилләтә-җилләтә)*. Аракы бит бу!

Халык көлә. Хөббел, башын калкытып, як-ягына каранып ала. Гибралтар, «әйе шул» дигәнне аңлатып, башын селки.

Х ө б б е л. Аракы? Кайда ул? Миңа да бирегез!

С а м а т. Юк, юк, аракы түгел... Су икән, су! Ят, ят, йоклап ал!

Х ө б б е л. Не командуй, капитан! *(Башы салынып төшә.)*

Ф а т ы й м а. Ят та йокла инде, Хөббел тәре! Самат Мансуровичны тыңларга мишәйт итмә.

«Зал» ишегеннән М и ң н и с а карчык килеп керә дә, кыймыл-кыймыл атлап, Гибралтар янына килә. Самат та, бүтәннәр дә, бермәл сүзсез калып, аның атлап килү рәвешен күзәтеп торалар.

М и ң н и с а *(Гибралтарга, әмма бүтәннәргә дә ишетелерлек итеп)*. Булды, кем, Гыйбрәт улым. Мунчам булды!

Самат әле Гибралтарга, әле Миңнисага карый. Гибралтар берни дә аңламыйм дигән кыяфәт чыгарып ала.

Г и б р а л т а р. Бик әйбәт, Миңнисаттәй, бик әйбәт. Бар инде, утыр берәр урынга!

Гибралтар, төрткәли-төрткәли, Миңнисаны «зал»га таба этәреп җибәрә. Миңниса сөрлегә.

М и ң н и с а. Әстәгыфирулла! *(Борыла.)* Бөтен авыл керерлек булды мунчам. Би-ик әйбәт булды, кем... Ул эссесе... ул эссесе... *(Утыра.)*

С а м а т. Короче...

Х ө б б е л *(башын калкыта).* Во! Понял все-таки... *(Башы салынып төшә.)*

С а м а т. Безобразие! *(Хөббелгә ачу белән карап ала.)* Короче, иптәшләр, безгә иптәш артистлар килде. Әйдәгез, иптәшләр, кул чабып каршылыйк әле артист иптәшләрне! *(Кул чаба башлый.)*

Гибралтар да, бүтәннәр дә аңа кушылып кул чабарга тотыналар. Сәхнәгә үзен эре, дәрәҗәле тотып Г а л л ә м һәм, аннан бераз калышып, Р и ф а т чыга. Икесе дә башларын иеп ала. Самат белән Гибралтар, кул чаба-чаба, үз урыннарына утыралар.

Г а л л ә м. Әфәнделәр! Ханымнар! Кадерле әбиләр, бабайлар! Энекәшләр, сеңелкәшләр! Минем дөньякүләм танылган экстрасенс булуым турында ишетеп беләсездер инде?! Шулай да үзем белән һәм *(Рифатка ишарәле)* бик тә сәләтле тугры ярдәмчем белән сезне таныштырып үтү зыян итмәс дип уйлыйм. Мин, белгәнегезчә, атаклы экстрасенс Галләм Сәлмән булам!

Р и ф а т *(нәфис сүз осталары шикелле кулларын җәеп).* «Дөньяны савыктыру» ассоциациясенең вице-премьер урынбасары әгъзасы... *(Тавышын тагын да күтәрә төшеп.)* Член Галләм Сәлмән!

Халык гөрләтеп кул чаба. Галләм, канәгать елмаеп, башын иеп ала.

Г а л л ә м *(бер кулын Рифатка таба җәеп).* Тиздән үзе дә тулы хокуклы халыкара экстрасенс әгъзасы-члены булачак Рифат Җәгъфәр!

Көчле кул чабулар астында Рифат башын иеп ала да сәхнәдә үзләре өчен әзерләнеп куелган өстәл янына килеп утыра.

Ф а т ы й м а *(урыныннан капылт торып).* Галләм, Галләм... *(Шулай үзалдына сөйләнгәннән соң, Галләмгә дәшә.)* Карагыз әле, экстрасенс әфәнде! Минем сезне кайдадыр күргәнем бар кебек тәсле тоела?!

Г а л л ә м *(бераз сагаеп).* Минеме?

Ф а т ы й м а. Әһә!

Г а л л ә м. Бик мөмкин, туташ. Чөнки мин бик күп җирләрдә, бик күп кешеләргә дәвалау сеансларын үткәрәм. Шунда күрүегез ихтимал.

Ф а т ы й м а. Юк, юк, минем сеансларга моңарчы йөргәнем булмады. Менә кайдадыр күрдем инде сезне... Таныш сыман...

С а м а т. Фатыйма! Синең күрү-күрмәвең безне кызыксындырмый. Бүлдермә артистларны! Утыр урыныңа!

Ф а т ы й м а. Менә... кайдадыр күрдем инде... *(Утыра.)*

Г а л л ә м. Әфәнделәр, иптәшләр! Миңа үз-үзегезгә ышанган кебек ышана аласыз. Мин дәвалый алмаган чир дөньяда юк! Гастрит, язвы желудкы, йөрәк, бавыр, сидек куыгы, күкәйлекләр, аналыклар минем өчен пүчтәк нәрсәләр. Бөер ташларын ә дигәнче алып атам...

Р и ф а т. Галләм Хатипыч, әгәр теләсә, ягъни мәсәлән, кирәк дип санаса, бөерне дә алып ташларга мужыт!

Халык гөрләтеп кул чаба.

Г а л л ә м *(ике кулын күтәрә дә учларын халыкка таба төби)*. Әфәнделәр, ханымнар! Мин әле генә сезгә установка бирдем. Мин сөйләгән арада сезнең барлык авыруларыгыз әкренләп юкка чыгачак. Дөрес, кайберәүләрегезнең чирләре бүген үк чыгып бетмәскә дә мөмкин. Чөнки, үзегез беләсез, чир ул — бик явыз нәрсә. Кабахәт нәрсә, мин әйтерием. Аны җиңәр өчен шактый тырышырга кирәк, энергияне байтак сарыф итәргә кирәк.

Хөббел, үзен белештермичә, башын бер яктан икенче якка чайкалдыра.

Г а л л ә м. Хәзер сез... *(Хөббелгә ишарәли.)* Әнә, иптәш әфәндегә минем установка тәэсир итә дә башлады.

Галләм, ике кулын күтәргән килеш, «зал»га карап, сәхнә буйлап йөренә.

Г а л л ә м. Хәзер сез гәүдәләрегездә гадәттәгедән үзгә җылылык тоячаксыз. Хәзер җылыначаксыз...

Галләм, шулай сөйләнә-сөйләнә, Гибралтар бүлмәсенә кереп китә. Рифат, урындыкка утырган килеш, ике кулын күтәреп, Галләмнең «дәвалау сеансы»н дәвам итә. Галләм бүлмәгә керүгә, Гибралтар бүлмәсендә ут яна. Аның ни эшләгәне тамашачыларга күренеп тора: ул, кулына шешә алып, андагы эчемлекне стаканга коя. Шуннан соң стаканны тиз генә авызына якынайта — эчә.

Г а л л ә м *(чыгышлый кулы белән авызын җилләтеп ала, үзе нидер чәйни)*. Менә хәзер сез җылындыгыззз... Җылындыгыз... Барыгыз да җылындыгыз... Хәтта минем үземә дә эссе була башлады... *(Хөббелгә карап.)* Бу иптәш әфәнде... күренеп тора... артыгы белән җылынган... Иншалла, күренеп тора, моңа файда булачак...

Рифат, Г а л л ә м күренүгә, кулын хәрәкәтләндерүдән туктата. Хөббел һаман башын чайкап утыра, үзе берөзлексез ухылдый.

Ф а т ы й м а *(ике кулын да мәктәп укучылары шикелле күтәреп, сүз сорый. Рөхсәт-мазар көтеп тормастан урыныннан тора).* Галләм әфәнде!

Г а л л ә м. Тыңлыйм сезне, туташ.

Ф а т ы й м а. Галләм әфәнде, сез Казанның берәр ресторанында официант булып эшләмәдегезме?

Г а л л ә м *(аптырап).* Сез нәрсә, туташ?! Сез нәрсә?! Мин бит экстрасенс! Андый эштә эшләргә сез мине кем дип белдегез?!

Ф а т ы й м а. Гафу итегез... Менә кайдадыр күргәнем бар инде сезне. Тавышыгыз да таныш кебек... Исемегез дә таныш сыман... Исемә генә төшерә алмыйм...

Л ә й с ә н. Мишәйт итмәгез инде, Фатыйма апа!

Г а л л ә м *(Фатыймага).* Сез мине кем беләндер бутыйсыз, ахры, туташ?!

Ф а т ы й м а. Бутыйммы-бутамыйммы, әмма йөзегез таныш инде менә...

С а м а т. Фатыйма, дим! Туктыйсыңмы-юкмы син артист иптәшне тинтерәтүдән?

Ф а т ы й м а. Бетте, бетте... Туктыйм, Самат Мансурович... *(Утыра.)*

Г а л л ә м. Әфәнделәр! Ханымнар! Хәзер мин...

Шул вакыт «зал»га К а ф и л килеп керә.
Еш-еш сулый-сулый, борынын лышт-лышт тарта-тарта, борын астын куллары белән алмаш-тилмәш сөртә-сөртә, Саматка таба якыная, Самат белән үз арасында шактый ара калдырып туктый, аңа карап тора.

С а м а т. Нәрсә терәлеп каттың, кисәү таягы?

К а ф и л. Мыскыл итсәң, әйтмим алайса. *(Борынын тартып куя.)*

С а м а т. Нәрсә әйтмәкче буласың тагы, холодецлы борын?

К а ф и л. Менә хәзер әйтмим дә әйтмим инде. Үзеңә үпкәлә. Бик кирәкле сүз әйтәдерием...

С а м а т. Теге көнне әйткән урысча сүз булса, матри! Торма каршымда сураеп! Ике дә уйламыйм, миңгерәү башыңны ыштан төбеңә тыгып куям!

Ф а т ы й м а. Сез нәрсә инде, Самат Мансурович... Кафилгә җикеренергә ярамый. Врачлар кушмый. Бар, утыр, улым, берәр урын табып.

Галләм әле Фатыймага, әле Кафилгә карап ала.

К а ф и л *(чалбарын тотып).* Әллә тиле инде син, персидәтел абзый... Ыштан түгел бит бу, чалбар! Шуны да белмисең... Ыштанны әбиләр кия бит аны. Үзең персидәтел абзый булып йөргән буласың...

Г а л л ә м *(Саматка).* Персидәтел әфәнде... *(Кафилгә.)* Иптәш дивана...

С а м а т. Хәзер, хәзер, разговорны бетерәбез, иптәш артист әфәнде... *(Кафилгә.)* Бар, барып утыр берәр җиргә. Торма минем каршымда дуракаваләйт итеп!

Кафил, башын селкеп, күзләрен уйнатып, Саматка карый-карый, бер читкәрәк китеп баса.

К а ф и л. Мин әйтәсе килгән сүзне беләсең килсә, сора син, җәме, персидәтел абзый...

Самат аңа, «яп авызыңны!» дигәнне аңлатып, йодрыгын селки.

Г а л л ә м. Әфәнделәр! Ханымнар! Әбиләр һәм бабайлар! Хәзер мин берәр авыруның минем тарафка килүен сорыйм.

Ул шулай диюгә, «зал»дагыларның һәммәсе дә диярлек урыннарыннан кузгала. Атылып Л ә й с ә н дә килеп җитә.

Г а л л ә м. Стоп! Стоп! Стоп! Утырыгыз, зинһар-пажалысты, урыннарыгызга! Миңа бер авыру ир-ат кирәк! *(Гибралтарга карый.)* Гибралтар әфәнде!..

Ләйсән, сөмсере коелып, урынына кире барып утыра. Гибралтар урыныннан сикереп тора да йокымсыраган Хөббелгә ишарәли. Башкалар урыннарына утыралар. Гибралтар белән Рифат Хөббелне урыныннан күтәрергә азаплана. Кафил дә шулар тирәсендә кайнаша.

Х ө б б е л *(башын күтәреп).* Што такуй? Милиция што ли? Не пойду! *(Карыша.)* Мин шып-шыр аек патамушто!

Г и б р а л т а р. Хөббел! Хөббел, дим! Уян!

Х ө б б е л. Ә, син татармыни?

Г и б р а л т а р. Татар инде, татар. Уян тизрәк. *(Галләмгә.)* Бу — безнең атаклы механизаторыбыз! Ике смена эшләгән иде — арыган.

Х ө б б е л. Никогда! *(Гибралтарга.)* Син татарча җырлый беләсеңме? Әйдә җырлыйбыз... *(Шыңшый.)* Тала, тал-ла, тала, тал-ла, тала ике беләге-ем... Их!.. Яклый мине, саклый мине-е-е... әнкәмнең догалары-ы-ы... *(Гибралтарга.)* Син кем? Полковник милиции?

С а м а т. Рәткә кертегез инде шул тәрене җәтрәк!

К а ф и л. Хөббел абзый, уян инде, айны! Бу бит дирехтыр абзый!

Х ө б б е л *(башын бик нык селкеп ала).* У-у-у-ух! *(Гибралтарны танып.)* Ментлар сине дә каптырдымыни, Гыйбрай? *(Бармагын селки.)* Нельзя пить! Понял? Давай,

Гыйбрай, сто грамм наливай! Беткән баш беткән... *(Чайкала.)*

Гибралтар. Потом, потом...

Хөббел *(бармагын иреннәренә терәп)*. Тс-с-с-с! Ты сказала шепотом: а что потом? А что потом?.. *(Бармагын өскә чөя, тавышын көчәйтә.)* Поэз-зия! Евтушенко! Понял?

Гибралтар. Понял, понял... Тушенканы да аңламаска! Ит күрмәгән кеше мәллә мин...

Рифат Галләм каршына урындык китереп куя.

Гибралтар. Хөббел, утыр менә шунда. Экстрасенс әфәнде хәзер сине дәвалый. Тыныч кына утыр.

Хөббел. Понял! Утырам. Утырам, тартам, кирпеч бар — раствор юк!

Гибралтар белән Рифат үз урыннарына барып утыралар. Кафил шул тирәдә йөренә.

Галләм *(Хөббелгә текәлеп карап тора)*. Әфәндем, сездә — менингит авыруы.

Хөббел *(чайкалып куя)*. Ә? Не понял што-то... Нишләп Ленин мент булсын... Ленин ул — юлбашчы! Укырга, укырга һәм и тагын укырга кушкан ул безгә! Наданнар!

Галләм. Сез, иптәш әфәнде, хроник баш авыртуы белән җәфаланасыз...

Хөббел. Точно! *(Башын тота.)* Дөрес әйттең. Минем баш пастаянны авырта. Менә әле дә перәме чатный. Юкмы берәр нәрсәң?..

Галләм. Хәзер мин сезнең баш авыртуыгызны бетерәм... *(Ике кулын күтәреп, Хөббелнең баш тирәсендә йөртә.)* Хәзер юып алгандай итәм мин аны...

Хөббел, чайкала-чайкала, урындык аркасына терәлә. Кинәт урындык җимерелеп, Хөббел идәнгә мәтәлә. Бераз ухылдый да гырлап йокыга китә.

Кафил *(Хөббелне торгызмакчы була)*. Хөббел абзый! Хөббел абзый!

Галләм. Иптәш дивана! Пажалысты, тимәгез аңа. Йокласын. Ярты сәгатьтән чын кеше булып уяна ул. *(Гибралтарга.)* Гибралтар әфәнде, әйдәгез, бу иптәш диваны... тфү!.. әфәндене сезнең кабинетка кертик тә... салыйк әле без. *(Рифатка.)* Ә син, дускаем, сеансны дәвам итә тор.

Галләм белән Гибралтар, Хөббелне култыклап, директор бүлмәсенә алып кереп китәләр. Бераздан анда Галләм белән Гибралтарның аракы эчкәне шәйләнә.

Р и ф а т *(Кафилгә)*. Кил әле монда, быр-рат. Хәзер мин сине гипнозлыйм.

К а ф и л. Нишләтәм дисең, абзый?

Р и ф а т. Мин сине йоклатам хәзер. Курыкма, курыкма... Шундук уятам мин сине.

К а ф и л. Акча бирәсеңме соң?

Р и ф а т. Бирәм, бирәм... Мә, хәзер үк бирәм. *(Кесәсеннән кәгазь акча алып, Кафилгә тоттыра.)*

М и ң н и с а *(Фатыймага)*. Әллә акча өләшәләрме, кызым? Пенсиядәгеләргә дә бирәләрме?

Ф а т ы й м а. Бирәләр, бирәләр. Сиңа да бирәләр. Янчыгыңны әзерләп куй.

М и ң н и с а. Әлхәмделлиллаһи шөкер...

С а м а т. Тик кенә утыр әле, яме, Миңнисаттәй. Мишәйт итмә халыкка!

М и ң н и с а. Бетте, бетте, Гапсамат улым... Янчыгымны гына кулыма тотыйм да... *(Күлмәк итәген күтәреп, оек керешенә кыстырылган янчыгын ала.)*

Р и ф а т *(ике кулы белән Кафилгә «йоклау энергиясе» җибәрергә азаплана)*. Син йоклыйсың хәзер... йоклыйсың...

К а ф и л. Теге икестрасин абый белән икегез эчкән даруны да бирәсең мәллә?

Р и ф а т. Йоклыйсың... *(Күзләрен акайтып.)* Ә? Йокла, дим!

К а ф и л. Йоклыйсы килми минем. Ашыйсы килә! Ашарга бир әле.

Р и ф а т *(кызарынып-бүртенеп)*. Мин сиңа сталавай мәллә! Йокла җәтрәк!

Ф а т ы й м а. Улым, йокла инде, йокла. Интектермә абзыеңны...

К а ф и л. Әйем лә...

Р и ф а т. Йоклыйсың, йоклыйсың...

К а ф и л. Синең машинаң бармы? Минеке бар. *(Кесәсеннән уенчык машина тартып чыгара.)* Менә! Йөрүен йөри... Утырып кына булмый. *(Идәнгә машинасын куеп йөрткәләмәкче була.)* Выж-жыйн...

Р и ф а т. Иелмә! Сүндер машинаңны! Тфү! Тыгып куй кесәңә. Атып бәргәнче!.. Йоклыйсың... йоклыйсың...

К а ф и л. Рульдә йокларга ярамый. Авария була.

Р и ф а т *(ярсып)*. Яшер машинаңны — он-талкан иткәнче.

К а ф и л *(машинаны кесәсенә тыгып куя да кулындагы акчаны әйләндереп-әйләндереп карый)*. Бу акчага күкәй алып буламы?

Р и ф а т *(кулларын һаман хәрәкәтләндерә-хәрәкәтләндерә кычкыра)*. Нинди күкәй ул тагы?

Кафил *(битараф кына)*. Тавыкныкы инде. Әтәчләр күкәй салмый ла... Минем күкәй ашыйсым килә. Безнең тавык бүчкәдәге суга төшеп үлде. Йөзә белми икән ул...

Рифат *(хәлсезләнеп)*. Ыслушай, мин сиңа миллион күкәй бирәм... Тыгынырсың... йокла, яп-яланаяк!

Кафил *(ботинкаларын карап)*. Әйем лә... Яп-яланаяк йокламыйм. Минем аяклар өши алайса...

Самат *(кычкыра)*. Йокла, диләр сиңа, миңгерәү тәре!

Галләм директор бүлмәсеннән ике кулын залга төбәп килеп чыга. Шактый кызмача икәнлеге сизелә. Гибралтар үз урынына чыгып утыра.

Галләм. Хәзер сез бик каты җылындыгыз инде... Сизәсезме? Мин сизәм.

Миңниса *(Фатыймага)*. Нәрсә дип әйтә ул?

Фатыйма. Сиңа әйтми ул. Дәваланып кына утыр.

Рифат *(Кафилне читкәрәк этәреп)*. Бар, читтәрәк тор. Яңадан кабатларбыз сеансны... *(Үз урынына барып утыра.)*

Галләм. Мин, әфәнде иптәшләр, туташлар-ханымнар... Мактанып әйтмим, име... Мин — халыкара категорияле экстрасенс. *(Бармагын өскә таба төбәп.)* Өстәгеләр, то есть тегендәгеләр белән, мин даими элемтәдә торам. Теләсәм — яңгыр, теләсәм — боз яудыра алам. Име?! Теләсәм, болытларны куып таратам. Мин хәтта, име, җир тетрәүләрне дә булдырмый кала алам. Моңарчы сезнең авылда җир тетрәмәгән икән — бу минем тырышлык нәтиҗәсе. Бу авылда җир тетрәмәскә тиеш — мин шундый установка куйдым...

Фатыйма *(янә кулын күтәрә дә урыныннан тора)*. Карагыз әле, Галләм Сәлмән әфәнде... Әйтегез әле... Сез Казанның берәр бүлнисендә гинеколог булып эшләмәдегезме?

Галләм *(айнып киткәндәй була)*. Ничек? Мин... гинеколог?! Сез нәрсә, әби җаным! Әйттем бит инде, мин — экстрасенс!

Фатыйма. Гафу итегез инде... Менә кайдадыр күргәнем бар инде...

Самат. «Сифилистан лечить итә торган бүлнистә эшләмәдеңме?» дип кенә сорыйсың калды инде, телеңә тилчә чыккыры!

Фатыйма *(үзе дә сизмәстән)*. Чыннан да! Галләм әфәнде, сез сифилис... тән... *(Як-ягына каранып, кинәт туктап кала.)* Кайдадыр күрдем инде мин сезне... Гафу итегез...

Самат. Утыр инде урыныңа канса да кансов!

Г а л л ә м *(Фатыймага)*. Туташ-ханым, име... Минем үземә дә сезне кайдадыр күргәнем бар кебек тоела... Сез миңа шундыйрак сорау-мазар бирмәгән идегезме?

Ф а т ы й м а *(сәерсенебрәк)*. Әй-йе... Ике мәртәбә... бирдем...

Г а л л ә м *(җиңелчә чайкалып куя)*. Во! Әйттем бит, сезне күргәнем бар кебек тоела, дип... Бүген күргәнем булган ызначит!

Галләм кул хәрәкәтләре белән Фатыйманы йоклатырга тырыша. Миңниса, урыныннан торып, Гибралтар янына килә.

М и ң н и с а. Гыйбрәт улым... Кәшәбет... бет... бет... динуф... эф... эп...

Г и б р а л т а р. Нәрсә тагы?

М и ң н и с а. Мунчам суынып бетмәде микән инде?

Г и б р а л т а р. Мин каян белим!

М и ң н и с а. Бик кызу булгач, күсе тишекләрен томаламаган идем. Суынмаса гына ярар иде инде...

Г и б р а л т а р. Бар, бар, мунчаң холодильникка әйләнгәнче, тизрәк кайт та шул тишек-тошыкларыңны томалый тор...

М и ң н и с а. Шулай итим, алайса... *(Кузгала.)* Кәнсирт бетүгә, әртистләрне алып кайтырсың инде, җәме, Гыйбрәт улым... Кәшәф... фет... бет...

Г и б р а л т а р. Бар инде, бар... Җәтрәк кыймылда. Өеңдә генә утыр. Мунчаңда гына утырсаң да ярый... Күселәр кереп тулмасын. Беркая да чыгып китмә...

Миңниса китә. Самат Гибралтарга сәерсенеп карап тора.

Г и б р а л т а р *(Саматка)*. Көне буе нервыны талкыды инде... Артистларны... ту ест... экстрасенс әфәнделәрне үземә алып кайтам, ди... Аптырагач, котылу өчен, мунча як, дип әйткән идем...

Г а л л ә м. Җитәкче әфәнделәр, сез бераз гәпләшә торыгыз, без ярдәмчем белән, име, теге әфәнде иптәшнең хәлен белеп чыгыйк әле...

Галләм белән Рифат Гибралтар бүлмәсенә кереп китәләр. Галләмнең аракыны шешә авызыннан гына эчкәнлеге, Рифатның бер-бер артлы ике стакан аракыны авызына «озатканы» шәйләнә. Сәхнәдә Кафил, Галләм шикелле кулларын өскә күтәреп, «зал»дагыларны «дәвалый».

К а ф и л. Хәзер терeләсез... Хәзер терeләсез... Дирехтыр абзый, син дә терeләсең... Персидәтел абзый да терeлә хәзер...

С а м а т. Нишлисең син, җил тегермәне? Төш хәзер үк сәхнәдән!

К а ф и л. Хәзер җылынасыз... Хәзер йоклыйсыз... Япьяланаяк йоклыйсыз...

С а м а т *(бармак изәп, Кафилне үз янына чакыра)*. Кил әле монда, Миңнисаттәй сыңары...

К а ф и л *(шүрли-шүрли генә Саматка таба якынлаша)*. Кыйнарга уйласаң, «Пожар!» дип кычкырам! *(Ара калдырып туктый.)*

С а м а т. Курыкма, курыкма, урыс теле ызнатогы... Сиңа кагылып кулымны пычратмыйм... Ә, әйт әле, баягынак нәрсә әйтмәкче идең?

К а ф и л. Әйтсәм, ачуланмыйсыңмы соң?

С а м а т. Юк, юк, давай әйт!

Г а л л ә м белән Р и ф а т кызып чыга. Рифат үз урынына утыра.

К а ф и л. Филдшер абзый әйткән ие... Персидәтел абзыеңны эзләп табып әйт, дигән ие...

С а м а т. Дальше. Шуннан?

К а ф и л. Менә шул инде.

С а м а т. Соң, тилекәем... Нәрсә әйтергә кушты соң сиңа фельдшер абзыең?

К а ф и л. Ә-ә-ә... Әйе шул... Филдшер абзый әйтте... теге... бу икестрасиннарга дигән... теге... күбенеп кайткан сыер үлеп ята, дигән ие... Үлгәнче суйыйк микән, дигән ие... *(Битараф кына.)* И-и... үлгәндер инде ул сыер...

С а м а т *(урыныннан сикереп тора)*. Чурт! Ник аны баягынак ук әйтмәдең, маңка тәре!

К а ф и л *(артка чигенеп)*. Бә-ә-ә-әй... мин бая ук әйтмәкче идем... Үзең бит... Әйттермәдең... Кызык икән син!..

С а м а т *(Кафилгә)*. Ну сине! *(Гибралтарга.)* Продолжайте! *(Кабаланып чыгып китә.)*

К а ф и л *(Гибралтарга Самат булып кыланып әйтә)*. Бырадалжайте.

Г и б р а л т а р. Төш сәхнәдән, нәгаләт!

К а ф и л. Әгәр миңа кычкырсаң... Кул болгаучы менә бу бырач икестрасин абзыйга әйтәм...

Г и б р а л т а р. Нәрсә әйтәсең?

К а ф и л *(сәхнәгә куелган Гибралтар банкасына ишарәли)*. Бу банкыда чишмә суы түгел, ә колонкы суы, дип әйтәм...

Г и б р а л т а р. Ә? Аh, дивана крис!

К а ф и л *(Гибралтарга ике учын төбәп)*. Хәзер син тереләсең, дирехтыр абзый... Хәзер йоклыйсың... дивана крис!

Г а л л ә м *(Кафилгә)*. Карап-карап торам да мин си-

ңа, иптәш дивана әфәнде... Синдә нидер бар бит... Мин сине икенче ярдәмчем итеп алам... Ие!

Кафил *(Галләмнең әйткәнен ишетмичә)*. Хәзер сез дә йоклыйсыз, хәзер тереләсез...

Рифат *(урыныннан сикереп торып, кул чабып ала)*. Афәрин, быр-рат!

Ул, шулай кул чаба-чаба, Гибралтар бүлмәсенә кереп китә. Анда аның авызыннан гына аракы чөмергәне шәйләнә.

Галләм *(Кафилгә карап)*. Талантлы егет! Дивана булмасаң, менә дигән экстрасенс чыгасы үзеңнән!

Кафил. Сөйләшмә! Хәзер йоклыйсың... Хәзер тереләсең... Хәзер чирлисең...

Рифат чыга.

Галләм. Ха-ха-ха! *(Рифатка.)* Настоящий экстрасенс бу! Сине дә уздыра, авызына кереп чыгыйм!

Фатыйма кинәт колагын шомрайта. Кафил һаман кулларын хәрәкәтләндереп йөрүен белә.

Рифат *(көлгән булып)*. Мине үк уздыра алмас анысы, Галләм Хатипыч... Әмма бу, күренеп тора, клад бу, клад! *(Кафилгә.)* Исемең ничек әле синең, быр-рат?

Кафил. Нигә? Кафил.

Рифат. Фамилияң?

Кафил *(аңламыйча)*. Нәрсә?

Рифат. Ну-у... Атаңның яки бабаңның исеме ничек?

Кафил. Атамныкымы? *(Фатыймага.)* Кем әле минем атам?

Фатыйма. Шул инде... Ни...

Рифат. Ни дигән исем буламыни? Нияз мәллә?

Галләм. Атаңның исемен дә белмисеңмени, авызыңа кереп чыгыйм!

Фатыйма янә колагын шомрайта, кинәт урыныннан капылт кына сикереп тора.

Фатыйма *(Галләмгә)*. Таныдым бит мин сине, грузчик тәре! Тәки таныдым!

Галләм *(шикләнеп)*. Сез нәрсә! Кем грузчик?

Рифат әле Галләмгә, әле Фатыймага карый.

Фатыйма. Авызыңа кереп чыгыйм! *(Галләмгә таба килә.)* Алкаш! Менә, улым, шушы булыр инде синең атаң.

Галләм *(әсәренеп)*. Бу? Минем улым?!

Г и б р а л т а р *(калкынып)*. Ә син миңа сылтап маташкан идең, тагарак!

Һәркем Гибралтарга борылып карый.
Гибралтар, ялгыш сүз ычкындырганлыгын аңлап, урынына сеңә.
Ләйсән сикереп тора да лып итеп урынына кире утыра.

К а ф и л. Эти! *(Галләмне барып кочаклый.)* Исәнме, этием! Минем бырач этием! Икестрасин!

Ф а т ы й м а. Әйтәм бит, кайдадыр күрдем, дип... Мин сине шул сүзеңнән таныдым...

К а ф и л. Эти! Икестрасин!

Р и ф а т. Да-а... Килеп җиттек, кода-а...

Г а л л ә м *(Кафилдән котылырга теләп, артка чигенә)*. Сез нәрсә? Сез нәрсә?! Нишләп мин бу дуракның атасы булыйм. *(Фатыймага.)* Мин сине беренче тапкыр күрәм, әби!

Ф а т ы й м а *(күкрәген калкыта төшеп)*. Йә, йә, исеңә төшер!

Л ә й с ә н (*Галләм белән Фатыйма арасына барып керә)*. Нәрсә бу? Аңлатыгыз җүнләп. *(Фатыймага.)* Фатыйма апа, нишләп син кешегә яла ягасың? Чит-ят кешегә...

Ф а т ы й м а. Тыгылма, үскәнем, яшь әле син... Нишләп ят булсын, Кафилнең атасы миңа ят була димени?!

К а ф и л. Эти! *(Кочакларга азаплана.)* Икестрасин этием! Мин дә икестрасин булам!

Л ә й с ә н. Галләм абый, әйтегез бер сүз! Юк, әйтмәгез. Әйдә, киттек. *(Галләмне өстери, Кафил аңа чат ябышкан.)* Мин сезнең белән китәм. Хәзер үк!

Г и б р а л т а р. Нәрсә!!! Нәрсә дидең?

С а л а в а т. Бу картлачка ияреп китәм, ди. Көне буе шашынып йөри инде кызың. Тыяр хәл юк.

Л ә й с ә н. Китәм шул. Бер гаепсез кешегә бәйләнәсез.

Г а л л ә м. Җибәрегез мине! Мин алкаш түгел! Мин элек тә аз гына эчә идем. Дәвäландым мин! Үз-үземә установка бирдем. Җибәрегез мине!

Г и б р а л т а р. Ләйсән, кит аннан! Кил монда!

К а ф и л. Эти! Мин дә этиле булдым!

Р и ф а т. Харап булды сыер...

Г а л л ә м *(Рифатка)*. Ни сөйлисең син... Нинди сыер... Мин харап булып ятам монда. Җыйна әйберләрне!

Ф а т ы й м а. Безгә кайтасыңдыр инде, Галләмчик? Таныдың, ниһаять... Казанда мин базарда сату иткәндә, син грузчик булганыңны исеңә төшергәнсеңдер, алайса. Әнә, кара малаеңа! Тач үзең инде!

К а ф и л. Эти! Тач син бит мин!

Ләйсән нишләргә белми тора, аның янында Салават.

Л э й с ә н. Ничек инде? Дөрес түгел бу! Ышанмыйм!

Г а л л ә м. Кәшәфетдинов әфәнде, зинһар, коткар. Сыерыгыз үзегезгә булсын! Үзем бирәм бер сыерлык акча!

Г и б р а л т а р. Атвались! Кызым, кил монда!

Л э й с ә н. Сез... Сез мине Салават... Салават Фәтхетдинов белән таныштырам, дидегез... Сез... мине алдадыгызмы?

Г а л л ә м. Белмим мин сезнең ул җырчыгызны. Күргәнем дә юк! Җибәрегез мине!

Л э й с ә н. Карт алдакчы!

К а ф и л *(Ләйсән янына килеп баса)*. Әйтмә минем этигә алай дип! Минем эти — икестрасин! Мин дә — икестрасин. Хәзер дәвалыйм мин сине. Тәти сүзләр генә сөйләшә торган итәм. *(Кулларын хәрәкәтләндерә.)* Хәзер син тереләсең... Хәзер син җырлыйсың...

Ләйсән чигенә, Салаватка сыена.

К а ф и л *(Салаватка)*. Син дә җырлыйсың... Икәүләп җырлыйсыз...

Шул вакыт шаккатырлык хәл була: Ләйсән белән Салават, кулга-кул тотынган килеш, бер-берсенә карап, үзләре дә сизмәстән җырлый башлыйлар. Башкалар сәерсенеп, гаҗәпсенеп күзәтә.

Л э й с ә н<br>С а л а в а т } *(икесе бергә җырлыйлар)*.

Кош баласы очар чак җиткән —
Кош баласы канат кагына.
Очып китмәс борын чит җиргә,
Туган ягын инде сагына.

Авыл өсләп урап узалар.
Чит җирләргә кошлар кузгала.
Сөйгән ярың монда кала бит,
Син дә китмә инде, кыз бала.

Кош баласы очар чак җиткән —
Канат ныгыткан ул кай ара?
Кошлар юлы, ай-һай, озын бик —
Барасы җир әллә кайларда.

К а ф и л *(башкаларга да карап, кулларын хәрәкәтләндерә)*. Барыгыз да җырлыйсыз!

Б а р ы с ы б е р г ә.

Авыл өсләп урап узалар.
Чит җирләргә кошлар кузгала.
Сөйгән ярың монда кала бит,
Син дә китмә инде, кыз бала.

Җыр тәмамлануга, Кафилдән башка барчасы, бер-берсенә карап, әле Кафилгә караш ташлап, сәерсенеп тора. Үзара: «Әкәмәт! Могҗиза бу! Авыл белән ычкындык мәллә? Фантастика!» — диешкәннәре ишетелә.

Г а л л ә м. Нәрсә бу? Әллә чынлап та гипнозладымы безне бу ти... ти... бу малай актыгы?!

Р и ф а т, үз әйберләрен җыйнап, Гибралтар бүлмәсеннән чыга.

Р и ф а т. Хатипыч, мин әзер! Киттек!

Г а л л ә м. Туктап тор әле. Хикмәт әле монда! Әгәр дә бу малай чынлап та... минем малай булса...

К а ф и л *(Галләм каршысына килеп баса)*. Улым, диген, эти! *(Кулларын хәрәкәтләндереп ала.)*

Г а л л ә м *(кыяфәтендә, үз-үзен тотышында үзгәреш сизелә)*. У... у... у...лым!

К а ф и л. Маладис, эти! Чын эти икәнсең! Мә, жывачка бирәм... *(Кесәсеннән сагыз алып, Галләмгә бирә.)* Бая чәйнәп бетермәгән идем...

Г а л л ә м. Рәх-мәт, у...у...лым!

К а ф и л *(Гибралтарга ишарәләп)*. Дирехтыр абзыйга әйт рәхмәтне. Жывачканы ул бирде.

Г а л л ә м *(Гибралтарга)*. Рәх-мәт... ди...дирехтыр абзый!

Р и ф а т *(Галләмгә)*. Син нәрсә, Хатипыч... Полоумныйланасың... Башыңа артык китте мәллә? Тайдык, әйдә!

Г а л л ә м. Туктале, тукта... Баш кайгысы түгел... Мәсьәлә җитди әле монда...

Кафил Рифат янына килеп баса. Аны, әле генә күргәндәй, баштанаяк күздән кичерә.

К а ф и л. Нихәл, саран абзый? Терелтимме сине дә? Япяланаяк тереләсең... *(Кулларын Рифатның сәерсенгән чырае тирәсендә йөртә.)* Хәзер тереләсең... Тереләсең... Әйбәт кеше буласың...

Г а л л ә м *(үзалдына сөйләнгәндәй)*. Әллә моңа Сәлмән бабайның җаны күчкән инде... о-пэ-рэ-эс-тэ-у-фэ! Кыланмышлары тач бабайныкы!

К а ф и л *(Рифатны җәфалый)*. Челт-мелт итмә күзеңне, саран абзый! Хәзер терелтәм мин сине...

Р и ф а т *(Галләмгә)*. Пажалыста, Хатипыч... Ал әле малаеңны... Күзгә керә бит инде...

Г а л л ә м *(кузгалмакчы була, кузгалалмый)*. Аяклар йөрми бит, быр-рат...

К а ф и л. Хәзер тереләсең... Хәзер яп-яланаяк йоклыйсың...

Р и ф а т. Энекәш... Акча бирәм... Күзгә генә кермә... *(Кесәсеннән акча чыгармакчы була.)*

К а ф и л. Акча кирәкми миңа... Мин акчасыз терелтәм...

Р и ф а т. Бабаң сыңары икәнсең! Алайса... күкәй бирәм... *(Янә кесәсенә тыгыла.)*

К а ф и л. Күкәең дә кирәкми... Хәзер йоклыйсың... Йоклыйсың...

Рифат аягүрә йоклап китә.

Г и б р а л т а р. Вәйт нәгаләт! Әллә аягүрә үлде инде?!

Ашыгып С а м а т килеп керә. Бернәрсәгә дә игътибар итмәстән, туптуры Кафил янына килә.

С а м а т. Әһә! Әле син һаман мондамыни? Түләтәм! Сыер хакын түләтәм! Ысспырафкаң бар дип тормам!

Ф а т ы й м а. Ник җикерәсең безнең малайга? *(Галләмгә карап ала.)* Атасы юк дип беләсең мәллә?

С а м а т. Тик кенә тор әле син! *(Кулын селти.)* Түләтәм!

К а ф и л *(артына чигенә-чигенә)*. Сыерны суйдыгыз дамыни, персидәтел абзый?

С а м а т. Үлгән сыерны суялар димени, ахмак!

К а ф и л *(Галләмгә якынаеп)*. Персидәтел абзый, бер әйбер әйтимме? Минем этием табылды. Икестрасин! Мин дә икестрасин! Хәзер мин сине терелтәм...

С а м а т *(уйламыйча гына)*. Сыерны терелт син... *(Кинәт.)* Ә?! Нинди эти тагы?! Кем ул? *(Әле үзенә, әле Гибралтарга карый.)*

Г и б р а л т а р *(Галләмгә ишарәләп)*. Әнә, каршыңда тора этисе.

С а м а т *(Галләмгә)*. Син? *(Кафилгә карап.)* Моның... этисе?! *(Фатыймага төртеп.)* Моның... нисе?

Ф а т ы й м а. Нисе түгел, ире! Улыбызның атасы, минем ирем! Әйеме, Галләм?!

Галләм бермәл нишләргә белмичә басып тора. Ул арада Кафил Рифатны уята. Рифат ни булганын аңышмый.

Г а л л ә м. Ни дип әйтим инде... иптәш персидәтел әфәнде... Малай минем Сәлмән бабайга охшаган да кебек инде... Бер караганда...

С а м а т. Икенче караганда... ничек?

Г а л л ә м. Икенче караганда... минем... экстрасенслык хыяты да бар сыман... шикелле... кебек... тоела үзендә...

Р и ф а т. Хужы! Бүгеннән член-әгъза...

С а м а т. Членында эшем юк... Миңа димәгәе, хет Алланың кашка тәкәсе белән туганлашыгыз! Мине данный

моментта бер генә нәрсә кызыксындыра: кайсыгыз түли сыер акчасын?

Рифат. Мин — юк! Минем түләрлек акчам юк. Мин... кешегә тагылып йөрүче генә...

Самат. Койрык штоли син тагылып йөрергә? Түләгез! Ике сыер өчен. Колхоз малын ни позволю әрәм-шәрәм итәргә!

Кафил. Персидәтел абзый, пысыйхланма... Мин хәзер терелтәм сине... Мин бит икестрасин! Үлгән сыерны да терелтәм...

Галләм. Ул-лым... Берүк мал-туарларга алынма. Хайваннардан ерак йөр. Кешеләр дә җиткән безгә!

Кафил. Ярар, әти. *(Саматка.)* Мин хәзер терелтәм сине... Әйбәт кеше итәм...

Самат дерелди-калтырый башлый.

Фатыйма. Әллә, Ходаем, әшәке җеннәре чыга инде...

Кафил *(Гибралтарга)*. Дирехтыр абзый, сине дә терелтәм...

Гибралтар. Юк, юк, кирәкми. Мин болай да әйбәт кеше... Эчмим, тартмыйм... Гүләйт итмим... *(Селкенә башлый.)* Бүтән...

Гибралтар бүлмәсеннән Хөббел чыга. Кулында буш стакан.

Хөббел. Гыйбрай! Наливай!

Кафил Хөббелгә таба борыла, селкенә башлаган Хөббелнең кулыннан стаканы төшеп китә.

Хөббел. Ненадо, я — сам! *(Бер чүгәли, бер тора.)* Бер! Ике! Бер! Ике!

Кафил. Әни! Әти! Күрәсезме? Мин — икестрасин! Мин терелтәм...

Барысы да төрле хәрәкәтләр ясап селкенәләр.
Абына-сөртенә Миңниса карчык керә.

Миңниса. Әстәгыфирулла! Шайтан туе мәллә монда? Лә-хәүлә-вәлә-куәтә...

Башкаларга кушылып, ирексездән Миңниса карчык та төрле хәрәкәтләр ясарга тотына. Музыка көчәя.

Пәрдә

*1996–2002*

# Коры куык

*(Моңсу комедия)*

КАТНАШАЛАР:

Фарис.
Нурмөхәммәт (Нурмый).
Сәйдә (Сәйдәттәй).
Мирзәки (Мирзәкәй).
Чегән хатыны.
Сөмбел.

## БЕРЕНЧЕ КӨН

Җәйге иртә. Авыл өе ишегалды. Сул якта өйнең болдырлы өлеше күренә. Түрдә, уң як тарафта, лапас шәйләнә. Печән өсте вакыты икәнлеген искәртеп, ярым җимерек коймаларга тырмадыр-сәнәктер ише әйберләр сөялгән, сул яктагы коймага терәлеп диярлек «уфалла» арбасы тора — өстенә печән салынган. Арбадан читтәрәк иске кое. Иске икәнлеге шуннан күренә — кое бурасы янтайган, сиртмәсенең чылбыры бар — асылынып тора, чиләге юк.

Алгы яктагы җил капканы шыгырдатып ачып берәү керә. Бу берәү башына чит илнеке икәнлеге кычкырып торган, әмма шактый ук тузган кепка сыман әйбер кигән, какча йөзен сакал баса төшкән Фарис. Ул, ишегалдына кергәч, бераз каранып тора. Шуннан соң, угры сыман сак кына атлап, болдырга таба атлый. Шулай ук ишекне сак кына тартып карый. Күрәсең, ишек бикле — ачылмый.

Фарис *(бик ук кычкырмыйча гына)*. Инәй! *(Тавышын көчәйтә төшеп дәшә.)* Инәкәй, дим! *(Ишекне тарткалап.)* Әткәй! Әткәй, дим! Вәт саңгыраулар!

Шул вакыт ул ишектәге йозакны күреп ала.

Фарис. Тфү, заразы! Кеше сыман сагынып кайтасың... *(Йозакны әйләндереп карый-карый.)* Ә алар... сыра кружкасы чаклы йозак асып куйганнар.

Ул болдыр баскычыннан төшә дә баскыч астына иелеп карый.

Фарис. Инәкәй, дим! Әткәй! *(Билен турайтып баса.)* Тәмам баш катты. Баскыч астында нишләп ятсыннар инде алар.

Өйгә ялганып киткән коймадан үрелеп карый-карый, лапаска таба атлый.

Фарис *(сөйләнә-сөйләнә)*. Күрешмәгәнгә ничә ел...

сагынып кайтасың... *(Лапас ишеген ачып, эчкә карап кычкыра.)* Инәй, дим! Инәкәй!

Лапас ишеген ачу белән кире яба да «уфалла» арбасы янына килә, печән астына кулын тыгып, аны өскәрәк күтәрә.

Фарис. Әткәй, дим! Вәт карт шайтаннар, ә? Гырылдап кына йоклап ятасы урында... Монда кешенең башы чатный... Җир шикелле ярылырга тора... Ә алар? Кайдадыр биләмдә йөри... Сагынып кайткан буласың тагы!

Кое янына килеп, аны бер әйләнеп чыга. Капкага арты белән торган килеш, коега иелеп карый.

Фарис. Коеларының суы да юк бит. Нишләп кенә яталардыр...

Шул вакыт ачык капкадан таушалып беткән күн букчасын аскан Мирзәки килеп керә дә, җәһәт кенә аксый-аксый атлап, Фарис аркасына, мылтык сыман итеп, таягын китереп тери.

Мирзәки. Руки верх! Атам!

Фарис кулларын күтәрә.

Мирзәки. Кту такуй? Эстриләйт буду!

Фарис. Әткәй, бу мин!

Мирзәки. Нәмәдәй әткәй булыйм мин сиңа! *(Арткарак чигенә.)* Анука, назад борылганский!

Фарис кулларын күтәргән килеш борыла.

Фарис. Бәй, Мирзәкәй абзый! Синмени әле бу? Мин сине әткәй дип торам бит. *(Кулларын төшермәкче була.)*

Мирзәки. Стуй! Руки верх! Мин сине ызнайт низнай!

Фарис *(авызын ерып)*. Нәрсә, Мирзәкәй абзый, бу корыган таягың мылтык шикелле ата мәллә хәзер! *(Кулларын янә төшермәкче була.)*

Мирзәки. Стуй! Идрит-кудрит! Минем исемне каян беләсең әле син? *(Артка таба бераз чигенә.)* Әһә, шпиун син, алайса! Анука, кәнсәгә!

Фарис. Нинди шпион? Нинди кәнсә? Син нәрсә, Мирзәкәй абый, танымыйсың мәллә мине?

Мирзәки. Ызнайт низнай! Пашшул артың белән пирут! *(Таягын, Фариска төбәгән килеш, уңга-сулга йөртә.)*

Фарис күз кырые белән генә җирдә яткан таякны күреп ала һәм, кинәт җәһәт кенә иелеп, шуны эләктерә.

Фарис. Кылычлашабызмы әллә, Мирзәкәй абый?!

Мирзәки. Но-но-но! Брусай таягыңны, шпиун сыңары!
Фарис. Син ташласаң, ташлыйм, Мирзәкәй абый.
Мирзәки. Аһ, идрит-кудрит!

Икәүләшеп кылычлаша башлыйлар. Әле берсе артка чигенә, әле икенчесе.

Фарис. Мирзәкәй абый, нүжәли танымыйсың инде мине?
Мирзәки. Танымаем. Танырга да теләмәем. Брусай таягыңны!
Фарис. Бу бит — мин! Мин — Нурмөхәммәт малае! Фарис мин!
Мирзәки. Нәмәдәй Нурмөхәммәт ул тагы? Ызнайт низнайт!
Фарис. Ну... Нурмый малае инде.
Мирзәки. Җукны сүләмә, шпиун тәре! Бәләкәй абдый малаеның Каданга китеп җугалганына бишбылтыр.
Фарис. Ничек югалсын инде. Менә бит ул мин!
Мирзәки. Син? Синме Харис?
Фарис. Харис түгел инде — Фарис! Нүжәли танымыйсың? Ышанмасаң, менә бу кулны күрсәтәм. Мин бәләкәй чакта син аңа утлы тәмәке баскан иең... Атнаш чокырына качып, тәмәке пыскытып ятканда әләктердең дә...
Мирзәки. Анука, күрсәт! *(Фарисны таягы белән болдыр баскычына китереп тери.)* Ату ышанмаем.

Фарис Мирзәкигә кулын күрсәтә. Мирзәки таягын төшерә.

Мирзәки. Бәй, апай, чыннан да, син бәләкәй абдый малае Харис бугай шул.
Фарис. Бугай гына түгел, нәкъ үзе! Нурмый малае Фарис.
Мирзәки. Табылдың алайса? Бишбылтырдан соң.
Фарис. И Мирзәкәй абый, артист кешенең туган авылына кайтырга вакыты буламыни инде аның.
Мирзәки. Бәй, апай, син әртисмени?
Фарис. Шулайрак иде, ачуланмасаң.
Мирзәки. Берләр генә дә синең турыда ишеткән җук бит, апай. Тиливидырдан да күрсәткәннәре булмады...
Фарис. Мин бит, Мирзәкәй абый, особый артист.
Мирзәки. Нәмә төсле була инде ул, җәгени мәсәлән, асабуй дигәнең?
Фарис. Юк-бар гына артист түгел, диюем. Әле менә гастрольдән кайтып килешли, юл оңгае булгач, әтәйләрне күреп чыгаем, дигән идем.

Мирзәки *(болдыр баскычына утыра)*. Әртис, дисең инде, алайса, кем, Харис апай...

Фарис. Фарис мин, Мирзәкәй абый.

Мирзәки. Әйе бит әле, Фарис бит әле син, апай. Нәмә соң... Очрашу уңаеннан берәр нәмәң җуктыр бит?

Фарис. Короче да... Ни бит... Чемоданда калды. Чемодан — машинада, машина — Казанда. Казан...

Мирзәки *(букчасы белән булашып)*. Апай, стаканың бармы?

Фарис. Стакан да бар иде. Ул да чемоданда калды. Чемодан — машинада, машина...

Мирзәки. Җарар, апай... Синдә булмаса, миндә бар... *(Букчасыннан бер шешә аракы белән стакан чыгарып, баскычка куя.)*

Фариска дәрт керә. Ул кулларын кушырып ала. Тирә-юньгә күз йөртеп чыга да баскычка утыра.

Фарис. Ну, Мирзәкәй абый, үзеңә кушаматны белеп кушканнар да инде.

Мирзәки *(стаканга шешәдән аракы агыза-агыза)*. Сталавайны әйтәсеңме?

Фарис. Әйе, сталавай. Сталавай Мирзәкәй.

Мирзәки. Кушалар инде, апай. Авылда кушаматсыз кеше булмай инде ул. Менә дөңкеп җиффәр әле! Күрсәт бездгә — авыл мокытларына үдеңнең җегет икәнлегеңне...

Фарис. Вообще-то, Мирзәкәй абый, мин аракы эчмим. Вообще минем эчкән юк. Вообще мин тартмыйм да...

Мирзәки. Син моны, агай, Каданыңа кайткач, берәр баганага сүләрсең, җәме. Ә монда кәнфитләнеп утырма. Манчы әйдә! Өлкән абдыеңны көттермә. Аның да менә, бу шешә төбе дурлыгында гына булса да, авылы бар. Мә, артыннан кабарга яшел суган белән әпи бирәм...

Фарис *(әле стаканга, әле Мирзәкигә карап)*. Вообще-то мин эчмим... Вообще-то... өлкән кеше бик кыстагач... *(Калтыранган куллары белән стаканга үреләә.)* Вообще-то... очрашу хөрмәтенә, дисәк кенә инде...

Мирзәки. Әйдә, җәтрәк кылан инде, апай... Минем ашаганым аркылы килә бит хәзер... Җилпе!

Фарис *(стаканны дерелдәтә-дерелдәтә иреннәренә якын китерә)*. Вообще-то... *(Әкрен генә эчә башлый.)*

Мирзәки. Вобщетылап утырасың... Авыдыңнан Фатихларның абчаркасын үтерерлек махмыр исе килә... Эчмәем, имеш... Мин дә эчмәем аны... Вәләкин эчмәй торганым да җук.

Фарис стаканга салынган аракыны көч-хәл белән эчеп бетерә. Бер кулына буш стакан тоткан килеш, икенчесе белән авызына җил өрдерә. Бермәл сүз дәшми тора.

Ф а р и с *(стаканын куеп, суган кыягын үрелеп ала)*. Яндыра-а-а... Вообще-то...

М и р з ә к и. Катымы! Туты! Минзәлә кәрәчине, диләр аны. Нитушто Кадански. Кияү Каданнан апкайткан иде берчак. Ни су түгел, ни аракы. Бүтән җөк итеп апкайтып җөрмә, дидем кияүгә. Хәдер апкайтмай. Миндәләдән генә апкитә. Шәп, ди. Шәп булмайча... *(Стаканга янә аракы агыза.)* Мин дә тәвәккәлләп караем әле.

Ф а р и с *(баш бармагын тырпайта.)* Класс! Мондыйны күптән эчкән юк иде...

М и р з ә к и *(киная белән)*. Вобшыты минем эчкән җугые... Кичәдән бирле... Вобшыты син карап тормале, апай, җәме. Җенем сөймәй, эчкәндә кеше карап торганны. Ул да ач күздләре белән минекен эчәдер күек... *(Эчә.)*

Ф а р и с *(Мирзәкигә яшел кыяк сузып)*. Ничек соң авылда тормыш итүләре, Мирзәкәй абый?

М и р з ә к и *(Фарис биргән кыякны тәмләп чәйни-чәйни)*. Иртән торабыз, кич җоклыйбыз, апай. Катынны күрергә дә вакыт калмай. Вобшыты менә шушы булса *(шешәгә күрсәтә)*, тормыш гөрләп бара. Трактор күек. Син, апай, безднең тормыш турында бәләкәй абдыйдан сораштырырсың инде. Лутчы син үдең турында сүлә. Кайларда җугалып җөрдең? Берәр институт бетерәлдеңме?

Ф а р и с. Берне түгел, өчне бетердем, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и. Кит аннан! Булмаганны сүлисеңдер.

Ф а р и с. Чын инде менә, Мирзәкәй абый. Артистлыкка укыдым, язучылыкка укыдым... Аннан соң теге... бар бит әле... Абыйсын үтергәннәр... Үзе ни инде... Аның турында халык җыры да бар... Карале, онытып җибәрдем... хәзер, хәзер искә төшерәм... Әллә кем инде... Маңгай чәчен ал тасма белән үргән... илле яшьтә дөнья бутап, кырык яшендә үлгән... Үзе пеләш инде менә...

М и р з ә к и. Ленин бабаймы әллә?

Ф а р и с. Вот-вот-вот! Шул! Мин менә шул Ленин укыган университетның общагасын бетердем.

М и р з ә к и. Алайсам, дур кеше булгансың икән инде, апай. *(Букчасыннан тәмәке белән шырпы ала.)*

Ф а р и с. Зур, дип... Зур инде, әйе, Мирзәкәй абый.

Мирзәки тәмәке кабыза.

М и р з ә к и. Вобшыты син тартмыйсың бугай, апай...

Ф а р и с *(Мирзәкинең тәмәке төтене суырганын*

*йотлыгып күзәтеп).* Вообще-то тартуын тартмыйм инде мин... шул... сиңа иптәшкә дисәм генә... Вообще-то... минем тәмәке чемоданда калган. Чемодан — машинада. Машина...

М и р з ә к и *(Фариска тәмәке белән шырпы суза).* Мә, апай, күздләреңне ач эт күек мөлдерәтеп утырма.

Фарис тәмәке кабызмакчы була. Шул вакыт ачык капкадан Ч е г ә н х а т ы н ы килеп керә. Тәмәке кабызырга өлгермәгән Фарис та, Мирзәки дә Чегән хатынына текәләләр.

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Алла сезгә исәнлек-саулык, йортыгызга иминлек бирсен! Мал-туарларыгыз күп булсын, келәтләрегез ашлык белән тулып торсын! Исәнмесез, асыл егетләр!

Ф а р и с. Аллага шөкер!

М и р з ә к и *(төксе генә).* Тагын синмени әле бу, алтын бытбылдык? Бу җулысы ни бурлашырга җөрисең?

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Гөнаһ сүз сөйләмә, чибәр егет. Нишләп урлашыйм мин? Ямьсез сүзләр әйтү бер дә килешми синдәй батыр егеткә.

М и р з ә к и. Нишләп җегет булаем мин, алама чүпрәк баш! Бар, бар, сыптыр моннан! Мәче күек күзеңне җылтыратып торма! Бар, кеше белән сүләшергә ирек бир.

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Ай-яй-яй, бигрәк усал бүген чибәр абый. Матур җиңги үзеңә ямьсез сүз әйтмәгәндер бит?

М и р з ә к и. Синең минем катында эшең булмасын, җәме, ут күз. Җугал күзд алдымнан!

Ф а р и с. Сайрасын инде, Мирзәкәй абый, кызык бит.

М и р з ә к и. Сиңа — кыдык, миңа кыдык түгел!

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Рәхмәт, чибәр егет. Кешене кешедән аера беләсең икән. Каяле, шуның өчен үзеңә бер әйбер күрсәтим әле. *(Букчасын актарырга тотына.)*

М и р з ә к и. Җүләр булып ала күрмә, апай. Былтырларны минем катын менә бу алдарбикәдән заграничный күлмәк алганые. Чуаш күлмәге булып чыкты. Катыргысын гына алыштырган булган, идриткудрит тәре!

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Менә таптым, чибәр егет. Карале бер генә! *(Хатын-кызлар эчке күлмәген күрсәтә.)* Нәрсә дип әйтә әле татарлар? Суйган да каплаган, диме?! Менә нәкъ суйган да каплаган инде!

Ф а р и с. Миңа нәрсәгә бу үтә күренмәле чүпрәк?

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Сиңа түгел, чибәр егет. Нишләп сиңа булсын... патша кызыдай сылу хатыныңа!

Ф а р и с. Һы... ха-ха-ха! Минем... минем хатын юк бит!

Мирзәки. Ала күрмә, апай. Алдырганчы тырышачак бу тәре!

Чегән хатыны *(Мирзәки сүзләрен ишетмәмешкә салыша)*. Хатының булмаса — булыр! Бүген булмаса — иртәгә булыр! Күзләреңнән күреп торам, би-и-ик чибәр, би-и-ик сылу, алсу алма шикелле би-и-ик татлы шаһзадәгә өйләнәчәксең тиздән. Туктале, тагын бер әйбер күрсәтәм. *(Янә букчасында казынырга тотына, Мирзәки белән Фарис аның уйнаклап торган артына ис китеп карап торалар.)*

Мирзәки. Би-и-ик йомшак, би-и-ик дәртле... Тфү! Ала күрмә, апай. Алдана күрмә. Валлаһи, дип әйтәм, үзебезнең әртилдә генә чурылган чүпрәгеңне тотып калачаксың! Мирзәкәй абый әйткән ие, диярсең. Вәләкин соң булыр...

Чегән хатыны. Менә! *(Күкрәкчәгә күрсәтә.)* Французский! Берәү генә, бүтән юк. Нәкъ менә синең булачак хатыныңа үлчәп теккәннәр диярсең? Товарын кара син аның: ул төсе, ул җыйнаклыгы...

Мирзәки. Ыслушай, дирул безд сахара, тешкә кызыл борычлы сагызд булып ябыштың бит, ә! Каян беләсең син апайның булачак хатынының күкрәк раздмерын? Бәлки, аңа бездраздмирный кирәктер? Бәлки, аңа минем катынныкы күек биштәр кирәктер? Идрит-кудрит!

Фарис. Шәп! Класс! *(Күкрәкчәне алып, үзенең күкрәгенә куеп карый.)* Үтергән дә суйган, суйган да каплаган!

Чегән хатыны. Әйтәм бит, каплаган да суйган инде менә! Ал, әйдә, даром-шаром отдам!

Фарис *(көрсенгән булып)*. И-их... *(Мирзәкигә күз кыса.)* Алыр идем мин моны...

Чегән хатыны. Ал, әйдә, ал! Икеләнеп торма!

Фарис. Ни бит... акча чемоданда калган...

Мирзәки. ...чемодан — машинада, машина — Каданда...

Чегән хатыны. Уф, сезнең белән сөйләшеп, вакытны гына әрәм иттем. *(Каударланып, күкрәкчәне букчасына тыга, букчасының телтебиен тартып, ябып куя.)*

Мирзәки. Маладис, апай, тәки җегет икәнсең!

Чегән хатыны. Булмады сез асыл егетләр белән уртак сүз табып. Каяле, киткәнче, чибәр абыйны гадать итеп алыйм.

Мирзәки торып баса. Чегән хатыны аңа таба килә. Мирзәки читкә тайпылмакчы була.

Мирзәки. Җакын килмә, бур тәре!

Ч е г ә н  х а т ы н ы *(Мирзәкине кулыннан эләктереп, аның күзләренә карый)*. Шундый чибәр абый, шундый мөлаем абый үзе. Киемнәре бигрәк килешеп тора үзенә. *(Бер кулы белән Мирзәкинең пинжәген, чалбарын сыйпап ала.)* Синең белән яшәгән хатын би-и-ик бәхетледер инде... М-м-м-му-ух! Үземә шундый иркәйләр насыйп булмады...

М и р з ә к и. Кит, кит! Тимә миңа, тимә минем катынга!..

Чегән хатыны Мирзәкинең кулын җибәрә дә Фариска таба атлый.

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Бигрәк усал абый бу, әйеме, чибәр егет?

М и р з ә к и. Синдәй яшел бәрәңгеле кыстыбый янында минем катын күпереп пешкән кабартма! Белдеңме, лыгырдык тел?

Ф а р и с *(чегән хатынына)*. Юк, юк, минем янга килеп тә торма!

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Юкка тырышасың, чибәр егет. Кайчан өйләнәсеңне, хатының кем буласын беләсең килми мәллә?

Ф а р и с. Кем булсын инде минем хатын? Минем хатын — минем хатын булыр инде.

Ч е г ә н  х а т ы н ы *(Фарисның кулыннан тотмакчы була)*. Ә балаларың? Ничә балаң буласын да беләсең килмиме?

Ф а р и с. Син әйтмәсәң дә беләм. Икәү булачак минем бала. Икәү и баста!

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Ю-у-ук, синдәй баһадирның икәү генә булырга тиеш түгел. Ким дигәндә, дүртәү булырга тиеш.

Ф а р и с. Калган икесен үзең табарсың, яме. Түлке миннән генә түгел. Давай, лутчы мин синең үзеңне гадать итәм. *(Чегән хатынының кулын үзе тота.)* Тә-ә-әк, юлдан килгәнсең икән. Тә-ә-әк... киткән чакта тагын юл белән китәсең икән... еракан килгәнсең икән. У-у-у... монда гел аркылы-торкылы юл да юл...

Ч е г ә н  х а т ы н ы. Анысын мин аның син әйтмәсәң дә беләм. *(Ачу белән этә.)* Гадальщик несчастный!

Зур букчасын күтәреп, капкага таба бара.

М и р з ә к и. Уф! Тәки котылабыз бугай...

Ч е г ә н  х а т ы н ы *(борылып, реверанс ясый)*. Пока, саран татарлар!

Чыгып китә.

М и р з ә к и. Аңкау шартлап җарыла дип торам... Әйдә, аракы очып беткәнче, тиешле җиргә шудыра тораек.

Ф а р и с. Вообще-то... Минем йөз граммнан артык эчкән юк югын да...

М и р з ә к и. Мәйлең, апай...

Ф а р и с. Мәйлең, дип... Вообще-то... Корсакка бер кергәч инде... Йөз грамм ни, ике йөз грамм ни...

М и р з ә к и. Алайсам, вабшылап утырма, апай... җаратмаем «җук, җук» дип җәелеп җаткан катыннар күек кыланган кешене. Гөпелдәт, әйдә!

Фарис стакандагы хәмерне җәһәт кенә каплап куя.

Ф а р и с. У-ух! Калай түбәдән төшкән кар шикелле чыжылдаплар шуды...

Фарис, бер кулы белән эчен уа-уа, икенче кулы белән яшел кыякка үрелә. Мирзәки шешәдә калган аракыны стаканга агызып бетерә.

М и р з ә к и. Әртис, дисең инде алайсам, апай?!

Ф а р и с. Мидәлле әртис.

М и р з ә к и. Мидәлле? *(Гаҗәпләнүдән күзләрен шарландырган килеш, стаканны бушата.)*

Ф а р и с. Әһе. Мидәлле.

Мирзәки стаканны букчасына тыгып куя да бер кабымлык ипине авызына озата.

М и р з ә к и *(буш шешәне Фариска суза)*. Мә, апай, куй шуны берәр җиргә. Бәләкәй абдый күрсә, ачуланыр җә.

Ф а р и с. Нигә? Үзең ал. Кибеткә тапшырырсың.

М и р з ә к и. Апай, безднең магадиннан әйберне алып кына була. Әгәр алырлык әйбер булса. Буш магадинда буш шешә белән нишләсен ул Мәликә. Су тутырып уйнасынмыни? Бу бит сиңа, апай, Кадан түгел. Эчкән саен, буш шешә күтәреп гастранумга чабарга... Ауыл бу! Дивня! Пунялмы, апай?

Ф а р и с. Пунял, Мирзәкәй абый, пунял...

М и р з ә к и. Ту-ты!.. Ыслушай, баягынак нинди мидәл турында сүләйдериең син?

Ф а р и с *(кәчтүм якасын кайтарып, медаль күрсәтә)*. Менә, Мирзәкәй абый, кара, күр. Шәп артист булган өчен хөкүмәт бүләк итте.

М и р з ә к и. Хөкүмәт кешене хөрмәтли белә инде ул, апай. Каяле, кулыма тотып караем әле мидәлеңне. Айяй, бик матур мидәл икән!.. *(Медальдәге язуны укый.)* Бәрәч, апай, «Мать-героиня» дип җадылган түгелме суң монда?

Ф а р и с. Әйе, шулай дип язылган, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и. Бә-әй, апа-ай, бу җалтыравык калайны бер казд оясы тутырып бала тапкан катыннарга бирәләрие түгелме суң? Әллә хәдер ир-атларга да бирәләрме? Ни пунял штү-ты.

Ф а р и с. Ни бит, Мирзәкәй абый... хөкүмәтнең миңа тиешле мидәле кайтып җитмәгән иде. Иң главный министр әйтте, иптәш Бәдримуллин, диде, пока шушы мидәлне тагып йөр инде, диде. Сиңа дигәне кайткач, алыштырырбыз, диде.

М и р з ә к и. Э-э-э... Алай икән... Алай да була икән... хөкүмәт белә инде ул... хөкүмәт белә.

Ф а р и с. Әле, «атказанган артист» дигән мактаулы исем дә бирмәкчеләр иде дә... Мәскәү карышып маташты. Бирдермәскә итә. Миннән көнләшәләр, заразылар.

М и р з ә к и *(аның хәленә кереп)*. Мәскәү тәгәрмәчкә таяк тыкмаса, Мәскәү булмай инде ул, апаем. Син, аңа карап, күңелләреңне төшермә, әртислегеңне ташлама. Әртис ул беләсеңме кем? Әртис ул — әртис! Карале, апай, әртис дигәннән, син нәмә әртисе суң? Җырлай торган гына әртисме, әллә тиатр уйный торганмы?

Ф а р и с. Мин, Мирзәкәй абый, мактанып әйтүем түгел, бөтенесен дә булдырам. Җырлыйм да мин, театрда да уйныйм. Менә син уйлыйсың инде, әйеме, сәхнәдә Рәсим Низамов җырлый, дип. Или, мәсәлән... Тагын кем бар әле шулай шәп җырлаучы?

М и р з ә к и *(бераз уйланып торганнан соң)*. Хәния Фәрхи!

Ф а р и с. Әйе, Хәния Фәрхи. Син уйлыйсың инде, алар сәхнәгә чыгып үзләре җырлый, дип. Ничего подобного, Мирзәкәй абый! Мин җырлыйм алар өчен. Алар прусты сәхнәгә чыгып басалар да, теге тавыш акырта торган грушаны тотып, авыз ачып кына торалар. Ә мин алар өчен сәхнә артыннан җырлыйм. Пунялмы инде, үзең әйтмешли?

М и р з ә к и *(ямьшәйгән кепкасы астына бармакларын тыгып, башын кашый)*. Пунялмы, дип... Пунял күек сыман инде. Әй, минем баш катлаулы нәмәләрне аңлап та бетермәй ул... Миңа бит, апай, катын әйткән гади сүзд дә өч көннән суң гына барып җитә.

Ф а р и с. Моннан соң, Мирзәкәй абый, сәхнәгә үзем чыкмакчы булам. Собственный гәүдәм белән. Җитте кеше өчен сәхнә артыннан җырлап ятулар.

М и р з ә к и. Нәмә, әллә сәхнә артында шулай җатып җырлайлармыни?

Ф а р и с. Юк инде, Мирзәкәй абый. Әлбәттә, басып җырлыйлар.

Мирзәки. Басып? Нәмәгә басып? Сине бит барыбер күрмәйләр. Утырып җырласаң да буладыр.

Фарис *(кинәт)*. Мирзәкәй абый, ничә класс бетердең син?

Мирзәки. Дүртне. Ә нәмәгә?

Фарис. Нәмәгә-нәмәгә? Күренеп тора, дип әйтүем.

Мирзәки. Нәмә күренеп тора?

Фарис. Уф, Мирзәкәй абый, дүрт класс бетергәнлегең күренеп тора, дим.

Мирзәки. Э-э-э... шулай диген аны...

Фарис. Хәзер мин, Мирзәкәй абый, халык җырларын эшкәртеп ятам.

Мирзәки. Эшкәртеп? Нәмәгә эшкәртәсең ул җырларны? Бүтән эшкәртер нәмә беткәнмени?

Фарис. Синең, Мирзәкәй абый, башыңа киттеме әллә? Ни черта да аңламыйсың.

Мирзәки. Әйтәм бит, катын да шулай ди миңа. Пенсиягә чыккач, катынның әйткән сүздләре бер атнадан гына барып җитә башлады башка.

Фарис. Ярар, син тыңла гына, Мирзәкәй абый, «нәмәле» сорауларыңны биреп, минем башны катырма, яме.

Мирзәки. Катырма, дип... катасы булгач ката инде ул баш. Шуңа да баш бит ул. Ту ката, ту авырта...

Фарис. Аңламасаң аңламыйсың икән... тыңла, халык җыры җырлыйм. Үзем эшкәрттем. «Алмагачлар» көенә.

Алмагачның ботагын ла
Төбенә хәтле утадым.
Үзем кечкенә булсам да...
Их!
Күтәреләә күңелләр...

Шәпме? Үземә ошый. Сиңа ничектер тагы.

Мирзәки. Безд бәләкәй чакта бу җырны бүтәнчәрәк җырлай торганыек. Асубенно ахыргы җулын.

Фарис. Син нәрсә, Мирзәкәй абый? Син бәләкәй чакта җырлаганча сәхнәдән җырлап була димени? Шуңа күрә эшкәрттем дә инде мин аны. Көен дә бераз эшкәрттем. Хәзер һәрбер артист шулай эшкәртә.

Мирзәки. Эшкәрттем дә эшкәрттем, дисең... Нәмә, эшкәртмичә генә җырлай торган җыр җукмыни халыкта?

Фарис. Бар, нишләп булмасын. Тыңла, алайса, шундыйны җырлыйм.

Һайлим, һайлим, һайларга...

Фарис, капкадан башын тыгып карап торган Сөмбелне күреп, кинәт җырлаудан туктый.

М и р з ә к и. Ник туктадың, апай?

Ф а р и с *(капкага таба ишарәләп)*. Анда бер туташның гүзәл башы күренә.

Мирзәки капка тарафына борылып карый. Аның йөзе ачылып китә.

М и р з ә к и. У-у-у... Минем кыдым! Ни бар, кыдым?

Фарис әле Мирзәкигә, әле капкадан башы гына күренгән Сөмбелгә карый.

С ө м б е л. Әткәй, әнкәй сине чакыра!

М и р з ә к и. Башта исәнләш, кыдым. Фарис абдыеңны күрмисең мәллә? Бәләкәй абдыйның җугалган малае табылып кайтты бит.

С ө м б е л. Мин исерекләр белән исәнләшмим.

Ф а р и с *(башын артка чөеп көлә)*. Ха-ха-ха! Ну, каты да әйтте кызың, Мирзәкәй абый!

М и р з ә к и. Анасына охшаган. Анасы да гел шулай каты әйтә.

С ө м б е л. Әткәй, дим! Әнкәй чакыра.

М и р з ә к и. Уф, нәгаләт. Хәдер чыгам, дидем бит инде. Бар, лутчы җәһәт кенә Бәләкәй абдый белән Сәйдәттәйгә барып сөенче ал. Югалган малаегыз табылып кайтты, диген. Алар монда, су буенда гына печән киптереп җаталардыр. Тизд бул!

С ө м б е л. Әнкәйдән мине сүктерәсең килмәсә, мин кайтканчы өйдә бул! Ишеттеңме, әткәй?

М и р з ә к и. Ишеттем, кыдым, мең кат ишеттем. Бар инде, бар... Фарис абыең өйгә кералмаенча утыра бит әнә. Җулдан кайткан кеше. Чәй эчәсе киләдер...

С ө м б е л. Җарар. Барып әйтәм. Тик син кара аны, җәме!.. Тагын эчә күрмә.

М и р з ә к и. Юк инде, юк инде, кыдым. Эчмәем. Бар.

Сөмбел китә.

Ф а р и с. Синең кызмыни инде бу, Мирзәкәй абый?

М и р з ә к и. Төпчек кызд. Сөмбел. Минеке инде, минеке. Характеры нәкъ анасы инде. Өдмәй дә, куймай да. Матурлыгы гына минеке.

Ф а р и с. Матур шул. Кыяфәт нәкъ синеке шул, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и *(горурланып)*. Ә кәкже. Планнаштырганда ук уйланылганые шулай буласы. Дөрес, планнаштыруын малай дип планнаштырганыек та... Нәмәшләтәсең ки, кызд булып чыкты. Ничава, кызд да артмый бездән —

каткан тезддән. Главный сау-сәламәт булсын. Саулык ул, апай, дур байлык!

Ф а р и с. Дөрес әйтәсең, Мирзәкәй абый. Саулык — и бәхет, и байлык ул. Менә минем бөтен нәрсәм бар. Тфү, тфү, күз тимәсен, саулык бар, байлык та бар. Менә бәхет юк инде.

М и р з ә к и. Нәмәшләп, апай?

Ф а р и с. Хатын юк чөнки.

М и р з ә к и. Нәмәшләп, әле син шушы җәшкә җитеп һаман өйләнмәдеңмени?

Ф а р и с. Соң, Мирзәкәй абый, артист кешенең вакыты буламыни инде аның. Һаман юлда. Һаман гастроль дә гастроль. Ту Мамадыш, ту Париж, ту Воркута, ту Кытай... Алты бүлмәле квартирга кайтып бер генә сәгать булса да йокларга вакыт юк. Күптән түгел генә «Волга»ны «мерседес»ка алыштырдым. Утырып йөрергә вакыт юк. Инде менә җай чыккач, «мерседес» белән генә кайтырмын дигән идем авылга — булмады, шайтан алгыры.

М и р з ә к и. Урлатмагансыңдыр бит, апай. Андый яхшы машинага карак крисләр бик кызыга, ди бит.

Ф а р и с. Урлатуын урлатмадым, Мирзәкәй абый. Зур урында эшли торган бер дус малай бар минем. Үзенеке ватылгач, минем «мерседес»ны сорап торган иде. Ниндидер туганының туена кайтырга дипме шунда. Әй, анысы не важно. Менә шул дус, кире Казанга кайткан чакта, «мерседес»ның карбюраторын юлда төшереп калдырган. Югыйсә бик каты боргалаштыргалаган да идем инде ул карбюраторның шөрепләрен. Дус әйтә, машина йөз метр бара да туктый, йөз метр бара да туктый, ди. Көчкә минем гаражга кайтып җиткән.

М и р з ә к и. Карбюраторсыз килешме?

Ф а р и с. Карбюратор гына булса бер хәл. Бензин кәчәт итә торган насостан шлангы ычкынып, бөтен горючий агып беткән.

М и р з ә к и. Суң, апай, карбюраторсызд, бенздинсызд ничек кайта алган синең дус-иптәшең? Машина бит пычагым да атламаска тиеш.

Ф а р и с. Дөрес сөйлисең син, Мирзәкәй абый. Ну бит минем «мерседес» газ белән дә эшли. Бензин урынына менә шул газга көйләп кайткан инде минем дус. Минем инде «мерседес»ны рәткә китереп торырга вакыт булмады. Җитмәсә, чемоданны шунда онытып калдырганмын. Әткәй-инәкәйгә, күрше-күләнгә дип күчтәнәчтер-мазардыр тутырган булган идем.

М и р з ә к и *(кинәт колагын сагайта)*. Ступ, апай. *(Пышылдап кына диярлек дәшә.)* Бәләкәй абдыйның аяк

атлаган тавышы ишетелә. Кайталар. Миңа таярга вакыт. Ату әбиең дөнья җимертер анда. Берәр нәмә тапкач, җаңадан сугылырмын.

Икесе дә утырган урыннарыннан торып баса. Мирзәки чайкалып ала. Шулай чайкала-чайкала капкага таба атлый. Капкадан озын буйлы Нурмөхәммәт белән бәләкәй гәүдәле Сәйдә керә. Нурмөхәммәт түбәтәй кигән. Берсенең кулында — сәнәк. Икенчесенекендә — агач тырма.

Мирзәки. Исәнме, Нурмый абдый, саумы, Сәйдәттәй. Менә малаегызд кайткан. Шуның хәл-әхвәлен белеп чыгаем дип, бер генә минутка кергәнием. Ыйк! *(Очкылык тота.)* Кемдер бик каты сүләй. Ыйк! Катындыр инде! Ыйк!

Китә.

Фарис *(әти-әнисенең каршына йөгерә-атлый).* Әткәй! Инәкәй! Сагыныплар беттем үзегезне! *(Башта әтисен кочаклый.)* Их, әткәй... Бөтенләй беткәнсең бит!

Моңарчы бөгелебрәк торган Нурмөхәммәт улының сүзеннән соң гәүдәсен турайта. Ләкин улын кочакламый. Сәйдә яулык чите белән күз яшьләрен сөртеп ала.

Фарис *(әтисен кочагыннан ычкындырып, әнисенә карый).* Инәкәй! *(Әнисен кочаклый.)* Шыр сөяккә калгансың бит! Чыра тек чыра! Их!.. *(Әллә чынлап, әллә юри елый.)*

Нурмөхәммәт Сәйдә кулыннан тырманы ала.

Сәйдә. Балам! Улыкаем! *(Фарисны аркасыннан сөя.)*

Икәүләшеп елыйлар.

Фарис *(сулкылдый-сулкылдый).* Беткәнсез бит... Минсез ничекләр яшәдегез?..

Нурмөхәммәт *(улына карап, башын чайкый).* Әртист! Үзгәрмәсә үзгәрмәй икән...

Ул кулындагы тырма-сәнәкне «уфалла» арбасы янына илтеп куя.

Сәйдә. Кайларда җөрдең, балам?

Фарис *(күз яшен кул аркасы белән сөртә-сөртә).* И инәкәй... Күрде инде башлар! Булмаган җир калмады. Казанның бөтен тыкрыгын, бөтен чокырын беләм хәзер...

Нурмөхәммәт, болар тарафына карап, башын чайкый-чайкый, болдырга таба атлый. Ишек өстеннән ачкыч алып, йозакны ача.

Нурмөхәммәт *(өйгә кереп, ишектән улына карап).* Әртист! *(Кереп китә.)*

Сәйдә. Нәмәшләп берләр дә хәбәр җибәрмәдең, улым? Безд бит монда атаң белән ут җотып җатабызд...

Фарис. И инәкәй... Кая ул хәбәр җибәрү. Пучтыга барып, конверт алып кайтырга вакыт җитми. Эш тә эш... Инде эшләмәгән эш калмады. Хәтта бер-ике ел саф һава директоры булып та эшләдем.

Сәйдә. Шулайдыр, улым, шулайдыр. Хуҗа кешенең вакыты булмай инде аның... Соң... Бер дә булмаса пумушнигыңа әйтәсең калган. Ул җадып җибәргән булыры бер-ике кәлимә сүз...

Фарис. Пумушникның, инәкәй, хат язудан башка да эше муеннан аның...

Сәйдә. Шулайдыр, улым, шулайдыр. Эш кешесенең эше чутсызд була инде аның. Тауык чүпләп бетермәслек. Тауык, дигәннән, атаңа әйтергә кирәк әле, тауык суеп бирсен...

Шул вакыт, пычак кайрый-кайрый, өйдән Нурмөхәммәт чыга.

Фарис. Сезгә күчтәнәчкә бүләкләр дә алган идем. Их, алып кайтып җиткерә алмадым. Шушы такта баш *(башына сугып ала)* аркасында инде...

Нурмөхәммәт *(үзалдына сөйләнә).* Аның беркайчан да акылы булганы булмады.

Фарис *(әтисенең сүзләрен ишетмәмешкә салына).* Чаллы автовокзалында урлаттым. Бер адәмгә саклап тор әле, дип, биш мең сум акча да биргән идем. Саклаган... Мин туалетка киткәч, чемоданнарны алган да качкан, кабахәт!

Сәйдә. Хәерле када булсын инде, улым...

Фарис. Ике зур чемодан иде.

Нурмөхәммәт *(пычагын кайрый-кайрый, лапас тарафына атлый).* Фтарой Муенхауҗен!

Фарис *(әнисенең гәүдәсенә карап).* Берсе-берсе синең чаклы булгандыр.

Сәйдә. И Ходаем, мөртәт тә кеше булган икән...

Фарис. Тотсам, эһ тә итмичә буып үтерә идем үзен... Менә болай итеп. *(Күзләрен акайтып, үзен-үзе буып күрсәтә.)* Э-э-э... Бәхете!

Сәйдә. Әстәгыфирулла!..

Лапас тарафыннан тавыкларның куркынып кыткылдаган тавышлары ишетелә.

Фарис. Синә, инәй, җиде-сигез сурттан разный яу-

лык алган идем. Тагын күлмәктер-ыштандыр шунда... Әткәйне дә онытмаган идем. Бер тартма одноразовый носкилар, читек-кәвеш, түбәтәй, фырт яңа кәчтүм чалбар. И такдалие... Их!..

Сәйдә. Рәхмәт инде, улым. Үзеңнең башың сау булганга шөкрана ит. Башың исән булса, малы табылыр... Бездгә бер нәмә дә кирәкмәй. Безднең, атаң белән, бер аяк монда, икенчесе гүрдә дигәндәй...

Фарис. Алай димә әле син, инәкәй. Чемоданда бит минем гомер буе җыйган акча да киткән. Бер чемоданы гел акча гына иде. Ну, шатлыгыннан бер атна эчкәндер инде теге кабахәт!..

Сәйдә. Милитсәгә дә хәбәр итмәгәнсеңдер инде, улым?

Фарис. Нинди милиция? Исләре дә китми аларның минем чемоданнарга. Алар урлаган машиналарны да таба алмыйлар хәзер, минем бер дусның троллейбусы югалган иде. Менә өч ел инде очына чыга алмыйлар. Милиция, имеш! Җүнле эш булса, мин эшләр идем анда...

Сәйдә. Шулайдыр инде, улым, шулайдыр. Үдең беләсеңдер...

Лапас ягыннан, суелган тавык тотып , Нурмөхәммәт чыга. Өйгә таба атлый.

Фарис. Хет кесәдә сезгә бирерлек берәр нәрсә калмады микән? *(Кәчтүменең уң кесәсенә кулын тыга. Кесәсе төпсез икән — кулы килеп чыга.)* Монысында юк.

Нурмөхәммәт, турсаеп, аның кесә актарганын карап тора.

Фарис *(сул кесәсенә кулын тыга — монысының да төбе юк икән, кулы янә тышка килеп чыга)*. Бусында да юк. Нәрсәдер тыккан кебек идем бит! Ә-ә-ә... *(Кулын түш кесәсенә тыга һәм аннан затлы беләзек чыгара.)* Менә ул! Инәкәй, бу сиңа! *(Әнисенә суза.)* Беләзек!

Сәйдә *(кулларын күлмәк итәгенә сөртә-сөртә)*. Улыкаем, кирәкмәс ие... Акчаңны әрәм итеп... *(Беләзекне ала.)* Бигрәкләр дә матур икән... Рәхмәт яусын инде үзеңә, улым. Ходай Тәгалә үзеңне берүк саулыктан мәхрүм итмәсен.

Фарис. Кулыңа киеп куй, инәкәй. Ярарга тиеш.

Сәйдә *(беләзекне кулына кия)*. Тап-таман, улым. Бәхетең-тәүфыйгың артсын берүк. Гомерең оздын булып, калган гомереңне куаныч эчендә үткәрергә язсын, Ходаем! *(Яулык чите белән күз яшьләрен сөртә.)*

Фарис *(өйгә таба атлаган әтисенә карап)*. Әткәйгә нәрсә бирергә инде. Туктале... *(Чалбар кесәсеннән ни-*

*дер тартып чыгара.)* Менә, эткәй, сиңа да. Әмирекәнский жвачка. Рәхәтләнеп бер чәйнәрсең. *(Әтисенә таба атлый да шып туктый.)* Әй, синең тешләрең юктыр инде. Үзем генә чәйнәрмен. *(Сагызны кесәсенә кире тыга.)*

Нурмөхәммәт, пычагын тоткан кулын селтәп, башын чайкый-чайкый, өйгә кереп китә.

Сәйдә. Улым, әйдә, өйгә керәек. Шунда сүләшербезд. Атаң тауык суйган әнә. Шулпа салып җибәрермен.

Фарис. И-и-их!.. Сагынып кайттым да инде үзегезне, инәкәй! *(Әнисен янә кочаклап ала.)* Ун ел ничек түзгәнемне үзем генә беләм...

Өйдән Нурмөхәммәт чыга. Бер кулында — тастымал, икенчесендә — кырыну әсбаплары.

Нурмөхәммәт *(карчыгына ымлап, кулындагы әйберләрне суза).* Менә кырындыр, җуындыр үден.

Сәйдә. Улым, җуынып ал әйдә. Аннан өйгә кереп, җал итеп алырсың...

Фарис әнисен кочагыннан ычкындыра. Сәйдә Нурмөхәммәткә таба атлый.

Фарис *(ике кулын да өскә чөеп).* Их, белсәгез иде сез минем ничек сагынганны!..

Нурмөхәммәт *(Сәйдәгә кулындагы әйберләрне биреп).* Малай сагынга-а-ан... *(Ике кулын Фарис шикелле суза.)*

Сәйдә. Җарар инде, атасы...

Нурмөхәммәт янә лапас тарафына китә.

Фарис. Безнең авыл ул санаторийларны бәреп ега, инәкәй. Кара инде бу һавасының сафлыгына! Сулаган саен сулыйсы килә. Үпкәләр киңәеп китте хәтта!

Сәйдә өй янындагы коймага беркетелгән юынгыч янына килеп баса. Фарис та аның янына килә.

Сәйдә. Мә, улым, башта чыраеңдагы җөннәрне кырып ташла. Алайса, бигрәкләр дә карт итеп күрсәтә үдеңне.

Фарис. Кичә генә кырынган идем инде үзе. Нишләтәсең, үлән кебек бәрә дә чыга, бәрә дә чыга...

Сәйдә. Суы җитәрлектер әле умальникның. Иртән генә яңартып өстәгәнием. *(Улының кырынганын сокланып күзәтә.)*

Фарис *(кырына-кырына).* Коймалар да череп беткән икән. Эткәй нәрсә карыйдыр...

Сәйдә. Атаң карт бит инде, улым... Бөтенесенә дә берүде. Бер генә дә өлгереп җитәлмай.

Фарис. Әткәй өлгермәсә, председатель бардыр бит колхозда. Ул ни карый. Гомер буе колхозга бил бөккән хезмәт ветераннарын карарга тиештер бит инде ул.

Сәйдә. Булыша инде ул, улым,булыша. Хәл кадәри ярдәм итә үде. Бик әйбәт персидәтел ул, безднең Гадинур.

Фарис. Бер дә әйбәтлеген күрмим Гадинурыңның. Коймалар черек. Лапас җимерелергә тора. Өйнең нигезе тәмам беткән. Капка шыгырдый. Район башлыгы булсам, мондый председательләрнең иманнарын укытып эшләтер идем мин. Бәхетләре — мин район хуҗасы түгел. *(Кырынып бетерә, пошкыра-пошкыра юына башлый.)* Менә мин саф һава директоры булып алты гына ел эшләдем. Бөтен җирдә порядок иде. Кул астындагылар дер калтырап тордылар.

Нурмөхәммәт, лапаска сөялеп, Фарисның сүзләрен тыңлап тора.

Сәйдә. Ул кадәрле усал булырга да җарамай, улым. Кешеләрнең дә төрлесе бар. Бер-бер хәл кылып куймагайлары үдеңә.

Фарис *(тастымал белән битен сөртә-сөртә)*. Кылырлар иде дә — куллары кыска. Бөтен Казан начальствосы минем таныш. Хәзер танышларсыз булмый, инәкәй. Мин сиңа — син миңа. Тормыш принцибы!

Нурмөхәммәт боларга таба килә.

Нурмөхәммәт *(яннарыннан үтеп барышлый)*. Коры куык! Кешене ышандырам дип уйлыйдыр... Ходай акыл бирмәсә, бирми икән кешегә... *(Кулын селкеп өйгә кереп китә.)*

Пәрдә

## ИКЕНЧЕ КӨН

Беренче пәрдәдәге күренеш. Ара-тирә кош сайраганы, эт өргәне, чалгы тавышлары ишетелеп ала. Болдырга күлмәкчән генә Фарис чыгып баса. Рәхәтләнеп бер киерелә.

Фарис. Сәламлим сине, кояш! Син дә мине сәламлә!

Фарис, болдырдан төшеп, юынгычка таба бара. Кинәт, дуңгыз мыркылдаганга охшаш тавыш ишетеп, сагаеп туктый.

Фарис *(тирә-юньгә, аеруча лапаска таба карап)*. Әл-

лә... инәкәйләрнең чучкалары бар инде?! Ау-у! Мырыйк-мырыйк! Сез кайда-ау?

Мыркылдаган тавыш катырак яңгырап ала. Фарисның күзе коега төшә. Коедан бер пар итек күренеп тора. Итекләр икесе тиң селкенеп куя.

Фарис *(бераз гына шүрләп)*. Нич-чего себе! *(Тавыш-фәлән чыгармаска тырышып, сак кына якынлаша.)* Ниччего себе!

Ниһаять, ул коега күз салырга батырчылык итә — коега иелеп карый.

Фарис *(гаҗәпләнүдән)*. Менә сиңа мә! Мирзәкәй абый, син түгелме соң бу? Нишләп ятасың безнең кое чүплегендә?

Кое эченнән Мирзәки тавышы ишетелә.

Мирзәки тавышы. Кем син? Мөнкирме, әллә Нөнкирме? Кая миңа тиешле хур кыздлары? Атвичай!

Фарис *(ике итекне, кысып кочаклаган килеш, үзенә таба тарта)*. Чык әле син башта, Мирзәкәй абый. Чык әле. Нишләп ятасың монда? Бәхетең бар икән. Ярый әле эткәйләр коены чүп белән тутырганнар.

Мирзәки тавышы. Алла, идрит-кудрит. Аякларны тартып өдәсең бит! Фәрештә дигәч тә... өстеңнән жалутса итәм хәдер...

Фарис. Нинди фәрештә булыйм мин сиңа. Саташма, Мирзәкәй абый. Тапкансың дүртпочмаклы гостиница!

Мирзәки тавышы. Тартма, дим, аякларны! Атың коргыры! Кәҗүнни аяклар бар дип беләсең мәллә?

Фарис *(Мирзәкинең аякларын ычкындыра)*. Алайса, үзең чык!

Кое эченнән мышкылдаган, мыгырдаган тавышлар ишетелеп тора. Менә берзаман чәчләре төрле чүп-чар белән чуалып-чорналып беткән Мирзәки башы күренә.

Мирзәки. Бәрәч, теге дөнья түгелмени бу? *(Фарисны күреп.)* Апай, әллә синме бу?

Фарис. Мин идем шул, Мирзәкәй абый, әгәр ачуланмасаң...

Мирзәки *(башын ике кулы белән дә тотып карый-карый)*. Баш минекенә охшаган... Димәк, баш исән! Кипкесе кая киткән инде тагы? Син күрмәдеңме, апай?

Фарис. Шундадыр инде, Мирзәкәй абый. Аяк астыңа иелеп кара.

Мирзәкәйнең башы югала.

М и р з ә к и   т а в ы ш ы *(шатлыклы)*. Таптым! Аяк белән басканмын икән!.. *(Бөгәрләнгән кепкасын баш очына элеп Мирзәки күренә.)* Җугалтканмындыр дип котым очты. Өр-яңа кипке бит бу, апай. Дастуй чорында җүн генә бәягә алган ием. Җугалтсам, катын бетерәдерие. Туксанга да җитмәенчә, кабергә тыгадырые, валлаһи! Бәхет бар икән... кая, чыгар инде бу базддан, апай.

Фарис аңа коедан чыгарга булыша.

Ф а р и с. Нишләп төштең син бу коега, Мирзәкәй абый?

М и р з ә к и. Менә мин нәкъ шуны синнән сорармын дигәнием. Өйгә кайтканны хәтерлим, сезнең коега ничек эләккәнне хәтерләмим. Әле җарый, бәхеттән коеның суы булмаган. Тәки эчеп бетерергә туры килгән булырые. Рәхмәт Бәләкәй абдыйга! Чүп тутырып дөрес эшләгән...

Кое бурасына сөялеп, җиргә утыра.

Ф а р и с. Кичә, алайса, каты җилпегәнсең син, Мирзәкәй абый. Безнең коега төшеп, иңен-буен үлчәрлек хәлгә килерлек булгач. Әткәй-мазар кушмагандыр бит?

М и р з ә к и. Нәрсәне, апай?

Ф а р и с *(көлеп)*. Мин әйтәм, әллә әткәй сиңа яңа кое бурасы эшләргә заказ бирдеме, дим? Синең турыда китап язарга була.

М и р з ә к и. Апай, көлмә абдаң тиешле кешедән. Алай килешмәй. Син лутчы ядучы булуың турында сүлә, апай. Ату кичә әртислегең турында сүләдең, ядучылык турысында сүләмәдең... Үдең бит әйттең, ядучылыкка укыдым, дип әйтеп әйттең...

Ф а р и с. Аның нәрсәсен сөйлисең инде, язучы тек язучы.

М и р з ә к и. Син сүлә, сүлә... Ух, баш чатный... Синдә җуктыр бит берәр нәмә? Әй... чумаданда калды, дидең бит әле... *(Кесәләрен капшаштыра.)* Стуй! *(Авызы ерыла.)* Ходаның хикмәте, монда нидер бар. *(Пинжәгенең түш кесәсеннән бер чәки тартып чыгара.)* Менә! Бирәм дигән колына — чыгарып куяр юлына. Мин бит моны утын куышына яшергәнием. Менә өйгә кайтып сорап та торасы булмады. *(Шешә бөкесен теше белән ача.)* Кара син аны, ә! Кичә дур шешәнең яртысын моңа күчергәнием, иртәгә баш төдәтергә кирәк булыр әле, дип. Менә кирәге дә чыкты. *(Фариска.)* Җилписеңме? Авыдыннан гына инде, иптәш гаспадин.

Ф а р и с *(ике кулын да алга сузып)*. Юк, юк, Мирзәкәй абый, күрәсе дә килми. Әткәйләр алдында да уңайсыз.

М и р з ә к и. Маладис, апай! Дөрес эшлисең. Миңа күб-

рәк кала. *(Шешә авызыннан гына аракы чөмерә.)* Ух! Әйбәт китте. *(Кул аркасын исни.)* Хәдер сүлә инде, апай. *(Шешәсен кесәсенә кире тыгып куя.)* Җә, безнең Роберт Миңнуллин нишләп җата анда?

Ф а р и с. Ята инде. Кайчагында йөри дә.

М и р з ә к и. Йөридер, йөридер... Безнең Актаныш раюнына гел кайтып җөри ул. Җадамы суң поюмаларын?

Ф а р и с. Яза, яза, нишләп язмасын — мин язып биргәч.

М и р з ә к и. Әллә Роберт Миңнуллинга да син җадып бирәсеңме, апай?

Ф а р и с. Кәнишне! Аңа да, бүтәннәргә дә.

М и р з ә к и *(чын күңелдән сокланып)*. Кит аннан, апай? Синдә дә шундый җаду-сыду осталыгы бармыни?

Ф а р и с. Кәнишне!

М и р з ә к и. Менә бит, ә! Безнең авылдан да җадучы чыгар икән. Рәхмәт, апай! Бөтен ауыл исеменнән рәхмәт сиңа, апай! Ниме суң, җадучы халкы нитәме? *(Муенына чиртеп ала.)* Безнең күек әзд-мәзд эчкәләйме?

Ф а р и с. Эчәләр. Барысын да мин өйрәттем.

М и р з ә к и. Эчкәч, җадып булмыйдыр бит ул, апай.

Ф а р и с. Әйттем бит инде, алар өчен үзем язып бирәм, дип. Әле менә Габдулла Тукай өчен язып ятам.

М и р з ә к и. Бәй, Габдулла Тукай күптән үлгән түгелме суң ул? Әллә монысы малаемы?

Ф а р и с. Юк. Бусы — икенче Тукай. Яшь әле ул. Син аны белмисең.

М и р з ә к и. Шулай дисәң генә, апай. Кая, тагын беразд манчыйм әле. *(Кесәсеннән шешәне чыгарып авызына коя.)*

Ф а р и с. Кызың чибәр синең, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и *(шешәне кире кесәсенә тыга)*. Хе-хе-хе... Әллә күздең төштеме минем кыздга? *(Шаяртып бармак яный.)* Кара аны, хи-хи-хи!

Ф а р и с. Юк инде, Мирзәкәй абый, син нәрсә? Мине кем дип уйлыйсың. Чибәр булганга күрә генә әйтүем.

М и р з ә к и. Кыдым чибәр анысы. Сүз дә юк. Чибә-әәр! Бөтен ауылга бер кызд инде, апай. Син андыйны бөтен Каданны айкап чыксаң да табалмайсың.

Ф а р и с. Дөрес сүзгә — җавап юк. Казанда гына түгел, бөтен Татарстанда юк синең кыз шикелле кызлар. Мин моны дөньяны аркылы-буйлы иңләгән кеше буларак әйтәм.

М и р з ә к и. Син, апай, салпы җакка салам кыстырмайча гына сүлә. Мин кыздның нинди икәнен үдем дә беләм. Миравай кызд! Ә син, апай, ни-ни-ни! Пунял?

Ф а р и с. Пунял, Мирзәкәй абый.

М и р з ә к и. Вот так-ты!

Шул вакыт капкадан С ә й д ә килеп керә.

Ф а р и с. Инәкәй, син кайда йөрисең?

С ә й д ә. Тордыңмы, улым? Мин, улым, казларны су буена куып кайтып киләм әле, бер оңгайдан үдебезд печән чапкан җиргә дә сугылдым.

Ф а р и с. Әткәй кайда?

С ә й д ә. Атаң шунда, печән чапкан җирдә. Хәдер кайтам, калган җирне чабып бетерәм дә, диде.

Ф а р и с. Нишлисез инде сез? Үзем чабып бетергән булыр идем инде.

М и р з ә к и. Саумы, Сәйдәттәй?

С ә й д ә. Аллага шөкер, Мирзәкәй күрше, үзең ни хәлләрдә?

М и р з ә к и. Кесә — сайский, кәеф — байский, Сәйдәттәй.

С ә й д ә. Улым, хәдер самаур җаңартам. Чәй эчәрсең.

Ф а р и с. Ярар, инәкәй.

С ә й д ә. Мирзәки күрше, син дә керерсең.

М и р з ә к и. Рәхмәт, Сәйдәттәй. Мин бүген эчкәнием инде, ике җомры. *(Фариска карап күз кыса.)*

Сәйдә өйгә кереп китә, капкадан С ө м б е л керә.

С ө м б е л. Әткәй, син тагын мондамыни? *(Фариска кыюсыз гына.)* Исәнмесез, Фарис абый.

Ф а р и с. Ис... Исәнме, Сөмбел!

М и р з ә к и. Мин, кыдым, чүмәләләрне саклап чыктым. Кешеләр бик җавыздланды бит хәдер. Печәнне урлаулары бар. Менә әле шуннан кайтышлый, Фарис абыеңның хәлен белеп чыгаем дип кергәнием.

С ө м б е л. Әткәй, хәдер үк өйгә кайт. Әнкәй борчылып ята анда. Төне буе җокламады. Әйтеп тә китмәгәнсең...

М и р з ә к и *(кинаяләп)*. Борчыладыр инде, әнкәң, бии-ик борчыладыр... Кара кайгыларга баткандыр... ике җатып бер төшенә дә кермәгәнмендер әле... Ир кадерен беләмени ул анаң... *(Коега карап ала.)* Җаткан буласың анда печән саклап. Керфеккә керфек тә какмаенча.

С ө м б е л. Әткәй! Инде тагын эчкәнсең бит. Бар, тидрәк өйгә кайт. Минем пучтыга барасым бар. Актаныштан гәҗит китергәннәрдер инде.

М и р з ә к и. Кыдым! Грам да эчмәдем. Кичәгенеке бетмәй интектерә.

Сөмбел. Әһе! Белмәйләр ди монда синең эчкәнеңне, эчмәгәнеңне! Бар, кайт тидрәк.

Мирзәки. Фарис апай, әйт әле шуңа, эчмәдем бит, әйеме?

Фарис. Юк, юк, Сөмбел, тамчы да эчмәде. Башка җирдә салган булса гына инде...

Мирзәки. Нәмәдәй башка җир, апай? Әдерләп куйганнар ди анда, печән чүмәләсе төбенә... Аракы түгел, су да юк анда.

Сөмбел. Син, әткәй, Фарис абыйны алдый алсаң да, мине алдый алмассың...

Мирзәки. Бигрәкләр дә каты бәгырьле инде син, кыдым. Бу хәтле анаң сыңары булырсың икән. Җарар, хәдер кайтам. Сүләшеп кенә бетерәек тә.

Сөмбел. Кара аны, бүтән эчмә! Ишеттеңме, әткәй?

Мирзәки. Ишеттем, кыдым, ишеттем. Әрекмән Гаптери күек саңгырау түгел.

Сөмбел. Ишетсәң шул: мин пучтыга киттем.

Мирзәки. Бар, бар, кыдым. Әйбәт кенә эшлә. Гәҗит-мәҗитләреңне җугалта күрмә!

Сөмбел Фариска күз сирпегәндәй карап ала да капкага юнәлә.

Фарис. Сау булып тор, Сөмбел, әлегә.

Мирзәки *(Фариска текәлеп карап)*. Әлегә-мәлегә, дип торма, апай. Әйтүем шушы, ни-ни-ни! *(Бармак яный.)* Күрше Бәләкәй абдыйның малае дип тормам.

Сәйдә болдыр баскычына чыгып баса.

Сәйдә. Улым, чәй эчәргә кер! Мирдәкәй абыеңа да әйт.

Фарис. Ярар, инәкәй. Хәзер керәбез.

Сәйдә кире өйгә кереп китә.

Мирзәки. Мин, апай, кереп тормам. *(Түш кесәсенә суккалап.)* Мин үдемнең чәйне эчтем инде. Рәхмәт дурлап әйтүеңә. Чыгаем мин. Ишеттең бит әнә... *(Капкага таба ишарәли.)* Түткәң анда ферма үгеде күек дулап җатадыр. Кемне сөдәргә белмәенчә... Какырас мине көтә инде ул. Әле җарай мин бар. Мин дә булмасам, кемне сөдәрие микән түткәң?

Капкадан иңсәсенә тырма салган Нурмөхәммәт керә.

М и р з ә к и *(урыныннан торып, чалбарын каккалый)*. Сау гынамы, Нурмөхәммәт абдый?

Н у р м ө х ә м м ә т. Нихәл, күрше? *(Тырмасын куярга дип, «уфалла» арбасына таба атлый.)*

Фарис, этисенең үзенә бер сүз дә әйтмәгәнлегеннән кыенсынып, үзен кая куярга белмичә, бер урында таптанып тора.

М и р з ә к и. Ару гына, Нурмый абдый. Бүген көн әйбәт күренә. Печәнне чүмәләләп тормайсыңдыр инде. Пакуста килеш кенә җыеп апкайтасыңдыр?

Н у р м ө х ә м м ә т *(өйгә таба атлый)*. Шулай итмәенчә булмас.

М и р з ә к и. Әле менә мин дә үдемнең чүмәләләрне саклап кайтып киләдерием.

Н у р м ө х ә м м ә т *(өйгә кереп китешли борыла да коега ишарәли)*. Безднең кое төбендә синең чүмәләләрмени ул? *(Кереп китә.)*

Фарис эче катып сыгылып төшә.

Ф а р и с. Уф... Үләм! Ну әйтте эткәй!

М и р з ә к и. Вәйт шайтан карты. Вәйт җомыкый, диген син аны! Коеда җоклаганны белгән бит бу, апай. Сәйдәттәй дә күргәндер инде. Оят, апай. Валлаhи, оят. Пинсәдәге башым белән кеше коесында җоклап җөр инде. Җугайсә, җоклаем, дисәң, үдебеднең бодау абдары да бар бит. Вәйт аракы тәре! Тәки Фатыйхларның чучкасына әйләндергән бит. Эчмә, апай! Җүнлегә илтә торган нәмә түгел бу. Шул, ара-тирә бәйрәм-сәйрәмнәрдә генә капкаласаң җарый инде... Вобшыты.

Ф а р и с. Эчмәскә иде шул, Мирзәкәй абый, вообще эчмәскә иде.

М и р з ә к и. Дөрес уйлайсың, апай... Синең урында булсам, мин дә шулай уйларыем. Менә әле...

Мирзәкинең сүзе шунда өзелә. Капкадан зур букчасын күтәргән Ч е г ә н х а т ы н ы дулый-дулый керә. Фарис нигәдер сагая.

Ч е г ә н х а т ы н ы *(усал тавыш белән)*. Әhә, икесе дә монда икән! Мине карак дип хур итеп җибәрдегез. Ә үзегез? Үзегез кем? *(Фариска.)* Менә, мәсәлән, син, чибәр егет? Син кем? Син үзең карак түгелмени? Гадальщик несчастный! *(Ачу белән букчасын җиргә куя.)*

М и р з ә к и. Нәмә сүләй бу тел тәгермәне, апай?

Ф а р и с. Белмим бит, Мирзәкәй абый. Үзем дә аңламыйча торам.

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Кара, кара! Аңламыйм, дип торган була. Күзен дә йоммый, шулер!

М и р з ә к и. Шулер нәмә дигән сүзд ул, апай?

Фарис, «белмим» дигәнне аңлатып, җилкәсен сикертә.

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Аңгырага салынма, абый кеше! Шушы яшеңә җитеп шулерның шома карак икәнен дә белмәскә син...

М и р з ә к и. Нәмә, бурның кытыршысы да буламыни?

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Телең белән ботка болгатып торма. Өлкән кеше дип тормам. Борыныңнан сөйрәп үзебезнекеләр янына алып барырмын — ник туганыңа үкенерсең. Давай, бирегез яхшы чакта!

Фарис дәшми.

М и р з ә к и. Син берәр нәмә пунялмы, юкмы, апай? Нәмә сорый ул безддән?

Ф а р и с. Акча сорыйдыр. Чегән хатынына тагын нәрсә кирәк инде... Акча кирәк!

М и р з ә к и. Һы! Акча татарга да кирәк ул! *(Чегән хатынына.)* Әллә бездгә акча биреп торганыеңмы? Нәмә күздләреңне алартып, тилебәрән орлыгы ашаган күек басып торасың.

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Сез нәрсә? Сез икәүләп миннән көләргә уйлыйсызмы? Ну-ка, бирегез хәзер үк беләзекне!

Ишегалдындагы шау-шуны ишетеп, болдырга С ә й д ә чыгып баса да тамашаны читтән генә күзәтеп тора. Ишегалдындагылар аны күрмиләр.

М и р з ә к и. Беләдек? Нәмәдәй беләдек ул тагын? Син, нәмә, чүпрәк магадины, олы абдыеңа җала җагасың. Не смий хезмәт витиранын мыскылларга! *(Фариска.)* Син нәмә, апай, бер сүзд дә дәшмәй торасың. Бу катыннан куркып астыңа пес итмәгәнсеңдер бит? Әйт сүздеңне! Җала җакмасын кешегә...

Ф а р и с *(тирән итеп сулыш ала да башта Мирзәкигә, аннан чегән хатынына карый)*. Әй, син, табор кәбестәсе, чыгып ычкын моннан! Хатын-кыз дип тормам...

Ч е г ә н   х а т ы н ы. Куркытма, тәти егет! Курка торган халык түгел без! Давай, боргаланмый-сыргаланмый беләзекне бир дә мин китәм. Авылыгызга бүтән аяк та атламыйм.

М и р з ә к и. Вәт сагызд! Вәт стиморул! Нәмәдәй беләдек?

Сәйдә әкрен генә кулындагы беләзеген сала.

**Фарис.** Ни сөйлисең син, шантажистка! Ни пычагыма миңа синең беләзегең?

Сәйдә болар тарафына талпынып куя. Бер кулы белән болдыр баганасын кочаклый.

**Мирзәки.** Бу катын бер-бер этлек уйлап килгән. Учаскавайны чакырмай булмас! Какрас минем өйдә утырадырые. *(Юри китмәкче була.)*

**Сәйдә.** Улым!

Өчесе дә Сәйдәгә борылып карый.

**Фарис.** Инәкәй!

**Сәйдә.** Мин... барысын да... *(беләзекле кулы белән йөрәген тота)* ишетеп тордым... Улы-ым!

**Фарис** *(әнисенә ташлана)*. Инәкәй!

**Сәйдә** *(сыкранып)*. Мә... улым... *(Беләзекне суза.)* Кайтарып бир хуҗасына...

Фарис бермәл беләзекне алырга да, алмаска да белмичә басып тора.

**Фарис** *(ачыргаланып)*. Инәкәй! Мин сиңа унны алып бирәчәкмен! Инәкәй! Йөзне алып бирәм!..

**Сәйдә.** Кирәкми... улы-ым... Мә... бир хуҗасына...

**Фарис** *(күз яшьләренә тыгылып)*. Инәкәй! Кичералсаң, кичер мине...

Фарис, чарасызлыктан гаҗиз булып, калтыранган кулы белән беләзекне ала. Акрын гына борыла да Чегән хатыны янына килә.

**Чегән хатыны** *(Фарис биргән беләзекне алып)*. Йөрәгең юктыр синең... *(Беләзеген кия. Китмәкче була.)*

**Фарис** *(тоныкланып калган тавыш белән)*. Кичә бу абзыйның кесәсеннән алган иллелекне кире кайтар.

Чегән хатыны күлмәге кесәсеннән акча ала да, Мирзәкинең аяк астына ыргытып, бер сүз дә әйтмичә капкага юнәлә.

**Мирзәки.** И апай, апай... Шушы кәгаздгә калган кешемени мин...

Мирзәки акчага басып бермәл тын тора да, «Беткәнсең икән, апай» дигән ишарә ясагандай кул селтәп, аксый-аксый чыгып китә.

Иңсәсенә хат ташучы сумкасы элгән **Сөмбел** керә. Фарис аны күрми. Сөмбелнең йөзе нигәдер борчулы.

Сөмбел. Фарис абый!

Фарис Сөмбелнең үзенә дәшкәнен ишетми.

Сөмбел. Фарис абый, дим!

Фарис ишетми.

Сөмбел. Фарис абый! Сездгә... телеграмма...

Фарис *(сискәнеп)*. Ә? *(Сөмбелне күреп ала.)* Син дәштең мәллә, Сөмбел? *(Елмаерга итә, елмаюы ясалма чыга.)*

Сөмбел. Сездгә телеграмма барые... тик ул...

Телеграмма кәгазен Фариска суза. Фарис алмый.

Фарис. Укы, Сөмбел.

Сөмбел. Фарис абый... Ачуланма, мин укый алмыйм моны...

Фарис. Укы, әйдә, укы. Мин аның эчтәлеген болай да беләм.

Сөмбел. Ничек? Каян беләсең? Монда бит...

Фарис. Беләм инде, Сөмбел. «Казанга срочно кайт» диелгән анда...

Сөмбел. Фарис абый! Бу... бу...бөтенләй башка телеграмма... Сезднең... синең... *(Кинәт үксеп елый башлый.)*

Фарис. Нәрсә булды, Сөмбел? Нигә елыйсың әле син?

Сөмбел *(Фарисның күкрәгенә каплана)*. Дөфәр... Дөфәр абый... үлгән!

Фарис. Ә? *(Сөмбел кулыннан телеграмманы тартып ала.)* Энекәш?! Ышанмыйм! *(Телеграмманы укый.)*

Җан тетрәткеч көй. Микрофон аша телеграммадагы текст яңгырый. Микрофондагы тавыш. «Ваш сын Зуфар Нурмухамметович Бадримуллин героически погиб при исполнении интернационального долга...»

Фарис *(ачыргаланып)*. Энекәш!

Фарис көтелмәгән хәбәрдән сыгылып төшә. Җиргә тезләнә. Башын җиргә бәрә-бәрә йодрыклары белән җирне төя.

Фарис. Энекәш! Зөфәр! *(Елый.)* Эне-кә-ә-әш...

Сөмбел, күз яшьләрен сөртеп, Фарис янына чүгәли. Куллары белән Фариска орынырга да, орынмаска да белмичә тора.

Сөмбел. Фарис абый, нык бул. *(Фарисның җилкәсенә кулын сак кына куя.)* Нык бул, Фарис абый...

**Ф а р и с.** Сөмбел!.. *(Сөмбелне кочаклап, башын Сөмбел җилкәсенә куеп үкси.)* Энекә-ә-әш...

**С ө м б е л.** Фарис абый... Сәйдәттәйләр барлыгын онытма, нык бул!

Сөмбел, урыныннан кузгалып, Фарисны торгызырга азаплана. Кинәт дөнья караңгылана. Тетрәндергеч көй яңгырый. Кисәк кабынган ут көлтәсе болдырда багананы кочаклаган Сәйдәне яктырта.

**С ә й д ә.** Улыкаем! Дөфәркәем!.. Соңгы өметкәем... *(Хәлсезләнеп сыгылып төшә.)*

Дөнья янә караңгылана. Ут көлтәсе бу юлы болдырда бөкрәеп утырган Нурмөхәммәтне яктырта.

**Н у р м ө х ә м м ә т** *(салмак кына сөйли)*. Бу җирдә бөтен кеше өмет белән яши. Минем дә өметләрем барые. Бу җиргә килгән кеше, һич җугы, бер агач утыртырга тиеш, диләр. Мин мең агач утырткanмындыр. Шуларның икесе бигрәкләр дә кадерле агачые... Ике агач... Ике имән!

Берсе тамырын тирән җәя алмады, яфракларын яралмады... Бөтен өметем икенчесендә иде. Анысын да менә җәшен сукты.

Пауза.

Корыган агач басты дөнҗаны. Җилләтәсе, җилләндерәсе килә. Инде җегәр җук, җегәр бетте...

Караңгылык эченнән Фарисның үзәк өзгеч тавышы ишетелә.

**Ф а р и с.** Әткәй!

Ут сүнә. Хәсрәт-сагышлы музыка.

П ә р д ә

*1995*



**II бүлек**

# Әп-че-хи!-хи-хи...



# Кызыл бәдрәф

*(Детектив)*

Карап торышка алар тигез ике рәт булып, бер-берсенә терәлеп үк диярлек басып торган хезмәттәшләреннән берни белән дә аерылмыйлар иде. Икесенең дә башында — саз бакасы төсендәге каска, өсләрендә — алай-болай яңгыр-мазар яуса дип кигән плащ-палатка, кулларында — гайрәтле айгырның нәрсәсендер хәтерләткән резин тәпәч...

Икесе дә, үзләренең каршында кызып-кызып нидер сөйләшкән кешеләргә, дәшми-тынмый гына колак салгалап, әлеге кешеләр тирәсендә әрле-бирле йөренеп торган адәмнәргә, яннарына төркем-төркем халык җыйнап, шуларга тавышкөчәйткеч аша ара-тирә «Яшәсен!» «Долой!» дия-дия дәртле-ялкынлы нотыклар тоткан сүзсөйләрләргә битараф карашларын ташлап, ваемсыз гына сагыз чәйниләр...

Әйе, аларның һәм төгәл исәбен үз хуҗаларыннан башка бер Ходай үзе генә белгән хезмәттәшләренең бүген янә эш урыны — мәйдан. Дөрес, кайберәүләрдән аермалы буларак, аларның икесенең дә урыннары иң кәттә, иң тыныч, ышык җиргә — битараф карашлы һәйкәл — юлбашчының арт ягына туры килде.

Алар тәме беткән сагызны байтактан бирле авызларында әвәлиләр инде. Бер урында каккан казык кебек басып тора-тора аяклары арыды. Тик бернишләр хәл юк, кем әйтмешли, служба тек служба!

Менә бервакыт түбәсенә ала-кола әләм беркетелгән мәһабәт бина артыннан кара-кучкыл болыт көтүе калкып чыкты. Бер-берсе өстенә тәртипсез рәвештә ташлаган кирза итекләрне хәтерләтеп калыккан әлеге көтү иң әүвәл әләм очына килеп сөрлекте, кузгала алмыйча торды, бераздан, артыннан куалаган җил куәтенә чыдый алмыйча, ары юл алды.

Ул да булмады, соңгы вакытларда «Спартак» ботинкасы, итек, «Адидас» кроссовкасы, чит ил туфлие, башмак, сабыйлар сандалие, әбиләр кәлүше, Арча читеге ише төрле калыптагы чутсыз аяк киемнәренең табан асла-

рын комсызланып ашаган мәйдан асфальтына яңгыр тамчылары төшкәли башлады...

Ару гына сибәли башлаган яңгыр нәрсәнедер кинәт исенә төшерде булса кирәк, икәүнең берсе — иптәшеннән бер башка тәбәнәгрәге телгә килде:

— Карале, Мышкин, минем ни бит... Пес итәсе килә бит. Нишләргә икән?

Мышкин дигәне холык-фигыле белән шаян кеше иде.

— Шушында гына җиффәр. Беркем дә сизми. Синең бәхеткә әнә яңгыр ява,— диде ул, йөзе агара башлаган иптәшенә карап, һәм күңелле генә хихылдап алды.

— Сиңа көлке,— диде Тәбәнәк буй.

Мышкин-Озын буй киңәш бирүен дәвам итте:

— Син болай ит... Бер кулың белән тәпәчеңне... кыххы-хы-хы... тәпәчеңне... итегеңә суккандай ит. Икенчесе белән плащ-палаткаңны рәтләгән бул... Кых-кых-хыхы... Конспирация!

— Шаяртмале,— диде Тәбәнәк буй.— Сиңа көләргә генә булсын. Монда эш шаяртудан узып маташа. Түзәр әмәл юк. Килеп терәлде бит, заразы...

— Сиңа киңәш бирә-бирә, үземнеке дә чыгымлый башлады әле,— диде Озын буй.— Йогышлы булды бугай...

Шул вакыт болардан бер ун адым чамасы гына ераклыкта басып торучы бер ыспай егет:

— Хәзер үк җимерергә кирәк бу һәйкәлне! — дип кычкырды.

Аның сүзен куәтләүче дә, сүзенә каршы төшүче дә булмады.

Ыспай егет тирә-ягына каранып алды да янә:

— Тормасын ачу китереп! — дип кычкырды.

Ыспай егетнең бу сүзенә дә игътибар итүче булмады.

— Ачуың килсә, ач та тешлә! — дип, үзалдына сөйләнде бер мизгелгә генә кече йомышы хакында оныткан Тәбәнәк буй.— Ничу һәйкәл җимерергә!..

— Т-с-с-с! — диде аңа Озын буй.— Безнең кеше ул...

— Ничек безнең кеше?

Озын буй аңа пышылдап кына:

— Тегеннән ул. Минем аны еш күргәләгәнем бар. Монда халыкны кыздырырга килгән. Махсус задание белән... Аңладыңмы?

— Ә-ә-ә...— дигән булды Тәбәнәк буй, йөзен тагын да катырак чытты.— Уф... үлә-әм... Шартлыйм...

Озын буйның да үз хәле хәл була башлаган иде инде. Ул нигәдер як-ягына каранып алды. Кинәт аның чырае балкып китте.

— Түз бераз. Әнә безнең янга таба подполковник килә! — диде ул, нигәдер тагын да сөенә төшеп.

Кулына тавышкөчәйткеч тоткан җирән чәчле, сипкелле подполковник бу икәүнең янәшәсенә якынлашты.

— Иптәш подполковник! Иптәш подполковник! Рөхсәт итегез.

Подполковник туктады да тавыш хуҗасына борылды:

— Нәрсә, сержант?

— Иптәш подполковник, кече йомыш белән барып киләсе бар иде... Рөхсәт итегез...

Подполковникның болай да караңгы чырае тагын да караңгылана төште. Кулындагы тавышкөчәйткечне икенчесенә күчерде.

—Минем дә... Минем дә... Иптәш подполковник... Шундыйрак йомыш иде,— диде түземлеге соңгы чиккәчә җиткән Тәбәнәк буй.

Подполковник фуражкасыннан чыгып-күренеп торган юеш, пырдымсыз чәчләрен рәтләгәндәй итте. Аннары саргайган кабан тешләре арасыннан кәгазьгә төшереп булмый торган бер сүзне төкереп чыгарды да:

— Черт побери! — диде.

Тәбәнәк буй дерт итеп куйды. Үзе дә сизмәстән, тәпәчен тагын да катырак кысты. Шул ук вакытта ул уң бот тирәсе җылынуын тойды. Тойды һәм үзен зур күңелсезлектән тиз генә тыеп өлгерде.

— Тапкансыз вакыт. Барыгыз, биш минут сезгә! — диде подполковник.— Җәһәтрәк булыгыз!

Озын буй белән Тәбәнәк буй мәһабәт бина янәшәсендәге «Миру — мир» кибете артында урнашкан тишекмошыклы, черек такталы, кызыл гомум бәдрәфкә таба кызу-кызу юл тоттылар.

— Пес иткәч, кибеткә кереп берәр стакан сок эчәрбез,— диде Озын буй тешләрен кысып, йөзен чытып барган юлдашына.

— Тагын пес итәргәме? — диде Тәбәнәк буй һәм ничек тә барып җиткәнче түзәргә иде, дип уйлады...

Гомум бәдрәфтән иң әүвәл Озын буй атылып чыкты. Чыкты да, җиде-сигез адым чамасы читкәрәк китеп, чалбар сәдәпләрен каптыра-каптыра, еш-еш һава сулый башлады. «Тагын бераз торсам, тончыгып үлә идем»,— дип уйлады ул.

Шул вакыт кызыл буяуга буялган бер агач йорттан кыяфәте белән нәселле дуңгызга охшаган симез хатын чүп-чар белән тулган ике шакшы чиләк тотып чыкты да бәдрәфкә таба килә башлады. Озын буй, гадәт буенча,

аның күптән ялтыратылмаган самавырга охшаган шәрә, юан аякларына, шул аяклар лыштыр-лыштыр сөйрәгән ертык кәлүшләренә караш ташлады. Аннары аның әрсез күзләре хатынның түсе уңган күлмәге аша бүселгән күкрәкләрен җәһәт кенә ләззәтләнеп капшап алды: «Их, минем хатынның да шулай булса-а-а...»

Озын буй татлы хыялга бирелергә өлгермәде, кай арада чиләкләрен җиргә куеп, кай арада бәдрәф ишеген ачкан хатын чырылдап кычкырып җибәрде:

— Ниткән галәмәт бу? Күзеңә...— ошбу урында хатын Тәбәнәк буйны гына түгел, хәтта Озын буйны да сискәндерерлек бик каты бер сүз әйтте, —үскән мәллә? Хатынкызныкына кермәсәң... Үзе милисия, җитмәсә! Пыразит...

Тәбәнәк буй, юан хатын бәдрәф ишеген каерып ачкан вакытта, йомышын бетереп, чалбарының соңгы сәдәбен каптырып азаплана иде.

— Но-но, но...— диде ул юан хатынга, кулы белән тәпәчен тотып. «Авызыңны чамалап ач, тиешле урынга алып китәргә дә күп сорамабыз!» — дип тә әйтмәкче иде дә, хатынның хаклы булуын аңлап тыелып калды. Аңа бәдрәфтән юан хатынның апара кебек кабарган корсагына ышкыла-ышкыла чыгудан башка чара калмады...

Бәдрәфтәге юан хатын белән Тәбәнәк буйны «минем боларда катышым юк» дигән кыяфәт белән бер читтә күзәтеп торган Озын буйга янә көләргә җай чыкты.

— Бик озак тордың. Әллә теге гүзәл хатын белән... кых-кых-хы-хы... сөешеп алдыгыз инде... хы-хы-хы...— диде ул, Тәбәнәк буй үз янына килеп җитүгә.

— Дивана түгел бит мин,— диде Тәбәнәк буй, бәдрәф тарафына усал карашын ташлап.

— Ха-ха-ха-хых... Нәрсә, әллә диваналар гына бәдрәфтә... хы-хы-хы... сөешәме? — дип, үзенә бер тәм табып көлде Озын буй.

— Һәрбер сүзгә бәйләнмәле. Транзисторыңны икенче каналга күчер. Бусы туйдырды...

— Япунский транзисторыңны, диген... Ха-ха-ха, хихи-хык!..— Озын буй кисәк көлүдән туктады. Аның күз карашы үзләреннән илле метрлар чамасы ераклыктагы янтайган агач йортка төбәлгән иде. Дөресрәге, Озын буй шул йорттан чыгып, тирә-юньгә ялт-йолт каранып алган портфельле бер адәмне күзли иде.

Озын буйның кинәт көлүдән туктавын шәйләгән Тәбәнәк буй да, сәерсенеп, әлеге тарафка карады.

— Нәрсә бар? Ник катып калдың? — диде ул.

— Т-с-с! — диде Озын буй, иптәшенә карамыйча гына.— Күрәсеңме әнә теге кешене?

— Күрәм. Шуннан?

— Шикле күренә,— диде Озын буй. Ул, теге адәмнән күзен алмыйча гына, кара тәпәчен кармалап кулына кысты.— Каракка охшаган...

«Бәлки, берәр куркыныч җинаятьчедер дә әле»,— дип тиз генә уйлап алды ул. Уйлап алды да, үзендә пистолет булмауга уфтанып, авыр сулап куйды: «Нишләп шушы тәпәчләрне ата торган итеп эшләмиләрдер...»

Портфельле адәм плащ-палаткалы һәм каскалы ике милиционерның үзен күзәтүләрен искәреп алды булса кирәк, ул «аэродром» кепкасын батырып киде дә, мәче җитезлеге белән бер якка сикереп, юкка чыкты.

Һәрхәлдә, Озын буйга да, Тәбәнәк буйга да шулай тоелды.

— Артыннан калмаска! — дип кычкырды Озын буй һәм портфельле адәм юкка чыккан тарафка ыргылды.

— Ә подполковник? Ә юлбашчы һәйкәле? — дип, бер мизгел урынында исәнгерәп торды Тәбәнәк буй. Аннары, чукынып китсеннәр лә дигәндәй, кулын селтәде дә, тәпәчен тотып, Озын буй артыннан чапты...

Портфельле адәм, камыт аяклы булса да, шәп йөгерә иде. Хәер, аны күз уңыннан ычкындырмаска тырышып эзәрлекләгән Озын буйның йөгерүе дә оста йөгерешчеләрнекеннән бер дә кайтыш түгел.

«Каска белән плащ-палатка булмаса, мин бу каракны өч атлауда каптырасы кеше бит»,— дип уйлады Озын буй, мышкылдый-мышкылдый. Ул, йөгергән шәпкә, артына борылып карады: Тәбәнәк буй, бер кулына тәпәчен тотып, бер кулы белән каскасын күзләрен каплатмаска тырышып, үзен һичкайчан тоттырмаслык куян артыннан чапкан тук, ялкау эт шикелле чаба-кыймылдый иде.

Әйе, портфельле адәм шәп йөгерә...

Шулчак, Озын буйның нәкъ алдына диярлек, каяндыр гөл чүлмәге килеп төште дә чәлпәрәмә килде. Гөлнең ак сарык йоныннан җегерләнгән дәү йомгакны хәтерләтеп укмашкан тамырларына китереп басканын сизми дә калды Озын буй.

Сул яктагы йортның икенче катындагы ачык тәрәзәдән бер ир белән хатынның кычкырышкан тавышлары ишетелде:

— Алкаш несчастный!

— Себерке!

— Ишәк!

— Бирәсеңме-юкмы акча?

— Бирде ди, көтеп тор!

— Соңгы тапкыр сорыйм... Бир!

— Тот капчыгыңны!

— Акайтма күзләреңне!

— Өч! Үтерә-ә-әм!

Тәрәзәдән янә бер гөл чүлмәге очып чыкты. Бу юлы ул, Озын буйның артыннан калышмаска тырышып чапкан Тәбәнәк буйның каскасына төшеп, онга әйләнде. Каскасы булмаса, теге дөньяга зур тизлек белән китә язган Тәбәнәк буй, туктый алмыйча:

— Авызыгызны...— дип, аты-юлы белән сүгенде. Чабуыннан туктап, йөгергән чакта ачылган авызына тулган туфракны җиргә төкерде, иңсәсенә кунган гөл сабакларын ачу белән читкә атып бәрде...

Йортлар арасыннан атылып чыккан портфельле адәм тукталыштагы «илле алты»нчы автобусның ачык ишегеннән эчкә чумуга, автобус аны гына көтеп torгандай кузгалып та китте.

— Тукта! Тукта! — дип кычкырды Озын буй, автобус артыннан җан-фәрман чаба-чаба.

Теләсә кайда һәм теләсә кайчан туктарга гадәтләнмәгән автобус шоферы аны ишетмәде.

Озын буй, чабуының мәгънәсез эш икәнен аңлап алгач, туктады да, өтәләнеп, үзенә таба килгән таксига тәпәчен күтәрде.

— Тукта!

Буш такси яшел утын җемелдәтеп выжлап узып китте. «Утыртты ди! Бушка мент утыртып йөрергә, җүләр түгел бит мин! — дип уйлады таксист.— Әнә, таягыңа атланып чап! Йә каскаңа утырып оч!»

Таксист, күңелле генә елмаеп, иреннәренә затлы сигарет кыстырган вакытта, машиналар туктатырга азапланган Озын буй янына шабыр тиргә баткан Тәбәнәк буй килеп җитте. Аның кыяфәтенә карарлык түгел иде: гөл туфрагы, маңгай тире белән юешләнеп, Тәбәнәк буйның чыраен цивилизациясез утрауда яшәгән кабилә кешеләренең чыраена әйләндергән иде.

Башка чак булса, Озын буй, аның кыяфәтенә карап, җәелеп-җәелеп көләр иде. Бу юлы көлмәде...

Менә ул ерактан ыжгырып килгән яшел «Жигули»ның каршына тәпәчен күтәреп чыгып басты.

«Жигули»ның тормозлары шәп икән — ул, тәгәрмәчләрен сызгыртып, нәкъ Озын буй каршында туктады.

«Жигули»ның эче буш иде. Дөресрәге, шофердан кала кеше юк иде.

Озын буй машинаның алгы ишеген ачты да җәһәт кенә утыргычка чүмәште. Тәбәнәк буй арткы ишектән керә алмый азапланды. Кергәч, ишекне ябалмый ин-

текте. Ярый әле үзенә сәерсенеп караган шофер булышты...

— Алга!— диде Озын буй.— Әнә теге автобусны куып җитәргә кирәк!

— Тыңлыйм, командир! — диде машина хуҗасы.

«Жигули» кузгалып китте.

Шофер, маңгаеның уң ягы тирәсендәге көзгегә багып, арткы утыргычка утырган Тәбәнәк буйга янә сәерсенеп карап алды: плащ-палаткасының әллә ишеккә кысылган, әллә кадак-фәләнгә эләккән итәк очын тарткалап маташкан Тәбәнәк буйның чырае сабый балаларның гына түгел, өлкәннәрнең дә котын алырлык иде...

— Хәрбиләрме? — диде машина хуҗасы.

Озын буй: «Бу карак рецидивист булырга тиеш! Әгәр дә мин моны каптырсам, лейтенантны берсүзсез бирәчәкләр. Бәлки, капитан итәрләр. Ике бүлмәле фатир да бирсәләр... Туйдырды бу тулай торакта сөрсеп яту да...» — дип, татлы уйга бирелеп бара иде...

— Ә-ә-ә... безнең мөхтәрәм тәртип сакчыларыбыз икән! — диде машина хуҗасы, бернинди дә җавап ишетмәгәч.

— Тизрәк куала тачкаңны! — диде Озын буй, уйларыннан арынып бетмичә генә: «Капитан булсам, фатир бирсәләр...»

Тәбәнәк буй, плащ-палаткасының итәге ишеккә кысылуына тәмам инангач, тарткалаудан туктап, юлны күзәтергә кереште.

«Жигули» кинәт тормозларын сызгыртып туктады.

— Ник туктадың? Куала! — дип боерды Озын буй, машина хуҗасына усал караш ташлап. Бу мизгелдә ул, аны машинадан типкәләп төшереп, рульне үзе кулга алыр чиккә җиткән иде.

— Светофор, иптәш командир! Кызыл ут! — диде машина хуҗасы тыныч кына.

Чаттагы светофорда яшел ут кабынды.

— Хәрбиләр дигәннән...— диде машина хуҗасы, тизлекне арттыра төшеп,— ...бер мәзәк искә төште әле.

«Чукынып кит мәзәгең белән!» димәкче иде Озын буй, ләкин дәшмәүне кулайрак күрде.

Автобусны куып җитәргә күп ара калмаган иде инде.

Машина хуҗасы сүзен дәвам итте:

— Ике солдат сөйләшә икән. Иванов белән Сидоров. Иванов дигәне әйтә икән Сидоровка: «Минем командирдан да ахмак, минем командирдан да тинтәк юктыр дөньяда! Беркөнне өч сум акча тоттырды да төсле телевизор алып кайтырга кушты...» — ди икән. «Шуннан»,— ди

икән Сидоров дигәне. «Якшәмбе көнне телевизор сата торган кибетләр эшләми бит!» — дигән Иванов. Ха-ха-ха... Шәп бит, ә! Шуннан Сидоров дигәне әйтә икән: «Синең командир ул хәтле үк тинтәк түге-е-ел... Минә минем командирны тинтәк, дисәң дә ярый. Беркөнне миңа болай ди бу: «Сидоров, бар штабка, белеш, мин шунда микән, түгел микән? Бел дә тиз генә монда кил!» «Шуннан?» — дигән Иванов. «Соң,— дигән Сидоров,— үзенең янында телефон тора. Шуннан шылтыратып кына да белә ала бит инде ул үзенең кайда икәнен!» Ха-ха-ха...

Машина хуҗасы үз мәзәгеннән үзе рәхәтләнеп көлде. Тегеләр көлмәде. Бу вакытта «Жигули» тукталыштагы «илле алты»нчы автобусның артына килеп төртелә язган иде инде...

Озын буй ишекне ачты да тышка омтылды.

—Тукта! Ә акча? — диде машина хуҗасы. Озын буйның плащ-палаткасы итәгеннән эләктереп.

— Соңыннан,— диде аяклары белән җиргә баскан Озын буй.

— Соңыннан соң була ул! — диде машина хуҗасы.

Озын буй плащ-палатка итәген кинәт үзенә тартты. Итәк ычкынды.

— Менә моны күрәсеңме? — диде Озын буй һәм кулындагы тәпәчен машина хуҗасының борын төбендә уйнатып алды.

Озын буй белән машина хуҗасы матавыкланган арада, Тәбәнәк буй чыгып өлгергән иде...

Милиционерларның икесе тиң автобусның арткы ишегенә томырылдылар.

— Тәпәчле хәерчеләр! — дип кычкырып, йодрыгын селкеп калды алар артыннан машина хуҗасы...

Алар автобусның арткы ишегеннән эчкә узуга, портфельле адәм урта ишектән чыгып өлгергән иде инде.

Ишекләр ябылды. Автобус кузгалды.

— Әнә ул! — дип, автобус эчен яңгыратып кычкырды Тәбәнәк буй, тәрәзәгә тәпәче белән төртеп.

Аның тавышыннан битәр, кыяфәтеннән өркеп, автобустагылар читкәрәк елыштылар. Сыңар аягында көчхәл белән генә басып барган бер карт чукынып алды.

— Автобусны туктат! — дип шәрран ярып кычкырды Озын буй, тәрәзәдән күзен алмаган килеш.

Автобустагылар шауларга тотынды:

— Шофер, тукта!

— Туктат автобусны!

— Туктат!

Автобус кинәт туктады. Автобустагылар алга сөрлек-

теләр. Сыңар аяклы картның керпе баласы чаклы җәлпәк башы мышкылдап барган бер түтинең калку күкрәкләре арасына кереп чумды. Түти, җәлпәк башның хуҗасы сыңар аяклы карт икәнен белгәч, чәрелдәп кычкырып җибәрде: «Карт тәре! Ал чүмечеңне!»

Сыңар аяклы карт:

— Мин гаепле түгел, автобус бит! — дип акланып мыгырданды.

— Ызнайт низнаю! Ал чүмечеңне!

Бер-берсе өстенә сыланган кешеләр бердәм гөжләргә тотынды:

— Анаңны сатыйм!

— Нечкә җиргә төрттең бит, күзле бүкән!

— Ай-яй-яй! Аякны сыттылар...

— Төш, дим, өстән! Төш!

— Нишлисең, псих!

— Фу-у-у! Кайсыгызның эше?

— Җибәр, дивана! Минем сумка бит ул!

— Чыдап булмый!

— Пиззабразые! Вәйт! Пиззабразые!

Озын буй ертылган плащ-палаткасын өстерәп тышка егылды. Аның өстенә каскасы очлы иягенә төшеп төртелгән Тәбәнәк буй чыгып ауды.

Озын буй, ничек кирәк алай торып, титаклаган уңайга плащ-палаткасын рәтләштерә-рәтләштерә, тротуардан торып азапланган Тәбәнәк буйга кычкырды:

— Арттан калма!

Кузгалып киткән автобусның ачык тәрәзәсеннән баягы чәрелдек хатынның:

—Бер бандитны куалар болар. Бандит, ата бандит, ди. Автоматлы, ди. Төрмәдән качкан булган! — дигән тавышы ишетелде...

Портфельле адәм хәвеф сизгән куян шикелле чаба иде: әле уңга, әле сулга кереп югала...

Озын буйга каяндыр бер түгәрәк йөзле адәм килеп кушылды. Түгәрәк йөзле адәм, мыш-мыш йөгерә-йөгерә:

— Иптәш милиционер, ярдәм итегез! Үтерә! — диде.

— Кем үтерә? — диде Озын буй, йөгерүеннән туктамыйча гына.

— Петька! Аракы таптыра. Үтерәм, ди...

— Кемне? — диде Озын буй.

— Һәммәбезне дә! Ау мылтыгы бар аның. Шуның белән атып үтерәм, ди. Коммуналкадагы бөтен кешене бәдрәфкә кертеп бикләде. Минем хатын да шунда... Кемнең аракысы бар, шуны гына чыгара...

— Кем чыгара? Каян чыгара? — диде Озын буй.

— Петька! Юк ла инде... Петька түгел! Аракысы булган кешене Петька чыгара. Булмаса, атып үтерәм, ди... Минем хатынның да аракысы юк...

— Ә син нишләп хатының янында түгел?

— Минем аракы талоннарым бар. Шуларны Петькага күрсәттем дә, хәзер алып киләм, дидем... Дидем диюен... Ә кибеттә аракы юк...

— Мин нишли алам? — диде Озын буй.

— Аракы кирәк! Аракы табып бир, иптәш милиционер! Юкса Петька үтерә... Хатынны да... Хатын чурт с ним, мине үтерә-ә-ә...

— Мин аракы кибете түгел! — диде Озын буй һәм кызурак йөгерергә кереште.

Түгәрәк йөзле адәм артка калды. Ул, теркелди-теркелди, Тәбәнәк буйга эндәште:

— Иптәш... иптәш милиционер! Аракы кирәк! Петька... үтерә Петька!

— Пашшул! — диде Тәбәнәк буй.

Түгәрәк йөзле адәм, аяк астындагы ташка абынып, гөрселдәп җиргә ауды.

— Аракы... Петька... аракы... хатын...— дип пышылдады ул.

Портфельле адәмне куа-куа, Озын буй «Күбек» сыраханәсе янына килеп җитте. Җитте җитүен, ләкин абайламыйчарак калды: сыраханәдән чыгып килгән бер салмыш ир кинәт нәрсәгәдер абынды да чәче шома итеп кыркылган башы белән аның касыгына каты гына килеп бәрелде.

Озын буй, ык итеп, бер мәлгә өнсез калды. Ул арада әлеге пеләш ир артыннан чыгып килгән икенче сәрхуш сөрән салды:

— Ментлар! Наших бьют!

Китте мәшхәр, кузгалды орыш-җәнҗал: сыраханәдән ургылып чыккан сәрхушлар, танышны, таныш түгелне абайлап тормыйча, үзара әүмәкләшергә тотындылар. Сыңар күзле бер адәм сыралы бокалы белән берәүнең башына кундырды, кемдер: «Суялар!» — дип кычкырды... Күкрәгенә «Не забуду мать родную!» дип язылган бер җирән баш: «Мать твою!» — дип акырды да асфальттан күзлеген эзләп маташкан адәмнең артына алагаем авыр ботинкасы белән ларкылдатып китереп типте. Күзлексез адәм үзара әвәрә килгән өер эченнән очып диярлек чыкты да җиргә чүп-чарлары, тәмәке төпчекләре коелган авыш чүп савытының пычрак авызына башы белән кереп батты...

Өер янына килеп җиткән Тәбәнәк буй белән плащ-палаткасыз, каскасыз һәм тәпәчсез калган Озын буй, уңай вакытны чамалап, читкә ыргылдылар.

Портфельле адәм әллә ни ерак китеп өлгермәгән иде әле...

Ул артына еш борылып карый башлады.

— Әһә, падла, хәлең беттеме? Хәзер иманыңны укытам мин синең!..— Озын буй, соңгы көчен җыеп, тизләгән арттыра төште.

Портфельле адәм «Яшелчә» кибете төбендә өелешкән халык төркеменә килеп кушылды.

— Ычкына алмассың, падла! — диде Озын буй һәм ул да халык төркеменә бәреп керде...

— Чиратсыз кертмәскә! — дип кычкырды бер ветеран, кызыл кенәгәсен һавада болгый-болгый.

— Бетмәс монда җыен этрәк-әләм! — дип гөрелдәде икенче ветеран. Анысы яшел кенәгәсен һавада селки иде.

— Бәрәңге ашыйсылары килсә, басуга барып җыйсыннар! — дип киңәш бирде өченче ветеран. Аның ни кызыл, ни яшел кенәгәсе юк иде. Шуңа күрәдерме ул баш очында кәкре башлы таягын уйната иде.

Гөнаһ шомлыгына каршы, ни кызыл, ни яшел кенәгәсе булмаган ветеранның таягы кулыннан ычкынып китте дә кибет тәрәзәсенә барып бәрелде. Пыяла чылтырап коелды...

— Каравыл! Талыйлар! Кибет талыйлар! — дип кычкырды кызыл кенәгәле ветеран.

— Чиратсыз кертмәскә! — дип акырды яшел кенәгәле ветеран.

— Таягымны бирегез, имгәкләр! — дип шәрран ярды ни кызыл, ни яшел кенәгәсе булмаган ветеран.

— Милиция! Милиция! — дип гөжләде хатын-кызлар.

Бу вакытта хәлдән тайган Озын буй белән Тәбәнәк буй портфельле адәм артыннан ниндидер ишегалдына кереп бара иде.

Портфельле адәм соңгы тапкыр артына борылып карады да, ни булса, шул булыр дигәндәй, каршындагы кызыл кирпечтән салынган бәдрәфкә кереп юк булды.

— Ниһаять! Каптың, падла! — диде кычкырырлык та хәле калмаган Озын буй. Һәм бәдрәфкә атылып керде. Атылып та керде, аяк очындагы кара мәченең койрыгына китереп тә басты... Мәче яман каты акырды. Озын буй аягын күтәрүгә, мәче Тәбәнәк буйның бот арасыннан тышка уктай атылды.

Озын буй кинәт тынсыз-өнсез булып катып калды: дүрт-биш кеше сыярлык бәдрәф эчендә, Тәбәнәк буй белән икесеннән кала, бер адәм заты да юк иде.

— Бә... бә... бә...— дип, нидер әйтмәкче булды авызыннан күбекләре күренгән Тәбәнәк буй.

— Бәэлдәмәле! — диде Озын буй кырыс кына.

— Бә... бә... бәлки, ул мо... мондадыр! — диде Тәбәнәк буй, тирләгән тәпәче белән бәдрәф тишегенә иелде.

— Чыннан да! — Озын буй, борынын җыерып, бәдрәф тишегенә иелде.

Анда да портфельле адәм юк иде.

Шул вакыт Тәбәнәк буй бәдрәфнең күренмәс пыялалы бердәнбер тәрәзәсе төбендә портфель барлыгын күреп алды. Портфель теге адәмнекенә бик охшаган иде. Портфельгә Озын буй игътибар итте.

— Сәер, бик сәер! — диде Озын буй.

Ул портфель тирәсендә безелдәгән эреле-ваклы чебеннәрне кулы белән кугалады. Портфельгә орынырга беравык кыймый торды. «Ә бәлки, анда бомба бардыр?» дип уйлады ул.

Тәбәнәк буй, аның уйларын сизгәндәй:

— Шартлаткычны бәдрәфкә куеп калдырмыйлар,— диде.

Озын буй портфельне сак кына кулына алды.

— Сәер. Портфель җип-җиңел,— диде ул.

Кабаланып портфельне ачтылар: анда язулы кәгазьдән башка бүтән әйбер юк иде.

Озын буй кәгазьне пычрак пыяласында чебеннәр бәргәләнгән тәрәзә яктысына китерде.

Кәгазьдә мондый сүзләр язылган иде:

«Хөрмәтле укучылар!

Юк вакытыгызны бар итеп, иренмичә ошбу хикәяне укып чыкканыгыз өчен автор Сезгә олуг рәхмәтләрен җиткерә. Киләчәктә Сезнең тук вә сәламәт булып яшәвегезне тели. Ә теге портфельле адәмгә килгәндә... Автор аның кая юкка чыкканын үзе дә белми. Бигайбә!

*Ләбиб Лерон.*
*7 ноябрь, 1991 сәнә».*
*1992*

## Алтын күкәй

### Сат күкәеңне, ахирәт!

— Әс... тагым!.. Нәмә бу?

Асилә, кетәклектән ишегалдына чыккач, анда да әле күзләре яктыга ияләшкәч кенә, коштабактагы ят күкәйне искәреп алды. Искәреп тә алды, тавык тизәгенә буялып беткән алты ак йомырка арасында әллә ничек сәер ялтыраган әлеге сары күкәйгә карап, текәлде дә катты:

— Әк-кәмә-ә-әт... Әллә... алтын инде бу?!

Ул, нәрсәнедер искә төшергәндәй, коштабакны җәһәт кенә сул кулына күчерде. Аннары уң кулының атсыз бармагына, төгәлрәге, башкалары белән бердәй кытыршыланган, кара-кучкылланып яргаланган бармагындагы алтын балдагына күз төшерде. Үлсәң дә салдырып булмаслык ул балдакны алтын, дип әйтергә тел әйләнмәс. Егерме ике ел бармакта йөреп, сыдырылып-ышкылып кечерәйгән, нечкәргән, төсе уңган, җуелган... Малтуар астындагы пычкылдык саламның төсе дә моннан арурак...

...Юк, юк!.. Каян килеп алтын булсын бу, дивана! Тавыкның алтын күкәй салганын кемнең күргәне бар?

Күкәйне коштабакта килеш әйләндергәләп, кабыгына бармагы белән баскалап карады Асилә. Хәтта берәр нинди ис-мазар килмиме, дип иснәштергәләп тә алды. Учында тотып, авырлыгын чамалагандай итте. Гадәти, чын йомырка авырлыгы бар үзендә. Бераз гына авыррак та бугай әле. Эче буш та кебек, түгел дә сыман...

Юк... Барыбер күкәй дияргә тел бармый моңа. Кыяфәте белән охшаса да, бер башы очлы, икенчесе тупыйк булса да...

— Абау! Әнекәем! Әллә алтын күкәй тоткан инде кулына?!

Асиләнең йөрәге жу итте. Коштабагын кулыннан чүт ычкындырып җибәрмәде. Сәер күкәй белән әвәрә килеп, күршесе Силүзәнең кергәнен сизми дә калган лабаса.

— Уф! Котны алдың бит! Ут чыккандай кычкырмасаң...— диде ул ахирәтенә.

— И-и, куркытырсың сине...— дип, Асилә янына шулай көтмәгәндә килеп керүеннән, ахирәтен кинәт куркытуыннан үзенчә тәм табып, рәхәтләнеп көлде Силүзә.— Котың ботыңа төшмәсен, дисәң, Әсләмеңә әйт, җә Билалыңа куш — аталы-уллы аягүрә йоклап йөрмәсеннәр... Капкагызга шалтыравык куйсыннар... Минеке әнә... Мәхтүмне әйтәм... Консерва калайларыннан бер нәмә әмәлләп элгән иде. «Безнең капканың ачылып ябылганы күрше авылга да ишетелә икән»,— дип, Тәкмәктән шаккатып кайткан беркөнне... Карале, ахирәткәем, кая яшердең инде ул арада? Күкәеңне миңа да күрсәт әле!

Күзләре үткер дә инде бу Силүзәнең — күреп калган бит. Асилә, үзе дә белештермичә, коштабакка кире саласы урынга, әлеге нәмәрсәне халат кесәсенә шудырган иде.

— Ә-ә, моны әйтәсеңмени?! — дип, кесәсеннән күкәйне кире чыгарды ул.— Менә... эш юкта бер эш булсын дип, кычытмаган җирне кашып торадырыем әле... Кызык өченгә алтынга буядым...

Силүзәнең күләч йөзе кинәт җитдиләнде. Алтын күкәйне кулына алгач, ул да Асилә шикелле җентекләп, әйләндерә-әйләндерә карады. Иреннәренә якын китереп, телен тидерде.

— Авызың зур, кабып йотасың мәллә? — дип көлде Асилә.

Силүзә ахирәте әйткән сүзне әллә ишетте, әллә ишетмәде.

— Бу бит... бер дә син буяганга охшамаган,— диде ул, ниһаять.— Бу бит... чынлап та алтын күкәй!

— Син әйтсәң, белеп әйтәсең инде. Син бит — знатук! — дип тыела алмыйча көлүендә булды Асилә.— Кайда алтын-көмеш ялтырый — шунда син. Бәләкәй чактан һәрбер ялтыравыкка кызыгып үстең...

— И-и, ахирәткәем, мин әйтмәсәм, белмичә үләсе булгансың икән... Исеңдә калсын: чын алтын ялтырамый ул! Ялтыраган кебек тоела гына... Үзем алдансам да...— Ялгыш сүз ычкындырганын аңлап, Силүзә тукталып калды. Аннары, әй, ир белгәнне — мир белә дигәндәй, сүзен дәвам иттерде: — ...күзләрем алдамый минем. Минем күзләрем чынны ялганнан бик тиз аера. Әйтсәм әйтим, бу — алтын күкәй! Шулай булмаса, ых та итмим, кулымны кисәргә бирәм...

— Аллам сакласын, диген! Дивана! Шундый сүз әйтәләрмени...

— Әйтмәгәнем булсын... Тфү-тфү! — дип, Силүзә төкеренгәләп алды да төпченә башлады: — Каян алдың бу күкәйне? Каян таптың?

— Каян булсын — тавык оясыннан! — диде Асилә.— Кетәклектән алып чыктым да... менә... нәрсә икән бу, дип аптырап торам баядан бирле.

— Чынлап та тавык оясыннан алдыңмы?

— Менәтерәк! Үзем салмамын бит инде...

Силүзәнең күзләре очкынланды.

— Син ышанмасаң — ышанма, әмма мин ышанам бу хәлгә. Әкият, димә, әллә нинди әкәмәтләр бар хәзер дөньяда. Беркөн «Таһир-Зөһрә» дигән гәҗиттән укыдым... Шундый гәҗит барын белмисеңдер әле син... Мин дә белмидерием... Минекенең анасы алдыра икән... Мәхтүм артыннан беркөн чәкчәк төреп җибәргән... Полиэтилен капчыгын җәлләгәндер инде... Саран тәре! Шул гәҗиттә язганнар, безнең илдәме, чит илдәме шунда, анысы тучны истә калмаган... Берәүнең күкәеннән...

Асиләгә көләргә янә җай чыкты. Ул, эчен тотып, сыгылып төште:

—Уф, көлдереп үтерәсең, Силүзәкәем...

— Исәр Вәсилә сыңары! Тавык күкәеннән, дип әйтәм мин... Сөйләп бетергәнне көт. Менә шул күкәй эченнән... ни чыккан дип уйлыйсың?

Гомер буе фермада чиләнгән Асиләнең теленә ни килсен инде тагын:

— Әллә сыермы? — дип, күзләрен түгәрәкләндерде ул.

— Син үзең — сыер... Сөткә су куша торгач, әллә синең дә баш миең сыегайган инде. Күкәй эченә сыер сыямыни? Җә, җә, турсайма инде. Суга сөт кушмаганыңны... Әй лә... сөткә су кушмаганыңны беләм лә мин... Сүз уңаеннан гына әйттем. Җә, тагын әйтеп кара: ни чыккан дип уйлыйсың ул күкәйдән?

Асилә Силүзәнең күп сөйләшүеннән арый башлаган иде инде. Аның әле генә әйткән мәгънәсез-тозсыз сүзләренә ачуы да килде. Шуңа, юри иҗекләп:

— А-лай-са... су-ве-ре-ни-тет! — дип әйтеп куйды.

Соңгы араларда Әсләменең авызында гел шул сүз иде. Ни икәнен аңламаса да, аның Татарстан өчен бик кирәкле нәрсә булуын Әсләмнең үз-үзе белән кызып-бәхәсләшеп, кемнәрнедер аты-юлы белән сүгеп йөрүеннән чамалаган иде Асилә.

— Әй, Әсләм сүзен әйтмәсәнә! Үзең дә аңламаганны тырылдап, миемне черетеп тормасаң!.. Күкәйдән алтын йөзек чыккан, бик беләсең килсә!

— Кит аннан! — Ышанмаса да ышана язды Асилә.— Булмаганны...

— «Күкәй эченә ничек керде микән?» дип, әле дә булса баш вата икән ученыйлар. Әле ул гына да түгел... Алтын йөзек тавык хуҗасыныкы булып чыккан! Колорадо корты чүпләргә дип, бәрәңге бакчасына чыгар алдыннан бармагыннан салып калдырган булган... Үз йөзеген күргәч, егерме елдан соң шуны исенә төшергән... Әкәмәт! Шуңа күрә, дим, синең күкәеңнең дә алтын булуына шигем юк.

Силүзә, ахирәте исе-акылын туплап өлгергәнче диптерме, катгый бер фикергә килепме, кинәт әйтеп куйды:

— Сат миңа күкәеңне! Акчасыннан тормам, күпме сорасаң — шулхәтле бирермен...

— Артык куаламале син... Тумаган тайның билен сындырасың бит! — диде Асилә. Ул, миңгерәүләнгән кеше төсле, беравык ни әйтергә белмичә торды.

— Бүтән кешегә сатсаң, мәңге кичермәячәкмен. Миңа гына, түлке миңа гына сатасың! Килештекме?!

— Туктале син, Силүзә. Әсләм дә күрмәде бит әле моны. Билал ни дияр тагы?

— Әсләмеңә алтын ни, әлүмин ни — икесе бер тимер. Аңа күрсәтеп тормасаң да була. Билалың Казанга бүген генә китте түгелме соң? Аннан кайчан кайта әле ул... интектермә, ахирәткәем. Сат хәзер үк миңа. Акчасын мамыйнт алып керәм... И Ходаем, күпме акча санап та калтырамаган кулларымны бизгәк тота башлады...

— Гомер буе шулай булдың инде: болай гына сорап алалмасаң, кеше жәлләтеп җылый башлыйсың...

—Бирәм, диюеңдер инде, ахирәткәем...

— Юк! — дип өзеп әйтергә булды Асилә.— Әсләм кайтмыйча, үзем генә берни дә ришәйт итмим. Бетердек сүзне. Коштабак тоткан кулым оеп бетте инде. Синең сайравыңны тыңлап, куярга да онытып торам икән...

— Ярый алайса, ахирәткәем. Синеңчә хәл итеп торыйк. Әсләмеңә күрсәтеп караган бул инде... Мин иртәгә керермен. Кузгалыйм булмаса. Мәхтүмкәем дә кайткандыр. Синеке дә кайтып җитәр.— Силүзә салпы якка салам кыстырырга да онытмады: — Әсләм кебек кешеләр бик сирәк бит алар. Политиканы аңлаган кеше безнең авылда бер ул гына! Ходай акылны кешегә сайлап кына бирә шул...

— Бар инде, бар... Чәй эчәргә кер, дисәм... чәй синдә дә бар инде ул, —дия-дия, Асилә Силүзәне капка төбенә хәтле озата килде.

Силүзәнең ихатасына кереп китәренә тәмам ышангач кына, Асилә кычкырып сорыйсы итте:

— Ни йомыш белән кергәниең соң?

— Әллә тагы!.. Оныттым! — дип кычкырып җавап бирде Силүзә дә.

— Тинтәк баш! — диде Асилә, үзенә генә ишетелерлек итеп.

— Саран тәре! — дип, шул ук вакытта ишегалдында дулап йөри иде Силүзә дә.

Аның күңеленә корт керде...

## Чукынчык

Мәхтүмне китереп ташладылар.

Силүзә: «Минекеләр дә алай-болай алтын күкәй салмады микән?» — дип, тавык ояларын, ояларга төшәлгән саламнарны пыр туздырып дигәндәй тикшереп, гөнаһсыз кошбикәләрен «әрәмтамаклар» дип каһәрли-каһәрли кетәклектән чыгып килгәндә, ыспай киенгән ике таза егет шактый мәлҗерәгән Мәхтүмне капка баганасына сөяргә азаплана иде.

— Үзең керәләсеңме инде, абзый? — диде егетләрнең берсе, Мәхтүмнең пинжәген рәтләштергәне.

— Әб... бизәтелне! — дип баш какты Мәхтүм.

Икенче егет Силүзәне күреп алды. Ул җәһәт кенә иптәшенә төртте:

— Тайдык! Хатыны чыкты!

Егетләр, Силүзәгә караган килеш, артларына чигенә-чигенә:

— Исәнмесез... кем... апа! Менә... абзыйны китердек... Сау булыгыз! —диделәр дә, хуҗабикә эт шикелле ырлап ябышканчы дип (кем белә бит!), ялт борылып, капка төбендә торган затлы машинага кереп тә утырдылар.

Егетләрнең үзеннән шөлләвеннән күңеле булды Силүзәнең. Ул, ирен чите белән генә елмаеп, көлемсерәп куйды.

Мәхтүм, бер мизгелгә генә башын турайтып, кузгалып киткән машина артыннан кычкырып калды:

— Чао, бомбино, җегетләр! Партия онытмас!

Ул, уң кулын өскә чөеп:

— Напасаран! Миру — мир! — дип тә өстәде...

— Күрсәтәм мин сиңа хәзер мирумирыңны! Исерек тәр...ре! — диде Силүзә.— Дөньяга тынычлык теләгәнче, өеңә теләргә иде башта...

Ул капка баганасын кочып өлгергән иренең кайсы төшеннән тотарга белмичә торды.

Мәхтүм, каенга охшатып буялган капка баганасыннан аерыласы килмичә, үзенчә җыр сузып маташты:

...Ялгыш каенны кочканмы-ы-ын...
Мин аны... син ди-и-ип... торам...

— Кердәсеңме, юкмы син канса канис! — Силүзәнең түземе тәмам төкәнде.— Бушлай концерт карарга бөтен авылны җыясың килә мәллә?

— Хатын! Чәпчемә, яме! Бәйрәм көнне... син миңа җикеренергә тиеш түгел!

— Нинди бәйрәм ул тагы?

— Ә син уйла, уйла, бәгырькәем!

— Уйламыйм да, нитмим дә... Җибәр, дим, багананы!

— Ну, җибәрдем ди... Ава бит ул хәзер, мин тотып тормагач...

Багана, ниһаять, Мәхтүмнең кочагыннан ычкынды.

— Бәйрәм көнне дә салмагач, ничу яшәргә! — Мәхтүм, егылмас өчен куллары белән һавага таяна-таяна, болдырга таба атлады.— Белмисең, ызначит, бүген нинди

бәйрәм икәнен... ә? Бүген... минем туган көн... Газиз әнкәем минем! Рәхмәт сиңа бу дөньяга тудырганың өчен! Мәхтүм күңеле тулып елап җибәрде.

— Ни сөйлисең син, исерек тәре! Туган көнеңне күптән түгел генә уздырдык бит!

Мәхтүм болдырга җитеп тукталды. Башта бер ботинкасын көч-хәл белән салгач, оекбашын тишеп чыккан баш бармагына карап әйтеп куйды:

— Яңа елны ике тапкыр каршылыйбызмы? Ике тапкыр. Яңача һәм искечә. Димәк...— Ул икенче ботинкасыннан да, әүвәлгесе кебек, азапланып котылды.— ...минем туган көн дә икәү булып чыга... Каһәр! Бу носки да тузган икән... Вәйт! Минем ни өчен эчкәнне аңладыңмы инде? Шул шул! Мин аңлатканны син дә аңламасаң...

— Әйдә, кер, кер...— Силүзә, Мәхтүмне бер читкә этәреп, өйалды ишеген ачмакчы булды. Мәхтүм ишеккә сөялеп өлгерде.

— Ашыкма, карчык,— дип, пинжәгенең эчке кесәсенә тыгылды ул. —Мин бит... туган көн бүләген күрсәтмичә торам икән... Менә!

Ныклап тотмаган күрәсең, Мәхтүм кулындагы кәгазь акчалар, кинәт ычкынып, баскычка, җиргә сибелде.

— Эшкуардан алыпсатарга бер төргәк кайнар сәлам! Җый, хатын, акчаларны!

Шулай диде дә Мәхтүм, исәнгерәп торган хатынының йомшак җиренә сугып алды. Силүзә корт чаккандай сикереп куйды. Ул, ялт борылып:

— Аек икән бит син, чукынчык,— дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

«Вәйт хатын диген, ә! Исерек түгел икәнемне күте белән сизде бит, каһәр!» — дип, исе китеп елмайды Мәхтүм.

— Акча эчкән кешене яратмый ул! Аны гына беләм мин,— диде ул. Аннары каударлана-каударлана акча җыярга керешкән хатынына тәкәббер караш ташлады да янә өстисе итте: — Тиз кер. Эчтәге бүреләр ашарга сорый! — диде.

Мәхтүм өйгә кереп югалды.

Җирдәге соңгы кәгазь йөзлекне иелеп алгач, Силүзә тураеп басты. Шул вакыт Асиләләр ихатасыннан әтәч кычкырган тавыш ишетелде.

Алтын күкәй кылт итеп исенә төште дә Силүзәнең күңелен янә корт кимерә башлады.

## Ходай бирде, җен алды

Менә хикмәт: алтын күкәй юкка чыкты. Аны әлеге дә баягы коштабакка йомыркалар өстенә салып, өйгә, мич аралыгындагы аулак урынга кертеп куйган иде югыйсә Асилә. Алты йомыркасы белән коштабак бар, ә теге хәерсез күкәй юк тек юк. Ялгыш орынып, песи идәнгә төшергәндер, дияр идең, ул мәхлукның өйдә күренмәгәненә ике-өч көн бар бугай инде. Ата мәчеләр белән себерелеп кайда йөри торгандыр анысы да. Яз җиттеме, алар котырына башлый...

Аптыраган инде... Халат кесәләренә дә әллә ничә мәртәбә кулын тыгып карады Асилә. Бер кесәсе тишек тишеген дә, ләкин чәнти бармак сыярлык ул тишектән күкәй берничек тә төшеп калалмый. Сөйләшкән-сөйләндергән булып, күз буып, әллә Силүзә тәресе алып чыгып китте күкәйне, әллә Ходай биргәнне җен генә алды шунда. Тәмам башы катты Асиләнең...

Әй, баш бәласе түгел лә... Югалмагае тагын. Силүзә сүзенә ышанып... Дивана! Алтын да булмагандыр әле ул күкәй. Асилә, үз-үзен шулай юатып, күкәй турында бүтән уйламаска тырышты.

Әсләм кайтуына пешә торсын дип, газга итле-бәрәңгеле шулпа куеп җибәрде. Туртаны алгач, кишер, суган, сарымсак турап салды.

Өй эченә тәмле аш исе таралган бер мәлдә ишек ачылып китте. Энесе Нәүфәлнең үзеннән алда тавышы гөрелдәп керде:

— Берәр эшең юкмы, Асилә апа? Куллар кычытып торадырые...— Көндәгечә шулай исәнләшүе инде бу Нәүфәлнең.

— И-и, шуның эшем кешесе булып кылануы! Эчәргә соранып керүеңне аңламыйм мәллә мин,— диде Асилә. Сүзләре үтмәсә дә, энесен бу юлысы да битәрләмичә калалмады.— Аракысыз бер дә торалмыйсыңмыни соң инде? Бетәсең бит, туктат ул эчүеңне. Мин дә әйтмәсәм, сиңа бүтән тукта, дип әйтүче булмас. Әнкәйне тыңламаганны, мине тыңламыйсың инде син...

— Ярар инде, Асилә апа, юкка нерваңны бетермә.

Нәүфәл өстәл янындагы урындыкка килеп утырды. Чынаяк төбендә калган салкын чәйне йотып куйды.

— Әнкәй мескен килен рәхәте күрмичә үлеп китте,— дип тиргәвен дәвам итте Асилә.— Кырыкка җиттең — башыңа акыл кермәде. Үлгәнче өйләнмичә йөрерсең микән инде?..

— Үзең әйтәсең бит, исерек, дип... Исереккә кем кияүгә чыксын?!

— Өйләнәсең килсә, айныйсың инде, энекәем!
— Бик айнырыем да... Йөз кырык морҗалык авылда күзгә кырып салырлык та кыз юк бит... дисәм... бар икән берәү. Кызыкканыем шуңа. Энекәш өлгер булып чыкты...
— Билал белән Дилүсәне әйтәсеңме?
— Соң! Кемнәр булсын тагы.
— Алар бәләкәй чактан ук гел бергә бит инде.
— Миңа димәгәе.
— Араларына берүк керә күрмә. Сиңа әйтәм, энем... Үзеңә тиңне тап.
— Мин түгел, араларына Фатыйма апа керә түгелме соң әле?! Чукынсам чукынам, шул хәерчеләргә кызымны бирәсем юк, дип әйткән диме шунда...
— Харап икән, бирмәсә!.. Билалга кыз беткән ие.
— Ашыкмаса да була әле Билалга,— диде Нәүфәл.— Гүләйт итеп калырга кирәк! Мин булсам, шулай итәрием...
— Шулай иткәнгә күрә кызсыз калдың бит инде. Кара ул кыяфәтеңә! Хатыннар гына түгел, әби-карчыклар да җирәнеп карарлык.
— Карасалар ни. Минем алар белән күкәй тәгәрәтешле уйныйсым юк әле...
Күкәй?! Инде оныткан иде бит Асилә. Энесе тагын искә төшерде.
— Асилә апа, эчмәм дигән ием инде. Синең белән сөйләшә торгач, тамак төбе коргаксып бетте. Салып бир булмаса! — дип, Нәүфәл мич аралыгына ишарәләде.— Җизнинең кирза итеге эчендә җылынып та беткәндер...
Кара, кара! Борыны сизә икән үзенең. Яшерелгән аракы шешәсенең кайда икәнлегенә чаклы белеп тора. Әллә баягынак, Асилә сыерга башак биреп йөргән арада, өйгә кереп чыккан инде Нәүфәл? Кергән булса... Теге алтын күкәйне күреп, шул алгандыр әле...
— Энем бәгърем,— дип, Нәүфәлнең күзләренә туп-туры карады ул.— Әйт әле дөресен: баягынак, мин лапаста чакта, син өйгә кереп чыкканыеңмы, юкмы?
— Син нәрсә, апа! Үзең барда килеп кердем бит. Алдан кереп эчкән дип уйлыйсың мәллә? Кеше өенә рөхсәтсез керергә кем дип белдең син мине. Бу юлысы да, баскыч төбендәге кәлүшләреңне күргәнгә күрә генә, кыңгырауга басып тормыйча килеп кергәнием. Менә... иснәп кара... бүген грамм да эчмәгән әле мин...
Нәүфәлнең күзләре алдамый иде. Энесеннән юкка шикләнде, ахрысы, Асилә.
— Үпкәләмә, энем. Аракының кайда икәнен белгәнеңә күрә генә соравым иде.
— Әллә чынлап та кирза итек эчендәме? Билләһи, Аси-

лә апа, белмичә әйттем. Ис сизәм икән үзем! — дип канәгать елмайды Нәүфәл...

...Ул, шактый кәефләнеп, урамга чыкты. Тәмәке кабызып җибәрде. Шуннан соң, кыймыл-кыймыл килеп, өенә таба атлады.

Клуб турысына җитәрәк, Нәүфәлгә Силүзә очрады. Мәхтүм хатыны кибеттән кайтып килә иде, ахрысы,— бүлтәйгән сумкалары шактый авыр күренә.

— Терелдеңме инде? — диде Силүзә. Асилә апасыннан мәлҗерәп кайтып килгәнен Нәүфәлнең кыяфәтеннән үк чамалап алган иде ул.

— Бырач түгелдерсең бит? — диде Нәүфәл.

— Түгел.

— Шулай булгач, ник сорыйсың, түтекәй?!

— Шуңа сорыйм: апаң сиңа алтын күкәй күрсәтте микән, дим?

— Нинди алтын күкәй ул тагы? Җизни кайтмаган әле,— диде Нәүфәл. Ул Силүзәнең соравын үзенчә аңлаган иде.

— Әй оятсыз тәре! Бар, бар, юлыңда бул,— дип, Силүзә Нәүфәлне аптыраштa калдырып китеп тә барды.

«Кара син аны, энесенә дә әйтмәгән. Миңа да әйтмәс иде, ярый әле үзем күреп калдым...»

Асилә турында, алтын күкәй турында шулай уйланасөйләнә, Силүзә өйләренә кайтып җитте...

Алтын күкәйнең инде югалганын ул әле белми иде.

## Мәхшәр

«Асиләнең тавыклары алтын күкәй сала башлаган икән!» дигән хәбәр, Силүзәнең авызыннан ялгыш ычкынып (ул бу хакта сатучы Фаягөлгә сер итеп кенә әйткән иде югыйсә), Зур Имәннең олысына-кечесенә көне-сәгате белән таралып өлгерде.

Шуннан соң и купты мәхшәр, мин сиңа әйтим!

Безнекеләр дә салмады микән, дип өметләнеп, һәркем үз каралты-курасын күздән-баштан кичерде. Кетәклекләрен, ким дигәндә, утыз-кырык кат айкап чыгучылар да булды. Печән сәндерәсенә дә менеп актарынды халык, бакчадагы карлыгандыр-крыжовниктыр ише куакларның төпләрен дә карарга онытмады. Кайберәүләр хәтта эт ояларына да башларын тыгып алды. Эт оясы дигәннән... Карун Хәйри Вәсимәсе каһәр суккан шул ояның тар авызыннан башын тыгып карау белән генә канәгатьләнмичә, гәүдәсе белән үк кергән иде. Керүен керде, кире чыгам дигәндә, иске сырган фуфайкасы җыерылып, Вәси-

мә оя авызында кысылып калды. Алай итеп карады, болай итеп карады... Ире Хәйри күрмәгән булса, ояда тончыгып үләсе иде Вәсимә. Кадак суыргычын эшкә җигеп, эт оясын сүтәргә туры килде Хәйригә.

Хуҗабикәнең ни өчен аның оясына кереп кысылганын тәки аңламады Тарзан. Сөяк кимерергә дисәң, аны оя эченә кермичә дә кимереп була бит югыйсә. Сәер бу кеше халкы... Җелексез сөяк кебек сәер...

Алтын күкәй турындагы хәбәр «Менә бүген үләм, Алла боерса... Менә иртәгә үләм, Ходай кушса...» дип, өч ел инде урын өстендә тәсбих тартып яткан Гайшә түтәйне кинәт аякка бастырды.

Тавыкларсыз яшәвенә бишбылтыр булса да, ул әүвәлтен үз ихатасын барлап чыгуын кирәк санады (кем белә, Ходайның рәхмәте белән, бәлки, Салиханыкылар, йә булмаса, Кифаяныкылар кереп салгандыр?!). Эзләнде-тулганды Гайшә түтәң, вәләкин алтын түгел, гадиен дә тапмады.

Шуннан соң ул, өйләрендә беркем дә юклыгын ике арадагы койма ярыгыннан карап-чамалап, бакча артлатып кына Салихалар ихатасына күчте.

Кайчандыр бер җирән тавыгы булганлыгын, шул явызның әле Салихаларда, әле Кифаяларда күкәй салырга гадәтләнгәнен исенә төшереп, әллә кайчан суелып ашалган булса да, аны бүген дә исән шикелле тиргәп-каһәрләп, Гайшә түти караңгы абзар эчендәге бер ишек тоткасына үрелде. Ишекне тимер бигеннән ычкындырып ачуы булды, кинәт ниндидер көч, кендек өлешен яман авырттырып, әбине артка чөеп ыргытты. Ачык ишектән чиныйчиный бер-бер артлы атылып чыккан иләмсез зур чучкаларны шәйләп, юеш, шакшы тагаракта яткан (нәкъ менә шуңа туры килергә кирәк бит ә?!) Гайшә түтәең тәһарәтсез калды...

Әбинең гомере бетмәгән икән әле — әҗәл бу юлы да аның җанын аласы итмәде. Хәтерен генә алды: Салихаларның тагарагына ни өчен кереп ятканлыгын күпме генә тырышса да исенә төшерә алмады Гайшә түти...

Кәрлә Бәширәнең ниндидер дини секта колына әйләнгән ире Хамис, ниһаять, үзенә янә бер шөгыль тапты: өйдәге барлык йомыркаларны ватып, аларның эченнән алтын эзләде. Моңарчы кулына кергән барлы-юклы акчасына хатыныннан чәлдергәннәрен дә кушып, бар туплаганын секта карамагына тапшырып, үзенчә изге гамәл кылам дип уйлаган Хамисның, алай-болай күкәй эченнән алтын тапса, ул байлыкны да шул максатта файдаланырга иде исәбе. Ни кызганыч, йомыркалар ватылып бетте, әмма эчләреннән сыңар күкәй сарысы хәтле дә алтын

чыкмады. Шуңа да карамастан өметен өзмәде тагын үзе: артларыннан күкәй коелып төшкәнен көтеп, һәр тавыкны сагалап йөри башлады...

Кәрлә Бәширә исә, хикмәт әтәчтәдер, дип уйлап, бер өер чеби-әтәчләр алу максаты белән Питрәчкә — атаклы кошчылык фабрикасына сәфәр чыгып китте. Китәр алдыннан, бер тәгам ризык пешереп ашый белмәгән мәхлук ире ачтан үлмәсен дип, бер казан күкәй боламыгы пешереп калдырды...

Күрше тавыгы күркә булып күренә, диюләре рас икән. Зур имәнлеләр, үлә-бетә язып, бер-берсенең тавыгыннан көнләште. Бер күрше икенчесенең тавыгын таяк белән сугып имгәтсә, икенчесе өченчесенекенә таш ыргытып зәгыйфьләндерде. Гөнаһсыз тавыкларның җан тәслим кылучылары да булды. Шунысы гаҗәп иде: күршеләр берсе дә бер-берсен җинаять өстендә тота алмады. Тагын бер могҗиза дигәндәй, Кәрлә Бәширәнең тавыкларын ике як күрше, никадәр тырышса да, кәңкәйтә алмады. Авылда зыян күрмәгән тавыклар бер аныкы гына калды. Сектант Хамис тавыкларын ялгыш та күз уңыннан ычкындырмады шул. Тик ни хикмәт, Хамис саклап йөри башлаган көннән соң тавыклар күкәй салудан бизделәр... Ишегалдында чемченеп тә йөргән булдылар инде югыйсә.

Асиләнең энесе Нәүфәл, тагын берничә сазаган егет эчүне бөтенләй ташлады. Кая ул эчү! Аракы шешәсе күрсәләр, шундук укшый-коса башлыйлар. Теләгән ризыклары да тамактан үтмәскә әйләнде. Ни хикмәт, егетләрнең моңарчы йомыркага бер дә исләре китми иде, авылда алтын күкәй шаукымы башлангач, алар бердәм рәвештә чи күкәй сарысын эчәргә гадәтләнделәр. Гайре ризык үтми, күкәй сарысы шуып кына төшә ашказаннарына. Әллә гел шул күкәй сарысын эчкәнгә инде, егетләр кинәт тазарып киттеләр. Битләре алсуланды. Күзләрендә яшәүгә өмет нуры кабынган кебек булды. Күзләр дигәннән... кешедә «белая горячка» айныгач була икән бит, эттәгенәсе! Егетләр белән дә шулай булды. Дөрес, аларның күзләренә җен-фәлән ишеләр күренмәде. Әмма алтын чебиләр күз алларына килеп интектерде. Галәмәт инде! Нәүфәл, алтын чеби тотам дип, ике көн буена Мөкатдисә карчыкның сары мәчесен куып йөрде. Башка егетләр дә шулайрак миңгерәде. «Күкәй зәхмәте тигән, бозык күкәй сарысы нерваларын параличлаган!» — диде сихерче Камилә карчык, егетләрне берәм-берәм өшкергән чакта. Иртәнге чык суына кызыл әтәч тизәге болгатып эчергән иде, әллә шуның файдасы булды инде — егетләрнең хәле бераз рәтләнгәндәй итте...

## Малик Шәрәфетдин интервью ала

Кай арада ишетеп белгәннәр диген. Зур Имәндәге алтын күкәй феномены белән Казан галим-голәмәләре бик җитди рәвештә кызыксына башлады. Ветеринария академиясеннән бер өер тавык белгече килеп төште Зур Имәнгә. Вертолет белән. Әллә нинди япон аппаратларына кадәр алып килгәннәр. Күчмә лаборатория оештырып җибәрделәр дә Асиләнең исән калган тавыкларын шунда урнаштырып, җентекләп тәҗрибәләр үткәрергә керештеләр. Әтәчне дә онытмадылар. Киресенчә, игътибарның зурысы аңа булды. Игътибар дип, интектереп, җәфалап бетерделәр инде үзен. Кан анализларын алдылар, тизәкләрен тикшерделәр, спермаларыннан әллә нәрсәләр эзләделәр, бот арасы белән канат астындагы температураның үзара тәңгәл килү-килмәвен ачыкладылар, экранлы аппаратлар ярдәмендә бүтәкәдәге пыяла-ташларның ничек эшкәртелүен күзәттеләр, кикригенең, томшыгының озынлыгын үлчәделәр...

Кыскасы, алтын күкәйнең ничек барлыкка килгәнен ачыклау өчен галимнәр бөтен аң-белемнәрен, тәҗрибәләрен эшкә җиктеләр...

Алар үз лабораторияләрендә тикшерү эшләре белән матавыкланып яткан көннәрдә, Казаннан янә кунаклар килеп төште. Ике алагаем зур автобус белән. Болары — телевидениедән булып чыкты. Тележурналист Малик Шәрәфетдинне зур имәнлеләр шундук танып алдылар. Танымаска, авыл-колхоз тормышы турындагы тапшырулары белән телевизордан гел күренеп тора бит ул. Малик Шәрәфетдин колхоз рәисе Фаяз белән ике куллап күреште.

— Исән-сау гына яшисездер инде, Фаяз Кәлимәтуллович?! — дип, рәискә дустанә елмайды ул.— Узган елга караганда быел уңыш та мул булгандыр инде сезнең, Фаяз Кәлимәтуллович?

Фаяз рәис халкына гына хас вәкарьлек белән җавап бирде:

— Әйе, узган елгыга караганда быел уңыш та мул булды инде, исән-сау да яшибез инде, так сказать.

Телеоператор аппаратын иңсәсенә куюга, Малик төп сорауга күчте:

— Фаяз Кәлимәтуллович, менә мин уйлап торам әле... сезнең алдынгы сыер савучыгыз, һәр сыердан көненә уналтышар-унҗидешәр литр сөт савып ала торган дояркагыз Асилә Гансовна Рәхимҗанованың тавыклары кинәт алтын күкәй сала башлауда сезнең дә өлешегез зур булгандыр инде, име?

Рәис, каушап кала торган кешеләрдән түгел иде, җавапны тиз тотты:

— Әйе... Безнең алдынгы сыер савучы дояркабыз Асилә Канисовна Рәхимҗанованың да, так сказать, дип әйтәсем килә, башка атаклы дояркаларыбызның да алтын күкәй сала башлавында безнең дә өлешебез зур булды инде, так сказать...

— Тавыкларның алтын күкәй сала башлавында, дип әйтергә теләдегез инде, име, Фаяз Кәлимәтуллович. Шулай бит?

— Шулай... Әйе... Тавыкларның алтын күкәй сала башлавында да безнең роль зур булды инде, так сказать. Көчебездән килгәнчә тырыштык инде. Бу яктан алганда, завферма Вәгыйз дә...

— Вәгыйз Кафиловичны әйтүегездер инде, име?!

— Әйе... Гафилович Вәгыйзне әйтүем инде. Ул да бөтен көчен, так сказать, шунда направить итте.

— Фаяз Кәлимәтуллович, Асилә Гансовнаның... Канисовнаның тавыклары тиктомалдан күкәй сала башламагандыр бит инде, име?! Моңа башта җирлек кирәк...

— Дөрес әйттегез. Нәкъ шулай, так сказать. Ирлек булса, җирлекне табарга була.

— Сорауны Асилә Канисовнага бирәм хәзер. Асилә Канисовна, менә синең күкәең инде, име, алтын күкәй инде, име?

— Ие, алтын күкәй...

— Сер булмаса, ул алтын күкәйне нишләтмәкче буласыз инде, Асилә Канисовна? Хөкүмәткә үз теләгегез белән тапшырырга җыенасыздыр инде, име?

— Ие, үзем... үзебез... теләгебез...— Мондый сорауны көтмәгән Асилә бер мәлгә югалып калды. Күкәйне бер дә хөкүмәткә тапшырырга уйламаса да, кеше алдында сер бирәсе килмәде.— Ие, үзем һәм ирем Әсләм, улым Билал белән киңәшләштек тә, үз теләгебез белән хөкүмәткә бирергә булдык. Безнең шикелле айлар-еллар буе хезмәт хакы күрмәгәннәргә тип-тигез итеп бүлеп бирсәләр, халык та сөенер, хөкүмәтебез дә җиңел сулап куяр.

Асилә, үз җавабыннан үзе канәгать калып, дөрес әйттемме дигәндәй, рәискә карап алды һәм, шунда нәрсәдер исенә төшереп, өстәп куясы итте:

— Безнең Фаязыбыз да бик әйбәт, печәнен-саламын бирә. Рәхмәт безнең персидәтелгә.

— Авылда шундый күркәм кешеләрнең күп булуы нур өстенә нур инде ул. Димәк, авыл, бу очракта Зур Имән авылы, якты киләчәккә ышанычлы, ныклы адымнар белән атлап бара. Халык бүгенгем, дип кенә яшәми, килә-

чәгем — көләр чагым, дип, көр күңел, сәламәт рух белән яши! — дип, әңгәмәне йомгаклады Малик...

Шунысы гаҗәп, алтын күкәйне күрү, аны тотып карау бәхете, Силүзәдән башка, берәүгә дә тәтемәде. Бик тотарлар иде дә... юк күкәйне ничек тотасың. Асилә табалмады бит әле аны. Шуңа күрә күкәйнең югалганлыгы хакында халыкка әйтеп тормады Асилә. Күкәйнең кайдалыгы белән кызыксынучыларга: «Бик каты яшердем... Урлатудан куркам!» — дию белән генә чикләнде.

Утсыз төтен булмый: халык-гавам алтын күкәйнең барлыгына болай да ышанган иде. Моңа Силүзәнең: «Үзем күрдем, үз күзләрем белән!» — диеп антлар эчеп әйтүе дә тәэсир итми калмады, әлбәттә...

Атна-ун көннән соң, телевизордан түземсезләнеп көтелгән тапшыруны караганда, экраннан кулына алтын күкәй тотып сөйләүче Малик Шәрәфетдинне күргәч, авыл халкы аһ итте. Үзләре алтын күкәй тотып карый алмаганнарына бик тә эчләре пошып, Малик Шәрәфетдинне дә, күкәй сыярлык итеп авызын ачып сөйләгән Асиләне дә бәреп үтерәселәре килде аларның. «Кара син аны! Безгә биреп-күрсәтеп алырга жәлләде, телевизор кешесенә китереп тоттырган!» — дип, эт итеп сүктеләр Асиләне. Телевизор экраныннан ялтырап күренгән алтын күкәйнең чын түгеллеген, бары тик ясалма, бутафор күкәй генә икәнлеген белмәде шул алар...

* * *

Малик Шәрәфетдиннең тапшыруы Татарстанда яшәүчеләр өчен сенсация булды. Халык соравы буенча, телевидение исеме «Туган як күкәйләре» дип үзгәртелгән тапшыруны атнасына җиде мәртәбә күрсәтте. Моңарчы урысча тапшырулар, җылаткыч сериаллар гына карарга яраткан халык татар каналына мөкиббән булды. Телевидение өчен бу зур казаныш иде. Экранда галәмәт кызык тапшырулар пәйда булды. Аларның ни хакында икәнлеген исемнәреннән үк чамаларга мөмкин иде: «Әтәч белән тавык», «Күкәй тәме», «Кытаклыйк әле», «Алтын күкәй», «Күкәй кабыгы аша...», «Киң күкәй», «Җомга көн күкәй белән», «Афәрин, күкәй!», «Утырып күкәй санадым»...

Шагыйрь-голәмәләр, бердәм кубып, ошбу тапшырулар өчен эт сигәнче исәпсез-хисапсыз такмаклар язып өлгерттеләр, ул такмакларны үзен композитор санаган һәркем көй белән сипләде. Буй-кыяфәтләре, тавыш-авазлары белән бер-берсенә инкубатор чебиләренә охшаш җырчы егетләр-кызлар әзер җырларны шул көнне үк халыкның ку-

целенә җиткерделәр. «Алтын балык» җырын шул ук шагыйрь язган «Алтын тавык» оныттырды:

Алтын тавык, алтын тавык,
Сөйгәнемә барчы алып,
Алтын балык!

Салкын-кайнар чәйләр, Сөләйман балдагы, каеннар, миләш-таллар, туган көннәр, әнкәйләр турындагы җырларны бөтенләй башкалары алыштырды: «Кайнар күкәй», «Салкын күкәй», «Асилә күкәе», «Күкәйләрем»...

«Күкәйләрем» җырын, күкәй сүзе еш кабатлангангадырмы, халык бик тиз отып алды. Бу җырның:

Күкәйләрем, күкәйләрем,
Сез минем сердәшләрем... —

дигән юлларын телсез Мөслимә, Зур Имән халкын шаккатырып, бик оста шыңшырга өйрәнде. Яше илледән узган Мөслимәнең шулай оста шыңшырга өйрәнүенең сәбәбен әлеге җырдан гына түгел, ә бәлки Асиләнең энесе Нәүфәлдән дә күрде авыл халкы...

«Чукынсам чукынам, шул хәерчеләргә алма күк кызымны бирәсем юк» дип сүз тараткан Фатыйманың соңгы араларда Асиләләрдә күренүе бигрәк ешайды.

— Кодагыйкаем, ни эшләр бетереп ятасың? — дип, Асиләләргә таң тишегеннән үк килеп керә торган булды ул, кырыкмаса-кырык мәртәбә. «Безнең Дилүсә белән сезнең Билал бигрәкләр дә пар килгәннәр инде. Бәхеткәйләре генә була күрсен берүк!» — дия-дия, Асиләнең колагын тондырып бетерде. Түзде инде Асилә, түзмичә кая барсын. Балалар өйләнешмичә торып, булачак кодагые белән, кара яндырып, талаша алмый бит инде ул. «Бер үк сүзләрне күпме чәйнәргә була?» — дип, хәзердән үк чәйнәшә башласаң...

Әсләмгә рәхәт. Өйдә торганы да юк аның. «Татарстанның киләчәген мин кайгыртмасам, кем кайгыртыр?» ди дә өйдән чыгып китә. Менә бүген дә, «Бөтиүгә (анысы ни дигән сүздер тагы) барам, үз партиямне оештырып кайтам. Мин кайтканчы, алтын күкәйне табып куй. Кыстати, яңа партиямне «Алтын күкәй» дип регистрасия аша үткәрергә уйлыйм»,— дип чыгып китте Казанга. Ул регистрасия дигәне нәрсәдер тагы... Әсләм белеп әйтә: политикада надан инде Асилә, надан...

Төннәрен биле бик каты сызлап интектергәч, сыер савуын ташлаган иде Асилә. Менә шул көннән бирле Фатыйма килә инде үзләренә. Бер көн дә калмый. Балалар башлы-күзле булганчы түзәсе инде, түзәсе...

...Алтын күкәйне үзенеке итә алмау кайгысыннан Силүзә эчүгә сабышты. Эчү җүнлелеккә илтәмени инде ул. Тагын башын югалтты Силүзә. Яшьлектәге мәхәббәте — күрше Тәкмәк авылының Фатихы белән гыйшык-мыйшык уйнап ятканда, өсләренә Мәхтүм кайтып керде.

Күкәйгә кызыгу харап итте Силүзәне...

* * *

Алтын күкәй табылмады. Кем белә, бәлки, булмагандыр да әле ул. Асилә белән Силүзәнең күзенә генә күренгәндер. Шулайдыр ул, мөгаен, шулайдыр...

Зур Имән авылында булган әлеге вакыйга Казанда яшәүче бер язучыны кулына каләм алырга, дөресрәге, кампитр каршына утырырга мәҗбүр итте. Кай ягы беләндер үзенең туган авылын хәтерләтте ул вакыйга...

...Кампитр экранында иң элек авторның исем-фамилиясе пәйда булды. Аннары әсәрнең исеме — Ләбиб Лерон «Алтын күкәй».

Шаян хикәя булырга тиешле әсәр шулайрак башланды:

— Әс... тәгым!.. Нәмә бу?

*Март, 2003*

# Уеннан уймак

## 1

Алып бәдәнле зәнки[1] үз гәүдәсе астында ләззәтле изелеп яткан хатынның имиләрен каты учлары белән изәәвәли иде. Үзе өзлексез мышкылдый, ухылдый.

Матур бизәкләр ясап сырланган агач ятакның затлы урын-җиренә сеңеп бетә язган хатын исә вакыт-вакыт гел бер үк сүзне кабатлый:

— Милый... Милый...

«Әле ярый балалар йоклый. Алар карап торса, оятыңнан кая керер тишек тапмассың» дип уйлый Зөлхәбирә.

— Тебе приятно? — дип пышылдый зәнкинең кабартма иреннәре. Аның азатлык утравы сыярлык киң маңгаендагы бөрчек-бөрчек тир тамчылары, тулышып, хатынның әле битләренә, әле борын очына, әле «милый...» дип ачылган иреннәре арасына тама...

---

[1] Зәнки — бу очракта: негр.

«Ярый әле балалар күрми» дип, янә куанып уйлый Зөлхәбирә.

— Скажи, тебе приятно? — дип кабат пышылдый зәнки...

Негр дигәч, студентларның төзелеш отрядында эшләгән чак искә төште. Минем бригадада алар икәү иде: һәрвакыт көләч Луис Ларинага һәм гудронланган телеграф баганасын алыштырырлык Лено Перес. Аерымлыклары буйларында гына булгач, бу ике кара-чутырның — Фидель Кастроны якыннан өч мәртәбә күргән һәм хәтта берсендә юлбашчының игътибарына лаек булган («О, кара малай! Кил әле бирегә!» дигән, имеш, Фидель) Луисның һәм «Ай былбылым»ны җырларга өйрәнгән Ленонын күзгә бәрелеп торган уртаклыклары да бар иде: мәшһүр утрауларына кире кайтып киткәнче, алар икесе дә совет хатын-кызларына үлеп мөкиббән булдылар (әллә киресенчә — хатын-кыз көмәшләреме?!). Берсе — Луис — марҗаларны аеруча үз итте: әгәр бүген Казан урамында нәни мулатлар очратсагыз, белегез — болар Луисның «автографлары». Икенчесе берне яратты, әмма берәгәйле ятады: Мөслим кызы Асияне үзе белән алып китте.

Тулай торакның кызыл почмагында туй мәҗлесе гөрләгән чакта, Асиянең әтисе тәмәке көйрәтергә фойега чыккач, без аңа үзебезчә «ехидный» сорау биргәндәй иттек:

— Ничек соң, агай, кызны кара халыкка биреп җибәрү җәлке түгелме?

Мөслим агаенын җавабы кыска булды:

— Өйдә тагын бер пачка кыз калды әле...

Хәер, мин әсәрдән читкәрәк киттем шикелле... Гафу...

— Скажи, тебе приятно?

— Да, милый... Да... да...

Шул вакыт гыйшык уены өзелде, телевизорның төсле экранында зифа буйлы, озын сары чәчле, зәңгәрсу күзле бер сылу кыз пәйда булды. Ул ап-ак тешләрен җемелдәтеп елмайды да:

— Дамы и господа! Всегда имейте при себе презервативы. Это — самый лучший способ защиты от СПИДа! — диде. Һәм күкәй капчыгын өреп кабартты.

Зөлхәбирә телевизорны сүндерде.

«Әле ярый балалар күрмәде бу рекламаны» дип, өченче мәртәбә сөенеп куйды ул.

Бу вакытта аның игезәк уллары Айрат белән Айдар, үз бүлмәләре ишеген эчке яктан бикләп, селәгәйләрен агыза-агыза, шәрә кызлар сурәте белән чуарланган журналлар актарып ята иде...

Зөлхәбирә китап шкафы янына теләр-теләмәс кенә килде дә аннан «Татарстан яшьләре» гәҗитен кулына алды, урта битен ачып, андагы вак-вак язмаларга күз салды. Ләкин аларны укудан тәм тапмады. Баязитның шылтыратмавына эче пошты аның. «Шефны каршыларга аэропортка барам»,— дип чыгып киткәненә дә өч сәгатьләп вакыт узды бит инде.

Зөлхәбирә гәҗитне урынына куйды. Суыткыч өстендәге бәллүр савыттан бер әфлисун алып, аны әрчергә кереште.

Ә Баязит һаман шылтыратмады.

«Бер-бер хәл булмагандыр бит инде». Зөлхәбирә телефонга караш ташлап алды да яшел бәрхетле кәнәфигә аякларын җайлап-бөкләп утырды.

Ул әфлисунның сусыл бүлемтеген авызына якын китергән мизгелдә, төнге каладагы икенче бер фатирда ату тавышы яңгырады...

## 2

— Всё! Душу Богу отдал! — диде кулына пистолет тоткан адәм. Ул кашлары өстенә төшкән эшләпәсен пистолет тотмаган кулы белән өскәрәк этәреп куйды.

— Кажется, еще жив...— диде аның юлдашы, кырын яткан корбанның гәүдәсен ботинкалы аягы белән кузгаткалап.

— Черт! — Эшләпәле адәм идәнгә лачт итеп төкерде дә аты-юлы белән сүгенде. Ул, пистолетын тоткан килеш, корбанга иелде, аны, беләгеннән әләктереп, чалкан яткырды.

Ату тавышы янә яңгырады...

Баязит, башын күтәрә төшеп:

— Лулу, сүндер әле шул «тартма»ны! — диде.— Колак гарык булды бу атышлардан...

Луиза, кофе чәйнеге, чынаяк-калак һәм вак шакмаклы шикәр тулы савыт куелган тәгәрмәчле кечкенә өстәлчекне тәгәрәтеп, кухнядан килеп чыкты да софада юрган ябынып яткан Баязит янына килде.

«Тартмачык»та атышлар тәмам кызды.

— Зерә бүләк иттем бугай мин сиңа бу видикны,— дип кыбырсынды Баязит.

Луиза, ирнең чәпчеп ятуына игътибар итмәскә тырышып, аның пеләшеннән сыйпады, маңгаена, кипшенгән иреннәренә үзенең сусыл, мимылдык иреннәрен тигезеп алды:

— Хәзер сүндерәм, арысланым!..

«Тартмачык»тагы эшләпәле адәм пистолетын бу юлы Баязитка төбәде, әмма атарга өлгермәде — Луиза телевизорны сүндерде.

— Өйгә шылтыратып аласы булыр,— диде Баязит, Луизаның чынаякларга чәйнектән кофе агызганын күзәтә-күзәтә.— Магнитофонга «аэропорт» кассетасын куярсың әле...

— Баш өсте, галиҗәнап! — диде Луиза.— Есть магнитофонга «аэропорт» кассетасын куярга!

— Сиңа кызык...— диде Баязит, чынаяктагы кайнар кофены аз-маз гына йоткалап.— Ул бит шефны каршыларга киттем дип уйлый...

— Уйласын. Хуҗа кеше хатынының эше шул бит аның: ашарга хәстәрләү, бала тәрбияләү, ирнең эштән кайтканын түземсезләнеп көтү һәм уйлану. Уйласын, уйласын... Миңа гына уйланырга дигәнмени?!

— Йә, ярар, телеңә салынма әле,— диде Баязит.— Болай да ачу килеп торган чак...

— Кемгә, миңа ачуың киләме? — Луизаның йөзендәге алсу елмаюы сүрелә төште.

— Юк ла инде, нишләп сиңа булсын, үземә! — диде Баязит.— Әйттем бит инде, соңгы вакытларда төрле яктан кыса башладылар... Этеннән алып бетенә хәтле бәйләнергә генә тора...

— Бет дигәнең мин түгелдер бит?

— Лулу! — дип, тавышын күтәрде Баязит.— Минем сине ничек яратканымны беләсең бит инде. Ташлале ул шаяртуларыңны, ә!

— Бетте, бетте, бетте... Бүтән шаяртмыйм. Авызга кофе кабам да бер сүз дә дәшмим.— Ул, авызын турсайткан булып, Баязит янына утырды.

— Яхшы. Кем әйтмешли, дәшмәү — алтын, кайчак дәшмим... Слушай, каяле, торыйм әле мин. А то яткан килеш шылтыратып булмый...

Баязит телефон трубкасын кулына алды.

— Лулу, магнитофонны куш!

Луиза магнитофон янына барып, аның бер төймәсенә бармагын төртте.

«Уважаемые пассажиры! Фирменный поезд «Татарстан» опаздывает...» дип сөйли башлаган гына иде магнитофон, Баязит, кулын дуамалланып изеп, Луизадан аны туктаттырды.

— Син нәрсә инде, Лулу, мин бит «аэропорт» кассетасын куй, дидем...

— Гафу, җаным, ялгыш куйганмын,— дип, Луиза тиз генә тасмаларны алыштырды.

«Уважаемые пассажиры! Самолет... рейсом...» дип магнитофон тәтелдәгән вакытта, Баязит телефон трубкасындагы төймәләргә баскалады...

### 3

Зөлхәбирә, кабаланып, телефон трубкасына үрелде.

— Әйе, Баязит, синме бу?

Шылтыратучының тавыш-авазы ишетелмичә торды.

— Синме бу, Баязит? — диде Зөлхәбирә, авызын телефон трубкасына батыра язып.

Телефонның теге башыннан кемнәрнеңдер быдыр-быдыр сөйләшкәне ишетелде. Бераздан бер ир-ат карлыккан тавыш белән:

— Кайда ул? — дип сорады.

— Кем кайда? — Зөлхәбирәнең күңеленә шом иңде.

— Кайда ул идиот?

Зөлхәбирәнең тәннәре куырылып килде: «Тагын тегеләр!»

— Әйт, дим, заразы. А ту хуже будет. Кайда ул идиот?

— Өйдә юк ул. Кайда икәнен белмим,— диде Зөлхәбирә. Ул дер-дер килде. Теге чакта да, шушылар шылтыраткач та, Зөлхәбирә куркуыннан шулай калтыранган иде.

— Ну что же,— диде карлыккан тавыш,— зату без беләбез аның кайда икәнен... Әгәр шылтыратса, кисәт: без дигәнчә булмаса, гомере белән бәхилләшсен! Приввет!

Карлыккан тавышны пипелдәү алыштырды...

Зөлхәбирә, телефон трубкасын урынына куярга да онытып, бер ноктага текәлгән килеш, шактый вакыт өнсез утырды...

— Телефон буш түгел. Хатын кем беләндер сөйләшә,— диде Баязит.— Тагын шылтыратып карыйм. Кассетаны кирегә әйләндер әле, Лулу...

— Минем өйдә аны хатын димәле,— диде Луиза, үпкәчел тавыш белән.

Ул, магнитофонны чырт-чырт китергәләп, тасманы кирегә әйләндертә башлады.

— Хатын, дими, кем дип әйтим тагы... Хатын булгач. Сыер, диим мәллә?

— Миңа димәгәең... Хет чучка, диген. Тик хатын дип кенә әйтмә. Минем өйдә...

— Минем өйдә? — Баязит әлеге сүзләргә басым ясады.— Бу өйне кем бүләк иткәнен онытасың, ахры, Луиза...

— Бүләкне кире сорап алмыйлар,— диде Луиза.— Бер бүләк иткәнсең икән, оныт инде син аны...

Магнитофон гөжелдәүдән туктады.

— Ярар, бетердек. Ташлале шул пастаянны үпкәләүләреңне,— диде Баязит.— Өйгә кайтсаң — хатын өзлексез мыжгып җәфалый. Бу мәхшәр дөньядан ял итим әле, дип, монда килсәң — син үпкәләп газаплыйсың...

— Сөяркә үпкәсен һәрвакыт белдереп тормаса, сөяркә булмый да ул, җаным...

— Сөяркә, дип... алай ук ямьсез әйтмәле син...

— Нигә? Сөяркәң түгелмени? Әллә сөекле, газиз хатыныңмы?

— Ну-у...— Баязит кирәкле сүзләр таба алмыйча торды.— Сөяркә, дип... Син — минем яраткан кешем...

— Ха-ха! — Луиза мыскыллы елмайды.— Мин — шәһәр хуҗасының... Юк... Ничек дисез әле сез үзегезне... ад-мини-стра-ция башлыгы дисезме?! Әйе... Мин ад-мини-стра-ция башлыгы иптәш Идиот... гафу... Һидиятуллин Баязит Хөббетдин улының яраткан кешесе! Әйбәт яңгыраймы, хуҗам?

Баязит дәшмәүне кулай күрде. Луиза ишеләрне моңарчы күп алыштырган кеше буларак, белә ул: сөяркә — үз хатының түгел, аны кыйнап-типкәләп тә, авыз тирәсенә терсәк белән кундырып та такылдавыннан туктатып булмый... Исе, фатирдан чыгып, бөтен дөньяга таралырга мөмкин... Әнә, коммунистлар заманында шәп иде ул, ичмасам! Сөяркәңнең муеныңа менеп атланырга маташуын сизенүгә шалт! сары йортка! Хәер, акчаң мулдан булса, ул йортка хәзер дә юл ерак түгел...

Баязитның дәшми торуы уңай нәтиҗә бирде: Луиза тынычланды.

— Кофе яңартыйммы? — диде ул, халатыннан ярты-лаш күренеп торган күкрәкләрен уң кулы белән каплаштырып.

— Яңартырсың,— диде Баязит.— Тагын берәр рюмка коньяк та тотарбыз. Бу юлы «Наполеон»ны салырсың... Тик... аңарчы нит әле... Магнитофонны куш. Тагын шылтыратып карыйм...

Телефоннан Зөлхәбирәнең «Әйе, Баязит, синме бу?» дигән тавышы ишетелгән мәлдә магнитофон телгә килде: «Уважаемые... рейсом... опаздывает...» Баязит телефон трубкасын сул колагына күчерде:

— Әйе, Зөлхәбирә, мин бу... Менә үзе кайтып җитми әле... Көтәбез... Нәрсә? Кем шылтыратты? Кем шылтыратты, дим? Нәрсә түгелә? Ә-ә-ә, тегеләр... Тегеләр?! Тагын шылтыраттылармыни? Анасын с-с-с... суга барган-

да... Нәрсә диден? Яхшы. Яхшы. Борчылма. Малайлар нишли? Йоклыйлармы? Бу вакыттамы? Ә-ә-ә... соң икән шул инде... Ярар... Менә самолетны каршы алам да... Юкса үзе гафу итмәс... Яшисе бар бит әле. Яшисе бар бит әле, дим!.. Кайтам... Озак тормам... Ярар, борчылма... Пока! Уф! — Баязит трубканы куйды. Тирләгән маңгаен уч төбе белән сөртеп алды.— Сүндер магнитофонны...

— Ни булган! Берәр хәтәр нәрсә юктыр бит? Маңгаең шабыр тир,— диде Луиза, магнитофонны сүндергәндә.

—Тегеләр... тагын тегеләр шылтыраткан өйгә...

— Кемнәр ул — тегеләр?

— Хәзергә берни дә сорама, матурым. Соңыннан барысын да тәфсилләп сөйләрмен.

Баязит рюмкадагы эчемлекне авызына койды.

## 4

Зөлхәбирә малайлары бүлмәсенең ишегенә колагын терәде: эчтә ул-бу ишетелмәде. «Йоклыйлар»дип уйлады ул һәм үзалдына елмаеп куйды.

Әни кеше ялгышмады. «Плейбой», «Эротикон» һәм шуның ише журналларны актарып алҗыган малайлар, чыннан да, төшләр күреп йоклыйлар иде инде: Айрат анадан тума калган география укытучысы Василә Сәхәбетдиновнаны Африка чүле буйлап җан-фәрман куып йөргән бер вакытта, Айдар, мышкылдый-мышкылдый, партадашы Сөмбелә Кудряшованың болай да кыска күлмәк итәген күтәрергә азаплана иде...

Улларының шундый интим төшләр күреп ятуы хакында әни кеше белмәде, әлбәттә. Ул, кәнәфигә халатын салып куеп, көзге алдында үз кыяфәтенә, үз гәүдәсенә карап сокланып тору белән мәшгуль иде.

Баязит аңа өйләнеп ялгышмаган. Күр инде аның аксыл беләкләрен, төз аякларын, тыгыз ботларын... Хәзерге кыз-хатыннарның прәннек чаклы күкрәкләре янында Зөлхәбирәнең түгәрәк «калачлары» үзләре генә ни тора! Аккошныкы шикелле муен, зур да, кечкенә дә булмаган авыз-иреннәр, шәрекъ хатыннарына гына хас нәфис борын, соргылт күзләр, озын куе чәчләр...

Зөлхәбирәнең үзе генә белгән бер кимчелеге бар анысы. Үзе генә дип, бәлки, аны Баязит та искәргәндер... Кем белә, кимчелек тә түгелдер әле ул: корсак өлеше бераз салынып тора аның. Бала тапканнан соң шулай булып калды. Корсагына массаж шикелле нәрсәләр дә ясап карамады түгел, ясады. Матавыклануы шуның хәт-

ле генә булдымы, эч тирәсендә әллә ни үзгәреш сизелмәде. Зур түрәләр, аларның хатыннары гына йөри торган махсус хастаханә табибларына да барып күренде. Нишләптер файдасы гына булмады.

Зөлхәбирә, корсагын эчкә җыеп, кулы белән баскалады. «Марҗа хатыннары шикелле симез булсаң, бер хәл иде»,— дип көрсенде ул. Нәселе юка, ябык нәсел югыйсә. Ашап кына тазара, симерә торган түгел. Әнисе шундый иде. Апасы шулай. Бу тәгаен Колыма тәэсире инде... Колыманы кинәт исенә төшерүенә үкенеп куйды Зөлхәбирә.

Телефон шылтырады.

Зөлхәбирә, халатын тиз генә киеп, телефон трубкасын алды.

— Баязит?!

— Зөлхәбирә Кәбировнамы? — диде трубкадагы көр тавыш.

— Әйе,— диде Зөлхәбирә шөбһәләнеп.— Кем әле бу?

— Полковник Зәйдуллин борчый сезне,— диде көр тавыш.— Тиз генә җыеныгыз да урамга чыгыгыз. Анда сезне машина көтә. Баязит Хөббетдиныч авариягә юлыкты... Борчылмагыз...

— Ул исәнме? — дип кенә әйтә алды Зөлхәбирә. Аякларының җегәре китте.

— Исән. Куркыныч түгел. Сезне сорый...

—Исән... Исән... Мин хәзер...— дип сөйләнде Зөлхәбирә.

— Сезне урамда майор Харрасов каршы алыр,— диде көр тавыш һәм нигәдер урысча өстәде: — Побыстрей, пожалуйста...

— Хәзер... Хәзер...— диде Зөлхәбирә.

Ул трубканы урынына куйды да беравык ни эшләргә белмичә торды.

— Әле генә шылтыратты бит... Бая гына... Ниткән авария ди тагын? — Зөлхәбирә, шулай сөйләнә-сөйләнә, халатын салды да күлмәк кия башлады.

Бүген нидер буласын күңеле сизенгән иде шул.

Зөлхәбирә, киенеп беткәч, малайларын уятыргамы-юкмы, дип икеләнә калды. «Төнлә пес итәргә чыксалар... Минем юклыкны күрсәләр... Куркулары ихтимал...» дип уйлады ул. Һәм олы улын булса да уятырга дигән карарга килде...

Бикле ишекне эчтән Айрат ачты. Шәп-шәрә Вәсилә Сәхәбетдиновнаны Австралиядә куып җиткән малайның үзен вакытсыз уятканга ачуы килгән иде. Ул, күзләрен ачмыйча гына:

— Нәрсә кирәк? — диде.

— Улым, Айрат,— дип, йомшак тавыш белән дәшәргә тырышты Зөлхәбирә.— Әтиең больницада. Мин хәзер шунда киттем. Телефоннан шылтыратып хәлегезне белешеп торырмын, яме?!

— Ладно,— диде малай, сүзнең ни турында барганын да чамаламыйча.

— Ишекне бикләп кал, улым...

— Ладно.

Теләсә нинди чит-ят кеше үтеп керә алмый торган подъезд ишеген ачып, Зөлхәбирә төнге урамга чыкты. Аны, полковник Зәйдуллин искәрткәнчә, бер милиционер егет көтеп тора иде.

— Майор Харрасов мин. Кисәткәннәрдер?! — диде милиционер.

— Әйе,— диде Зөлхәбирә. Ул, туктап тормыйча, күзенә шәйләнгән җиңел машинага таба атлады.

Машина милициянеке түгел иде.

Майор Харрасов, арткы ишекне ачып, Зөлхәбирәне эчкә уздырды. Үзе аның янәшәсенә утырды.

«Уеннан уймак»ның шушы өлешенә җиткәч, Ләис Зөлкарнәй:

— Нишләп Ркаил Зәйдуллин — полковник, ә мин майор гына? — дип, чын күңеленнән үпкә белдерде (Ләиснең чын фамилиясе — Харрасов).

— Беренчедән,— дидем мин,— үзең беләсең, полковник Зәйдуллин да, майор Харрасов та — әдәби геройлар. Уйлап чыгарылган персонажлар, ягъни мәсәлән. Икенчедән, Ркаил Зәйдуллинның милициядә әшнәләре күбрәк, шулар аның чинын күтәрергә ярдәм иттеләр... Хәер, синең дә ул тирәдә дус-ишләр шактый бугай: әйтеп кара үзләренә, бәлки, сине дә полковник дәрәҗәсенә күтәртерләр... Һич югында, Ркаил Зәйдуллага мөрәҗәгать ит, ул булышыр, бәлки?! Миннән соң бу әсәрне ул дәвам итәсе бит... Ә хәзергә — бигайбә!..

Шофер егет янындагы урынга күн куртка якасын күтәреп куйган бер ир-ат чүмәшкән иде.

— Кайсы больницада ул? — дип сорады Зөлхәбирә.

«Күтәрелгән яка» дәшмәде.

«Ишетмәде, ахры» дип уйлады Зөлхәбирә.

— Баргач — белерсең,— диде майор Харрасов. Нигәдер аның тавышы бу юлы төксе яңгырагандай тоелды. «Баязит өчен борчыладыр...»

Машина кузгалып китте.

## 5

Сүз сөреше кинәт үзгә төсмер алды.

— Синең этиең теге заманда НКВД начальнигы булган икән...— диде Луиза һәм, касәдәге кофены уртлаган булып, Баязитка күз кырые белән генә карап алды.

— Ә син... каян беләсең? — Баязит имәнеп куйды.

— Мин күрәзәче бит. Миңа тегеннән...— Луиза имән бармагы белән өскә ишарәләде: — Хәбәр итеп торалар...

— Шаяртмале. Каян белдең? — диде Баязит.

Әтисенең НКВДда эшләгәнлеге турында хәтта Зөлхәбирә дә хәбәрдар түгел иде бит.

— Әйттем ич инде, күрәзәче мин, дидем...

— Сәер... Нәрсәдер яшерәсең инде әллә, Лулу?

— Юк. Синнән нәрсә яшерим соң мин?! Беркөнне үзең саташып сөйләнгән идең. Хәтерлисеңдер бит, бик каты салып килгән идең. Ботинка бауларыңны да чишеп тормыйча, мине софага өстерәдең...

— Булгандыр инде,— диде Баязит, хәтеренә берни дә төшерә алмыйча.— Ул көнне ярыйсы гына эчәргә туры килде шул... Шиһаповның туган көне иде...

— Әле син минем теге зәңгәрсу күлмәкне дә ерттың.

— Ярар, узган эшкә — салават,— диде Баязит. Ул өстәлчектәге рюмкага эчемлек агызды.

— Күлмәкне ертып, күкрәкчәне салдырдың да гырлап йокыга да киттең...

— Ярар инде, ярар,— дип, Баязит кулын селтәде дә рюмкадагы коньякны эһ тә итмичә йотып куйды.— Алып бирермен берәр күлмәк. Тегесеннән дә матуррагын... Саташканда, тагын берәр нәрсә сөйләмәгәнмендер бит?

—Юк. Ә-ә-ә... теге нәмәстәңне Колымада туган, дидең бугай. Әллә атасы шунда Колымада булган инде...

— М-м-м-да-а... Байтак нәрсәләр ычкындырганмын икән.

— Ычкындырганмын икән, дип, аңа артык борчыласы юк инде. Заманасы шундый булган ла: кемдер саткан, кемдер аткан...

— Минем этиатмаган да, сатмаган да,— диде Баязит, чарасыздан бичара дигәндәй.

— Ә минекен атканнар,— диде Луиза.

—М-м-м-да-а...— диде Баязит.

Кинәт урамда көчле шартлау тавышы ишетелде. Шул ук вакытта бүлмәдә телефон шылтырады.

— Нәрсә шартлады анда? — диде Баязит, тәрәзәгә таба борылып.

— Кооператорлар киоскысы. Рэкетерлар эше. Ике көнгә бер шартлатып-яндырып торалар аны...

Луиза өзгәләнеп шылтыраган телефон трубкасын алды. Баязит, кулын селкеп, аңа «Мин — юк!» дигән ишарә ясады. Әйтерсең лә аның монда икәнен белүчеләр бар.

— Әйе, мин. Яхшы. Аңлашылды. Яхшы,— диде Луиза, бик җәелеп сөйләшәсе килмичә генә.

— Кем булды ул? — диде Баязит, Луиза трубканы куйгач.

— Әй лә, бер подругам шунда! — Луиза исе китмәгән кеше сыман кулын селтәде. Үз-үзен тотышыннан сизелеп тора: ул Баязиттан нидер яшерә иде.

— Подругалар белән алай коры сөйләшмиләр инде,— диде Баязит һәм Луизага сынап карады.

— Аның миңа бирәсе байтак бурычы бар иде. Шуны иртәгә бирермен, ди. Бурычын вакытында кайтармаган кеше белән чөкер-чөкер килеп сөйләшмәм бит?! Хәтта ул иң якын подругам булса да...

— Бирәм, дигәч, сөйләшсәң дә ярый...

— Бирде ди. Көт, чираттагы алдашуы...

— Нәрсә, әллә аның тавышы катымы? Ирләр шикелле сөйләшә...

— Ничек ирләр шикелле?

— Син сөйләшкән чакта миңа да ишетелгәнгә күрә әйтәм...

— Әйе. Тавышы калын аның. Сигаретны авыздан төшермичә тартсаң, аракыны су урынына эчсәң... Минеке дә шулай булыр иде...

— Син дә кимен куймыйсың анысы. Ләкин синең тавыш саф, мөлаем...

— Комплементың өчен рәхмәт.

Луиза, трюмодан фильтрлы сигарет алып, аны алсу иннек мул сыланган иреннәре арасына кыстырды да зажигалка кабызды. Аннары төтенне эчкә тирән итеп суырды. Бераз авызында тоткач, иреннәрен бөрештереп, аны кире чыгарды: зәңгәрсу-аксыл түгәрәкләр түшәмгә күтәрелде...

Баязит тагын өенә шылтыратып карарга булды.

— Кемгә шылтыратасың? — диде Луиза. Аның авызыннан янә зәңгәрсу түгәрәкләр бөркелеп чыкты.

— Өйгә.

— Кассетаны куйыйммы?

— Кирәкми. Мин бу юлы аэропорт начальнигы кабинетыннан шылтыратам.

— Ә-ә-ә... Шулай дисәң генә...

— Сөйләшмичә тор, яме,— диде Баязит һәм трубкага

дәште: — Алло! Алло! Зөлхәбирә! Алло, дим! Әллә йоклап киткән инде. Алмый.

— Киткәндер шул. Сине көтә-көтә көтек булгандыр да киткәндер... Сөяркәсе янына...

— Дәшми тор әле, Лулу! Алло, Зөлхәбирә! Алл... Ә, синмени бу, улым. Әниең йоклыймы әллә? Ә? Кая китте дисең? Больницага? Черт! Анда ни калган аңа? Минем янга? Мин бит... Мин бит больницада түгел! Кайсы больницага китте? Әйтмәдемени? Черт! Ладно. Өйдә генә торыгыз...

Баязитның маңгае тагын шабыр тиргә баткан иде.

— Черт! Тегеләр! Тагын тегеләр! Алдап чакырткан булырга тиешләр...

Аның куллары калтыранды.

— Нишләп алай уйлыйсың? — диде Луиза.— Бәлки, сөекле нәмәстәң синең кебек ял итәдер... Аның да бит кайбер нәрсәгә сусый торган нәрсәсе бар...

Баязитның Луизага ачуы кабарды.

— Җитте, дим, Лулу! — дип кычкырып җибәрде ул.

— Кычкырма. Күршеләрне куркытырсың,— диде Луиза тыныч кына.

— Курыксыннар! Миңа гына куркырга димәгән...

Баязит ике кулы белән башын тотты.

«Тегеләр! Тегеләр эше генә!» дигән уй бәргәләнде аның башында.

Саб-бакылар! Ник алындым мин бу эшкә? Аларның тасма телләренә ник ышандым? «Син генә булдырасың, синнән башка кеше юк!..» имеш... Хәзер алар мине тереләй җиргә күмәчәкләр. Күмәчәкләр. Өскә менеп бииячәкләр. Ике дә уйламаячаклар. Чөнки мин бүтән кирәк түгел аларга. Сукылар! Үз кулым белән үземне үтерәләр. Хатын күпме тукыды. Алынма, диде. Түп башына утыртачаклар сине ялган дусларың, диде. Сукы! Сукылар! Алар өчен курчак булачагымны чамаладым бит югыйсә. Кем гаепле? Үзем! Хәзер үкенеп ни файда? Ни файда хәзер үкенеп? Яндыралар, тәки терелэй яндыралар... Саб-бакылар... Теге йортны — аларга, бу ресторанны — аларга... Приватизация! Үлсәң — үл, булыш, имеш... Сукылар!.. Без сиңа ярдәм иттек, син безгә ярдәм ит!.. Кабахәтләр!

Нишләргә?

Нишләргә??

Нишләргә???

Зөлхәбирә! Ул кайда икән, ни хәлләрдә икән?

Баязитның башы гөжли.

Луиза дәшми. Сигарет төтәтүен белә. Сукы. Ул да сукы. Баязит та сукы. Бөтен кеше сукы! Дөньясы да сукы, кабахәт!

Кинәт ишек тарафында кыңгырау чылтырады. Ул да булмады, ишекне ярсып дөбердәтә башладылар.

—Тегеләр... Тегеләр бу...

Баязитның күз аллары караңгыланды. Әллә каян еpактан Зөлхәбирәнеңме, Луизаныңмы шаркылдап көлгәне ишетелде...

## Әчтерхан чикләвеге

*(Бүләк яхтаның төбен карамыйлар)*

Ләбиб Лерон төш күреп ята иде. Саташа да иде бугай. Саташуын шуннан чамаларга мөмкин иде: әле боргалана, әле ниндидер сүзләр быдырдый, кайбер сүзләре аңлашылган да сыман... «Чайкала! Чайкала!» диме, әллә «Чайпала! Чайпала!» диме шунда. Хәер, ул күргән төшне син күрмәгәч, аның нидән гасабиланганын каян беләсең инде...

...Мөштәри урамындагы Язучылар йортында урнашкан «Салават күпере» журналханәсенә Ләбибнең, гадәттәгечә, эшкә килеше, имеш... Гадәттәгечә, таң тишегеннән. Ул шулай өйрәнгән: бүлмәдәшләре килеп җиткәнче, язасы-сызасы эшләрне әтмәлләп өлгерергә тырыша. Гадәттәгечә, Язучылар йорты ишегалдында аны җанлы киез катаны хәтерләткән биш-алты кара-сары әнчек, рәхәтләнеп чәңгелдәргә дип, түземсезләнеп, дүрт күз белән көтеп тора... Әкият-мәкиятләрендә сөеп-яратып язгаласа да, Ходай биргән гомерендә эт-фәләнне җене сөймәгән Ләбиб, әнчекләргә ыргытырдай ризык-мазары булмаган буш кесәләрен капшаштыргалап, гадәттәгечә, шүрли-шүрли генә аякларын алга таба кыймылдата. Гадәттәгечә, беркөнне сакаллы, икенче көнне сакалсыз килгән бу саран адәмнән сыңар ипи валчыгы да тәтемәячәген өч көн алдан сизенгән «киез каталар», җирдән метр ярым өскә сикергәли-сикергәли, Ләбиб мескенне һәрьяктан кысрыклап та өлгергәннәр... Гадәттәгечә, «киез каталар»ның бер сыңары — үтә дә явызы — Мәдинә Маликова фондына ярдәм сорап килгән бер түтәйнең һәм «Салават күпере» журналханәсенә сугылган рәссам Юрий Денисовның Язучылар йортына бүтән мәңге аяк атламаслык итеп ботларын тешләгәне — галәмәт тә нык котырына, әшнәләренә карап ымлый: «Менә миннән, абзагыздан үрнәк алыгыз!» — дигәндәй, сальто-мальтолар да ясап ала, имеш...

Өеннән тәм-том ташып әнчекләрне үзенә ияләштергән тетя Гашаны исенә төшерә дә Ләбиб: «Тетя Гашага әй-

теп, иманыгызны укыттырам мин сезнең, сабакылар!» — дип уйлый...

Бу мизгелләрдә Ләбиб фәкыйрьнең хәл-әхвәле бүтән көннәргә караганда да аяныч, имеш... Шулчак искитмәле хәл була... Әле генә гайрәт чәчеп адарынган әнчек тәреләр, бата башлаган корабтан котылырга теләп чабышкан күселәрдәй, кайсы кая шыла, югала. Хәвеф-хәтәрсез котылуына сөенергә дә, җиңел сулыш алырга да өлгермәгән Ләбиб, Язучылар йортының сул канатында урнашкан «Идел» журналханәсе бинасына карап, кинәт, янә шүрләп, баскан урынында катып кала, имеш...

Башта иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып, пышылдатып, аннары кычкырып җибәрә Ләбиб:

— Чайкала! «Идел»ләр чайкала!

Чыннан да, «Идел» журналханәсенең бинасы, көчле штормга юлыккан җилкәнсез корабтай, уңга-сулга чайкала, имеш...

— Чайкала-а-а! Чайкала-а-а!..

Ләбиб әле бармаклары, әле йодрыклары белән күзләрен угалый, «Бәлки, төш кенәдер, өн түгелдер бу?!» дип уйлый, имеш...

Күзләрен бер ачып, бер йомып карый — бина чайкала... «Әллә үзем чайкаламмы соң?» — дип уйлый, имеш, Ләбиб. Гәүдәсен, кул-аякларын тотып карый — юк, үзе чайкалмый шикелле. Ләбиб, үзе чайкалмаганга сөенеп, бинага карый — чайкала бина, чайкала, нәгаләт!

— Яп-яланаяк! — дип кычкырып җибәрә Ләбиб.— «Идел»ләрнең Бурсык исемле сөекле мәчеләре шундадыр бит?! Җыештыручы Мәйсәрә апа килгән булса, ул да тәгаен шунда?!

«Коткарырга кирәк үзләрен!» дип уйлый Ләбиб. Ул, өтәләнеп, өч-дүрт адым атлый да икеләнеп дигәндәй туктап кала. «Мәче ул, хәвеф-хәтәрне сизеп, алдан ук бәла буласы җирдән тая торган җан иясе,— дип уйлый-фараз кыла Ләбиб.— Хатын-кызга килгәндә... Алар любой положениедән чыгу җаен табалар... Тем более Мәйсәрә апа... Димәк, ноу проблем!»

Ләбиб, авыр мәсьәләне җиңел чишкән өченче сыйныф баласы шикелле куанып, канәгать елмаеп, тирә-юньгә карап ала. Шуннан соң ул:

Идел бит ул, Идел бит ул,
Идел бит ул киң бит ул... —

дип, җеге җеккә килмәгән ниндидер бер ят көй көйлекөйли, милли төсебез булган яшелнең яшелсезенә буял-

ган тимер ишекне акыртып елата-елата ача да Язучылар йортының эченә уза, имеш...

...Ләбиб үткән-сүткән һәрбер кеше борылып карап китә торган тәрәзәсеннән тыштагы әнчекләргә йодрыгын күрсәтте дә кулкуйгычының почмак башы ашалып беткән кәнәфиенә чүмәште. «М-м-да-а, бүген күргән төшне нәрсәгә юрарга икән инде?» дип уйланды ул. Шактый уйланды.

Шуннан соң Ләбиб, җитди бер карарга килгәндәй, урыныннан торды да «Идел»ләрнең хәл-әхвәлен белергә ашыкты...

* * *

...Әчтерхан каласыннан көтмәгәндә килеп ирешкән телеграмма-хәбәр «Идел» журналханәсендә эшләүче барча хезмәткәрләрне гаҗәпкә калдырды. *«Хөрмәтле дуслар! «Идел» журналының чыга башлавына ун ел тулу уңаеннан әчтерханлылар Сезгә яхта бүләк итә. Игелеген күрегез. Яхта бүген Казан елга портында булачак!»* диелгән иде әлеге телеграммада.

Куанычның иге-чиге юк иде. Һәркемнең яхтаны тизрәк барып күрәсе килә. «Журналханәнең көндәлек эшен җәһәт кенә тәмамлыйбыз да елга портына китәбез»,— дип мәш килеп, ашыгып-кабаланып йөргән арада хезмәттәшләре Әчтерхан кызы, баш мөхәррир урынбасары Роза Кожевникова-Баубекованы да мактап, аңа рәхмәтләр яудырып алырга онытмадылар. Моңарчы үзләрен Роза еш авыз иттергән Әчтерхан балыкларын да, шомырттай эре кара уылдыкларны да искә төшерделәр.

Баш мөхәррир Рашат Низами да, форсаттан файдаланып, Розага коллектив исеменнән рәхмәт әйтте.

— Заманалар әйбәтләнеп, хезмәт хакларын вакытында ала башлагач, шактый күләмдә акчалата бүләк тә бирербез әле, бәлки, үзеңә,— диде ул, сүзләрен кулларының кискен-кискен хәрәкәтләре белән җөпләп-куәтләп.

Көчле кул чабулар астында үзләренең дә Әчтерханда тумаганнарына кайберәүләр эчтән генә үкенеп куйды.

— Рашат Мияссәрович, акчалата бүләк бирү турында дөрес әйттегез. Роза моңа бик лаек! — дип, баш мөхәррирнең сүзләрен гамәли хезмәткәр тетя Гаша да җөпләде.

— Фикерегез өчен рәхмәт, Гәүһәрия апа. Хәзер мин ашыгам, эшем күп. Барып киләсе җирләр бар,— диде баш мөхәррир. Аннары ул үзенең беренче урынбасары Рәфикъ Юныска карап эндәште: — Рәфикъ, елга портына баруны оештыра торыгыз. Мин хәзер кайтам. Гәүһә-

рия апа, Рәфикъка оештыру мәсьәләләрендә булышырсыз, яме.

Рәфикъ Юныс: «Ярар, Рашат, оештырырбыз»,— димәкче генә иде, тетя Гаша-Гәүһәрия өлгеррәк булып чыкты:

— Барысын да уңай хәл итәрбез, Рашат Мияссәрович. Борчылмагыз, Рәфикъ Юнысович белән бергәләп оештырырбыз! Шулай бит, Рәфикъ Юнысович!

Баш мөхәррирнең беренче урынбасарына:

— Әйе, шулай, Гәүһәрия апа,— диюдән бүтән чара калмады...

Рашат Низами китүгә, хезмәткәрләр янә тыз-быз килә башлады. Тетя Гаша: «Ләис, Ләис!» дип, коридор башында Марат Закир белән сигарет төтәтә-төтәтә, көлешә-көлешә гәпләшеп торган Ләис Зөлкарнәйне эзләп китте...

— Нишләп тыз-быз киләсез? Бер-бер хәл булмагандыр бит? — дип сорады «көфер почмагы»на тетя Гашадан алдарак килеп җитешкән Ләбиб Лерон. Ул янә үзенең кечәге төшен искә төшереп алды.

Марат Закир «Безгә...», Ләис Зөлкарнәй «...яхта...» дияргә өлгермәде, тетя Гаша, Ләбибкә илтифат итмичә генә, Ләискә карап:

— Сөйләшеп торырга вакыт юк, Ләбиб. Бүген безгә Әчтерханнан яхта хәтле яхта килә. Бүләк итеп җибәргәннәр! — диде. Аннары, Ләбибкә карап, Ләискә дәште: — Сөйләшәсе сүз бар иде, Ләис. Әйдәле, Азнакайдан факс...

Ләис, әле генә кабызган сигаретын чүп савытына ташлап, тетя Гашага иярде.

Аңлашылды. Ләбибкә төш юрыйсы калмады.

Бу вакытта Рәфикъ Юныс җаваплы сәркатип Роза Шәрәфиева бүлмәсендә журналның яңа санына нинди язмалар җитешмәве белән кызыксына иде. Аннары ул, бүтән бүлмәләргә кереп, хезмәткәрләргә таләпчән фәрманнарын биреп чыкты. Шуннан соң ул елга портына бару мәсьәләсен хәл итәргә керешге...

Баш бухгалтер Альберт Сөләйманов бүлмәсе тирәсенә якын килерлек түгел иде. Бүлмә эчендә дә, коридорда да акча-фәлән, гонорар сорап йөрүчеләр мәш килә. Баш бухгалтер: «Акча юк бит әле. Барасы җир бар иде»,— дип тәкрарлап торса да, берсенең дә китәсе килми, барыбер нәрсәдер өмет итәләр.

Элекке даһи юлбашчыбыз Ленин берьюлы әллә ничә эш башкарырга сәләтле булган, диләр. Хактыр. Моның шулай икәнлегенә Альбертка карап та ышанырга мөмкин. Кайчан күрсәң дә, аның бер колагында телефон булыр. Үзе сөйләшә, үзе нидер яза, үзе йомыш белән керү-

чене тыңлый, елмая. «Бензинга да акча юк»,— дип, гамәли хезмәткәр Резидә Әхмәтҗанова әзерләп алып кергән ниндидер исәп-хисап кәгазьләренә кул куя...

«Идел»нең баш рәссамы Фәридә Хәсьянова җаваплы сәркатип белән Рәфикъ Юныс бүлмәсенә кереп чыкты да, чираттагы сан өчен бик тә ашыгыч кирәк булган фотосурәтләрнең кайдалыгын белергә теләп, кемнедер эзләп китте. Кемнедер, дип... Әлеге дә баягы Ләисне инде... Азнакай спонсорларының фотограф Альберт Тәхәвиев төшергән сурәтләре бары тик Ләистә генә булырга тиеш!..

Һәрчак ашкынган, ашыккан Ркаил Зәйдулла эшкә төш вакытында ук кабаланып килеп җитте дә төгәлләнеп бетмәгән күләмле бер язмасына тиз генә нокта куйды. Шуннан соң эшкә килешли киосктан сатып алган калын бер гәҗитне тәмләп «йотарга» тотынды.

Озак вакыт та үтмәде, коридорда пәйда булды ул.

— Елга портына кайчан барабыз? — дип сорады Ркаил Рәфикъ Юныстан.

— Рашат кайтуга китәбез, Ркаил. Монда гына бул! — диде баш мөхәррирнең беренче урынбасары.

— Әйтергә онытмагыз,— диде Ркаил һәм коридор башында тәмәке көйрәтүчеләр янына таба атлады. Бераздан аның яңгыравык вә көчле көлү тавышы ишетелде.

— Ркаил, әллә кичә үк килгән идеңме эшкә? — дип каршы алды аны Ләбиб.

Журналханәнең Бурсык исемле мәчесе, Ркаил Зәйдулланың көлү тавышыннан исәнгерәпме, әллә башка сәбәп беләндерме, кай тарафка барырга белмичә үрсәләнеп йөри-чаба башлады...

Ниһаять, баш мөхәррир Рашат Низами, ашыгыч эшләрен тәмам хәл итеп, журналханәгә кайтып җитте.

— Барыгыз да әзерме? — дип сорады ул, үзен түземсезләнеп көтеп торучыларның һәммәсенең дә терекөмештәй ялтыраган күзләренә җәһәт кенә карап.

— Әзер, Рашат Мияссәрович, барыбыз да әзер. Ләис тә, Марат Закир да, Нәгыйм дә монда. Ркаил да монда инде! — дип, һәммәсе өчен җавап бирде тетя Гаша.

Тетя Гашаның аякларына сырпаланып торган Бурсык, Ркаил исемен ишетүгә, бер як читкә тайпылды да як-ягына каранып алды.

— Яхшы. Киттек алайса,— диде баш мөхәррир.— Тик, җәмәгать, үзегез беләсез, барыгыз да «Волга»га сыймаячак. Альбертның «Нива»сына да өчегез генә эләгер. Калганнарыгызга үз хутыгыз белән барырга туры килер. Рәфикъ, Гәүһәрия апа һәм Фәридә, әйдәгез, сез — «Волга»-га! Кампитрчы кызларыбызга «Волга»ны кире җибәрәм.

Калганнарыгыз үзара хәл итегез. Елга портында очрашырбыз. Киттек!..

Киттеләр. Ркаил Зәйдулладан кала барчасы да елга портына килеп җитте. Ркаил Язучылар йорты китапханәсенә яңа гәҗит-журналлар алырга дип килгән язучы Ризван Хәмид белән сөйләшеп калган булып чыкты.

Бераздан аларның да килгәннәре күренде.

— Менә син, Ркаил, «тибен тибү» дигән сүзләрен ничек аңлыйсың? — дип сорады Ризван Хәмид һәм, белмисең дигәндәй, хәйләкәр елмайды.

— Ха! — диде Ркаил.— Кар астыннан тибенеп үлән табу! Шул мәгънәне аңлатамы?

— Беләсең икән, афәрин! — диде Ризван Хәмид.

— Белмәскә! Ә менә син, Ризван абый, әйтеп кара, «көчегән» нәрсәне аңлата?

— Бөркет! Дөресме?

Икесе дә дәррәү көлеп җибәрделәр.

Алар үзләрен көтеп торучылар янына килеп җиткәннәр иде инде.

— Безнең яхта кайда соң? — дип сорады Ркаил янәшәсендә басып торган Рәфикъ Юныстан.

— Күрмисең мәллә? — диде Рәфикъ Юныс, башы белән күк йөзенә таба ишарәләп.

Күк йөзендә эленеп торган галәмәт зур вертолет трослар белән эләктерелгән яхтаны порттагы махсус җайланмага төшереп куярга азаплана иде.

— Әчтерханнан ук шушы вертолет алып килгән,— дип әйтеп куйды Нәбирә Гыйматдинова, белмәсәң бел дигәндәй.

Шулай диде дә Нәбирә, өенә кайткач яза башлыйсы яңа повестенең сюжет-эчтәлеге хакында уйлануын дәвам итте.

— Әчтерханнан су аша гына кайтып була бит югыйсә. Нәрсә, әллә төбе юкмы яхтагызның? — диде Ризван Хәмид, Ркаилгә карап.

—Мин каян белим. Синең белән әле генә бергә килдек бит,— диде Ркаил.

— Төбе бар икәне күренә,— диде Марат Закир, йөзенә бик белдекле кыяфәт чыгарып.— Бик җиңел сыман әле бу яхта, мотор табарга туры килмәгәе!

— Мотор гына табасы булса — ерунда! — дип, сүзгә кушылды Нәгыйм Шаһи.— Минем бер таныш бар. Әйтсәң, моторны җир астыннан табып бирәчәк.

— Аңа бит акча түлисе буладыр? — дип, сораулы карашын Нәгыймгә текәде баш бухгалтер Альберт Сөләйманов.

Нәгыйм сәерсенеп аңа карады:

— Менә тиле! Бушка кем бирсен инде сиңа мотор хәтле мотор!

—Егетләр, сөйләшмәгез әле! — дип кискен генә әйтеп куйды Рашат Низами.

«Да-а,— дип уйга калды баш бухгалтер,— кайдан акча табасы булыр инде?»

Ниһаять, ничек итсә итте вертолет, тәки яхтаны махсус җайланмага куя алды.

— Яхтасы ярыйсы гына күренә моның,— диде Рәфикъ Юныс.

— Сез бик дөрес әйттегез, Рәфикъ Юнысович,— диде тетя Гаша, яхтадан күзләрен алмыйча гына.

— Эченә кереп карамыйча, берни дә әйтеп булмый әле, җәмәгать! — диде баш мөхәррир.

— Сез дә бик дөрес әйттегез, Рашат Мияссәрович! Эченә кергәч, бөтенесе дә күренә инде аның,— дип, баш мөхәррирнең сүзләрен хуплады тетя Гаша.

— Май чүлмәге тышыннан билгеле! — диде Ркаил һәм портны яңгыратып янә көләргә тотынды...

Вертолет китәргә дә өлгермәгән иде әле, әллә каян гына шагыйрь Мөдәррис Әгъләм килеп чыкты.

— Моны кеше итәргә була әле! — диде ул, яхтага бер күз төшереп алуга.

—Кеше түгел инде, Мөдәррис абый, яхта, диегез! — диде гамәли хезмәткәр Гөлсинә Хәмидуллина, кулындагы көрән сумкасы эченнән нидер эзли-эзли.

—Барыбер инде,— диде Мөдәррис Әгъләм,— йөзәргә өйрәтсәң, кеше дә йөзә, вакыты җиткәч, яхта да үлә!..

Һәммәсе яхта янына ук якын килде. Яхтага орынгалап, кагылгалап алдылар, астын тикшергәләделәр, өстенә менделәр, анда-монда кереп чыктылар.

Җентекләп тикшерә торгач, шул ачыкланды: чыннан да, яхтада мотор дигән нәмәрсәкәй юк икән! Шулай да байтак кына прибор-мрибор, шөреп-мөреп юклыгын, ишек-утыргыч ише нәрсәләрнең җитешмәгәнлеген, берничә урында тишек-мошык барлыгын, буярга-сыларга туры киләчәген исәпкә алмаганда, яхта үзе карап торышка күркәм тәэсир калдырырлык иде.

— Пиратлар эше бу! — дип нәтиҗә ясады Мөдәррис Әгъләм.

— Яхтаны вертолет алып килде бит! — диде Рашат Низами, Әгъләмнең нәтиҗәсе белән килешмичә.

— Алайса, һава пиратлары кыланган инде монда! — диде Мөдәррис.— Хәзер бик нык азындылар алар... Күзгә күренмәгән нәрсәләрне дә чәлдерергә генә торалар...

— Пиратлармы, каракланмы, барыбер монда алып килгән чакта талаганнар инде,— диде тетя Гаша.

Тетя Гашаның сүзләре белән, Мөдәррис Әгъләмнән кала, барысы да килешергә мәҗбүр булды. Чөнки аның күпчелеккә каршы һәрчак үз фикере була.

— Иртәгәдән үк яхтаны рәткә китерергә тотынабыз, җәмәгать,— диде Рашат Низами.— Кирәк-яраклар табу турында сез дә уйлагыз, эшләрем күп булса да, мин үзем дә уйлармын!.. Эштә кешеләр калдырмыйча булмый. Шуңа күрә яхтага чиратлашып килербез. Оештыру эшләре, Рәфикъ, синең карамакта. Мин контрольдә тотармын...

— Яхшы! Аңладык! — диде Рәфикъ Юныс.

— Борчылмагыз, Рашат Мияссәрович. Менә дигән итеп башкарып чыгарбыз,— диде тетя Гаша.

«Акча каян табасы булыр инде» дип борчыла башлады баш бухгалтер һәм тиз генә телефон трубкасына сузылды. Ләкин һавада телефон юк иде. Акча турында гына уйлап башы каткан Альберт, ялгышканын аңлап, һавада эленеп торган кулын җәһәт кенә кәчтүм кесәсенә яшерде.

...Икенче көнне яхтада кызу эш башланды. Егетләр шөреп-мөреп борырга, тишек-мошык ямарга тотынды, кызлар кырасы урыннарны кырырга, сылыйсы җирләрне сыларга кереште.

Рәфикъ Юныс хезмәткәрләргә киңәш биргәләп йөри, үзе дә әле бер эшкә, әле икенче эшкә барып тотына.

Күп тә үтмәде, яхта янына бер үзбушаткыч «КамАЗ» килеп туктады. Кабинадан әлеге дә баягы Мөдәррис Әгъләм килеп төште. Аның артыннан ук тетя Гаша пәйда булды.

— Кирәк-яраклар алып килдек,— диде тетя Гаша һәм шоферга йөкне бушатырга кушты.

Кайда кемдер дача төзи, кайда кайсыдыр мунча сала, шунда Мөдәррис Әгъләм булыр. Менә бит, иренмәгән. Яхтаны рәткә китерешергә дә килеп җиткән.

— Алла ярдәм бирсен! — дип кычкырды ул яхтадагыларга, ничектер өстән аска карап.

— Рәхмәт! Үзеңне дә монда бирсен! — диештеләр яхтадагылар. «КамАЗ» калай ише, такта-мазар шикелле әйберләрне, ишек-урындыкларны бушатты да китеп барды.

— Мотор алып килергә китте,— диде тетя Гаша.

— Ул хәтле калай нәрсәгә? — дип кызыксынды Ркаил Зәйдулла.

— Яхта түбәсен, киңәйтеп, әйбәтләп ябасы булыр,— диде тетя Гаша.— Аннан соң яхтада «Волга»ны куярга

да урын әзерләргә туры киләчәк. Рашат Мияссәровичка, яхтада йөзгәндә, Казанга кайтып килергә машина кирәк булачагын гына чамалыйсыздыр инде?

— Аңлашылды,— диде Ркаил.— Калай эше — Ләис белән безнең эш. Студент чактан ук шабашкаларда фермаларга калай түбә ябып юкка гына йөрмәдек. Ләис, тотындык түбә ябарга!

Алар калай ташыган арада, Мөдәррис Әгъләм бүтәннәргә үзенең эшлекле киңәшләрен, күрсәтмәләрен биреп чыккан иде инде. Техниканы күреп үскән Марат Закирны шөреп сүтәргә, Нәгыйм Шаһины тишек-мошык ямарга өйрәтте. Марат белән Нәгыйм аңа рәхмәт әйттеләр дә, соңга калмагаек дип, калай ташучылар янына ашыктылар. Ярты сәгать дигәндә, калай ташылып бетте.

— Ләис, баягынак калай күп күренгән иде, хәзер нишләптер аз тоела,— диде Ркаил.

—Минем дачам да, йортым да юк, Ркаил,— диде Ләис, бер кәкрәйгән калайны куллары белән турайтырга азаплана-азаплана.

— Бик борчылма, синеке дә булыр әле,— дип тынычландырды аны Нәгыйм.

— Ләискә бирәү җитми аңа, өч-дүрт кирәк. Шулай бит, Ләис. Кстати, каяле, бер тәмәке бир әле,— диде Марат, тузанга, калай тутыгына баткан кулларын кайда сөртеп алырга белмичә.

Ркаил хәлиткеч мизгелләрдә генә файдалана торган мәгънәви вә фәлсәфи күз карашын әле Маратка (ул, җитди йөзенә битараф төсмер өстәп, тыныч кына сигарет төтәтә иде), әле Нәгыймгә (ул бераздан барыбер тузанга тиенәчәк ботинкаларын нигәдер өр-яңа кулъяулыгы белән сөртеп-чистартып азаплана иде) ташлап алды.

Ничек итсә итте Ләис, тәки җәфа калайны турайтты. Ркаил ул турайткан калайга нәүмизләнеп калган карашын төбәде. Әлеге караштан «Минем дә дача бар иде бит югыйсә. Түбәсез сарайны әйткән дә юк. Хәтерсез баш!» дигән уфтанулы уйларны укырга була иде...

Ул арада Мөдәррис Әгъләм, яхта тирәсендә йөри-йөри, аның астына кергәләп-чыккалап, бераз яткалап алып, Рәфикъ Юныс белән үзара бәхәсләшеп тә өлгерде.

— Яхта капитальный ремунттан соң ялт итеп торырга тиеш! — диде Мөдәррис.

— Аны син әйтмәсәң дә беләм мин! — диде Рәфикъ Юныс.

— Белгәч соң! Яхтаның астын күптән буяп куярга кирәк иде инде. Суга төшкәнче кибә торырга тиеш!

— Анда тишек бар. Шуны ямарга кирәк әле башта!

— Тишекне аны теләсә кайчан ямап була! — диде Әгъләм.

Алар, бәхәсләшә-бәхәсләшә, янә яхта тирәли йөри башладылар...

...Яхтадагы эш җитез генә башланса да, атна-ун көнгә сузылды тагы.

Инде эш бетте бугай, дигәндә, әле тегесе, әле монысы кирәк булып чыга торды.

Менә, ниһаять, эшкә нокта куяр көн килеп җитте. Өряңа кебек балкып, ялт итеп торган яшел түбәле яхтага матур, затлы исем генә табасы калды.

— «Иделлия» дип атыйк,— дип тәкъдим итте Ләис Зөлкарнәй.— Шигъри исем! «Идел» дигәне «Идел» журналыннан икәнлегебезне дә искәртеп торачак!..

— Тагын кемнәрдә нинди тәкъдимнәр бар? — диде Рашат Низами. — Бәлки, «Идел» генә дияргәдер?!

—Уйлашыйк әле, җәмәгать, башка яхшырак исем табылмасмы? — диде Нәбирә Гыйматдинова, языласы повестеның тагын бер җөмләсенә нокта куеп.— «Идел» үзе начар исем түгел дә түгелен... Әмма без ул исем белән еш мавыгып, аның тәмен җибәрмик. Кинотеатр да шул исемне йөртә, ашамлык-эчемлек кибете дә, фильтрсыз сигарет та, сыра да, төнге клуб та...

— Бәлки, «Казан» дип куяргадыр? Ни әйтсәң дә, үзебезнең бердәнбер башкалабыз исеме бит...— диде Гөлсирә Гайнанова.

Бик озак бәхәсләшә-фикерләшә, киңәш-табыш итешә торгач, уртак бер фикергә килделәр «Идел» хезмәткәрләре: яхтаны «Идел-Казан» дип атарга булдылар.

Бераздан яхтада әлеге сүзләр балкый иде инде.

— Җәмәгать,— диде шуннан соң баш мөхәррир, һәммәсенең игътибарын үзенә җәлеп итеп.— Хәзер мин сезгә куанычлы хәбәр әйтәм. Без, кайбер иптәшләр белән сөйләшкәннән соң, шундый карарга килдек: ике көннән, ягъни дүшәмбе көнне, Идел буйлап сәяхәткә чыгабыз!

«Ур-ра» диешеп, барчасы дәррәү кул чапты. Хәтта Мөдәррис тә. Бу юлы аның фикере башкаларныкы белән уртак иде.

— Тик, җәмәгать, тагын шунысын да әйтәм: без сәяхәт вакытында ял гына итмәячәкбез, эшләячәкбез дә. Мөдәррис, сиңа да эш табарбыз. Яхтада эш өчен барлык кирәк-яраклар да булачак. Кәгазь-каләм һәм язу машинкалары турында әйтеп тә тормыйм. Сәяхәттән без журналның махсус санын — юбилей санын эшләп кайтырга тиешбез. Аңлашылдымы барыгызга да? Аңлашылса, дүшәмбе көнне яхтада очрашабыз! — диде Рашат Низами...

* * *

...Дүшәмбе көнне «Идел» хезмәткәрләре барысы да бәйрәмчә киенеп килгән иде. Ркаил хәтта малае Баязитны да иярткән. Баязитны күргәч, баш мөхәррирнең сөмсере коелды, әлбәттә.

— Син нәрсә инде, Ркаил,— диде ул.— Әйттем бит инде, без ял итәргә генә түгел, эшләргә дә барабыз...

— Комачауламый ул,— дип акланды Ркаил.— Аннан соң мин аны кайда калдырыйм. Хатын таң белән эшкә чыгып китә, төнгә генә кайта. Балалар бакчасына кем алып барсын да кем алып кайтсын Баязитны. Артыксынсагыз, калабыз алайса...

Рашат Низами йомшарды:

—Ярар, әйдә, барсын! — диде ул.— Кайда соң әле Баязит? Кая югалды?

Ркаил як-ягына карап алды да:

—Яхтага кереп тә киткән инде ул ташбаш малай! — диде.

— Ну, малай! Ну, Баязит! — диде Рашат Низами, башын чайкап. Шуннан соң ул җыйналып торучыларга эндәште: — Затлы яхтабызга утырыштык, җәмәгать! Хәерле сәгатьтә!

...Яхтадагы «Идел-Казан» дигән язудан «н» хәрефе сәяхәт башында ук төшеп калачагын, Ркаилнең малае Баязитның шактый шуклыклар эшләячәген, үзләрен күптөрле маҗаралар көткәнен «Идел»дәшләр үзләре белми иде әле...

*1999*

# Портрет

Фәннәр кандидаты Тәхәвин, гадәт буенча, янәшәсендә йокымсырап утырган олпат гәүдәле Кәшбиевнең (шулай ук фәннәр кандидаты) алга сөрлеккәннән корсагына терсәк белән үз итеп кенә төртеп алырга ниятләгән иде, әмма өлгерми калды. Иске сүс төсендәге сирәк чәчләрен артка таба сыпыргалаштыргалап, чәчәкле кулъяулыгы белән күзлек пыялаларын сөртә-сөртә, Вәгазов галимнәр киңәшмәсен ачып җибәрде...

— Галим иптәшләр! — диде ул.— Барыгызга да мәгълүм: тиздән киң җәмәгатьчелек унтугызынчы йөзнең акыл иясе, атаклы мәгърифәтче Акмал Зөбәрҗәтинең юбилеен зур бәйрәм итеп билгеләп үтәргә җыена. Без, галимнәр, беләбез: Зөбәрҗәти үзе исән чагында сурәткә төшәр-

гә яратмаган. Монда, әлбәттә, диннең роле дә зур булгандыр... Дөрес уйлыйсыз, иптәшләр, мин Зөбәрҗәти диндар кеше булган, дип әйтергә җыенмыйм. Чоры шундый булган, заманы!.. Кыскасы, Зөбәрҗәтинең сурәтен архивлардан эзләү файдасыз икәнлеген барыгыз да төшенгәнсездер дип беләм. Аннан соң, иптәшләр, сезгә бер күңелсез фактны әйтергә мәҗбүрмен: Зөбәрҗәти белән аралашкан яисә аны якыннан күреп белгән зыялы кешеләрдән бүген беркем дә исән түгел! Зөбәрҗәтине соңгы булып күргән кеше, бездәге мәгълүматларга караганда, моннан нәкъ илле бер ел элек вафат булган...

— Нинди зур югалту! — дип әйткәнен сизми дә калды Мисахов һәм маңгай сырларында адашып йөргән берничә тир тамчысын сөртеп алды.

— Әйе, бик кызганыч хәл, әлбәттә,— дип җөпләде аның сүзен Вәгазов.— Ләкин, иптәшләр, нишләмәк кирәк, тормыш бер урында гына тормый, алга бара! Без, галимнәр, моны беләбез һәм бик яхшы аңлыйбыз. Аңлап кына да калмыйбыз, үз өстебезгә бик җаваплы миссияләр дә алабыз. Минем ни әйтергә теләгәнемне кайбер галим иптәшләр төшенгәннәрдер инде: әйе, әйе, озакка сузмыйча, Акмал Зөбәрҗәтинең портретын эшләтергә кирәк!

Вәгазовның һәр сүзен дикъкать белән генә тыңлап утырган берничә галим дәррәү кул чапты. Аларга кисәк кенә йокыдан айнып киткән башка галим-голәмә кушылды.

— Дөрес!

— Ашыкмыйбызмы?

— Күптән вакыт инде!

— Вафатына бер генә гасыр бит әле!

— Портретны алтыннан эшләтергә кирәк!.. — Вәгазов уң кулын күтәрүгә, бүлмәдә тынлык урнашты.

— Галим иптәшләр,— дип, сүзен дәвам итте Вәгазов,— инде хәзер мәсьәләнең асылына килик: башында рәисе мин фәкыйрегез булган юбилейны үткәрү комиссиясе портрет ясауны нәкышче-рәссам Вилһаҗ Әхмәтовка тапшырырга дигән уртак фикергә килде. Сезнең барыгыз да аны бик яхшы белә булыр: җиде ел элек Болгари портретын да ул ясаган иде. Ишетүебезчә, халык портрет тәэсиреннән әле һаман айный алмыйча йөри икән...

— Әхмәтов — талант!

— Кеше сурәтен ясый белми бит ул, аңа бирмәскә кирәк!..

— Әхмәтов — Рембрандт ул!..

— Заказны менә шул Әхмәтовка бирер алдыннан,— диде Вәгазов,— без катгый бер фикергә килергә тиеш-

без: Зөбәрҗәтинең башына чалма кидереп ясау әйбәтме, әллә түбәтәйме? Бәлки, башка төрле баш киеме кидерү мәслихәттер?! Уйлашыйк, иптәшләр...

Вәгазов ашыкмыйча гына урынына утырды да, алдындагы графиннан стаканга су агызып, аны готгылдап эчеп бетерде. Аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торган фәннәр кандидаты Тәхәвин, үзе дә сизмәстән, төкереген йотып куйды.

Галимнәр уйга чумды, бераздан һәрвакыт үз фикерен иң алдан әйтергә яраткан Мисахов тынлыкны бозды.

— Галим иптәшләр! — диде ул, үзен Вәгазовчарак тотарга тырышып.— Безнең уебызча, Зөбәрҗәтинең портретын башына чалма кидереп ясау бүгенге көндә килешеп бетмәс төсле. Гәрчә чалма — халкыбызның ул заманындагы милли баш киемнәреннән саналса да. Чөнки бүгенге яшьләр аны белмәскә мөмкиннәр. Башы авыртканга күрә юеш сөлге ураган икән, дип уйлаулары бар. Безнең уебызча, Зөбәрҗәтинең башына кидерәсе әйберне һәркем — олысы-кечесе танып-белергә тиеш!

— Иптәшләр, Мисахов иптәш хак сөйли,— дип, урыныннан сикереп торды Мурзин.— Кайбер иптәшләр, бәлки, мине дөрес аңламаслар, әмма кайбер иптәшләр мине дөрес аңларлар дип уйлыйм: иптәш Зөбәрҗәтинең башына чалма да, түбәтәй дә кидермәскә кирәк! Ни өчен дисәгез, иптәшләр, аңлатам: без бүгенге көннең бик күп шагыйрьләрен беләбез, безнең арабызда ул халык белән якыннан таныш булган иптәшләр дә бар. Менә шул шагыйрь иптәшләр арасында түбәтәйле бер шагыйрь иптәш бар. Әгәр без иптәш Зөбәрҗәтинең башына түбәтәй кидерәбез икән — соңыннан, портретны карагач, халык аны әлеге шул түбәтәйле шагыйрь иптәш дип кабул итмәсме? Яисә түбәтәйле шагыйрь иптәш үзен ясаганнар дип уйламасмы? Менә шуларны исебездән чыгармаска кирәк, иптәшләр...

Сүзне Тәхәвин алды:

— Минемчә, Зөбәрҗәтигә колакчын бүрек кидерергә кирәк! Ул заманда да колакчын бүрекләр модада булган. Бүген дә без аны яратып киябез. Тик мәсьәләнең бер ягы бар, иптәшләр: бүрек куян тиресеннән тегелгән булырга тиеш түгел. Куян бүрек кидерсәк, халыкта Зөбәрҗәти куркак булган икән дигән фикер калырга мөмкин. Төлке бүрек бармый да бармый инде. Мин иң әүвәл әллә Зөбәрҗәтигә бүре бүрек кидерергә микән, дип уйлаган идем. Әмма уемнан шундук кире кайттым: бүре булган икән Зөбәрҗәти, ач булган икән Зөбәрҗәти, дигән уй калдырырга мөмкин кешедә. Калды бер бүрек — чәшке бү-

рек! Әнә шуны, безнең хөрмәтлебез иптәш Вәгазовныкы шикелле бүрекне кидерсәк, халыкта Зөбәрҗәтигә карата ихтирам, олылау хисе уяначак. Бернинди шикләнүсез әйтергә мөмкин, нинди зур кеше булган икән Зөбәрҗәти! дигән фикер калачак халыкта. Портретны карагач, дип әйтүем. Кыскасы, мин Зөбәрҗәтигә чәшке бүрек кидерү ягында!

Киңәшмә кызганнан-кыза барды. Берәүләр Зөбәрҗәтигә салам эшләпә кидерергә кирәк, диде, икенчеләр каракүл папаха кулай булырга тиеш, өченчеләр кепка йә панама ничек булыр икән, диде...

— Ә ни... ни... нишләп әле без Зө... зө... зөбәрҗәтине яланбаш и... и... итеп кенә ясатмыйбыз? — дип, Кәшбиев тотлыга-тотлыга гына сөйли башламакчы иде, аның авызын өч-дүрт пеләш баш бик тиз йомды...

— Портрет ясауны, бәлки, рәссамның үз ихтыярына калдырырга кирәктер,— дип, тәкъдим сүзе белән чыкты Мисахов.— Ни генә әйтсәң дә, нәкышче-рәссам бит әле ул!

— Шулай итмичә дә булмас! — диде Вәгазов, бөтен сөйләшүгә нокта куеп.

...Галим-голәмә әлеге киңәшмәдән разый булып таралышканга ике ай булды дигәндә, нәкышче-рәссам Вилһаҗ Әхмәтов портретны өлгертеп алып та килде. Зөбәрҗәтинең сурәтен күргән һәркем аһ итте.

— Вәйт, баш та бар икән Әхмәтовта!

— Рәссам дисәң дә рәссам икән Әхмәтов! Молодец! — диештеләр галимнәр...

Рәссам Вилһаҗ Әхмәтов, елмаеп, бер читтә портретын күзәтеп торган мәлдә, Зөбәрҗәтинең рам эчендәге, маңгаеның өске өлеше сыймыйча ясалган башына һәр галим үзенең баш киемен кидереп карый иде...

*1987*

# Кыек Мәтәште гүзәле

Мактанып әйтүем түгел, җәмәгать, дуслар-иптәшләр, оештыруга бик һәвәс, бик маһир кеше мин. Шуңа күрәдер инде безнең Кыек Мәтәште халкы мине бикләр дә хөрмәт итә, минем оештыру сәләтемә дөрес бәһа биреп, «үзебезнең оештыручы Корбангалиебез» дип кенә тора. Халык белми әйтми бит ул, тимбулие безнең Кыек Мәтәште халкы, турысын ярып сала торган халык. Салу, дигәннән, җәмәгать, әлеге дә баягы шул мәгълүм указдан соң... тфү, каһәр, әлеге дә баягы шул мәгълүм указга

кадәр мин үзебезнең Кыек Мәтәштедә атаклы туй алып баручы идем. Шундый да искитмәле итеп башлап җибәрә идем туйны... Ярты сәгатьтән соң халык кем туенда утырганын да оныта иде. Өстәлгә кайнар аш килгәнен түземсезләнеп көтә-көтә күзләр әлҗе-мөлҗе килә башлагач, сүз дилбегәсен кулдан ычкындырмыйча гына мин табындагыларга уен тәкъдим итәм — шешә тәгәрәтү уены. Шуннан соң мәҗлес кыза инде: өстәлнең әле теге башында ду килеп шешә тәгәрәтәләр, әле бу башында бөтереләләр. Халык канәгать, халык дулый, халык аяк тибә, «Яшәсен Корбангали!» дип кычкыра...

Минем шулай оста алып баруым нәтиҗәсендә туйның ахыры аеруча күңелле тәмамлана: кияү белән кәләш берберсен икенче көнне төш вакытында гына эзләп таба торган иде...

Менә шул әлеге дә баягы мәгълүм указдан соң, ялгышларымны тирәнтен аңлаган хәлдә, үз теләгем белән туй алып бару вазифасыннан кәтигәрически баш тарттым, һәм дә килеп, җәмәгать, үземә фырт яңа вазифа таптым. Оештыручы вазифасы. Оештыра белеп оештырсаң, әллә ниләр оештырырга була икән ул, җәмәгать, дуслар-иптәшләр! Иң беренче эш итеп мин үзебезнең Кыек Мәтәштедә «тузга язмаганны сөйләүчеләр» ярышы, ягъни гади генә итеп әйткәндә, «гайбәтчеләр» ярышы оештырдым. Шулай-шулай, мин әйтәм, дуслар-иптәшләр, шушы ярышка актив катнашыгыз, дидем. Җиңүчеләргә колхоз махсус бүләкләр дә хәстәрләде, дип тә өстәдем.

Җыелды, минсиңайтим, халык кәмит карарга... Хөббетдин агайларның иске мунчасы кадәрле клубыбыз шыгрым тулды. Халык гөж килә. Карап торулары күңелле. Ярышта катнашучыларыбыз, берсеннән-берсе уздырып, булырдай хәлләрне булмастайлар белән укмаштырып, чәчләреңне үрә торгызырлык авыл вакыйгаларын халыкның көләргә дип шар ачылган авызына ыргытып кына тора. Халык көлә, халык, чыдый алмыйча, мунча идәнендә, тфү, клуб идәнендә, тартмадан коелган шешәләр шикелле тәгәрәп йөри. Тегеләр, исләре дә китмичә, борчак сибүләрен беләләр...

Колхоз хәстәрләгән бүләкнең кемгә тәтегәнен хәтерләмим, вәләкин ду килгән халыкны күтәрә алмыйча, идәннең ике-өч сайгагы шартлап сынганы, бер матчаның көтүче Сәлахинең киң җилкәсенә гөрселдәп төшкәне әле дә булса истә...

Шуннан соң мин икенче ярыш оештырдым. Бусы тегесенә караганда да әкәмәтрәк булды.

...Бер ярты бирсәгез, керәм, дигән Канау Габдерәүф-

тән башка беркем дә клубка керергә атлыгып тормаганлыктан, «Кыек Мәтәште гүзәле» дигән ярышны авыл читендәге болынлыкта уздырырга булдым. Әлбәттә, бикләр дә һәйбәт иттереп, бөтен шартын китереп, осталардан мәйданчык ясаттырдым. Колхоз акчасына. Сәхнә эшләттердем. Әгәр дә мәгәр ул сәхнәне оча торган тәлинкәгә утырып, Рәсәй буйлап сәяхәт кылган «яшел» әзмәверләр күргән булса, валлаһи, әллә ниләр уйлаган булырлар иде... Кыскасы, оештыруның бу өлеше турында җитеп торыр, күчик төп мәсьәләгә — гүзәлләр мәсьәләсенә...

Үзегез беләсез инде, җәмәгать, дуслар-иптәшләр, авылда хәзер кыз-кыркынны көндез чыра яндырып эзләсәң дә табалмыйсың. Булганнарның да беришесе, мәктәпне тәмамлар-тәмамламастан ук кияүгә чыгып, бала-чагага баткан кызлар, беришесе каладан авылга тамак туйдырырга кайткан кызлар... Шул сәбәпле мин ярышны бераз үзгә итеп оештырдым...

Чакырдым ярышка Кыек Мәтәштенең ялгызак әбиләрен. Баштарак ялындырып маташкан булдылар: килешмәс, фәлән-фәсмәтән... «Колхоз ярышта җиңеп чыккан әбигә бик шәп бүләк хәстәрләде»,— дип, һәммәсенең колагына бүләкнең ни булырга мөмкинлеген сер итеп кенә әйткәч, әбиләр ярышта катнашырга берсүзсез ризалык белдерделәр.

...«Кыек Мәтәште гүзәле» ярышын карарга бөтен авыл халкы җыелды. Колхозның бердәнбер гармунчысы, «Баламишкин»нан гайре бүтән көй шыңгырдата белмәгән Мыштыр Гәрәйҗан менә таралам, менә таралам, дип торган гармун күреген каударланып җәеп җибәрүе булды, болын кадәрле сәхнәгә дүрт карчык тыпырдап чыкты...

Менә шуннан соң башланды инде хикмәтләр... Иң элек шуны әйтеп куйыйм әле: безнең гүзәлләр, телевизордагы гүзәлләрдән аермалы буларак, баерак киемсалымнарны кияргә тырыштылар. Шуңа күрә әллә нәрсәләр өмет итеп килгән берничә картның кәефе шундук кырылды. Ләкин, аларның кәефләре кырылганга карап, тамашабыз сүрелмәде. Язу-сызу халкы әйтмешли, киресенчә, отыры дөрләп китте.

Конкурс шартлары буенча әбиләр башта биеп күрсәтергә тиешләр иде. Менә берзаман тотындылар болар, минсиңайтим, аяк астында йолдыз чәчрәтергә! Мыштыр Гәрәйҗанның «таралам-таралам» гармуны бер җәелде, бер кысылды. «Баламишкин» көенә әбиләрнең дүрт төрле бию биегәннәрен күзәткән халык, көлүнең соңгы чигенә җитеп, мүкәли-мүкәли, чирәм йолкырга кереште.

«Кыек Мәтәште гүзәле»нә беренче кандидат булган Вәсиләттәй үзенең бәби итәкле күлмәгенә үзе ялгыш басты да «залда» чүмәшеп утырган жюри әгъзаларының хәлсез кочагына төшеп чумды... Әле ярый әгъзаларны — аксакалларны — сәхнә авызына терәп үк диярлек утырткан идем. Юкса Вәсиләттәйнең хәлләре мөшкел буласы иде...

«Көлү концерты» тынганнан соң, әбиләрнең аң-белем дәрәҗәләре һәм фикерләү сәләтләре нинди булу белән кызыксындык. Вәсиләттәй бу юлы да безне аяктан екканчы көлдерде. Жюри члены Кыңгыр Сабир агай: «Синең нинди хыялың бар?» — дип сорагач, Вәсиләттәй, телевизордан күргән Казан гүзәле шикелле чатнатып: «Майкалы Җексинны барып күрәсе иде!» — диде. Вәсиләттәйнең җавабын аңлаганы да, аңламаганы да янә, эчен тотып, чирәме йолкынып беткән җиргә ауды да кара туфракка башын бәргәләргә тотынды.

Шуннан соң Кыек Мәтәште гүзәлләре җырулар җырладылар, бәйләм бәйләп, аш-су пешереп күрсәттеләр. Соңыннан жюри членнары үзара бераз әвәрә килгәч, беренче урынны Вәсиләттәйгә бирделәр. Халык гөрләп кул чабарга, «Яшәсен мисс Кыек Мәтәште!», «Вәсиләттәйгә дан!», «Вәйт булдырды!» дип кычкырырга тотынды. Мине дә онытмадылар, колхоз идарәсе каршындагы бакчада үскән аллы-гөлле чәчәкләрне өзеп алып килеп бүләк иттеләр: «Мең яшә, Корбангали! Җир шарында бердәнбер оештыручы бит син!» — дия-дия, сабантуйда батыр калган көрәшчене чөйгән кебек, мине дә күккә чөйделәр...

Пенсия акчасы арткан кешедәй сөенгән Вәсиләттәйнең кулына жюри рәисе Сабирҗан агай җиңү бүләген — ярты кило шикәр белән сыңар кер сабыны китереп тоттырды. Вәсиләттәйнең йөзе тагын да ыграк балкый төште. «Кыек Мәтәште гүзәле» ярышында катнашкан һәм икенче-өченче, шулай ук дүртенче урыннарны бүлешкән әбиләр «Чебурашка» дигән теш пастасына лаек булдылар...

Авыл халкы, гүзәлләр кулындагы бүләкләргә соклану катыш көнләшү хисләре белән караган килеш, бераз кул чапты да Корбангали тагын берәр нәрсә оештырыр әле, без дә бүләк-мазарсыз калмабыз дигән җылы өмет белән өйләренә таралды...

*1989*

# Мин президент булгач...

Сәгать иртәнге җиделәр иде.

Мин президент булдым.

Болай булды бу хәл.

Биксән дүртенче елда алган кызыл матрасны идәнгә җәеп, бабайдан калган толыпны баш астына салып, биш тәңкәлек радиодан «Сүз чәйнибез дә су эчәбез» дигән тапшыру тыңлаштыргалап, «Соңгы хәбәрләр» гәҗите мөхәрриренең «Чуар ыштан — менә дигән әләм!» дигән көлкеле-фаҗигаи язмасын укып ята идем. Кинәт бер бүлмәле фатирымда бер хатын пәйда булды. «Күзләремә күренәме әллә?» дип уйларга да өлгермәдем, кулымдагы гәҗиттән хәрефләр юкка чыкты, радио бытылдаудан туктады...

Әлеге хатын, утлы карашлары белән мине өтә-өтә:

— Бөкәшкин, телисеңме, мин сине хәзер үк президент итәм,— диде.

Минем ярым пеләш башымдагы сирәк чәчләрем үрә торгандай булды.

— Карале, иптәш туташ-ханым, минем фамилияне каян беләсең син? —дидем мин, оекбаштан төртеп чыккан ямьсез бармакларымны матрасның ертык өлешеннән бүселгән кара-кучкыл мамык арасына яшерә төшеп.

— Исемең Хәрамша икәнен дә беләм, Бөкәшкин... Бүлдермә мине. Мин бүлдергәнне яратмыйм,— диде утлы карашлы хатын.— Сорауга җавап бир, президент буласың киләме, әллә юкмы? Теләмисең икән, бигайбә, Бөкәшкин!..

Каты-коты ашап, сәләмә кием киеп, сөрсеп яшәү туйдырган иде, шуңа күрә мин, ике дә уйлап тормастан, катгый итеп:

— Президент буласым килә, иптәш туташ-ханым! — дидем.

Туташ-ханым минем күзләремне иләс-миләсләндереп торган ике күкрәге арасындагы чокырдан көзге сыман нәмәрсә алды да, шуңа текәлеп, үз телендә ниндидер әфсен-төфсен укый башлады:

Керпе-эс-эс... Депе-те-эр...
Чете-бөте... Гөке-чөпе...
Гур-шәй-син-түш... Чүрә-түрә... Һөс!

Һәм мин... президент булдым.

Әле менә халык турында уйланып торам...

Бозылды бит бу халык, бозылды. Бер тиенлек эш эшләгәннәре юк, ә ашарга сорарга беләләр. Беләләр ашарга

сорарга. Радионы борсаң, аннан «Ит кирәк!» дип кычкыралар, телевизорны ачсаң, «Ипи! Ипи!» дип акыралар... Кайсы гәҗиткә күз салма, анда «Чәй бетте! Ярма юк!» дигән сүзләр генә...

Барысын да миннән таләп итәләр. Әйе, әйе, әдәп белән генә сорамыйлар, ә таләп итәләр! Көн саен югары мөнбәргә менеп: «Миңа кадәр булган президентлар ашапэчеп бетергән, минем үземә дә ел ярымлык кына запас калдырганнар!» дип әйтеп-аңлатып карыйм... Юк, аңламыйлар. Халык ул — аңгыра сарык! дип кем әйткәндер, белмим. Мәгәр ул бик белеп әйткән.

Президент булган көннән алып шул халык өчен дип тырышам бит инде югыйсә. Халыкны кайгыртам дип, элеккеге конституцияне карап чыгарга гына елга якын вакытымны сарыф иттем. Җитмәсә, конституциядәге кайбер мөһим статьяларны укырга, аларга шактый гына җитди төзәтмәләр кертергә туры килде. Бер статьяда нокталы өтер тиешле урында түгел иде, икенчесендә бер сызык, бер өтер артык иде. Алып ташладым.

Шулай газапланып, газиз җаныңны фида кылырдай булып эшләгәнеңне халык аңламасын инде. Перәме йөрәк әрни. Нәсел-нәсәптә булмаган хәл — беркөнне чигә тирәсеннән бер бөртек ак чәч тапты хатын. Дөрес, соңыннан ачыкладым ачыклавын: ул ак чәч минем секретарь кызныкы булып чыкты...

Халык өчен дип җан атып йөри-йөри, күптән түгел генә Африкадагы Җәм-Җәм кабиләсендә булып кайттым. Кабиләнең аксакалы Җитез Яланаяк белән ике яклы килешү төзедек. Без аларга нефть бирәчәкбез, алар безгә бамбук таяклары җибәрәчәкләр. Кармак сабына бик шәп икән ул бамбук таяклары.

Сизеп торам, шул бамбук таяклары өчен халык миңа печтек кенә дә рәхмәт әйтмәячәк. Аш биргәнгә таш белән бәрергә гадәтләнгән халыкка тагын рәхмәт әйтү! Әйтте ди! «Тотарга балыгы булмагач, ниемә хаҗәт ул бамбук таягың!» дип, шул затлы таяк белән сыртыңны каезламасалар, бик хуп булырсың...

Әле теге чакта, аппаратка үз кешеләремне туплаган вакытта, ни генә кыланмады халык. Әллә ниткән митинглар оештырдылар, «Бөкәшкинне долой!», «Бөкәшкин — кәбестә бөккәне!», «Бөкәшкин — ата бет!» дип шәрран ярдылар...

Характерым минем тимердән булмаса, баш бүлнистән чыгасы түгел иде. Характерым каты шул минем. Шуның аркасында аппаратка үз кешеләремне куйдырттым да инде. Бер урынбасарым Зайцев, икенчесе Птичкин бул-

ды. Минем указның шифалы тәэсире нәтиҗәсендә Воронов, Медведкин, Крысин һәм тагын берничә дус министр кәнәфиенә утырды. Беркөнне кадрлар бүлеге мөдирен чакыртып әйттем:

— Абрам Исаакович,— мин әйтәм,— мин интернациональ рухта тәрбияләнгән кеше, надан халыкның дөрес аңламавы мөмкин, шуңа күрә штатка җыештыручы алганда, әбизәтелне татар түтиен алырга кирәк. Безнең аппарат интернациональ булырга тиеш! — дидем.

Инде менә янә тоз мәсьәләсе килеп чыкты...

Миңа хәтле булган президентларның берсе — аракыга, икенчесе — шикәргә, өченчесе чүпрәгә каршы бик вакытлы, бик кыстати указ чыгарган иде. Гомумән, һәр президент, ил башы булуга, иң әүвәл халык күңелендә уйнарлык шундыйрак указ чыгарырга тиеш. Бу — борын-борыннан килгән гореф-гадәт. Бу — язылмаган канун. Мин дә, шуңа тугрылыклы булып, тозга каршы указ игълан иттем. Ә халык... Ә халык... Билгеле инде, халык — ахмак. Башта дәррәү указны япладылар, аннары мине сүгә башладылар...

Аларның мине урынсыз сүгүләренә колак салмадым, әлбәттә. Бөтен чараларны эшкә җигеп, тозның зыянлы булуы хакында халыкка аңлату кампаниясен дәвам иттердем. Табиблар «Тоз табан астына утыра», «Тоз — кешенең шәхси дошманы», «Тозлы кеше тозсыз кешедән яманрак» дигән темага гәҗит-журнал саен, радио-телевидениедән ясаган чыгышлары саен тукып тордылар. Җиләк-җимеш, алма-чияне шикәрсез кайнатырга өйрәнгән атаклы пешекчеләр кыяр-помидор, кәбестә ише яшелчәләрне тозсыз тозлау әмәлләрен халыкка тәкъдим иттеләр...

Беркөнне гекечепе фетнәсе вакытында Ак йорт тирәсендә йөргән бер төркем ветераннарны кабул иттем. Бик күркәм кешеләр. Кайсы шул мәгълүм көннәрдә, мылтык күтәреп, патрон эзләп йөргән, кайсы гекечепенең бетәчәген алдан сизгән...

Ветераннарның үтенечләрен канәгатьләндердем: барысына да кибетләрнең арткы ишегеннән чиратсыз кертү хакында кенәгә эшләттердем. Бик күңелләре булды үзләренең. Ширпы кабына салып, һәммәсенә бераз тоз да биргәч, берничә ветеранга инфаркт булды, бер-икесен паралич сукты сугуын...

Хәзер чит илләрдән, әйтик, Молдовадан яки Мордовадан килгән кадерле кунакларны әүвәлге шикелле ипи-тоз белән түгел, ә бәлки Камал театрыннан прокатка алган бутафор чәкчәк һәм кызыл борыч тотып каршылыйбыз. Әлегә кызыл борыч җитәрлек. Ул да бетсә, борычка

каршы яңа указ чыгарырга исәп. Бу хакта урынбасарларга әйттем инде. Алар бу арада указның караламасын хәстәрләү белән мәшгульләр... Академик Әчтерпәчтинскийнең «Борычның милли үзаңыбызга кире тәэсире һәм аннан котылу чараларының юклыгы» турындагы олуг хезмәтен булачак указның нигезе итеп алыгыз, дидем үзләренә...

Менә шул указны халыкка игълан иткәннән соң, тынычланып, чираттагы ялга китәргә уйлыйм. Ни әйтсәң дә, борын төбендә генә август. Үзегез беләсез, август — минем шикелле президентлар иркенләп ял итә торган гүзәл чак. Кем Фороска китә, кем — Рица күленә, кем — Пицундага... Мин үзем һәр ел саен гаиләм белән Кукмарага, Октябрино күле буендагы дачама барып ял итәргә яратам. Ошбу күлнең җанга шифа, тәнгә сихәт бирә торган бер табигый үзенчәлеге бар — аның суыннан юкә мунчаласының затлы хуш исе килә. Шул исне нәкъ менә август аенда иснәсәң, борын тишекләрең киңәя, күзләрең телемләп киселгән дуңгыз колбасасы чаклы булып ачыла, йөзләрең бурлаттай кызара...

Кыскасы, шундый шәп ялдан соң көч-куәт белән дәртләнеп, яңадан-яңа указлар чыгарасы килә башлый...

— Ашыкма, Бөкәшкин! Яңа указларны яңа президент чыгарыр!

Әлеге тавышны ишетеп, сискәнеп киттем. Тавыш килгән тарафка борылып карадым. Анда... Теге... мине президент иткән сихерче хатын басып тора.

— Бөкәшкин, син дә халыкны аңлый торган, аңа ярдәм итәргә омтылган кеше булып чыкмадың. Бөкәшкин, син тумышың белән эшлексез икәнсең. Саубуллаш кәнәфиең белән! — диде ул, утлы карашын миңа төбәп.

Шулай дип ул теге мәгълүм әфсен-төфсенен укый да башлады:

Керпе-эс-эс... Депе-те-эр...
Чете-бөте... Гөке-чөпе...
Гур-шәй-син-түш... Чүрә-түрә... Һөс!

Һәм мин... сиксән дүртенче елда алган ертык матрасым өстендә пәйда булдым. Үтереп ашыйсы килә — ит юк, ипи юк! Үтереп эчәсе килә — мәй юк, чәй юк!

Минем шикелле эшче-крәстиян ачка интегергә тиеш түгелдер бит инде, шайтан алгыры?!

Нәрсә генә уйлыйдыр бу чутсыз президентлар гаскәре?

Ни уйлаганнарын мин дә белмим, син дә белмисең, үзләре дә белми...

Ә кем белә?

*18 ноябрь, 1991*

# Караңгы авыл вакыйгасы

Үзгәртеп коруның уңышлы тәмамлануына ун ел тулган көннәрендә Карл Маркс исемендәге «Коммунизм» колхозына күктән, дөресрәге, вертолеттан, шифрограмма ташладылар. Көтүче Сәлахинең кыр казанында быгыр-быгыр кайнаган бәрәңге шулпасы өстенә чепелдәп төшкән әлеге шифрограммада болай дип язылган иде: *«Шушы көннәрдә сезнең авылга шагыйрь, сатирик язучы, композитор һәм җырчы киләчәк. Каршы алырга әзерләнегез. Таубаш районы президенты Ивангалиев»*.

Үз гомерендә такмакчы вә гармунчы Әсләхетдиннән башка әртистне күрмәгән авыл өчен шагыйрь, сатирик язучы, композитор һәм җырчының бергәләп килүе олы вакыйга иде.

Халык сабан туена әзерләнгәндәй кабалана башлады. Куанычлы хәбәрне беренчеләрдән булып ишеткән В.Ленин исемендәге ферманың чучка караучылары һәм Ф.Энгельс исемендәге ферма савучылары ертык-мортык, ала-кола халатларын юыштыргаларга, ямаштыргаларга керештеләр. Юыштыру-ямаштыру кебек ашыгыч эшләр улак төбендә мышкылдаган Күтәрәм Сәрбиҗамал белән скутник Вәсимгә генә кагылмады. Чөнки алар башка ашыгыч эш белән мәшгуль иделәр.

Күтәрәм Сәрбиҗамалның ире, Октябрьнең 17 еллыгы исемендәге агач клубның мөдире Черки Вәлиәхмәт, язучыларны һәм әртистләрне каршылау хәстәрләрен күрү өчен, җиң сызганып эшкә тотынды. Иң әүвәл ул Н.Крупская исемендәге тулы булмаган урта мәктәп директоры Варфоломей Сәләхетдиновичка җыештыручы булып эшләүче Аксак Кәримәне йөгертте (кызганычка каршы, Карл Маркс исемендәге «Коммунизм» колхозында телефон дигән нәмәрсә гомер-гомердән булмады). Октябрьнең 17 еллыгы исемендәге клубның нәкъ борын төбендәге В.Павлов исемендәге кибетнең артында урнашкан Н.Крупская исемендәге тулы булмаган урта мәктәп директоры Варфоломей Сәләхетдиновичка «Әртистләрне каршыларга пионерларыңны әзерлә» дигән хәбәрне җиткергән Аксак Кәримә өч сәгать ярымнан соң мөдир Черки Вәлиәхмәт янында Сөембикә манарасы шикелле бер якка янтаеп басып тора иде инде.

Мөдир Черки Вәлиәхмәт, күмердән эшләнгән карага каурый каләм белән мана-мана, 1937 елның 7 ноябрь санында «халык дошманы» җүләр Гаптерине фаш итеп язган район гәҗитенең ак өлешенә нидер сызгалады да аны Аксак Кәримәнең кәкре башлы таяк тотып кыршыл-

ган кулына тоттырды. Аксак Кәримә, титаклый-титаклый, Павлик Морозов исемендәге ятимнәр йорты мөдире ирсез Сәкинә янына ашыкты...

Петр Беренче урамында үзенең салам түбәле өендәге сәкесендә хаста булып яткан япун сугышы ветераны йөзьяшәр Габделхак карт, «Әртистләр килә!» дигән хәбәрне тәрәзә ярыгы аша ишетүгә, урыныннан җәһәт кенә сикереп торды...

Ничәмә-ничә еллар бала табарга зар-интизар булып яшәгән сазаган кыз Әсманың, «әртист» дигән сүз ишеткәч, кендек тирәсендә нәрсәдер җиңелчә чәнчеп-чәнчеп алды...

Черек бәрәңгедән әмәлләгән әче суын эчәргә борындаш табалмый интеккән Бәрәңге Мәгъсүм, өметле елмаеп, казанда өзлексез бытырдаган болганчык суын герман сугышыннан трофей итеп алып кайткан җиз чүмече белән вакыт-вакыт болгата башлады...

Шулай итеп, табигатьнең иң матур җирендә — тирәягы гүзәл камышлар, бөдрә таллар белән әйләндереп алынган сазлык уртасында урнашкан Карл Маркс исемендәге «Коммунизм» колхозында олысы-кечесе шагыйрь, сатирик язучы, композитор, җырчы халкын, бердәм әзерләнеп, түземсезләнеп көтте.

Менә беркөнне күк йөзендә йокымсыраган болытлар янәшәсендә әлеге дә баягы вертолет пәйда булды. Вертолет авыл өстеннән бер әйләнеш ясап алды да Унтер Мөдәррис коесы турысында эленеп калды. Бераздан вертолеттан баудан үрелгән баскыч төшә башлады. Баскычка аркасына мандолина (авыл халкы аның гитара икәнен белми иде әле) аскан озын чәчле бер ир-ат чытырдап ябышкан иде.

Озын чәчле ир-ат Унтер Мөдәррис коесына чүт ычкынмады. Аны Күтәрәм Сәрбиҗамалның ире, Октябрьнең 17 еллыгы исемендәге клуб мөдире Черки Вәлиәхмәт, көч-хәл белән тотып өлгерде.

— Калганнарыгыз нишләп төшми? — диде Карл Маркс исемендәге «Коммунизм» колхозының вице-президенты Кәрамгали, әле озын чәчле ир-атка, әле кояшны каплап торган вертолетка карап.

Ул арада баскычны өскә кире тартып алдылар.

— Мин генә килдем,— диде озын чәчле ир-ат һәм җилкәсендәге мандолина сыман нәрсәсен җайлабрак куйды.

— Син кайсысы соң? — дип сорады «ЧТБТ фетнәчеләрен тулысынча җиңүнең 7 еллыгы» исемендәге янгын сүндерү каланчасы каравылчысы Песиболыт (аның чын исеме Всеволод иде).— Артистмы, язучымы, ягъни мәсәлән...

— Артист та, язучы да, композитор да мин берүзем булам,— диде озын чәчле ир-ат.— Таныш булыйк: мин — Зөлфәт Хәким. Бәлки, беләсездер...

Телевизорның «т», радионың «р», гәҗитнең «г» хәрефләрен дә белмәгән авыл халкына бу исем бернәрсә дә сөйләми иде.

— Ярар, безгә берәү дә җиткән,— диде Бәрәңге Мәгъсүм һәм бакчада казынып каралган уң кулы белән муен астын кашып алды.

— Булдыра торганга охшаган,— дип куйды аның артында яулык читен авызында җебетеп торган сазаган Әсма. Аның кендек тирәсендә янә нәрсәдер ләззәтле генә чәнчеп алды.

— Калганнарын «Клара Цеткин» колхозы үзенә алып өлгергәндер инде. Ярар, чукынып китсеннәр,— диде В.Ленин исемендәге ферма мөдире Әсфан...

Н.Крупская исемендәге тулы булмаган урта мәктәп пионерлары Унтер Мөдәррис коесы янында сураеп басып торган озын чәчле ир-атка өченче көн үк пешереп куйган ипи белән ярмалы тоз тоттырдылар. Такмакчы Әсләхетдин авылның дөнья күргән бердәнбер гармунын шыңгырдатып алды.

Павлик Морозов исемендәге ятимнәр йортыннан килгән балалар «Әтиләр җире — безнең җир» дигән җыру җырладылар. Ирсез Сәкинәнең бердәнбер улы Лаурентий башлап җырлаучы иде. Шуннан соң авыл халкы, кунакны уртага алып, Октябрьнең 17 еллыгы исемендәге клубка юл тотты. Күтәрәм Сәрбиҗамалның ире — мөдир Черки Вәлиәхмәт — клуб ишегенә тотынган иде, йә партия, клуб, дөбер-шатыр килеп, җимерелеп төште. Черек такта һәм агач өеме арасыннан ургылып чыккан тузанны япун сугышында да күрмәгән йөзьяшәр Габделхак карт:

— Бирмәсә бирми инде ул... Ходай,— диде. Аның «Ходай» сүзен үз гомерендә беренче мәртәбә әйткәнен ишеткән тирә-юньдәгеләр, тузан болытын аралый-аралый, читкәрәк тайпылдылар. Павлик Морозов исемендәге ятимнәр йорты мөдире, ирсез Сәкинәнең бердәнбер улы Лаурентий каядыр чатыр чабып китте... Авыл халкы тузан таралгач кына җырчы, композитор, сатирик язучы Зөлфәт Хәким дигән иптәшнең юкка чыкканын шәйләде.

— Бер килде артист дигәне, анысын да Ходай алды,— дип, йөзьяшәр Габделхак Ходайны икенче тапкыр телгә алды...

...Бу вакытта, чәчләре арасына тулган тузанны кагакага, табигатьнең иң матур җиренә урнашкан Карл Маркс

исемендәге «Коммунизм» колхозыннан чыгып, Зөлфәт Хәким, зифа камышларны ера-ера, бөдрә талларны аралый-аралый, сазлыкка кереп бара иде.

Казан каласындагы фатирына атна-ун көннән кайтып егылачагын һәм «Бүтән мәңге караңгы авылга бармаячакмын!» диячәген ул әле белми вә башына да китерми иде...

*10 сентябрь, 1991*

# Токмачлы якшәмбе

Бүген якшәмбе. Сездә ничектер, белмим. Безнең өйдә ял көне. Ягъни мәсәлән, эшкә бармыйбыз. Ял итәбез. Хатын да ял итә, мин дә. Бергәләп ял итәбез, һәр якшәмбе көнне шулай. Ә дүшәмбе көнне икебез дә эшкә китәбез. Хатын үз эшенә, мин үз эшемә. Иртәгә, ягъни мәсәлән...

Ә бүген ял көне. Якшәмбе. Мин, өебезгә нур биреп торган бердәнбер иске диванга утырып, гәҗит-журнал укыйм. Дөресрәге, укымыйм. Караштырам. «Саулык — зур байлык», «Табигать шифаханәсе», «Табиб киңәш итә», «Нитрат — организм дошманы» дигән язмаларны эзләп табып, тутыккан кайчы белән кисеп алам. Аннары һәммәсен бер дәфтәр сыман нәрсәгә җилем белән ябыштырам. Андый язмалар «Здоровье» дигән журналда аеруча күп була. Бүгенге көндә нәрсә ашарга ярамый — шул хакта бик тәфсилләп язып чыга бу журнал. Чөгендер ашарга ярамый — нитрат бик күп икән анда, кишер ярамый — тәнне-йөзне саргайта, бәрәңге ярамый — җүләргә әйләндерә икән, кара ипи ярамый — картайта, ак ипи ярамый — симертә, ит ярамый — янә картайта, йомырка ярамый — салманыйлла...

Ә менә токмачны ашарга ярый. Әлегә. Кибет киштәләрендә күренми башласа, аны да авызга алырга ярамый башлаячак. Моны мин үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: врачлар токмачтан бер зарарлы нәмәрсә табачаклар әле...

Атна буена җыйналган гәҗит-журналларны актарып чыгу бик җиңелдән түгел. Авыр шөгыль. Вакытны күп сарыф итәргә туры килә. Менә әле дә, имән бармакны җилемгә мана-мана, кисеп алынган язмаларны ябыштырып утырам. Хатын кухняда кайнаша. Иркенләп, дөбер-шатыр китереп табак-савыт юа, югыйсә шулкадәрле шау-шу чыгарып юарлык әллә ни ашамадык та инде. Табага бераз сужы салып (май урынына) токмач кыздырдык та ике баш чи суган чәйнәдек, ике телем кара ипине авызда әвәли-әвәли, бөтнекле чәй

эчтек (шикәрсез)... Бөтенесе шул гына. Ә хатын, зур эш кырган кешедәй, мәш килгән була. Әнә өйдәге ике стаканның берсен идәнгә төшереп ватты да бугай инде...

Дөресен генә әйткәндә, хатынны да аңларга мөмкин. Ул бит теге... торгынлык еллары дип аталган заманда савыт-сабаны мул итеп юарга өйрәнгән кеше. Урал тавы кадәр булып өелгән савытны юган вакытта кичергән халәте мескенкәемнең канына сеңеп калган. Ул заманда хатынымны шулай интектергәнем өчен хәзер дә үкенеп бетә алмыйм. Гужларча, бирәннәрчә ашарга, дистәләгән табак-савытны пычратырга кирәк бит, ә!

Әнә хәзер хатын да, мин дә ашказаны белән интегәбез. Язвы. Врач әйткән була, организмыгызга витамин җитми, ди. Көн саен гел бертөсле ризык ашый торгансыздыр, ди. Үзе дә белмәстән, безнең гел токмач белән генә тукланып ятуыбызга ишарәләве инде. Юк, токмачтан түгел, элек тыгынганчы, корсаклар шартлар дәрәҗәгә җиткәнче, күзләр акайганчы ашаганга авырта безнең ашказаннары. Витаминны уптым илаһи сосканга авырта.

Токмач зыянлы булса, итек кадәрле Италия халкы күптән язвыдан кырылып беткән булыр иде инде. Токмач аларның яраткан ризыкларыннан санала бит. Үзләре «сапогетти» дип атыйлар бугай. Әллә «спалнетти» инде? Һәрхәлдә, «етти»е бар. Шундый токмач инде, бездәге кер бавы шикелле бә-ә-әк озын. Менә шул «сапогетти-спалнетти»ны пешергәч, бер бавын тәлинкәгә салалар. Икенче бавын икенче тәлинкәгә, өченчесен — өченчесенә... Шуннан әлеге «кер бавын», чәнечкегә чорнап, бик тәмләп ашыйлар. Димәк, зыянлы түгел — файдалы! Капиталист нәрсә ашарга кирәген белә ул, идрит-кудрит!..

Уф! Бармакка җилем катты. Кәгазьне сизми башлады. Ашыйсы да килә. Кай арада карын ачып өлгерде соң әле, шайтан алгыры! Ә-ә-ә, төш вакыты җиткән икән. Ашыйсы килү шуннан икән. Әһә, кухня тарафыннан кыздырылган токмач исе килә башлады. Хатын тагын токмач кыздыра, димәк. Без яраткан токмачны. Кич янә токмач кыздырса, хатын — шәп буласы инде. Тамак тук килеш йоклаулары рәхәт шул бигрәкләр дә! Үзеңне әллә кем итеп, изрәп йоклап китәсең... Дөрес, кайвакыт төшкә әллә ниткән ризык-нигъмәтләр кереп йөдәткәли йөдәткәләвен. Еш кына саташтыра да. Өченче көн бугай, төшемдә горчицага манып күсәге белән ит ашаганымны күрдем. Ике кулым белән дә чытырдап тотканмын итне, бармаклар арасыннан май (чын, май!) ага. Мин комсызланып чәйним, чәйним, чәйним... Уянмаган булсам, күпме вакыт чәйнисе булганмындыр тагын ул итне, белмим.

Уянгач, исем китте. Мендәр почмагын юешләп, бозау шикелле чәйнәп бетергәнмен. Хатын мендәренең дә шулай теткәләнеп бетүенә игътибар иткән идем аны беркөнне. Димәк, ул да нидер чәйнәгән булган төшендә?! Тик беләсе иде, идрит-кудрит, нәрсә чәйнәде икән ул шулай: итме, әллә башка төрле берәр затлы ризыкмы? Бәлки, балык ашагандыр, бәлки, тавык яки каз боты кимергәндер... Үзеннән сорап булмый шул хатынның. Әллә ничек соравы. Кыен, дип әйтимме... Аннан соң хатынның шәхси эшенә тыкшыну кебегрәк килеп чыга бит ул. Үзем, мәсәлән, яратмыйм эшемә кеше тыкшынганны...

Шул төштә тәмләп ит ашавымны күргән көнне сару кайнап изалар чиктем. Яшелчә тартмасы төбеннән бер бөршәйгән бәрәңге табып, шуны шактый суыргалап, чәйнәштергәләп йөргәч кенә хәл керде.

Уһу-һу! Токмач исе борын тишекләрен киңәйтеп җибәрде. Перәме совет армиясе кебек бәреп керә...

Бүгенге көнне дә шулай матур итеп кенә үткәрсәк иде инде кана. Кыздырылган токмач ашап, башлы суган суы суырып, бөтнекле чәй йоткалап, табак-савыт юып (монысында хатынымны күз алдында тотып әйтәм), сәламәтлек турындагы язмаларны кисеп-ябыштырып, ягъни мәсәлән...

Иртәгә, ни әйтсәң дә, эш көне! Эшлибез. Хатын да эшли, мин дә. Икебез дә эштә булабыз. Көне буе. Ашау мәсьәләсен кайда туры килсә, шунда хәл итәрбез әле. Ач булмабыз, шәт! Ничек тә киләсе якшәмбегә кадәр чыдарбыз. Ә якшәмбе инде ул, үзегез беләсез, ял көне дигән сүз. Суда кыздырылган токмач, башлы суган, кара ипи, бөтнекле чәй дигән сүз!

Кыскасы, якшәмбедән якшәмбегә кадәр яшәргә дә яшәргә әле безгә.

*28 ноябрь, 1991*

# Нострадамус II фаразлары

Мишель де Нострадамус дигән күрәзәче турында ишеткәнегез бармы? Бардыр, бардыр, шикләнмим. Менә мин фәкыйрегез дә шуның шикелле инде — күрәзәче. Астрологик күрәзәче, ягъни мәсәлән. Хәтта гасырларда булачак хәл-вакыйгалар турында үтә дә дөрес фараз кылучы мин.

Нострадамус, дигәннән, ул үзенең күрәзә-фаразларын шигырь калыбына салып бәян итә торган булган... Шуңа күрәдерме аның күрәзәләрен бүген дә тулысынча бик күп галим-голәмәләр аңлый алмый интегәләр. Шигъри

күрәзәне әле тегеләй, әле болай боргалап, әвеш-тәвеш китереп азапланганда, аларның маңгайлары тирли, борын аслары юешләнә, башлары пеләшләнә. Бик катлаулы, диләр. Шагыйрь Ләис Зөлкарнәйнең башваткыч әсәрләреннән дә хужырак катлаулы, диләр...

Мин үзем фаразларымны алай шигырь-мигырь калыбына салып-нитеп тормыйм — турыдан гына сибәм. Ягъни Арча якларында яшәп ятучы Бибигыйльмениса түтиләр дә аңларлык телдә әйтәм.

Җөмләдән әлеге табигый сәләтнең миндә тумыштан ук булачагы турында мсье Нострадамус үз заманында ук абруйлы итеп белдергән булган. Телдән, әлбәттә...

— Халкы ат шикелле эшли торган бер илдә дөньяга килер ул,— дигән мсье Мишель минем хакта. Спирт кушылган сырасын уймак-уймак кына йоткалаган әңгәмәдәше мсье Эмильгә тирән мәгънәле караш ташлап алган да ул янә сүзен дәвам иткән: — Әлеге ил кешеләренең оекбашсыз иске башмак кигән каралган аяклары астыннан алтын бәһасенә тотарлык кара сөт шаулап агар... Егерменче гасыр ахырына таба бәндәләрнең берише, әүвәлгечә көнне төнгә көч-хәл белән ялгап, ачлы-туклы яшәр. Халыкның Җилкуардар дигән бер кавеме читилский сагызлар һәм «Актаныш таңнары» дигән астматик тәмәке вә миңгерәткеч хәмер сатып баер. Башкаласы Ярлы Чаллы (Нострадамус «Казан» дип әйтергә теләгәндер инде.— *Автор.*) дигән ул ил белән исемендә «тимер» сүзе булган кеше идарә итәр. Менә шул чорда минем кебек француз исем-фамилияле бер кызыклы шәхес киләчәкне күзаллар...

Күрәзәченең бүгенге көн өчен бик тә кыйммәтле булган ошбу фаразларын тыңлаган мсье Эмиль әфәнде, шактый мәлҗерәгән гәүдәсен (спирт кушылган сыра бит, тәэсир иткәндер инде) туры тотарга тырышып, өенә кайткан. Кайткач, бу хакта хатыны мадам Софига сөйләгән. Мадам Софи исә, үз чиратында, әлеге хәбәрне иң якын дусларына әйткән, тегесе — подругасына, ягъни ахирәтенә.

И шуннан киткән, киткән... Мсье Нострадамус фаразы, шулай итеп, безнең болганчык көннәргә килеп җиткән. Мәшһүр күрәзәченең фараз кылуы хакындагы бу сөенечле хәбәрне миңа дустым сөйләде. Ул аны, Парижга барып, француз халкына «Эйфель белән Сөембикә манараларының рухи якынаюы һәм аларның милли-җенси мөнәсәбәтләргә уңай тәэсире» дигән докладын укыган көннәрдә ишеткән булган.

Куанычлы хәбәр мине искиткеч дулкынландырды. Урам чатындагы җилкуар алыпсатарлардан ике йөз тәң-

кәгә генә алган кәрәчин аракысын бер чәркә деңкегәч тә дулкынлануым кимемәде, киресенчә, отыры көчәйде. Күбесе буш кибетләрдәге кием-салым, ризык-фәлән янына куелган ярлыкларны укый-укый чекерәеп беткән күзләрем торгынлык елларында ашаган шикәр шикелле шакмакланды, тыннарым яшелчә кибетендә кереп еш-еш сулаганнан да болайрак булып кысылды...

Шулхәтле дулкынланмаслык та түгел иде шул: Нострадамус фаразын телгә алган француз исем-фамилияле шәхес мин идем бит! Мин — Лемон Лерон!

Исем-фамилиям шундый булуына ышанмасагыз, элеккеге совет иле биргән паспортыма карый аласыз. Дөрес, хәзер һәрбер нәрсә, һәрбер хәрәкәт акча белән исәпләнә. Шуңа күрә искәрегез, әфәнделәр: минем паспортка күз төшереп алу бәхетенә йөз сум акча түләп кенә (ит-майга дигән чек та ярый) ирешергә мөмкин! Казан каласыннан читтә яшәүчеләр юлда акча югалтудан курыкса-нитсәләр (адым саен рэкетчы, кесә карагы, жулик, исерек... дигәндәй), үз төбәкләрендәге саклык кассасына барып, әлеге тиешле сумманы минем исәп-хисап счетыма күчерә алалар... (Файдалы ул саклык банкында сәмән саклау, дәүләт синең белән санашса да, файдалы.)

Акчага хирыс кешеләрнең: «Татар җирендә француз исем-фамилияле татар булуы мөмкин түгел!» — дип, шикшөбһә белдерүләре, ышанмаулары ихтимал. Ләкин юкка. Мин андый адәмнәргә үзем туган-үскән төбәккә — Мөслим, Актаныш якларына барып чыгарга киңәш итәм. Аһ, нинди генә исемнәр юк минем гүзәл төбәгемдә! Иреннәрне ярырлык, телләрне сындырырлык затлы исемнәр: Долорес, Кобра, Фикус, Ленарис, Рулт, Рафакаил, Термос, Кипарис, Фердинант, Фикалия...

Сүзне озын-озакка сузмыйча, мин сезне хәзер үземнең күрәзә-фаразларымның кайберләре белән таныштырып үтәргә телим:

Җөмһүриятебез халкы өчен шаккаткыч хәбәр: тиздән 2000 ел килеп җитәчәк. Бу хәл 1999 елның соңгы төне белән хушлашканнан соң иртәгесе көнне булачак!

Татарстанның беренче Президентыннан соң илбашы булып хәйләкәррәк икенче кеше киләчәк. Аннары — өченче, дүртенче...

Татарстан киләчәктә, әгәр теләсә, БМОга керәчәк. Кермәве дә ихтимал — еламаган балага ими каптырмыйлар. Ул чагында аның БГШТРМОга керүе дә икеле.

Татарстанда китаплар хәзергедән дә аз басылачак, басылганнарын да укымаячаклар. Чөнки халык талон, купон, чек, доллар, ваучер дигән кәгазьләрне тотып-укып

кына да аң-белем дәрәҗәсенә ирешә алуын аңлый башлаячак.

Татарстанда һава торышлары әүвәлгечә үзгәреп торачак. Әйтик, кыш көне — кар, җәй көне яңгыр явачак. Яки киресенчә дә булачак. Татарстанда, микрофон алдына чыгып, сүз боткасы пешерергә атлыгып торучыларның саны кимемәячәк, киресенчә, ашарга яраксыз гөмбәләр шикелле үрчиячәк.

Татарстанда сөткә һәм сырага су, каймакка кефир кушу кебек матур гадәтләр киләчәктә дә дәвам итәчәк.

«Татарстан» телекомпаниясе бер мең өч йөз егерме сигез серияле нәфис фильм күрсәтә башлаячак. «Елыйсыларыгыз алда әле» дип исемләнгән ул фильмның ахырын 2134 елда яшәячәк тамашачылар карый алачак.

Татарстан кибетләрендә мөселманча суелган ат колбасалары һәрдаим булачак. Югары сортлы «Бахбайская» дигән ул колбасаларның төп өлешен, бүгенгечә, чучка ите, крахмал, түбән сортлы кәгазь тәшкил итәчәк.

Татарстанның мәркәзендә, ягъни Казанда, күпсанлы кооператив бәдрәфләр барлыкка киләчәк. Саунасы, видеозалы, буфеты булган ул бәдрәфләргә бер кереп чыгу 100 доллар гына. Кесәләрендә доллар түгел, сукыр бер тиеннәре дә булмаган кешеләр йомышларын элекке гадәт буенча йомышлаячаклар: кая туры килсә — шунда.

Игътибар иткәнсездер, минем фараз кылуларымның һәммәсе дә Татарстанга гына кагыла. Әлбәттә, мин Русия, Прусия, Тужысия шикелле башка илләр һәм ул илләрдә яшәүчеләрне киләчәктә ниләр көткәнен дә бик тәфсилләп фараз кыла алам. Ләкин болары бүтән мәсьәлә. Ул илләр акча түләсә — әйтәм, түләмәсәләр... үзләренә карасыннар.

Сүз соңында Татарстан халкы өчен тагын бер куанычлы хәбәр белдерәм: халык үлгәнче яшәячәк! Бу инде, беләсез, яшәү өчен дип җан тартышып ятканда бик тә мөһим!

*1992*

# Медаль

Беләсездер инде мине, берәрегез белән сыра-мазар да эчкән чак булгандыр әле. Гәрәй мин. Әтәй мәрхүм әйткәнчә әйтсәм, болай була инде минем исем — Миңлегәрәйша. Миңлегәрәйша Габделмөхәммәтвәлиевич, ягъни мәсәлән. Миңа тегеләй дип тә дәшәләр, болай да. Ләкин мин үзем, гади кеше буларак, нигәдер Гәрәй дип дәшкәннәрен кулайрак күрәм.

Бик асубы җаваплы эштә эшлим мин. «Таксекмекретчирмирпромбаш»та. Дөресен генә әйткәндә, моның ни аңлатканын мин үзем дә тәгаен генә белмим. Бер салып утырган чакта, хуҗадан сораган идем, ул: «Гәрәй дус, юк белән башны катырмале. Аның ни аңлатканын белсәм, мин монда директор булып утырмас идем. Әллә кайда әллә кем булыр идем инде!» — дип кенә җавап бирде.

Ләкин мин үземнең кем булып эшләвемне беләм. «Таксекмекретчирмирпромбаш» берләшмәсе биләмәсендәге барлык ресурсларны барлау-исәпкә алу буенча директор урынбасары мин. Бу, гади генә итеп әйткәндә, каравылчы дигән сүз. Без менә «Таксекмекретчирмирпромбаш»та ике кеше эшлибез: мин һәм директор. Директор дигәнем, элекке партком секретаре Дермантин Сәхибгәрәеч була инде. Миравай кеше. Актаныштан. Эшлибез дип, без әллә ни эш майтармыйбыз инде. Иртән эшкә дип киләбез дә, аннан-моннан бер ярты юнәтеп, аны тәмләп кенә эчә-эчә дөнья хәлләре, хатын-кыз кәмәшләре хакында гәп сатабыз. Ул ярты беткәч, тагын табабыз. Тагын эчәбез...

Көн саен шулай. Без бушаткан шешәләрне Әсма килеп җыештыра. Әйтергә онытып торам икән. Бездә тагын ике кеше эшли. Берсе менә шул җыештыручы Әсма, икенчесе бухгалтер-кассир булып хисапланучы Кәримә эби. Ләкин алар чутка кермиләр. Чөнки алар ярты ставкага гына эшлиләр...

Әсма дигәннән, соңгы вакытта ул бик тулыланып, матурланып китте әле. Бу — язын безнең бик каты эшләвебезнең нәтиҗәсе инде. Без эчеп бушаткан шешәләрне сатып, череп баеды инде ул. Җүнле күлмәк кигәч, бизәнгәч-ясангач, адәм карамаслык хатынга да кыяфәт керә икән, малай!

Башта Әсмага Дермантин Сәхибгәрәеч үзе мөкиббән булды. Гашыйк булды, ызначит. Аннан соң мин. Ничава хатын булып чыкты ул...

Хәзер Әсма тулы хезмәт хакына эшли. Эшкә акча алган көнне генә килеп, безнең күңелләрне күреп китә. Акча аласы көнне сагынып көтәбез үзен. Сагынмый булмый. Бухгалтер да булды бит әле ул безнең Әсма.

Соңгы вакытта Дермантин Сәхибгәрәеч кәефсез күренә әле. Каяндыр ниндидер йогышлы чир эләктергән бугай. Гриппер диме шунда, триптих диме... Ишеткән-белгән нәрсәм түгел. Шулай да, әгәр ул чыннан да йогышлы булса, миңа дә бүлнискә барып күренергә туры килмәгәе...

Бу Әсма турында сөйләп тәмам сүздән читкә киттем ләбаса мин, каһәр.

Мин бит медаль турында сөйләмәкче идем. Ничек итеп миңа медаль бирүләре турында.

Беркөнне Дермантин Сәхибгәрәеч салып утырганда әйтте:

— Мин кирәкле кешеләр белән сөйләштем, тиешле кешеләргә документлар тутырып илттем,— ди,— сиңа шушы көннәрдә медаль бирергә тиешләр,— ди.

— Нишләп миңа? Ә үзегезгә түгел? — дидем мин чын күңелемнән.

— Заманында мин «Герой-ана» медаленнән кала барысын да алып бетердем. Бүтән яңа медаль ясамадылар әле,— диде Дермантин Сәхибгәрәеч.— Синең бит бер медалең дә юк. Аннан соң безнең «Таксекмекретчирмирпромбаш»тан кем дә булса бүләкләнергә тиеш ләбаса.

— Каравылчыга медаль кем бирсен!

— Ташла ул сүзеңне. Син каравылчы түгел. Белеп тор, яме! — диде Дермантин Сәхибгәрәеч.— Син «Таксекмекретчирмирпромбаш» берләшмәсе биләмәсенең барлау-исәпкә алу буенча директор урынбасары!

Эчә торгач шактый мәлҗерәгәнгәме, күңелем нечкәреп китте, чүт кенә җылап җибәрмәдем.

— Аннан соң сиңа тиздән илле яшь тула. Илле яшь! Безнең илдә юбилее җиткән һәр кеше медальле булырга тиеш. Борчылма. Синең кайда, нәрсә эшләвең әллә ни мөһим түгел. Главный безнең аргумент бар — юбилей! Бүгенге матур заманда теләсә кем килеп җитә алмый әле бу возырыстка, белдеңме?!

Дермантин Сәхибгәрәеч тотынса, булдыра инде ул. Капкан җиреннән өзмичә туктамый.

— Читай, синең бер медалең бар инде. Мин сине «Кавалер всех орденов» иткәнче тырышачакмын! — диде хуҗа.— Давай, сал стаканнарга! Юа башлыйк медальләрне...

Мин шешә бөкесен, гадәттәгечә, «хөкүмәт» тешләрем белән тешләп, чыртлатып каерып ачтым да кырлы стаканнарга аракы агыза башладым...

...Медальне кем бирер микән, Президент үзе бирер микән, дип уйлаган идем. Вакыты булмагандыр инде Президентның, нindидер памушнигы тапшырды.

Хәзер медальне Брежнев агай заманындагы шикелле түшкә тагып тормыйлар икән. Кочаклап аркага суккалаулар да, чулт-чулт итеп үбешүләр дә юк. Медаль салынган кәгазь капны, ачып та тормыйча, кулга гына тоттыралар. Ә мин, җүләр, моңарчы сыңар медаль дә алып карамаган кеше буларак, рәхмәтне элеккечә әйтәләрдер дип уйлап, кочакларны җәйдем дә памушникны үбәргә

теләп, авызымны суздым. Памушник корт кугандай авызы тирәсендә кулын уйнатып алды. Аңлыйм мин аны, махмыр исе коточкыч икәнен беләм мин.

Кемдер Дермантин Сәхибгәрәечнең кәчтүненнән (мин аның иске кәчтүнен кигән идем) артка таба тартты.

Борылып карадым. Тәбәнәк кенә буйлы, түгәрәк корсаклы тагын бер памушник басып тора. Ул, минем колагыма пышылдап:

— Хәзер алай итмиләр инде. Берәр сүз әйт тә... Башкаларны көттермә,— дип, бер як читкә тәгәрәп китте.

Мин телемә килгән җөмләне тантаналы елмаеп кычкырдым:

— Илебез халкына дан!

Элек райкомда беренче секретарь-мазар булып эшләгәндә шомарып беткән булгандыр инде, теге кәчтүнле туп кире тәгәрәп килеп җитте. Килде дә янә пышылдады:

— Син нәрсә? Нишләп илебез халкы надан булсын? Бездә ничә мәктәп, ничә институт, ничә универсамитет...

— Университет,— дип төзәттем мин.

— Не важно,— диде ул,— син сүзеңне тизрәк бетерүеңне бел...

Главный памушник безнең ни сөйләшкәнне әллә ишетмәде, әллә аңламады... ул сабыр гына карап торды.

Адәм әйткәнне эт шикелле тиз аңлый торган кеше мин. Хатамны шундук төзәттем:

— Илебезнең ху-җа-ла-ры-на — дан! — дип кычкырдым.

Түгәрәк памушникның комач йөзе ап-ак булды, авызыннан күбекләр күренде. Медаль алалмыйча торган бер мужик аны тотып калмаган булса, паркет идәнгә лапылдап төшәсе иде... мәрхүм.

Аңа «скурый» чакырттылар. Ләкин мин аңа бер караш ташлау белән аңладым — соң иде инде... Инфаркт... Минем бер шешәдәш дустым нәкъ шулай авызларыннан күбекләр чыгарып ычкынган иде. «Шул вакытта йөз грамм эчкән булса, исән каласы иде бу»,— диде врач...

Кешеләр шул памушник янында әвәрә килгән вакытта, кемдер минем кулымдагы медаль салынган капны тартып алмакчы булды. Ләкин алалмады. Мин аны, медальле капны әйтәм, тиз генә чалбар каешы тирәсеннән эчкә, аннан аска шудырып өлгердем. Бер алган медальне кире бирү юк инде ул! Җитмәсә, беренче генә алуым. Күңелем сизә, шушы медаль әле соңгысы булмагае...

Ничек өйгә кайтканымны сөйләп тормыйм. Шуны гына әйтә алам: медаль исән кайткан! Исән дә булмаска мөмкинлеге бар иде. Чөнки, абына-сөртенә качкан чакта, медальнең савыты чалбар балагыннан төшеп калган

иде. Ә медаль трусик төбенең быелтыр ертылган өлешенә энәсе белән эләккән булган... Әле нинди медаль диген? «Герой-ана» медале!..

Дермантин Сәхибгәрәеч документларны салмыш баштан тутырган инде. Югыйсә минем ун бала түгел, бер балам да юклыгын белә иде үзе. Аннан соң хатын-кыз да түгел бит инде мин, үзегез беләсез, ир-ат! Өстәвенә беркайчан да өйләнмәгән кеше...

Менә уйлап торам әле, илтеп бирергә микән бу медальне, әллә хөкүмәтнең якты истәлеге итеп үземдә калдырыйм микән... Дөньяларда тормыш итүләр гел шулай гына бармаса, сатарга туры килмәгәе...

Әгәр Дермантин Сәхибгәрәечкә генә бүләк итсәм? Аның нәкъ менә «Герой-ана» медале генә юк иде. Бирим әле шуңа. Бер сөенсен, ичмасам. Аннан бергәләп юарбыз...

*1993*

# Мин ничек Ысталинны кунак иттем

*(Хәтмулла картның тарихи шәхесләр турындагы истәлекләреннән)*

— Тыңлале, кем, гаспадин-иптәш, бер әйбер сөйләем. Сугышка хәтле бу.

Бик ачык хәтерлим әле бүген дә: уң як күрше Кәлә Мирзәкәйнең кәҗә тәкәсе, минем кәҗә тәкәсе белән сөзешеп, көтүдән мөгезен сындырып кайткан җыл ие. Кәлә Мирзәкәй миңа үчләшеп тә йөргән ие әле ул җылны. «Атабыз Ысталинга әйтәм, жалу итәм, атабыз Ысталин синең кәҗә тәкәңне печтерәчәк!» — дип, бер атна чамасы һауһаулагач, түзмәдем, тәкәмне бисмилларахимлап ташладым. Кәҗә тәкәсе ите итмени ул!..

Менә шул җылның Алланың бирмеш бер көнендә мин үзебезнең авыл җанындагы күлгә барганыем. Балык эләктерү нияте белән инде, кайсыдыр ки мәсәлән, һәм дә эләкте бит вәләкин, гаспадин-иптәш. Әле нинди балык диген! Сөйләшә белә торганы. Безнеңчә иттереп. Кайсыдыр ки мәсәлән, адәмнәрчә иттереп. Шуның өстәвенә үзебезнең мөэмин-мөселман телендә. Ышанмыйсыңмы, кем иптәш-гаспадин? Мин үзем дә әкият-фәләнгә ышанмыйм.

— Ни теләсәң, шуны эшләем, галиҗәнап Хәтмулла хәзрәтләре, мәгәр мине суга кире җибәр генә! — ди бу адәми телле мәхлук җан. Чүт җыламый гына...

Мин әүвәлтен шүрләдем анысы, дөрес. Кырык җамаулы ыштаным аздан гына җүешләнмичә калды, һы! Адәмчә җиффәрә бит санак сыйрак. Ачуым килмәгәе, үзенең буе бер аршын булгандыр... Бер пот тарта да тартае инде анысы, факты! Ике пот ук булмаса әле... Булгандыр...

Менә шул мәлне минем баш эшләүдән туктады бит, нәгаләт. Эшләми һәм дә ки вәссәлам!

Төпсез чүлмәк эленгән читән казыгы кебек сураеп торам шулай.

Бервакыт сизәм, авызымдагы телем кыймыл-кыймыл килә. Ниндидер җүнле сүз әйтергә теләем сымак, инде кайсыдыр ки матур иттерепләр.

Ә теге шайтан вәсвәсәсе отыры җалына гына бит:

— Хәтмулла хәзрәтләре, теләгеңне әйт тә җибәрсәнә, зинаһар! — ди.

Хикмәти Ходa: баш эшләми — колаклар эшли. Тыңлыйлар, кайсыдыр ки ау этләре шикелле шомраеп.

Ул да булмады, минем тел авыз эчендә отыры борсалана башлады — бүре күреп шүрләгән ат сымак.

Берзаман колагыма янә сүзләр килеп ирешә, үзем сөйлим икән, Хода бәндәсе.

— Син мине атабыз Ысталин белән очраштыр. Килсен ул безнең Саз-Күлгә, керсен ул минем өйгә, кунак булсын, кайсыдыр ки матур иттереп! — дим икән теге су мәхлугына.

— Җибәр генә суга, Хәтмулла хәзрәтләре. Син теләгәнчә булыр! — ди бу.

Күлгә чапылдавы булды моның, артымнан иңсәмә кемдер саллы кулын китереп салды. Соңыннан белдем инде аның кулы икәнен.

Борылып карыйм... Йа Хода! Каршымда, төребкәсен пыскытып, атабыз Ысталин тач үзе басып тора. Кырыенда Бириә. Күзлек пыяласы җылык-җылык килә Бириәнең. Күзләре безнең мәченеке шикелле җалт-җолт итә. Ә минем әлеге дә баягы кырык ямаулы ыштан эчендәге сыйракларым икесе тиң җилфер-җилфер килә. Бакчага карга куркытырга куелган карачкы бишмәт җиңнәре төсле җилферди, ягъни мәсәлән...

Бириә әйтә миңа:

— Курыкма, иптәш Бәрәкәтуллин,— ди,— иптәш Ысталин белән без сине бу җулысы алырга килмәдек. Без сиңа җул оңгаеннан гына сугылып, кунак булып китәргә килдек,— ди...

Дөрес, факты: Бириә урысча әйтте анысы. Вәләкин мин, укымышлы кеше буларак, аның ни сөйләгәнен су-

зен-сүзгә аңладым. Җарты җыл күрше урыс авылында укыганыем... Ырувалусиегә чаклы...

«Кунак» сүзен ишеткәч, минем аяклар җилфердәүдән туктады. Җанга кыюлык иңде, ягъни мәсәлән.

Билне бөгеп, үзебезнең халыкка хас кунакчыллык белән:

— Пажальте, иптәш атабыз Ысталин Йосыф Бишсарыйонич! Пажальте, иптәш Бириә! Костем булырсыз ки,— дидем.— Түлке,— минәйтәм,— гафу кылгански, сезләрне ипи-сүл белән бестеричәйт итеп булмагански. Балык бит каптырайт...

— Үз телеңдә генә сөйлә! Иптәш Ысталин аңлый. Без бит иртерноскиямаллар,— диде шулчак Бириә иптәш.

— Якши,— минәйтәм,— аңлагански...

Шуннан соң минем кармак-җепләрне җыйнаштырдык та киттек безнең өйгә. Менә шунда, безнең өйгә кайткач, булды инде хәлләр.

Теп-тере иптәш атабыз Ысталинны күрүгә, минем Вәсбикамал аңын җуеп идәнгә җыгылды. Җыгылган чакта, алабута камырлы уклавы хәлсез кулыннан ычкынып китте дә иптәш атабыз Ысталинның көзге кебек җалтыраган итегенә дыңк итте. Ай түземле кеше дә икән атабыз Ысталин — ыһ та итмәде. Йөзен генә чытты.

Иптәш Ысталинның җалтыр итегенә сыланган алабута камырын мин җәһәт кенә билбау очы белән сөртеп алдым. Үзем авыз эченнән быкырдыйм:

— Гафу итә күр инде, иптәш Ысталин. Кичерегез инде безне! — дим.

Бириәнең ярдәмчеләре минем Вәсбикамалны, «ә» дигәнче җилтерәтеп торгызып, күрше урыс авылындагы бүлнискә алып киттеләр.

«Кунакларга аш-мазарны кем хәстәрләр инде»,— дип, бер мәлгә кара кайгыга чумып торганда, Бириә минем уйны сизгәндәй:

— Борчылма, иптәш Бәрәкәтуллин. Безнең аш пешерүчеләребез үзебез белән! — диде.

Аш пешерүчеләр казан тирәсендә тавыш-тынсыз гына кайнашкан арада, иптәш Ысталин, мин ясаган сәкегә утырып, төребкәсен пыскыта-пыскыта, нәрсәдер язгаларга кереште.

— Иптәш Ысталин бөек урыс теле турында тәгълимат яза! — дип пышылдады миңа бер пубыр, казандагы быгыр-быгыр кайнаган сарык шулпасын агач чүмеч белән болгата-болгата.

Аш телне йотарлык булып пешкәч, иптәш Ысталин сакчылары бер җамаяк шулпаны башта миңа ашатып карадылар.

— Иптәш Ысталин, кунакка баргач, иң әүвәл хуҗаның үзен сыйларга ярата! — диделәр миңа сакчылар. Әйбәт ата әйбәт ата инде, мактаудан гайре бер кәлимә сүз әйтерлек түгел иптәш Ысталинга.

Ашны бик яратып ашады атабыз. Состы гына дип әйтү килешеп бетми инде ата кешегә карата, вәләкин бик дуамал сыптырды мәгәр. Сарык итеннән пешкән ашка бик мөкиббән икән иптәш атабыз Ысталин.

Сәкедән кузгалган вакытта, ниһаять, бер сүз әйтте атабыз. Шундый итеп, тирән мәгънәле итеп әйтте иптәш Ысталин, минем мәңге тураймас кебек гәүдәм кинәт тураеп, өй түшәмендәге алагаем җарыктан чүт өскә сузылмыйча калды.

— Ыспасибы! — диде иптәш Ысталин. Дәү кунак киләсен сизенгән кебек, шул көнне мунча яккан идек.

— Мунча кереп, бераз җиңеләеп чыкмыйсызмы, иптәш атабыз Ысталин? — дигән идем, ике-өч сәгать эчендә авылның унбишләп хатынның хәл-әхвәлен белешеп кайткан Бириә бурлаттай кызаринган, бүртенгән чыраен уч төбе белән сыпырды да:

— Рәхмәт, Бәрәкәтуллин, ак мунчаңа. Иптәш Ысталин ысланган кара урыс мунчасында җуынырга җарата. Анда да әле вакыты булган чакта гына,— диде.

Машина кузгалып китә инде дигәндә генә, Бириә, нәрсәсендер онытып калдырган кеше шикелле, минем җанга килде дә, сарымсак исен алагаем бөркеп, колагыма пышылдады:

— Әлегә сине алмыйбыз. Гафу ит, урын юк...— диде.

Иптәш Ысталин белән җәнәшә утырып Мәскәүгә бик үк барасым килеп тормаганые торуын, вәләкин Бириәнең әлеге кайсыдыр ки матур сүзләре эчемә сары май булып җатты. Мәгәр хак — шулай.

Иптәш атабыз Ысталин Йосыф Бишсарыйонич, минем өйдә шулай күңелле генә җал итеп, кунак булып киткәннең икенче көнендә Кәлә Мирзәкәй, мөгезе сынган кәҗә тәкәсен муенчагыннан сөйрәп, безнең ихатага килеп керде:

— Хәтмулла күрше,— ди,— ал минем кәҗә тәкәсен! Сиңа бүләгем булсын,— ди.

Шүрли, шайтан. Иптәш Ысталинга мин жалу бирүдән курка. Моның шулай икәнен сиздем дә мин:

— Мөгезсез хайван хайван түгел инде... Ярар, бик кыстагач, калдыр булмаса,— дидем.

Шуннан соң Кәлә Мирзәкәйнең сөенгәнен күрсәң иесин, кем, иптәш-гаспадин, билләһи газыйм, бер чүмеч эче балны әһ тә итмичә эчеп бетерер иең... Факты!

Тагын шул. Бер атнадан хатынны урыс авылыннан алып кайттым. Терелеп, аңына килеп кайтты Вәсбикамал. Дөрес, факты: кайчак чүпрәк миле башында бераз җил сызгыргалый анысы. Бигрәкләр дә йокларга җаткач:

— Нишләп, сез, атабыз Йосыф Бишсарыйонич, матур мыегыгызны кырдыгыз? — дип, минем борын астындагы гомер бакый мыек үсмәгән шома төшне бармагы белән сыйпый... Бәйләнепме бәйләнә шул...— Нишләп төребкәңә ут алмыйсың бер дә ...— ди.

*7 сентябрь, 1993*

# Биләмче карчык

«Әттәгенәсекәем, парадит!.. Җөрәккәемнең коткайларын алмасаң... Кергәнесаем кәлүшкәемә ураласың, чукынмыш!..» — дип, үзалдында сукрана-сукрана, Мөслимә кортка өйалды идәненә аяк сөртер өченгә җәеп куелган иске киндер капчыкны читкә тибеп җибәрде. Аннары, караңгыда әйле-шәйле генә күренгән тимер тотканы шыр сөяк бармаклары ыргакны хәтерләтеп укмашкан кулы белән каптырып алды да, дуамалланып, ишекне кинәт үзенә таба шундый итеп тартты, күгәннәре Сәлахетдин карт вафатыннан бирле май шәе күрмәгән авыр ишек ыңгырашырга да өлгерми калды хәтта!

— Минәйтәм... бу Чатан Шаһиның әрәмтамагы нигә бик җаман өрә дисәм, син икәнсең әле бөтен ауылга көлчә искәйләре таратып җатучы! Бергәнәкәйләр дә оялмыйсыз инде кешедән...— Ишек баягынак нинди тизлек белән ачылган булса, шулай ябылды да...— Дабхузд кияүеңне әйтәм... Туймаса туймый икән... ташып кына тора калхузднын пирвай сурт онкайларын...

Бу — Мөслимә карчыкның Вәсбиҗамал кортка белән шулай исәнләшүе.

— Таң ката кем җөри дисәм, әпәйт син икәнсең әле кеше өркетеп җөрүче... Әйтсәм әйтәем... Синең кияү тәрең дә бер дә тикләр тормай анысы, кемкәем... Калхузднын кышлык курмысын шуның мүкләге генә сосып җата... Ул бидраздмир корсакның ашкаданы ничекләр генә чыдыйдыр...

Бусы — Вәсбиҗамал кортканың Мөслимә карчыкка «Әйбәт кенә әле, күршекәем. Үзең исән-саумы?» диюе...

Мөслимә кортка, гадәттәгечә, ялгышмады: Вәсбиҗамал карчык, чыннан да, мичтән көлчәләрен алып, шуларны майлап маташа иде.

— Акаеб карама, җәме, Вәсбиҗамалкаем... Аякларымда ырматизд икәнен бөтен районда беләләр... Кәлүшкәемне салып тормаем инде... Балауызд кеүек сап-сары идәнеңне, кисәүгачыңа мунчала чорнаб, уңлы-суллы ышкыб алырга гына иренмәссең әле... син миннән ике айга җәшрәк тә!..— дип, сөйләнә-сөйләнә, Мөслимә кортка өстәл янындагы гадәти урынына, шакмак-шакмак итеп тегелгән чуар япмалы урындыкка килеп утырды.

Көн саен шундый хәл кабатланганга күрә, Вәсбиҗамал кортка аның сүзләренә әллә ни әһәмият бирмәде. Бары тик:

— Җәшкә килгәндә... анысы... син үдең миннән ике айга җәшрәк инде...— дип кенә әйтеп куйды. Үзе алдындагы көлчәләрне әйләндерә-әйләндерә, мич ризыклары өчен генә дип тоткан кечкенә канатны каз маена манчып ала-ала майлавын белде.

Мөслимә карчык Вәсбиҗамалның әлеге сүзләрен әллә ишетте, әллә юк — көлчәдән күзләрен алмыйча гына үзенекен сөйли бирде:

— Җугарычның Димагур Нәҗиб Хәмдиясен әйтәм әле... Җыгылган бит... Түшәккә җыгылган... Дәп-дәңгәр булып җата, ди... Дөнҗасына сыймагандай кыланыблар җөридерие...

— Кит аннан! Булмастайны сүләмәсәнә! Әле кичәгенәкләр генә күргәнием бит мин аны,— диде Вәсбиҗамал, Мөслимә карчыкның әйткән сүзләренә бик үк ышанып җитмичә.

— Кичәгенәктән суң күпме үтте битсәнә... Менә шуны... Димагур Хәмдиясен әйтәм... үлеб киткәнче күреб калаем диб чыкканыем... Бармаенча булмай, җараб бетмәс бер дә... Аллаһы Тәгалә ходурына үдебезднең дә җул тотасыларыбызд ба-а-ар...

— Кара инде син аны... Менәтерәк... Кичәгенәк кенә күргәнием бит...— дип сөйләнде Вәсбиҗамал кортка.

— Димагуры чакыргандыр... «Нишләб бер җалгыдым гына җатаем» дигәндер... Әллә шуңа инде тамаккаем ачыб киткән кеүек булды...— Мөслимә карчык Вәсбиҗамал урталай кискәләп куйган көлчәнең яртысын үрелеп алды.

— Нишләп берүде генә булсын Нәҗибулла?.. Безднең ярты авыл шунда бит... Минем Сәлахетдинкәем дә шунда... Синең Хөснимәрдәнең дә... Әтәй-инәйләр дә...

— Үдекәең тәмле итебләр пешерәсең инде пешерсәң...— диде Мөслимә карчык, авызын чапылдата-чапылдата.— Мин үдем дә анысы би-и-ик тәмле итеб пешерәм... Камырга синең кеүек осталыгым бар... Бар осталыгым... Аллага шөкер!.. Бу араларда гына пешергән

җук әле бер дә... Вышшай сурт онкаем бар җугыйсә... Вакыт тимәй бит... вакыт тимәй... Көн туганы саен синең кеүекләрнең хәлкәйләрен белеб җөре-җөре дә, каян килсен ди ул вакыт... Үлеб китсәгезд, миннән башка белүчекәй дә җук бит сездне... Җарый әле иренмәенчә үдем җөргән булам... Ырматиздлы аякларым белән... Аякларымның җаман ауыртканын бөтен ауыл, бөтен районуи белә җугыйсә... Ник берәрегезд: «Мә, Мөслимәкәем, сөртеб карале шуны!» — дип, берәр төрле әптик мае бирсен...

Мөслимә карчыкның кулы көлчә салынган коштабак белән авыз тирәсендә байтак хәрәкәтләнә торгач арыды, ахры,— аның авыз чапылдатуы сирәгәйде.

— Башта бик тәмле сымак тоелган кеүек булган иде. Әллә син камырыңны күкәйгә идмәдеңме? Тозд барлыгы да сиделми,— диде ул, суына төшкән чәен тәмләп кенә уртлый-уртлый.

— Тагы да бер сынык ашасаң, камыр барлыгы да сиделмәс сиңа... Әч, әйдә, чәй ясаем...— диде Вәсбиҗамал карчык һәм икесенең дә алдындагы чынаякларга бәләкәй чәйнектән чәй агызды.

— Күкәй дигәннән, синең тауыкларың саламы суң? Минем бер җауыз тәре Һаҗәргә иләшәште бит, нәгаләт... Шуның лапасыннан алып чыгам көн саен... Үдең беләсең... Аяклар ауырткач, җөрүе ауыр... Ике арадагы читәнгә атланалмай интегебләр бетәм... Ул атлангач төшәлмәй җәфалануларымны күрсәң син... Бер Ходай үде генә белә гадапланганнарымны... Бал Әхәтенә суйдырмай булмас ул җавызд керисне... Бөтенләй адынды... Күршеңә ирең белән таугың иләшмәсен берүк, дип бә-ә-әк белеп әйткәннәр шул борынгылар... бә-ә-әк белеп әйткәннәр, Вәсбиҗамалкаем...

Мөслимә карчык тимер караватның ялтыр дугасыннан тастымал үрелеп алды да тирләгән маңгаен, битләрен сөртергә тотынды.

— Тастымалыңны күргәч искә төште әле... Пырашуклаб җуасыңмы суң моны? Агарган кеүек күренә... Моңа кер сабыны әрәм итмәгәнсеңдер?.. Минем үдемнең бу араларда кер-мадар җуыб пычраныргa вакыткайларым булмады... Кыдым былтырларны өч каб пырашук китереб киткәние... Шул килеш җаталар... Пырашук бик кадерле бит ул хәдер... Җукка-барга тотыб булмый аны... Аннары суң, аяклар да бик җаман сыздлаб интектерә бит. Вәсбиҗамалкаем... сыздлай, ие!.. Үләм-бетәм икән диб торам кайчакларда... Ие... Бөтен районуи белә бит минем аякларда ырматизд икәнен... кеше генә ышанмый... Мин бу бастырык чаклы таякны җукка гына сүрәб җөрмә-

ем... Аякларым бик җаман ауыртканга сүрәем... Үзд башыңа төшкәч кенә ышанасың икән аны, Вәсбиҗамалкаем... Кая... Куздгалаем инде мин... Ашыккан кешенең җулда булуы хәерле... Барыб кайтаем инде шул Димагур Нәҗиб Хәмдиясенә... Үлеб-мадар китмәгәе... Аңа ышансаң... Үләр дә! Исән чагында беркайчан кешегә әйтеб эш эшләй белмәде... Әйтеб дигәннән, рәхмәт әйтеб тормаем... Кайтканда, җаныңа тагы сугылырмын... Хәлеңне белеб чыкмау килешмәс... Күрше була торыб... Аннан суң... дөнҗа хәлен дә белеб бетереб булмай... Үлебнитеб куюың бар...

Мөслимә кортка, шулай сөйләнә-сөйләнә, ишеккә таба атлады.

— Син, кемкәем! — дип дәште аңа Вәсбиҗамал карчык,— уклауыңны оныттың бит. Үдең аяк сыздлай, дисең...

— Җарар, торсын әле синдә,— диде Мөслимә кортка, артына борылып карамыйча гына,— ул бастырыкны җугарычка чаклук сүрәб җөрмәм инде... Аякларым болай да... ырматиздлап тора...

Ул җил капканы ачып урамга чыкты. Бермәл әле уңга, әле сул тарафына карап алды...

«Сәхипкамалга кереб чыгаем әле. Морҗасыннан төтен бик мул чыга. Тәгаен бер-бер нәрсә пешереб җатуыдыр»,— дип уйлап, Мөслимә кортка аякларын хәрәкәткә китерде.

*2 февраль, 1994*

# Ярдәм итегез, иптәш язучылар!

*(Зур Имән авылында яшәүче Габдрахман Хисмәтуллинның язучыларга үтенеч-хаты)*

Сәламәтләрмесез, иптәш язучылар?!

Сезләргә Зур Имән авылының атказанган калхузнигы Габдрахман Хисмәтуллиннан ялкынлы кайнар сәлам!

Минем тормыш иптәшем катын да, и шулай ук безнең уртак кызыбыз белән аның иптәш кияве дә сезләргә тагын да катырак сәламнәрен җибәреп калалар. И тагдалие...

Кайнар сәламнәр тәмам, и мин хәзер төп вапруска күчәм.

Вапрус вот нәрсәдә, иптәш язучылар!

Менә ничәмә җыл инде минем катын сезнең шикелле дикламатсияләр яза. Шуның өстәвенә бәетләр, җырулар чыгара. И тагдалие...

Баштагынак мин аның бу эшенә, кем әйтмешли, бармак аша гына караганыем. Үзегез беләсез, яшь чакта һәркем үзенчә исәр була бит инде ул. Катын-кызлар бигрәк тә! Ә минем катын исәр генә түгел, ә исәрлекнең аръягына чыккан катын булып чыкты, нәгаләт! Асубый исәр, мин әйтерием... Шулай дигәнгә үзе үпкәләми тагы...

Әйткәннәрие аны, язучы-сызучы халкы бераз тегеләйрәк була, диеп... Хак икән... Мин моның тәгаен шулай икәнлегенә үземнең катынга карап ышандым.

Әйе, дикламатсияләр яза бу. Көне буе быдыр-быдыр сөйләнеп, авыз эчендә ботка пешереп йөри-йөри дә төне буе яза...

Шуннан чыгып, чәй кайнату, калган ашны җылыту, көтү чыгару кебек иртәнге көндәлек эшләрнең минем җилкәгә төшкәнен чамалыйсыздыр инде...

Ашап-эчкәч, мин үз эшемә — скутник мин — фермага чыгып китәм, ә катын үз эшенә... Эш дип, аның эшен эш дисәң дә инде. Китапханәче ул... Кешеләргә укырга китап биреп торучы. Биреп торучы дип, хәзер китап укучы кеше дә юк бит безнең авылда. Шул бер Кылый Габдерәүф бар. Ферма каравылчысы Габдерәүф абзыйны әйтәм... укый-укый ул да дөм сукырга әйләнеп бара бугай инде. Болай да минус-плүс әллә ничәле күзлек кия!.. Хәзер бит тиливизыр заманы. Күрсәтәме-күрсәтмиме, шул яшнигенә сагыздайябышып ята...

Бер җыл түздем катынның кәгазь туздыруына. Ике җыл чыдадым. Өченче җылны тәртә сынды: тотып кистем мин моны. Катынны әйтәм... Кистем дип, кисүен үк кисмәдем инде... Ну бер-ике тапкыр ару гына чиртеп алдым... И тагдалие... Әллә минем чиртү чиртү ише генә булмады, әллә катын асубый сурттан булып чыкты... Мие селкенеп, ике кабыргасы сынып, ашказаны урыныннан күчеп, бүлнистә ярты җыл ятып кайтты бу.

Үзенең гаепле икәнлеген аңлаганга микән, мине судка-фәләнгә биреп тормады тагы катын... Ул яктан миравайлыгы бар. Анысы факты!.. Төпченергә азапланган участкавай Бәдримуллинның авызын мунча ләүкәсеннән егылып төштем, дип каплады да куйды. Тегесе дә тинтәк инде, мунчага кереп карыйсы гына бит. Керсә, ләүкәнең юклыгын маминт күрәсе иде җугыйсә... Аның тинтәклеге минем файдага плүс булды. Факты!

Катынның анасы, ягъни миңа әби тиешле кеше, бик адарынып караган иде тужы. Катын үзенекен сукалагач, ул да тынарга мәҗбүр булды...

Катынның мие селкенүе бер дә минем файдага булып чыкмады, иптәш язучы иптәшләр: ул отыры котырып

яза башлады. Гәҗитләрдә кайбер кыз-катыннарның дикламатсияләрен еш бастыралар. Шуларны күргәч, минем калхузник башыма бер уй килеп-килеп киткәләп алды... Әллә, минәйтәм, боларның да миләрен селкеткәләп алдылар микән? Бу, канишне, минем, прастуй кешенең, прастуй уе гына инде. Алай ук булмавы да бик мужыт. Үземнең катынга карагач, аптыраганнан шундый уйлар да уйлап куярга туры килгәнгә генә әйтүем...

Шулай итеп, әкертенләп, иртән мал-туарны көтүгә чыгару минем җилкәгә төште. Тора-бара сыерны сава башларга туры килде...

Катынның язганнарын бер дә укып караган юк иде. Беркөнне укырга җай чыкты. Мусыр чиләгенә ташлаган бер кәгазен юри алып карадым. Болай үзе язган-сызганнарын чит-ят күздән яшереп саклый ул. Чит-ят күзнең кем икәнлеге аңлашыладыр инде...

Чәй чүпләренең сарысы сеңеп саргайган, бөгәрләнгән, юешләнгән кәгазьдәге дикламатсиянең мин укый алган чаклысы болайрак иде:

Бакчадагы чәчәкләргә
Бидрәләп су сиптем инде...
Сине көтеп, җанкисәгем,
Саргайдым, киптем инде...

Бу сүзләр мине тагын чыгырдан чыгарды. Ләкин бу юлысы катынга чиртмәдем. Аяк-куллар үтереп кычытты кычытуын, ләкин чиртмәдем. Капкан саен майлы калҗа, кочкан саен марҗа булмый дигәндәй... Катын гел-гел баш биреп тормас, тотар да участкавайга телен чишәр... Анасы да миңа кыҗрап, җай чыкканны гына көтеп йөри...

Чиртмәсәм дә, ну әйтәсен әйттем катынга!.. Күгәреп ләр катты месkенкәем... Әйе, үзен бераз жәлләп тә куйдым шул чакта. Ни генә әйтсәң дә, катын тиешле кеше бит инде ул... Кем әйтмешли, балага — ана, миңа — тумача... и тагдалие...

— Син нәрсә,— мин әйтәм,— үз гомереңдә сыңар бидрә тотмаган башың белән шундый дикламатсия яздың? Син нәрсә,— мин әйтәм,— тагын кемнедер уйлап, саргаеп-кибеп ятасың әле? Атвичай?!

Признавать итәм, иптәш язучылар, бик яман сүгендем... Анысы факты! Беләсезме, минем ярсып кычкыруымнан куркып башта телсез калса да, бераздан кеше кыяфәтенә кайтты тагы үзе. Мин аны аяк астына егылып ятар дип уйлаган идем... Какуй!

— Габдрахманкаем,— ди,— мин бит уйлап чыгарып кына язам,— ди... — Хыялымда үзем тудырган кешегә

шулай дәшәм мин,— ди... — Бөтен язучы да дикламатсиясен шулай уйлап чыгарып яза,— ди... и тагдалие...

— Бүтән язучыда минем эшем юк! — минәйтәм.— Язучылар шуңа да язучылар алар! — минәйтәм.— Ә син — минем катын! Яснымы? — минәйтәм...

«Ясны!» дими бит катын, нәгаләт... Күзләрен иләмсез шарландырып, гөнаһсыз бала шикелле тик карап тора.

— Соң,— минәйтәм,— аңла син, фәлән итим: ашарга пешерүне оныттың, идән-мазар юу ике ятып бер төшеңә дә керми, табак-савытларны әйткән дә юк... Инде анаңа әйтсәң, анаң да ышанмас — чөлкә каткан саен үзем юам бит! — минәйтәм...

— Мин гәҗиттән укыдым,— ди бу, тыныч кына,— чит илдә аднаразывый чөлкәләр генә кияләр икән... Безгә дә шулай итәргә кирәк... Акча эшләп торабыз бит!..

Күрәм, өй эшләре белән матавыкланырга исәбендә дә юк моның...

Бермәлләрне мин бу дикламаторны әллә аерып җибәрим микән, дип тә уйлаган идем. Бала жәлке булды. Бала дигәннән, анысы белән хәзер иптәш кияү интегә. Алма агачыннан ерак төшми, диләр... Дөрес бу, факты!.. Кыз тужы яза. Бер чорларны иптәш кияү миңа килеп зарлангалап караган иде дә, минем хәлнең хужырак икәнен белгәч, зарлануыннан туктады. Хәзер көне-төне эчә. Кыз көне-төне яза... И тагдалие...

Мин дә дөньясын онытып эчәр идем дә анысы... Ярамый, нәгаләт. Язвы желудкы... Ә катында чурт та юк! Җүләр кешене чир алмый, диләр бит аны...

Кыскасы, иптәш язучылар, күреп торасыз, минем хәлләр бик коточкыч. Шартлап үләрлек!

Мин уйлап-уйлап утырдым да беркөнне мондый карарга килдем, иптәш язучылар: ярдәм итсәгез, сез генә ярдәм итә аласыз икән бит миңа... Ничек итепме?

Минем ишеткәнем бар: сез үзегезнең калхузыгызга әгъзамы-членмы итеп бераз гына язган-сызгалаган кешеләрне дә аласыз икән... Ул язган-сызган кешеләр әгъза булгач, бөтенләй язуларын ташлыйлар икән... Зинаһарлап сорыйм, иптәш язучылар, алыгыз минем катынны да әгъза итеп, ә?! Ярдәм итегез, пажалысты! Майларга-җайларга кирәк булса, анысыннан гына тормам... Кирәк икән, итен-маен, хәтта балын да табырмын. Баҗай умартачы минем. Берочтан кызны да алсагыз иде. Кияү бигрәк жәлке бит!.. Күрәләтә шәп кеше бетеп бара бит, иптәш язучылар... Урыныгыз җитәрлек булса, катынның анасын да алыгыз! Ул язуын язмый түлке... Әмма теле бик зәһәр... Тел белгече итеп алыгыз аны!.. Теленнән

язмас микән?! Чәчләремне вакытсыз шул гына и аннан — кызы, ягъни минем катын гына агартты... Сез ярдәм итмәсәгез, пеләшкә әйләндерәчәк алар мине...

Ату, дөньясына үч итеп, үзем дә яза башлаячакмын! Безнең калхуз менә дигән скутнигын югалтачак югалтуын... Чурт с ним!.. Зату, сезнең калхуз отачак миннән!.. Сезнең шикелле үземә кушамат уйлап куйдым инде: Габдрахман Зур Имәни булачакмын. Китаплар итеп тә бастырачакмын, белеп торыгыз аны! Каралты-кураны сатсам сатам, вәләкин шуларны эшләячәкмен! Минем бүтән хутым юк!..

*Сездән утенеп, тиз көндә шатлыклы хәбәр көтеп:*
*Габдрахман Хисмәтуллин (Габдрахман Зур Имәни).*
*13 март, 1994*

# Скелет

Якшәмбе киче. Барчабыз да өйдә. Хатын белән икәү кухняда юктан барны хәстәрләргә азапланабыз. Олы кызыбыз Айсылу, телевизорыннан арынып, безнең тарафка сугыласы итте.

— Иртәгә миңа тавык кирәк! — диде ул.

— Беребезгә дә мишәйт итми ул,— дидем мин.

— Юк, әти, дөрес аңламадың,— диде кызым.— Укытучы алып килергә кушты аны.

— Нәрсә, хәзер укытучыларны ашатырга-эчертергә дә тиешмени инде без? — дидем, хатыныма мыскыллы караш ташлап. Ул да укытучы, шуңа күрә аңа карап әйттем.— Әллә сиңа да тавык-каз алып килеп ашаталармы? Без монда сөтле су чөмереп интегәбез...

— Син дөрес аңламадың,— диде хатыным да.— Тавык Айсылуның дәресенә кирәк ул. Укытучылары һәр укучыга да алып килергә кушкан.

Мин җүләр түгел, аңладым.

— Сыер да сорамаганмы әле? — дидем мин, укытучыларына яман да ачуым килеп.

— Әлегә юк,— диде кызым, битараф кына.— Әмма иртәгә тавык кирәк.

— Анаң сыңары! — минәйтәм.— Суыткычта сөяк валчыгы да юк бит. Каян килсен ул тавык хәтле тавык!

— Алыгыз соң! — диде кызым.

— Алырга акча юк! — дидем мин.

— Иртәгә иртәнгә тавык кына булсын. Анысы мине кызыксындырмый. Сезнең аркада икеле аласым килми,— диде дә кызым телевизоры янына китте.

Мин сораулы карашымны хатыныма төбәдем. Хатын да ул хәтле җуләр түгел икән, шундук аңлады.

— Кырып себерсәк, акча күгәрчен хәтле тавыкка гына җитәргә тиеш! — диде ул.

Киенгәндәй иттек тә киттек кибеткә. Акча булмаганда кирәк нәрсә бик тиз күзгә чалына бит ул. Тавык шәен бик тиз күреп алдык. Сагындырга-а-ан...

Чыннан да, хатын дөрес чамалаган икән. Акча күгәрчен төсле бер күксел «йодрык»ка тәки җитте.

— Пешерергә яратасың, үзең пешерерсең,— диде хатын, тавык йомарламын чүпрәк букчаның төбенә үк иләп кенә куеп.

— Әле моны пешерәсе дәмени?! — дидем мин. Хатынымның җавабы шул булды:

— Аш майлы булсын дисәң, шулпага аз гына үсемлек мае тамызырсың...

Ярый, кайттык. Пешердем. Тавыкны бүлгәндәй иттем дә кызны чакырдым.

— Минем эш беттеме инде? — минәйтәм.

— Миңа ите кирәкми, сөякләре генә кирәк,— диде кызым.

— Ите булса, сөяген генә табарбыз! — дидем мин, эре генә.

— Тавыкны ботарламаска иде. Миңа скелет кыяфәтендә булуы кирәк. Кайсы сөякнең кайсы сөяктән соң килүе беленерлек булсын! — диде кызым.

Ул әйтте — мин эшләдем. Кемнең кулында — шуның авызында дигәндәй, бер-ике чеметем ит валчыгын буш ашказанына сиптем. Ашказаным әллә ни сөенмәде шикелле.

Икенче көнне кызым бишле алып кайтты. Аннан битәр мин сөендем. Ни әйтсәң дә, ул белемдә минем өлешем бар бит. Элгәре хатын да шулай сөенгән булган икән. Балык скелеты хәстәрләп җибәргәч. Нигәдер мин анысын хәтерләмим. Эштәге көндәлек мәҗлестән кайткан чагым булгандыр инде.

Балык, тавык... Болар белән генә эш бетмәде әле. Сыерга ук барып җитмәдек, әмма мескен сарыкны хәл итеп мәктәпкә озаттык.

Сыерга әзерләнеп йөргән көннәрнең берсендә сөекле кызыбыз кайтып әйтте:

— Әти, укытучы иртәгә сине алып килергә кушты!

— Кешегә үк җиттегезмени инде? — дигәнемне генә хәтерлим... Хатынымның төкеренгәләвеннәнме, су бөркүеннәнме аңыма килдем.

— Әти, син дөрес аңламадың,— диде кызым.— Иртә-

гә Динарның әтисе акула скелетын алып килә. Беләсең инде син Динарны?! Әтиләре гел чит илгә барып кайта. Акула скелетын шуннан алып кайта. Шуны күтәрешергә әтиләр кирәк. Аңладыңмы инде?

Мин хәлсез генә елмайгандай иттем.

— Кешегә килгәндә... «Кеше» дәресе киләсе елда гына керә бугай әле, әти! — диде кызым. Тынычландырды.

*13 сентябрь, 2000*

## Шундый кеше инде мин

Нишләптер шундый кеше булганмын инде мин. Тумыштан ук, ягъни мәсәлән. Әни, вакыты җиткәч, бүлнискә киткән. Дөресрәге, әти ат белән илтеп куйган. Әни абыйны табарга тиеш булган. Ләкин, Ходайның хикмәте, мине тапкан. Әти миннән алдан туасы абыйга исем дә уйлаган булган: Кипарис. Әти бакчачы минем, һәвәскәр. Табигатьне бик ярата. Миңа абый тиешле кеше тумагач,— аның урынына мин туганмын бит инде,— әти миңа башка исем кушкан. Гөл исеме — Фикус. Безнең Актаныш ягында әтиләр яңа туган балаларына гел шундый ягымлы, матур яңгырашлы исемнәр куярга яраталар.

Әле уйлап куйдым: абый урынына туганга, мин шундыйрак кешедер инде. Ничек дип әйтим, сәеррәк дисәң, сәер дә түгел инде мин, башсыз дияр идем — баш бар, артык акыллы дип әйтер идем — акыл да болай таман гына кебек шикелле. Кыскасы, әллә нинди... әллә нинди кеше инде мин...

Беркөнне шулай урам буйлап барам. Урам буйлап дип... Тротуардан барам. Күрәм: зеррә шәп бер хатын минем алдан теркелди. Тек-тек, тек-тек... Алдан ничектер, әмма дә ләкин арттан коточкыч шәп күренә инде. Тотып карыйсы килеп, перәме кул кычыта башлады. Чыдаплар гына булмый, ялгыш кына булса да орынып китәсе килә бит моңа. Түзмәдем, адымнарымны кызулаттым да, куып җитеп, җәһәт кенә әлеге хатынның бил тирәсенә кагылып алдым. Бу җәлт борылып карауга, мин чүт кенә артка авып китмәдем. Каршымда үз хатыным акаеп тора иде. Минем яңакка төшәсе кулы һавада эленеп калды. Бүлнис ятагында атна-ун көн чиләнәселәрем күз алдымнан яшен тизлегендә йөгереп узды.

Менә шундый кеше инде мин. Гел шулай. Чит хатын дигәнем үземнең хатын булып чыга, үземнеке дип уйласам, чит-ят булып чыга.

Минем өйләнүем дә кешенеке төсле булмады бит. Сәкинәгә өйләнергә тиеш идем мин. Загска гариза да илтеп биргән идек. Язылышасы көнне трамвайга утырам дип, электричкага утырганмын ялгыш, ә ул электричка дигәнем скорый поезд булып чыкты. Канаштан көч-хәл белән кайтып җиттем. Югыйсә мин трамвайга утырып, парикмахерскийга гына барып, дустым Шәвәли үзенең кара «Волга»сы белән килеп җиткәнче, чәчне төзәткәләп кенә кайтмакчы идем... Шул... мин икенче көнне загска килгәндә, Сәкинә бүтән кешегә кияүгә чыгып куйган иде инде. Ә бу, хәзерге хатынны әйтәм, шул загс төбендә ялгызы басып тора. Кыбырсына. Нигә шулхәтле өтәләнә икән бу дисәм, булачак кияве килмәгән икән. Соңыннан, без өйләнешкәч, ачыкланды: булачак кияү таң тишегеннән үк мунчага киткән икән дә юлда дусишләре очраган. Шуннан вәссәлам — оныткан өйләнәсе икәнен. Бәхете булган инде. Бәладән Ходай үзе саклап калган булырга тиеш аны. Әле хәзергәчә өйләнгәне юк...

Әйтәм бит, тумыштан ук шундый кеше инде мин. Бервакыт кибеттән пластмасс урындык сатып алып кайттым. Кайткач, урындыкны идәнгә куеп караган идем — што-то ни то. Дүрт аякның берсе озынрак шикелле. Нишләргә? Уйладым-уйладым да, газ плитәсенә таба куеп, шунда урындыкның озын аягын әз генә эретеп тигезләмәкче булдым. Эреткәч карыйм: өч аяк озын, бусы кыска. Шуннан тотындым әлеге өч аякны эретергә... Аннан соң дүртенче аякны... Бүлмәгә зәңгәр төтен һәм ачы ис таралганда, урындыкның аяк дип әйтерлек нәрсәсе калмаган иде инде...

Шундый инде мин — әллә нинди. Берчакны шулай, эштән иртәрәк кайттым. Туктале, мәйтәм. Суыткычны ачтым, полиэтилен капчыкта фарш сыман бер йомарлам ит бар иде — тондырдым шуны мискидәге суга. Тотындым бәрәңге әрчергә. Ашка тоз салып, болгаткалап алам.

Хатын кайтып керде бермәл.

— Нишлисең? — ди бу гаҗәпләнеп.

— Күрмисеңмени, бәрәңге әрчим,— мәйтәм.

— Кыздырасыңмы? — ди хатын.

— Юк,— мәйтәм,— ашка салырга бу.

— Ит кайдан алдың? — дип төпченде хатын.

— Суыткычта бар иде, фарш! — мәйтәм.

Хатынның күзләре әрчелмәгән бәрәңге хәтле булып зурайды.

— Безнең ит юк бит, миңгерәү тәре! Ул бит чүпрә иде! — ди бу.

— Әйтәм аны,— мәйтәм,— мин ашны болгаткан чакта, ит юкка чыкты...

Шундый инде мин...

Кичә «Балык» кибетенә сугылган идем. Балык исе — заразы ис бит ул, каһәр. Башта ис борынны кытыклады, аннары тамак төбен кымырҗытты, шуннан соң ашказанын аңгырайтты. Кесәдә акча бар чак иде, кызыгып, бер кила скумбрия сатып алдым. Өйгә кайткач, беренче сорт онда әвәләп, тозын-тәмләткечләрен салып кыздырырга куйдым. Таба белән капкач ярыгыннан кысылып пар чыга башлагач, балыкның хәл-әхвәле белән кызыксындым. Күяргә маташу түгел, пешәргә дә уйламый, нәгаләт. Кыяфәте дә әллә нинди шунда, шыксыз. Кабып карагач кына белдем — кибеттән тозлы балык сатып алган булганмын икән. Шуны кыздырып азапланам икән...

Шундый инде мин...

Бүген хатынның туган көне. Күңеле булсын, бүләк алып кайттым әле үзенә. Затлы күлмәк. Изүе ачык. Чәчәкле. Чәчәклесен чәчәкле... Тик менә... Җәеп карарга гына шөлләп торам. Што-то ир-ат ыштанына охшаган. Нишләптер...

Шундый инде мин...

## Юк-юк, агай-эне!..

Юк-юк, агай-эне, мин эчмим. Ташладым. Җитте! Күпме эчәргә була инде. Организм — тимер түгел бит ул. Тимер булып тимер дә әле, әгәр аңа яңгыр-мазар яисә су тисә, тутыга башлый. Күп эчтем мин заманында, ай-яй күп эчтем. Кем әйтмешли, бүчкесендә йөздем. Хәзер юк, эчмим. Эчмим и шуның белән вәссәлам! Ә син эч, эч. Син яшь әле. Организмың нык чак. Минеке генә менә... Төннәрен йоклый алмый интегәм. Алай-болай йоклап китсәм дә, коточкыч төшләр күреп, шундук уянам. Һай, ул төшләр! Боевикларың, куркыныч киноларың бер читтә торсын. Элек алай түгел иде. Андый төшләр керер интектерми иде. Эчәр идең, рәхәтләнеп йоклар идең. Уянгач, ләззәтле минутлар кичерә-кичерә, баш төзәтеп җифәрер идең... Төзәлгән башны җайлап-майлап, эштә көне буе ду килеп, ял итеп йөргән булыр идең...

Әй-йе, бар иде шәп чаклар... Юк-юк, агай-эне, үткәнне сагынып әйтүем түгел. Мин, гомумән, үткәнне сагыну түгел, искә төшерергә дә яратмыйм. Киләчәкне сагынам мин. Анысы факыт! Киләчәк — кеше хисабына эчәсе йөз грамм кебек үк кадерле ул. Мин элек тә шулай уйлый идем, хәзер дә шул фикердә. Син эч, эч, миңа карама. Үтмәсә, аз-азлап йотып кара. Менә миндә балык са-

ңагы бар икән, шуны суырып җиффәр. Тозлы нәрсәләрнең кайвакыт файдасы тия аның. Например, мин үзем, махмырдан интеккән чакларда, гел тозлы ризыклар каплыйм. Эчеп куйгач, зерә дә шәп нәрсә инде алар. Биш яшьтә чакта эчә башладым мин. Дөрес әйтәсең, стаж бар анысы. Бар. Бу яктан әллә кайчан ук пенсионер инде абзаң...

Безнең өйгә кунаклар еш килә иде. Әлбәттә, эчәргә-ашарга киләләр. Умарта күчедәй гөжли-гөжли сөйләшәләр, макташалар, мактанышалар. Исерешәләр. Мин, әйткәнемчә, биш яшьлек малай, аларның тизрәк кайтып китүләрен теләп кыбырсып йөрим. Әти белән әни һавага таяна башлаган ахыргы кунакны озатырга дип тышка чыгып китүгә, мин авызга әллүр бер-ике эрүмкәне. Кыяр телемен эләктереп, янә әллүр юрган астына. Әти белән әни өйгә кайчан кергәнне кая ул хәтерләү! Әллә йокы, әллә аракы бик тиз ала иде, каһәр... Хәзер канкрыйт әйтә алмыйм, агай-эне. Мөгаен, икесенең дә роле зур булгандыр...

Беренче класста укыган чакта, сигезенче классның бер малаен тәпәләп аттым. Дөресрәге, бик каты бәргәләгәнмен. Исерек баштан инде, исерек баштан, һай, ул чаклар... Сагындыра балачак, сагындыра-а-а... Кайсыдыр җырчы җырлагандай, кайтыр идем шул чакларга, әгәр кайта торган юл булса... Ул вакытта аның аракысы да очсыз иде бит, шайтан алгыры! Бормотухалар турында әйтмим дә инде...

Күрәм, синең хәлең җиңеләйде, ахрысы. Йөзләрең алсуланып, яктырып китте. Болай булгач, үлмисең инде, үлмисең. Кара, кара, күзләреңдә кояш көлә башлады хәтта. Килешкән кешегә килешә бит ул, каһәр. Әллә соң... Әйдә, чукыныплар гына китсен дөньясы, сал миңа да бераз. Булды, булды, булды! Стаканны мөлдерәмә итмәсәң дә ярый иде бу юлысына. Син, агай-эне, минем кулларның дерелдәвенә игътибар итмә инде. Кичә... ни... каты нителгән... Хатынның энесенең, бертуган энесенең дип әйтүем инде, шуның бердәнбер җизнәсе белән ару гына җиффәргәнбез... Әйдә, манчыдык!

## Кырыктан соң – шырыкка (түгел)

— Сиңа ничә яшь, энекәш? Унтугыз?! Булмас. Шаяртасыңдыр. Чынлапмыни?! Мин бит сине утыз яшьлек җегет дип торам. Чөнки дә кыяфәтең шулай сөйли. Күп эчкәннеке ул, дисеңме? Шулкадәр үк эчмисеңдер инде. Яшь бит әле син. Күп эчәр өчен балачактан ук тәҗрибә тупларга кирәк. Минем кебек. Юк, энекәш, ялгышасың.

Эчкәннән генә йөз-кыяфәт болай булмый. Тормыш баса кешене, энекәш, тормыш изә. Хәзер заманасы авыр бит, яшәүләре үзе бер газап. Синең яшьтә миңа утызны бирмиләр иде. Утызны ук... Ю-ю-ук! Кырыкны биргәләделәр, утызны ялгыш та бирүче булмады... Унтугыз, дисең, ә?! Синең яшиселәр алда икән әле. Үлмәсәң. Өйләнгәнме соң үзең? Әйтергә кыенсынсаң, әйтмә. Болай гына соравым. Аерылыштыгызмыни инде? Кайчан? Алты ел элек? Да-а... Саумы, кода!.. Хәзер яшьләр тиз өлгерә шул. Күкәй салырга өлгермисең, этәч булып кычкыра башлыйлар. Тагын өйләнергә исәп юкмы? Әйе шул, ныклап уйланыр өчен алты ел гына аз. Авызың бер пешсә, уйландыра ул. Син күргәннәр минем дә баштан үтте. Бер, ике, өч... Тәк. Җәмгысы алты икән. Алты тапкыр бик каты уйландым мин дә. Җиденчесеннән соң да уйланырга туры килмәгәе дип йөрим әле менә... Әйе шул! Хак әйтәсең. Хатын-кызны аңлап булмый аны. Өйләнгәнче, фәрештә кебек үзләре, өйләнгәч, иблистән дә хужега әйләнәләр. Өч тиенлек акыллары юк, сиңа акыл сатып маташалар. Өйләнмәсәң дә кыен. Шешәләрне үзең көн саен җыештыргаласаң да, өйне тәртиптә тотарга барыбер хатын-кыз кулы кирәк. Шапшак тормышны җенем сөйми минем. Гигиена — минем яшәү рәвешем. Дус-ишләр килгәндә, стаканнар һәрчак юылган була. Юмыйча ярамый. Үзең беләсең, хәзер СПИДтыр-чурттыр ише аразалар басты дөньяны. Саклангинны саклармын, дигән Ходай. Сакланырга кирәк...

Ничә яшь дидең әле үзеңә?.. Әйе... Унтугыз, дидең бит әле. Миңа менә — кырык. Узган ел тулды. Хак бугай. Бөтен гәүдәне чир басты. Тудый-судый эчемлектән гайре ризык-фәлән үтми тамактан. Көн саен иртә белән баш авырта. Түзәр-чыдар әмәлләр юк. Синең дә шулаймыни?! Сәе-ер... Яшь бит әле син. Хәер, кыяфәтеңә карап, утызны бирергә була, дидем бит әле... Иртәләрен бик яман укшыта. Ашказаны, үпкәсе-бавыры — бөтенесе бергә укмашып-каерылыплар килә инде менә. Синең дәме? Йөрәккә китереп сукканчы, табибка күренергә кирәк сиңа, энекәш. Эт врачына булса да күрен. Йөрмә болай, үзеңне бетереп. Яшь бит әле син...

Ниме соң, исәпләгәнең бармы — эчкәнең көнгә күпме чыга? Да-а-а... Саумы, кода-а!.. Монысы ничәнчесе? Икенчесе?! Көнгә ике шешә күп бит, уйлап карасаң... Ә-ә-ә... Тәүлек буена дүрткә җыела, дисәң генә... Эчкәндә капкалыйсыңдыр бит?! Ризык-фәлән, диюем... Ю-ю-ук, энекәш, болай булмый. Бетәсең. Сәвсим бетәсең. Ике-өч бөртек көнбагыш чәйнәп кенә ерак киталмассың син... Ми-

нем яшь чактагы шикелле, сәламәтлегең ярыйсы гына инде. Миннән үрнәк ал син. Кесә төбендә булса, кайчагында ипи катысы суыргалап алам мин. Менә мә, сиңа да бирәм. Җитә ул сиңа. Миңа калдырмасаң да була. Минем ашыйсым килми. Әйтәм бит, ризык үтми тамактан, дим. Кара, кара, эһ тә итмичә эчеп куйдың. Чыраеңны да сытмадың хәтта. Яшь шул әле син. Яшь чакта су шикелле үтә инде ул шулай. Менә минем кебек кырыкка җиткәч... Минеке дә әйбәт үтте тагы. Икенче мәртәбәсендә гел әйбәт үтә ул, сынаганым бар...

Ниме соң, атаң-анаң исән-саумы? Монысы әйбәт икән. Әти-әни исән булганда, яшәүләре үзе бер ләззәт. Кайда эшлиләр? Ә-ә-ә... пенсиядәмени? Ашарга-эчәргә җитәме соң пенсияләре? Сиңа җиткәч, ярый инде. Карт-коры чәй белән дә торала ул. Әй-йе, хәзер бит чәкүшкәсе генә түгел, ризыгы-фәләне дә, кием-салымы да бик кыйммәт. Робинзон кебек ярым шәрә йөреп булмый бит инде. Теге-бу йомыш белән урамга чыгасы, кибеткә барасы була. Менә шулай, синең белән минем шикелле, күңелле итеп гәпләшәсе дә килә. Киемсез кем син? Трусиклы маймыл! Ыштаның да булмаса... Шул... шул... кыңгыраулы адәм гыйбрәте!

Карале, син мәлҗерәйдең түгелме соң? Салма инде башыңны пычрак тәлинкәгә. Безнеке түгел ул. Әнә бу сукбайныкы. Иелеп карасаң, күрәсең син аны — безнең аяк астында гына ята ул. Шулкадәр эчмәсә... Алкаш тәре! Кая ятасың инде син дә? Йә Хода! Косыгыңа чыраеңны батырдың бит. Уф! Үземнең дә аяклар тотмый башлады... Хәл бетте... Син генә җәелеп ятарга димәгән. Читкәрәк ал әле сыйракларыңны...

*2001*

# Черек алма

Бер-бер нәрсә күрсәм, икенче бернәрсә искә төшә минем. Гел шулай. Әйтик, мәсәлән, кибеттәме, базардамы, күрше бакчасындамы, кеше букчасындамы, хет теләсә кайда, хет теләсә кемдә алма күрәм икән,— әйе, әйе, гапгади алма! — шундук Черек Сапый искә төшә. Черек Сапый — минем коренной дус, ягъни, үзебезчә, гәҗит теле белән әйтсәк, тамырдаш дус. Черек Сапый — дусның кушаматы. Кесәсендә һәрвакыт черек алма йөртә чөнки. Бер-бер кирәге чыгар дип. Кирәге чыга да! Берәрне җиффәргән саен, чиратлап, әзләп-мәзләп кабабыз. Сапыйның шул бер черек алмасы, өч борыннан, кайвакыт-

та икедән генә исәпләгәндә дә, дүрт флакон спиртны манчыргга җитә. Әле кала да... Калганын, айныгач, өстәп, тагын кабабыз. Әз-әзләп...

Әйтәм бит, бер-бер нәрсә күрсәм, кайчак бер-бер нәрсә ишетсәм дә, гел шулай икенче бернәрсә искә төшә. Кремль күрсәм, мәсәлән, йолдызлар күпләп-күпләп күз алдыма килә. Сапый искә төшә. Кичә Сапый дус белән тагын саф һавада шактый ятылган. Салкын йолдызлар дер-дер янып уятмаса, кайтыр юлны, билләһи газыйм, табасы түгел идек. Адәм баласына авыр чакта йолдызлар ярдәмгә килер, дип, борынгылар бик белеп әйткәннәр шул... Тәҗрибәләре булмаса, алай бик кистереп әйтә алмаслар иде, бахырлар...

Аһ, нәгаләт, әнә тагын Сапый килә... Икесе дә дерелдиләр... Берсе өстәвенә черек тешләрен «җемелдәтеп» көлгән була, хәерсез. Сапые да көчәнеп хихылдаган була. Черек алмасыннан гайре сукыр бер тиене дә юктыр әле үзенең... Тагын шул черек алма дигәннән, икенче бернәрсә искә төште әле... Шул инде... беләсез...

*29 сентябрь, 2002*

# Яшәсен безнең партия!

*(Нотык)*

Нәселле чучка диярсең Рәсәйне!

Бер-бер артлы туып кына тора партияләр! Анархистлар, монархистлар, радикаллар, социал-демократлар, либераллар, эсерлар... Кыскасы, очына чыгарлык түгел. Хәер, очына чыгарга кирәк тә түгел. Ниемә хаҗәт аларның очына чыгу, мәсәлән, миңа. Минем үз партиям бар. Иптәшләрем бар. Инанган иманым бар.

Безнең партиягә бернинди проек-мраект та, устав-мустав та кирәкми. Трибунага чыгып, көчәнә-көчәнә борчак сибеп азапланасы да түгел.

Безнең партия чакыруын ишеткән кешеләрнең йөзендә кояш нурлары уйный башлый, дөньясына ачудан эчкә баткан йөзләрендә өмет чаткылары кабына, күз төпләренә ике тапкыр кудырылган көмешкәдәй саф, чиста күз яшьләре бәреп чыга.

Безнең партия әгъзалары хезмәт хакларының һәммәсен партиянең уртак казнасына салалар. «Партия взносы кая китә?» дигән мәгънәсез сорау биру берсенең дә башына килми. Чөнки кешеләр белә: безнең партия һәр әгъзасы турында чын күңелдән кайгырта.

Партиябезгә керү ирекле булган кебек, аннан чыгу да ирекле. Керү өчен бернинди дә рекомендация-мазар кирәкми. Чыгу өчен дә. Аннан соң шунысы да бар: безнең партиягә бер инанып кергән кеше чыгу турында уйламый. Әлбәттә, чыгучылар да бар. Бар. Ләкин алар, әйтегез, кайсы партиядә юк соң? Башка партияләрдән аермалы буларак, безнең партиядән чыгучыларның күпчелеге алны-ялны белмичә, фидакарьләрчә эшләп, төрле хроник авыруларга дучар булган кешеләр. Урыннары җәннәттә булсын аларның!

Бер-беребезгә игътибарлы булу — безнең төп бурычыбыз. Бурыч дигәннән, безнең партия әгъзаларының һәммәсенең дә бик күп бурычлары бар. Мин үземнең бурычларым хакында уйланып утырган идем беркөнне — чәчләрем үрә торды.

Кыскасы, партиябез көннән-көн ныгый, үсә, оеша бара. Әлбәттә, безнең партиянең ныгуына, бердәмлегенә аяк чалучылар да юк түгел. Көнләшәләр, шайтаннар! Шуңа күрә нотыгымны канатлы сүзләр белән тәмамлыйсым килә:

— Барлык илләрнең пролетарийлары, Өч борынга берләшегез!

— Яшәсен Өч борынның какшамас бердәмлеге!

— Яшәсен Өч борын партиясе!

— Ур-р-ра, борындашлар!

*1990*

## Башыма тай типмәгән

Җитте — бүтән эчмим. Җырчылары да: «И Мөслим! Бүтән эчмим!» —дигән шикелле җырлый бит... Минем аркада хатын җәфалана. Үземне әйткән дә юк. Югыйсә ничә мәртәбә сүз бирдем бит: «Эчмим, авызга якын да китермим!» — дидем. Хатынга гына күпме тукыдым. Юк, ышанмады хатын. «Синең кайчан сүзеңдә торганың бар соң, җанкисәккәем?» — генә диде. Сүздә торган чаклар булгалады инде анысы. Әле былтырларны гына: «Синең миңа сыңар яулык та алып кайтып биргәнең юк бит»,— дип зарланыпмы-зарланган иде хатын. Ә мин сүземдә тордым. Беркөнне базардан сатып алып кайттым яулык. Бәһасе кесәгә шактый сукты сугуын... «Рәхәтен күр, үз башыңда тузарга язсын!» — дидем хатынга. Аның гына исе китмәде: «Ярар, минем энигә нәкъ менә шундый эбиләр яулыгы кирәк иде»,— диде дә яулыкны битараф кына алып куйды. Ир кадерен белә торган затмыни ул хатын-кыз?! Аларга шул зарланырга гына булсын... Ми-

нем эчмим дигән сүзгә дә ышанмый тора бит әле менә. Саңгырау ана эт тә аңларлык итеп әйттем югыйсә...

Тамак төбе кымырҗып авырта. Юк, моннан соң эчмим. Суыткычтагы шешәнең гурласыннан гелән-гелән салкын сөт эчәргә башыма тай типмәгән лә минем! Юк, бүтән эчмим ул салкын сөтне!

Гурлама салкын тидерә-тидерә туйдым инде. Аракыга күчмичә булмас. Ичмасам, хатыннан авыр сүз ишетмәм...

*18 октябрь, 1990*

# Кояшлы әсәр

*(Фаил Шәфигуллинчарак)*

Әчтах Сөргәлинең яңа китабын карап чыктым. Искиткеч китап! Әйтер идем, уникаль китап. Сүзләрен, җөмләләрен исәпкә алмаганда, әсәрдәге һәр өтер, һәр нокта үз урынында. Ялгыш бер генә өтерен дә алырга ярамый. Алдыңмы — бетә, әсәр шундук таралып төшә... Югыйсә гап-гади генә тыныш билгесе бит өтер, ә! Ә нинди кодрәткә ия үзе!..

Сүз дә юк — талант бар Сөргәлидә! Әйтер идем, тумыштан килә торган талант! Ә бит күпләр шул талант булмау аркасында гына язучы булып йөриләр. Талантлары да булса, нишләр иде микән ул каләмчеләр?

Китапның исеме җисеменә тач туры килеп тора: «Кояш чыга да бата». Әйтер идем, просто гениальный исем! Дөрес, мин үзем Әчтах Сөргәли урынында булсам, исемне башкачарак куйган булыр идем. Әйтик, менә мондыйрак исем: «Кояш чыкмый да батмый да». Яисә мондыйрак: «Кояш чыксаный да батсаный». Яки болай: «Кояш чыкты, ләкин батмады».

Һәрхәлдә, Әчтах Сөргәлигә исем мәсьәләсендә бераз уйланасы булган, кәнишне. Хәер, әсәрне караганда, исемнең зыяны ул кадәрле зур түгел. Иң мөһиме — әсәр!.. Чөнки китапны әсәр тотып торырга тиеш. Әсәр юк икән — китап та юк. Ә монда китап бар. Димәк, әсәр дә бар дигән сүз! Димәк, көчләрен зерәгә түкмәгән китап төпләүчеләр! Менә бит ничек килешле итеп төпләгәннәр — кулга тотулары ук приятны. Ни кытыршы түгел, ни шома. Юкса кайбер язучы китабын кулга да алып булмый. Алган очракта да, җирәнгән сыман гына итеп аласың. Юри генә берәр җөмләсен укысаң, үзең дә сизмичә ахыргача җырып чыгасың тагы... Әйе, әдәбият дөньясында аеруча без, тәнкыйтьчеләр, арасында андый хәлләр дә булгалый...

Җөмлә дигәннән, җөмлә — Әчтах Сөргәлинең стихи-

ясе. Юри иренмичә санап чыктым: әсәрдә эреле-ваклы өч мең дә тугыз йөз туксан тугыз җөмлә бар. Дүрт меңгә берәү генә җитми. Минем уйлавымча, Сөргәли моны умышленно шулай эшләгән булса кирәк, һәм, әйтер идем ки, бик дөрес эшләгән. Болай иткәндә, әсәр тагын да ота төшә. Кыйммәте отыры арта. Аннан соң, туксан тугыз санында ниндидер тирән мәгънә дә бар сыман... Кыйммәте дигәннән, китап кыйбат түгел. Әйтер идем, бүгенге кыйммәтчелек заманында очсыз китап чыгару бәхете теләсә кемгә бик тәтеми ул. Бу яктан Сөргәли бәхетле. Чиксез бәхетле. Көнләшәм мин аннан, заразыдан! Матур итеп көнләшәм. Кайвакыт үземнең дә аның шикелле язучы булып китмәвемә үкенеп тә куйгалыйм. Ләкин мондый өч тиенлек кичерешләр миндә, әлбәттә, вакытлыча гына була. Чөнки мин әдәбиятта үземнең лаеклы урынымны тапкан кеше. Тәнкыйть остасы булу да бик җиткән миңа. Аннан соң өстәвенә «атказанган хезмәт работнигы» да бит әле мин. «Кырчылыкта зур җиңүләргә ирешкән өчен» дигән ызначук та бар, җитмәсә... Хезмәтеңә күрә хөрмәтен дигәндәй... Хөкүмәтебез кемгә нинди мидәл бирергә тиешлеген бик белеп тора ул...

Мидәл дигәннән... Әчтах Сөргәли иптәшкә дә берәр бүләк-мазар тиештер бит инде, җәмәгать?! Теге вакытта да, бөтен кешегә Ленинның йөзьеллыгы уңае белән чыгарылган мидәлне өләшкәндә дә, ул, бүлнистә сукыр эчәгесе белән ятып, алалмый калган иде. Бу юлысы безгә ныклап уйларга кирәк. Язучы Сөргәли иптәш стоящий кеше. Пенсиягә чыкканына әле өч кенә ел. Аннан соң, аның бу китабының күпьеллык хезмәт нәтиҗәсе икәнлеген дә һич истән чыгарырга ярамый. Шуның өстәвенә беренче китап та әле бу, җитмәсә. Ахыргысы да булуы ихтимал... Сөргәли озак еллар инде хроник баш авырту белән җәфалана... «Иртәләрен яман чатный... Чыдар әмәлләр юк... Каян гына табарга инде?!» дип, үземә дә әйткәләгәне бар.

Соңга калмаскае, җәмәгать...

Хәер, болары сүз уңаеннан әйтелде. Өстәге мөхтәрәм иптәшләр үзләре карарлар тагы...

Кыскасы, авырсынмыйча, тагын бер мәртәбә кабатлыйм: китап бар! Ул китап кибетләрендәге киштәләрдә үзенең лаеклы урынын алды инде. Иншалла, халык, аеруча Әчтах Сөргәли иҗатын яратучылар (ә андыйлар хет берничә генә кеше булса да, бар, дип уйлыйм мин) китапка уңай карар, шәт. Бу урында китапның сыйфатлы йомшак кәгазьдә басылган булуын да искәртеп үтү кирәктер. Китапның очсыз булуы хакында әйткән идем инде... Хәзер бит, үзегез беләсез, бәдрәф кәгазенең бәһасе дә күзләреңне нүлләндерерлек!..

Сүз ахырында каләмдәшем Әчтах Сөргәлигә озын гомер телим. Әйтер идем, әле ул иҗатының башында гына тора. Алга таба атлап китәлсә, күрсәтәчәк әле ул безгә.

## Гаилә низагы

Ир. Мин сине үтерәм!

Хатын. Үтерсәң үтерәсең инде...

Ир. Юк, мин сине үтерәм!!

Хатын. Үтерсәң үтерәсең инде...

Ир. Ыслушай, мин сине үтерәм бит!!!

Хатын. Үтерсәң үтерәсең инде...

Ир. Карале, аңлыйсыңмы син, юкмы? Мин сине үтерәм, дим!

Хатын. Үтерсәң үтерәсең инде...

Ир. Уйнама минем нервы белән! Мин сине үтерәм!!

Хатын. Үтерсәң үтерәсең инде...

Ир *(бик яман сүгенә)*. Аңлыйсыңмы син? Мин үтерәм сине!

Хатын. Үтерсәң үтерәсең инде...

Ир *(ярсуына чыдый алмыйча)*. Аһ, анаң сыңары! Үтерәм мин сине! Атам!! Буам!!! Асам!!!! Кисәм!!!!! Суям!!!!!! Коега ташлыйм!!!!!!!

Хатын. Үтерсәң үтерәсең инде...

Ир. Аһ, кабахәт! Үтерәсең син мине! *(Йөрәген тота)*.

Хатын. Үтерсәң үтерәсең инде...

Ир. Соңгы тапкыр... Соңгы мәртәбә... әйтәм... Үт... үт... *(Йөрәген тоткан килеш егыла)*.

Хатын *(халат кесәсеннән кәгазь акча чыгарып, аны иргә ыргыта)*. Мә, эч! Чукын! Кадалып кит!

Ир *(башын күтәрә)*. Үт... тердең!.. *(Үлә)*.

Хатын. Уф! Тәки үтерә дип торам!.. *(Иелеп акчаны ала)*.

Пәрдә

## Мәхәббәт романы

*(Сюжет)*

Вәли Сәлимәне сөя. Сәлимә — Хәлимне. Хәлим — Галияне. Галия —Вәлине...

Әсәр катлаулы борылыш ала. Вәли белән Галия аерылыша. Сәлимә белән Хәлим кавыша. Вәли һаман Сәлимәне сөя. Галия — Хәлимне.

Әсәр тагын да катлаулана. Хәзер Сәлимә белән Хәлим аерылыша. Вәли Сәлимәгә өйләнә. Хәлим Галияне сөя.

Әсәр отыры кискенләшә. Вәли белән Сәлимә аерылыша. Галия белән Хәлим кавыша. Ләкин Галия Хәлимне сөйми. Вәлине дә.

Әсәр коточкыч катлаулана. Галия белән Хәлим аерылыша. Вәли Сәлимәне дә, Галияне дә куралмый. Хәлим тужы.

Әсәр көтелмәгәнчә тәмамлана. Дөресрәге, тәмамланмый: автор укучыга уйланырга урын калдыра...

**Искәрмә:** соңыннан автор Тукай премиясе ала.

## Яфрак турында указ

*(Чын әкият)*

Гыйнвар өченче дистәне ваклый башлаган көннәр иде.

Карурман патшасы Сөрхәнтәй Аю кинәт куркып вә туңып уянды. Уянды да бераз исәнгерәп торды.

— У-у-ух! Салкын! Берәр указ игълан итәргә кирәк! — диде ул.

Ошбу сүзләрне әйтәчәген белеп-көтеп торган бүреләр башлыгы Җанкыяр үзе әзерләгән указны Сөрхәнтәй Аюның йөнтәс кулына тоттырды...

Указның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт иде:

— Карурмандагы яфракның дәрәҗәсе бик нык төште. Моңа, һичшиксез, бүреләр өере сәбәпче. Безгә мәгълүм булганча, алар имән һәм каен яфракларын күпләп-күпләп үзләренә тупладылар. Карурмандагы киеренке хәлне җиңеләйтү өчен, боерык бирәм: үзләрендә каен яфраклары булган җан ияләре өч тәүлек эчендә аларны хөкүмәткә китереп тапшырырга тиеш! Яфракка алмашка ылыс энәләре биреләчәк...

Әлеге указ җилләр һәм ала каргалар ярдәмендә карурманның һәммә төбәгенә барып ирешүгә, башланды мәхшәр, купты ыгы-зыгы, шау-шу...

Бериш җан ияләре кар астына һәйбәтләп күмеп куйган имән һәм каен яфракларын казып алырга мәҗбүр булды, кайберәүләр указда әйтелмәсә дә, үзләрендә булган усак һәм тал яфракларын да биштәрләренә дыңгычлап тутырды.

Карурманда, күрше-күлән арасында барган ызгыш-талашлар, әйткәләшү-төрткәләшүләр өч көнгә тукталып, онытылып торгандай булды. Беркавым җанварлардан кала кышны ничек чыгармын икән? дип шөбһәләнгән һәр җан иясе яфрак турында гына сөйләде, яфрак турында

гына гәп сатты. Ашау-эчү, черем итү, хайвани мөнәсәбәтләргә керү турындагы уйлар бу өч көндә аларның башына да килеп карамады...

Указ бары тик бүреләр өеренә генә тәэсир итмәде. Арысланнарның да колаклары гына тырпайгандай итте. Төлкеләр исә хәйләкәр генә елмайдылар...

Указ барысыннан да бигрәк куяннарга сукты. Алар, кара көнгә дип берәмтекләп-берәмтекләп җыйган имән һәм каен яфракларын төенчекләргә төйнәп, тизрәк хөкүмәткә тапшырырга чаптылар. Ләкин күз ачкысыз буран уйнап торганда, йомшак кар өстеннән чабу алай бик җиңелдән түгел иде аларга. Шул сәбәпле, бетәшкән, хәлсезләнгән куяннарның берише, юлда туңып, җан тәслим кылды, икенчеләре бүреләр һәм төлкеләр кулыннан гаип булды, өченчеләрнең гомере яфрак тапшыру чиратында өзелде...

Шуңа да карамастан имән һәм каен яфраклары байтак җыелды. Иң оста тегүче керпеләр җыелган яфраклардан Сөрхәнтәй Аюга тун тектеләр, бик зур, йомшак мендәр хәстәрләделәр. Ул, җылы тунын киеп, зур, йомшак мендәргә башын төртте һәм, өстенә сырган юрган ябып, татлы йокыга талды. Ә бүреләр өере башлыгы Җанкыяр яңа указ язарга кереште...

*28 гыйнвар, 1991*

# Тереләй алырга

*(Детектив)*

Кызу тизлек белән ыргылган ике җиңел машина олы юлдан читкә — урманга таба тайпылды. Төн карасын айкаган фараларның көчле яктысыннан куркышкан агачлар бер-берсенә сыенып, читкәрәк елыштылар.

Менә алдагы машина кисәк туктап калды. Шапылдап ишек ачылганы ишетелде һәм озын кара шәүлә җәһәт кенә куе караңгылыкка кереп югалды.

— Тереләй алырга! — дип кычкырды икенче машинадан чыккан бер шәүлә, һәм ул да караңгылыкка кереп чумды.

— Соңгы чиктә аягына атарга! — диде икенче шәүлә. Караңгылык аны да йотты.

«Качулар едва ли...» — дип уйлады Әкмәлетдинов.

...Шарт-шорт сынган ботак тавышларын күмеп, ату тавышы яңгырады. «Бет...те...»

Әкмәлетдинов шабыр тиргә баткан киң маңгаен йонлач кул аркасы белән сыпырып алды.

Янә ату тавышы яңгырады.

Әкмәлетдинов дерт итте, тәннәре чымырдап куйды. Ул тирә-ягына күз салды. Урман сурәтендәге поши мөгезеннән башка берни дә күрмәде.

Шәүлә аксый-аксый юлын дәвам итте. Аяк астында корыган ботаклар шартлады. Шулчак тагын ату тавышы ишетелде...

«Их, тәки электермәделәр бит»,— дип үрсәләнде хәлсез Әкмәлетдинов һәм экранда «Беренче серия тәмам» дигән язулар йөгергән телевизорны ачу белән сүндерде...

*1985*

# Котлау

Быелгы сабан туе көнне дә Габделхәй таң әтәче белән бергә уянды. Уянды да иң беренче эш итеп сакал-мыегын төзәтергә кереште. Көзге тирәсендә хатын-кыз шикелле бик озак юанды. Шуннан соң урамга чыкты.

Төтен төсендәге кәчтүненең түш кесәсеннән сигарет алды да кипшенгән иреннәре арасына кыстырды.

«Бүтән кеше өлгергәнче, күршеләрне бәйрәм белән котлап чыгарга кирәк. Башта кемгә керим икән? Госмангамы? Әллә Хөсәенгәме? Хөсәенгә керергә кирәк. Кичә хатыны кибеттән бик күтәренеп кайтты...»

— Нихәл, күрше? — диде Габделхәй керә-керешли.— Бәйрәмнәр мөбарәк булсын!

Хөсәен белән хатыны кара-каршы утырып чәй эчә иде.

— Һа, Габделхәй күрше! Мактап йөрисең икән әле үзең,— дигән булды Хөсәен һәм күз кырые белән генә хатынына ымлады.— Әйдүк, әйдүк, түргә уз!

Күрештеләр.

— Менә бәйрәм белән котларга кердем әле,— диде Габделхәй.— Күрше була торып, мин дә котламасам, ни була инде ул, минәйтәм...

Ул арада өстәлгә, кем әйтмешли, «котырган сыер сөте» менеп утырды.

...Шактый кәефләнеп, гайрәтләнеп чыкты Габделхәй. Чыкты да туп-туры сул як күршесе Госманны бәйрәм белән котларга ашыкты. Бераздан аның:

— Нихәл, күрше! Бәйрәм котлы булсын! — дип гөрелдәгәне ишетелде.

Каршы як күршесе Әхәтләрдән чыкканда, диңгез тубыктан иде инде.

Мәйданда гайрәтле ирләрнең һәм атларның көч сынашканын күрүдә быел да кайгысы юк иде инде аның...

*1985*

# Алдый белмисең, быр-рат!..

Алдау көне иде. Эш өстәле янына килеп утырырга да өлгермәдем, Гәрәй хәйләкәр елмаюын яшерергә тырышып әйтә куйды:

— Рәхим, быр-рат,— ди бу,— кая болай ышкындың әле? Аркаң акка буялган бит!

Аркаң акка буялган, имеш! Бигрәкләр дә алдый белми инде бу Гәрәй. Болай дип әйтеп бишектә яткан сабыйны да алдап булмый хәзер. Шулай да мин аның алдаганын белгәнемне сиздермәскә тырыштым.

— Әй, баягынак кына үзебезнең яндагы гастрономнан бер капчык шикәр комы алып, шуны кайтарып килгән идем өйгә. Шул капчыктан йоккандыр инде, шайтан алгыры,— дидем мин һәм кәчтүнне салдым да, карамыйча гына каккаларга керештем...

— Сүләмә юкны, быр-рат, булмаганны! — диде Гәрәй, шикләнүле карашын миңа төбәп (алдамыймы бу, янәмәсе!).— Шикәр комын нишләп капчыклап сатсыннар ди. Бер килосын да ярты көн чират торып талонга гына алганны...

— Үзем дә аптырадым шул: нишләп, мәйтәм, тик торганда капчыклап саталар әле болар? Сатучы әйтә: бер вагун китереп бушаттылар, куяр урыныбыз юк, ди, шуңа күрә кем күпме алырга тели, шулкадәр сатабыз, ди... Алдым инде, кирәк бит... Акча да барые янда...

Гәрәй «ә» димәде, «җә» димәде, үз урынына барып утырды. Утырды дип, утырып ук тормады ул: «Штуты теш сызлаштыра, быр-рат, булмаса, җәһәт кенә үзебезнең врачка күренеп килим әле»,— дип, тиз генә чыгып шылды...

Аркаң акка буялган, имеш! Шул да булдымы алдау?! Менә шулайрак алдыйлар аны, быр-рат!

*28 гыйнвар, 1998*

# Берлек

Гыйбадның акчасы югалды.

Тегеннән эзләде, моннан эзләде, кәчтүнен генә дә җитмеш җиде мәртәбә капшап чыкты — юк, суга төшкәндәй эзсез югалды акча! «Кичә Мөшәрәф кергән иде, шуның гына кулы уйнаган монда,— дип уйлап алды Гыйбад. — Билләһи, шул чәлдергән! Имансыз гына икән, карак тәре! Гуҗ! Бер атна эчә инде ул хәзер шул акчага!»

Гыйбад ашык-пошык кына киенде дә гаражга чапты. Җәһәт кенә машинасын кабызды, каланың икенче очында яшәгән Мөшәрәфкә элдерде. «Бетерәм, сытам мин ул

каракны! Кулын сындырам! Имгәк ясыйм!» — дип җенләнә-җенләнә куды машинасын Гыйбад.

— Бүген иртән ашыгыч эш белән командировкага җибәрделәр аны. Мәскәүгә! — дип каршы алды Гыйбадны Мөшәрәфнең хатыны.

— Алай икә-ән,— диде мондый борылышны көтмәгән Гыйбад һәм Мөшәрәфнең ияк төбенә кундырырга дип төргән йодрыгын хәлсез генә чишеп җибәрде. «Эт җан! Чыгып качкан бит, ә! Болай гына калдырмыйм моны! Эшенә барам. Нәчәлствосына әйтәм. Кандала урынына сыттырам, издерәм!.. Вәйт син аны, ә! Качып котылмакчы! Шалишь!» — дип тузынды Гыйбад, машинасына чыгып утыргач.

Шуннан соң ул машинасын кабызып артка чиккән иде — фаралар, фонарь баганасына туры килеп, чылтырап коелды. Машина янә кала урамнары буйлап чапты. Тик озак чабарга туры килмәгән икән! Милиция сыбызгысы тиз туктатты Гыйбадны. Правасын алдылар, штраф түлә, диделәр. Ниндидер кәгазь тоттырдылар. Машинаңны гаражга кайтарып куй, диделәр...

«Кайтсын гына командировкасыннан! Иманын салдырып киям әле мин аның!» — дип, үз-үзен юатты Гыйбад, машинасын гаражга куеп өенә кайткач.

Тирләгән маңгаен ванна бүлмәсендәге чөйгә эленгән сөлгегә сөртте дә чишенә башлады. Кәчтүн-чалбарын, күлмәкләрен салды, оекбашын...

Шулчак идәнгә нәрсәдер төшкән кебек тоелды. Караса, ни күрсен: югалган акчасы аягына елышып ята. Әйе, әйе, шул! Нәкъ шул берлек — кырык дүрткә бөкләнгән!..

Шуннан соң гына Гыйбад хәтеренә төшерде: хезмәт хакы алганчы кассадагы акчасына орынмаска булган иде ул, шушы бер сумга бер атна яшим әле мин, дип, оек эченә тыккан иде шул...

Ул кәгазь берлекне кадерләп кенә кулына алды да, югала күрмәсен тагын дигәндәй, кәчтүненең иң яшерен кесәсенә кыстырды...

Икенче көнне Гыйбадның тагын акчасы югалды. Әлеге дә баягы шул кәгазь берлеге... Тотынды Гыйбад илле еллык гомере буена шкафка җыелып килгән оекбашларының эчен актарырга!

«Тагын Мөшәрәф эше! — дип тузгыды ул.— Шул гына яшерә минем акчаларны оекбашка! Кайтсын гына әле!»

Бу юлы акча Гыйбадның эшләпә астарыннан табылды...

*1987*



## III бүлек

# Әгъләмисина



## Мөдәррис Әгъләмгә

Авылда тугандыр, үскәндер,
Чишмәдән салкын су эчкәндер...
Шәһәргә укырга килгәндер,
Шигырьгә ургылып кергәндер...
Туфанны, Зөлфәтне күргәндер,
Бергәләп сөйләшеп йөргәндер...
Язгандыр, ниткәндер, көлгәндер,
Миллион «әкият» белгәндер...

Ул — безнең Мөдәррис!
Бердәнбер...

## Мәгарәдән хат

*(Пародия)*

Вәгъдә биреп, вакыт җигеп,
Баралмасам сиңа,
Мәгарәдә ята, диген
Әбүгалисина.
*Мөдәррис Әгъләм*

Тунлы килеш туңып ятам,
Тешләр шыгырдатып.
Боздай салкын мәгарәне
Чыгыйм мәллә ватып?
Ярдәм сорап ялварыйммы,
Тагын нишли алам?..—
Коткар мине бу котыптан,
Галиҗәнап Аллам!
Искә төшә ашаган чак,
Ашка катык катып.
Сохарига әйләнгәнмен,
Акыл җыеп ятып.
Шигырь ничек языладыр,
Күптән белмим инде.
Син барын да оныткан мын,

Кичер, шигырь, мине.
Вәгъдә биреп тормый гына
Кайта алсам сиңа,
Мәгарәдән чыккан, диген
Әгъләмисина.

## Мөдәррис Әгъләмгә

*(Фатирсыз Шагыйрьнең Аккош күлендәге хәрабә-алачыгында яшәп иҗат итүенә ишарә)*

Карагыз сез Мөдәррискә!
Күрегез сез Әгъләмне:
Аккош күле «рейхстагы»на
Элгән шигъри әләмне!

*2002*

## Әгъләм юбилее

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллинның эш бүлмәсе ишеген шакып-нитеп тормады ул, ишекне кисәк кенә тартты да түргә узды.

Башына килешеп торган «аэродром» кипке өстенә ясалма мехтан тегелгән кара тун һәм хәтта пөхтә киенергә яратучы Роберт Әхмәтҗановны көнләштерерлек итеп үтүкләнгән куе зәңгәр чалбар кигән, уң кулына какланган чүпрәк букча тоткан кешене күргәч, Равил Фәйзуллин беравык аңышмыйча торды. Әлеге кеше Мөдәррис Әгъләмгә охшаган да, охшамаган да иде.

Баш мөхәррир, исәнме, Мөдәррис, дип эндәшим микән, юк микән, дип икеләнеп азапланганда, ниһаять, теге кеше сүз катты:

— Телефоның сөйлиме? — диде.

Шушы ике сүз Равил Фәйзуллинның бөтен икеләнүен юкка чыгарды.

— Исәнме, Мөдәррис? — диде ул җанланып.

Телефон тартмачыгының дыңгыр-дыңгыр килүе Мөдәрриснең сәламне кабул итүен аңлата иде.

Кирәкле кешесе урынында булмады булса кирәк, Мөдәррис кулындагы телефон көпшәсен ачу белән тартмачык өстенә төшереп җибәрде.

— «Шәһри Казан» егетләре маладсы! — диде ул һәм тәрәзә аша урамга карады. Урамда ниндидер бер адәм фильтырсыз сигарет тартып тора иде. Мөдәррис ул кешенең үзеннән битәр сигаретына бераз сыкрап карап торды да:

— Хәлим Гайнуллин егетләре маладсы! — диде.— Миңа илле яшь тулуга багышлап, Аяз абыйның табак ярымлык мәкаләсен биргән «Шәһри Казан».

Аңлаган кешегә аңларлык әйтте Мөдәррис.

— Мөдәррис, ни бит...— дип, нәрсәдер әйтмәкче иде мөхәррир, Мөдәррис аны бүлде:

— Мин бу дөньяга килгәнче үк Мөдәррис идем! — диде.

— Болай да сан саен диярлек синең шигырьләреңне биреп барабыз бит инде, Мөдәррис,— диде Равил Фәйзуллин, тирли башлаган маңгаен кулъяулык белән сөртә-сөртә.

— Анысы сезнең төп эшегез! — дип кырт кисте Мөдәррис һәм эшлекле хәрәкәт белән җәһәт кенә тун сәдәпләрен тышаусызландырды.

Равил Фәйзуллинга «Марсель онытып җибәрде микәнни?» диюдән башка чара калмады. Мөдәррис чалбар кесәсеннән каешсыз кул сәгатен алып карады да янтайган колагына якынайтты.

— Кайсы Марсель? Теге... минем турыда букый-сукый язып кеше булган Азнакай егетеме? Фамилиясе ничек әле аның? — диде ул, сәгать колагын болгый-болгый.

— Галиев. Марсель Гали,— диде баш мөхәррир.

— Минем илле яшькә ярты табаклык кына булса да мәкалә язган булса, язучы итә идем мин ул егетне,— диде Мөдәррис һәм каешсыз сәгатен чалбар кесәсенә сак кына шудырды.

Шул вакыт ачык ишектән Марсель Гали үзе килеп керде.

— О-о, бөегем! — диде ул Мөдәррисне күрүгә һәм Әгъләмнең тунын пианинода уйнарга гына ярый торган бармаклары белән капшаштыргалап алды.

— Ясалма мех! — диде ул бераздан, канәгать елмаеп.

— Һәрхәлдә, ясалма шигырь түгел! — диде Мөдәррис.

Марсель Гали, сүзнең ялгыш борылыш алганын сизенеп, ахры:

— Нишләп йөреш, бөегем? — дигән булды.

— Минем илле яшькә ник бернәрсә дә бирмәдегез? — дип, Мөдәррис хәрәкәтчән күзләрен әле Марсельгә, әле Равил Фәйзуллинга төбәде.

Марсель Гали хәлнең катлаулана баруын секундның

өчтән бер өлешендә аңлап алды. Ул үзегез хәл итегез инде дигән карашын мөхәрриргә ташлап алды да:

— Юбилей дигәннән, Мәһдиевкә шалтыратасы бар икән,— дип, бүлмәдән чыгарга омтылды.

— Әллә кая югалмый тор! — диде аңа Мөдәррис, әйткән сүзләренә ниндидер эчке мәгънә салып.

Ишекне теге яктан япкан Марсель Галинең: «Җәл, мин кызыл шәраб капмыйм шул»,— дигән сүзләрен үзеннән башка бүтән беркем дә ишетмәде...

Мөдәррис Әгъләм янә телефон тартмачыгын дыңгырдатырга тотынды.

— Алло, «Идел»ме бу? — диде ул бераздан.— Римзил андамы? Кайда? Англиядә?! Англиядән татар эзләгәнче, журналына кәгазь эзләсен. Кайчан кайта? Нишләп белмисең? Бүген күренсә, әйт, хәзер Мөдәррис абый килә, диген!

Мөдәррис телефон көпшәсен янә ачу белән ташлады.

— Римзил Вәлиев «Идел»дән инде дүрт ел элек китте бит. Хәзер анда Фәиз Зөлкарнәй баш мөхәррир,— диде Равил Фәйзуллин.

— Миңа димәгәе,— диде Мөдәррис һәм тиз генә тунын төймәләргә тотынды.

«Бер тапкыр илле яшеңә җитәсең, аны да кешечә билгеләп үтә белмиләр...» — дип сукранды ул.

...Бераздан ул Комлев урамында урнашкан «Идел» журналханәсенә килеп керде. Гадәттәгечә, бөтен бүлмәләр дә шыр ачык, җан әсәре күренми иде. Мөдәррис баш мөхәррир бүлмәсендәге телефон көпшәсенә үрелде дә «Сабантуй» гәҗитханәсен кәшәләргә кереште.

Гәҗит мөхәррире Роберт Миңнуллин бүлмәсендә булмады, ахры, телефон шактый вакыт озын-озын тавыш биреп торды.

Мөдәррис икенче номерны җыйды. Кемдер алды.

— Мөхәрриregез кайда? — диде Мөдәррис. Телефонның теге башыннан: «Ашханәдә түгел микән ул»,— дигән нәзек тавыш ишетелде.

Мөдәррис кесәсеннән каешсыз сәгатен алып карады да:

— Әле сәгать унбер дә тулмаган бит,— диде.

Өченче номерны җыйды.

Мөгаен урысчаны үз теленнән дә шәп белгән берәүнең: «Он, по-моему, в Москве»,— дигән тавышын ишетте Мөдәррис.

Дүртенче номерны җыйды.

— Роберт сессиядә бугай ул,— дип җавап кайтарды хатын-кыз тавышы.

— Өендә түгел микән? — дип сораугa сорау бирде бер гөрелдәвек тавыш...

— Сезнең гәҗит чыгамы соң? — дип сорады Мөдәррис, алтынчы номерны җыйгач.

— Укып барырга кирәк, Мөдәррис! — диде Госман Садә тавышлы кеше.

Телефон көпшәсендә кыска гудоклар йөгерде.

«Хәлләр бар икән монда» дигән уйдан башка уй килмәде Әгъләм башына.

Мөдәррис тирләгән пеләшен какланган букчасы белән сөртештергәләп алды да «Татарстан яшьләре»нә — Исмәгыйль Шәрәфигә шылтыратты.

Мөдәрриснең мәгълүм сөалеп ишетүгә, Шәрәфи үзенең сүзлек запасында булган ике гыйбарәнең берсен Мөдәррискә ирештерде:

— От того слышу,— диде. Мөдәррис аңлады. Шуңа күрә:

— Кем язды? — дип сорады.

Шәрәфинең таушалып беткән икенче гыйбарәсе Мөдәррискә килеп җитте:

— Сам дурак.

— Аңлашылды,— диде Мөдәррис һәм телефон көпшәсен куйды.

«Димәк,— дип фараз кылды Мөдәррис,— минем турыда кемдер ярты табакка якын мәкалә язган, аны бүлек мөдире Флүрә Низамовага китереп биргән, ә Флүрә аны бер генә минутка каядыр куеп торган, хәзер эт белән эзләсәләр дә табалмыйлар. Үзем тапсам гына инде».

«Идел» журналы редакциясеннән чыгып барышлый, Мөдәррис үз-үзенә: «Әле илле яшь тулмаган килеш шулай кыланалар, илле яшь тулгач нишләрләр иде микән бу гәҗитчеләр?» — диде...

...Мөдәррис Әгъләмгә кырык сигез яшь тулып, бер ай да өч көн ярым вакыт үткән чак иде бу.

*1995*

## Мөдәррис рәис булгач...

XX гасырның соңгы тешләре коелыр чиккә җиткән көннәрдә, татар дөньясының әдәби мохите кискен үзгәрешләр кичерде. Бер төркем каләм әһелләренең «Китмә, Сафич!» дип гозерләнеп ялваруына карамастан, Ринат Мөхәммәди Язучылар берлеге рәислегеннән китте. «Шактый йончыдым, ял итәсем килә»,— диде ул яңа эшкә — әдәбият министры вазифасына керешү уңаеннан уздырган матбугат конференциясендә.

Хуҗа урыны буш тормас, диләр. Хактыр: Ринат Мөхәммәди яңа кәнәфигә утырган арада, Язучылар берлегенә рәис булып үз теләге белән шагыйрь Мөдәррис Әгъләм килде. Иң әүвәл Әгъләм урысчаны шәп белгән дусты Зөлфәтне язу-сызу, кәгазь арасында чокчыну эшләре буенча урынбасар итеп алды. Туда-суда барып килү кебек эшләр белән шөгыльләнергә тиешле икенче урынбасары урынына Эдуард Мостафинны куйды. Урындык-мазарга утырып эшләргә күнекмәгән Эдуард, Мөдәрриснең үзе белән яшьтәш көн букчасын эләктереп, шундук кибеткә, кирәк-яраклар алырга чыгып чапты.

Эш бүлмәсенең җитди үзгәрешкә мохтаҗ икәнлеген Эдуард чыгып китүгә үк чамалап алды Мөдәррис: кабул итү бүлмәсендә телефон шылтыраганын көтеп утырган сәркатип кызны чакырып кертте дә сусыз самовар тирәсендәге уймак хәтле касәләрне кырлы стаканнарга алыштырырга кушты.

Бүлмәдә затлы телефон сайрарга тотынды. Әгъләм трубканы җәһәт кенә алды да колагына якынайтты. Әхәт Гаффар икән. Мөдәррисне рәис булуы белән котлавы.

— Кыстати, Мудрыйк әкә, быел Тукай премиясен миңа бирерсең, җәме?! Башка кандидатура эзләп маташма. Юкса хатын... халык дөрес аңламас! — дип, үгезнең мөгезеннән алды Гаффар.

Үзе Тукай премиясе лауреаты булганга күрә Мөдәрриськә бу бүләкне кем алса да барыбер иде.

— Гәҗитләрдә үз иҗатың турында мәкаләләр чыгарта тор,— дип киңәш итте Мөдәррис.

— Ню! — диде Әхәт Гаффар.— «Ватаным Татарстан»да иҗат портретым ята. «Шәһри Казан»да да бар, диләр... Ә «Мәдәни җомга»га псевдоним белән үзем язам...

— Иҗат портреты дигәннән, тиздән минем яңа китап чыга,— диде рәис.

— Ню!

— Премияне сиңа бирергә исәпләп торам...

— Аңладым, Мудрыйк әкә... Сыра эчәргә бармыйсыңмы? Ню!

— Иртәгә! — диде Әгъләм һәм трубканы куйды.

Мөдәррис пинжәк кесәсеннән фатир ачкычы белән бергә аунап яткан кипкән балык койрыгы алып, иреннәре арасында җебетергә дә өлгермәде, янә телефон шылтырады:

— Сәлам, бөегем! Котлыйм! Нишләп ятыш?

Әгъләм тавыш иясен шундук танып алды: Марсель Гали, әле генә Азнакайдан кайткан икән.

— Чатыр тау урыныңдамы? Бу юлы Азнакайдан нәр-

сә алып килдең? — диде Мөдәррис, Марсельнең туган төбәгеннән буш кул белән килмәгәнлегенә тәгаен инанып.

— Ерунда-а-а... Ике капчык бәрәңге... Берсе-берсе карбыз чаклы... Каклаган каз... Үзең беләсең инде, бездә казны каклый беләләр... Синең Зәеңнең ун казын берүзе бәреп ега... Өч литр бал... Натуральный! Карабодай. Тагын кайбер вак-төякләр дә кыстырып җибәрделәр... Карале, бөегем!.. Быел Тукай премиясен миңа хәл итәсе иде бит инде...

— Баягынак Әхәт Гаффар да үзенә сорап шалтыраткан иде...

— Што-што? Гаффун былтыр гына ала язды түгелме соң?! Ел саен бер үк кешеләр булмас... Әле Миңнуш, әле Гаффун... Гаффунга киләсе елга бирерсең!

Мөдәррис трубканы куеп, балык койрыгын кесәсенә кабат шудырган вакытта, ишекне шакып-нитеп тормыйча гына, бүлмәгә бер кочак кәгазь күтәргән Зөлфәт килеп керде.

— Язучылар берлегенә әгъза итеп кичекмәстән алынырга тиешле кешеләрнең исемлеген әзерләдем,— диде ул һәм кәгазьләрне Әгъләмнең өстәленә таратып ташлады.— Бу исемлектә «Чаян» авторлары, бусында — колхоз рәисләре, ә менә монысында — пенсионерлар, сатучылар, вахтерлар, сыер савучылар...

Мөдәррис кәгазьләрне күздән кичереп алды да, Зөлфәтнең сыра күбегенә охшатып таралган бөдрә чәчләренә карап:

— Араларында язгалаучылар да бармы? — дип сорады.

Зөлфәт рәиснең соравына туры җавап кайтарды:

— Бар!

— Алайса, бөтенесен дә берьюлы алырга кирәк! — диде Әгъләм катгый төстә.

Зөлфәт кәгазьләрен кире күтәреп чыгып китүгә, Әгъләм телефон трубкасына үрелде. Исәбе Илбашка шылтырату иде аның.

— Чордаш, миңа «Халык шагыйре» исемен бирү турындагы фәрманың матбугатта нишләптер күренми әле,— диде ул, Илбашның «Нихәл, Әгъләм?» дигән сүзләрен ишеткәч. Илбаш мәсьәләнең уңай хәл ителгәнен әйтте дә сүз уңаеннан рәисне олуг исем алуы белән чын күңелдән котлады, аңа иҗади уңышлар, саулык-сәламәтлек һәм озын гомер теләде.

— Миннән соң исемне Зөлфәткә бирергә хәстәрләсәк иде. Тукайның йөз егерме еллыгы тирәсенә чамаларга була. Аңарчы бер-ике шигырь, өч-дүрт кереш сүз, минем иҗат турында биш-алты мәкалә язса, Зөлфәтнең ярсу шигърия-

те олпат төс алып өлгерәчәк! — дип, Мөдәррис якын дусты хакында аталарча кайгыртырга онытмады. Дәрәҗәле исемне Мөдәррис белән Зөлфәтнең икесенә бергә бирергә дип, кичә кич үк планлаштырып куйган Илбаш рәиснең дусты турындагы үтә җитди тәкъдиме белән берсүзсез килеште.

Илбаш белән шулай дустанә сөйләшеп алганнан соң, Әгъләм, рәис халкына хас дәрт-дәрман белән каударланып, Мулланур Вахитовның гаять четерекле язмышы һәм революцион эшчәнлеге турында «Агач күпер» дигән документаль роман-трилогия язарга кереште. Моңарчы вак-вак хикәяләрдән гайре чәчмә әсәр язып карамаган Мөдәррис романга бик җиңел кереп китте. Дөрес, романның язылган кадәресе, әгәр укып карасаң, гап-гади укучы түгел, Әгъләм үзе дә аңламаслык иде. Хәер, язмышлары катмарлы булган революционерлар турындагы роман шулай катлаулы булырга тиеш тә.

Мөдәррис, язуыннан туктап, сигарет кабызды, бер мәлгә ләззәтле уйга чумып алды: «Төркиягә барып, «Агач күпер» буенча егерме бер серияле нәфис фильм төшерү мәсьәләсен хәл итәсе булыр...»

Әгъләм, шулай уйланып, бөтен җаны-тәне белән тантана итеп утырган вакытта ишек тарафында икенче урынбасар — Эдуард Мостафин пәйда булды. Эдуард, тукталып, отыры кызарган чыраендагы эре тир тамчыларын кул аркасы белән идәнгә коеп төшерде дә, канәгать елмаеп, түргә таба атлады, шактый юанайган букчаны Әгъләмнең аяк очына җайлап кына куйды. Букча эчендәге кирәк-ярак, күңелгә — дәрт, җанга илһам бирердәй матур аһәңнәр чыгарып, җиңелчә генә чыңлап алды...

...Мөдәррис үз биләмәсендәге эшләрне җайга салып бетергәч, игътибарын Язучылар берлегенә кагылышлы журналханәләргә юнәлтте. «Казан утлары»ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллинга ул көтелмәгән тәкъдим ясады:

— Мөхәррир булып эшләп арыганыңны беләм, шигырь язудан барыбер туктамаячагыңны беләм, машина яратканыңны беләм... Әйдә, минем «джип»ка шофер булып кил! — диде.

— Ошбу тәкъдимне ишеткәч, Равил Фәйзуллинның ындыр табагы чаклы маңгае күз алдында тагын да киңәйде, баш түмеченә елышкан чәчләренең һәммәсе үрә катты. Мөхәррир шулкадәр дулкынланды ки, хәтта Мөдәрриснең өстәл өстендә җемелдәп яткан авторучкасын үз кесәсенә салып куйганын сизми дә калды.

Ниһаять, ул телгә килде:

— Син... син нәрсә, әкә... Син нәрсә! Мин бит — шагыйрь!

— Беләм, дустым, беләм,— дип, Мөдәррис каләмдәшенең җилкәсенә кулын куйды.— Халык та шагыйрь...

— Миңа кагылма инде син, әкә... Шофер кирәк булса, әнә Хөсниярны ал... Ул шәп йөртә машинаны.

— Йөртүен аны мин дә йөртергә могу... Миңа шофер кирәк! Ватылган саен төзәтә белгән шофер! Йә, ярый, мин шаярттым гына... Журналны әлегә чыгара тор. Шулай да минем тәкъдим турында уйлан.

Сөмсере коелган Фәйзуллин рәис бүлмәсеннән чыкты.

— Бу — Мөхәммәди генә түгел бу! Бу — әллә кем бу! — диде Фәйзуллин коридорның бер башында сигарет төтәтеп торган Рөстәм Мингалимгә.

— Эшләр болай барса, киләчәктә тагын да матуррак яшәрбез әле! — диде Мингалим һәм, төтенне аралап, матур итеп елмайды.

Фәйзуллиннан соң чират «Салават күпере»нең баш мөхәррире Зиннур Хөсниярга күчте.

— Бала-чага журналын күп тарттың, «Казан утлары»на җигелергә вакыт сиңа,— диде аңа Әгъләм.

Хөснияр бу хәбәргә сөенергә дә, көенергә дә белмәде.

— Фәйзуллин китәмени, минем урынга кем килә? — диде ул, «Салават күпере» редакциясенең ремонттан башы чыкмаган машинасы турындагы уен очлый алмыйча.

— Заһид Мәхмүди килергә атлыгып тора,— диде Әгъләм.— Мин эшләп карамаган редакцияләрдән бердәнбер «Салават күпере» генә калды, ди... Тек шту, уйлана тор, Хөснияр!

Зиннур «Казан утлары» журналы редакциясенең «Волга» машинасы хакында уйлана башлаган иде инде.

— Мине котлый аласың,— диде Хөснияр Мингалимгә, коридорга чыккач.

— Котлыйм! — диде Мингалим.

— «Казан утлары»ның баш мөхәррире мин хәзер!

— Шәп. Бик шәп булган! — диде Мингалим.

— Әгъләмгә мине Илбаш үзе тәкъдим иткән!

— Булыр, булыр,— диде Мингалим.— Була торган хәл...

...«Идел» журналының баш мөхәррире Фәез Зөлкарнәй мәсьәләсендә бераз сабыр итәргә булды Әгъләм. Ник дигәндә, әле генә шул журналда Мөдәрриснең бер көлтә шигыре басылып чыкты. Өстәвенә «Идел» бухгалтеры шактый мул гонорар тоттырды Мөдәррискә...

Әгъләм сигарет кабызды да тәмләп суырырга тотынды...

Татар язучыларының күрәчәге алда иде әле.

*1995*

# Космодром һәм сессия, космонавт Әгъләм

Ниһаять, безнең урамга да бәйрәм килде. Русия президенты Казанда Татарстанның Илбашы белән чираттагы очрашуында «Нишләп татарлар космоска очмый?» дип тинтерәттегез, менә хәзер сезгә ирек, күпме телисез, үзегездә шулкадәр космодром төзегез!» — диде. Әлеге очрашуга ниндидер юллар белән килеп эләккән бер татар агаена хәбәр гаять көчле тәэсир итте. Ул, дулкынлануын яшерә алмыйча, җиңелчә калтыраган куллары белән үз башындагы түбәтәен алды да Русия президентының тузганактай ак башына батырды. «Өлкән туган»ның моңа бик тә күңеле булды. Ул балкып елмайды һәм: «Спасибо, россияне!» — диде. Аннан соң уң кулын, йодрыклап, өскә чөеп алды...

Казан трамвайларында акчасыз халыкны шаккатырып йөргән Русия президентына мылтык чехолы, машина утыргычы япмасы, Арча башмагы, Кукмара киез итеге, ау өчен махсус тегелгән мех чалбар һәм Казан сырасы, Буа шикәре, Азнакай карабодае, Минзәлә аракысы ише хисапсыз бүләк күчтәнәчләр биреп, китәр алдыннан Чистайның «Гимаев» аракысы белән сыйлап, аны көч-хәл белән озатып җибәргәч, атна саен чит илләргә барып, аларның пляжларында, суперкибетләрендә ике як өчен дә бик файдалы булган эшлекле сөйләшүләр уздырып кайткан җитәкче депутатлар һәм гади депутатлар Дәүләт Советының чираттан тыш үткәреләсе сессиясенә җыелдылар. Сессиянең көн тәртибенә бер генә мөһим һәм төп мәсьәлә куелган иде: кичекмәстән космодром төзү. Мәсьәлә, артык җитди булуга карамастан, ул, гадәттәгечә, бик тиз хәл кылынды: депутатлар Болгарнур (матур яңгырашлы бу исемне депутат Ренат Харис тәкъдим итте) космодромын «Татарфильм» киностудиясенә моннан биш-алты ел элгәре бүлеп бирелгән җирдә төзергә дигән бердәм фикергә килделәр. Шуннан соң депутатлар галәмгә беренче булып очарга тиешле татар космонавты кандидатурасы хакында, аерым алганда атаклы тракторчы яки көненә һәр сыердан уналтышар литр сөт савып алган алдынгы савымчы кандидатурасы турында, кызыклы әңгәмә-бәхәс куертып җибәрделәр. Шулай ике көн дәвамында бәхәсләшкән, дустанә чәкәләшкәннән соң, бер мәшһүр татар шагыйрен җибәрүдән дә отышлы булмас, дигән фикергә туктадылар. Тик менә кемне җибәрергә?

— Галәмгә урыс телен, Дәрдмәнд иҗатын тирәнтен белгән шагыйрь очарга тиеш! — дип, барча депутатка да аңлаешлы итеп, урысча кистереп әйтте депутат-шагыйрь Ренат Харис һәм, мөмкинлектән файдаланып, пөхтә кәчтүменең түш кесәсеннән Дәрдмәнднең уч төбе хәтле китабын тартып чыгарды. Аннары алдан ук үзе билгеләп куйган бер битен ачты да мәгълүм шигырьдән өзек китерде:

...Чыкты җилләр,
купты тулкын —
Ил корабын җил сөрә!..

Әлеге шигъри юлларны татарча укыгач, Ренат Харис өзекне урысчага тәрҗемә итеп бәян кылды.

— Дәрдмәнднең бу шигырьдә татарның беренче космик корабы турында сүз алып барганлыгы инде һәркемгә дә аңлашылгандыр, шәт?! — диде депутат-шагыйрь.

Ренат Харистан соң мөнбәргә тагын бер депутат-шагыйрь — Роберт Миңнуллин күтәрелде. Ул да сүзен урысча шома гына башларга җыенган иде, өлгермичә калды, залдан икенче Миңнуллин — депутат Туфан Миңнуллинның көр вә гаярь тавышы ишетелде:

— Телебез бетә бит, җәмәгать! Шул хакта сөйләшик! Югыйсә без һаман сарыклар хәлендә!

Сессия барган залның бер кумырыгында — журналист халкы өчен билгеләнгән урыннарның берсендә утырган Риман Гыйлемханов иртәгә «Татарстан яшьләре» гәҗитендә чыгасы мәкаләсенең тәүге җөмләсен язып куйды: «Туфан абый, гадәттәгечә: «Сарыкларга тел кирәкми!» — дип, бик образлы итеп әйтте...»

Залны үзенә каратып торудан җиңелчә ләззәт кичереп алганнан соң, депутат-шагыйрь Роберт Миңнуллин сүзен татарча башларга булды:

— Үтә җитди, үтә мөһим мәсьәлә хакында сөйләшә башласак, Туфан абый сүзне гел шулай читкә алып китә инде ул,— диде.— Аның хәлен аңларга була: ул бит драматург...

Шулай диде дә депутат-шагыйрь сүзнең мөгезеннән эләктерде:

— Хөрмәтле коллегалар, депутат иптәшләр! Ренат Мәгъсумович дөрес әйтте. Чыннан да, балалар шагыйрьләре моңарчы гел рәнҗетелеп, кыерсытылып киленде. Инде менә ничә еллар аларга Тукай бүләге бирелгәне юк. Исеме чит илдә дә билгеле булган балалар шагыйрен галәмгә очырасы иде. Андыйлар бездә бар. Алар икәү. Икесе дә халыкара Андерсен бүләге лауреатлары. Берсе, инде

шактый олыгайган булуына карамастан, һаман да шәп шигырьләрен язып, балаларны куандыручы Шәүкәт абый Галиев, икенчесе... Анысын әйтмәсәм дә беләсез инде! — диде ул һәм, сүзләрен раслап-җөпләп дигәндәй, депутат-шагыйрь балалар өчен әле генә тәнәфестә урысча иҗат иткән «Энекәш кирәкми миңа!» дигән шигырен укыды.

Депутат Туфан Миңнуллин «Нинди остроумный шигырь!» дип, башын чайкап куйган мәлдә, президиумда көчле кул чабу тавышы ишетелде. Р.Миңнуллин, сөенеп, артына борылып-күтәрелеп карады: каты кул чабучы Югары Совет рәисе иптәш Лихачев үзе икән! Ул татарча шәп белүен әнә шулай дәртле алкышлап раслады.

«Шигырьне татарчага хәзер үк тәрҗемә итәргә!» дигән катгый фикергә килеп, депутат-шагыйрь үз урынына барып утырды да кулына шигъри очлы автокаләмен алды...

— Без ел саен елның иң яхшы китап авторын ачыклыйбыз,— дип, махсус татарча сүз башлады шулай ук янә депутат-шагыйрь, республикабыздагы китапханәләрнең башлыгы Разил Вәлиев.— Әле күптән түгел генә, узган ел нәтиҗәләреннән чыгып, җиңүчеләрне билгеләдек. Минем тәкъдим: кайсы авторның шигъри китабы җиңеп чыккан — шуны җибәрәсе иде галәмгә.

Ул, итагать саклаптыр инде, үз китабының менә ничә ел рәттән беренче урын алуы хакында әйтүне кирәксенмәде.

Разил Вәлиев сүзен тәмамлауга, мөнбәргә депутат-шагыйрь-композитор Илсур Хөснетдинов сикереп менде. Татар телен шәп белгәнгәдерме, ул сүзен урысча башлады:

— Вот туты наши паеты... Татарски паеты гаварили... Туты... Они сказали... Ну инде... Гаварили о том... потом... что летать надо кому-то... космосу... И туты я должен гаварит... Пает далжен быть ишчо замечательный композитором, и ишчо популярным певцом... и... ни... деньги надо иметь... Туты...

— Галәмгә очарга өлгерербез. Телне кайгыртырга, телне коткарырга кирәк, җәмәгать! — дип, янә залга реплика ташлады депутат-драматург Туфан Миңнуллин.

«Татарстан яшьләре» хәбәрчесе Р.Гыйлемханов, ошбу сүзләрне ишетүгә, алдындагы кәгазенә иелде, «Галәмгә очу өчен тел белү кирәк!» дип, Туфан абый дөрес әйтте...»

— Ветераннар, пенсионерлар арасында татар телен яхшы белгән шагыйрьләр дә бар. Аларны да онытып бетермик! — дип, Т.Миңнуллинның сүзен җөпләп куйды депутат Фәндәс Сафиуллин. Ул нишләптер, депутат булса да,

ни шагыйрь, ни драматург, хәтта соавтор-композитор да түгел иде. Депутат-прозаик Ринат Мөхәммәдиев, озын буйлы булуына карамастан, сүзне кыска тотты:

— Безнең Язучылар берлегендә өч йөздән артык чамасы әгъза бар. Шуларның яртысы — шагыйрьләр. Ярты дигәннән... Галәмгә кайсы шагыйрьне җибәрсәк тә, аларның да, безнең дә йөзебез кызармаячак. Мин бу хакта үзем Мәскәүнең югары даирәсе белән еш очрашкалап-гәпләшеп йөргән вакытта Русия президентына да әйткән идем. Минем тәкъдимем: галәмгә шагыйрь Мөдәррис Әгъләмне очырырга кирәк! Ике дә уйламыйча очырыйк аны! Без моның белән отачакбыз гына. Ул галәмнән кире кайтып тормаска мөмкин. Бу ни дигән сүз? Бу Мөдәррис Әгъләмгә фатир бирү мәсьәләсе уңай хәл ителде дигән сүз!

Илбашы да Язучылар берлеге рәисенең тәкъдимен хуплады. Илбашы үзе хуплагач, башка депутатлар да ризалашты. Баксаң, Илбашы Әгъләм белән бик нык таныш икән. Президент, сабан туе карарга дип, Теләчегә баргач, Мөдәррис исә Казан «Оргсинтез» берләшмәсе төтенен бөркәнгән Аккош күлендәге дачасына — алачык-фатирына кайткач танышканнар икән. Мөдәррис бу хакта кемгәдер сәгатьләр буе сөйләп торган, диләр...

«Иртәгә Мөдәррис Әгъләмне сессиягә җитәкләп булса да алып килергә, үзе белән конкрет сөйләшергә, ризалыгын алырга» дигән карарга килеп, депутатлар кайсы кая таралыштылар...

Әмма ни кызганыч: Мөдәррис Әгъләм Казанда юк икән. Дачадагы алачыгына барып карадылар — анда үзе түгел, эзен дә тапмадылар. Чебен гөмбәсе җыеп йөрми микән дип, урманны айкап чыктылар — юк Мөдәррис. Бакчадашы, мичче-маляр-шагыйрь Сафуан Муллагалидә шигырь язышып ятмый микән дип, аңа сугылдылар — юк тек юк. Шулай ук бакчадашы шагыйрь-прозаик-журналист Ркаил Зәйдулла һәм редактор-язучы Зиннур Хөснияр бакчаларында чүп утап, суган йолкып, бәрәңге казып ятадыр дигән өмет белән аларга да кагылып чыктылар — юк Мөдәррис, юк...

Әйтерсең лә Мөдәррисне җир упкан.

...Инде М.Әгъләм кандидатурасы бераз онытыла төшеп, сессиядә бәхәс депутат-шагыйрь Ренат Харисның «Татар космонавты шагыйрь булу, Дәрдмәнд иҗатын белү өстенә, рәсем дә ясарга тиеш!» дигән тәкъдиме тирәсендә әйләнгәләгән көннәрнең берсендә М.Әгъләмнең кайдалыгы ачыкланды.

Бу хактагы мәгълүматы белән сатирик-язучы Фәнзаман Баттал матбугат аша уртаклашты. Ул, радио тыңларга бик хирыс кеше буларак, чит ил радиотапшыруларыннан шундыйрак хәбәр ишеткән: галәмнең кайсыдыр төпкеленнән Җиргә җибәрелгән татарча сигналлар алган икән Америка галимнәре. Бу сигналларны радиотыңлаучыларга да ирештергәннәр. «Мөдәррисегезне алып китегез!» — дип чәрелдәп кычкырган еламсак тавыш арасыннан Мөдәрриснең дә тавышын танып алган Ф. Баттал. «Алып китегез Мөдәррисегезне! Мондый мөдәррисләр үзебезнең планетабызда да мүре!» дигән ялварулы чәрелдек тавыш янәшәсендә Әгъләмнең «Еракка китеп кара син, еракка китеп кара!» дигән шагыйранә тавышы коточкыч каты ишетелә иде...» — дип язган гәҗиттә Ф.Баттал. Парламент халкы аптыраштa калды. Мөдәрриснең галәмгә ничекләр очуы, әлеге планетага ничекләр эләгүе хакында беркем дә анык кына әйтә-аңлата алмады.

Хәзерге вакытта парламент та, халык та беренче татар космонавты Мөдәррис Әгъләмнең кабат җирдә пәйда булуын зур түземсезлек белән көтә.

**Автордан.** Соңгы сессияләрнең берсендә депутатлар космодром мәсьәләсенә янә кайтып алдылар: «Татарфильм» киностудиясе төзеләсе урынга салынырга тиешле Болгарнур космодромы нигезенә яңа суверен Шәрәф мәчетен вакытлыча торгыза башларга, дигән бердәм фикергә килделәр алар. Халыктан акча җыясы гына калды.

*1997*

# Метро һәм сессия янә Әгъләм

Дәүләт Советының чираттагы вә гадәти сессиясенең бусында да чынбарлыкка әйләнергә мөмкин булырдай җитди, эшлекле мәсьәлә күтәрелеп, сүз-бәхәс «Кичекмәстән Казанда метро төзи башларга кирәк!» дигән тәкъдим-фикер тирәсендә куерган бер мәлдә, гүзәл Болак буендагы хәрабә йортлар арасыннан чалбарының бердәнбер сәдәфен каптыралмыйча чиләнеп, изаланып чыгып килгән шагыйрь Мөдәррис Әгъләмне кинәт... җир упты.

Бер мизгелгә аңын җуйган шагыйрьне «Нишләп ятасың монда, Мөдәррис әкә?» дигән кара-кучкыл тавыш исенә китерде. Әле генә судан ярга чыккан чүрәкәй үр-

дәк шикелле башын дерелдәтеп, гәүдәсен калтыратып, Мөдәррис өс-башындагы тузан-туфракны янәшә-тирәгә сипкәләде дә тавыш иясенә күтәрелеп карады.

— Бәт-әч! Котны ала яздың бит... Мин сине Карл Маркс дип торам,— диде ул үзенә текәлеп карап торган драматург Ризван Хәмидкә.— Нишлисең монда — җир астында? Рөстәм Мингалимең кайда?

— Рөстәм дустымны күптән күргәнем юк. Өендәдер. Мин инде биредә бер атна актарынам. Борынгы кулъязмалар, китаплар эзлим,— диде Ризван Хәмид.

Мөдәррис янә гәүдәсен калтыратып алды.

— Борынгы китапларны китапханәләрдән эзлиләр акыллы вә сакаллы бәндәләр, җир астыннан түгел,— диде ул.

— Дөрес, мин дә шулай уйлыйм. Мөдәррис әкә, китапханәсен генә табалмыйм...

— Ә-ә, аңлашылды... Син теге... кем әле... егерменче елларда кызыл башкисәрләр ике катлы йортын җир белән тигезләгән кемнең... профессорның шәхси китапханәсен эзлисеңдер... Эзлә, эзлә... Уңышлар юлдаш булсын үзеңә. Тапсаң, укырга берәр китап биреп торырсың.

— Карале, Мөдәррис әкә, китапханә турында син дә беләсең икән! — дип, Ризван Хәмид гаҗәпләнеп башын чайкап алды.

— Белмәскә! Ул профессор агай минем әни ягыннан әбинең әтисенең бертуган тиешле энесенең бик якын дусты булган. Аның Сәйф Сараи, Акмулла, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил белән кочаклашып төшкән фотосурәтләре, телевидение төшереп алган видеотасмалары минем Аккош күлендәге дачамда әле дә кадерле истәлек булып саклана,— диде Мөдәррис. Ризван Хәмиднең гаҗәпсенүе гаять көчле иде, шуңадырмы, ул Әгъләмнең мантыйксыз сүз сөрешенә әллә ни игътибар итмәде.

— Ник язмыйсың бу хакта, Мөдәррис әкә? Пьеса өчен менә дигән чимал бит! Пьеса дигәннән, мин бүген иртән генә өр-яңа драма язып тәмамладым.

— Беләм,— диде Әгъләм.— «Кайткан чакта китеп барыш» дип атала...

Ризван Хәмиднең күзлеге кашлары өстенә менеп кунаклады.

— Пьесаның эчтәлеген сөйләү түгел, хәтта исемен дә бер кешегә әйткәнем юк бит әле минем,— диде ул, исеакылы китеп.

— Миңа димәгәе,— диде Мөдәррис, кузгалырга ниятләп.— Ризван дус, мин очып төшкән җирдән гайре бүтән юл бармы чыгарга?

— Мин монда йөрим икән — димәк, бар! — диде Ризван һәм, пьесаның исемен Мөдәррис белгәнгә әле дә булса аптырап, милли сакалын сыйпап алды.

— Карале, киткәнче әйтим әле,— диде Әгъләм,— пьесаңда кеше ышандырмый торган бер урын бар. Йә алып ташла, йә төзәт син аны. Үзең булдыралмасаң, Туфан Миңнуллиннан киңәш сора. Хәер, үз башыңда булмаса, кеше төзәткән белән генә ерак киталмассың...

Мөдәррис беравык тын торды. Ризван «Мөдәррис әкә...» дип, нидер әйтергә җыенган иде, Әгъләм аны бүлдерде:

— Кайчагында шагыйрьләрнең дә сүзенә колак салырга кирәк, Ризван дус. Менә син аңлатып бир миңа. Пьесаңда Габдрәшитнең бот арасына сөяркәсе кайнар чәй түгә. Ялгыш, дисең инде син аны... Ярый. Габдрәхимнең...

— Габдрәшитнең ...— дип төзәтмә кертте Ризван Хәмид.

— Миңа димәгәе! Менә шул Габдрәшитнең, син әйтәсең инде, бик яман пешә... бот арасы... Ярый. Ампутациясез булмый, дисең инде син. Кисәргә кирәк, дисең. Моңа ышандык ди. Операцияне Габдрәиснең...

— Габдрәшит...

Ризванның сүзен Мөдәррис ишетмәмешкә салынды.

— ...беренче хатыны ясый. Кисә, ялгый, тегә... Мәтәштерә инде, үзең беләсең. Ярар, бусына да ышандык ди. Шуннан соң Габдрәхимнең икенче хатыны ташлап китә. Беренчесе сөенә. Габдрәшит кайгыра. Үзе кайгыра, үзе «Мәдәни җомга» чыгарган «Интим» гәҗитендәге урысча-татарча язмаларны татарча-урысча укырга тотына. Аннары «Интим» кибетенә чаба. Аннан гыйбрәторбибратор дигәнме шунда, бер дерселкеткеч сатып ала. И... өченче хатынга өйләнергә җыена...

Мөдәррис кинәт черт итеп җиргә төкерде дә:

— Батуллага иярмә син, Ризван дус! Батулланың әкиятләрен барыбер уздыра алмассың,— диде һәм, башын кыңгыр салып, күздән югалды.

Ризван: «Ну, Мөдәррис! Ну, шагыйрь?» — дип исенә килгән мәлдә, Әгъләм бер чакрым җир киткән иде инде.

Шагыйрьне иң әүвәл шул гаҗәпләндерде: башта ук искәрмәгән иде, бактың исә, җир асты көн яктысы кебек якты икән бит! Могҗиза дисәң дә могҗиза! Яктылык таш диварлардан да, түшәмнән дә, аяк астыннан да сирпелә. Хикмәти хәл! Бабаларыбыз ай-һай башлы булган икән. Кирәк бит шушыны уйлап табарга. Бу сиңа Ильич утлары гына түгел инде!

Әгъләм таң калып, тирә-юньгә текәлеп карый-карый ары китте. Китте дип... Бер егерме адым атлагандыр атласа. Әллә каян гына бер ак «Волга» килеп чыкты да, Мөдәррис янына килеп җитүгә, шып итеп туктады. Ишек ачылды, аннан «Идел» журналының баш мөхәррире Рашат Низаминың башы күренде:

— Мөдәррис, ашыгам! Эшем күп. Теләчегә очрашуга чакырдылар. Мамадыш белән Нурлатка да сугыласым бар. Ашыкмасаң, беркая да китмә. Мин бер сәгать ярымнан кайтып җитәм. Нәшриятка барасың булса, кайтышлый утыртырмын,— диде ул һәм ишекне шап итеп япты. Мөдәрриснең: «Ярар, мин радиода булам»,— дигән сүзләрен ишетмәде Рашат, машина космик тизлек белән кузгалып китте...

«Да-а, җир астында машина юллары да бар икән...» — дип уйлады Әгъләм һәм бер-ике адым гына атлады да катып калды: бәт-тәч, нинди тимер юл бу тагын? Аның сул ягыннан өч-дүрт метр читтә рельслар ята иде.

Мөдәррис имән шпалларның берсенә ботинкасының үкчәсе белән бәргәләп алды. Шык-шык иткән тавышлар рельс буйлап йөгерде. «Ренат Харисның «Һарут белән Марут» поэмасындагы шигъри юллар шикелле чыкылдап тора бит бу шпаллар!» — дип, үзалдына сөйләнде Әгъләм һәм, юлын дәвам итәргә теләп, икенче шпалга басты. Басуын басты, ләкин чүт кенә егылып китмәде. Мөдәрриснең катыга басарга тиешле уң аягы шпалга батып кергән иде. «Да-а... шпалларның черегәннәре дә бар икән. Еллар барыбер үзенекен итә шул»...— дип уйлап куйды Әгъләм.

Шагыйрь ары атлады. Карашы шома, якты дивардагы «Салих Сәйдәшев» дигән алтынсу язуга төште. «Бәй, «Салих Сәйдәшев» дигән тукталыш микәнни бу?» — Мөдәрриснең баш миен бораулап шундый уй йөгереп узды.

— Хәлләр ничек, Мөдәррис абый?

Әгъләм дерт итеп китте. Тавыш иясе шагыйрь Ләбиб Лерон икән.

— Нәрсә соң бу? — диде Мөдәррис.— Әле генә Ризванны, Рашатны очраттым... Татар язучыларын җир астына әллә учлап сиптеләрме бүген?

Ләбиб аның соравына сорау белән җавап бирде.

— Шәпме? — диде ул, «Салих Сәйдәшев» дигән язуга ымлап.— Минем эш. Үзем беркеттем.

— Изге эш эшләгәнсең,— диде Әгъләм.— Сәйдәшнең һәйкәлен генә куясы калган монда...

— Һәйкәлгә җир өстеннән урын алалмыйча ярты гасыр изаланалар бит. Булыр-булмас һәйкәлгә халыктан тиенләп акча да җыеп карадылар. Чыннан да, һәйкәл

өчен урын җир астында булмагае,— дип килеште аның белән Ләбиб.

— Бер хуттан минем һәйкәлгә дә, үзеңнекенә дә урын әзерләп куй, —диде Мөдәррис һәм саубуллашып та тормыйча китеп барды. Ләбиб Лерон «Һәйкәлне дә үземә генә эшләргә туры килмәгәе әле!» дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, Салих Сәйдәшев һәйкәле куеласы урынны бер метр озынлыктагы таяк белән үлчәп калды.

Мөдәррис Әгъләм, ары атлый-атлый, карашын шома, якты диварга төшерде. Шул вакыт аның башына янә шагыйранә уй килде: «Роберт Миңнуллинга әйтергә кирәк әле. Үзе өчен менә дигән фотокүргәзмә булырлык урын бит бу! Туган көненнән бирле төшкән фотосурәтләренең барысын да чәпәп чыксын»...

Әгъләмне шундый уй биләгән вакытта сессиянең мөнбәреннән метро турындагы шигырь укырга керешкән депутат Роберт Миңнуллинны очкылык тота башлады. Алдындагы чынаяктан кабаланып чәй йотты да залга акыллы караш ташлап:

— Мине кемдер исенә төшерә,— диде.

— Кем булсын, хатыныңдыр инде,— дип, гадәттәгечә төрттереп алды депутат-шагыйрь Разил Вәлиев.

— Бик ихтимал,— диде шулай ук депутат-шагыйрь Ренат Харис. Аны да баягынак тиктомалдан очкылык тота башлаган иде.

— Хатын эштә минем,— диде Роберт Миңнуллин. Әлеге сүзләре белән ни әйтергә теләгәндер — депутат халкы аңламады. Хәер, аңларга теләүчеләр юк иде шикелле.

Залны бер тын үзенә каратып торганнан соң, Роберт Миңнуллин «Энекәш кирәк миңа» шигыреннән сүзләре, рифмалары, кайбер хәрефләре белән гаять дәрәҗәдә үзгә булган «Метро кирәк миңа» дигән җитди эчтәлекле шигырен дәртләнеп укый башлады.

Метро кирәк безгә,
Метро кирәк сезгә,
Метро кирәк сиңа,
Метро кирәк миңа!
Поезды йөрмәсә дә,
Төзелеп бетмәсә дә,
Метро кирәк сезгә,
Метро кирәк безгә!
Метро кирәк сиңа,
Метро кирәк миңа,
Ике катлы фатирым бар,
Машина кирәкми лә...
Җир астында рәхәтләнеп
Җәяү йөрмәү ни тора?!
Шуңа күрә... ыйк!..

Тукай бүләге иясен янә очкылык бимазаларга тотынды:

...Шуңа күрә... ыйк!.. депутак... ыйк!

Депутат сүзен әйталмыйча интеккән депутат-шагыйрь янә чәй йотып куйды. Шуннан соң гына шигырь төгәлләнү стадиясен алды:

...Шуңа күрә депутап... депутат дуслар,
Метро кирәк, метро!

Шигырь үзенчә шулкадәр тирән эчтәлекле, тәэсирле булуына карамастан, депутат-драматург Туфан Миңнуллинның әсәргә карата мөгамәләсе кыска булды: ул бер сүз дә әйтмәде. Озын булуына карамастан, тәнкыйтьче-прозаик Ринат Мөхәммәдиев, шигырьне мактап, гомумән, Роберт Миңнуллинның кабатланмас олы иҗаты хакында җентекләп, тирәнтен анализ ясап, кыска гына чыгыш ясаган булыр иде дә, вәләкин ул бу чакырылышта депутат түгел иде...

Барча депутат «Метроны кичекмәстән төзи башларга кирәк!» дигән бердәм фикергә килеп таралышкан вакытта, Мөдәррис Әгъләм җир астындагы тимер юл буйлап баруын дәвам итә иде. Ниһаять, ул шпаллардан титаклап арыды. Читкә чыгып, уң тарафка юл алды.

«Илбашына әйтергә кирәк әле, әгәр Мәскәү Казанда метро төзергә рөхсәт бирсә, бабайлар салган шушы җир асты юлын гына файдаланырга кирәк. Хәер, безнең төзүчеләргә әйттең ни, әйтмәдең ни. Ярты метр гына читтән интегә-интегә яңа юл салсалар салырлар, бу юлга керә белмәсләр...»

Мөдәррис шундый уйлар уйлап әллә ни күп ара да китмәде, каршысына бер кеше килеп төште. Үзе кулына бал калагы чаклы чүкеч тоткан, җитмәсә.

Аяк астындагы кеше башын күтәрүгә, Мөдәррис аны шундук танып алды: шагыйрь дусты, әшнә-энекәше Нияз Акмал икән!

— Нишлисең монда, Мөдәррис? — диде Акмал, авызына тулган тузан-туфракны җиргә төкергәләп.

— Өйгә кайтып барыш. Ә син нишлисең? — диде Әгъләм.

— Беркөнне минем агач фатирда булганыең бит әле,— дип сөйләп китте Акмал.— Идәндәге тырпайган кадакка эләгеп түбәтәең җыртылганые. Бүген, буш вакыт табып, шул йөз иллеле кадакның түбәсенә берне китереп суккан идем... Менә... нәтиҗәсен үзең күреп торасың.

— Да-а... Өс-башларыңны алыштырып идән җәяселәрең алда икән әле,— диде дә Мөдәррис башын кыңгыр салып китеп барды.

Нияз аның артыннан:

— Карале, Мөдәррис! Сиңа әйтәм! Тартырга калдыр әле! — дип кычкырды.

Ерактан:

— Үзеңнекен тарт! — дигән сүрән тавыш ишетелде.

...Бик озак барды Мөдәррис. Бара торгач, эскалаторга юлыкты... «Бу баскыч мине, һичшиксез, өскә алып менәчәк»,— дип уйлады ул. Һәм ялгышмады: ике-өч минут та узмагандыр, Әгъләм Дәүләт Советы бинасыннан әллә ни ерак булмаган бер иске агач йорт ишегалдына килеп чыкты.

Опера һәм балет театры каршындагы Ленин һәйкәле янында бер кочак иске китап күтәргән Ризван каләмдәшен янә очратачагын Әгъләм белми иде әле.

*1 ноябрь, 2000*

## Фатир, сессия һәм янә Әгъләм

Ниһаять!

Әйе, әйе, ниһаять, безнең урамга да бәйрәм килде. Җөмһүриятебез җитәкчелеге, Кол Шәриф мәчетен торгызу, Раифа тыюлыгын яңарту-төзекләндерү, Казанның үзәк урамын транспорт хәрәкәтеннән арындырып ямьләндерү, Кабан күле белән Болакны чистарту, Салих Сәйдәшевкә һәйкәл кую, Казансу аша яңа күпер салу, эрелеваклы базарлар ачу, «Татарфильм» киностудиясе, ипподром, автодром, космодром һәм метро төзү, сыра-шәрабхәмер заводларын заманча җиһазлап, камилләштереп, тулы куәтенә эшләтә башлау кебек үтә мөһим, үтә җитди эш-гамәлләрне уңай хәл кылганнан соң, әдәбият әһелләренә йөз белән борылып, аларның тормыш-көнкүрешләренә аталарча игътибарын юнәлтте. Дәүләт Советының соңгы, гадәти сессиясендә депутат халкының нәкъ менә шул хакта артык каударланмыйча, шапырынмыйча, хисэмоциягә бирелмичә, талант ияләренең үзләренә караганда да ныграк борчылып, көн кадагында эленеп торган гаять авыр мәсьәләнең асылын тирәнтен аңларга тырышып хәлиткеч сүз алып баруы —югарыдагы җөмләбезне, әйтергә кирәк, хәтта һәр хәрефеннән яктылык вә шатлык-куаныч нурлары сирпелеп торган җөмләбезне куәтләүгә күркәм бер дәлилдер.

Фикер алышу вакытында иң әүвәл Татарстан Язучылар берлеге рәисе, депутат-галим Фоат Галимуллин сессия мөнбәренә күтәрелде һәм, затлы ир-ат дикторларга гына хас булган көр, мәһабәт тавышы белән сүз башлап, моңарчы телгә алып әйтердәй ремонт-фәлән күрмәгән Язучылар бинасында, ниһаять, капиталь ремонт башлануы хакында бәян итте, XIX гасыр ахырындамы, әллә XX йөз башындамы Марков Оконищинков дигән сәүдәгәр, үз мәнфәгате максатында төзеткән әлеге тарихи бинаның бүгенге көндә мөшкел хәлдә булуын үз вакытында күреп алып, хәл кадәри матди ярдәм иткәне өчен хөкүмәткә һәм хөкүмәт җитәкчеләренә олуг рәхмәтен җиткерде.

— Эшне без подвалдан башладык,— диде депутат-галим.— Ташландык хәлгә килгән бүлмәләрнең берсен спортзал иттек. Бинабыздагы кайбер бүлмәләрне арендага алып торган эшмәкәрләр өчен генә түгел, хәтта спиртны... гафу итегез... спортны дус иткән каләмдәшләребез өчен дә менә дигән ял итү урыны булыр ул дип ышанабыз. Язучылар берлегенә яки Әдәби фондка тиешле ярдәм-фәлән сорап яисә үтенеч-гозер белән килгән өлкән әдипләребез дә, һич югында, шунда тәннәрен язып, җаннарына тынычлык, күңелләренә иҗат дәрте алып китәрләр. Спортзалы булгач, душы-саунасы да кирәк. Бер уңайдан бу мәсьәләне дә хәл итәргә керештек. Дөрес, подвалдагы бүлмәләр кысанлыкка кысан анысы. Ләкин, халкыбыз әйтмешли, күңелең киң булсын. Безне тагын бер мәсьәлә борчый иде. Ул да булса, язучыларны кафелы, ягъни ашханәле итү. Әлбәттә, Язучылар йорты ишегалдында «Сарман» кафесы бар барын. Әмма ул кулларына челтәрле телефон тоткан эшмәкәрләр өчен генә. Артык кыйммәт анда. Ул кафедан бердәнбер Ринат Мөхәммәдиев кенә — беләсездер инде, ул безнең берлегебезнең элекке рәисе — даими файдаланды булса кирәк. Бинабызның подвалында тагын ике бүлмә бар. Янәшә бүлмәләр. Менә шуның берсен кухня, икенчесен туклану залы итәргә исәбебез. Ашау-эчү артык кыйбат булмас дип фараз кылып торабыз. Инде язучыларны, хөрмәтле шагыйрьләребезне фатирлы итү, яшәү шартларын яхшырту мәсьәләсенә килсәк... Әйе, фатирга мохтаҗ каләмдәшләребез байтак әле. Әйтик, күренекле шагыйрь, күпсанлы шигырьләр һәм поэмалар авторы, җөмһүриятебезнең Габдулла Тукай исемендәге бүләге иясе Мөдәррис Әгъләм, шулай ук шагыйрь, публицист, Кукмара районының Зур Сәрдек авылы егете, Гаяз Исхакый исемендәге мәртәбәле бүләк иясе

Газинур Морат, аннары килеп, менә дигән прозаик, талантлы шагыйрь, сәләтле журналист, «Мәдәни җомга» гәҗитенең әдәби хезмәткәре Нияз Акмал, шагыйрә Роза Хәлиуллина... Тагын... Саный китсәң, күп алар бездә. Әйе, Башкортстаннан ук килеп-китеп йөрүче, Казанда яшәштергәләп тә яшәр урын табалмыйча җәфаланучы драматургыбыз Эсфир Яһудин да бар әле тагын... Бу урында Нияз Акмал мәсьәләсенә ачыклык кертү мәслихәт булыр. Бүгенге көндә Нияз Акмал гаиләсе белән Мөштәри урамында, Ленин музеена күрше булган бер фәкыйрь агач йортта яшәп ята. Суга, бүтән йомыш-фәләнгә тышка чыгып йөрешле. Яшәү һәм иҗат итү өчен шартлар куандырырлык булмаса да, Нияз Акмалның ул фатирдан күчеп китәргә исәбе юк кебек сизелә. Берәр заман Ленин музеена реконструкция уздырганда, бәлки, үзе яшәгән йорт урынында таштан яңа йорт төзерләр дип өметләнә ул. Акмалның аннары шул тирәдә гомер чиккән ниндидер Петька дигән керәшен дустын да ташлап китәсе килми бугай. «Петька — «Мәдәни җомга»да басылган һәр язмамның төп каһарманы. Фатир турында сүз чыкса, иң элек Петька дустыма бирү җаен карагыз!» Бу — шагыйрь Нияз Акмалның Татарстан Язучылар берлеге рәисенә, ягъни миңа, шәхсән үзе әйткән сүзләре. Әлбәттә, без язучылар әсәрләренең алыштыргысыз герое Петька Фәләнович Төгәновка фатир тәкъдим итә алмыйбыз. Киләчәктә, бәлкем, бу мәсьәлә уңаеннан да төпле бер нәтиҗәгә киленер...

Депутат-галимнән соң сүзне һәр җитди мәсьәләгә карата үз фикере, канатлы репликасы яисә яңа шигыре булган депутат-шагыйрь Роберт Миңнуллин алды.

— Шагыйрь Нияз Акмал турында күп сөйләргә мөмкин. Әмма минем сүзем кырык биш яшенә җитеп тә әлегәчә фатир шәе күрмәгән Газинур Морат хакында да түгел,— дип сөйли башлады депутат-шагыйрь.— Ул әле яшь, талантлы, энергиясе ташып тора. Аның кебек чагында минем кайбер яшьтәшләрем-остазларым да фатирсыз-нисез интекте...

— Ничек? Газинур Моратның Батый дигән малае бар түгелме соң? Гаиләле килеш моңарчы ничек фатирсыз яшәргә мөмкин? — дип гаҗәпләнүен белдерде депутат-шагыйрь Ренат Харис.

Ошбу урында янә бер депутат-шагыйрь Разил Вәлиев төзәтмә кертәсе итте:

— Газинур Моратның малае Чыңгыз исемле,— диде ул.— Мөдәррис Әгъләмнеке кызыксындырса, анықын да әйтә алам: Идел исемен йөртә аның улы...

— Һем... Чыңгыз... Идел... Ә Батый кем малае соң алайса? — дип, Ренат Харис кызыксынулы карашын Роберт Миңнуллинга төбәде.

Балалар шагыйре үзенә генә хас юмор белән әйтеп куйды:

— Минеке түгел, Ренат Мәгъсумович. Минеке — Алмаз исемле,— диде.

— Беләм, Роберт Мөгәллимович, беләм. Синеке Алмаз икәнен дә, телевизордан «Алмаз +» тапшыруын алып баруын да. Фамилиясе Хәмзин бит әле аның? — дип, дустанә елмайды Ренат Харис.

Дәрдмәнд хәтле Дәрдмәнднең иҗатын тулаем яттан белгән Ренат Харисның Алмаз Миңнуллин белән Алмаз Хәмзинне бутавына кәефе кырылган Роберт Миңнуллин, йөзенә елмайган кыяфәт чыгарырга тырышып:

— Юк, Ренат Мәгъсумович... Фамилиясе — Харисов! — диде.

— Алайса, Хәмзин малае булып чыга инде Батый,— диде Ренат Харис, үзенчә нәтиҗә ясады.

Депутат-шагыйрь Разил Вәлиевнең баядан бирле теле кычыта иде, ул төрттермичә калалмады:

— Аңлашылмады, Ренат Мәгъсумович, Хәмзин үзе кем булып чыкты соң әле?

— Хәмзин Батыйның этисе була инде! — диде Ренат Харис һәм залдагы депутатларны карашы белән сөзеп чыкты да, шуны да аңламаска инде дигәндәй, җилкәсен сикертеп алды.

Мөһим мәсьәлә турында сөйләшүнең мәгънәсез сүз сөреше алуына ачуы килгән депутат-драматург Туфан Миңнуллин утырган урынында кыбырсый башлады.

«Да-а... Югары урыннарда эшләү хәтерне чуалта...» дип уйлап, Туфан Миңнуллин Ренат Харис тарафына карады. Чыннан да, шактый еллар җитәкче урыннарда эшләү сәбәпле, Ренат Харис күп нәрсәләрдән, аерым алганда, соңгы елларда әдәбият тирәсендә булган хәл-вакыйгалардан, каләмдәшләренең көн-күрешләреннән, хәл-әхвәлләреннән — ни кызганыч — бихәбәр иде. Олыгаю, олпатлану нәтиҗәседер, күрәсең, хәтердәгеләре дә бутала башлаган...

Туфан Миңнуллинның нервысы какшады, ахры, ул залга берәгәйле реплика ыргытырга мәҗбүр булды:

— Җәмәгать! Фатир турында гына сүз алып барырга телибез икән, шул хакта сөйләшик! Мәсәлән, мине Батыйның да, Аксак Тимернең дә кем малае булуы гүпчим кызыксындырмый!

— Туфан абый дөрес әйтте,— дип, сүзен дәвам иттерде Роберт Миңнуллин.— Әйе, Мөдәррис дигәннән... Ул миннән ике яшькә генә өлкән үзе, әмма шулай ук бик талантлы шагыйрь. Берничә ел элек Тукай премиясенә лаек булды. Шуңа карамастан балалар өчен дә әйбәт кенә шигырьләр язуын дәвам итә. Без аның белән күптәнге дуслар. Кайчандыр Мөдәррис Әгъләм, язучыларның Аккош күлендәге дачасыннан үз алачыгын миңа калдырып, берара гомумән йортсыз-нисез яшәп йөргән иде. Мөдәрриснең шул вакыттагы изгелеген әле дә булса онытасым юк. Тынчу шәһәрнең икеме-өчме бүлмәле фатирыннан вакытлыча гына булса да котылып, урманның саф һавасын сулый-сулый, аксакал язучыларыбыз, могтәбәр шагыйрьләребез Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким һәм Нәби Дәүли белән үзара аралаша-ярыша иҗат итү ул чакта минем өчен бик тансык иде. Рәхмәт Мөдәррискә! Әгәр дә без әле дә булса фатирсыз газап чиккән Әгъләмне берәр заман тораклы итәргә теләсәк, безгә бу мәсьәлә турында бүген-иртәгә яисә киләсе сессияләрнең берсендә җитди уйланып карарга кирәк!

Әллә балалар шагыйренең җиңел телле сүзләре тәэсир итте, әллә депутатларның чынлап торып Мөдәррис Әгъләмне шатландырасылары килде, сессиядә куерган фикер алышуларда сүз ахыргача гел әлеге шагыйрь һәм аны кичекмәстән фатирлы итү турында барды.

— Җәмәгать! — дип сүз алды Разил Вәлиев.— Миндә бер шик туды әле. Мөдәррис Әгъләмнең берүзенә өчмедүртме бүлмәле фатир бирдек ди. Шатландырдык, сөендердек ди. Ярый. Тик менә илле биш яшьлек шагыйрь болын кадәрле фатирда элеккечә үк иҗат итә алыр микән? Элеккечә үк шәп шигырьләр, поэмалар яза алыр микән? Ул бит әсәрләрен вокзалларда, трамвайларда, тукталышларда, күпер асларында, куак төпләрендә, Рәис Даутов, Хәлим Җәләй дачаларында, сыраханәләрдә, лифтта, капка төбендә, печәнлектә, мунчада һәм... кыскасы, теләсә кайда язарга күнеккән кеше. Яңа фатир аның иҗатына комачау гына булмасмы?

— Минемчә, юк! — дип сүзгә кушылды Туфан Миңнуллин.— Менә мин язам бит әле. Кичә генә «Минһаҗ маҗаралары»ның туксан тугызынчы сериясен язып тәмамладым...

— Синең бит ул — проза-а, Туфан абый!.. Шигырь түге-ел!..— диде Разил Вәлиев.

— Монысын шигырь белән яздым,— диде Туфан Миңнуллин.

— Мине дөрес аңлагыз. Мөдәррискә фатир бирүгә мин бер дә каршы түгел,— диюдән гайре сүз әйтә алмады Разил Вәлиев.

Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиевкә шагыйранә карап:

— Үземә бик ошаган барча шәп шигырем дә, җырчылар бик яратып җырлый торган популяр җырларым да яңа фатирларда язылды,— дип, адашы Туфан Миңнуллинга теләктәш-фикердәш булуын белдерде...

Кыскасы, көне буена сузылган фикер алышуларның нәтиҗәсе көтелгәннән дә шәбрәк килеп чыкты: сессия, сайлап алу мөмкинлеген күздә тотып, «Шагыйрь Мөдәррис Зөфәр улы Әгъләметдиновка шәһәрнең төрле төбәгеннән өчәр бүлмәле өч фатир тәкъдим итәргә» дигән карар кылды...

Арыган, йончыган депутатлар кабалана-кабалана таралышкан вакытта, шагыйрь Зөлфәтнең хатыны Фирая ханым, сессия шундый карарга киләсен әллә кайчан ук белеп, барлык эшләрен ташлап, таксилар яллап, Мөдәррис Әгъләмгә тәкъдим ителгән фатирларның өчесендә дә булып, алардагы һәр уңайлыкны, һәр җитешсезлекне җентекләп тикшереп, беренче карауда күренмәстәйләрен дә энә күзеннән үткәреп кайткан иде инде. Кайткан иде дип... Алай дию генә дөрес булмас.

Тынгысыз җанлы, таныш түгел кешеләргә дә һәрчак ярдәмгә килергә, авыр хәлләрен җиңеләйтергә әзер булган бу ханым, кайта-кайтышлый ук, Зөлфәтнең иң якын дусты Мөдәррисне Казан буйлап эзләп чапкан иде инде. Фирая ханымның фатир алу мәсьәләсендә тәҗрибәсе зур. Аның үзләренә, Зөлфәт исеменә бирелгән фатирны алалмыйча шактый газап чиккәнен, җәфаланганын, папка-папка кәгазь күтәреп ары-бире чапканын ул вакытта ярты Казан белеп, күреп, кызыксынып торды. Шуңа күрә Фирая ханымның бу очракта Мөдәррис Әгъләмгә булышырга атлыгып торуыннан бернинди дә хилафлык-чаталык эзләргә кирәкмидер. Аннары килеп, шунысы да бар бит әле: моңарчы яңа фатир алып карамаган Мөдәррискә, Фирая ханым үзе әйтмешли, ике бөекнең икенчесенә (берсе Зөлфәт икәнен әйтеп тормасак та була) кем дә булса киңәш бирергә, аның белән тәҗрибә уртаклашырга тиештер ләбаса...

Фирая ханым шәһәр урамнары буйлап чатыр чаба торгач, ниһаять, эзләп тапты Әгъләмне. Эссе көн булуга карамастан, даһи фикерләр генә сыйдырган башына йонлач кепкасын батырып ук кигән шагыйрь, «Рәссамнар йорты» каршындагы Бакый Урманче һәйкәле янында

сынчы-рәссам дусты Фәһим Фәсхетдиновка карап, ленинчыл уң кулын кискен хәрәкәтләндерә-хәрәкәтләндерә, үз шигырен сөйләп тора иде:

... Динең гөнаһ санаганда
Әле шәрә сурәт,
Бакый Урманчелар барды,
Ил сәнгатен сөйрәп.

Бакый халыкка һәр чорда
Юл авыр салына.
Тудыру авыр —
Бакыйлар
Меңгә бер табыла...

Шигырьне ахырынача тыңлап бетерергә исәбе булса да, Фирая ханым Мөдәррисне укуыннан бүлдермичә түзә алмады:

— Мөдәррис! Сөенче! Сиңа фатир бирделәр! — диде ул. Аның уенча, әлеге куанычлы хәбәрне ишеткән Мөдәррреснең йөзе кинәт балкып китәргә тиеш иде. Ләкин Әгъләмнең, чырае үзгәрү түгел, мыегы да селкенмәде.

— Беләм, Фирая ханым, беләм,— диде ул, исе дә китмичә.

— Белгәч, нигә сөенмисең соң? — дип гаҗәпләнде Фирая ханым.

— Нәшрияттан гонорар алмаган әле мин,— диде Мөдәррис.

Фирая ханым Әгъләм янәшәсендә тыйнакчыл гына басып торган сынчы-рәссам Фәһим Фәсхетдиновны әле генә искәреп алды булса кирәк:

— Бәй, сезне абайламыйча да торам. Исәнмесез! — диде ул аңа. Аннары күңеленнән ташып түгеләм-түгеләм дип торган сөенечен аның белән дә уртаклашасы итте: — Мөдәррискә фатир бирделәр!

— Беләм,— диде Фәһим Фәсхетдинов, шагыйрь дусты кебек үк, аның да әллә ни исе китмәде.

— Беләм дә беләм, дисез... Үзегез шатланмыйсыз да. Кайдан, кемнән белдегез соң сез? — дип, отыры гаҗәпләнде Фирая ханым.

— Әле генә Илбашы шылтыратты,— диде Әгъләм.

Тиз ышанучан Фирая ханымга шул җитә калды.

— Чынлап тамы? — дип әсәренде ул.— Үзе шылтыраттымы? Ни диде? Син нәрсә әйттең? «Рәхмәт» дияргә онытмадыңмы? Кабинетына үзем алып керимме? Әйдә, иртәгә үк, юк, бүген үк барабыз!

Мөдәррис алдашуына үкенеп куйды.

— Минем өчен борчылма, чәчеңне вакытыннан алда агартма, Фирая ханым,— диде ул бераздан һәм сигаретын кабызды.

— Нинди борчылу булсын. Юкны сөйләмә, Мөдәррис. Карале, сиңа тәкъдим ителгән өч фатирны да барып карадым. Берсе — Дәрвишләр бистәсендә, икенчесе Лаеш районы белән чиктәш җирдә, өченчесе «Оргсинтез» заводы ягында. Тик син боларның берсенә дә риза була күрмә. Син бит — бөек шагыйрь! Үз дәрәҗәңне бел. Фатирны үзәктән, депутатлар ала торган йорттан сора. Аннан соң...

— Миңа фатир кирәкми! — дип, битараф кына бүлдерде аны Мөдәррис.— Фатирлы итеп, мине язудан, галиҗәнап Шигърияттән биздермәкче булалар!

— Фатир бирәм дип торганда, кем алмый инде?! Җүләр син, Мөдәррис! — диде ялыну-ачынулы тавыш белән Фирая ханым.

Әгъләмнең үз сүзе сүз иде:

— Беләм мин аларны! Мине халыктан аерырга ниятлиләр. Халык шагыйре итмәскә исәпләре. Шалиш! Барып чыкмас! Пока, Фирая ханым!

Ул шулай диде дә, Фәһим дустына «Әйдә!» дигән ишарә ясап, сул кулын чалбар, уң кулын кәчтүм кесәсенә, йонлач кепкалы башын күлмәк якасына чумдырып, эре-эре атлап китеп барды.

*Декабрь, 2000*

## Шагыйрь, илле тәңкә һәм... тәнкыйтьче

Мөдәррис Әгъләмнең университет шәкерте булып саналып йөргән чагы икән.

Университетка баргалап-кайткалаган өчен бирелгән стипендия акчасының язмышын ике-өч көндә хәл иткәч, Мөдәррис Әгъләм, өстенә тоз сибелгән ипи катысын авызында җебетә-җебетә, стаканыннан Мәскәү Кремле күренеп торган чәен эчкән вакытта, берәр студенттан әҗәткә акча сорап торырга уйлаган...

Менә коридорның бер башында Мамадыш егете, ике Мөдәррис буйлык Ринат Мөхәммәдиев дигән студент пәйда була.

Шигъри хәрәкәтле адымнар белән Мөдәррис аның каршына чыга да:

— Карале, Чаллыдагы апаның туган көне иде. Котлап телеграмма сугарга акча җитми. Стипендия алганга кадәр илле тәңкә биреп тор! — ди.

Ринат Мөхәммәдиевнең каядыр ашыга торган чагы булгандыр инде, ул Мөдәррискә иелеп карый да кесәсеннән акча чыгара. Тиешле сумманы санагач:

— Телеграммага ике сум гына җитә түгелме соң? — дип сорап куя. Мөдәррис акчаны җәһәт кенә үрелеп ала да, бүтән төпченмәслек итеп:

— Мин телеграмманы җизнигә дә сугам! — ди...

Көннәр, айлар уза. Көне-төне шигырь язып яткан җиреннән аерылып, ике тапкыр стипендия акчасы алып кайта Мөдәррис. Ринат Мөхәммәдиев тә ике тапкыр аның бүлмәсенә кереп хәлен белеп чыга. Ләкин икесендә дә Мөдәрриснең хәле мактаныслык булмый.

— Әле генә Зәйдәге абыйның хатынының энесенең этисенә телеграмма суктым. Юбилее иде. Кесәдә ике сум егерме җиде тиен генә акчам калды. Стипендия алгач кайтарырмын,— ди Мөдәррис...

Тагын көннәр уза. Мөдәррис Әгъләмнең кайсыдыр гәҗиттә бер бәйләм шигырьләре дөнья күрә. Ринат Мөхәммәдиевнең, ниһаять, түземлеге төкәнә.

— Ыслуш-шай, Мөдәррис,— ди ул шул көнне,— илле сумны бирергә уйлыйсыңмы син, юкмы? — Һәм иелеп сыңар кулы белән шагыйрьне үз буе озынлыгына кадәр күтәреп ала.

— Нинди илле сум тагы? — ди Мөдәррис, бик нык гаҗәпләнеп.— Инде ничә тапкыр ниндидер акча сорап тинтерәтәсең. Шагыйрь бит мин. Акча ясаучы түгел. Вакытың булса, менә минем шигырьләрне укы, өйрән!

Һәм ул үзенең шигырьләре басылган гәҗитне Ринат Мөхәммәдиевнең зур акча янчыгы хәтле кулына тоттыра да, идәнгә сикереп төшеп, тиз-тиз генә китеп бара...

Күп тә үтми, матбугат битләрендә тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиевнең исеме күренә башлый.

Аның тәүге тәнкыйть язмаларының берсе Мөдәррис Әгъләм шигырьләре турында иде, дип сөйлиләр...

*17 сентябрь, 1991*

# Әңгәмә

Борын-борын бервакыт яшь язучы Ләбиб Лерон шагыйрь Мөдәррис Әгъләмгә болай дигән:

— Мөдәррис абый, чын дөресен әйт әле, зинһар: синең хет бер генә мәртәбә булса да алдашмый торганың бармы?

— Ә син нигә алдашасың? Алдашма! Бервакыт мин, Женя, Зөлфәт ресторанда утырдык...— дип сөйли башлаган Мөдәррис Әгъләм.

— Гафу ит, Мөдәррис абый... Женя дигәне кем була инде аның?

— Бүлдермә — бүлтереккә әйләнерсең... Женяны да белмәгән башың белән... Женя ул... Женя! Ефтушинкы! «Ягодные места»ны язган шагыйрь. Зөлфәт тә яза... Пьесалар... Ә мин өченче көн роман бетердем... «Орлык кыяры» дип атала... Шәп килеп чыкты! Бер йөз яшьлек карт белән аның туксан биш яшьлек малае турында...

— Гафу ит, Мөдәрр...

— Өлкәннәрне тыңларга өйрән, дип әйттем бит инде. Женя минем шигырьләрне дә тәрҗемә иткән. Урысчага...

— Татарча белмидер бит ул Евтушенко?

— Миңа димәгәе!

— Белмәгәч ничек тәрҗемә итә инде ул?

— Каспаров та белми. Ә үзе — чемпион! Талантлы шагыйрьләргә тел белү ниәбизәтельне! Женя Зөлфәтнең ике поэмасын,— берсен язылып бетмәгән килеш,— җиде шигырен тәрҗемә иткән. Татарчага! Ресторанда шуларны укыды. Зөлфәтне «скурый» белән алып киттеләр. Әле менә шунда барышым. Берәр кила алма суты табам да... Зөлфәт бик ярата бит алма сукларын... Әчегәннәрен бигрәк тә!

Шулай дигән дә Мөдәррис Әгъләм, башын кыңгыр салып, ары киткән...

*1984*

# Әзмәвер

Мөдәррис Әгъләм белән журналист Айрат Садыйк кичке Казанның караңгы бер урамы буйлап, ни турындадыр гәп сатып баралар икән.

Кинәт боларның каршысында, кувшиннан чыккан җен шикелле, бер әзмәвер пәйда була.

— Закурить не найдется? — дип сорый бу. Мөдәррис

Әгъләм авызының бер як читендә төтәп килгән сигаретын икенче якка авыштыра да:

— Не куряшие! — ди һәм юлын дәвам итә.

Шул вакыт кичке Казан тагын да караңгылангандай була...

...Мөдәррис Әгъләм, сигарет кузы пешергән иреннәрен бармаклары белән сыйпый-сыйпый, тротуар читендәге куаклык арасыннан башын чыгарып, ай яктысы төшкән юлга карый: әзмәвер күренми, Айрат Садыйк кына өс-башын кагып азаплана...

Мөдәррис Әгъләм, яртылаш сынган сигаретын аяк астындагы чирәм арасыннан эзләп табып, авызына сак кына каба да битләре сыдырылган Айрат Садыйк янына килеп, берни булмагандай сүз ката:

— Карале, бик озак сөйләштегез. Авылдашың идеме әллә ул егет? — ди...

*1985*

## «Он со мной...»

Журналист Рәис Сабировның «Социалистик Татарстан» гәҗите редакциясенә баш мөхәррир булып эшкә килгән көннәре, имеш...

Беркөнне, гәҗит-журнал нәшриятына — үзенең эш урынына кереп барганда, моны ишек төбендә сакта торучы милиционер туктата. Рәис Сабировны беренче күрүе булгандыр, күрәсең — мөхәррирдән ул пропуск күрсәтүен сорый.

Баш мөхәррир пропускын эзләп матавыкланган вакытта, әллә каян гына шагыйрь Мөдәррис Әгъләм килеп чыга да милиционер егеткә артык илтифат итмичә генә:

— Пропустите его, он со мной! — ди һәм аңышмыйча торган Рәис Сабировка, нишләп торасың инде, дигән караш ташлап, борыласы якка «аэродром» кепкалы башын даһиларча кырын салып, зур тизлек белән үтеп тә китә.

Милиционер егет Мөдәррис Әгъләм тарафына карап тора-тора да, үзеннән битәр гаҗәпләнгән баш мөхәррирга елмаеп:

— Рәхим итегез, узыгыз! — ди.

*1984*

# Кайда эләгәсең бит!

Борын-борын бервакыт. Гәҗит-журнал нәшрияты коридоры. «Яшь ленинчы» гәҗите мөхәррире Роза Туфитулова коридордагы утны кабыза да:

— Тегендә баргач та җитешербез әле караңгыга өйрәнергә,— ди. Шулчак Мөдәррис Әгъләм килә дә:

— Анда да кайда эләгәсең бит әле! — дип, башын кыңгыр салып китеп бара...

*1984*

# Төтен

Борын-борын бервакыт «Яшь ленинчы» гәҗитханәсенең әдәбият һәм сәнгать бүлегенә үзешчән композитор Сөембикә Вәлиева килеп кергән. Кергән дә, бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыккач:

— Языгыз әле җыр өчен шигырьләр. Сезнең бит баскан җирегездә төтен чыгара торган вакытыгыз! — дигән.

Шулчак Мөдәррис Әгъләм килгән дә:

— Төтен самавырдан да чыга ул! — дип, башын кыңгыр салып китеп барган...

*1984*

# Татарлар бөтенесе дә бөек

1984 елның сентябре.

«Яшь ленинчы» гәҗитханәсе. Әдәбият-сәнгать бүлегендә бер төркем шагыйрь бөекләр хакында гәп корып утыра икән. Тумышы белән Башкортстан төбәгеннән булган шагыйрь Госман Садә:

— Безнең башкорттан гына бик күп бөекләр чыккан... Мәсәлән, Мостай Кәримне генә алыйк...— дип сүзгә кушылган. Шулчак Мөдәррис Әгъләм:

— Шулай инде... Башкортка татарның бөтенесе дә бөек булып тоела! —дигән дә, башын кыңгыр салып, китеп барган...

*1984*

# Катмый әле...

1984 елның ноябре. Эльс Гадел, Ркаил Зәйдулла һәм Ләбиб Лерон, урыс язучысы Валентин Катаев турында үзара әңгәмә куертып, тәмәке пыскыталар икән. Шулчак болар эргәсенә таба Мөдәррис Әгъләм килә.

— О-о-о, Мөдәррис... Катаев! — дип каршылый аны Ләбиб.

— Катмыйм әле мин тиз генә,— ди Мөдәррис Әгъләм, һәм барысы белән дә сул кулын кыйшайтып күрешеп чыга да, башын кыңгыр салып китеп бара...

*1984*

# Кәләш яки «Наполеон» коньягы

Борын-борын бервакыт шагыйрь Ркаил Зәйдулла белән язучы Зиннур Хөснияр үзара бәхәсләшкән.

— Авылга кайткан саен, әни: «Кайчан өйләнәсең инде?»— дип аптырата. Яңа елга өйләнмичә дә булмас! — дигән Ркаил.

— Әгәр Яңа елга кадәр өйләнсәң, миннән сиңа бер «Наполеон» коньягы! Әгәр өйләнмәсәң, син миңа коньяк алып бирерсең,— дигән Зиннур.

— Ярый,— дигән Ркаил. Куллар бирешкәннәр болар...

Бераздан:

— Коньягыңны әзерләп куй! — дигән Хөснияр.

— Коньяк кына табарбыз ла ул...— дигән Ркаил, бәхәсләшүенә үкенгәндәй.

Шулчак болар янына Мөдәррис Әгъләм килгән дә:

— Уйла, Ркаил. Уйла. Өйләнүгә караганда хәзерге заманда коньяк очсызгарак төшә ул...— дип, башын кыңгыр салып китеп тә барган...

*21 ноябрь, 1991*

# Тәрәзә

Көз. Әбиләр чуагы. «Салават күпере» журналханәсе.

— Тышта җылы. Бүлмәдә суык,— ди Зиннур Хөснияр, форточкасы ачык тәрәзә янына елышып.— Әллә тәрәзәне ачарга микән?

1946 елның октябреннән бирле, ягъни якты дөньяга

аваз салган көннән алып суыкның ни икәнен дә белмәгән Мөдәррис Әгъләм:

— «Тәрәзәгезне ачыгыз!» дип, мин сезгә күптән әйттем бит инде,— ди.— Газинур Моратка багышлап язган шигыремне укымадыгыз мәллә?

Ачыгыз тәрәзәгезне,
Булса тәрәзәгез!..

Тирән мәгънә салып язган шигырьнең ошбу юлларын Газинур Моратка карап әйткәч, Мөдәррис Әгъләм:

— Хәер, сез язучылар бит әле, укучылар түгел,— ди дә, башын кыңгыр салып, ишеккә таба юнәлә.

— Синең ул шигыреңә ышанып, тәрәзәне ачкан идем,— ди Газинур Морат аның артыннан,— мин эшкә китүгә, караклар, кереп, радиоалгычны һәм шигырь язган вакытта гына кия торган чалбарны алып чыгып киткәннәр...

*18 сентябрь, 1991*



## IV бүлек

# Һәйбәт гайбәтләр



# Мин сөйләем, син тыңлама...

*(Ярты пәрдәлек сюжетсыз-нисез гәп-кәмит)*

КАТНАШАЛАР:

Рабату — аш-суга бик маһир, зәвык белән генә аклы-каралы сакалмыек җибәргән, кайбер сүзләрнең килеп чыгышы турында телдән тәфсилләп язылган әдәби диссертация авторы. Яше илле бишләр тирәсендә.
Марчелло — аксыл-карасу мыеклы. Кием-салым, төсле телевизор һәм тел очында эри торган затлы балык турында гәп куертырга ярата. Илле яшьләрдә.
Камкәрим — шулай ук бу да мыеклы. Очынып сөйләүчән. Бик күп һөнәрләреннән берсе — теләсә кем булып сөйләшә һәм җырлый ала. Кырык биш яшьтә.
Рөсмин — мыексыз. Уйчан. Әйтсә — турысын әйтә. Портфельле. «Идел» сигаретының буй-буй сызык төшерелгәнен генә тартырга ярата. Андый сигареты булмаган чакта, бүтәннәрен дә рәхәтләнеп тарта.
Нәдирә — хатын-кыз. Сихер-михер турында күп белә. Гомумән, бел мәгән нәрсәсе юк.
Вахтерша хатын — марҗа.

(Искәрмә: әсәрдә катнашучыларның (Рабит Батулла, Марсель Галиев, Камил Кәрим, Рөстәм Мингалим, Нәбирә Гыйматдинова) исем-фамилияләре кайбер сәбәпләр аркасында үзгәртелеп бирелә.)

Вакыйга безнең көннәрдә Язучылар йортының бер бүлмәсендә бара.

## БЕРЕНЧЕ ҺӘМ СОҢГЫ КҮРЕНЕШ

Рабату. Ракетаның каян килеп чыкканын белмисездер әле сез... «Өрә-китә»дән килеп чыккан ул. Ракета — өрә-китә... Өрә дә китә, ягъни мәсәлән... Пуф-пуф! Чуррррр... выжт! Төтен генә кала өрәкитәдән!.. Кыңх! *(Көлә.)*

Марчелло. Мунча кереп килдем әле. Пары затлы иде. Коры. Паяльный лампа белән сөзгәк үгез башын өткән шикелле өтте эссесе. Затлы, парин! Мунча үзебезнең янда гына... Очсызлы ягына кереп тә тормыйм. Анда гегемондыр, пенсионердыр кереп тулган була. Кыйбатлы-

сы шәп! Микробассейн бар... Иртә белән мунча керсәң, көне буе кеше булып йөрисең инде, парин!..

Рөсмин *(үз уеннан аерылмыйча гына)*. Шулай. Рабату дөрес әйтә... *(Сигаретын тирән итеп суыра.)*

Нәдирә. Рабату абый, Рабату абый! Тегене сөйлә инде... Тегене... Кайсысы дип... Ну... тегене инде... ни турында...

Камкәрим *(Рәшит Сабиров тавышы белән сөйли)*. Хәзер сезнең алдыгызда — Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның Питрәч районы Шәле авылының пачутлы әгъзасы, хәзер сез тыңлаячак юмористик хикәянең авторы... *(Үз фамилиясен әйтә.)*

Рөсмин. Шулай. Дөрес. Рабату дөрес әйтә...

Рабату. Аның өчен унбиш килограммнар чамасындагы бик шәп бәрән кирәк...

Марчелло. Ак вельвет чалбарны рижский кәнәфинең арка терәвеченә сындырып кына салып куйгач, финский софада төсле телевизор карап ятам шулай... Туктале, Ләбиб Леронның телевизоры ничегрәк күрсәтә микән, дип, ара-тирә төсләрне ак белән карага гына калдырып карыйм... *(Үз сүзләреннән үзе канәгать булып, рәхәтләнеп көлә)*.

Нәдирә. Рабату абый, сөйләгез инде тегене... Карагыз әле, тартмагыз әле, тартмагыз әле шул тәмәкегезне!

Рөсмин. Әйе, Рабату дөрес әйтә. Нәкъ шулай булды... *(Сигаретын бармаклары белән изеп сүндерә.)*

Камкәрим. Гөлшат апа белән Әгерҗегә барып кайттык. «Татарстаннан зур кунаклар килде»,— дип, безне зурлап каршы алдылар. Мин теге юморесканы сөйләп җибәрдем, малай! Күзгә генә карап утыралар... У-у-ух, малай!.. *(Кулын кулга суккалый.)*

Рабату. Башта койрык тирәсендәге шалтыравыкларны... кыҥх... *(Көлеп ала.)*... кыркып ташлыйсың...

Марчелло. Безнең авылда ярым мыеклы кеше бар. Һәрвакыт махмырдан булыр. Авыз читендәге селәгәе җеп шикелле асылынып тора. Менә шуның башкисәр энесе бар иде...

Рөсмин. Дөрес әйтә Рабату. Шулай. Нәкъ шулай булды...

Нәдирә. Тегене сөйлә инде, Рабату абый...

Камкәрим. Бер елны булдык без анда. Рифләр белән. Мин теге юморесканы сөйләп җиффәрүем булды... У-у-ух, малай!..

Рабату. Тире эченә сигез килолап итне саласың. Тозборыч, карлыган яфрагы, суган-сарымсак, әнисише үләннәрне әбизәтелне тутырасың инде. Тәменә карап...

Кыңх!.. *(Көлә.)* Шуннан тирене йон кертмичә генә тегә башлыйсың...

Марчелло. Мәскәүдә югары курсларда укыган чакта, Гәрәй белән икәү Миргазиян Юныс фатирына бардык. Башта шылтыраттык. Үзе генә икән. Хатыны каядыр, командировкадамы шунда, киткән иде. Ялгыз кешедә ризык әллә ни булмас дип, Гәрәй белән бер тавык кыздырып алып бардык. Миргазиян Юныс без килүне көтеп торган... Ә өстәлдә... җаның ни тели, шул бар! Кәптит ителгән тавыктан алып затлы кара икрага кадәр бар иде. Безнең мескен өтәләнгән тавыкның дәрәҗәсе шундук төште. Без аны пакет-сумкадан чыгарып тормаска булдык...

Шул вакыт бүлмәгә Вахтерша хатын килеп керә. Ул, Нәдирәгә караган килеш, Марчеллога таба атлый, аннан, Рөсмингә караган килеш, Камкәримгә якынлаша. Соңгысының колагына чумып диярлек эндәшә: «Вас к телефону!»

Камкәрим белән вахтерша хатын чыгып китә.

Рабату. Шуннан шундый да тәмле булып... чәп-чәп... ләм-ләм... *(Иреннәрен ялап, чапылдатып күрсәтә.)* ...телеңне йотарлык булып җитә бу. Кыңх! Шуннан соң ашап та күрсәтәсең инде... Великолепный ризык! Юныс Әхмәтҗанга өйрәткән идем шушы ризыкны. Ышанмады. Кстати, Юныс Әхмәтҗанның соңгы китабына минем өч-дүрт рецепт кергән. Ә монысына ышанмады. Исеме шәп, ә?! Чабан куырмасы! Үзем уйлап таптым...

Рөсмин *(уйлары белән һаман читтә)*. Әйе. Шулай. Рабату дөрес әйтә. Нәкъ шулай булды...

Марчелло. Писүк юк, дисез. Сез нәрсә, писүк ашыйсыз мәллә? Мин, мәсәлән, бал ашыйм. Иртән — бал, көндез — бал, кич — бал... Гарык булдым инде ул балдан... Хәзер вәринҗә белән генә мавыгып ятыш... Җир җиләгенеке белән... Затлы!

Нәдирә. Тәки сөйләмәдегез тегене, Рабату абый. Шундый кызык ие бит ул... Тәгәрәп көләрлек ие иде инде менә!

Бүлмәгә вахтерша хатын килеп керә.

Вахтерша хатын *(бүлмәдәгеләрнең барысына берьюлы карап)*. Кого-то из вас вызывают к телефону. Кого, не знаю.

Бүлмәдәгеләр барысы бергә чыгып китәләр.

Тәмам.

*1 ноябрь, 1987*

# Коммунист та кеше ләбаса

Талонга алган аракысын эзләп матавыкланганда, башлап язучы пенсионер Миңнулла Әптрәй партиягә керергә карар итте. Коммунистларныкына. Бу турыда үзе белән утыз ел гомер иткән хатыны Майбәдәргә әйткән иде, тегесе, базардан язгы сарык ите сайлаган хуҗабикә шикелле, озак кына карап торды. Ачылса ябылмый, ябылса ачылмый торган авызын шактый вакыт көйгә китералмый азапланды.

— Син нәрсә, карт җүләр,— диде ул, ниһаять.— Такмак укып, такмак яза торгач, алай-болай нитмәгәнсеңдер... алышынмагансыңдыр бит?

— Үз акылымда,— дип, кыска гына җавап кайтарды башлап язучы пенсионер Миңнулла Әптрәй.

— Соң... соң...— дип, беравык ни әйтергә белмичә торды Майбәдәр.— Соң... Кешеләр көтүе белән чыкканда, акылы булган адәм шунда керәме? Теге... ни... Җилсин дә шул партиядән чыкты түгелме соң? Телевизордан күрсәткәннәрие берчакны...

— Елсиндә минем эшем юк,— диде Миңнулла Әптрәй.— Минем иманым бар. Миндә шагыйрьләрдә генә була торган саф, керсез иман! Рәдиф Гатауллин әйтмешли:

Әйе, ялгышмыйсыз, «азат дөнья»дагы дуслар!
Без — коммунист.
...Бездә — коммунистик иман...

— Соң алайса, андый иманың да булгач, ник әллә кайчан кермәдең соң ул коммунистлыкка? — дип, янә сөаль бирде Майбәдәр.

— Ул чакта мин идейный яктан ныгымаган идем шул әле. Ышанычым да юк иде. Хәзер ышанычым бар. Роберт Миңнуллин әйтмешли:

Ышанабыз Ленин акылына —
Коммунистлар бит без,—
Ленindарлар!

— Әйтәм аны, такмакларыңны балалар гәҗите генә баса. Ышанычың алай бик зурдан булса, әнә талоннар, бар, буш кибеттән берәр ризык алып кайт. Мәскәү күренеп торган чәйдә сохари җебетеп утырмас идек, ичмасам.

— Чәпчемә, чәпчемә,— диде Миңнулла Әптрәй, үпкәчел тавыш белән. —Шигырь белән такмакны аермаган килеш ничек ышаныч турында сөйли аласыңдыр... син бит, ачуым бер килмәгәе, берни аңламыйсың, берни белмисең. Ә без, Әхмәт Рәшитов әйтмешли:

Без беләбез: Коммунист Таңга
Безне тик Ул әйдәп барасын...

— «Ул» дигәне кем инде аның? Гарбачуфмы? — диде Майбәдәр, картының берни белмисең, дигән сүзләренә печтек тә үпкәләмичә.

Миңнулла Әптрәй мондый сорауны көтмәгән иде. Шуңа күрә сүзне ул колак тирәсеннән генә үткәзеп җибәрде. «Ул»ның тәгаен кем икәнен белсә, һичшиксез, әйтәдер иде әйтүен.

— Гарбачуф дигәннән,— диде Майбәдәр,— ул да, мәйтәм, Җилсин шикелле, коммунистлыктан чыкса, кем генә калыр икән ул партиядә? Бер син калырсың микән сураеп?

— Мин һәм минем кебек инанган шагыйрьләр калачак! — дип катгый итеп әйтте башлап язучы пенсионер Миңнулла Әптрәй.— Чөнки Равил Фәйзуллин әйтмешли:

Без — мәрмәр!
Безгә — ныклык
Һәм Матурлык!
Безнең иман —
Коммунизм!

— Кай арада ятлап бетердең соң син боларны? — диде Майбәдәр.— Хәер, көне-төне китап, гәҗит-журнал укыйсың шул...

— Ятламадым мин аларны. Яхшы шигырьләр бер укуда хәтердә кала. Кояш кебек күңелне җылыта андый шигырьләр, барыр юлны яктырта. Җылыту-яктырту дигәннән, Рөстәм Мингалим юкка гына мондый шигъри юллар язмагандыр:

Яктыртасың җирне, җылытасың —
Коммунистмы әллә син, Кояш?

— Кибетләрдә бернәрсә дә юк. Бәлки, син коммунист булгач, дөньялар рәтләнеп китәр,— диде Майбәдәр.— Берәр могҗиза булып, кешечә яши башларбыз әле, Алла боерса...

— Әлбәттә, әлбәттә,— диде Миңнулла.— Фәннур Сафин әйтмешли:

Чын коммунист сыман борчылганда
Туар көннәр өчен һәр кеше,
Могҗизалар иҗат итә-итә,
Килмәсен соң кемнең яшисе?!

— Заманнар җүнле якка гына үзгәрсен иде инде берүк,— диде ни сәбәптәндер күңеле йомшарган Майбә-

дәр һәм бишбылтыр элек алган очсыз яулык читен күз төбенә китерде...

— Роберт Әхмәтҗанов әйтмешли, «Заман минем — коммунистик заман», шәт, шулай булгач, әйбәт булыр! — диде Миңнулла Әптрәй.

— Киләчәктә берүк ачлык кына булмасын инде,— диде Майбәдәр. Ул янә күз төпләрен сөртеп алды.

— Моңарчы без әллә нинди сират күперләрен кичтек. Сынатмадык! —диде Миңнулла Әптрәй.— Ренат Харис әйтмешли:

Без — коммунистлар — чыныккан халык,
яңа дәверне тудырган утта...
Без — коммунистлар! Безнең юл дөрес,
моңа инаныр җирдә бар кеше —
чөнки чор үз сәгате итте
коммунистларның йөрәк тибешен!

— Шулаен шулай да...— диюдән башка сүз әйтмәде Майбәдәр.

— Коммунистларның кулыннан килмәгән нәрсә юк! — диде Миңнулла Әптрәй.— Коммунист нәрсә теләсә — шул була. Башкорт язучысы Мостай Кәрим үзенең бер шигъри язмасында бу хакта менә болай ди:

Ул коммунист иде. Тыны белән
Туңган планетаны эретте...
Күкрәгендә, йөрәк янында ул
Йомарланган байрак йөретте.
Йөрәк тынды, башка типмәде,
Байрагын ул алып китмәде.

Белдеңме инде, карчык? Менә шулай. Мондый эшләрне бары тик коммунист кеше генә эшли ала. Нури Арслан әйтмешли:

Үрлибез биеккә — йолдызлар янына,
Юлыбыз бер генә — коммунизм ягына!
Бармы шул зур юлны үтәрлек батырлар?
Ленинча бергә без:
Андый көч бар! — дибез, —
Андый ПАРТИЯ бар!
Ул — Коммунистлар партиясе!

— Карт,— диде Майбәдәр,— коммунистларның бармаклары үзләренә таба кәкре була, дип сөйлиләр. Син коммунист булгач, өйгә аннан-моннан әйбер ташымассың инде, җәме?! Килешмәс ул безгә. Хәрам ризыксыз да яшәрбез әле.

— Хак сүз сөйлисең, карчык. Ләкин бер шагыйребез

әйткән сүзләрне онытмаска кирәк. Менә нәрсә ди ул: «Коммунист та кеше ләбаса!»

— Нишләптер башым авырта башлады әле,— диде Майбәдәр.— Әллә соң әптиктән берәр дару-фәлән алып кайтасыңмы?

— Соң үзең әйтеп тордың түгелме беркөнне,— диде Миңнулла Әптрәй,— әптиктә бернинди дару да юк, дидең. Ятып тор әнә. Яткач, хәлләнә ул.

— Шулай итәрмен, ахрысы,— диде Майбәдәр.

Миңнулла кинәт, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, әйтә куйды:

— Карале, карчык, дару дигәч искә төште: талонга алганның төбендә бераз калган иде бугай. Кая куйдың син аны?

— Кая булсын, урынында инде — суыткыч артында,— диде Майбәдәр. —Шешә төбе корыткачы, чират торып ипи алып кайтыр идең. Иртәгә җитмәве бар...

Ятакта башына сөлге чорнап яткан Майбәдәрнең соңгы сүзләрен ишетмәде Миңнулла Әптрәй. Чөнки ул «Мөдәррис Әгъләмов әйтмешли, Коммунистик сәнгать өчен! Коммунистик сәнгать өчен!» дия-дия, шешә төбендәгене кырлы стаканга агызу белән мәшгуль иде.

*9 декабрь, 1990*

# Мәтәштерү

...Узган гасыр ахырларында, күргән-ишеткәннәрен түкми-чәчми язарга күнеккән журналист халкы төгәллеге белән әйткәндә, әллә туксан бишенче, әллә туксан алтынчы елның җәй урталарында иҗади командировканы сылтау итеп, мин фәкыйрегезгә Ырынбур якларын иңләп кайтырга туры килгән иде. Ошбу якның табигатенә сокланып, кешеләре белән очрашудан биһушланып, халыкның көн-күрмешеннән, гореф-гадәтләреннән берникадәр хәбәрдар булып, биниһая тәэсирләр алып йөргән көннәрнең берсендә юлыбыз безне бер авылга китерде. Шунда мине Гыймади исемле туксан яшьләр чамасындагы бер карт белән таныштырдылар. Төс-кыяфәте, килешкилбәте белән татарның мәшһүр Мөдәррис Әгъләмгә тач охшаган (кем әйтмешли, суйган да каплаган инде менә!), хәтта ике каз янәшә оялап, алтын йомыркалар гына салып утырырлык йонлач кепкасын да Мөдәррисчә батырып кигән әлеге бабай бер-ике кәлимә сүз әйтүгә үк, мин аның гаять дәрәҗәдә җор телле кеше икәнлеген абайлап алдым.

— Казаныгызда һаман Галиябануны мәтәштереп ятасызмы? — диде Гыймади агай, үзара хәл-әхвәл алышкач.

Минем берни аңламыйча торуымны шәйләп, юлдашларымнан берсе —шушы авыл кешесе — картның соравына ачыклык кертәсе итте:

— «Галиябану» спектакле турында әйтә ул. Шуны һаман театрда уйныйлармы әле, диюе...

— Тикмәгә кызыксына дип уйлама,— диде икенче юлдашым.— Ул спектакльне караган булсаң, хәтерлисеңдер: катнашучылар арасында Гыймади исемле малай да бар. Күренеп кенә ала ул. Мирхәйдәр Фәйзи аннан бер-ике сүз әйттерә дә ат җигәргә чыгарып җибәрә. Белмәсәң бел: ул малай хәзер синең каршыңдагы Гыймади бабай үзе була инде!

Йа Хода!

Халыкны тетрәткән, зар елаткан фаҗигале Мәхәббәтнең тере шаһиты белән көтмәгәндә очрашып, гәпләшеп торам түгелме соң мин?!

— Мирхәйдәр Фәйзи мәтәштергән... Купайтып күрсәткән... ахыры бөтенләй җалган... Исмәгыйль абый булмады анда...— дип, үзалдында сөйләнгәндәй әйтеп куйды Гыймади ага.

— Ничек Исмәгыйль булмасын инде? Хәлилгә револьвердан ул ата бит?! — дип, сәерсенүле, кызыксынулы карашымны картка төбәдем.

— Ырвалбирдан да атучы булмады...

— Һе! Кыз-ык... Хәлил ничек үлде соң, алайса?

— Үлмәде ул. Исәнгерәде генә.

— Менә сиңа мә, иске авыздан яңа сүз! Хәлил спектакльдә үлә бит!

Гыймади карт «Син аңгыра мәллә!» дигән төсле карап алды да, төксе генә итеп:

— Әйттем бит инде... Мирхәйдәр Фәйзи мәтәштергән! — диде.

Юлдашларым минем янә сәерсенеп торуымны күреп:

— Син Гыймади агайның сөйләп бетергәнен көт. Без йөз мәртәбә тыңладык инде. Тыңлаган саен тыңлыйсы килә...— диделәр дә үзара көлешеп алдылар.

— Гаҗ-әп... Исмәгыйль булмаган, револьвердан атмаганнар, Хәлил үлмәгән...— Мин төртмәле сорау бирәсе иттем: — Хет Галиябану бар идеме соң ул фаҗига буласы кичтә?

Гыймади агай ашыкмый гына сигарет кабызды:

— Галиябану түгел, Сәгадәтбану исемле иде ул. Мирхәйдәр Фәйзи мәтәштергән. Җырларга җайлы булсынга

үзгәрткән... «Сәгадәтбану, сылуым-иркәм...» дип тә мәтәштереп була югыйсә...

Моңарчы картның әйткәннәренә ышанмыйчарак тора идем, бу да Мөдәррис Әгъләм шикелле борчак сибәргә ярата, үз әкиятенә үзе ышана, ахрысы, дип уйладым. Әмма ул Галиябануны Сәгадәтбану диюе белән минем күңелемә туплана төшкән шик-шөбһәләр өерен таратты да ташлады.

— Тәки ышандыра башладың бит, Гыймади агай... Билләһи-валлаһи, әлегә кадәр һич кенә дә ышанасым килми тора иде,— диюдән башка чарам калмады.

— Кесәмдә булмаган акчамны биреп кенә ышандыра алмыйм инде, кем, энем,— дип, тәмәке сарысы сеңгән аксыл мыек чылгыен бөтереп алды карт. —Үз күзләрем белән күргәннәремне генә сөйлим... И-и, ул мин күргән-белгәннәр!.. Сөйләсәм — сөйләп, язсам язып бетерерлек түгел... Әтәй мәрхүм гел әйтә торганые: «Яз, улым, яз. Талыстуй кебек зур язучы булырсың!» — дия торганые... Язсам, Мирхәйдәр Фәйзи ише генә мәтәштермидерием инде, анысы...

Мин, аның сүз сөрешен бер эздән генә юнәлтергә теләп:

— Гыймади агай, беләсе иде, Хәлил-Галиябану-Исмәгыйль вакыйгасының ахыры чынлыкта ничек бетте? — дидем.

— Мин ул кичне печ итәргә чыкканыем...— Гыймади карт янә сигарет кабызды. Төтенне ләззәтләнеп суырганнан соң, үпкәсендә бераз тотты да, иренеп кенә кире чыгарды.— Инде печ итеп бетердем дигәндә генә...

Ул сөйләгәннәрдән чыгып, әлеге күренешне мин болайрак күз алдына китердем...

...Кич. Бәдри абзыйларның ишегалды. Күрше ихата белән чиктәш койма. Койманың теге ягында Гыймадиның кече йомышын йомышлап торганы шәйләнә. Шулчак аяк тавышлары ишетелә. Як-ягына каранып, Хәлил керә. Гыймади, иелә төшеп, койма ярыгыннан күзәтә. Коймага елыша-елыша өй тарафына атлаганда, Хәлил нәрсәгәдер абынып егыла.

Хәлил. Яффаймайт!

Хәлилнең ачудан ярым пышылдап, ярым кычкырып әйткән тавышын ишетеп, Галиябану ачык тәрәзәдән башын чыгара.

Галиябану. Кем бар анда?

Хәлил. Бу мин... Хәлил! Кеше-кара күргәнче чык җәтрәк!

Галиябану *(чыгарга азаплана)*. Булышыр идең, ичмасам!

Х ә л и л. Чыгып торсаң ни була.

Г а л и я б а н у. Килмәссең дип уйладым... Ай, кытыгым килә! Ипләбрәк кылан.

Х ә л и л. Нәрсә состың соң шулкадәр? Тәрәзәгә дә сыймыйсың...

Г а л и я б а н у. Әни бишбармак пешергән иде.

Х ә л и л. Ишектән чыгып карыйсың мәллә?

Г а л и я б а н у. Шулай итмичә бул...

Галиябану сүзен әйтеп бетерергә өлгермичә кала. Гыймадиның кинәт төчкергәне ишетелә. Галиябану түенчеге-ние белән ишегалды ягына мәтәлеп төшә.

Х ә л и л *(курка калып)*. Исмәгыйль?!

Г а л и я б а н у *(нигәдер сөенгәндәй)*. Исмәгыйль!

Х ә л и л. Нишләп Исмәгыйль булсын. Акбай төчкерде бугай... Әйдә, киттек. Ат әзер тора анда.

Г а л и я б а н у *(тирә-ягына каранып)*. Бераз... көтик әле...

Х ә л и л *(ачуы килеп)*. Кемне? Исмәгыйльнеме?

Г а л и я б а н у. Караңгы төшкәнне көтик, дим...

Х ә л и л. Моннан да ары караңгы булмый инде. Киттек, Сәгадәтбану!

Г а л ә ү керә.

Г а л ә ү. Китми генә торыгыз әле!

Г а л и я б а н у *(ни сөенергә, ни көенергә белмичә)*. Галәү?!

Х ә л и л *(җиргә черт итеп төкерә)*. Борчак бүксәсе?! Ни калган монда Исмәгыйль ялчысына?

Г а л ә ү *(Хәлилгә)*. Көндез булдыралмагач, кич урлыйм дисең, ә?

Х ә л и л. Кит юлдан! Исмәгыйль кайда?

Г а л ә ү. Мин аның урынына!

Г а л и я б а н у *(елмая төшеп)*. Исмәгыйль... абый... үзе килмәдемени?

Х ә л и л *(Галиябануга сәерсенеп карый)*. Син нәрсә, Сәгадәтбану... Нишләп ул хайван сиңа абый булсын!

Г а л и я б а н у. Мин болай гына... Ялгыш әйттем. Миннән өлкән булганга күрә...

Г а л ә ү. Киттек, Сәгадәтбану!

Х ә л и л. Нәрсә? Ни дидең, борчак бүксәсе? Яле, тагын кабатлале!

Г а л и я б а н у. Зинһар, Хәлил, кызмыйча гына...

Г а л ә ү. Киттек, Сәгадәтбану, сылуым-иркәм...

Х ә л и л. Аһ, мин сине хәзер... Мин сине... Он итәм хәзер... Исмәгыйль олтаны!..

Г а л ә ү *(башын югары чөеп)*. Егетләрнең солтаны!
Г а л и я б а н у. Хәлил, кирәкми берүк!

Хәлил белән Галәү әүмәкләшә башлыйлар. Галәү, җаен туры китереп, кесәсеннән револьвер чыгара.

Г а л и я б а н у. Аһ!
Х ә л и л *(курка калып)*. Исмәгыйльнең ырвалбиры?!
Г а л ә ү. Әйе. Үзе бирде. «Ул хәерче Хәлилне атып үтереп черисем юк әле» диде... Хәзер мин сине атам!
Х ә л и л *(кинәт батыраеп)*. Ат, әйдә, ат!
Г а л ә ү. Әйтергә онытып торам икән әле. Исмәгыйль абый әйтте: «Сәгадәтбану да, туасы баласы да үзеңә булсын!» — диде. Менәтерәк!
Г а л и я б а н у. Хараплар булдым... *(Аңын югалтып егыла.)*
Х ә л и л *(ялгыш ишеттем мәллә дигәндәй, әле Галәүгә, әле аңсыз яткан Галиябануга карый)*. Ә?
Г а л ә ү. Кәҗәгә — кәбестә, миңа бирнәле Сәгадәтбану!
Х ә л и л. Әле син шулаймы? *(Пәке чыгара.)* Чәнчим мин сине, суям! Үземне дә харап итәм...

Хәлил адарынып-ярсып Галәүгә таба килә. Шул вакыт шарт иткән тавыш яңгырый. Хәлил, өнсез-телсез булып беравык басып торганнан соң, гөрселдәп җиргә ава. Галәү, бер кулы белән чалбарының арткы өлешен капшаштырып, икенчесе белән револьверын әйләндергәләп, аптырап тора.

Г а л ә ү. Исмәгыйль абый револьвер корылмаган, дигән иде бит! Нәрсә инде бу? *(Кинәт борынын җыерып иснәнә.)* Әллә... (*Янә чалбарының арткы өлешен тотып карый.)* Фу! Нәгаләт, борчак боткасы... *(Кабаланып чыгып китә.)*

Өйдән Бәдри белән Галимәбану чыга.

Б ә д р и
Г а л и м ә б а н у } *(икесе бергә)*. Аһ! Кем атты?

Койманың теге ягыннан Гыймадиның башы күренә.

Г ы й м а д и *(кинәт тыела алмыйча көлә башлый)*. Борчак Галәү... артын тоталмыйча... пыртлатты!
Б ә д р и белән Г а л и м ә б а н у *(Гыймадиның ни әйткәнен аңлап җиткермичә)*. Аһ, хараплар иткән икән балакайларны...

...Гыймади агай, сөйләвеннән туктап, тынып калды. Мин көләргәме-көлмәскәме, ышаныргамы-ышанмаскамы,

дип торганда, юлдашларым икесе тиң пырхылдап көләргә тотынды. Алар көлүдән туктагач, карт, мыек астыннан гына елмайгандай итеп:

— Сине хәзер аларның шуннан соңгы язмышлары кызыксындырадыр инде? — диде.

— Әйе шул,— дидем мин, гайре ни әйтергә дә белмичә.

— Хәлил абый шул кичтән соң гелән-гелән алышына торган булып калды. Кулына ырвалбирга охшаган берәр нәрсә тоткан кеше күрүгә, шундук аңын югалтып җыгыладырые, мескен. Аңына килгәч, сабый бала шикелле акырып җыларые. Гомере буе эшләде инде үзе — Исмәгыйль абыйда батрак булды. Үзен ашаткан-эчерткән өчен, кием-фәлән белән ярдәм иткән өчен Исмәгыйль абыйга гел рәхмәтле иде, мәрхүм...

— Галиябану белән... тфү лә... Сәгадәтбану белән тигез гомер иткәннәрдер инде?

— Сәгадәтбану Хәлилгә чыкмады. Тегесе дә алам димәде бугай.

— Сәгадәт корсаклы булганга күрәдер инде?

— Җу-ук... Исмәгыйль абый нишләп андый эшкә барсын. Борчак Галәү җүри әйткән булган... Сәгадәтбануны үзенә хатын итәсе килеп...

— Алайса, Галәүгә чыккан инде Сәгадәтбану?

— Сәгадәтбану кияүгә чыкты чыгуын... Вәләкин башка берәүгә. Күрше авыл урысына. Мәңге исерек Митрәйгә. Җаманатың чыкса, маймулны да кияү итәрсең... шуннан шул, туп-туры пашшул... Галәү шул җылның көзендә борчак күп ашаудан күбенеп үлде. И-и, борчакны бигрәкләр дә үлеп җаратадырые, мәрхүм... Утырып торса да, җатса да, арт ягы бер генә дә җал белмәде инде...

— Исмәгыйль абый ничек? Аның язмышы ничек булды?

— Ул күптән мәрхүм инде... Ә-әнәү теге ташпулатны күрәсеңме? Исмәгыйль абыйныкы ул. Хәзер фирмир оныгы яшәп ята. Сез генә очрап, юлымны бүлдегез. Минем шунда барышымые... Үзләре җукта күз-колак булырга кирәк бит. Аннары, мәйлек белән чәйлек тә тия дигәндәй...

Гыймади карт, безнең белән саубуллашты да, яшьләргә хас адымнар белән, керт-керт атлап китеп барды...

# Саклык кассасы

Борын-борын бервакыт Фаил Шәфигуллинның, Зөлфәтнең һәм Зиннур Гыйбадуллинның кайсыдыр бер районда очрашулар уздырып, шигырь-хикәя сөйләп, гармун уйнап йөрешләре икән.

Бүген бер авылда очрашу, иртәгә — икенчесендә. Кичә, гадәттә, кич, клубта була. Аңарчы юлдашлар фатирга урнашып, тамак ялгап ала. Очрашуга кадәр вакыт байтак — бераз ял итеп, черем итеп алсаң да ярый. Ләкин кая ул черем итү! Берсе күзләрен йомып, борынын мендәргә чумдыруга, тотына калган икәү мәзәк сөйләргә! Үз башларыннан кичкән хәлләр хакында борчак сибәргә...

Тормас җиреңнән торырсың, кушылмас җиреңнән кушылырсың сүзгә. Аеруча Зөлфәт белән Фаил сибә борчакны. Зиннур Гыйбадулла да: «Егетләр...» дип, шомарып, бүтән мәңге үзгәрмәс хәлгә килгән мәзәген туксан беренче мәртәбә сөйләп карамакчы булып карый — ләкин юк, тегеләр ирек бирми.

Ниһаять, Фаил белән Зөлфәт сөйләүдән туктый. Сөйләргә чираты җиткән Зиннур Гыйбадулла тыңларлык та хәлләре калмаган шагыйрьләргә карап ала да уфтанулы тавыш белән сөйли башлый:

— Егетләр... Бервакыт бер тәңкә югалткан идем... Әйе... Карале, тыңлагыз әле... Шуны эзләмәгән җир калмады... Берсе бер атна эчкәндер инде... тапкач... Әйе...

Шул югалган бер тәңкәне берничә мәртәбә сагынып искә алгач, Зиннур Гыйбадулла акчаны саклап йөрү хакында сөйләргә кереште.

— Минем саклык кассам үзем белән! — ди.

Зөлфәт тә, Фаил дә инде күптән мес-мес йоклый. Зиннур Гыйбадулла, алар күзләрен йомган килеш тыңлап яталар дип уйлап, һаман сөйли:

— Кала ыштанына шәп итеп кесә тектем дә... Әйе... Полиэтилен капчыкка акчаны төреп шул кесәмә салам да... егетләр... булавка белән каптырып куям... Эт тә белми, берәү дә сизми. Әйе... Югалмый да, урламыйлар да...

Ике шагыйрьнең берсе гырлау стадиясенә җиткәч кенә Гыйбадулла сөйләүдән туктый...

Иртән — янә икенче авылга. Бу авылның бик шәп буасы бар икән. Ерак та түгел, ди. Юлдашларның кичәге очрашулары озаккарак сузылган, ахры, алар ара-тирә башларын тотып алалар, уфылдап куялар. Кичәгә кадәр су коенып кайтсак, шәп булыр иде кана, диләр...

Буаның куаклы-камышлы тирәсенә килеп туктыйлар

болар. Зөлфәт күлмәк сәдәпләрен ычкындырып, Фаил чалбарын салып азапланган вакытта, кичә халыкны «иртәгә язган яңа көемне уйныйм» дип көлдергән Гыйбадулла, кала ыштаныннан гына калып, яр читенә килеп баса.

Менә ул:

— Егетләр... әйбәт суы... бугай моның! — ди дә, чирканчык та алып тормыйча, баян хәтле гәүдәсен суга ыргыта.

Һәм... шампан бөкесе шикелле, кире атылып та чыга Гыйбадулла. Атылып та чыга, кала ыштанын куллары белән сәер тотып, куаклык артына элдерә дә.

— Нәрсә булган бу Гыйбад тәрегә? — ди Зөлфәт, чалбарын сала-сала.

— Кичә алай артык та нитмәгән иде бугай,— ди Фаил. Шул вакыт кош тоткандай сөенгән Гыйбадулла куак артыннан чыга. Бер кулында полиэтилен капчык җилферди, икенчесендә — кәгазь акчалар...

— Егетләр... Юешләнмәгән...— ди ул берни аңламыйча торган Фаил белән Зөлфәткә.

# Вакыйфның күргәннәре

Яшь журналист Вакыйф Нуриев үз гомерендә бер барды Мамадышка, әмма берәгәйле бармады...

Вакыйфның «Яшь ленинчы» гәҗитендә эшләгән вакыты. Беркөнне гәҗитнең баш мөхәррире Роза Туфитулова аңа:

— Мамадышка барып кайтырсың әле. Нишләптер быел «Яшь ленинчы»га аз язылганнар. Бер уңайдан гәҗиткә материаллар да тупларсың,— ди...

Вакыйф, командировка өчен кирәкле кәгазьләрне, юллык акча мәсьәләсен хәл кылгач, Мамадышка, комсомолның район комитетына шылтырата:

— Мин Вакыйф Нуриев булам. Казаннан. «Яшь ленинчы»дан! — ди Вакыйф Нуриев, Мамадышта кемнеңдер телефон трубкасын алып, тавышын бөердән чыгарырга тырышып: «Алло, райком комсомола слушает...» — дигән сүзләрне ишеткәч.— Фәлән көнне фәлән сәгатьтә автобус белән Мамадышта булам. Кунакханәгә заказ биреп куймассызмы...

...Килеп төшә Вакыйф Нуриев Мамадышка. Килеп баса моның янына кыяфәтле генә берәү.

— Казаннан килүче язучы сез буласызмы? — дип сорый ул Вакыйфтан, әдәпле вә итагатьле итеп.

— Әйе, мин булам,— ди Вакыйф, үзен язучы дигәнгә күңеле булып.

«Яшь ленинчы»да балалар өчен ике шаян хикәячек бастырганымны каян белеп торалар болар?» — дип гаҗәпләнә Вакыйф, язучы дигән сүздән һаман айный алмыйча...

Вакыйфны үзендә мәлҗерәтеп кенә алып барган ак «Волга» партиянең район комитеты ишек төбенә выжлап килеп туктый.

Инструкторлар, төрле йомышчылардыр инде — тыз да быз киләләр.

— Арыгансыздыр инде, Вакыйф Нуруллович,— ди шактый өлкән күренгән бер агай.— Хәзер тамак ялгап алырбыз!

«Вакыйф Вәкилович мин» дип төзәттерәсе килсә дә, Вакыйф:

— Вакыйф кына дисәгез дә ярый,— дип өстәп куя...

Торгынлык заманы. Ашарга мул чак. Эчәргә җитәрлек. «Күпме районда булган бар, мондый кадер-хөрмәтне беренче күрүем. Кунакчыл икән мамадышлылар!» — дип уйлый Вакыйф, итле бәлешнең каз мае сеңгән камырын тәмләп чәйни-чәйни...

Тамак ялгагач (алай дип әйтү генә гөнаһ булыр), баягы сүзчән агай:

— Маршрутларны ачыклыйк әле, Вакыйф Нуруллович,— ди.— Менә алдынгы колхозлар исемлеге... Кайсысына барырга телисез?

Вакыйф, «Нуруллович»ны төзәттереп торуны кирәк санамыйча гына:

— Берәр мәктәпкә барырга иде,— ди.

— Була ул, эшлибез аны, Вакыйф Нуруллович,— ди сүзчән агай...

Мәктәпкә килеп төшсәләр...

Алдагысы бала гына булган икән, менә кайда икән анасы! Берсеннән-берсе матур балалар тезелеп басканнар ишегалдына: берничәсенең кулында аллы-гөлле чәчәкләр, берсе ипи-тоз күтәргән...

Мәктәпнең концерт залы дигән җиренә кергәч кенә Вакыйфның башына нидер барып җитә башлый: бер озын өстәлгә тезгәннәр Вакыйф Нуруллинның төрле елларда чыккан дистәләгән китапларын!

Менә бер укучы бала чатнатып:

— Сезнең без яратып укый торган «Әгәр син булмасаң...» дигән китабыгыздан бер өзек сөйлим! — ди.

Йөзе әлеге баланың пионер галстугы кебек алсулан-

ган Вакыйф «Кай арада ятлап өлгергән бу бала» дип уйларга өлгерми, икенче укучы чәчрәп чыга:

— Мин хәзер хөрмәтле язучыбыз Вакыйф абый Нуруллинның «Шинельсез солдатлар»ыннан бер өзек укыйм,— ди...

«Мин бит Вакыйф Нуруллин түгел! Бу — аңлашылмаучылык!» — дип әйтергә уйлый Вакыйф «Нуруллович», ләкин теле әйләнми...

«Ахыргача түзәргә дә бүген, нинди автобус белән булса да, Казанга таярга!» — дигән ныклы фикергә килә Вакыйф...

Мәктәптән китеп барыр алдыннан гына өлкән яшьләрдәге бер укытучы ханым туктата да:

— Вакыйф Нуруллович, хатыныгызга миннән сәлам тапшырыгыз! — ди.— Без аның белән кайчандыр бергә укыган идек...

— Ярый, ярый, тапшырырмын,— дип, авыз эчендә ботка пешереп ала Вакыйф. Аның бу газаптан ничек тә тизрәк ычкынасы килә... Юлда үзен озатып йөргән агайларга әйтә Вакыйф:

— Иптәшләр,— ди,— мөһим эшем барлыгы искә төште. Миңа кичекмәстән Казанга китәргә кирәк! — ди.— Автобуска өлгерәсе иде! — ди...

Кичке мәҗлес турында уйлап, тантаналы изрәп барган юлдашлар, Вакыйфның әлеге сүзләрен ишеткәч, аптырап калалар, билгеле.

— Сез нәрсә, Вакыйф Нуруллович,— диләр,— эш качмый ул, Вакыйф Нуруллович! — диләр...

Вакыйф «Нуруллович»ның сүзе сүз: «Ачуланмагыз, иптәшләр, сый-хөрмәтегез өчен рәхмәт, иптәшләр, гаеп итмәгез, иптәшләр, китәргә кирәк, иптәшләр... Икенче вакытны...»

Шуннан соң нәүмизләнеп калган агайлар:

— «Волга» белән илтеп куябыз сезне, Вакыйф Нуруллович, Казанга чаклы,— диләр.

— Иптәшләр...— ди Вакыйф...

Шул көнне кич автобус белән, арып-талып, эштән чыгып кайтып төшкән ди Вакыйф Казанга...

*1990*

# Ленин... тирләгән маңгаен сөртә

Камал театрының иске бинасында (хәзер анда Тинчурин театры урнашкан) Н.Погодинның «Баһадирлар» дигән пьесасын сәхнәгә куярга әзерләнгән чак.

Соңгы генераль репетиция бара. Сәхнәдә — шабыр тиргә баткан артистлар, залда спектакльне кабул итү-итмәүне хәл кылырга тиешле комиссия әгъзалары. Әгъзалар арасында Мәскәүдән килгән яһүд режиссеры — Ленин ролен башкаручылар буенча белгеч тә бар. Спектакльнең алдагы күренешләре тоткарлыксыз үтә. Ә менә Ленинның нотык сөйләве өлешенә җиткәч, хәлләр кисkенләшә. Мәскәүдән килгән белгечкә Шәүкәт Биктимеров-Ленинның нотык сөйләгән чакта үзен тотышы нигәдер ошап бетми генә бит.

Бер кабатлыйлар әлеге күренешне, ике кабатлыйлар...

— Извините! Еще раз повторим, товарищ артист! Пожалуйста! — ди белгеч.

Биктимеров-Ленин кулындагы йомарланган кепкасы белән маңгай тирен сөртеп ала. Бераздан кепка тоткан кулын алга — зал ишегенә таба сузып, Ленин тавышы белән болай ди:

— Иптәшләг! А-ыгансыздыг! Ба-ыгыз! Ба-ыгыз Кекинга[1]! А-ыгыз бег ягты! Са-ыгыз! Безнең эш җиңәчәк!

Сәхнәдәге артистлар да, спектакльне куючы режиссерлар да өнсез булып катып кала. Татарчаны «ипи-тозлык»та белмәгән Мәскәү кунагы, кояштай балкып, урыныннан сикереп тора да кул чаба-чаба:

— Наконец! — ди.— Отлично! Как настоящий Ленин говорил! — ди.— Большое спасибо! Спектакль принят! — ди...

Катып калганнарның тезләре йомшара, җиңел сулап куялар.

«Ленин», канәгать елмаеп, тирләгән маңгаен кулындагы дымсу кепкасы белән сөртеп ала.

*1990 ел*

[1] Кекин — театр бинасыннан ерак түгел генә урнашкан кибет.

# Нарасый бәһасе

Балалар шагыйре Рафис Корбан китап кибетенә еш сугылырга ярата. Кергән саен буш кул белән чыкмый: танылган һәм танылмаган шагыйрьләрнең балалар өчен дөнья күргән шигырь вә такмак китапчыкларын букчасына тутыра.

Өенә кайткач, язгы кара сарык тиресе җәелгән йомшак кәнәфиенә чүмәшеп, кызын алдына утыртып, әлеге китаплардагы шигъри такмакларны радиодагы «Таныш моңнар» тапшыруында яңгыраган дәртле тавышы белән кычкырып укый.

Күпсанлы вә акчалы бүләк алган шагыйрьләрнең һәрбер такмагын укыган саен, Рафис Корбан, кызына тантаналы елмаеп:

— Пүчтәк бит, әйеме, кызым? — ди.

Әтисенең һәр сүзен җөпләргә иялэнгән нарасый:

— Пүчтәк, әтием, пүчтәк! — ди.

Рафис Корбан, канәгать елмаеп, башка такмакны укый. Сорау-җавап әүвәлгечә:

— Пүчтәк бит, әйеме, кызым?

— Пүчтәк, әтием, пүчтәк!

Шигырь-такмаклар укылып беткәч, Рафис Корбан иҗат бүлмәсенә кереп бикләнә дә, илһамланып, яңа шигырен яза башлый.

Бераздан ул табадан гына төшкән шигыре язылган кәгазьне тотып, талонга 250 грамм чамасы затлы кәнфит алган кешедәй сөенеп, кызына әсәрен укый.

— Шәп бит, кызым, ә? — ди Рафис Корбан, очлы иягеn муен чокырына батырып.

Һәрвакыттагыча бер үк җавап бирергә гадәтләнгән нарасый йокылы тавышы белән:

— Пүчтәк, әтием, пүчтәк! — ди...

*12 сентябрь, 1991*

# Кабарган букча

Борын-борын бервакыт язучы Солтан Шәмси шәмдәлләрдә шәмнәр янган дәвер турында чираттагы хикәясен язып утыра икән. Кинәт кыңгырау чылтыраган. Солтан, язуыннан бүлдергән кешегә яман ачуы килеп, каударланып ишек ачкан.

— Гафу итегез,— дигән ишек төбендә кулына таушалып беткән, юка күн букча тоткан бер ямьшәйгән эшлә-

пәле адәм.— Мин электрик булам. Подъезддагы электр чыбыкларын карап йөрешем. Буем җитми, бер урындык бирен тормассыз микән?

Ачуы сүрелә төшкән Солтан:

— Пажалысты,— дигән, һәм урындык чыгарып тоттырган моңа.

Вакытсыз өзелгән хикәяне ялгаучы мөһим җөмләне кәгазьгә төшерәм генә дигәндә, янә кыңгырау чылтыраган.

— Борчыган өчен гафу итегез. Барысы да тәртиптә икән,— дигән «ямьшәйгән эшләпә» һәм Солтанга урындыгын биргән.— Бик зур рәхмәт!

— Пажалысты! — дигән Солтан.

«Ямьшәйгән эшләпә» кабарынган күн букчасын уң кулыннан сул кулына күчереп:

— Сезгә алай-болай лампочкалар кирәкмиме? Миндә запас лампочкалар бар иде,— дигән.

— Юк, юк, рәхмәт, кирәкми! — дигән Солтан.

— Бигайбә, алайса. Сау булыгыз! — дигән «ямьшәйгән эшләпә».

— Сау булыгыз! — дигән Солтан...

Менә берзаман тәрәзәдән караңгылык иңә башлаган. Хикәянең соңгы ноктасын куюга, Солтан өендә ипи юклыгын исенә төшергән.

Хуҗалык сумкасын алып подъездга чыгуга, дөм караңгылык килеп бәрелгән. «Утны кабызырга кирәк!» — дип уйлаган Солтан. Ут кабызгычны чамалап эзләп табып, төймәсенә чырт-чырт баскалаган, әмма ут кабынмаган. Дүртенче һәм өченче каттагы ут кабызгычларны да чыртлатып караган Солтан Шәмси — юк, кабынмаган.

«Соң, кичә генә үзем һәрбер каттагы лампочкаларны алыштырып, яңаларын куеп чыктым лабаса»...— дип гаҗәпләнгән Солтан.

Әллә...

Шунда гына Солтанның башына барып җиткән:

— Аңлашылды,— дигән ул үз-үзенә.— Аңлашылды... Теге «электрик»тан үземнең лампочкаларымны сатып аласым калган аны...

*19 сентябрь, 1991*

# Шәмсия

Борын-борын бервакыт мәшһүр җырчы Илһам Шакирның кайсыдыр каладамы, әллә саладамы (мөһим түгел) гастрольдә чагы икән.

Концерт тәмамлануга, сәхнә артына чырайларына «байлар төсе» кунган берничә хуҗа кергән.

— Бер сөйләшү — үзе бер гомер! — дип, Илһам Шакирны вә аның юлдашларын әзер мәҗлескә чакырган болар.

«Ашап-эчеп алу зыян итмәс иде!» — дигән артистлар да, Илһам Шакирның һәрбер сүзеннән кытык-кытык көлгән юан-юан корсаклы хуҗалар да машиналарга чыгып утырган. Үрдәк бәбкәләре кебек тезелгән җиңел машиналар дәррәү кузгалыр алдыннан гына Илһам Шакир нидер исенә төшергән.

— Җегетләр! Шәмсия онытылып калды! Сәхнә артыннан алып чыгыгыз әле шуны! — дигән ул юан корсакларның әле берсенә, әле икенчесенә карап.

Хуҗаларның яшьрәге, корсагы җитлеккән бройлер тавык чаклысы, җәһәт кенә урыныннан кузгалган да «ә» дигәнче тәгәрәп юкка чыккан.

Биш минут көткәннәр моны, ун минут көткәннәр...

Берзаман шабыр тиргә баткан «бройлер тавык» Илһам Шакир янына тәгәрәп килеп тә җиткән.

— Эзләмәгән җир калмады, Илһам абый. Юк, беркайда да юк! — дигән ул, байлар төсе качкан чыраендагы тимгел-тимгел тир тамчыларын кул аркасы белән сыпыргалап.

— Соң... Шунда, урындыкта гына иде бит! — дигән Илһам Шакир.

— Юк инде, Илһам абый, юк. Җыештыручы Сәрмәдияттәйдән гайре бер хатын-кыз да юк!

— Мин сиңа хатын-кыз эзләргә кушмадым бит, энекәем,— дигән Илһам Шакир.— Мин сиңа шәмсияне табып алып чыгарга куштым. Шәмсия, дим, шәмсия! Кулчатыр!

— Кулчатыр дигәне кем... нәрсә инде аның, Илһам абый? — дигән «бройлер тавык», бушый төшкән чалбарын күтәребрәк.

— Сезнеңчә... зонтик буладыр инде ул, апаем! — дигән Илһам Шакир.

Сабыйларча сөенгән бәләкәй корсаклы хуҗа:

— Башта ук шулай дип әйтәләр аны, Илһам абый! — дигән дә, җәһәт кенә тәгәрәп, янә шәмсияне эзләргә кереп киткән, ди...

*25 ноябрь, 1991*

# «Әйе» сүзе күпме тора?

Совет кинофильмнарындагы патроны бетмәс автомат кебек берөзлексез такылдаган Айдар Үтәгәннең нәрсә сөйләгәнен татар дөньясында шагыйрь Зөлфәт кенә шәрехли ала.

Көн саен кемнәндер ишеткән мәзәген сөйли Айдар Үтәгән. Зөлфәт үз янында булмаган вакытта бер ун мәртәбә сөйли. Дөресрәге, сөйләттерәләр. Мәзәкнең ни турында икәнен унынчы мәртәбә тыңлагач кына аңлагач, тыңлаучылар дәррәү көләләр. Хәер, әллә аңлап көләләр, әллә юк — әйтүе кыен.

Менә шул мәшһүр мәзәкче, тел бистәсе Айдар Үтәгәнне бервакыт телевидениегә — «Ялкын» журналы — бездә кунакта» дигән тапшыруга (Айдар Үтәгәннең ошбу журналда эшләгән чагы) чакыралар. Телевидение режиссеры Идмас Үтәгән (Айдарның туган абыйсы) Айдарны күрү белән әйтә:

— Синең өчен Тавил Хаҗиәхмәт сөйләр. Кирәк вакытта син «әйе» дип әйтерсең, әйтә алмасаң, башыңны кагып куйсаң да ярый,— ди.

«Инструкция» беткәч, тапшыру башлана. Тавил Хаҗиәхмәт алдындагы балалар сурәтләрен күрсәтә-күрсәтә сөйли:

— Балалар, сезнең бу рәсемнәр «Ялкын» журналы редакциясенә килгәч, турыдан-туры Айдар абыегыз кулына килеп ирешә. Шулай бит, Айдар?

Тапшыруга бәйрәм вакытында гына тага торган затлы галстугын тагып, пөхтә кәчтүмнәрен киеп, чәчләрен чит ил шампуне белән генә юып килгән Айдар Үтәгән:

— Ие,— дип куя.

Тавил Хаҗиәхмәт янә сөйли:

— Шул рәсемнәр арасыннан иң матурларын, иң уңышлыларын сайлап алгач, Айдар абыегыз аларны журналга тәкъдим итә. Шулай бит, Айдар?

Айдар, вәкарь белән генә:

— Ие,— ди...

Тапшыру бетеп, атна-ун көн узгач, Айдар Үтәгән исеменә элемтә бүлегеннән акча килеп алуны сорап язылган кәгазь килә. Ике тапкыр «ие» дигән өчен җиде сум илле тиен!

Торгынлык чорында шулкадәр акча алганга сөенгән Айдар Үтәгән телевидениегә янә чакыруларын түземсезләнеп көтә. «Ие» диеп күбрәк әйтәсем калган аны»,— дип йоклаганда да саташып чыга...

Гөнаһ шомлыгына каршы, телевидениегә әлегә кадәр чакырганнары юк икән үзен...

# Бәдрәф... Туалетов?

Язучылар йортының Тукай клубында җыелыш бара.

Үзләренең яшәү шартлары барыбер яхшырмаячагын белгән каләм ияләре, кайнарланып, бер-бер артлы нотык тоткannan соң, җыелышны алып баручы тәнәфес игълан итә.

Фойега чыккан язучыларның берише, каядыр ашыккандай, йотлыгып тәмәке төтене суыра, кайберләре әле язарга өлгермәгән әсәренә түләнергә тиешле гонорар хакында гәп куерта. Язучылар йортына җыелыш булганда гына килергә гадәтләнгән каләм чарлаучылар исә, рәисне яки аның урынбасарын «эләктереп», аларга гозерләрен җиткереп калырга ашыга...

Җыелышка килер алдыннан гына ике-өч чынаяк чәй эчкән олпат гәүдәле Салих Баттал ике катлы бинаның коридорлары буйлап әйләнеп-тулганып йөри-йөри дә кием-салым алып-биреп торучы чибәр кызый янына килеп туктый. Туктый да, кызыйга бераз текәлеп-сәерсенеп карап торганнан соң:

— Бәдрәф кирәк иде. Кайда икәнен әйтмәссезме? — дип сорый.

Урыс телен үз теленә караганда мең мәртәбә яхшырак белгән әлеге сылу татар кызы өлкән шагыйрьнең соравына сорау белән җавап кайтара:

— Бәдрәф? А аның фамилия ничык?

«Туалетов» ди мыгырдап Салих Баттал һәм, йөзен чытып, озын, тар палас җәелгән коридор буйлап, янә бәдрәф эзләп китә.

*1994*

# Шигъриятебез көчләре

Бүгенге татар поэзиясенең колачы шактый киң, тавышы, тормышның үзе шикелле, төсмерләргә һәм нәкышләргә бай. Шигырьләрнең композицион пөхтәлегенә, ритмик төгәллегенә, фикри сүзнең җегәрлегенә, метафорик образларга, лирик-фәлсәфи һәм фәлсәфи-лирик, социаль-экономик һәм интим-публицист шагыйрьләребез бик зур әһәмият бирә. Шундый шагыйрьләребез рәтенә мин Нури Арслан, Илдар Юзеев, Хисам Камалов, Шәүкәт Галиев, Гамил Афзал, Нур Гайсин, Әдип Маликов, Зәки Нури, Зәет Мәҗитов, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Кави Латыйп, Сафуан Муллагалиев, Рашат Низамиев, Эдуард Мостафин, Разил Вәлиев, Фәннүр Сафин, Харрас Әюпов, Ркаил Зәйдуллин, Мөдәррис Әгъләмов,

Зөлфәт, Роберт Миңнуллин, Хәйдәр, Хәйдәр Гайнетдинов, Госман Садә, Ләис Зөлкарнәй, Рөстәм Фәйзуллин-Акъегет, Газинур Моратов, Марсель Галиев, Әхмәт Рәшитов, Зиннур Мансуров, Рәфикъ Юнысов, Нур Әхмәдиев, Рәшит Гәрәй, Кадыйр Сибгатуллин, Ямаш Игәнәй, Мөхәррәм Каюмов, Гарифҗан Мөхәммәтшин, Рәшит Әхмәтҗанов, Әзһәр Габиди, Роберт Әхмәтҗанов, Әхсән Баянов, Рөстәм Мингалим, Әхмәт Гадел, Әмир Мәхмүдов исемнәрен куяр идем.

Сүзнең соңында бер фикер: хәзерге поэзиядә үзгәрешяңарыш процессы дәвам итә.

## Хәерле кич!

*(Ярым шаяру)*

Алып баручы *(хатын-кыз)*. Хәерле кич, кадерле телевизор караучылар! Бүген сез безнең чираттагы «Язучы һәм тормыш» тапшыруын карарга әзерләндегез. Тапшыруыбызга кунак итеп без бүген барыбызга да бик яхшы таныш булган язучы... э-э-э... язучыбыз... э-э-э *(алдындагы кәгазенә күз чумдырып ала)* без яратып укый торган... әйе... хөрмәтле Хәммәт Сәламәтуллинның улы, әлегә мәктәп укучысы, әмма киләчәктә илебезгә файдалы кеше булачак *(кәгазьгә карап ала)* Глори Хәммәтович Сәламәтуллинны дәштек. Күпләрегез бик яхшы хәтерлидер, Глори Хәммәтович безнең «Язучы һәм тормыш» тапшыруында өченче класста укыган чагыннан бирле катнашып килә. Глори Хәммәтович, ялгышмасам, сез хәзер тугызынчы класста укыйсыз бугай?

Глори Хәммәтович *(кәгазьгә карап)*. Юк, ялгышмадыгыз...

Алып баручы. Глори Хәммәтович, иң элек сезгә бер җитди сорау. Әйтегез әле, зинһар, әтиегез бүгенге көндә нәрсә өстендә эшли? Кичерегез, әлбәттә, бу традицион сорау...

Глори Хәммәтович *(кәгазьгә карый)*. Әйе, бу традицион сорау. Шулай да җавап бирергә тырышырбыз. Мин үзем, гадәттә, өйгә бирелгән эшләрне хәзерләргә туры килгәндә, тез өстенә дипломат куя идем. Минем папа, наверно, өстәл өстендә эшлидер. Бүгенге көндә, наверно, шулайдыр. Бүгенге көндә мин дә...

Алып баручы. Тагын бер тапкыр гафу итегез, Глори Хәммәтович. Хәзер әзерләнгән сорауны без сезгә бер очрашуда биргән идек инде. Әмма тамашачыларның күп-

санлы таләбен искә алып, бу юлы да шул сорауны сезгә тәкъдим итәбез. Рәхим итегез, Глори Хәммәтович...

Глори Хәммәтович. Рәхим итегез... Бу сүз бик кызыклы. Бу турыда мин бик күп китаплар укыганым бар. Мине бигрәк тә фантастика кызыксындыра *(кәгазьдән укый)*. Мәсәлән, Беляевның томан турындагы китабын әти бала чагында бик яратып укый торган кешеләрне бүген дә әйбәт хәтерли. Аннан соң мине бүгенге көндә авыл исемнәрне кызыксындыра. Пичәттә дә шул турыда күп язалар...

Алып баручы. Авыл дигәннән, мин үзем Әгерҗе районыннан. Анда бик матур авыл бар, Сахра исемле...

Глори Хәммәтович. Их, минем шул авылда булганым юк. Сөйләгез әле шул авыл турында.

Алып баручы. Авыл дип... анда урман бар, сулар күп. Чишмә дә әллә ничә бугай әле анда.

Глори Хәммәтович. Минем язучы әтием дә *(кәгазьгә карап сөйли)* туган авылы турында бик интересно итеп сөйли. Миңа әйтә, сине дә бер алып кайтырмын әле, ди. Язудан бушагач, ди. У-у-ух, авылга кайтсаммы?!

Алып баручы. Балык тотарга барыр идегез, шулай бит!

Глори Хәммәтович. Юк, рәхәтләнеп йоклар идем. Туйганчы...

Алып баручы. Сизенгәнсездер инде, Глори Хәммәтович, әңгәмәбез җанлана төште. Җәл, тапшыру вакыты *(сәгатенә карап ала)* бетеп килә. Сезгә бик зур рәхмәт инде әңгәмәбез өчен.

Глори Хәммәтович. Интервью өчен дип әйтүегездер инде.

Алып баручы. Әйе, әтиегезгә сәлам әйтегез. Бөтен тамашачылар исеменнән. Без аның тормышы турындагы яңадан-яңа әсәрләрен көтеп калабыз. Сезгә тагын бер тапкыр рәхмәт. Чакыруыбызга каршы килмәдегез...

Глори Хәммәтович. Рәхмәт үзегезгә дә *(кәгазьгә карый)*. Тапшыру бик кызыклы узды. Мондый тапшыруны бик матур интересно традициягә әйләндереп бик яхшы әйбәт иткәнсез *(экранга карый)*. Киләсе тапшыруда очрашканга кадәр. Пока, дуслар.

Алып баручы *(кәгазьгә текәлеп)*. Сау булыгыз! *(Матур итеп елмая.)*

# Телсез шаһит

*(Мәгъсүм Насыйбуллинга ияреп)*

«Бу, һичшиксез, карак Чумаков эше булырга тиеш. Сейфны ачканда, ул гына мондый «имза»лар калдыра ала»,— дип уйлады өлкән тикшерүче Гайнан Ибраһимов.

Тәҗрибәле белгеч ялгышмады.

— Иптәш кече сержант Гаптериев, хәзер үк Зур Урам чатындагы сыраханәгә юл тот! — дип фәрман бирде өлкән тикшерүче Ибраһимов һәм кече сержант Гаптериевка карак Чумаковның төс-кыяфәте, кием-салымы турында күз алдына китерерлек итеп сурәтләп бирде.

Кече сержант Гаптериев китүгә, өлкән тишерүче Ибраһимов ватык сейф өстендә карак Чумаков онытып калдырган китапны сак кына кулына алды.

«Телсез шаһит»ның «телгә» киләчәгенә ул һич тә шикләнми иде...

* * *

Өлкән тикшерүче өстәл астына җайлап урнаштырылган магнитофонны көйләштергәләп куйды да каршындагы яшел төймәгә басты. Бүлмәгә кече сержант Гаптериев керде.

— Иптәш кече сержант Гаптериев, гаепләнүче Чумаковны кертегез,— диде аңа өлкән тикшерүче Ибраһимов. Гаепләнүче бүлмәгә кергәнче, ул үзенең балачагын, Казан дәүләт университетына укырга кергән елларын һәм өйләнүен ләззәтләнеп күңелдән кичерде.

— Утырыгыз, гаепләнүче Чумаков,— диде өлкән тикшерүче Ибраһимов, карак Чумаковка елмаеп (гаепләнүче белән ягымлы сөйләшү — ярты җиңү ул, диярргә ярата иде ул үзенең шәкертләренә), һәм сигарет тартырга рөхсәт итте.

— Рәхмәт, гражданин начальник,— диде Чумаков. Ул мондый кече күңеллелектән каушап калган иде.

— Бу китапны таныйсыздыр, шәт, гаепләнүче Чумаков? — диде өлкән тикшерүче Ибраһимов һәм карак Чумаковка ватык сейф өстеннән алган китапны күрсәтте. Гаепләнүче китап тышлыгындагы «Мәгъсүм Насыйбуллин. Телсез шаһитлар» дигән сүзләрне укып өлгерде. Аның иреннәре, куллары дерелди башлады, йөзе акшарланган мич төсенә керде...

Гаепләнүче Чумаковка бөтенесен дә түкми-чәчми сөйләп бирүдән башка чара калмады.

*1987*

# Телефон

*(Пролог)*

Кабыргалары беленеп торган дүрт меринос сарык тиресеннән тегелгән тун кигән бер агай трамвайдан төште дә, светофорның чекерәеп янган кызыл утына карап, ашыкмыйча гына урам аркылы чыкты, һәм шул ашыкмавы аның язмышын хәл итә язды: «Фиалка» кибете яныннан ук кычкыртып килгән сары «Запорожец»ның астында чүт кенә кәлҗемә булмыйча калды.

Ачудан ярсыган шофер — татар егете — машина тәрәзәсеннән ярты гәүдәсе белән чыгып, йодрыгын болгыйболгый, агай артыннан: «Диривня! Скатина!» — дип кычкырды. Шофер хак әйтте: агай чыннан да авылдан иде...

Шоферның кычкыруына агай артык әһәмият бирмәде. Яшелчә кибетеннән өшегән кәбестә күтәреп чыгып килүче бер юантык хатынны туктатты да, урысчаны вата-җимерә:

— Тавариш, где дум писател, а? — дип сорады.

Юантык хатын үзебезнең халыктан булып чыкты, ахрысы, ул да агай шикелле үк вата-җимерә:

— Вут там далжна быт! — дип җавап кайтарды һәм өшегән кәбестә тотмаган кулы белән Язучылар йортына төртеп күрсәтте.

Агай, хатынга дустанә елмаеп, өч мәртәбә «Ыспасиба, тавариш» диде дә, теге йортны күз уңыннан ычкындырмаска тырышып, алга атлады...

## 1

Язучылар йортына җиткәч, агай туктады да, сырган чалбар кесәсеннән Оренбург шәле зурлыгындагы каракучкыл кульяулыгын алып, зәмһәрир суыкны сындырырлык итеп борын сеңгерде — баш очындагы ябалдаштан энҗе бәсләр коелышты...

Шуннан соң ул кипшенгән иреннәре арасына «Ватра» сигареты кыстырды, аны вәкарь белән генә кабызгач, йон бияләе эченнән җиде-сигезгә бөкләнгән бер кәгазь тартып чыгарды. Китап нәшриятында кемдер биргән ул кәгазьгә шәмәхә карандаш белән «Марсель Галиев» дип язылган иде.

Агай (сизенүебезчә, ул башлап язучы пенсионер булса кирәк), тун эченнән биленә солдат каешы белән кысып куелган шакмаклы унике дәфтәрне капшаштыргалап, аларның исән-имин икәнлегенә тәмам инангач, Язучылар йортына күтәрелеп карады. Карады һәм... телсез-өн-

сез калды: тәрәзә пыялалары тигез ритм белән зең-зең калтырана иде. Бер мизгел эчендә агайны «Җир тетри бугай бит!» дигән коточкыч уй биләп алды. Ул арада тәрәзә пыялалары, ритмны югалтып һәм челпәрәмә килер чиккә җитеп, өзлексез дерелдәргә тотынды. Агайның авызы ачылып китте, сигареты, очлы ияктә тырпаешкан җиз төкләрне көйдереп узгач, ачык изү аша ялкау гына тун эченә төшеп чумды...

## 2

Агай янына кешеләр җыйнала башлады. Алар да тәрәзәләрнең чытыр-чытыр килгән пыялаларына караган килеш, «Җир тетри!» дип шауларга тотындылар. Челтәрле сумкасыннан буш кефир шешәләре күренеп торган хатын агайның изүеннән ургылып чыккан төтенне күрде дә чәрелдәп кычкырып җибәрде...

Агай аңын югалтты, гөрселдәп, бөтен буе белән җиргә ауды. Тунның корсак өлеше, бәрәңге кыздыра торган уртача таба зурлыгындагы түгәрәк хасил итеп, шакмаклы унике дәфтәр белән бергә янып беткәнен, ярты сәгатьтән килгән «ашыгыч ярдәм» машинасы үзен алып киткәнен ул белми иде әле...

## 3

Агайның аңын югалтыр дәрәҗәгә җиткергән мондый хәлне тарих хәтерләми.

Ә хәл болай иде...

...Союзда телефон шылтырады. Дүрт бүлмәдәге дүрт телефон трубкасын берьюлы дүрт кеше алды.

Мөсәгыйт Хәбибуллин тавышы:

— Әйе. Мөсәгыйт тыңлый. Хәбибуллин. Хәбибуллин, дим, Хәбибуллин! Исәнмесез! О-о-о... Бәйрәм белән сезне, Александр Владимирович... Якынлашып килүче бәйрәм белән, дим... Алексан...

Гәрәй Рәхим тавышы:

— Мөсәгыйт, куй әле трубканы. Миңа бу. Сәлам, Шамил Бариевич... Әйбәт. Рәхмәт. Әйе... Шамил Маннапов юбилее уңае белән инде...

Туфан Миңнуллин тавышы:

— Мөсәгыйт! Гәрәй! Куегыз әле трубканы!.. Миңа Мәскәү... Ашыгыч! Сергей Михалков...

Римма Миңнуллина тавышы:

— Дания апа, синме бу? Исәнме, Дания апа?..

М.Хәбибуллин:

— Куллар куелган... Рабочийлар килергә тиеш...

Әйе... Кабельләрне җир туңдыру белән казытып күмдердем...

Т. Миңнуллин:

— Мөсәгыйт, трубканы... Мәскәү...

Р. Миңнуллина:

— Дания апа, бәйрәмгә тортлар-мазарлар кирәк булыр ул, име?!

М. Хәбибуллин:

— Торбаларны да салдырттым...

Г. Рәхим:

— Кичәне гадәттәгечә үзем алып бармакчы булам.

Т. Миңнуллин:

— Трубканы куегыз әле!!!

...Тәрәзәләр дөбер-шатыр килә. Тавышлар һаман ишетелә:

— Кабель сузганда...

— Юбилей мәшәкатьләре...

— Дания апа, Яңа ел...

— Куегыз әле трубканы!!!

Мәскәүдән Сергей Михалков тавышы:

— Т-т-тьфу, черт, оп-пять т-татарское нашествие!

### Эпилог

Әйе, агайның аңын югалтыр дәрәҗәгә җиткергән мондый хәлнең булганлыгын тарих хәтерләми иде: бер генә «точка»лы телефон аша бер үк вакытта дүрт кеше ничек сөйләшә алды икән?

Гаҗәп!

Хәтта японнарның башы җитмәслек хәл...

*1987*

## Депутат таныклыгы

Дус-ишләр яхшы белә: вак-төяк йөк ташыр өчен уңайлы минем машина.

Беркөнне Баяныч (язучы Марсель Галиев):

— Ләбиб, «Рухият» офисыннан минем китапларны алып, шуларны Үзәк китапханәгә генә илтеп килик әле,— дип үтенде.

Алдык, киттек. Юлыбыз Ирек мәйданына килеп төртелде. Китапханә бинасы күренеп тора. Әмма аңа турыдан барырга ярамый. Урау юл белән китсәң, шактый әй-

ләнергә кирәк. Аклы-каралы тәпәч тоткан «дуслар» күз уңында күренми әле дип, тәвәккәлләдек...

Күзгә керәсе черки керә инде ул: юл читендә торган гадәти җиңел машина эченнән түгәрәк гәүдәле бер «таныш агай-эне» туп кебек атылып чыкты да, машинаны туктатырга ишарәләп, тәпәчен күтәрде.

Кирәкле документларны түш кесәмнән тиз генә алалмыйча изаланган арада, Баяныч милиционерга ниндидер кызыл таныклык күрсәтеп тә өлгерде. Гаишник егет, кинәт тураеп, Баянычка честь биргән вакытта, әлеге таныклыктагы «Дәүләт Думасы депутаты...» дигән сүзләр күзләремә чалынды. «Бә-әй, Баяныч та Дума депутаты микәнни? Кайчан депутат булды соң әле ул? Мин нишләп белмичә калдым?» дигән уй-сораулар йөгереп узды башымда.

Гаишник егет минем кулдан документларны алды да, машинаны җәлт кенә күздән кичергәч, сәерсенеп, янә Баянычка карады. «Үзе — депутат, үзе хөләпә «Москвич»ка утырып йөри» дип уйлады, ахрысы, һәрхәлдә, миңа шулай тоелды.

Менә ул аптыраган кыяфәттә басып торды-торды да, документларны алып, баягы машинада утырган хезмәттәше янына ашыкты. Бераздан, кире килеп, документларны сузды:

— Әнә тегеннән әйләнеп уз!

Рәхмәт әйтеп, кузгалып киттек.

— Җиңел котылдык,— дидем мин Баянычка. Ул кемне утыртып йөргәнеңне белдеңме инде дигәндәй, елмаеп куйды.

Соңыннан сере чишелде Баянычның: ул Рәсәй Дәүләт Думасы депутаты Фәндәс абый Сафиуллинның ярдәмчесе икән ләбаса.

## Безработный

30 август. Кәеф шәп — бәйрәмчә. Машинага хатыным Фиданияне дә утыртып, киттек Казан читендәге дачабызга. Күңел җырлый, машина җилдерә... Компрессор заводы ягына чыга торган күпергә якынлашканда — тфү, нәләт! — гаишниклар пәйда булды.

— Абый, машинаң шәп инде, шәп! «Девятка»ларны да выжлап кына узасың,— диде тәпәчле егет, машинадан чыгуымны түземсезләнеп көтеп алгач.

Аның «эш булмәсенә» — юл читендәге машинасына кереп утырдык. Минем исем-фамилиямә исе китте егетнең:

— Леронов Лемон Леронович. Хы! Әллә сез чегәнме? — диде ул, минем төс-кыяфәтемне күздән кичереп.

— Юк,— минәйтәм,— татар мин!

— Кызы-ы-ык,— дип сузды ул.

Үземә дә кызык булып китте: моңарчы «Керәшенме, еврейме син?» — дип сораганнары бар иде, ә менә чегән диючеләре юк иде әле.

— Кайда эшлисең?

— Язучы мин. «Салават күпере» журналы редакциясендә эшлим, —дидем.

Егет, алдындагы кәгазьне язып тутыргач, үзендә берсен калдырып, икенчесен миңа сузды:

— Йөз сумыңны фәлән җиргә барып түләрсең, абый,— диде.

Кәгазьгә күз төшердем. Эш урыным күрсәтелгән урынга «Безработный» дип язылган иде.

— Мин бит эшлим — язучы мин! — дидем, «Безработный» булуым белән килешмичә.

«Барыбер инде!» дигәндәй итеп кулын селтәде дә гаишник нәфселе карашын юлдан килүче чираттагы корбанына юнәлтте.

## Аңлашыла

Ләбиб Лерон «Идел» редакциясенә керә дә зарлана башлый:

— Нинди ил соң бу, нинди ил? — ди.— Авторлык хокукын кайчан саклый башларлар бездә?

— Нәрсә булды, рәтләп сөйлә әле...— диләр аңа.

— «Йомарлам» дигән поэмамны, бастырганда, шул кадәр кыскартып бетергәнсез, хәзер бернәрсә дә аңлашылмый. Укучы нәрсә дияр инде?

— Кыскартканга кадәр аның аңлашылуы безгә аңлашылмый иде,— ди мөхәррир Ркаил Зәйдулла.— Хәзер исә хет аңлашылмавы аңлашыла.



## V бүлек

# Кайбер әйберләр

## Имеш...

— Бүген командировкадан кайтып керсәм...
— Ха-ха-ха-ха!..
— Ник көләсең? Әле мин сөйли генә башладым бит...
— Ха-ха-ха-ха... Бәй, син иденмени ул?.. Ха-ха-ха...

*1994*

## Киңәш

Кечкенә кызы әтисенә әйтә икән:
— Әтием, син моннан соң өйдә тәмәке тартма инде...
— Нигә алай дип әйтәсең, кызым? — дигән әтисе.
— Син өйдә юк чакта әни янына килгән абый гел: «Фу, яратмыйм шушы тәмәке исен!» — дип әйтә...

*1992*

## Балыкчы Галләм

— Хатын! Мин балыкка киттем! — диде Галләм һәм балык тоту өчен кирәк булган әйберләр салынган биштәрен кулына алды.

— Берүк бүген минтай ала күрмә,— диде хатыны.— Акчаң җитсә, скумбрия генә ал!

## Кайсыгыз минем әти?

*(Комедия)*

К ы з. Безнең балабыз булачак! Ишеттеңме, Рәис?
Е г е т. Ишетәм. Чукрак түгел. Әтисе кем? Нәсимме?
К ы з. Аңламассың сезне! Нәсим син дип уйлый... Гали Нәсим дип.

*1994*

# Ирне ир итим дисәң...

*(Хатын-кызларга әз-мәз киңәш)*

Иреңә вакыт-вакыт «Сине генә сөям, җаным!» дип әйткәләп торырга кирәк. Ир-ат халкы юк-бар сүзләргә бик тиз ышанучан бит ул.

Әгәр ирең күзәтүчән түгел икән, син аның каршында шәп-шәрә килеш бөтерелеп күпме генә йөрмә, ул барыбер синең яңа алкаларыңны күрмәс.

Ирең синнән «Бирәсеңме инде, юкмы, канса канис!» дип, өзми-куймый сорый икән, сөенергә ашыкма. Бәлки, ул кабахәт тәре синнән бер сыралык акча гына сорыйдыр...

«Ирең эчәме соң?» дип сораган ахирәтләреңә, ирең эчмәсә дә, «Эчмәгән кая!.. Эчә-ә-ә... Бүчкесендә йөзә!..» диген. Ахирәтләреңнең үлә-бетә язып сөенгәннәрен шул чакта күрерсең.

Әгәр өеңә үзең генә белгән сәбәпләр аркасында соңлап кайтсаң, бусагадан атлап керүгә үк: «Бүген нишләп күзләреңне тозландырып иртә кайттың әле? Себеркең себереп җибәрдемени?» — дип, иреңә ябыш. Шулай итсәң, иртәгесен ирең үзе соңлап кайтачак. Ул чагында инде син аны ничек каршыларга икәнлеген үзең дә бик яхшы беләсең.

Әгәр иреңне гомер эчендә бер мәртәбә сөендерәсең килсә, бер шешә сыра ал. Әгәр инде бик каты сөендерәсең килсә, аракы ал. Әгәренки ирең эчми торган кеше икән, киңәш бирә алмыйм.

# Һәр хатын алтын булмас...

*(Ир-атларга әз-мәз киңәш)*

Булачак хатыныңны айлы төндә өенә озатканда, «Сиңа йолдыз бүләк итәрием!» дип шапырынма, соңыннан үкенергә туры килмәгәе. Мәңге хәтереңдә тот: хатын-кыз заты туры мәгънәсендә аңлаучан.

Беркайчан да өеңә соңлап кайтма. Инде кайбер сәбәпләр аркасында соңга калып кайтасың икән, берүк хатының каршында мескенләнеп, акланып маташа күрмә. Ни сәбәпле соңаруыңны хатының үзе ничек аңлата бит әле. Әүвәл аның вариантын тыңлап кара. Бәлки, ул вариант синең өчен кулайрактыр?!

«Балаларның берсе дә минеке түгел бугай...» дип уйлама. Әгәр шулай уйлыйсың икән, димәк, хатының үзеңнеке түгел.

«Туйдым синнән, җир бит! Син хәсис белән бер минут та яшәмим. Хәзер үк әниләргә кайтып китәм!» — дип, хатының бик яман тузына икән, син сөенгәнеңне сиздермәскә тырыш. Хатыныңның кире уйлавы бар.

## Кияүгә чыгу галәмәтләре

Кәримнең хатыны Сәлимә малай тапты. «Шулхәтле охшаса охшар икән этисенә! — дип сокланды Сәлимә. — Кара инде борынын! Кара инде ияген! Кара инде авыз чәпелдәтүен! Тач Галинеке!»

Гөлләрия дүрт тапкыр кияүгә чыкты. Җиде баласы бар. Шунысы кызык: җиде баланың җидесе дә җиде ирдән!

Ә менә Вәсилә, кияүгә әле беренче мәртәбә генә чыгуына карамастан, берьюлы өч кешене бәхетле итте: үзен һәм ике сөяркәсен.

## Игълан тактасында ни булмас...

### Ак бәхетләр тели

Җирән чәчле, тукмак борынлы, соры күзле (уң күз төбендә зәңгәр фонарь бар), буе ике уклау озынлыгы хәтле ирем югалды. Аны тапкан хатынга ак бәхетләр, корычтай нык сәламәтлек, мәңге какшамаслык нервы телим.

### Пар эзли

Әле бер генә тапкыр да өйләнеп карамаган утыз яшьлек ир мәхәббәт романнары укырга һәм анекдотлар тыңларга ярата торган үзенә тиң пар эзли. Кияүдән кайтмаган кызларны тәкъдим итмәскә.

### Кайгысын уртаклаша

Кичә «Дуслык» кинотеатры залында 251 сум 10 тиен акчасы булган янчык таптым. Югалтучының кайгысын чын күңелдән уртаклашам.

### Консультант

Инглиз телен татарча өйрәнергә теләүчеләргә консультация бирәм.

## Дип әйтте ди берәү...

— Талантны «Дефицит! Дефицит!» дисез, ә берегез дә кайсы кибеттә икәнен әйтмисез...

— Мин ике әсәр өстендә берьюлы эшләргә яратам. Менә әле генә бер шәп драман язып бетердем...

— Китап никадәр юка булса — шулкадәр әйбәт: барыбер хәтердә бернәрсә дә калмый...

— «Кадерле иптәш! Каләмең үткен күренә, уңышлар телим» дип яза-яза үз каләмем үтмәсләнде инде.

— Премиянең фәлән язучыга биреләчәген белүгә, мин ул премиядән шундук баш тарттым.

— Минем өченче китабымны да урта кулдан түбән дип бәяләргә ашыкмагыз әле сез, җәмәгать. Халкыбызның үтә дә акыллы бер мәкален искә төшерик: тавыкның һәр салганы алтын булмас!

— Кеше язганны аны кем дә укый, менә син мин язганны укып кара!

— Яңа тәнкыйть китабыңны укып чыктым — оригинально! Иң мөһиме — үзеңчә: бер генә тәнкыйть сүзе дә юк!

## Тәгәри китте җөмләгем...

Барлык юллар да Римга илтсә, мин инде күптән анда булыр идем.

Тау күрмәгән кешеләргә түмгәкләр дә биек.

Үткәнемне начар күрәм — арпа чыкты күземә.

Замана төше: китап кибетендә шигырь саталар, дилбегә буе чират, һәр кешегә бер генә шигырь бирәләр — аны да талоның булса гына...

Кичә язган яңа шигыремне өченче көн ертып ташладым.

Мунчага идән мунчаласы белән бармыйлар.

Әгәр кулыннан килсә, вакытны чабуыннан тартып туктатыр иде.

Шикаять яза-яза акылдан язды, ниһаять!

Кеше биргән киңәшне колагына киртли торгач, берәү бөтенләй колаксыз калган.

Тел тегермәнеңне күпме генә әйләндерсәң дә, бодай тарттыра бу, димәсләр.

Кайберәүләргә күз буяу өчен күзге кирәкми.

Эт эзенә басып йөрсәң, эткә әйләнүеңне көт тә тор.

Гайбәт чәйнәп тә тамак туйдыручылар бар.

Арык сарыкның карыны ярык.

Табак чырайларга карап, тамак туймый.

Дефицит товар эзләп кибеткә алгы ишектән керүдән

ни файда да, шыгрым тулы трамвайга арткы ишектән керүдән ни файда?

«Туйдым бу хатынның бизәнүеннән!» — дип әйткән ди бер Көзге.

«Күр инде, тире белән сөяккә генә калгансың бит»,— дип әйткән ди берәүгә тире-сөяк җыючы.

«Һи, сүзеңнең ата-анасы юк, хет үзеңнең ата-анаң бармы?» — дип сораган ди берәү яңа танышыннан.

Ул кеше кесәсенә сүз эзләп керми. Акча эзләп керә.

Ул үз хатынын үлеп ярата. Сөяркәсе шуны аңламый.

Ул тумыштан ук башлы иде анысы... тик акылы гына булмады бичараның...

Ул бик бай кеше. Хыялга.

Ул — шизофреник һәм юрист. Ләкин Ленин да, Жириновский да түгел.

Ул дүрт бала атасы. Хатыны шуны белми.

Ул ахмак. Син дә ахмак. Мин дә ахмак. Алар да ахмак. Ну, җегетләр, кемдер акыллы булырга тиештер бит инде, канса канис!..

# Анадан тума җөмләләр

## Чарасызлык

Ул, наркоман буласын белүгә, ана карынында ук үзүзен үтерде.

## Айныгач

Аракы эчәсе килмәгән чакта, ул өч-дүрт касә коньяк йотып кую белән генә чикләнде.

## Бәхет

Бер бала тәрбияләп кенә чиләнгән гаиләгә килсә килә бит ул бәхет: берьеллык командировкадан кайткан ирен хатыны өч игезәк бала табып каршы алды.

## Талант

Чын шагыйрьне рәхәтләнеп газаплыйсың килсә, аңа үз талантыңны биреп кара.

### Җырчы кортлар

Җырчылар Колорадо коңгызы шикелле үрчеде. Тыңлаучыларга Ходай ярдәм бирсен.

### Сүздә тору

Үлде. Үкенмәде. «Үлсәм дә үкенмәс идем!» — диюе хак булган икән.

## Ашыгыз тәмле булсын!

### Кара борыч шулпасы

Дөбер-шатыр кайнаган суга (2 л) җаның теләгән кадәр кара борыч сибәсең. Әгәр кул астында андый борыч юк икән, кызыл борыч та ярый. Инде, гөнаһ шомлыгына каршы, кызыл борыч та юк икән, тоз гына салсаң да була. Табынга кайнар килеш бирелә.

Искәрмә: хроник гастрит, ашказаны җәрәхәте белән интегүчеләргә бу ашны ашамау хәерле.

### Итле бәрәңге

Суыткычны ачып карыйсың да ябасың. Аннан соң, бәрәңге булса, бәрәңге әрчисең. Биш-алты штук әрчи алсаң — шул җитә. Әзер бәрәңгеләрне кайнап торган суга тондырасың (салганда сак булырга кирәк, кайнар су чәчрәмәсен!). Түменә карап тоз җиффәргәннән соң, янә суыткычны ачып карыйсың. Ярты сәгатьтән соң бәрәңге пешеп җитә. Бәрәңге яшь бозау ите белән ашарга тәкъдим ителә. Яшь бозау ите булмаса, күркә яки үрдәк ите дә ярый.

### Яшел борчак боткасы

«Симәнә» кибетеннән алып кайткан борчакларны керәч яки эмаль савытка салынган суга бүрттерергә куясың. Аларны берничә көн (шытымнар күренгәнче) шул суда тотасың. Аннан соң алдан ук тәрәзә төбенә хәстәрләп куелган агач тартмалардагы кара туфракка бер-берсеннән 2–3 см калдырып төртәсең. Түземлегең җитеп, берничә ай көткәннән соң, тәүге уңышларны җыеп аласың да ботка пешерәсең. Мондый ботканы балалар гына түгел, өлкәннәр дә бик ярата.

*19 март, 1996*

# Чыктым аркылы күпер

*(Трилогия-пародия)*

## Эпилог

Кара сыер шикелле кара төн иде...

## Кискен борылышка кадәр

Авыл хуҗалыгы университетының ат печүчеләр хәзерли торган бүлеген бик яхшы билгеләргә генә тәмамлагач, ул куе кызыл тышлы дипломын шараварының арткы кесәсенә сак кына чумдырды да, бик шәп бер берләшмәнең тулай торагына урам себерүче булып эшкә урнашты...

Икенче көнне үк үзе белән бер бүлмәдә коммунизмны узып киткәнче яшәргә ризалык биргән бер сөлектәй матур түти белән никахка кереп, аны судсыз-нисез аерып җибәрде. Шул көннән башлап, урам себерүче яшь иптәшнең шәхси тормышында катлаулы һәм кискен борылышлар башлана...

Беренче китап тәмам.

## Яшәү өчен көрәш

Авторның исем-фамилиясе күрсәтелмәгән ниндидер бер китабы бар иде аның, ләкин ул китапның битләре бөтенләй коелып беткән булу сәбәпле, аны укып чыгарга аның шактый мөмкинлеге булмый торды; ә бүген, теге тәрбиясез хатынны аерып җибәргән көн искә төшкәч, анда шул китапны укып карау теләге туды һәм ул, максатын кичекмәстән тормышка ашыру нияте белән, өченче көн генә такталары идәнгә ишелеп төшкән киштәгә бөтен гәүдәсе белән сузылып, кечкенә чакта ялгыш пилорам пычкысына тиеп өзелгән сул кулына янә шул китапны алды да битләрен берсе көньякка, икенчесе төньякка караган озын-юан бармаклары ярдәмендә кабаланып актарырга кереште...

Икенче китап тәмам.

## Авылдашлар өмете акланды

Авылдашлары, туган-тумачалары аның дөньяда атаклы кеше булачагына өмет баглап ялгышмадылар. Ул, чыннан да, зур кеше булды: пенсиягә чыккач, тормышны күп күргән булуын хәтеренә төшереп, атаклы башлап

язучы булып китте. Очсыз-кырыйсыз әсәрләрендә ул теге чакта, шимбә көнне иртә белән судсыз-нисез аерып җибәргән көмештәй саф кызга булган керсез, бернинди тапсыз мәхәббәтен сурәтләде. Бүген үк дөнья әдәбиятының алтын фондына керерлек, әмма әле языла да башланмаган трилогиясенә (әйтергә кирәк, өр-яңа трилогиясенә!) исем уйлап тапты. Исеме «Чыктым аркылы күпер...» дип атала.

### Пролог

...Бу вакытта Чатан Хәмделгали агайларның салам түбәле лапаслары артыннан, алтындай елмаеп, миски капкачы чаклы кояш күтәрелеп килә иде...

Тәмам.

*Казан — Дубулты — Гагра — Малеевка — Нида — Крутушка —Переделкино — Ялта — Казан.*
*1961–1987*
*1992*

## Туңкайган әфлисун

Шигырь язып кына баеп булса, татар шагыйрьләренең барчасы да машинада гына җилдерер иде...

Миңа машинаны әти бүләк итте. «Москвич-комби». 1988 елгы гына булса да, кем әйтмешли, өр-яңа — сәвсим йөрелмәгән. Матур — нәкъ әфлисун төсендә. Биш ел элек үк машина йөртү таныклыгын алып куюым тикмәгә булмады, дип сөендем.

Мин — машинага, машина миңа ияләшкән көннәрдә, дустым Ркаил Зәйдулла мәзәк тә чыгарып өлгергән...

— Ләбиб, шагыйрь кешегә машина йөртергә өйрәнү авырмы? — дип сораган, имеш, Ркаил.

— Нишләп авыр булсын... Шоферлар да йөртә бит әле! — дип, эре генә җавап кайтарган, имеш, Ләбиб...

Беркөнне Ркаил дус минем эш бүлмәмә авызын ерып килеп керде дә, исәнләшергә дә онытып:

— Килгәндә уйлап килдем. Беләсеңме, машинаң нәрсәгә охшаган синең? — диде.

— Белмим,— минәйтәм.

— Туңкайган әфлисунга!

Шулай диде дә Ркаил, әйткәненнән канәгать булып, шаркылдап көләргә тотынды.

Үпкәләвемне сиздермәскә тырышып: «Синең андые да юк бит әле!» — диясем килде-килүен... Дусның үзен үпкәләтәсем килмәде...

Авылларда сугым вакыты. Ркаил өйгә шылтырата:

— Авылга кайтып килик әле! — ди.

— Машина төзек түгел бит әле,— минәйтәм.— Радиатордан тосол ага. Карыйсы бар...

— Байтактан ага бит инде ул. Шул килеш Кукмарага да кайтып килдең. Дустыңа дигәндә, машинаңны җәллисең, ә! — ди Ркаил.

Сагыз булды — тәки ризалаштырды.

Радиаторга тосол өстәп, Ркаилнең улы Баязитны да алып, кузгалдык юлга...

Кунак булып, төянеп, Казанга кире кайтканда, Баязит (сабый бит — кызыксынучан) минут саен:

— Казанга җитәбезме әле? — дип сорап йөдәтә башлады. Ркаил, аңа җавап бирә-бирә арыгач, сүзне икенчегә борырга теләп:

— Хәзер Ләбиб абыең сиңа безнең ничек танышуыбыз турында сөйләр, тыңла, Баязит,— диде.

— Миңа игътибарны читкә юнәлтмичә генә юлны карап барырга кирәк. Үзең генә сөйлә инде, Ркаил,— дидем мин.

— Юк, син сөйләсәң, Баязитның хәтерендә яхшырак кала ул! — ди Ркаил.

«Син сөйлә» дә «син сөйлә» ди торгач, тәпәч күтәргән милиционер янына килеп туктаганны сизми дә калдык.

— Килеп җиттек! — дидем мин, кабина ишеген ачарга азапланып.

— Казангамы? — диде Баязит.

Ркаил дәшмәде.

Ярый әле тәпәч ияләре (юл читендәге машина эчендә утырганы да) татар егетләре булып чыкты. Безнең язучылар икәнлекне дә белеп, кәгазь-фәлән тутырмыйча гына йөз тәңкәне алып, дустанә елмаеп калдылар. Киткәндә, юл чыгымының кечтеки генә өлешен кире кайтардык тагы: Ркаил, үзенең кесәсендә булса да, милиционерларның берсеннән сигарет алып кабызды...

## Һавадагы торнага...

Татарстан Язучылар союзын яңа бинага күчергәндә, архив кәгазьләре арасыннан бер документ табып алдым. Утырыш беркетмәсен. Эшлекле сөйләшүләрне, кайнар бәхәсләрне, мәгънәсез әңгәмәләрне, авыздан кош очырып мактануларны — һәммәсен бүгенге көнгә саклап алып килгән ул.

**Беркетмә**

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең чираттагы утырышы. 12 август, 1969 ел.

**Катнашалар:**

И. Гази, А. Шамов, М. Әмир, В. Синев, Ә. Исхак, Г. Кашшаф, С. Хәким, Х. Госман, Г. Ахунов, Г. Бәширов, И. Юзеев, Л. Ихсанова, Р. Ишморат, И. Нуруллин, Ф. Хөсни, Л. Хәмидуллин, З. Нури, Х. Туфан, Г. Афзал, М. Шабаев, архитектор Зиннуров.

Председательлек итә — И. Гази.

**Утырышта бүгенге көннән (1989 ел) бер кеше катнаша — Л. Лерон.**

**Көн тәртибендә:**

1. Язучылар йорты проектын карау.

Көн тәртибе буенча архитектор Зиннуров сөйли.

Зиннуров. Язучылар йорты Карл Маркс һәм Комлев урамнары чатында худфонд бинасы белән бер ансамбль тәшкил итәргә тиеш! Каршысында — бассейнлы сквер һәм балалар кинотеатры булачак. (Ошбу җөмләне укыгач, нигәдер «Сиксәненче елда коммунизмда яши башлаячакбыз!» — дигән «канатлы сүзләр» искә төште.— *Л.Л.*)

Йорт үзе, нигез этажы белән исәпләгәндә, дүрт катлы, тыштан караганда, өч катлы. Тимер-бетон, кирпеч һәм пыяладан салынырга тиеш.

Нигез этажында (ярым подвалда) 100 урынлы ресторан, бильярд бүлмәсе (80 кв. м), ишегалды ягында складлар, ике машиналык гараж төзү күздә тотыла.

Беренче этажда 365 урынлы зур тамаша залы (ике этаж биеклегендә), иркен фойе, 60 урынлы конференц-зал, 10 мең томлык китапханә, уку залы белән яңадан 3 бүлмә һәм санузел.

Икенче этажда кунаклар өчен холл, Союз аппараты өчен эш бүлмәләре — барлыгы 9 бүлмә.

Өченче этажда «Казан утлары» һәм «Идел» (бу сүзләрнең астына сызылган) журналы редакцияләре.

**(Йа Хода, ошбу 1989 елның июлендә чыга башлаячак «Идел» журналы редакциясе өчен моннан егерме ел элек үк эш бүлмәләре мәсьәләсе уңай хәл ителгән булган бит. Рәхмәт кенә яусын инде юмарт һәм киң күңелле архитекторларыбызга!)**

**Фикер алышу.**

И. Н у р у л л и н. Әдәби музей юкмы?

З и н н у р о в. Юк. (Нинди кызганыч. Әдәби музей нәкъ шушы йортта булырга тиеш иде!) Музей башка урында булырга тиеш. (Соңгы чиктә монысына да риза инде без, әдәби музей гына булсын! — *Л.Л.*)

И. Г а з и. Милли колориты булырмы? Нәкъ менә татар язучылары йорты икәне күренеп торсын иде.

З и н н у р о в. Анысы инде эскиз-проект раслангач хәл ителәчәк.

**Ресторан хакында кайнар бәхәс китә. Ниһаять, аерым ишек белән булса, ресторан кирәк, дигән фикергә киләләр.**

**Дагасы булды, ат кына табасы калды дигәндәй, ресторан язмышы да хәл ителде. (Өй салуның ние бар, мүклисе дә чутлыйсы!)**

**Чү! Хәсән Туфан сүз ала. Ни әйтмәкче була дөньяның ачысын-төчесен күп татыган аксакал шагыйрь? Ресторан (аерым ишек белән булса да) кирәкми, димәкчеме әллә?..**

Х. Т у ф а н. Яңа проект миңа ошамый. Мин хәзерге республика китапханә бинасын үзебезгә сорарга тәкъдим итәм. Бер комиссия барып карасын иде аны.

**Менә сиңа мә! 4 этажлы, холлы, фойелы, конференц-заллы, бильярд бүлмәле һәм 100 урынлы ресторанлы (аерым ишек белән) шәп йортны ошатма инде. Ничек аңларга моны?**

Г.Бәширов та Х.Туфан фикерен куәтли. Яңадан бәхәсләр.

И. Г а з и. Безнең өчен бик кечкенә ул (китапханә бинасы.— *Л.Л.*). Иске. Аны үзгәртеп кора башласаң, матурлыгы да калмый, акча да күп китәчәк.

М. Ә м и р. Ни стиле, ни уңайлыгы юк. Ярамый ул безгә, иптәшләр.

Проект тавышка куела.

12 — риза, 1— каршы (Х. Туфан), 1 — бер якка да кушылмады (Г. Бәширов). (6 кеше, димәк, идарә әгъзасы булмаган.)

К а р а р  к ы л ы н д ы: Язучылар йорты проектын ярый дип кабул итәргә. Ресторан өчен урам яктан икенче ишек тә булдырырга.

**Язучылар союзы идарәсе председателе — (И. Гази)**
**Җаваплы секретарь өчен (М. Шабаев)**

## Соңгы сүз урынына

**Кыскасы шул: әлеге дүрт катлы «җәннәт сарае»н Карл Маркс һәм Комлев урамнары чатыннан көндез чыра яндырып эзләсәң дә табалмыйсың бүген. Юк ул. Булмады да. Бассейнлы сквер да, балалар кинотеатры да, әдәби музей да юк.**

**Бүгенге көндә Татарстан язучылар союзы идарәсе Комлев урамындагы 14 нче йортта урнашкан. Ул монда күптән түгел генә Бауман урамындагы 19 нчы йорттан күченде.**

**Комлев урамындагы 14 нче йорт XIX гасыр ахырында яки XX йөз башында төзелгән. Аның хуҗасы Марков-Оконищинков дигән сәүдәгәр булган.**

**«Идел» журналы редакциясе дә шушы йортта урнашкан.**

*«Идел» журналы*
*№1, 1989*

# Абайлап түгел, айлап

«Радиотоварлар» кибетендә ике сәгать ярым чамасы чират торсам тордым, вәләкин, тәки эләктердем бит аппаратның кәттәсен —видеошигърививизатор! «Юлбарыс-86-АЙ-12» маркалы. Җаның теләгән төймәсенә бас — теттереп сөйли башлый. Экранында сурәтләр пәйда була хәтта!

Сүзне озакка сузмыйча гына, әйдәгез, «январь» дип язылган төймәгә басыйк...

Хыял белән җирдән ваз кичеп
Йөргән чакта, **январь** урамында
мин кечкенә генә яз исен
тоттым!

*Роберт Әхмәтҗанов, «Январь урамында»*

...Кичкә табан
Январь бабай арган
Һәм бөкшәйгән туңып...

*Әхсән Баянов, «Январь бабай»*

Күрдегезме инде, чәтелдәтә генә минем аппарат?! Менә бусы «февраль» дигән төймә. Каяле, һава хәлләре ничек икән февральдә?

Әле язның юк бит эзе дә —
**Февраль** патша ич җир йөзендә.

*Гәрәй Рәхим, «Февраль уртасы»*

Ылысларда **февраль** аккордлары...

*Роберт Әхмәтҗанов, «Ылысларда...»*

Чабып китә буран, өерелеп,
**Февраль** бураннары артыннан.

*Роберт Миңнуллин, «Бозлар ага»*

Бармагым «март» дигән төймәне эзләп тапты...

Урманнарга шыплап март тулган...

*Разил Вәлиев, «Яз»*

Тышта март.
Аңа ничә яшь?
Кем белсен, бик карт бит ул.

*Гәрәй Рәхим, «Тышта март»*

...**Март**та туган җирем шунда белде
**Апрель**гәчә дөнья салкынын.

*Рәдиф Гатауллин, «Кал җырымда»*

Язып та күрсәтәләр инде безнең шагыйрьләр дип, эчемнән генә горурланып куйдым. Сүз дә юк — маладцы!

Хәзер «апрель»не тыңлап карыйк әле...

**Апрель** килә чынлап. Иңә таулар...

*Рәфикъ Юнысов, «Яз белән Кыш»*

Чыннан да, экранда нидер инде. Мин урындыгыма җайлабрак утырдым — кинәт, алай-болай, мин дә иңеп куймагаем!

...Килде апрель,
Тәрәзәләр чыңлап ачылды.

*Әхсән Баянов, «Сез аңларсыз мине»*

Тышта тагын **апрель** бөреләнә.

*Гәрәй Рәхим, «Тышта тагын...»*

**Апрель** ае төскә ярлы, хисләргә бай...

*Гамил Афзал, «Апрель ае...»*

Кыш китмәскә күпме тартышмасын,
Шау бөредә **апрель** иртәсе!

*Госман Садә, «Кайтып киләм...»*

Бөреләргә утлар кабызучы
**Апрель** юлда — яфрак иленнән.

*Марсель Галиев, «Март бураны»*

Апрель — шигырь язы.

*Кави Латыйп, «Апрель — шигырь язы»*

Мин ышанмыйм **апрель** чыр-чуына...

*Әхсән Баянов, «Беренче апрель»*

Тукталмадык. Борылышта
Зәңгәр **апрель** калды!

*Роберт Әхмәтҗанов, «Соңгы рейс»*

«Май» төймәсенә басуым булды — авызым колакларыма кадәр ерылды...

**Май** башында кызлар ачылалар...

*Марс Шабаев, «Май кызлары»*

Шулчак башыма җүләр сорау килде: «Ә кайчан ябылалар? Май ахырында штули?»

Хәзер **май**. Җирдә яшеллек.

*Равил Фәйзуллин, «Көн шыксыз дип...»*

Инде **май**! Ә яшь шомыртлар
Курка чәчәк атарга!

*Роберт Миңнуллин, «Җимеш булмаган шомырт чәчәге»*

«Да-а-а-а!» дип суздым мин һәм «июнь» төймәсенә төрттем...

Җиргә тагын көләч **июнь** инде.
*Гәрәй Рәхим, «Җиргә тагын...»*

Җилләп керде **июнь** басудан...
*Харрас Әюпов, «Арыш кыры»*

Күз яшьләрен миңа хәтерләтә
Таңда янган июнь чыклары.
*Рәшит Гәрәй, «Таңда төшкән июнь чыклары»*

Җир шундый яшь! Җирдә **июнь** тора.
*Роберт Әхмәтҗанов, «Иртән...»*

Шуннан соң июльнең хәл-әхвәлен беләсем килде...

— **Май**,— дидем мин. Ә син **июль** икән.
*Рәдиф Гатауллин, «Шулай тиеш идеме...»*

**Август**ка чират җитте:

...Төяп олау-олау кибәннәрен,
Керде **Август** яшел болынга...
*Фәннур Сафин, «Болын»*

Ашыктыра **август** игенчене...
*Әхмәт Рәшитов, «Август»*

**Август** — спортсмен.
Бронза тәне
Сузылып ята әнә комлыкта...
*Марс Шабаев, «Август»*

Ятты **август** болыт түшәгенә,
Сары чәче төште коелып...
*Әхмәт Гадел, «Ятты август...»*

Бакча-кырда **август** ята,
Котылыр тиздән, гүя баладан...
*Әхсән Баянов, «Бер сәбәпсез...»*

«Аязучан болытлы һава...» кайсы айда булыр икән соң инде?

Котылган ана баладан:
**Сентябрь** — көзгә басу...
*Әхсән Баянов, «Сентябрь»*

...**Сентябрь** — җәйнең картлыгы.
*Ренат Харис, «Сентябрь»*

...**Сентябрь**— табигатьнең Яңа елы...
*Роберт Әхмәтҗанов, «Гөмбә чоры»*

Байрак чөя болытларга кадәр
Яшьлегемнең иле —
**Сентябрь.**
*Зөлфәт, «Сентябрь панорамасы».*

Берьялгызым керәм **Сентябрь**гә...
*Эдуард Мостафин, «Бер ялгызым керәм...»*

Сары нуры белән җилкендереп,
Тәрәзәмә кунды **сентябрь**...
*Мөхәммәт Шәйхи, «Соңгы нуры белән...»*

Сыгылып елый **Сентябрь**...
Елаудан ни файда?
*Роберт Миңнуллин, «Белмәсен Агыйделең...»*

Юк, булмады бу «Аязучан болытлы һава»! Бөтен ышаныч октябрьдә!

...**Октябрьдә** манма чыланып мин,
Эзләп йөрим **июль** яңгырын...
*Разил Вәлиев, «Яңгыр иде»*

...**Октябрь**нең кайнар сулышы өргән
Язмышына безнең нәселнең.
*Рәшит Гәрәй, «Басуларны күреп сөендем»*

Кабаланып «ноябрь» төймәсенә бастым. Юк, эшләми. Кинәт видеошигъривизатор экранында «Азапланма, туган, бу төймә ватык!» дигән язу йөгерде.

Әйтәм бит, ватык аппарат биргәннәр кибеттә! Менә «декабрь» төймәсенә генә басып карыйм да, вәссәлам — кире илтеп бирәм... Үзләренә булсын...

Сәхнә — ачык. Түргә таба уза
**Декабрь**нең коры салкыны...
*Марсель Галиев, «Ул уйнаган рояль»*

Мин туганмын карлы **декабрь**нең
Буран котырып торган мәлендә.
*Әхсән Баянов, «Мин туганмын...»*

...инде **декабрь** бит, ничек алар
Аягүрә басып калганнар?!
*Гәрәй Рәхим, «Кылганнар»*

Ботинкамның моңсу җырын
Тыңлап ята **декабрь.**
*Ләбиб Лерон, «Җир — шыгырдап торган идән...»*

Ә-ә-ә?!

Әлеге шигъри юлларны һәм исем-фамилиямне ишеткәч сискәнеп киттем. Күзләрем видеошигъривизатор экраны кадәр булып ачылды.

*1986*

# Кул болгадым поездларга

...Син киттең. Поездда. Мин, кул болгап, озатып калдым. Хәзер менә, Тукай әйтмешли, эч поша, яна йөрәк... Җитмәсә, янган йөрәккә керәчин сипкәндәй, күңелгә шигъри юллар килеп кенә тора...

...Соңгы өметләрем синең белән
Яшел вагоннарда китәләр.

*Әмир Мәхмудов, «Соңгы поездлар»*

...Авыр сулап куйды синең поезд,
Шапылдатып япты ишекләрен...
...Сине алып киткән иске поезд
Яшел түгел иде ни өчендер...

*Роберт Миңнуллин, «Авыр сулап...»*

Поезд китте. Күзнең күрешеннән
Ара инде киңрәк, ераграк.
Караңгылык: «Аердылар!» — диде.

*Әхсән Баянов, «Аерылышу»*

Торган саен моңсулана бара...
...үткән поездларның
Борылмада югалулары...

*Равил Фәйзуллин, «Тау төшү»*

...Поездларны юлга күп озаттым,
Тик берсен дә каршы алмадым.

*Разил Вәлиев, «Рельслар»*

...Поезд ыргыла,
Вакыт эченә, киңлек эченә кисеп,
ярып керә.

*Рөстәм Мингалим, «Борчулы минутта»*

Шул вакыт, үзем дә сизмәстән, Такташның «Үтеп барышлый» шигырен сөйләп җибәрдем:

Поезд ыргый таныш урманнардан,
Тәгәрмәчләр шаулап баралар...

Кешеләр сәерсенеп миңа карыйлар. Ә минем аларга исем дә китми. Кайчандыр колакка кереп калган шигъри юлларны борчак урынына сибәм генә!

...Сөюнең соңгы поезды
Җыенган кузгалырга.

*Роберт Миңнуллин, «Сөюнең соңгы поезды»*

Китә поезд, китә моңсу гудок биреп,
Китә ерак, якты офыкларга кереп.

*Зөлфәт, «Күзге учакларда...»*

...Урман аша узган поездларның
Гудоклары никтер моңсулар.

*Рәшит Гәрәй, «Урман аша уза поездлар»*

...Кинәт миңа карап тамаша кылып торган халык арасыннан колгадай бер адәм атылып чыкты да каршыма килеп басты.

— Ибдәш, җитте! — диде ул, гудоктай тавышын бөереннән чыгарып. —Уйнама халык нервысында. Сүләмә шул поезд турасында. Монда поезд көтеп куна-төнә ятучылар вагон-вагон. Сыртыңны каезларга күп сорамабыз, понимаешь! Әгәренки тагын сүлисең икән... менә бу йодрыкка үпкәләмә, җарыймы?

— Исем китте инде бик. Ай, куркыттың! — дигән булдым мин. Шулай да бер як читкә киттем. Халык таралды. Шулчак мин сине искә төшердем. Тагын эч поша башлады. Тагын сине алып киткән поездны күз алдыма китердем... Ул да булмады, янә кычкырып шигырьләр сөйли башладым:

...Шпалларны кысып,
Поезд үтә...
...Вагон тәрәзәсеннән тел күрсәтеп,
Малайлар үтә...

*Рөстәм Мингалим, «Шпаллар»*

...Поезд үтә, араларны бүлеп,
Яшел елан кебек сузылып.

*Марсель Галиев, «Борылышларда...»*

Тоннельдә бер үптең!
Поезд, һай, тиз үтте...

*Равил Фәйзуллин, «Тоннельдә...»*

...Очар коштай поезд чаба,
кырлар буйлап.

*Булат Сөләйманов, «Кырлар буйлап»*

...Поезд чаба, ыргый алга,
Ачык аңа яшел урам.

*Лена Шакирҗанова, «Яшел урам»*

...Поезд чаба. Арчаларны
Җилдәй узып китәбез.

*Газинур Моратов, «Поездда»*

Әкияттәге кебек поезд чаба,
Уйлар чаба поезд алдыннан.

*Әхмәт Гадел, «Арча поезды»*

Тукта әле, тукта тик беразга,
Әгерҗе поезды!

*Рәдиф Гатауллин, «Әгерҗе поезды»*

Атта түгел,
Мин поездда чабам,
Картлыгымнан гүя качып барам...

*Нури Арсланов, «Барнаулга»*

— Туктыйсыңмы, юкмы син, канса канис!

Дерт итеп киттем. Әпәйт теге Колга икән. Йодрыгын минем баш тирәсендә биетә.

— Соң син, ибдәш, колакка катырак мәллә? Үзебезчә әйттем ләбаса мин сиңа. Җитте, дидем! Әллә син үзем генә беләм дип уйлыйсыңмы ул поезд турындагыларны. Мин дә беләм аны. Мин дә сүли алам аны,— диде дә ул сөйли башлады:

...Кайвакыт төн буе поездда
Үтәли тишеп төн карасын
Йокламый уйланып-күзәтеп
Барасың, барасың, барасың...

*Рифгат Закиров, «Кайвакыт...»*

Колга туктады, мин сөйли башладым:

...«Очрашу» дигән поезд килмәде,
Куганнар аны тупикка.

*Зөлфәт, «Сентябрь панорамасы»*

Әле генә минем белән әрепләшкән Колга, канатланып, шигырь сөйләвен дәвам иттерде:

...Маңгайдагы рельслар буйлап,
миемне изеп,
хәсрәт поездларның
арлы-бирле йөрүе
гаҗәп түгел.

*Равил Фәйзуллин, «Әгәр әле...»*

— Шәп дуэт булып чыкты әле бу! — диде Колга һәм шигъри дилбегәне миңа тоттырды:

Шигъри моң кайный күңелдә,
Поезд гүя шигырь яза.

*Әмир Мәхмүдов, «Уртак язмыш»*

Ул арада каяндыр кәтүктәй бер кеше килеп чыкты да нечкә тавыш белән чәтелдәде:

Тол атадай бераз бөкерәеп,
Күзгә керә талган поездым.

*Эдуард Мостафин, «Башка язлар эзләп барышлый»*

Колга аңа сөзеп кенә карап алды да Марсель Галиевнең «Ераклык һәм вакыт ярыннан» дигән шигырен укырга кереште:

...Поезд туктый. Бар да төшә гүя
Ераклык һәм вакыт ярыннан...

Сөйләргә минем чират дип, авызымны гына ачкан идем, өлгермәдем, Кәтүк янә чәтелдәде:

...Поезд килеп туктауга,
Елмая сиңа чуваш.

*Кави Латыйп, «Олы юлда бер шәһәр бар»*

Бу юлы мин Зөлфәтнең «Мәхәббәт» шигырен сөйләргә тотындым:

...Төнге поезд. Пассажирлар йоклый...
Йокы бирми миңа бер агай...

Шигырьне Колга күтәреп алды:

Дүрт аю мин алдым, энекәем,
Гәрчә үзем... болай... сулагай!

Колганы Кәтүк бүлдерде:

Мин — простой!
Шигырь-мазар язмыйм...

Кызып-кызып шигырь сөйләгән Колга белән Кәтүккә карап: «Поездга соңга калуларын миннән генә күрерләр»,— дип уйладым да болар янынннан тизрәк таю ягын карадым.

...Куучы-мазар юк микән, дип, артыма борылып караган идем, шулчак келт итеп син искә төштең...

Әйе, син киттең. Поездда...

*1986*

# Суда йөзаласыңмы?

Әдәбият белән «җенләнә» башладым бит, әй! Хәтта бер әкәмәт аппарат та әмәлләп ташладым. Исеме дә җисеменә туры килеп кенә тора: «Фокус!»

...«Фокус»ның бер бәләкәй генә төймәсенә бастым. Аппарат суыткыч кебек дерелдәп алды да сөйли башлады:

— Тыңлагыз! Сезне китап исемнәре белән таныштырам: «Гөлләр су сорый» (1966), «Каен суы» (1972), «Ут һәм су» (1973), «Су башы» (1975), «Кар сулары»(1975), «Бер йотым су» (1980), «Су хикәяте» (1981), «Йөз суы» (1983), «Су өстендә чәчәкләр» (1984),»Идел суы — илле батман» (1984)...

— Җитте! — дидем мин һәм икенче төймәгә бастым. Аппаратым тагын китап исемнәре санарга керешмәсенме!

— «Туган як моңнары» (1971), «Моңнарым» (1978), «Ташлар моңы» (1978), «Язлар моңы» (1982), «Якты моң» (1983), «Шахтер моңы» (1983), «Еллар һәм моңнар» (1984), «Таныш моң» (1984), «Төсле моң» (1985)...

— «Фокус»каем,— дидем мин, аппаратымны янә туктатып.— Күңелгә ятышлырак бүтән китап исемнәре юкмыни соң, ичмасам...

— Ә кәкже, бар. Пажалысты! — диде «Фокус» һәм әйттерергә тотынды:

— «Күңел күзе белән» (1962), «Үрләргә күңелем гашыйк» (1968), «Син безнең күңелләрдә» (1969), «Күңел ташлары» (1970), «Сиңа тартыла күңел» (1970), «Күңел кыңгыраулары» (1971), «Күңел йомгагы» (1971), «Күңел күзе» (1972), «Ихлас күңелдән» (1980), «Дуслар күңеле» (1980), «Яшьләр күңеле» (1981), «Мөлдерәмә күңел» (1982)...

Тыңлый-тыңлый үземнең дә күңел тулып китте.

— Булды, җаныкаем,— дидем һәм каушый-каушый өченче төймәгә бастым...

«Фокус»ым хәлләремне аңлады бугай, бу юлы шигырь юллары тезә башлады:

Аэропорт — һава порты, сагыш йорты...
...Аэропорт — шатлык йорты, кавышу йорты!

*Рәфикъ Юнысов, «Һава юлы»*

Кешеләрнең йөрәгеннән күчкән, ахры, монда ут,
Ерак җисемнәргә карап, күзен кыса аэропорт.

*Әмир Мәхмүдов, «Аэропорт»*

Аэродром иде безнең урам:
Казлар күтәрелде каңгылдап.

*Рөстәм Мингалим, «Авылдашка хат»*

Мин ямь-яшел аэропортка
Акчарлак булып кунам...

*Роберт Миңнуллин, «Актаныш аэропорты»*

...Саргылт чәчле Роберт
аэродромда аны
Бүтән мәңге каршы алмас.

*Равил Фәйзуллин, «Самолетта. Биеклек — 8000 м»*

Самолетта очам, самолетта —
Мин дә менә күккә мендем бит!
Ут кабызган аэропортлар кебек,
Бар йолдызлар тора тезелеп.

*Разил Вәлиев, «Самолетта»*

Самолет уты күкләрдә
Бик тансык утлар икән...

*Зәки Нури, «Аэропортта»*

Утлар янган кичке аэропортта
Галәмнәргә ашар хисләр туа...

*Гамил Афзал, «Бөгелмә аэропортында»*

Монда хозур!
Аста...
...Әй самолет, төшер мине җиргә —
Аязсыннар күңел күкләрем.

*Әхмәт Рәшитов, «Ил-18, биеклек — 7000 м»*

Очучы дус, беләм, күк тә зәңгәр,
Син сөясең биек киңлекне.
Тик шулай да әллә, җиргә төшеп,
Чирәмендә аунап меникме?!

*Рәшит Гәрәй, «Пропеллер тавышы астында»*

Очучы дус,
Тизрәк борыл,
Үзем сикермәс борын!

*Роберт Миңнуллин, «Казан өстеннән очканда»*

— Җитеп торыр,— дип туктаттым «Фокус»ны.— Юкса шагыйрьләр, самолеттан сикереп, кул яки аяк шәрифләрен имгәтеп-нитеп куймагайлары... Ни белән язарлар аннары?

...Кинәт «Фокус» әллә нишләде. Дөбер-шатыр килде дә күреге ертылган гармун кебек тынып калды. Тегеләй әйләндереп карадым, болай иттем — юк, эшләми һәм вәссәлам. Ничек рәткә кертергә моны дип, бик озак баш кашып тордым-тордым да, йодрыгымны йомарлап, аппаратка берне ордым. «Фокус» йокысыннан яман төш күреп уянган кеше шикелле үрсәләнә-үрсәләнә сөйләргә кереште:

Йодрык сугар өчен йомарлана! —
Һәм сугар ул төптән каерып.

*Зөлфәт, «Йодрык»*

Яңа дәлил, яңа төшенчәләр
Маңгаена сукты Абсолютның.
Сукты Галилейлар үчен алып,
Коперниклар сүзен хаклап сукты...

*Әхмәт Рәшитов, «Йолдыз вакыты»*

...Беренче ир сугалмады: сулга алды.

*Ләис Зөлкарнәев, «Бүре сугу»*

...Каерылып сукты, кизәнеп
Чаңга түгел,
Җанга сукты язмыш —
Өлгермәгән әле төзәлеп.

*Харрас Әюпов, «Иске чаң»*

Йомылды күз. Ә йодрык калды,
Ә йодрык калды сугарга.

*Газинур Моратов, «Нәфрәт турында җыр»*

Рифма белән мин рифмага суктым —
Чәчрәп керде сүзгә кара кан...

*Ренат Харис, «Кара таракан»*

Йодрык белән сугып, диварларын
Сеңдерермен кебек җиргә мин.

*Гәрәй Рәхим, «Этәчләнү»*

Без сугабыз бик күп кануннарга,
Алар кайтып безгә кире суга!..

*Нияз Акмалов, «Сират күпере»*

...Ә йодрык тагын күтәрелде...
Байрон булып сукты яңагына
Леди-политиканның...

*Газинур Моратов, «Нәфрәт турында җыр»*

Ирләр суга. Хатын — түзә ул...

*Зөлфәт, «Мәхәббәт»*

...Шуннан соң мин «Фокус»ымны сугып та, кыйнап та туктата алмадым. Сөйләде дә сөйләде ул...

# Кәҗә-Кәҗәләй

*(Өлкәннәр өчен әкият)*

## Мемуар

Көннәрдән бер көнне Кәҗә-Кәҗәләй истәлек язарга утырды. Иң элек ул «Кәҗә белән сарык» дигән мәгълүм әкияттә үзенең зур роль уйнавы хакында әйтеп үтте. Аннан соң ул шул ук әкияттәге кайбер төгәлсезлекләргә тукталды, ягъни капчыкта унике генә бүре булмавын, ә бәлки егерме ике арыслан башы да булуын ассызыклап әйтүне кирәк санады. «Сарык чыннан да аңгыра иде»,— дип, әкияттә язылганнар белән килешкәнлеген белдерде. Шуның өстенә ул: «Сарык чирләшкә иде, шизофрения белән еш авырый иде»,— дип, сарыкны бик якыннан белүенә янә бер ишарә ясап алды. «Яшь чакта мин бокс, самбо, дзю-доише спорт төрләре белән шөгыльләнә идем, кайбер мактау кәгазьләремне әле дә күз карасыдай саклыйм» дип, спортка булган мәхәббәтен дә кәгазьгә төшерде. «Мин әле бүген дә, курыкмыйча, капчыктан егерме ике арыслан тартып чыгара алам, ләкин, кызганыч, безнең якларда арысланнар юк...» дип тәмамлады ул истәлеген...

Нәшриятта аның истәлекләрен укып чыгарга теләүчеләр бик күп булмаса да, ниһаять, берәү табылды. Истәлекләренең язмышы белән кызыксынып йөз дә беренче мәртәбә килгәч, әлеге шул Берәү аңа үз фикерләрен җиткерде.

— Хөрмәтле Кәҗә-Кәҗәләй иптәш,— диде әнә шул Берәү,— романыгызны игътибар белән укып чыктым, һәм дөресен әйтергә тиешмен: бик җитди темага тотынгансыз. Бездә бу темага язучылар бар, әлбәттә, кайберәүләр китап итеп бастырып чыгару бәхетенә дә иреште. Әмма дә ләкин сезнең роман шәп! Дөрес, тел кытыршылыклары, конфликтның, шулай ук сюжетның бөтенләй булмавы, әсәрнең идеясезлеге, автор сөйләме һәм персонажлар теленең аерылгысыз булуы романның дәрәҗәсен бераз төшерә төшерүен... Әмма сезнең аңа карап кәефегез кырылмасын! Безнең күпчелек язучыларыбыз да андый җитешсезлекләрдән арынып бетә алмыйлар...

— Мин бит истәлекләр язган идем,— диде, ниһаять, Кәҗә-Кәҗәләй һәм эченнән генә «Роман язасым калган аны» дип уйлап куйды.

— Истәлекләр?! Бигрәк тә әйбәт. Китерегез. Укырбыз. Сөйләшербез. Ә хәзергә... кем иптәш... сау булыгыз! Аң-

лыйсыздыр инде, муеннан эш! — диде дә әлеге шул Бераү, үз дөньясына чумды...

Кәҗә-Кәҗәләй, истәлекләрен сорап алырга да онытып, Бераү бүлмәсеннән чыгып китте. Өйгә кайткач, канатланып, автобиографик роман язарга утырды. Бераздан кәгазьгә бер-бер артлы сүзләр тезелә башлады: «Мин туганда ук сакаллы булганмын...»

## Телевизор

Гөнаһ шомлыгына каршы дигәндәй, Кәҗә-Кәҗәләйнең телевизоры ватылды. Шул ук көнне Кәҗә-Кәҗәләй өенә мастер чакыртты. Мастер дигәне озак көттермәде, ай ярым-ике ай эчендә балкып килеп тә җитте. Кәҗә-Кәҗәләй аны, зур кунак каршылагандай, кочак җәеп каршылады. Мастер телевизор тирәсендә кайнашкан арада, өстәлгә тегесен-бусын хәстәрләп куйды...

— Бик кирәкле лампочкасы янган,— диде мастер.— Ике унлыксыз төзәтеп булмас моны...

Кәҗә-Кәҗәләй, кабаланып, кулын түш кесәсенә тыккан гына иде, шулчак, үзендә гомердә акча булмаганлыгын исенә төшерде...

Мастер да шыр надан икән: соң, кәҗәдә кайчан акча булганы бар инде, ә?

## Диңгез кәбестәсе

Түзмәде Кәҗә-Кәҗәләй — чыгырыннан чыкты.

— Нәрсә бу? — дип кычкырды хатынына.

— Нәрсә булсын, күрмисеңмени, кәбестә бөккәне! — диде хатын, бер дә исе китмичә генә.

— Бөккән икәнен күреп торам мин аның, күз чыкмаган! Нишләп тагын кәбестә? — дип чәпчеде Кәҗә-Кәҗәләй.— Кичә булды кичә, өшегән кәбестә салаты ашаттың! Өченче көн сыек кәбестә шулпасы... Инде бүген тагын кәбестә! Маемлатып үтерәсең бит инде!

— Нишлим соң? Бүтән бернәрсәбез дә юк бит! — диде хатыны.

— Тап! — дип ярсыды Кәҗә-Кәҗәләй.— Теләсә каян тап! Хет берәрсеннән бурычка алып тор! Кыямәт көнне кайтарып бирербез, диген!

...Кәҗә-Кәҗәләйнең хатыны кибет мөдире булып эшләүче бер ахирәтеннән сигез диңгез кәбестәсе консервасы алып кайтты. И кинәнде соң Кәҗә-Кәҗәләй: ярты сәгать тә үтмәгәндер, сигез консерваның сигезен дә ялтыратып куйды. Рәхәтләнеп бер кикергәч, тук елмаеп,

хатынының биленнән кочып алгандай итте. Укылмаган гәҗитләрен алып, диванга гына сузылган иде, кинәт хәле мөшкелләнүен сизде...

Җиденче тапкырын һава суларга дип чыгып чапкан Кәҗә-Кәҗәләйгә карап, хатыны үз-үзенә әйтә куйды:

— Эт эченә сары май килешми шу-у-ул...

## Сакал

Кул куйдырттырырга дип алып кергән кәгазьләрен Сарык Үгезнең өстәленә җайлап куйды да иелә төшеп пышылдады:

— Үгез Мөгезович, ишеткәнсездер инде, шәт, Кәҗә-Кәҗәләйнең сакалы агара башлаган. «Озакламый аксакал булам»,— дип әйтә ди Кәҗә-Кәҗәләй...

Үгезнең йөзе бурлаттай кызарды.

— Кемнән ишеттең? — диде ул.

— Хайваннар сөйли,— дип җавап бирде Сарык.

Алдындагы барлык кәгазьләргә дә «Рөхсәт итмәскә!» дип язып, имзасын сырлагач, Үгез авторучкасын өстәлгә атып бәрде.

— Хәзер үк минем кәбиниттә булсын! Әйт үзенә! — дип кычкырды ул.

— Хәзер әйтәм... Хәзер әйтәм, Үгез Мөгезович...— диде Сарык һәм Үгез кул куйган кәгазьләрне папкасына салды да башын ия-ия, бөгелә-сыгыла арты белән ишектән чыгып китте...

Ике минут та үтмәгәндер, каушаган Кәҗә-Кәҗәләй, кулъяулыгы белән маңгаен сөртештергәләп, Үгез каршында басып тора иде инде. Шактый озакка сузылган тынлыктан соң, бүлмәдә Үгезнең көр тавышы яңгырады:

— Кәҗә-Кәҗәләй, синең сакалың миңа ошамый башлады,— диде ул, башын күтәрмичә генә, һәм түгәрәкләр-өчпочмаклар белән чуарланган кәгазьгә квадратлар төшерә башлады.

— Гафу итә күрегез инде, Үгез Мөгезович,— диде Кәҗә-Кәҗәләй,— парикмахерскаяга барырга вакыт булмыйчарак торды. Эш тә эш... Аннан соң квартал ахыры дигәндәй...

— Анда минем эшем юк. Бүген үк сакалың кырылган булсын! — диде Үгез.

— Ничек инде, Үгез Мөгезович, сакалсыз кәҗә була димени? — диде Кәҗә-Кәҗәләй күзләрен челт-челт йомгалап.

— Анда минем эшем юк! — дип кабатлады Үгез.— Әйткәнне үтә!

— Үгез Мөгезович...

— Карале, мур кыргыры, син бик тискәре икәнсең! — диде Үгез.— Болай булса, эштән статья белән очуың бар...

— Бүген үк... хәзер үк... Үгез Мөгезович... сакалны кырам,— диде тәмам куркып калган Кәҗә-Кәҗәләй.

Үгез син азат дигән ишарә ясап, тоягы белән ишек тарафына ымлады... Кара кайгыга баткан Кәҗә-Кәҗәләй башына бер җүнле фикер килми азапланды. «Сакалны кырмасам, Үгез бетерәчәк, кырсам, хатын алдында дәрәҗә төшәчәк» дип уйлады ул. «Нишләргә инде?» дип аптырап торганда, бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына дигәндәй, Кәҗә-Кәҗәләй бер таныш артистын исенә төшерде. Һәм «Коткарса, ул гына коткарачак!» дип, эш вакыты тәмамлануга, аның янына чапты...

Артист артист инде, шундук җаен тапты. Грим салучылар, Кәҗә-Кәҗәләй аңына килгәнче, тиз генә аның сакалын кырып ташладылар да шоп-шома иягенә ясалма сакал ябыштырып та куйдылар.

— Нишләргә икәнен хәзер үзең дә төшенгәнсеңдер инде, Кәҗә-Кәҗәләй дус,— дип елмайды Артист.

Кәҗә-Кәҗәләй ул хәтле үк җүләр түгел иде — төшенде. Шул көннән башлап, Кәҗә-Кәҗәләй эшкә сакалсыз килде һәм эштән сакал белән кайта торган булды.

## Кәҗә тоягы

— Күрмәгәнеңне күрсәтәм бит хәзер, Бәти актыгы! — дип кычкырды Кәҗә-Кәҗәләй.

Бәти актыгы дигәне — күрше Кәҗәлетдиннең төпчеге иде. Шул Бәти актыгы көпә-көндез дип тормаган, Кәҗә-Кәҗәләйнең кәбестә бакчасына кергән. Нигә кергәне билгеле инде — кәбестәгә!

— Валлаһи, дип әйтәм, күрмәгәнеңне күрсәтәм! — дип, җикеренә-җикеренә, аның артыннан чапты Кәҗә-Кәҗәләй. Кәбестә бакчасын аркылыга-буйга иңләп пырдымсыз рәвештә чапкан Бәти актыгы кинәт туктап калды: «Кызык, нәрсә күрсәтмәкче була икән бу миңа?» — дип уйлап алды ул. Шулай дип уйлап кына калмады, янында еш-еш сулыш алып торган Кәҗә-Кәҗәләйгә әйтте дә:

— Кызык, нәрсә күрсәтмәкче буласыз инде сез миңа, Кәҗә-Кәҗәләй абзый?

— Күрмәгәнеңне бик күрәсең киләмени, Бәти актыгы? Хәзер күрсәтәм, хәзер! — диде дә Кәҗә-Кәҗәләй, Бәти актыгының йомшак җиренә тояк белән китереп торып төртте. Бәти актыгы ярты сәгатьтән соң гына аңына килде. Ләкин күпме генә тырышса да, Кәҗә-Кәҗәләй-

нең ни күрсәткәнен хәтеренә төшерә алмады. «Алдады ул мине, карт тәре!» дип уйлады ул соңыннан.

Юк, Кәҗә-Кәҗәләй аны алдамады: күрмәгәнен күрсәтте. Кәҗә тоягы — нәкъ шул үзе иде бит инде.

## Мики-ки-ки!

Беркөнне Кәҗә-Кәҗәләй радиодан ишетте: ниндидер бер кәҗә туксан сигез телдә сөйләшә белә икән. Шушы хәбәрдән соң Кәҗә-Кәҗәләйнең төн йокылары качты. Силос тәме килеп торган кәбестәне чәйни алмый азапланды, чәйнәгәнен йота алмый интекте. Соңгы араларда шактый мантый башлаган Кәҗә-Кәҗәләй күзгә күренеп ябыкты — акшарлы мичкә сөяп куелган кисәү таягына әйләнде дә калды. Эшләр болай мөшкелләнсә, Хуҗа Насретдин ишәге кебек җан тәслим кылуың да бар. Шулай да Кәҗә-Кәҗәләй соңгы чиккә җиттем инде дигәндә генә үзен кулга алып өлгерде. «Мин кемнән ким?! Нишләп әле мин дә башка кәҗәләр телен өйрәнмим? Мин булдыра алмыйм мәллә аны?» дип уйлады ул.

Кәҗә-Кәҗәләй, җиң сызганып, чит телләр өйрәнергә керешти. Иң элек ул җирән сакаллы кәҗәләр телен үзләштерде. «Бу телне мин чәйнәп кенә йоттым»,— дип мактанганнан соң, Кәҗә-Кәҗәләй мыштым кәҗәләр телен өйрәнә башлады. Телнең бусы өйрәнү өчен бераз авыррак булып чыкты. Кәҗә-Кәҗәләй «микокукио» сүзен әйтә алмыйча интекте. Бу сүзне аңа, һичшиксез, өйрәнергә кирәк иде. Чөнки бу сүз исәнләшүне аңлаткан сүз иде. «Микокукио» — безнеңчә «Сәлам, аңгыра сакал!» дигән сүз.

Шуннан соң Кәҗә-Кәҗәләй сөзгәк тау кәҗәләре телен, иркен кыр кәҗәләре телен һәм тагын бик күп, бик күп кәҗәләрнең телен өйрәнде.

Хәзер Кәҗә-Кәҗәләй бик тырышып үз телендә сөйләшергә өйрәнә, дөресрәге, азаплана. Шактый интегә торгач, бер сүзне әйтергә өйрәнде Кәҗә-Кәҗәләй. Ул сүз «Мики-ки-ки» иде.

*1989*

# Эчтәлек

*I бүлек.* **Ике кыйсса, ике пьеса**


Шайтан шаяруы . . . . . . . . . . 6
Бәллүр төн . . . . . . . . . . 56
Җүләр малайның әтисе . . . . . . . . . . 83
Коры куык . . . . . . . . . . 127


*II бүлек.* **Әп-че-хи!-хи-хи...**


Кызыл бәдрәф . . . . . . . . . . 156
Алтын күкәй . . . . . . . . . . 167
Уеннан уймак . . . . . . . . . . 183
Әчтерхан чикләвеге . . . . . . . . . . 195
Портрет . . . . . . . . . . 205
Кыек Мәтәште гүзәле . . . . . . . . . . 208
Мин президент булгач... . . . . . . . . . . 212
Караңгы авыл вакыйгасы . . . . . . . . . . 216
Токмачлы якшәмбе . . . . . . . . . . 219
Нострадамус II фаразлары . . . . . . . . . . 221
Медаль . . . . . . . . . . 224
Мин ничек Ысталинны кунак иттем . . . . . . . . . . 228
Биләмче карчык . . . . . . . . . . 232
Ярдәм итегез, иптәш язучылар! . . . . . . . . . . 235
Скелет . . . . . . . . . . 239
Шундый кеше инде мин . . . . . . . . . . 241
Юк-юк, агай-эне!.. . . . . . . . . . . 243
Кырыктан соң — шырыкка (түгел) . . . . . . . . . . 244
Черек алма . . . . . . . . . . 246
Яшәсен безнең партия! . . . . . . . . . . 247
Башыма тай типмәгән . . . . . . . . . . 248
Кояшлы әсәр . . . . . . . . . . 249
Гаилә низагы . . . . . . . . . . 251
Мәхәббәт романы . . . . . . . . . . 251
Яфрак турында указ . . . . . . . . . . 252
Терелəй алырга . . . . . . . . . . 253
Котлау . . . . . . . . . . 254
Алдый белмисең, быр-рат!.. . . . . . . . . . . 255
Берлек . . . . . . . . . . 255


*III бүлек.* **Әгъләмисина**


Мөдәррис Әгъләмгә . . . . . . . . . . 258
Мәгарәдән хат . . . . . . . . . . 258
Мөдәррис Әгъләмгә . . . . . . . . . . 259
Әгъләм юбилее . . . . . . . . . . 259
Мөдәррис рәис булгач... . . . . . . . . . . 262
Космодром һәм сессия, космонавт Әгъләм . . . . . . . . . . 267

Метро һәм сессия янә Әгъләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 271
Фатир, сессия һәм янә Әгъләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 277
Шагыйрь, илле тәңкә һәм ...тәнкыйтьче . . . . . . . . . . . . . 284
Әңгәмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 286
Әзмәвер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 286
«Он со мной...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 287
Кайда эләгәсең бит! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 288
Төтен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 288
Татарлар бөтенесе дә бөек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 288
Катмый әле... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 289
Кәләш яки «Наполеон» коньягы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 289
Тәрәзә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 289

## *IV бүлек.* **Һәйбәт гайбәтләр**

Мин сөйләем, син тыңлама... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292
Коммунист та кеше ләбаса . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 295
Мәтәштерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 298
Саклык кассасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 304
Вакыйфның күргәннәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 305
Ленин... тирләгән маңгаен сөртә . . . . . . . . . . . . . . . . . 308
Нарасый бәһасе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 309
Кабарган букча . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 309
Шәмсия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 311
«Әйе» сүзе күпме тора? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 312
Бәдрәф... Туалетов? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 313
Шигъриятебез көчләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 313
Хәерле кич! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 314
Телсез шаһит . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 316
Телефон . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 317
Депутат таныклыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 319
Безработный . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 320
Аңлашыла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 321

## *V бүлек.* **Кайбер әйберләр**

Имеш... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
Киңәш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
Балыкчы Галләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
Кайсыгыз минем әти? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
Ирне ир итим дисәң... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 323
Һәр хатын алтын булмас... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 323
Кияүгә чыгу галәмәтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 324
Игълан тактасында ни булмас... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 324
Анадан тума җөмләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 326
Ашыгыз тәмле булсын! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 327
Чыктым аркылы күпер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 328
Туңкайган әфлисун . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
Һавадагы торнага... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 330
Абайлап түгел, айлап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 334
Кул болгадым поездларга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 338
Суда йөзаласыңмы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 342
Кәҗә-Кәҗәләй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 345

Литературно-художественное издание

*(Лябиб Лерон)*
*Леронов Лемон Леронович*

# Шиворот на выворот

(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Ф.Я.Мулллахмәтов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.З.Шиһапова, Г.Г.Гарифуллина, Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 17.12.2004. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 18,48 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 19,74.
Нәшер-хисап табагы 18,63 + форз. 0,36.
Тиражы 3000. Заказ Э-953.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.